

# Равиль Файзуллин

Избранные произведения

В шести томах

Том 4

*Литературно-публицистические статьи*

КАЗАНЬ • ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • 2005



# Равил Фәйзуллин

## Сайланма әсәрләр

Алты томда

4 том

*Әдәби-публицистик*
*мәкаләләр*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2005

УДК 821.512.145
ББК 84(2Рос=Тат)
Ф91

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин,
И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов,
Р.Х.Корбанов*

**Фәйзуллин Р.Г.**

Ф91 Сайланма әсәрләр: 6 т./Равил Фәйзуллин. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.

ISBN 5-298-04201-5

4 т.: Әдәби-публицистик мәкаләләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 415 б.

ISBN 5-298-03904-9

ISBN 5-298-03904-9 (4 т.)
ISBN 5-298-04201-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Фәйзуллин Р.Г., 2005



# *Ватан була бер генә!*





# ЯҢА МЕҢЬЕЛЛЫККА КҮЧКӘНДӘ

## 1.КОЯШ АСТЫНДА БЕЗ ДӘ БАР

Булсаң икән ул бер Ташбалбал да, җиргә береккән килеш утыр икән Җил-Вакыт дигәннәренә исең дә китмичә. Үтсен еллар, үтсен гасырлар, ә син, мәңгелеккә каккан казык кебек, битараф рәхәтлектә оеп утырасың... Бакый гомер җил-яңгырларның сыйпап иркәләүләре туйдыргач, бермәл нинди дер илаһи кодрәт белән җанланасың, кызык өчен генә булса да бу Күк гөмбәзе астында, Ай-Кояш яктысында Адәм балаларының мәш килеп ниләр майтарып ятканына күз саласың... Әһә, Дөнья дигән Яшәү Үзәнендә эшләр болайрак икән... Карыйсың-күрәсең, аңлыйсың-беләсең дә, янәдән Ташбалбалга әвереләсең. Күпмедер ел-гасырлар үткәч, тагын бер җанланып, Тормыш дигәннәренә янә күз салып, үзеңчә анализ-нәтиҗә ясыйсың...



*Борынгы кыпчак далаларында сакланып калган таш сын-балбал. Галимнәр исәпләвенчә, бу сын-һәйкәлгә ике мең ярым ел...*

Бу уйлар — әкияти хыял. Безгә, бер саплам җеп озынлыгында гомер бирелгән Кеше атлы Адәм балаларына, мәңге яшәр таш сын да, шигырьдәгечә «ак болыт булырга да язмаган»... Яшисең икән (бүтән чара юк! — «ирексездән туасың, гаҗәпләнеп яшисең, сагыш белән үләсең...») — уйланмый хәлең юк: борчыласың, хыялланасың, исәп-хисапларыңа муафыйк эшгамәл кылырга тырышасың. Гадәттә, кылган эш-гамәлләр корган уй-хыялларның бик аз өлеше генә булып чыга...

Гаме булган Җан иясенә уйланыплар калыр өчен җай чыгып кына тора ул. Тиздән, тагын берәр елдан, Кешелек яңа гасырга аяк басарга тора. Хәер, гасырлар үлчәме — шартлы нәрсә. Миладича 1999 ел булса, һиҗричә 1421 ел исәпләнә. Ә яһүдләрдә — 5759 ел. Яшәешебез шартларына бәйле рәвештә бездә инде байтак гомерләр григориан календаре исәптә йөри. Туу-үлемебез дә, гомер кичкәндәге төп вакыйга-даталар да шушы календарьдагы саннар белән билгеләнә.

Әйе, без «Егерме» дип йөрткән гасыр тәмамлануга бара. Алдагылары белән чагыштырганда җәһәтрәк, тизрәк үткәндер сыман тоела ул миңа. Җир Кояш тирәли кызурак әйләнмәгәндер, билгеле. Ә планетадагы Тереклекнең яшәү рәвеше, кеше гамәлләренең башкарылу тизлеге, вакыйгаларның үзара үрелеп агуы, ил-халыкларның бер-берсенә керешеп аралашуы ягыннан бу гасыр, һичшиксез, «тыгызрак», динамиграк булыр. Чагыштырып карыйк: бу йөз елга якын дәвердә халык бик нык үрчеде, берничә мәртәбәгә ишәйде. Кытай кебек халкы миллиардлап исәпләнгән илләр хасил булды. БМО мәгълүматларына караганда, хәзер Җир йөзендә 6 миллиардлап кеше яши. Димәк, тыгызландык. Кояш астында тере күләгәләр күпкә артты, җирдән шуышып искән җилгә җанлы киртәләр күбәйде.

Элгәреге гасырларда кешеләр үзләре яшәгән җир өсте киңлекләрен биек тау башларына менеп манзара кылган булса, Егерменче гасырда Адәми зат Җир шарын Яшел Планета дип атап, галәм киңлекләреннән чыгып, «читтән капшап» карады, хәтта Айга җитеп, «Зөһрә кыз көянтәсен тотып кайтты». Җир-бишеккә мөнәсәбәт үзгәрде. Матдәнең «җанында» казыну көчәйде. Атомны таркаттылар. Ягъни кеше акылы макродөньяга да, микродөньяга да тирән үтеп керә бара.

Кеше яман чир кебек сырхауларны (соңгы чорда алар рәтенә СПИД кебекләре дә өстәлде әле!) дәваларга чарасыз булса да, тереклекне күпләп кыра торган атом, водород, нейтрон һәм тагын әллә нинди бомба-кораллар уйлап тапты. Җирнең өстен-астын үлем заводлары челтәрләде.

Диңгез-океаннарның төпләренә кадәр бүлгәләнелде. Энергетик ресурслар — нефть, ташкүмер, газ бетүгә таба авышты. Озонлы биосфера катламы, тузган сүрү кебек, ертылырлык юка элпәгә калды. Табигать мәсхәрәләнде. Сугыш-эпидемияләрдән дә мәхшәррәк афәт — экологик афәт килде. Чын чиста сулар Арктик бозлар куенында гына калды бугай инде. Җир-Су, дигәч, ирексездән күңелгә «җирсү» сүзе килә. Та-

бигый Табигатьне сагынып җирсү... Гасырыбызның 50 нче елларында телдән төшми йөргән «Без Табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз, аны аңардан тартып алу — безнең бурыч!» дигән лозунг-шигарьнең икенче өлешен «коммунистларча» шәп үтәдек бугай.

Кеше нинди генә көч-куәткә, аң-зиһенгә ия булмасын, ул иң әүвәл Табигать баласы. Вәхшиләрчә мөнәсәбәттән Табигатьнең әчке гармониясе бозылган икән, димәк, аның баласы — Кеше дә шул дәрәҗәдә үк камиллеген, игелеклелеген югалткан дигән сүз. Миңа калса, үтеп бара торган гасыр Кешенең кешелеген Яшәү сәхнәсендә шундый итеп сынады ки, һәм бөеклеген, һәм түбәнлеген, көзгедәге кебек, үзенә һәм җирдәшләренә бөтен нечкәлекләре белән күрсәтеп бирде. Шигырьдәгечә, «бөтен прогресслар фәкать регресс кына, кеше җаны череп таркалса...»

Меңнәрчә телләрдә сөйләшеп тереклек итүче халыклар (Җир йөзендә 5 меңнән артык тел һәм шивәләр бар дип исәпләнә) яшәешендә дә, ягъни дөньякүләм иҗтимагый тормышта да, Табигать-Ана кичергән хәлләргә охшаш үзгәрештетрәнүләр, һай, күп булды бу үткән гасырда! Гасыр яшьтәшләре булган йөзьяшәр аксакаллар ул хәлләрне бөтен күзәнәкләре белән тоеп аңлыйлардыр. Әле безнең, чагыштырмача яшьрәкләрнең дә, ишетеп, укып, күреп, кичереп белгәннәре дә байтакка җыйнала.

Менә ул Тарих «капчыгыннан тырпаеп торган» кайбер тенденция-контурлар. Егерменче гасырда бик күп халыклар милли бәйсезлекләре өчен көрәшкә күтәрелделәр, күп корбаннар бәрабәренә булса да җиңделәр, максатларына ирештеләр. Искә төшерик: Европаның төп баскынчы илләре — Англия, Испания, Франция — күпме колонияләреннән колак кактылар! Африкада, Азиядә бик күп яңа бәйсез дәүләтләр барлыкка килде. Димәк, кимсетелгән, изелгән, каһәрләнгән халыкларның күз яшьле каргышы «костырды» аларны. Ә Тормыш-Яшәү дигән бөек сәгадәтнең антиподы — «ихтыяҗи» сугышлар? Егерменче гасыр бу яктан күрсәтте инде күрмәгәнне! Үзәге без яшәгән Европада кайнап чыгып, аннары бөтен кыйтгаларга да таралган беренче бөтендөнья сугышы, янә Икенче бөтендөнья сугышы (исемнәре генә ни тора!), булуы ихтимал өченчесе... Тфү! Тфү!

Ихтимал, Күк җәнабларыннан җибәрелгән иң зур каһәр һәм сынау элеккеге Рус империясе, соңрак СССР, хәзер Россия дип йөртелгән җирләргә тигәндер... Инкыйлаб, гражданнар сугышы, җирне хуҗасыннан аеру — колхозлашу, сыйнфый дошман эзләү, искитмәле салымнар чоры, «комму-



*«Безнең якта борынгыдан хәрабәләр генә...» X—XI гасыр ядкаре*

низм төзү» дәвере, «бөек» торгынлык, һәм, ниһаять, янәдән килеп байлар белән хәерчеләргә бүленү еллары...

Бу гасырда Россия империясе элеккеге Рим яки Госманлы империяләре шикелле таркалды, дисәк тә була. Әлеге дә баягы шул «косу» галәмәте бит бу. Гасыр башында Польша, Финляндия кебек илләр мөстәкыйльлек алып үзбашка чыкса, гасыр ахырында зур тоташ киңлекләрнең кырыйларыннан кителгән язгы бозлар шикелле, хәзер шактый ук кечерәйгән территориядә ярым ач, ярым җимерек, ярым исерек Рәсәй утырып калды (шуның уртасында без...). Прибалтлар да юк, кырый-украин яклары да юк, Кавказ да, Урта Азия дә... Кояш астында алар бар. Әмма алар — бүтән! Гомумтенденция: халыклар, бер яктан, икътисади, сәяси җирлектә берләшергә омтылсалар (мәсәлән, Европа илләре бердәмлеге һ.б.), икенче яктан, мөстәкыйльлек, милли аерымлык, үз йорт-дәүләтен булдыру юлын сайладылар. Моның бер ачык мисалы гасыр урталарында Израиль дәүләте оешу булды. Тел вә дин ягыннан үзара кардәш төркемнәр тәшкил иткән халыкларда да үзенчәлекле зур эволюцион үзгәрешләр туды, әлбәттә.

Кемгә ничектер, миңа калса, төрки халыклар, әйтик, славян халыкларына караганда, тетрәнүләрне, катаклизмнарны күбрәк кичерделәр шикелле. Гасыр башында бөтен төрки халыклар диярлек, тарихи бәйсезлекләрен югалтып, аяусыз колониаль басымга дучар ителделәр. Егерменче елларда чагыштырмача көчле һәм мөстәкыйль булган Төркия дә бәйсезлеген югалта язып калды. Урта Азия ягы төркиләре бу гасырда мәгълүм бер тәрәккыяткә ирешсәләр дә, барыбер инкыйлаб китергән уртак нәтиҗәләрдән, уртак әйләнештән читтә кала алмадылар. Шул ук бер идеологик максат-принциплар, шул ук тоталитар идарә итү системасы, шул ук совет халкы (дөньядагы иң алдынгы!) рәвешендә урыслаштыру сәясәте... Сүздә никадәр генә ирекле һәм тугандаш саналмасын, «бәйдә тоту» принцибы шулкадәр мөкәммәл эшләнгән иде ки, хәтта бер генә республиканың да үзендә теге яки бу төрдәге тулы производство-җитештерү циклы булдырылмады. Төп деталь, двигатель бер җирдә эшләнсә, ә бер бик тә кирәкле икенче бер шөреп меңәр чакрым ераклыктагы бүтән бер өлкә йә республикада ясала иде.

Әмма тарихи дөреслек өчен гадел булыйк: Урта Азия халыкларына бу үткән гасыр шактый ук «көн төште». Ижти-



*1552 елны русларның Казанны яулап алуы. К.Вениг (XIX г.) картинасыннан репродукция*

магый формацияләрнең эволюцион үсеш чоры тизләнү сәбәпле, икътисадта алар Уртагасырчылык мирасыннан шактый тиз арына алдылар. Нинди генә бәрелешләр, сугышлар, сынаулар булса да, халыкларның тарихи рухлары, нигездә, бетмәде, яшәү рәвешләренең төп принциплары сакланды, өмет-максатлары югалмады. Һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба алар хакыйкый бәйсезлек тә алдылар. Күрәбез, беләбез: бүген алар зур икътисади кыенлыклар кичерә. Үтә торган авырлыклар бу. Иң мөһиме, «Аh, татлы нәрсә шул ул Азатлык!» дигән шикелле, халыкның киләчәгенә гарантия булган мөстәкыйль дәүләтчелек барлыкка килде. Димәк, өмет бар!

Безнең җирлектә яшәгән өлкән һәм урта буын өчен Егерменче гасыр тарихы ул, асылда, СССР тарихы. Ә СССР — ул Җир шарындагы коры җирнең алтыдан берен тәшкил иткән галәмәт зур территория. Шушы киңлек гел генә Егерменче гасырның халыкларны «печү» полигоны булган икән дип уйлаучылар ялгышырлар. Байтак ил-халыкларга якты нур булып төшәрлек прогрессив идея-гамәлләр дә туган һәм тормышка ашкан җир дә бит әле ул Советлар Союзы. Егерменче гасырның иң авыр сынауларын кичеп тә, рухлары сынмаган, талантлы халыклар яшәгән бу җирләрдә. Күп кенә бөек башлангычлар иле дә булган ул. Халкы ачлы-туклы яшәсә дә, киләчәккә иманы нык булган аның. Җаны сау булган. Конфуций әйткән, имеш: «Дәүләт белән идарә итәр өчен өч нәрсә кирәк: ашар-эчәр ризык, ил сакларлык корал һәм халык ышанычы». Аннан сораганнар: «Шуларның берәрсе булмаса, Дәүләтне тотып буламы?» — «Коралсыз да була», — дип җавап биргән ул. «Әгәр шул өчнең тагын берсе булмаса?» — «Хәтта ризыксыз да була, — дигән акыл иясе, — кешегә, барыбер, бер үләргә туры килә, ә менә халык ышанычын югалтса, бернинди Дәүләт тә яши алмый», — дип җавап биргән. Әйе, ышаныч, киләчәккә ышаныч бөек нәрсә ул! Дөрес, ышанычларның күбесе акланмаган... Халыкларның бөеклеге һәм фаҗигасе кардиограммасы. «Ул елларга инде кайтып булмый...» дигән шигырь юллары бар. «Сагынып кына була!» дип дәвам итеlә ул. Хикмәт ностальгиядә, сагыну-сагынмауда гына түгел, әлбәттә. Әмма бүгенге кискен контрастлар, дәүләти дәрәҗәдәге җинаятьчелек, эшсезлек, сәяси башбаштаклык... Әнә шулар үткәнне сагынырга мәҗбүр итә. Ә сагыныр нәрсәләр юк түгел: социаль гаделлек; хезмәткә, укуга, ялга, дәвалануга реаль хокуклар; билгеле бер әхлакый-этик нормаларның үтәлүе, канун-законнарның әзлекленыклыгы...

Инде килеп, үзебезгә — татар кавеменә кайтыйк. Ни гамәлләр кылынды бу дәвердә? Бүген ниләр майтарабыз? Киләчәктә нәрсәләр эшләргә җыенабыз? Сорауларны бирдем бирүен дә, ә җавап бирүләре, ай-һай, кыен. Яңа гасыр башланыр алдыннан бик күпләр уйлана-уйлана, кайта-кайта үзенчә җавап эзләячәк әле бу сорауларга. Шулай булгач, шул меңнәрнең берсе, бу очракта шушы гасырның икенче яртысын кичкән кеше, бүгенге әдип һәм мөхәррир буларак, үземчә фикер йөртеп карау гаепмени? Сизенәм, мөгаен, субъективлыкта гаепләүчеләр дә табылыр. Халык язмышы турында фикерләшкәндә, бәхәсләр туу табигый хәл ич! дип кабул итәргә кирәктер. Иң элек күңелгә шуны киртләп куйыйк. Үтеп баручы гасырда без сан ягыннан (рәсми мәгълүматларга табынмаган хәлдә дә) әллә ни артмадык, үрчемәдек, ишәймәдек. Бүтән төрки халыклар белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык күренә. Сәбәпләрен һәркем үзенчә гөман кылыр. Заманында хәзер уртак ватан саналган иксез-чиксез киңлекләргә дәгъва кылган милләт XV — XVI гасырларда каршы як милләт белән бер чамадарак булган бит ләса! Нидән бу туктап әкренәю? Бар булып та, бүтән халыклар мохитендә балавыз күк изрәп «эрүебез» нәтиҗәсеме бу? Әллә



*«Яшәсен Советлар Союзы...»*



*Империяләр бер көн таркала*

сәбәп генофонд оеткысының сыеклануындамы? Әллә неомальтусчылык (күп үрчү, янәсе, сыйфатка «бәрә», интеллект кимүгә китерә. Гадәттә, Африка һәм Азия илләре мисалында шулай аңлаталар) тарафдарлары булып киттекме? Әллә элегрәк прогрессив күренеш дип бик пропагандаланган катнаш никахлар җимешеме? Ни генә булмасын, факт инкяр итеп булмаслык факт булып кала. Димәк, санның сыйфатка әверелү ягыннан да без әллә ни алгарышка өметләнә алмыйбыз.

Каршылыклы тагын бер сорау туа: гасыр башында татарның матди һәм мәдәни хәле ничегрәк булган? Гасыр ахырында ничегрәк? Россия империясе кысасында ниндирәк урын тотканбыз да, хәзер шул ук ил-халыклар (хәзер статуслары бүтән булса да) арасында ниндирәк рейтингта без? (Әлбәттә, һәр вакытка, һәр чорга чагыштырмача нисбәттә!) Без гасыр башында бүтән халыклар белән чагыштырганда баерак, зыялырак булганбызмы әллә?.. (Янәдән кабатлыйм: чагыштырмача.) Төгәл, кистереп җавап бирү кыен. Гомумконтурны ретроштрихлар белән генә чамаларга кала. Шунысы факт: заманасына күрә Россиядә — Дума җыелышла-



*Оренбургта Хөсәеновлар салдырган «Хөсәения» исемендәге гали мәдрәсә (XIX гасыр ахыры)*

рындамы, фабрика-завод цехларындамы, прииска-шахта тирәнлекләрендәме — татар факторы шактый көчле булган. Сәүдә дөньясы турында әйтәсе дә юк. Халыкның билгеле бер катламында милли сәрмая, ягъни милли капитал тупланган булган. Хосусый кулларда булса да, бу капиталның шактый өлешен милли байлык, дип тә әйтеп була. Моңа бер дәлил — меценатлык. Әгәр хәйрия оешмалары (бу хәрәкәтнең үзәгендә торган Хөсәенов, Кәримов, Яушев, Юнысов, Акчурин, Рәмиев кебек затларга дистә еллар аша рәхмәт!) булмаса, әйтик, мәгариф өлкәсендәге казанышларга (чагыштырмача уку-язу буенча татарлар урыс туганнарга караганда гыйлемлерәк тә саналганнар әле. Бу хакта Ленин да язып калдырган) ирешелер идеме? Матбага эше гөрләп тормаса, көчле әдәбият каян килер иде? Рухыбыз дөньясында бер Тукай феномены гына да күп нәрсәне аңлата.

Ул заманда безнең халык күпләп яшәгән һәр губерниядә, һәр төбәктә татар теленә, татар китабына, милли яшәү рәвешенә табигый көчле ихтыяҗ булган. Татар китабы, гомумән татар матбугаты, империянең дистәләгән регионнарында мул күләмдә, күп санда нәшер ителгән. Театр труппалары оешкан. Дини оешмалар һәм мәчетләр массакүләм рухи-идеологик үзәк миссиясен үтәгән... Кыскасы, рухи күтәрелеш булган. Дәрт тә, дәрман да булган.

Мәгълүм хакыйкать: һәр халыкның көчен-куәтен аның милли байлыгы билгели. Бүгенге дөнья байлыгы кайсы илләрдә һәм кемнәр кулында тупланган? Әйтәләр: кимендә 70% мәгълүм бер халык хозурында. Ә безнең милли байлыгыбыз (республика банкларының берсендә Татарстанның да үз алтыны — фәлән килолы бер кирпеч коелмасы бар, дип сөйлиләр) күпме дә һәм кемнәр кулында? Югары цивилизацияле илләр мисалы шуны күрсәтә: әгәр байлык чын мәгънәсендә уртак милли байлык булса, чын хөкүмәт аны әрәмшәрәм итүгә, урлауга юл куймый. Хәер, бу кадәресе хәзерге Россиягә дә, Татарстанга да карамый шикелле.

Үткәнне мактыйммы? Һич юк. Булганын искәртәм генә. Бүгенге күзлектән караганда, ул заманның, сәнәгатендә булсын, мәгърифәтендә, сәнгать һәм әдәбиятында булсын, дөнья кадәр тискәре якларын табарга мөмкин. Ә бүгенгебез? Совет чорында чыккан йөзләгән фәнни-гыйльми саналган хезмәт-китапларны актарсак (аларда совет чорындагы бишьеллыкларның «уңышларын», гадәттә, нигәдер 1913 елгы күрсәткечләр белән чагыштыралар иде), теге заман белән чагыштырганда йөзәрләгән, хәтта меңәрләгән тапкыр үсеш турында күрсәткечләргә юлыгырбыз. Әйтик, матбугат турында сүз чыкса, әйтерләр, хәзер бер Татарстанда гына йөзләгән нәшрият бар. Шәһәрләрдә йөзләгән татар мәктәбе. Фәлән йөз язучы, фәлән мең мәдәният сарае, клуб... Ә заводлар, фабрикалар, промышленность предприятиеләре, бигрәк тә хәрби заводлар турында сүз китсә, үсеш темпларына шаккатып тел шартлатырга гына кала. Геополитик яктан Европа-Азия казанышларына ия Татарстан фәненең казанышларын шик астына алырга теләмибез. Читләрдән караганда, чыннан да, милли аспект турында уйламасаң яки аны инкяр итсәң, без фәкать тәрәккыят аванпостында гына торабыз диярсең.

Ярый, без, каләм ияләре, гомерләребезне багышлап, күп гасырлы зур әдәбиятыбыз бар, дип, эчке куаныч кичереп яшәүчеләр, бөек рухи чыганак — Галиҗәнап Әдәбиятыбыз турында бүген ниләр уйлыйбыз соң? Өзек-төтек кенә белгән Болгар чоры, Алтын Урда, Казан чорларына кереп тормыйча, күпмедер дәрәҗәдә шаһиты без булган Егерменче гасыр әдәбиятын күздән кичерик. Гасыр башы һәм гасыр ахыры чишмә башлары чыганакларын барлыйк.

Кайларда туып, кайлардан килгән соң талантлар татар әдәбиятына? Әлбәттә, Идел-Урал буе — Татарстан һәм Башкортстаннан, Самара, Сембер, Пенза, Нижгардан; Әстерхан, Тобол, Сарытау, Оренбург, Троицк, Чиләбе, Курган якларын-

нан... Тагын дистәләгән шәһәрләрдән... Хәер, йөрәк яндырып санап торуның хаҗәте юк. Хәзерге әдәбиятыбызга әзмекүпме килеп кушылган яшьләр — үзебезнең Татарстаннан да Башкортстаннан. Калган регионнардан инде килмиләр диярлек. Мәктәпләр беткән, китапханәләрдәге рухны вакыт җилгәргән. «Киткән ватан белән сөт тә кипкәнме әллә?..» Әй мөхтәрәм зат Закир Рәмиев — иптәш Дәрдемәнд! — ямьле Юлык буйларында нинди варисларыгыз үсә? Сыркыдыда Такташ якташлары татар китаплары укыймы? Пенза якларында Г.Коләхмәтов, К.Тинчурин, Ш.Усманов, Г.Кутуйлар рухы исәнме? Камышлы Әнвәр абый Давыдовны юксынамы?

Тагын кайсы якларга карап оран салыйк? Беренче татар романнары авторы З.Бигиев (Ростов), Ш.Камал, Г.Әпсәләмов (Мордовия), К.Нәҗми (Т.Новгород), Г.Сәмитова (Ташлыяр), Х.Госман (Пермь), А.Расих (Троицк), Н.Арслан (Кызылъяр)...

Театр, музыка, сынлы сәнгать дөньясыннан кайбер исемнәрне искә төшереп үтик: З.Хәбибуллин (Орск), Л.Фәттахов, Р.Ваһапов (Т.Новгород), Г.Кайбицкая (Уральск), Ф.Туишев (Сембер)... Хәзер, кызганыч, ул төбәкләрдән мондый олуг «йолдызларны» телескоп яки төнлә күрсәтә торган приборлардан карасаң да күреп-табып булмый инде...

Әдәбият китапсыз була алмый. Татар китабының, гомумән матбугатының, бүгенге хәле күңел күгәртерлек дәрәҗәдә мөшкел. Китап кирәксез товарга әйләнде. Үзенең кирәксезлеген тою — һәр талант, гомумән һәркем өчен, иң авыр тойгыларның берсе. Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла кебек, кул-арбага китап төяп ил буйлап йөрергә дә риза булыр идең дә хәтта, әмма бүгенге яшь-җилкенчәккә син язган җыру-моңнар кирәк микән? Ә бит Егерме беренче гасырга алып чыгарлык әдәби мирасыбыз бар һәм ул әлегә өстәлеп тора! Аяныч. Мирасыбыз өчен түгел, бүгенге хәлебез өчен аяныч.

Хәзерге татар әдәбияты әлегәчә элеккеге «эч мае» хисабына (фольклор, классик мирас тәэсире, чирәмле авыл рухы, җыр-моң, балачак хатирәләре, табигый җир-су...) яшәп килде. Телебезнең бишегә булган авыл да, ай-һай, бик нык үзгәрде шул бу дистә елларда!.. Берничә буынны тәрбияләгән «Галиябану», «Агыйдел», «Йөзек кашы», «Туган ягым — яшел бишек» әсәрләрендәге каһарманнарның реаль оныклары укый микән әле бу гүзәл әсәрләрне? Шикләнәм.

Кыскасы, нигезебезне — авылны югалтып барабыз. Бәс, шулай булгач, сугыштан соң тирәлегебезне чорнап алган ВПК

предприятиеләре, нефть промыселлары, КамАЗ, нефтехимнарның югары даирәдәге шәхесләре турында үз телебездә нинди югары художестволы әсәр туарга мөмкин! Базарың (бәяң мәгънәсендә) булмагач, әдипнең дә кадере юк. Кадерсез әдип үзе дә сансызлана. Бүгенге көндә югары исемнәр йөрткән, яшьләре белән 70ләрдән узган мөхтәрәм әдипләребезнең дә байтагының интеллектын гасыр башындагы С.Максуди, Й.Акчура, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимовлар интеллекты, зыялылыгы һәм затлылыгы белән чагыштыру кыен. Әмма үзен татар дип йөрткән, үзендә милли үзаң бар дип исәпләгән һәркем бер нәрсәне онытмаска тиеш: дәүләтчелек идеясе теге йә бу формада иң әүвәл Сүздә — гыйлем иясләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә сакланды. Байтак гасырлар буенча Дин, беренче чиратта, милләтне таркатмаска булышса, әдәбият иң мөкатдәс хисне — Азатлык, Бәйсезлек, Мөстәкыйльлек идеясен, йә ачыктан-ачык, йә эзоп теле белән, эчтән саклап, үстереп килде. Әйе, 90 нчы елларда беркадәр яуланган суверенитетмөстәкыйльлегебезнең юл башыерактарак... Шуңа күрә дә, шул Олуг Әдәбият варисларының бүгенге көндә үз талантларына кирәк кулланыш таба алмаулары, кирәксезлекләре — ил хуҗалары, дөнья чыгырын әйләндерүчеләр өчен оят булырга тиеш.

Халык рухының ышанычлы көзгесе булган әдәбият турында сүз кузгаткач, милләтне милләт иткән бүтән компонентлар турында да берничә сүз әйтми калып булмый. Ул — **туган тел язмышы**, ул — **милли тарих**, ул — **милли мәгариф системасы**, ул — **дин тәгълиматы**... Бу олуг мәсьәләләрне бер язмада хәл итү түгел, чишелешен дөрес куя белү дә ифрат авыр. Теләгәндә дә, әзерлегем, көчем дә җитмәс иде. Кайбер күзәтүләр белән чикләнәм. Тел хакында сүзем кыска: ул — сорау гына. Ана телендә гасыр башында күбрәк сөйләшкәнме татар халкы, әллә хәзерме? Өч алфавит кичкән халык яңа гасыр башын нинди имля белән башлар? Җавапларны укучы үзе табар. Дин өлкәсендә, кызганыч, махсус белемем юк. Шулай да, мәсьәлә артык зур булганга күрә, бу хакта һәркемнең үз фикере булу лязем. Әгәр динебез булмаса, бу дүрт-биш гасыр эчендә без милләт буларак күптән беткән булыр идек инде. Безне моңарчы дин, эчке иман саклап килде. Шуны аңлап, дәһшәтле кара көчләр төрле гасырларда динебезне юк итәргә ташландылар да инде!

Үтеп баручы гасырда, рухка иркенрәк еллар булгаласа да, нигездә, динебез, галимнәребез бик нык каһәрләнде, дин хадимнәренең күбесе җисми юк ителде. Болары һәркайсы-



*1992 елның май аенда Бөтендөнья татар конгрессының беренче җыены үткәрелде. Президиум манзарасы*

бызга мәгълүм. Һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба дин иреге генә юл бирелде. Күп җирләрдә, тирә-юньгә ямь биреп, манаралы мәчетләр калкып чыкты (дөрес, аларның күбесе ашыкпошык, зәвыксыз һәм фәкыйрь салынды. Хәер, әлегә алары да ярап тора). Ә халык йөриме? Ниятләнгән максатка ирешеләме? Динчеләребез әзерлеклеме? Дөресен әйтик, безгә чын мәгънәсендәге динле халык булырга ерак әле. Гади халык кына түгел, хәтта күп руханиларыбызның да гамәле, Диннең асыл рухы һәм Аллаһ иңдергән тәгълимат белән иманланудан бигрәк, яшәешләре, гамәлләре, асылда, ритуал йола-гадәтләрен үтәүгә кайтып кала. Дин, алда әйтелгәнчә, бөек көч. Иншалла, киләсе гасыр дәвамында милләтне саклауда аның роле зур булсын иде.

Ә уку-укыту, гомумән мәгариф системасына килсәк, безнең өчен аеруча авыр дәвер булгандыр бу гасыр. Бигрәк тә алтмышынчы-сиксәненче еллар арасында татар мәктәбен ачыктан-ачык юк итү сәясәте алып барылды. Моннан егерме еллар элек Казан булып Казанның үзендә тулысынча татарныкы дип әйтерлек бер генә мәктәпнең дә калмавын искә алсак, бу хакта артык сүз куертуның кирәге юк. Милли мәктәпләрне үстерүдә соңгы еллардагы күтәрелеш беркадәр өметне уята уятуын. Тик болар әлегә үсентеләр, көзге болында калкып килүче курпылар гына... Булган милли

рухны кире кайтарыр өчен генә дә берничә яңа буынның үсүе зарур. Бер сөргән болында янәдән тигез чирәм-бәпкә үләне булдыру өчен күпме вакыт кирәклеген күпләр белә булыр...

Үткәнебезне өйрәнүдә дә эшләр шулайрак. Егерменче елларда татар тарихы беркадәр өйрәнелә башласа да, соңгы илле-алтмыш елда ул партия идеологиясе басымында бер яклы, Мәскәү тарихына кулай кушымта булып «фәнниләште». Без, дөресен әйтик, дәүләтчелегебез тарихын, үсеш дәверләрен, аның хаким-шәхесләрен, алар кылган гамәлләрнең яхшы-яманын бөтенләй диярлек белми үстек. Хәзер генә, яңа туган песи баласыныкы шикелле, күзебез ачыла башлады. Тарихыбызны оныттыру, хәтерсезләндерү — Егерменче гасырның (алдагы дүрт-биш гасырның дәвамчысы буларак, әлбәттә) безләргә кылган иң «саваплы» гамәлләренең берседер...

Ишеткәнем бар: янәсе, һәр гасыр башында зур социаль тетрәнүләр булып ала, һәм шул нисбәттә рухи дөньяда даһилар пәйда була. Миңа калса, мондый фараз, кемнәрнеңдер чынаяктагы кофены болгатып, язмыш юравы шикеллерәк нәрсә. Әмма халыклар язмышында (календарь тәртибе буенча түгел, билгеле) чоры-чоры белән ыргымнар, яңарышлар була тора. Безнең Татарстан мисалында да бу шулай. Соңгы ун-унбиш елда эчке үзгәрешләр бик күп. Җитмешенче еллардагы Татарстан обкомы чорлары белән туксанынчы еллар ахырындагы идарә системасы, элеккеге Верховный Совет белән хәзерге Югары Совет (Дәүләт Советы), элеккеге Конституция белән хәзерге Конституция арасындагы аерма аңлаган кеше өчен бик зур бит. Дөрес, җирле кануннар Үзәк тарафыннан бик нык «үтүкләнә» соңгы дәвердә...

Евразия үзәгендә Татарстан дигән республика барын хәзер бөтен дөнья белә. Бу — бик мөһим фактор һәм Егерменче гасырда ирешкән зур казанышыбыз. Акча яки корбаннар бәрабәренә сатып алып була торган нәрсә түгел ул. Парадокс: бер яктан, ярлар тарая, ә агым көчәя генә; басым арта, бәреп чыгу дәрманы арта... Тик шунысы кызганыч: Татарстан ул әле бөтен татар халкы дигән сүз түгел шул... Гасыр башында империя киңлекләрендә татар өчен «күтәрәсе (уңыш бирәсе!) чирәмлекләр» шактый иде әле. Хәзер ул чирәмлекләр тупас төрән белән аннан-моннан сукаланган, аларга ашлама дип агу мул сибелгән (эчкечелек — шуның иң каһәрлеседер, мөгаен). Шулай да, акрынлап булса да, иман индерү

бара. Соңгы җиде-сигез ел эчендә үткәрелгән Бөтендөнья татар конгресслары... Исеме генә ни тора! Тупланырга, яһүдләрдән ким булмаганча, бер-беребезгә таяныч булырга бөек омтылыш бит бу.

Элек исемнәре дә як-якка каранып, пышылдап кына әйтелә торган чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән, хәзер кулга-кул бирешеп, киләчәктә ничегрәк яшәү турында иркенләп фикер алыша алабыз. Тоталитар режим балалары өчен бу да зур казаныш. Шәп, матур, тантаналы очрашулар үтә, мәгънәле генә карар-резолюцияләр кабул ителә. Делегатлар таралалар. Һәм... үз җирләрендә киләсе җыелуларны көтеп яши бирәләр. Дөрес аңлашылсын, Конгресс комитеты эшләрен һич тә киметергә теләмим, хәл кадәри тырышалар, чит өлкәләргә чыгалар... Уяту һәм беркадәр ояну бар. Әмма кайчак шундый уй да килә: төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә сүнеп яткан учактагы күмерләрнең уңай исеп куйган җилдә беркавым җемелдәп алуы гына түгел микән бу олуг җыеннар?.. Әгәр татарлар ишле яшәгән җирләрдә милли-мәдәни мохтарият төзелми, федераль үзәктән, җыелган салымнар бәрабәренә, тиешле средстволар бирелми торып, милли хәрәкәт мактанырлык алга китә алмастыр.

Хәзер ерактагы һәм якындагы чит илләрдә Татарстанның уннарча Вәкиллекләре бар. Алар, бәлкем, республика өчен зур эшләр башкара торганнардыр. Америка, Франциядәге кебек илләрдә, дип әйтмим, әйтик, татарлар күп яши торган төрки дәүләтләрдә — Казакъстанда, Үзбәкстанда яшәп ятучы ул Вәкиллекләр безнең рухи байлыгыбызны — китапларны, газета-журналларны оешкан тәртиптә тарату эшенә алына алмыйлар микәнни? Татар матбугаты хәзер, нигездә, Татарстанда гына тарала. Урта Азия, Казакъстан белән бу җәһәттән аралар киселгән диярлек. Менә бит ул тараюлар каян килә! (Кайчак уйлап куясың: ул якларда милли җанлы эшмәкәрләр табылмый микәнни? Хәзерге заманда әллә нинди могҗизалар эшләп була бит. Әйтик, «Казан утлары» яки бүтән берәр басманың куен кесәсенә сыя торган бер-ике санлык дискетын ал да, шунда кәгазь табып, бастырып, таратып файдасын күр! Юк бит...)

Сүзне йомгакларга да вакыттыр. Без гасырны бераз иртәрәк төенлибез бугай. Шулай да берле (1) һәм дә тугызлы (999) саннар белән саубуллаштык инде. Аннан — икеле (2), нольле (0) саннар башланыр. Егерме беренче гасырга

үз язмышына, үз тарихына һәр халык үзенчә аяк басар. Инглиз инглиз булып, француз француз булып, гарәп гарәп булып... Алар да, әлбәттә, бу үтеп баручы гасырда әллә ничаклы фаҗигаләр, регресслар, тантаналар, үзгәрешләр кичергәннәрдер. Әмма милләт буларак алар, фәкать чыныгу, сынау алып, шул ук тарихлы, шул ук телле, шул ук мәдәниятле халык-милләт булып калдылар. Ә без, татарлар, бер гасыр эчендә әллә нинди метаморфозалар кичереп, сыйфатый, әхлакый, генетик яктан бик-бик нык үзгәрдек. Үтеп баручы гасырда безнең күбебезгә, кәлтә еланы кебек, кирәк буыннарны да өзеп (теләп яки мәҗбүр ителеп) калдырырга туры килде. Ә шулай да күпме генә сыкранып-сыктасак та, табигатьтә Бөек Хәят дәвам итәчәк. Ышанасы килә: дөнья халыклары арасында, дөнья цивилизациясендә Татар милләте булачак. Кояш астында Татар иленең үзенә лаек урыны булыр, иншалла.

*1998, ноябрь*

## 2. ИМАН БЕЗНЕ ТАШЛАМАСЫН

Календарьда — Яңа ел. Безнең өчен гамәлдә булган григориан (христиан) календаре буенча — 2001 ел, хиҗри-мөселман исәбенчә — 1422. Ходайның бирмеш гадәти бер елы... Шулаен шулай да, дөньяның байтак кыйтгаларында (шул исәптән бездә дә): «Яңа гасыр, яңа меңьеллык башлана!» — дип, халык мәш килә бит әле! Әйдә, шулай да булсын. Яшәештә бик күп нәрсәләр шартлы символ-атамалар белән билгеләнә. Яңа гасыр икән, яңа гасыр. Үткәннәр турында уйлану, киләчәк хакында фараз кылу, хыяллану өчен бер уңай форсат.

Телибезме-юкмы, Язмыш тарафыннан бүген татар дип йөртелә торган халыкның дөнья буйлап сибелгән балалары без. Гыйбрәтле, озын тарихы, заманында шанлы Дәүләте булган борынгы бер кавемнең варислары. Без әле, шөкер, бүген дә исән-сау, һәм, киләчәккә йөз тотып, Кояш астында мәңге яшәү нияте белән хәят кичереп ятабыз. Шундый уйлар белән яшисең икән, табигый, «без каян?», «ни кылабыз?», «кая барабыз?» дигән сораулар бимазаламый кала алмый.



*Әҗем мәчете манарасы (Казан)*

Мәңгелек Кануннар катгый үзгәрешсез булса да, тора-бара, буыннар алышына-алышына, аңыбызда Вакыт һәм Киңлек төшенчәләре дә үзгәрә сыман: вакыт тизрәк ага, киңлек-пространство кысыла бара шикелле... Чынлап, ышанып та куярсың, үткән йөз елдагы үзгәреш-метаморфозалар шаккатарлык! Уйлап карыйк: Җирдә адәм баласы нык үрчеде (димәк, тыгызландык!); Табигать коточкыч таланды (үзебез утырган ботакны кисәбез!); фән-техника өлкәсендә фантастларның да башына килмәгән ачыш-табышлар булды (күбрәк бәхеткә тиендекме?); ил-халыклар арасында, минут-сәгать эчендә

дигәндәй, кызу-тиз аралашу-бәйләнешләр урнашты (дуслык-туганлык ныгыдымы?)... Һәр конструктив хакыйкый фактка берничә контрсорау килеп баса. Парадокс: объектив шартлар һәм заманасына хас яшәү шартлары (техник казанышлар уртаклыгы, хәбәр-информация берлеге, максат юнәлеше...), бер яктан, төрле ил-халыкларны берләшү дәрәҗәсендә якынайтса, ягъни интеграцияләштерсә, икенче яктан, һәр халыкның үзенә генә хас тарихи гадәт-сыйфатларын ныгытып, телне саклап, аерым бер үзгә милләт булып калу тенденциясе, саклану инстинкты көчәя бара... Факт, бу процесс төрле милләттә үзенчәрәк: берәүләрендә әйдәүче көч империячелек булса, икенчеләрендә үзенә бәйсезлек яулау идеясе төп этәргеч булып тора.

XX гасыр татар милләте өчен аеруча авыр сынау гасыры булды. Алгарыш дәрәҗәсе, табу-югалтулар, стратегик ялгышлар, фаҗигаи язмышлар турында Киләчәк үзенең хак сүзен әйтер әле... Акыл ияләре өчен бүген дә күп нәрсә ачык инде. Бу кыска язмада тирән тарих, сәяси төеннәр, тотрыксыз кануннар, катлаулы икътисад хәлләренә кереп тормыйча, без белгән рухи мирас — якындагы үткән һәм бүгенге әдәбиятыбыз турында чагыштырып уйлану рәвешендә кайбер фикерләребезне бәян итсәк, гайре табигый хәл булмастыр.

Әдәбиятыбыз байтак дәверләр дәвамында, соңгы гасырда бигрәк тә, милләтне саклап калуда, диннән кала (аларны аерып карап та булмыйдыр), иң төп фактор булды. Халык җаны догада, китап сүзендә, җыр-моңда сакланды. Нигездә, соңгы гасырда оешкан һәм беркадәр үсеш алган сәнгать төрләренең өлешен дә инкяр итәргә җыенмыйбыз — алар да зур рухи чишмәләр. Әмма төп чыганак барыбер әдәбият бит! Кемнеңдер «нишләр идек фәлән булмаса!» дигәне шикелле, әдәбият (кулъязма һәм басмадагысын, халык авыз иҗаты әсәрләрен дә кертеп) булмаса, татар нишләр иде икән дә, кем булыр иде икән? Кимендә телсез калган, дөресрәге, ана телен күптән югалткан булыр иде. Шөкер, үткән гасырда кан кардәшләребез яшәгән төбәкләрдә татар китабы милләттәшләребезнең гомер юлдашы булып килде. Күп тә чыкты бит ул китаплар! Дистәләгән мең исемнәрдә, йөзәр миллион данәләрдә... Үткән гасырлардагы акыл ияләре өчен горурланып, авыз тутырып әйтә алабыз: төрки киңлекләрдә генә түгел, тәрәккыятле бөтендөнья масштабында татар әдәбияты дигән зур байлык-хәзинә бар! Бүтән халыкларга да белдерәсе иде, күрсәтәсе иде ул байлыкны, килер буыннар аңына сеңдерәсе иде!



*«Йосыф вә Зөләйха» китабыннан бер сурәт (1813) Бизәүче-каллиграф — М.Кәшмири*

Бүген күңелләрне борчып торган иң төп уйларның берсе шул: яңа гасырда әдәбият үзенең элгәреге миссиясен дәвам итә алырмы? Язучыларыбыз әсәренә ихтыяҗ калырмы? Тере сүзне ясалма аң — компьютер-тамга алыштырып бетермәсме? (Гыйбрәтле хәл: каләмдәшләребезнең байтагы язу машинкасына тиенеп тә өлгермәгән иде әле, инде аларның хаҗәте дә бетеп бара.) Әгәр телең югалса, әдәбиятың бетсә, сәнгатең йотылса, нинди мөстәкыйльлек, нинди суверенитет, нинди бәйсезлек булырга мөмкин икән? Бу урында шуны да искәртеп узу урынлы булыр: үзендә милли аң бар дип исәпләгән татар онытмасын иде — коллык кичергән халкыбызның гасырлар буена Дәүләтчелек идеясе теге йә бу формада иң әүвәл Сүздә — гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә ачыктан-ачык йә эзоп теле белән эчтән сакланып, үстерелеп киленде. 90 нчы елларда беркадәр яуланган суверенитет-мөстәкыйльлегебезнең юл башы — әнә шул ерактагы әдәби офыкларда.

Сер түгел, дөнья тоткан ил-дәүләтләр белән чагыштырганда, без, кызганыч ки, милли байлыкка ия халык түгел. Әйләнә-тирәдә күзгә күренгән хәзинә-байлык, асылда, безнең өчен рәшә генә. (Бер юлаучы, капка ачып, ишегалдындагы кешедән сораган, имеш: «Кем монда хуҗа?» Теге Хуҗа исемле кеше икән, әйткән: «Хуҗасын мин Хуҗа, ә йорт-җир Идриснеке...») Бүгенге көндәге вазгыять моны бигрәк тә ачык сиздерә. Төп байлыгыбыз — иман, акыл, рухи мирас...

Аларның иң күп өлеше — гасырлар буе җыйналып килгән китапларда. Шуңа күрә дә олуг әдәбият варисларының — бүгенге язучыларның — җәмгыять, киләчәк алдындагы җаваплылыклары ифрат зур дип уйлыйм мин, һәм шушы уңайдан каләмдәшләргә дә искәртәсе килә: тарихи миссиябезне онытмаска, позицияне бирмәскә иде бит! Сүзнең җегәре заман басымына чыдарлык, кешеләрне әйдәрлек булырга тиеш. Юкса халыкның нинди вөҗданы ди син! Шуңа күрә, хөрмәтле каләмдәш, сиңа да, миңа да үзгәрергә, яңарырга, максат юлларын яңадан карап, барлап чыгарга туры киләчәк. Үзең өчен кадерле, әмма бүтәннәр өчен әллә ни әһәмияте булмаган күренешләрне, вакыйгаларны су буе итеп тасвирлау яки хикәяләү чорлары узды. «Фәтхулла хәзрәт»чә фәлсәфә кору дәверләре үтте... Фикерләү рәвеше, язу стиле үзгә булган яңа тип әдипләр заманы килде. Ә без аңа әзерме? «Мин — язучы, мин иҗат иттем, ә каләмхак түләү, китап чыгарып, аны тарату — бүтәннәр вазифасы» дип уйлаучылар күп әле безнең арада. Әйтеп куюлары да бар бит: «Ә кем язарга мәҗбүр итте соң әле сине? Инәлеп сорадылармы?» Ата-ана үз баласының тормышта урын табуын гомер буе күзәтеп-барлап торган шикелле, язучы да үз әсәренең укучы күңеленә барып ирешүенә ингач кына беркадәр тынычлана аладыр. Шу-



*90 нчы еллар — онытылмас еллар!*

нысын да онытмыйк: без әлегә талантның халык байлыгы икәнен аңламаган халык мохитендә яшибез.

XXI гасыр хәтәр гасыр булырга охшап тора. Кояш системасындагы планеталарның Җир белән хәрәкәти мөнәсәбәтләреннән бигрәк (ахырзаман дигән тәгъбир күңелдән китмәсә дә), Табигать белән Кеше, илләр белән державалар, халыклар белән милләтләр (бу төшенчәләр еш бутала...) арасындагы мөнәсәбәтләрнең торган саен кискенләшә баруыннан туган уй бу. Кояш астында, бүтән халыклар арасында үз халкыбызның да үзенә лаек урын алуын теләү — табигый хис. Әмма гасырлар буе коллыкта иза чиккән кавемгә дәүләтле, тулы канлы милләт булу бәхете үзеннән-үзе күктән төшми. **Әгәр безнең һәркайсыбыз җанында милли идея формуласы** (ул әлегә күбебез аңында эмбрион хәлендә) **юк икән, әгәр без тарихи нигезебездә бер йодрык булып тупланмыйбыз** (без әлегә һаман таркау һәм дөнья буйлап чәчелгән) **икән, безнең хыялларның буш куык булып калуы бар.** Әйе, инкыйраз дигән хәвеф юк түгел. Шунысы куанычлы: булу ихтималы булган бу хәвефне булдырмый калырга көрәшүче көчләр дә бар. Димәк, алда өмет, ышаныч бар!

*2000, ноябрь*

# ЙӘ, НИШЛИБЕЗ, ГАЗИЗ КАЛӘМЕМ?

Йомшак кар явып үткән. Тирә-юнь ап-ак, шундый тын, чиста, пакь... Өстәвенә сихри яктырып ак каеннар тезелеп киткән... Бу аклыкны күңелләргә генә күчерәсе! Авыл өемнең тәрәзәсеннән караганда әнә шундый идиллик манзара. Яшәешнең шушы мәлендә, Табигатьнең җанлы бер күзәнәге буларак, аклык эчендә рәхәтләнәсе, талгын гына тибрәнәсе, хәтта эреп югаласы килә... Аннарысы янәдән тереләсең, сабый бала күзләре белән тирә-юньгә карыйсың. Ә Дөнья шундый гүзәл! Яшәү шундый бәхет! Тик баштагы уйлар гына менә...

...Янә берәү үз-үзен (камикадзе, диләрме әле?) шартлаткан. Соңгы чиккә җитеп, якты Кояш белән хушлашкан. Кемдер аны террорист-бандит, ди, кемдер шәһит-патриот саный...

Вәгъдәләр ярминкәсе — сайлаулар үтте. Алда — яңалары... Аларга киткән чыгымнарны фәкыйрьләргә тотсаң, тормыш бераз яхшырыр иде... Нәни улымның иртән балалар бакчасына барасы килми, киреләнә, күрәсең, «шәхес иреге» кысыладыр. Ә халыкларныкы?.. Нишләптер Страсбург мәхкәмәсе искә төште... Рәссам Әхсән Фәтхетдиновның альбомын Шүрәлеләрнең үзләренә дә күрсәтәсе иде, нишләрләр



икән?.. Котыплар ел саен әкренләп җылына бара, имеш. Нух пәйгамбәр көймәләре кирәк булмагае... Сәйдәшнең бик матур һәйкәлен күрдем. Төштә. Ә чыны Высоцкийныкы булып чыкты. (Хәер, бу арада, хәтта бер ай эчендә, тагын һәйкәлләр куелды әле: «Бакыр бабай» — Державин торгызылды, Әгерҗедә Таҗи Гыйззәт бюсты куелды, Кремль эчендә татар-рус осталары истәлегенә сыннар калыкты... Афәрин, хәрабәләр түгел, сыннар калка, тынычлык-иминлек, хәтерлелек билгесе бит!) Борынгы Багдадны янәдән утка тотканнар (моннан мең еллар элек безнең якларга ислам динен юллаган шәһәр!). Бу Америка дигәннәре кайчак теләсә кемне тукмап китә торган яшь, таза, кансыз урам бандитын хәтерләтә... Казаныбызның меңьеллыгы да җитеп килә. Ә бәйрәмгә кадәр башкарасы эшләр бихисап икән!..

Тышта ап-ак кар. Өстәлемдә ап-ак кәгазь. Кеше гомеренең сабый чагы кебек чип-чиста. Йә, синең ярдәм белән, Каләмем, ниләр төшәр икән бу ак кәгазьгә?! Хәер, каләм изгегә тартыр, диләрме әле, вөҗданы булган әдип җанның кешеләр күңеленә ниләр түгәсе мәгълүм инде. Гуманист булу, халкыңның асыл сыйфатларын үстерешеп, гомумкешелеккә хезмәт итү, киләчәк буыннар язмышы өчен җаваплылык тою, үз чорыңның һәм халкыңның игелекле баласы булу... Мөмкин эшме бу? Әдәбиятның алтын гасырлары үтте түгелме? Үзен алыштырырлык роботлар ясаган, алай гына түгел, клонлаштырып, теләгән җан иясен укмаштырыр сәләткә ия XXI гасыр затлары өчен эмоциональ әдәби сүз, образлы сурәт кирәкме? Җәмгыятьтә әдәбиятка ихтыяҗ бармы? Ак кәгазьдәге язу буразналарын без дөрес сөрәбезме, Каләмем? Моннан йөз еллар элек тикмәгә генә әйтмәгәндер бит шагыйрь: «Шигырь бүтән дә, дөньяны әйләндерә торган чыгыр бүтән!» Гомумән, гуманлы әхлак хасмы бу заманга? Чыннан да, Акча кодрәте белән Дөнья чыгырын әйләндерүче идарә көчләр (алары да күктән төшмәгән, шул бер камырдан әвәләнгән адәмнәр ләбаса!) Кешелек дөньясы моңарчы тудырган хикмәтле китаплардан, аларда тупланган акылдан гыйбрәт-сабак алсалар, ахырзаман галәмәтләренә охшаш вәхшилекләр, сугышлар, геноцидлар, янау-талаулар, җәбер-золымнар, ашкынып коралланулар шаһиты булыр идекме? «Әй наив җан! — дияр кемдер, — каргалар шигырь укыса, күгәрчен булыр иде!»

Шулай да оптимист буласы килә. Эчке тоемым белән әдәбиятыбызның киләчәгенә өмет белән карыйм, аның үзенә

йөкләнгән тарихи миссиясен югалтмаячагына ышанам. Әлбәттә, нинди генә көчле әдәбият булмасын, ул барыбер замана басымына дучар. Тамыры булмаган әдәбият юкка да чыгарга мөмкин. Зур традицияләргә, бай мираска ия булганнары тиз генә югала алмый. Элегрәк Җир шарының алтыдан бере дип исәпләнгән киңлекләрдә әдәбиятыбыз иң борынгылардан исәпләнә. Китап рухы — безнең геннарда. Әдәби сүз культурасы бүген дә югары дип исәплим мин. Әйтик, «әдәбият әнкәсе» саналган шигъриятебез дөньядагы теләсә кайсы халык шигърияте белән ярышырлык хәлдә. Проза яки драматургия жанрларында да югары сәнгать әсәрләре җитәрлек... Киләчәк турында уйланганда, иң кирәкле төп сорау туа: бармы бездә бүген талантлы язучылар? Иҗади учаклар дөрлиме? Аңлашыла торган табигый сорау. Кистереп «бар!» дип әйтер идем. Шөкер, әдәбиятыбызның горурлыгы саналырлык дистәләгән менә дигән язучылар, шагыйрьләр, драматурглар бар. (Дөрес, гасыр алышынган елларда байтак могтәбәр әдипләребезне югалттык. Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Т. Әйди, Ш. Хөсәенов, Г. Афзал... Алар белән тулы бер чор, кабатланмас дөнья китте! Һәрчак сагындырачак шәхесләр!) Исемнәр атау гаять четерекле, үпкә-сапкага сәбәп хәл булса да, әйтелгән сүземә дәлил итеп, бүген исән-имин иҗат итүче кайбер каләмдәшләрем турында искәртеп китәм. Туфан Миңнуллин. Ул — бүгенге көннең иң абруйлы аксакалларыннан берсе. Хезмәте зур, иманы нык, холкы гаярь, дәрәҗәсе югары. Ә Нурихан Фәттах? Үткән әдәбиятыбызда мондый тарихчы әдип булдымы икән әле? Илдар Юзеев. Берничә буын шигырь сөючеләрнең Такташ кебек кумиры булып кара әле! Без Фәнис Яруллинлы әдәбият, дип горурланып әйтә алабыз. Хезмәте белән кеше рухының бөеклеген раслаган язучы ул... Айдар Хәлим. Мондый публицист белән теләсә кайсы әдәбият горурланыр иде. Кирәксә шигырьне, кирәксә прозаны коеп куя... Күпкырлы иҗаты белән поэзия, җыр, төрле музыкаль жанрлар, гомумән сәнгатьнең байтак төрләрен үстерүгә зур өлеш керткән Ренат Харис... Дингезен, күген иңләп чын ир-егет булып яшәгән, тематик яктан әдәбиятыбызны баеткан Миргазиян Юныс... Иҗатлары белән үз шигъри дөньяларын тудырган, шул дөньяга байтак укучыларын кертә алган, шәхес буларак та үзләре үк бер кызыклы дөнья булган олуг шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов... Шагыйрь,

җәмәгать эшлеклесе сүзләре үзләренә табигый ябышып торган, халык арасында популяр каләмдәшләребез Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим... Иҗаты һәм эшчәнлеге әлегә тулы бәяләнеп җитмәгән, эпик киңлекләрдә тирән сөрә алырлык фәлсәфи шагыйрь, матбугат хадиме Зиннур Мансуров... Кабатланмас стиле, юмор-сарказмы белән алыштыргысыз Марсель Галиев... Тәнкыйтьтә дә, прозада да ат уйнатучы олпат галим Тәлгат Галиуллин... Үзләренең публицистикасы белән күпләргә үрнәк булырлык Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла. Ә бит алар иң әүвәл кызыклы шагыйрьләр. Икенчесе өстәвенә менә дигән прозаик та... Шул ук буын вәкиле — Зиннур Хөснияр. Потенциаль мөмкинлеге зур булган прозаик, нәшер эшләрен заманча оештыручы уңган мөхәррир... Соңгы елларда әдәбиятта феномен саналырлык Мөслим егетләре төркемен кая куясың?! Флүс Латыйфи, Зөлфәт, Фоат Садриев, Харрас Әюпов, Факил Сафин, Наис Гамбәр... Русча язып та, татар мәнфәгатен кайгыртып яшәүче язучыларыбыз — Рафаэль Мостафин, Рауль Мир-Хәйдәров, Равил Бохараев, Локман Закиров... Ир-атлар да көнләшерлек иҗат итүче Фәүзия Бәйрәмова, Нәбирә Гыйматдинова, Флера Гыйззәтуллина, Клара Булатова... Бөтен яктан да ил агасы саналырлык, татар тарихы буенча энциклопедик гыйлемгә ия Миркасыйм Госманов. Милләтебезнең уникаль шәхесләре Рабит Батулла, Зәки Зәйнуллин. Яшьрәкләрдән — Рамис Аймәт, Луиза Янсуар... Берничә исем белән чикләнермен дигән идем дә, өч дистәдән артык исем саналган. Иҗатлары зур булган каләмдәшләребез, шөкер, байтак. Исемлекне тагын дәвам итәргә була. Әйтик, халык шагыйрьләре, халык язучылары исәбенә дә... Югарыда искә алып киткән каләмдәшләр үзләре дә бик төрле, бик катмарлы халык. Арада карашлары, холыклары, иҗат алымнары буенча берсе белән берсе сыеша алмый торганнары бар... Нишлисең, иҗат мәйданы шулай булырга тиештәдер. Шул төрлелек белән кызыклы һәм көчледер дә әле без. Безгә бергә, бердәм булмый ярамый. Төрекләрдәге мәгълүм сүзне үзебезчәләтеп болай дибез: татарның татардан башка дусты юк...

Димәк, әле базда дары бар! Ә укучылар бармы соң? Дары юешләнеп эштән чыкмасын өчен шарт — коры урын, ышыкнгытма, учак дөрләсен өчен утын, аның өчен урман кирәк. Язучы өчен Укучы кирәк. Алдында торган килеш, сырхау тәнеңә ризык үтмәсә, Галиябану кебек сылу булып үсеп тә,

ярың табылмаса, бөек җыр туып та, аны башкаручы булмаса?.. Сер түгел, ни кызганыч, татар китабын укучылар кими бара (дөрес, юлын табып, авыруга укол ясаган шикелле, кешеләр күңеленә вакытында «китап вирусы» сала алсаң, күпләр, файдасын күреп, рухи савыгып, рәхмәтләрен әйтәчәкләр). Моннан ун еллар элек тикмәгә генә мондый юллар язылмагандыр:

Кичәрләр дип, озак еллар күпер салдым,
Эш беткәндә карап баксам, елгам кипкән...
Нур чәчәм дип, гомер буе җырлар яздым,
Томнар чыккач карыйм: укыр җаннар беткән!

Ни өчен? Чөнки үз дәүләтең юк. Телебез декларатив рәвештә дәүләт теле саналса да, асылда, ул үз функциясен үтәми. Телнең иясе — халык, хуҗасы — дәүләт. Нинди имляграфикада язасын да бүтәннәр хәл иткәч, чамалап була... Өстәвенә йотылу, ассимиляцияләшү процессына интеграция, глобальләштерү кебек замана хикмәтләре килеп кушыла... Социологик анализлар ни күрсәтәдер, белмим, минемчә, элек караңгы дип саналган Россия империясендә — Себердә, Идел буе төбәкләрендә, Азиядә — татарча сөйләшүчеләр күбрәк булган. Тел булгач, нигез-тамыр булган, шаулап тормаса да, рухи шытымнар булган. Ә хәзер?..

...Авыр сорау тугач, кәгазь буйлап йөгерек кенә барган Каләм арган ат кебек тукталып кала. Мин дә, урынымнан торып, йөренеп алам. Тәннәр язылып китә. Янәдән тыштагы идиллик күренешкә карап торам. Гаҗәп: көч кереп, уй яктырып китә!

Миллилекне билгели торган кайбер сыйфатлар югалып барса да, гомумән, Җир йөзендә татар кимемәде дип уйлыйм. Бетә торган милләт түгел бу! Күбрәк сәясәт уенына корылган, дөрес үк булмаган җан-исәп алу буенча да хәйранга чыга әле ул! Татарны тикмәгә генә яһүдләр белән ярыштырып тиңләмиләр шул. Яһүдләр дигәннән, гыйбрәт-сабак алырлык охшашлыклар да бар бит. Һәр икәве дөнья буйлап сибелгән, байтагы телен җуя баруга дучар ителгән, гасырлар буе геноцид кичергән... Һәм шул яһүдләр, бер көн җыелып (әле бик ерак тарихта түгел, моннан 60–70 ел элек кенә), дәүләт кордылар, югалган дип әйтерлек алфавитларын торгызып, телләрен яңарттылар, бөтен дөньядан җыйган малларын милли байлык итә алдылар. Бу, мөгаен, гомумтарихта чыгарма хәлдер. Ә начар чыгармамыни! Гаҗәп үзенчәлекле тарихи

катаклизмнар кичергән татарның, чыгармалымы, чыгармасызмы, нигә үз юлы булмаска тиеш ди әле. Милли идеягә, югары үзаңга, олы максатка, бердәм хәрәкәткә ия чакта булмастай нәрсә юк ул! Әлбәттә, иң мөһиме — үзаң. Үткән гасырның совет дәверендә (кайбер халыкларның тәрәккыятен таныган хәлдә) үзаңы үсешенә иң нык киртә куелган халык, мөгаен, татар булгандыр. Чын мәгънәсендә торгынлык (бу сүз безгә бик туры килә) чоры. Шөкер, соңгы дистә елларда, үзаң терелеп, милли яңарыш башланды. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән сорауга анык җавап табылды, ул уянган! Дәлилләрме? Уяну халәте булмаса, төрле кыйтгаларда яшәүче милләттәшләребез уртак мәсьәләләр турында фикерләшергә берничә мәртәбә Бөтендөнья татар конгрессына җыела алырлар идеме? Меңнәрчә мәчетләрнең манаралары кораб-ракетадай күккә төбәлер идеме? Милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә уртак бәйрәм — Сабантуйлар гөрләп үтә алыр идеме? Соңлап булса да Урал буйларында (соңрак Башкортстан дип йөртелгән төбәк) яшәүче татарларга игътибар артыр идеме (ә бит бу төбәктә татарның бик зур потенциалы)? Республика көне оештырылыр идеме? Туган тел бәйрәмнәре (халык бәйрәме дәрәҗәсенә күтәрергә иде бу бәйрәмне. Латышлардагы «Җыр бәйрәме» кебек) үтәр идеме?..

Әйе, халык булып киләчәктә сакланып калу юнәлешендә җәмгыятьнең төрле катламнары арасында билгеле бер уңай аңлашу бар. Зур нәрсә бу. Җитәкчелек белән халыкның берлеге нәтиҗәсендә 90 нчы елларда кайбер биеклекләр яуланды да... Шул нисбәттә пропорциональ каршылык та җитәрлек. Хәтта артыгы белән. Шовинистик даирәләр (күрелмәгән хәл: матбугатта һәм радио-телевидениедә кайбер партия вәкилләренең ачыктан-ачык расистик, фашистик рухтагы чыгышлары еш булып тора хәзер) Россиядә, рустан тыш, милли факторны бөтенләй үк юк итмәкчеләр. Алда бераз әйтелгәнчә, бу мәсьәлә дөнья күләмендә җитди төс алды. Әйтик, Америка бөтен Җир шарын үзенчә әйләндермәкче. Синең телең, рухың, тарихың кирәкме аңа (әнә Иракны нишләттеләр! Кеше хокукларын яклау кирәкме? Юк, нефть кирәк! Бай Америкага тагын да күбрәк байлык кирәк!)? Бөтен дөнья халкын идентификацияләп, компьютер белеме (дөресрәге, үзләренә кирәк информация җыеп) биреп, алардан интер-космополит көч — робот-коллар ясап, җиһангир булу, дөнья белән идарә итү кирәк. Һәр кеше код — «шөреп»

исәбендә булгач, аларны автоматик рәвештә юк итү технологиясен эшләү дә җиңеләя бит!

Менә кайларга кереп киттең бит әле, газиз Каләмем! Сүз башы гадирәк — әдәбият хәлләре турында иде бит. Башы шулай иде дә, ә дәвамы, төбе әнә нәрсәләргә килеп чыкты. Милләт язмышы, балаларыбыз язмышы, тел язмышы... Бу хәл табигый дә. Әйтик, тел — минем эш коралым, ахыр чиктә, яшәү чыганагым, язмышым... Тел — милләтне билгеләүче иң төп компонент. Ягез, туган телләреннән башка французны, немецны яки японны күз алдына китереп буламы? Юк, билгеле. Бу канун җирдәге бөтен халыкларга да кагыла бит! Ә телнең бакчасы ул — мәгълүм хакыйкать — Әдәбият. Кайчандыр дәүләтләрен югалткан, әмма яңарышка өметләнгән халыклар өчен бу бакча — Әдәбият аеруча әһәмияткә ия. Аңа дәүләти институтлар башкарырга тиеш булган кайбер идеологик вазифалар да йөкләнә. Әйтик, бездә дәүләтчелекне тою хисе дүрт-биш гасыр буе югалмаган икән, иң әүвәл без Сүзгә, язуга, Әдәбиятка бурычлы. (Дин факторын да исәпләми мөмкин түгел. Әйтик, телне, әхлакны саклауда аның роле ифрат зур. Соңгы вакытларда мөселманнарның да кайберләре Коръәнне дә русча укып өйрәнүләре генә сәеррәк.) Бәс, шулай булгач, әдәбиятны саклау турыдан-туры милләтне саклау булып чыга түгелме соң? Бер шагыйрь әйтмешли, «ул шулайдыр әле, уйласаң»! Чыннан да шулай. Әгәр Әдәби Сүз бетсә, милли сәнгатьнең бүтән төрләре дә юкка чыга. Иң әүвәл театр бетә, музыка, рәсем һәм башка сәнгатьләр дә, табигый сүлен югалтып, космополитик дәрьяда эри, югала...

Менә шулай, газиз Каләмем! Син кодрәтле дә, хәвефле дә, көч тә бирәсең, исәп-хәсрәткә дә батырасың. Ил теленнән сүз җыеп, арган чакларың да буладыр... Язучының эш нәтиҗәсе — китап. Китап — әдәбиятның таҗы, язучының йөз аклыгы. Бездә гомер-гомердән Китап Сүзе дигән төшенчә яшәп килә. Китап сүзе, ягъни кануни сүз. Коръәннең бер сүрәсендә «кыямәт көнендә һәр халык үз китабы белән кубарылыр» дип тә әйтелгән бит әле! Без үскәндә һәр җәмәгать урынында, үткән гасыр термины белән әйтсәк, һәр кызыл почмакта, «Китап — белем чишмәсе» дигән шигарь-язулар эленеп тора, яше-карты шул өндәмәгә тугрылыклы булырга тырыша иде. Кызганыч, идеяләр, идеаллар үзгәрә-үзгәрә, акчага табыну иманга әверелә барган заманда хәлләр нык үзгәрде. Елында түгел, гомерендә бер генә татар язучысының китабын да укымаган (хәтта тәрҗемәдә дә!) бәндәләр

ишәйде. (Шунысы көлке: шундыйларның кайбер активистлары татар зыялыларына нинди алфавитта язарга өйрәтеп маташа!) Татар мәктәбен бетереп, татар мохитендә яшәп, бүгенге әдәбияттан бөтенләй бихәбәр эреле-ваклы түрәләр ничаклы! Бер генә данә «Казан утлары»н алмаган татар авыллары бар. (Сүз уңаеннан әйтеп узыйк, Кама аръягы, Тау ягы районнарында әдәби журналлар, шул исәптән безнең журнал да начар тарала. Нәтиҗәсе хәзер үк күренеп тора: бу якларда яшь әдәби талантлар күренми диярлек. Димәк, җирле түрәләр, мәгариф һәм мәдәният җитәкчеләре тарафыннан әдәбиятыбызга мөнәсәбәт шуның кадәрле генә.) Хәтта әдәбиятның, бигрәк тә бүгенге әдәбиятның көзгесе булган журналыбызны кулына да алмаган татар теле һәм әдәбияты «укытучылары» бар. Әйе, «юк»тан да яманрак әнә шундый «бар»лар да җитәрлек шул. Вазгыятькә фаҗигаи төсмер бирергә теләмим. Сүз тәмен тоючылар, китап кадерен белүчеләр, әдәбиятның тәрбияви ролен тирән аңлаучылар да байтак. Шигырь юлларын ташка, агачка чокып уючы ир-егетләребез, сүз энҗеләрен кулъяулыкларга, сөлгеләргә чигүче кызларыбыз да яши арабызда. Шөкер, туган телдә бишек җырларын көйләп, сабыйларын юаткан аналарыбыз бар. Дәүләткүләм бәяләргә лаек яңа әсәрләребез бар. Әмма...

Әгәр без, бердәм булып, Әдәбиятны (китапны) милләтне саклауда һәм үстерүдә иң төп чыганакларның берсе дип саныйбыз икән, вазгыятьне һич кенә дә үз агымына куя алмыйбыз. Планета коммуникаль бәйләнеш ягыннан «кечерәеп» һәм «ачыгаеп» калганда (кирәксә, космостан авылдагы өеңнең морҗасын да күрәләр бүген!), халыкара аралашу тәртипләре, алда әйтелгәнчә, аз санлы яки державага ия булмаган халыклар өчен торган саен кырысрак, рәхимсезрәк төс ала башлады. Без Гаяз Исхакый юраган инкыйраз рас киләме-юкмы дип яки «уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк» җырын шыңшып, тез кочаклап, оеп утыра алмыйбыз. Максатчан актив хәрәкәт кирәк. (Җан башына туган телдә чыккан китап исәбе бездә алдынгы илләрдәгенекеннән шактый түбән икәнен дә онытмыйк!) Күрәсең, милли китап үсешен тәэмин итәрлек дәүләти махсус Программа булдыру зарурдыр (әйтик, тузган торакны бетерү кебек нәтиҗәле Программа). Китап чыгару, китап тарату, гомумән нәширлек эше сәясәтен үз кулында тоткан махсус координацион Үзәк кирәклеге үзен бик нык сиздерә. (Дәүләт структураларында эшне белеп алып баручы милли рухлы җитәкче кадрлар җитенке-

рәми әле. Совет заманындагы кайбер эш алымнарының тәҗрибәсен өйрәнү дә һич комачау итмәс иде бүген.) Әлеге Үзәк (ничек дип аталуына карамастан) реаль ихтыяҗны өйрәнеп (элек нәшриятның тематик планнары буенча җирле оешмалардан реаль заказлар җыйнала иде, тираж комиссияләре эшли иде), мөмкинлекләрдән чыгып, халык ихтыяҗларын үтәү, тиешенчә тәэмин итү вазифаларын да башкарыр иде...

Гомумән, татар китабы — газаплы, авыр язмышлы, данлы тарих. Башлангычы да (XVIII гасыр башында басмаханәләр ачарга рөхсәт алгандагы кимсетелүле хәлләр турында мәшһүр галимебез Ә. Кәримуллин тәфсилләп язып калдырды), бүгенгесе дә... Язучы һәм башка сәнгатькяр дә, үз эшенең киләчәккә кирәклеген тоймаса, эшли алмый, иҗат итә алмый. Әдәбиятмәдәният өлкәсендә хәл итәсе мәсьәләләр күтәрелгәч, гадәттә, «базар» дигән сүз калкып чыга. Базар мөнәсәбәтләре хәзер, барысын да шул хәл итә, базар шартларында яшәргә өйрәнегез, диләр. Элек тә булган ул базар. Бар һәм булачак. Исәпләшми булмый: яшәешнең матди бер «чыгыры» инде ул. Әмма базарга иман кирәкми. Базар ансыз да яши. Ә кешегә — кирәк, кешегә күп нәрсә кирәк. Җанлы сүзе дә, ягымлы көе дә, күңел байлыгы да... Байлык димәктән, узган гасыр башында да булган ул байларыбыз. Булган төрлесе, булган мәгърифәтлеләре, булган «каралары». «Ак» байлардан хәтер булып мәдрәсәләр, мәчетләр, китапханәләр калган. Ә фәкать мал өчен генә яшәгәннәренең исемнәре дә нәмәгълүм диярлек. Тирәнтен уйлап баксаң, татарның төп байлыгы — фәкать рухи мирас кына. Җырлар, көйләр, китаплар... Безгә мирас булып калган рух байлыгын тудыручыларны кемнәр ничек кенә санаса да, барыбер, исемнәр бер тирәдә булыр. Алар — Тукай, Исхакый, Сәйдәш, Җиһанов, Урманче... Хәер, империя шартларында бүтән байлыкның, матди милли байлыкның, дип әйтүем, булуы да мөмкин түгел бугай (әнә Мәскәүдә Әсәдуллаев йортын татарлар һаман үзләренеке итеп бетерә алмыйлар әле). Ә бүгенге, зур хосусый байлыкларга ия яшь байларыбызга килсәк, алар турында ниндидер фикер, бигрәк тә уңаен әйтергә иртәрәк әле. Күбесендә — «кыргый базар» шаукымында гади халыкның «күзен буып», алдап-йолдап җыйналган байлык. Капитал туплауның да үз кануни традицияләре, үзенә генә хас этик кысалары, әйтер идем, үз культурасы бар. Киресенчә икән, димәк, исраф итү культурасы да юк дигән сүз. Хәрам кергән малның, гадәттә, бәрәкәте

булмый, тиз әрәм-шәрәм ителә яки «этләргә» кала… Бу хакта сүз куертып та тормас идек тә, юк шул, китап чыгару өчен дә чыгымнар, байтак чыгымнар кирәк. Ярый да хәзергә дәүләт өлешчә булыша, ә беркөн килеп андый мөмкинлек бетсә яки «бик өстән» бетерттерелсә? Ирексездән меценатлык мәрхәмәтенә өмет тотачаксың. Ә бармы соң ул бездә меценатлык? Меценатлык дәрәҗәсенә күтәрелер өчен, малтабар кеше үзе дә күңеле белән күпмедер дәрәҗәдә шагыйрь, музыкант, рәссам, артист булырга, һәрхәлдә, рух дөньясын, сәнгатьне тоярга, аңларга тиеш. Кайда сез, бүгенге Рәмиевләр, Хөсәеновләр, Кәримовләр, Юнысовлар, Акчуриннар?

Сәнгать әсәре — кем өчендер товар. Әйе, бер караганда, товар да. Оста тарафыннан бердәнбер данәдә ясалган (язылган) бәһале товар. Китап рәвешендә меңнәрчә тираж белән чыгарылганнары чыннан да товар. Шул ук вакытта ул товар да түгел. Бөек әсәр бәясез ул! Уй-кичерешләрне, шатлык-кайгыларны үлчәр берәмлек юк.

Ике хәзинә бар дөньяда, саклагыз!
Каберстан — аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә — икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр…



*Равил Фәйзуллин үз китаплары куелган күргәзмә-стенд янында. Казан, Тукай музее, 1999*

Бүгенге көндә гомерен язучылык эшенә, әдәбиятка багышларга алынган кеше — фидакарь зат ул. Әшәкелек күзгә кереп торган заманда якты шигырь язу — үзе бер батырлык. (Дөрес, кайбер спектакльләрдә, аерым әсәрләрдә — аңлапмы-юкмы — шагыйрьне ниндидер зәгыйфьрәк зат, наив, беркатлы итеп күрсәтүчеләр дә очрый. Күрәсең, андый иҗатчылар чын шагыйрьне белмиләр.) Үзен зур миссиягә әзерләгән кеше генә чын язучы була ала. Кемнәрнеңдер күзлегеннән караганда, яшәештәге рейтингы зур булмаса да, бай һәм тук яшәмәсә дә, шушы хаос, имансыз заманда халык күңеленең елъязмачысы, алай гына да түгел, халык рухының байракчысы булырга омтылу пәйгамбәрләргә хас сыйфат. Тарихи җаваплылыкны, авыр миссияне кемнәрдер алырга тиештер бит! Кемнәр соң алар? Җирле хакимият түрәләреннән берәрсеме? Депутатмы? Банкирмы? Шикләнәм...

Газиз Каләмем! Хискә бирелебрәк салулап китмәдеңме? Артык катгый сүзләр тезәсең түгелме? Халык рухының байракчысы!.. Бик зур сүзләр бит... Бәлки... Хезмәтең язмышыңа әверелгәндә, сайлаган юлыңны идеаллаштыру да булырга мөмкиндер. Әлбәттә, тарихи миссия кебек категорияләр белән сөйләгәндә, Шәхес факторы алга баса. Шәхес юк икән, әллә нинди юл, әллә нинди профессия сайла, һични барып чыкмас. Шәхес бар икән, яшәеше тормыш үзәгендә булып, халыкның иң мөкатдәс теләкләрен эшкә ашырып, киләчәк өчен бөек гамәлләр кыла икән, андый Шәхеснең байракчы саналуы гаҗәп түгел. Әйтик, Минтимер Шәймиев соңгы дистә елларда татар халкының байракчысы түгелмени?! Җир шарының төрле почмакларында ул халык вәкиле, аның илчесе булып татарны танытмадымыни? Шулай, Вакыт галиҗәнаплары билгеле бер илнең, билгеле бер дәвернең символ ияләрен үзе сайлый.

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.
Вакыт-Яу — иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны.
Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
данлы исемен алып кала.

Булды заманнар — теге яки бу халыкның байрак-символы итеп бөек шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, сынчылар, гомумән сәнгать кешеләре саналды. Итальян Данте, ис-

пан Сервантес, әзәри Физули, рус Пушкин, украин Шевченко кебек даһиларны искә алып китик тә, үзебез яшәгән чорда иҗат иткән, үзләре белән беркадәр аралашырга да туры килгән бөек язучыларның кайберләрен барлап узыйк. Алар да шул когортадан!.. Дөнья алдында үз халыкларының тулы вәкаләтле вәкилләре, илчеләре. Кыргыз Чыңгыз Айтматов, авар Рәсүл Гамзатов, калмык Давыт Көгелтинев, рус Александр Твардовский, башкорт Мостай Кәрим, казакъ Олжас Сөләйманов... Ә үзебезнең Тукай, Җәлил шул миссияне башкармадымы? Шөкер, маяк саналырлык үрнәкләр бар. Булган һәм булачак алар. Шәхес кенә бул, үлемсез әсәрләр генә иҗат ит! Вакыт Кояш астындагы тарихи урыныңны үзе билгеләр ул!

Язучы исеме, язучылык хезмәте моңа кадәр һәр халыкта да дәрәҗәле саналды. Ерак гасырлардан бирле. Ул шагыйрь дип аталамы, чичән яки акынмы, халык аларны үз итте, хезмәтләреннән гыйбрәт-сабак алды, әйткәннәрен күңелендә йөртте, мирас-васыять итеп балаларына сөйләде... Килешмәгән, хәтта дошман очракта да хаким-хөкемдарлар санлашырга, исәпләшергә мәҗбүр булды алар белән. Юкса шагыйрьләрне хандай зурламаслар яки иленнән сөрмәсләр иде, төрмәләрдә череtмәсләр, асмаслар-кисмәсләр иде! Шулай да Дөнья гел хәрәкәттә, гел әйләнештә. Мәңгелек дип саналган аксиомалар да үзгәреш кичерә. Язучы дигән атамада да мәгънәви үзгәрешләр бар. Инглизләрдә writer (райтә) сүзе, язучы дип тәрҗемә ителсә дә, мәгънә спектры үзгәрәк... Монысы бер хәл булса, үзебезнең халыкта да язучы сүзенә караш беркадәр үзгәрә башлады кебек. Сәбәпләре бар. Мәгълүм гыйбарәне үзгәртебрәк әйтсәк, «килде бер көн, язучылар йөрер төркем-төркем». Дөресрәге, үзләрен язучы санаган графоманнар армиясе нык ишәйде. Андый төркемнең булуы гаҗәпләндерми дә, һәрчак булган алар (хәтта булырга тиешләрдәдер), ләкин пәри башка, җен башка дигәндәй, элек алар, гадәттә, үзешчән статусында иделәр. Көндәлек матбугатта, күмәк җыентыкларда басылгалыйлар иде, әдәби мохитнең күренеш-фонын тәшкил итәләр иде. Ә хәзер... күбесенең амбицияләре бөтенләй бүтән! Акча юнәтеп (өлгер, булган халык!), төрле басмаханәләрдә бер-бер артлы китапны чыгарып кына торалар! Калын итеп чыгаралар, яхшы кәгазьдә, матур бизәкле итеп... Аннан Язучылар берлегенә керүне максат итеп куялар. Язучылык билеты чын язучы итә дип уйлыйлардыр инде (әнә, кесәсендә язучы билетын

йөртмәгән, оешмада рәсми әгъза булып тормаган Зөлфәт Хәкимнән Бөтендөнья татарлары конгрессында барлык язучылар, гомумән интеллегенция исеменнән чыгыш ясавын сорадылар һәм ул менә диган нотык тотты). Өстәвенә бу «актив язучылар»ның күбесе иҗат эшенә пенсиягә чыккач тотынган иптәшләр. Әйдә, җаны теләгән елан ите ашаган, язсыннар рәхәтләнеп, дияр идең дә... Алай да булмый. Халык алдында әдәбиятның дәрәҗәсе төшә, китапның абруе кими. «Кар башына кар җитә» дигән гыйбарә бар; шуның кебек, эшләр болай барса, «китап башына китап җитә» диярсең! Чүп үләне баскан басуны күргәнегез бардыр, кайда бодай анда, кайда сарут та билчән... якын килеп карамасаң, белмәссең дә, еракта һәммәсе ямь-яшел булып үсеп тора!

Әдәби мохит, китап дөньясы чүпләнүнең икенче бер әшәке формасы да бар әле бездә. Ул кеше өстеннән әләк, шикаять, донос язу. Нинди генә негатив фактлар табылмый да кайларга гына (министрлыкларга, прокуратураларга, төрле дәрәҗәдәге президентларга...) язылмый алар! Дәүләт структураларында интеллектуаль өлкәдә аннан башка да бик аз сандагы җитәкче хезмәткәрләрнең күпме вакытын, күпме җегәрен ала ул «гаделлек сагында» торучы яла ягучылар! Мәхкәмәләргә дә тынгылык юк, процесс арты процесс... Әлбәттә, әдип кеше, талантлы кеше шөгыльләнми моның белән. Ул кирәген, күңелендәгесен ярым аноним шикаятьләр белән түгел, кешеләргә турыдан ярып әйтә. Шикаятьчелек белән әлеге дә баягы көнләшү катыш амбициядән чирләүче, русча әйтсәк, окололитературный контингент шөгыльләнә дә инде. Бу чир, кызганыч, галим-голәмә арасында да җитәрлек икән. Бер-берен хурлаган, хәтта дошманлашу дәрәҗәсендә ярсыган бәгъзе адәмнәрнең матбугатта (татарча гына җитми, күбрәк русча матбугатта «бугазлашалар», ишлерәк кеше укысын, татарның үзара талашын күбрәк кеше белсен!) чыккан язмалары укшыта кайчак... Кораб давыл-штормда бату хәлендә чайкалганда, кемнәрнеңдер, каюташханәдә тиешенчә ашатмыйлар, компотка җимешне җитәрлек салмыйлар, дип, коры җир — материкка жалу язуы белән бер бу гамәлләр. Күрәсең, рух-иман юлында, «кеше җаны өчен көрәш»тә, акыл-фикер бәрелешендә шайтан вәсвәсәсе булмый калмыйдыр. Иблис тә фәрештә санала түгелме соң? Бер яктан, әлеге тискәре күренешләр бик аяныч булса, икенчедән, язу эшенең, иҗат эшенең күпләр өчен никадәр кызыктыргыч мөһим, никадәр җаваплы һәм дәрәҗәле миссия икәнен дә күрсәтә.

Ширбәте булган чәчкә тирәсендә генә бал кортлары оча, шулай ук чебен-черкие дә...

Иҗат итү — илаһи халәт, кеше акылының җиңүле тантанасы. Иҗат — илһам дигән күңел дәрте белән бәйле рухани акт. Шуңа күрә үтә индивидуаль, серле, тылсымлы шөгыль дә инде ул. Галимнәр арасында бөекләрнең иҗат лабораториясенең хикмәтләрен ачарга омтылучылар бар. Әлбәттә, иҗатның кайбер тенденцияләрен, алымнарын, стиль рәвешен һ. б. ачыкларга була. Әмма кош юлының эзен «тотып» булмаган кебек, иҗат процессының төбенә төшү дә мөмкин эш түгел. Еш кына автор үзе дә бер нәрсә турында язарга тотынып, башта уенда да булмаган әллә нәрсәләргә килеп чыга... Хикмәт! Шулай да әдәбиятта сер булмаган тәртипләр, кагылгысыз традицияләр дә бар. Әдәбиятта иң элек әдәп булырга тиеш. Әдәбият багына, гыйбадәтханәләргә кергән шикелле, чиста күңел, изге уй белән керү мөһим. Бу бакчага кергәннәр нәрсә яхшы, нәрсә яман, нәрсә ярый, нәрсә тиеш түгел кебек сорауларга җавапларны алдан ук белеп керергә тиешләрдер. Сүз эстетик идеал, әдәби этика, профессионализм кебек төшенчәләр турында бара. Хәзер, сүз иреге дип, теләсә нәрсә турында, теләсә ничек язгалаучылар барлыкка килде. Әдәбият бүген генә яралмаган, үткән юлы аның әллә ничә мең еллар. Татар әдәбиятының традицияләре дә, Аллага шөкер... Укы, бел, гыйбрәт ал. Әлбәттә, әйтелгәнчә, читтән яки өстән кушып, диктат белән иҗат итү мөмкин түгел. Өндәмә белән генә булса, совет чорында партиянең «әдәбият-сәнгатьне үстерү турында» чыккан бихисап карарларыннан соң әллә никадәр шедеврлар туар иде. Иҗатны стимуллаштырып була. Конкурслар, иҗади ярышлар, фестивальләр, премияләр... Әдәби хәрәкәтне идарә итү (элек без ышанганча) мөмкин үк булмаса да, булган әдәби байлыкны анализлап, орлыгын кибәктән аерып, халыкка аңлатып, яшь талантларга булышып була. Бар әдәби җәмәгатьчелек, бар иҗади оешма, бар әдәби профильдәге журналлар... Бу өлкәдә һәммәбезгә дә эш җитәрлек. Бу — корылтайлар, семинарлар, утырышлар кебек компания рәвешендә генә түгел, әдәбиятта үз җаваплылыгын тойган һәркем өчен көндәлек даими эш булырга тиеш.

...Алдымдагы кәгаземнең байтак битләре шыплап тулды. Ә тәрәз алдымдагы күренеш һаман шул: ап-ак килеш. Дөньяда Яңа ел икән бит! Күпләр шуның хозурында. Күңелем белән үзем борын заманнардагы ерак бабаларым көтеп

алган Яңа ел — Нәүрүз ягында. Яңа елның яз булуы табигый. Шәрык илләрендә ул шулай да. Яз, чыннан да, яңа фасыл булып, яңарыш циклын башлый. Җиргә орлык чәчелә, кошлар кайта, табигать уянып, яшелләнә, күңелләргә яңа дәрт өстәлә, өмет-ышаныч арта. Зәмһәрир кыш уртасында, суыклар, бураннар котырган көннәрдә, менә, апай, пәрәмәч! дигәндәй, менә сиңа Яңа ел! Вакытны болай сындыру мизгелен шартлы рәвештә биле өзелергә җиткән кыска көннең тулыша башлау вакыты дип аңлатсаң гына инде... Хәер, аны Раштуа, Христос тууы белән бәйлиләр, европалылар гадәтен Россиягә Петр патша кертkән, диләр. Шулайдыр. Күбебез бу хакта уйламый да инде. Яңа ел тек Яңа ел. Яшәгән дөньяң, бөтен тирә-юнең гөрләп мәш килгәндә, бәлки, безгә дә, бәйрәм рәвешен китереп, бераз ял итеп алырга ярыйдыр?

Шулай дип яздым да тәрәзәдән күренгән тышкы аклыкка карап алдым, аннары янәдән алдымда яткан кәгазьләремә текәлдем. Йә, нишлибез, газиз Каләмем? Җиң сызганып эшлибез, дисеңме? Әйдә, шулай булсын!

*2004, гыйнвар*

## ИЛЕ БАРНЫҢ — ТЕЛЕ БАР

*Җир кемнеке булса,*
*җил — шуныкы.*

Тел дигән Бөек Хәзинә турында яңа нәрсә әйтеп була икән? Читен эш. Ә әйтергә кирәк. Бүген әйтмәсәк, иртәгә соң булуы бар. «Сүзнең атасы — акыл, анасы — тел» дигәннәр борынгылар. Бар булган акыл белән, киңәш-табыш итеп уйлану-фикерләшү өчен, әнә шул Ана дигәннәренә, баш иеп дигәндәй, якынрак килеп карыйк әле...

Әйе, телне бөек хәзинә, байлык, диләр. Ә Табигатьтәге һәр нәрсә үз урынында, үзенчә байлык түгелмени? Һәркайсының үз үлчәү-бәяләү берәмлеге. Тауларның биеклеге, җимешнең тәме, диңгезләрнең тирәнлеге, йолдызларның яктылыгы, далаларның киңлеге... Ә тел байлыгын, тел кыйммәтен ничек бәяләргә? Сүзләрнең күплеге, сөйләшүчеләрнең ишлелеге беләнме? Озак яшәүчәнлеге, кешелек тәрәккыятенә керткән өлеше беләнме? Бу әйтелгәннәр тел зурлыгын дәлили тасвирласалар да, барыбер төгәл билгеләмә үк түгел. Һәр тел — үзенчә бөек. Җәмгыятьтә урын торткан һәр тел турында, бәлки, гади генә болайрак әйтеп буладыр: тел ул — иксез-чиксез, төпсез-кырыйсыз, хисапсыз-бәясез...

Җир йөзендә телләр бик күп. Аларның төгәл санын әйтү дә кыендыр. Бериш галимнәр алты мең ярым тел бар дип исәплиләр. Бар миллиардлап кеше сөйләшкән кытай, инглиз телләре, бар берничә мең, хәтта берничә йөз кеше сөйләшкәннәре... Мисалга ерак барасы түгел, үзебезнең Казаныбызда борынгы ассирия телендә сөйләшүче берничә дистә гаилә бар.

Төркем-төркем кошлар һавада!
Шуларның берәрсе
минем телдә сөйләшәдер күк.

Ә үзебезнең — татар теле дип йөртелгән Туган телебез ни хәлдә соң бүген? Заманында халыкара телләрнең берсе булган, хәзерге көндә дә бөтендөнья күләмендә сөйләшер өчен уңай ун-унбиш тел арасында саналган, җәмгыять яшәеше барышын бөтен тулылыгы һәм нечкәлекләре белән чагылдыра алырлык бихисап сүз байлыгы булган Ана телебезнең бүгенгесе ничек тә, киләчәге ничегрәк булырга охшый? Сораулар катлаулы һәм авыр. Әнә шул билгесез авырлык каләм алырга мәҗбүр итә дә инде. Телнең бөеклеге,

байлыгы, үлемсезлеге, бердәнберлеге, көч-кодрәте, тылсымы турында абстракт фәлсәфә, рәхәт оета торган вәгазьләр чоры үтте. Әгәр телне милли үзаңны билгеләүче бер төп күрсәткеч дип санайбыз икән, безнең хәлләр бүгенгә мактанырлык түгел. Халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул — тулы милләт, яртысы сөйләшә икән — ярым-йорты милләт, ә биштән бере сөйләшсә... Безгә хәзер, чаң сугып, «Уян, татар!» дип кенә түгел, «Тел сагына бас, Татар!» дияр чак җитте. Телебез аңлауга, ярдәмгә, яклауга мохтаҗ.

Көелә утларда,
сандалларда таптала,
ярыла сәяси тегермән-ташларда...
Имгәнә, сызлана, көрәшә,
яңгырый алыр хокук өчен.

Хакыйкатьнең күзенә карау җиңел түгел. Күп нәрсәләрне танып, тәкрарлау авыр булса да, моннан күп еллар элек бер студент шәригемә хатта әйткәндәй, «Ирләр булыйк!», реалист булыйк, дөресен әйтик. Дөньялыкта глобаль процесслар бара. Кеше дигән зат, Бөек Табигатькә зыян салып, яшәү сутын җимереп (иң аянычы, бер аңда яралган адәми кардәшләрен үтереп), экологик фаҗигагә — ахырзаманга барса — анологик процесс Рух Дөньясында бигрәк тә кызу бара. Гамьсез, ваемсыз җаннарыбыз әлегә артык сизми аны яки сизмәмешкә салыша. Сер түгел: үзләрен дөнья тоткасы санаган илләр, аз санлы халыклар телен үз «тегермәннәре» аша («на мельнице русской смололи заезжий татарский язык») үткәреп, бөтенләй таптап, бетереп бара. Кайбер «табышка» әверелгән фактларны (үзебезгә инъекция рәвешендә!) искәртеп үтик: Ана телебезнең бөтен нечкәлекләрен тойган, кабатланмас аваз аһәңе белән ләззәтләнгән укучылар катламы бик юкарды; чын әдәби китапларны (китап рәвешендә дөнья күргән чүп-чарны әйтмим) укучылар ник кимеде: милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдән әдәбият-сәнгатебезгә килгән яшь талантлар ифрат сирәгәйде...

Үткән егерменче гасыр, тел җәһәтеннән (бөтентатар җәһәтеннән түгел микән?) безнең файдага булмады. Элегрәк заманнарны никадәр генә караңгы итеп күрергә тырышмыйк, кайтып булса да таныйк: милли тамырлар ул чакта ныграк, саурак булган. (Ерак Көнчыгыш, Кытай, Япон илләрендә яки Төркестан, Кавказ якларында үзенең икътисади базасы, мәдәни учагы, басма китабы, театры, мәхәлләсе булган тулы

канлы татар даирәсен күреп буламы соң хәзер?) Татар Конгрессларында, төрле милли җыеннарда берәм-сәрәм шытым-«курпылар» күренгәләп, чыгышлар ясаштыргаласалар да, чынында тамыр-зәмин, нигездә, корыган... Гомумтатар әдәби теленең барлык этник төбәкләрдәге үзенчәлекләрен бар тирәнлеге һәм байлыгы белән Идел-Урал, Казан төбәге тирәсендә генә саклау кыен... Соңгы елларда бар булган дәрман белән Казаннан читтә яшәүче кардәшләребезгә игътибар (шәмдәлләргә соңгы май тамызу булмаса ла!) артты артуын. Әмма бу бөек миссиягә тартым хәрәкәт мәгълүм бер кампания уңаеннан гына булып, даими, эзлекле гамәл булмаса, уңай нәтиҗәләр бик чыкмас.

Йодрык — төен. Ул язылса —
аерылыр бармаклары...
Өчпочмаклар булып калыр —
өзсәң йолдыз канатларын.
...Бүлсәң бишкә бер халыкны,
аннан исем калыр бары...

Ананың балага биргән иң зур бүләге — тел. Шуңа да ул байлык, хәзинә санала. Ә бүләкне, байлыкны, хәзинәне кадерләп саклый алу, күбәйтә-ишәйтә алу үзе бер батырлык сорый. Файдасын күреп яши белмәгәндә, тиз исраф итү, югалту бик җиңел аны. Телнең үз-үзен саклау «инстинкты» көчле көчлесен (диннәр алышынганда да тел калган!), әмма... Кояш астында һәр халык үзенә үзенчә урын даулый. Җир йөзендәге көрәш-тартышларның, орыш-сугышларның бер нигез сәбәбе, төптәнрәк уйлап карасаң, әнә шул телдә бит инде! Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җыр-моңын, матурлык өлгесен сакламакчы, үзенең яңа токымнарына тапшырмакчы. «Теле барлар — халык булган, теле юклар — балык булган» дигән сүзләр юктан тумаган. Әлбәттә, иҗтимагый күренеш буларак, тел объектив кануннарга буйсынып яши. Субъектив факторның, хәтта бик теләгәндә дә, роле ул хәтле зур була алмый. Әгәр тел сау-сәламәт икән, ул телдә җәмгыятьнең бөтен катламнары сөйләшә: ил башы да, бомж да, сырхау кеше дә, мәхбүс тә, шагыйрь дә... Тел үзенең иҗтимагый функциясен тулы кимәлдә башкара алганда гына мөмкин хәл бу. Әгәр тел кешенең тормыш иҗтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алмый икән, ул аны кирәксенми, яхшы дигәндә дә, аңа битараф кала. (Аяныч булса да, искә төшерик: авылдан шәһәргә килгән сәләтле күпме та-

тар яшьләре тел «казасы» аркасында югары уку йортларына керә алмый калды заманында!) Рухи байлык (бу очракта тел) матди байлык тупларга булышырга тиеш булып чыга. Бу процесс тормышта шул хәтле бер-берсенә керешеп беткән ки, кайчак кайсысының беренчел икәнлеге дә онытылып китә. Бу очракның мисалы шул: яһүдләр, кешелек матди байлыгының иң күп өлешен үз кулларына җыйгач, онытылып бетә язган «үле тел»не — ивритны тергезә алдылар, егерменче гасырга аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрделәр. Үзаң дигән төшенчәне аңлар өчен бик тә гыйбрәтле хәл бу.

Тел — диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас. Күңелдә сызланып йөргән уй-зарларны бер читкәрәк куеп, «ниләр эшләргә, ни гамәлләр кылып була» дигән сорауларга җавап эзләп карау дөресрәктер. Телебез халәтенә дөрес диагноз куярга сәләтле без бүген. Димәк, аны савыктыру өчен дәвасын да бергәләп табу ихтималыбыз бар. Фикри һәм гамәли хәрәкәтләр фарыз. Әлбәттә, уй-фикернең иң беренчесе һәм зурысы — Дәүләтчелек идеясеннән баш тартмыйча, Республика статусын саклап калу. Тел язмышы шушы статуска бәйләнгән. Моның шулай икәнен үткән егерменче гасырның соңгы ун елындагы милли күтәрелеш бик ачык күрсәтте. Кыска гына вакыт эчендә тарихи геннар яңарып, байтак күркәм гамәлләр кылынды. Шул исәптән тел үсеше ягыннан да. Милли идеянең максаты һәм асылы булган Дәүләтчелекнең ышанычлы нигезе ул, шиксез, мәгариф системасы. «Мәгърифәт — азатлык юлында беренче адым» дип тикмәгә әйтмәгән бөек әдибебез Гаяз Исхакый. Мәгърифәт — киләчәккә күпер ул, дип өстәргә генә кала. Мәгърифәт белән һәрчак бергә үрелеп баручы дин тәгълиматыбыз да бар бит әле. Дин — гомер бакый әхлакны һәм телне саклап килде. Соңгы вакытта диннең көчәюе, һичшиксез, телебез үсешенә дә уңай йогынты ясый ала. Мәгърифәт, гомумән тәрбия турында сөйләгәндә, халкыбыз тарихында төп рухи роль уйнаган китап — Галиҗәнап Китап турында аерым әйтеп китү кирәк. Мең еллар буена безнең рухны китап яшәтеп килгән (күпләр өчен заман үрнәге саналган, тарихы нибары ике йөз ел исәпләнгән, җирле халыкны кылыч һәм туп белән кырган Америка җәмгыяте өчен китап нинди роль уйнагандыр, әйтү кыен. Гәрчә бөек язучыларын таныган хәлдә дә, алар инде тарихи мәгънәдәге китаптан җиңел генә ваз да

кичеп киләләр шикелле). Китапта безнең тарих, безнең тел, безнең язмыш. Китап — татар өчен яшәү символы ул! Тел хәзинәсе сагында торган язучыларыбыз моны яхшы аңлыйлар. Халык язучысы Нурихан Фәттах болай язган: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым». Мондый хис әдипләрдә генә түгел, үзен татар дип санаган һәр кешедә булырга тиеш.

Киләчәкнең башы бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнендә —
оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
матур итеп туган телеңдә!

*2002, декабрь*

## ЯҢА ЕЛДА ЯҢАРГАН УЙЛАР

Һәр яңа адым аякларның бер-берсенә таянып алга ыргылганы кебек, һәр Яңа ел да — Искесенең алгарышка таба дәвамы ул. Яңа елда, кичәге-бүгенге мәшәкатьләрдән онытылырга тырышып, матур киләчәк турында күпме генә хыяллансаң да, үткән ел гамәлләре сине барыбер ычкындырып бетерми, ихтыяримы-юкмы, аларны янә бер күңелеңнән кичерәсең.

Үзгә бер алгысыну белән көтелгән, яңа бәхет-шатлыкларга өмет ителгән Яңа гасырның беренче елы ничек үтте? Теләкләребез кабул кылындымы, фаразлаганнар тормышка аштымы? Һәркем үзенчә җавап бирер. Шулай да галәми-гавами фикер йөртсәк, болайрак әйтергә мәҗбүрбез: шомлырак башланып китте бу XXI гасыр дигәннәре. Бер кар китеп, икенче кар яткан аралыкта, бигрәк тә җәй-көз фасылларында, дөнья масштабындагы хәвефле, канлы вакыйгалар артыгы белән күп булды шул. «Глобаль катастрофалар булмагае» дигән шик күңелләргә үтеп керде, өченче бөтендөнья сугышы башлану чигенә җителде. (БМО мәгълүматларына караганда, җирдәге халык бер ел эчендә илле млн. чамасы кешегә арта икән. Димәк, җир тыгызлана, яшәү пространствосы кысыла, кояш астындагы урын өчен көрәш-дау көчәя, терсәккә терсәк ныграк тия, йөрәкләр ярсурак тибә!..) Тулы бер кыйтгалар, системалар, диннәр арасында нәфрәт пәйда булды. Американың һәм Көнбатыш христиан илләренең мөселман дөньясына элек-электән килгән кырын карашы үткән ел үзенең апогеена җитте. Илбасар-атаман державалар «терроргa каршы көрәш» сылтавы белән аерым бер халыкларны, дәүләтләрне юк итү гамәленә керештеләр. Сугыш, үлеш-кырылышлар, нигездә, диндәшләребез яшәгән җирләрдә бара. Ничә дистә елларга сузылган Әфганстандагы мәхшәр, Чечня-Ичкериядәге геноцид, ватаннары «диннәр бишеге» булган фәләстинлеләр язмышы. Шуңа өстәп Балкандагы албаннар, Кытайдагы уйгырлар, Һиндстандагы кашмирлыларның аяныч хәлләре... Һәр илнең, һәр халыкның үзгә ярасы, үзгә фаҗигасе. Тик бер уртаклык: атышлы-орышлы сугыш хәлләре, нигездә, таулы илләрдә бара. Янар таулар... Яралы халыклар... Янаулы йөрәкләр...

Үз ватаныбыздагы үткән елгы вазгыять-хәлләрнең дә күбесе күңелләргә бәлзәм булып ятты димәс идем. Милли җанлы татар кешесенең дәртен сүндерерлек байтак акция-



*Татарстан белән Россия арасында төзелгән шартнамәгә кул кую. Мәскәү, 1994*

гамәлләргә, борчу-мәшәкатьләргә юлыктык. Моннан ун еллар элек күңелләребездә горур бөркет булып очкан мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә омтылыш хисе соңгы елларда күшегеп, бәләкәйләнеп, хәлсезләнеп калды. Татарстан күп дистә еллар буе СССРдагы союздаш республикалар хокукына дәгъва кылса (халыкара масштабта алар кая ыргылдылар да, без кайда калдык...), хәзер элеккеге автономия кысаларына (түбәнрәк булмаса!) тәмам әйләнеп кайтты бугай. Халык ихтыяры һәм парламент кабул иткән Конституциянең күп маддәләре (алар кырыктан артык) капылт үзгәртелсен, хәтта кайберләре мәхкәмәгә бирелсен әле! Хәтта Татарстандагы мәктәпләрдә татар теле укыту мәсьәләсе дә суд залларында күтәрелде. Кыскасы, 90 нчы елларда яулап алынган хокуклар кире тартып алынды, кануннар коллык психологиясенә туры килә торган итеп тәмам «тәңгәлләштерелде». Татар халкын рәсми рәвештә, ачыктан-ачык төрле этник төркемнәргә ясалма бүлгәләү бара. Хәтта нинди графикада язу-язмау кебек һәр халык фәкать үзе хәл итә торган мәсьәләләр дә «Ак патша» пайтәхете кулына күчте. Кайбер шовинистик сәясәтчеләр, үз башына ашкынган козгын кебек, Татарстанның республика булып яшәренә күп калмады инде, дип тә каркылдыйлар...

Дөньяга һәркем үз оя-мөнбәреннән бага, биеклегенә карап офыкларны ачыклый, ихтыяҗына күрә максат-таләпләр куя. XXI гасырның өермәле чатына чыгып җиткән татар язучысын, гомумән каләм ияләрен ниләр борчый соң бүген, яңа һәм алдагы еллардан ниләр өмет итә ул? Гомумән, язучының җәмгыятьтәге роле нинди дә хезмәтенең хаҗәте ни дәрәҗәдә? (Без үскәндә «язучы булам!» дию хәтта якын кешеңә дә әйтергә базылмый торган татлы хыял иде! Бармы хәзер андый хыялый үсмерләр?)

Язучы — асылда, елъязмачы ул. Язучы үз халкының тарихын язарга тырыша, аны бүтән милләт-кавемнәрдән ким итеп күрмәскә тели. Әлбәттә, үзенең табигый миссиясен үтәү өчен аңа да, кәгазь-каләмнән тыш, тән-җан саулыгы, горур басып йөрерлек дәрман-барлык һәм, ахыр чиктә, киләчәккә ныклы ышаныч кирәк бит! Чын язучы милләт язмышы белән яши. Ә милләт кая бара? (Бәлкем, кеше дигән «homo sapiens» заты клонлаштырылган заманда бу төшенчә кемнәргәдер анахронизм булып яңгырыйдыр? Шулай да кытай, немец, япон, гарәп, һинд, инглиз кебек кавемнәр үзләренең кан белән яратылган исемнәрен һич тә онытырга теләмиләр бугай!) Безнең өчен әлегә җавапсыз иң кыен сораудыр бу. Ни өченме? Гомум ил күләмендә үткәрелә торган кайбер реформа-акцияләрдән туа бу сораулар. Әйтик, үткән ел федераль дәүләт төзелешенең асылын тәшкил иткән — Үзәк белән регионнар арасындагы демократик мөнәсәбәт күрсәткече — үзара шартнамәләр юкка чыгарылды диярлек. Федерация төзү үрнәген күрсәтә башлаган Татарстанның пионерлык әләме кыйшаеп авып кала язды... Янә бер факт: үткән ел Россиядә милли мәсьәләләр буенча министрлык (ул болай да күтәрәмгә калган, вәкаләтләре юк дәрәҗәдә булган идарә структурасы иде) бетерелде диярлек. Шомлы сигнал бу! Димәк, империя стратегиясенә андый идарә-мәшәкатьнең кирәге юк. Димәк, милли проблема да юк! Бүгенге Россиядә миллилеккә күпмедер дәгъва кылучылар кемнәр? Әлбәттә, беренче чиратта сан ягыннан икенче урында торучы татарлар... Өстәвенә, көтмәгән-уйламаганда, газета-журнал, басма-нәшрият әһелләрен аптырашта калдырып, Татарстанның үзендә Матбугат министрлыгы бетерелде. Безне, ягъни матбугат органнарын, аларда эшләүчеләрне, Элемтә министрлыгы карамагына тапшырдылар, авылдагыча әйтсәк, «пушта»га беркеттеләр. Матбугат, ничек кенә димәсеннәр, иң әүвәл идеология, тәрбия үзәге. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Мат-




*Милләтнең җаны — туган телдә*

бугат — безнең шартларда дәүләтчелекнең нигезен тәшкил иткән милли идеяне формалаштыручы бер мөһим үзәк тә әле ул. Шуңа күрә элемтә, идеологияне үткәрүдә мөһим бер хуҗалык структурасы булса да, бу очракта рухи әйдәүче ролен һич тә үти алмый.

Хәер, бүгенге артык буталчык сәяси сәнәгать хәлләренә бик артык тирән кермичә, язучының төп хезмәт нәтиҗәсе булган китапка кайтыйк әле. Мәгълүм хакыйкать: китапсыз — язучы юк! Китапка мөнәсәбәт — язучыга мөнәсәбәт, һәм безнең шартларда тарихка мөнәсәбәт дигән сүз. Шөкер, теләгән кеше өчен бүген китап бар. Яхшылары да җитәрлек. Үткән ел, һәм классикадан булсын, һәм бүгенге әдипләр булсын, байтак яхшы китаплар дөнья күрде. Шулай да китап дөньясындагы проблемалар кимемәде. Беренчедән, нигездә татар яшәгән җирдә — авылларда — китап сәүдә системасының җимерелүе сәбәпле, китапларның укучыларга барып җитүе авырлашты. Икенчедән, китап дөньясы үзе бик чуарланды, художество-эстетик кыйммәте булмаган чүп-чар чын җәүһәрләр белән бер шүрлеккә менде (кыргый базар китапка килеп керде, җөмлә төзи беләме-юкмы, акчасы һәм амбициясе булган байтак адәм үзенең язмасын басма итеп тәкъдим итә башлады). Өченчедән, критерийларның югалуы, әдәби тәнкыйтьнең юк дәрәҗәсендә булуы әдәбият белән кызыксынучыларны, бигрәк тә яшьләрне авыр хәлгә куйды. Өстәвенә гомумтенденция — телевидение, компьютер системасы һәм башка замана могҗизалары китапны кысрыкла-

вын да искә алсак, уйланырлык хәлләр күп. Безнең өчен китапны югалту — милли генетик мирасны югалту, киләчәкне югалту дигән сүз ул. Безнең өчен һәр ел Китап Елы булырга тиеш. Һәм быелгы бу елыбыз да. «Без китаплы халык!» дибез үзебезне; әгәр ахырзаман килә торган булса, ахыргача китап белән бергә булыйк! Коръән сүрәсендәге сүзләр искә төшә: «Һәр халык үзенең китабы янына чакырылып китерелер...».

Яңа елда языла торган мондый баш сүз-язмалар, гадәттә, «ел буена җитәрлек» дәрт бирә торган оптимистик рухта була. Бәлки, ул шулай кирәктер дә. Минеке күңелләргә беркадәр гамь-шом сала торганрак булып чыкты шикелле. Нишлисең, бүгенге халәтебез, вазгыятебез, күрәсең, шулайрак. Әмма күңелләр төшенке үк димәс идем. «Көл, күңел! Дөнья моңы бер безгә генәмени!» Җанны беркадәр тынычландыра торган бер нәрсә — уртаклык. Ни булса да, ил белән, Дөнья белән хәзер. Адәм балалары бер-берсе белән шулкадәр чәбәләнеп бәйләнеп беткән хәзер. Дөньяның бер читендәге яра икенче бер полюстагыларның җаннарында сызлау булып иңри. (Чечнядагы сугыш бөтен Россияне яраламадымы?) Бүгенге заманның тагын бер үзгә ягы: күңелләребездәгене ачыктан-ачык әйтә-белдерә алабыз. Шул җөмләдән халкыбыз язмышы турында да. Әрни-әрни үзебезгә үзебезчә «диагноз» куя алабыз. Димәк, төзәлүгә, терелү-яңаруга өмет бар дигән сүз. (Ә безнең шартларда тулы бер буыннарга бөтенләй тәтемәгән ирек бит!) Әйе, без һәммәбез дөньяга сыналыр өчен яратылган. Һәр аерым затка гына түгел, милләт-халыкларга да карый бу. 2002 ел, һичшиксез, яңа сынау-сыналулар елы булачак. Җиңел булмастыр. Хәер, егылып-торып җиңәргә өйрәнгән халык бит без! Әнә, әле кайчан гына Казанның 800 еллыгы дигәнен күпсенеп үткәрүгә каршы төшкәннәр иде, хәзер 1000 еллыгын үткәрергә әзерләнеп мәш киләбез! Моннан 20 еллар элек Кремль диварларыннан Кол Шәриф мәчете кебек гүзәл корылма күтәрелер дип кайсыбыз гына уйлый алды икән! Быел бөтендөнья татарларының чираттагы Конгрессы булачак. Бергә туплану, уртак максатларны барлауда мөһим бер этап булыр дигән ышаныч зур. Быел халык санын исәпкә алу да булачак бит әле. Ничек кенә санамасыннар, Җир йөзендә татар кимемәс ул.

Әдәби хуҗалыгыбызда да быел истәлекле бәйрәмнәр, зур юбилейлар, киңәш-оештыру җыеннары узачак. Безнең өчен

иң мөһим чараларның берсе ул — «Казан утлары»ның чыга башлавына 80 ел тулу юбилее. Бу дата милли матбугат үсешен күрсәтә торган зур бер әдәби-мәдәни бәйрәм булыр дип уйлыйбыз. Быел шулай ук татар язучыларының чираттагы корылтае узачак. Бу олуг җыенда да әдипләрнең әдәбият турында әдәпле фикер алышулары булыр, киләчәккә бару юллары ачыкланыр дип ышанасы килә.

Өстәп шуны да әйтеп узыйк: журнал үз укучыларын җуймыйча керде бу Яңа елга. Киләчәктә әбүнәчеләребезнең тагын да ишәюе насыйп булсын!

Кешене өмет яшәтә. Өмет ышаныч тудыра, ышаныч — хыялландыра. Ә хыяллар тормышка ашса, бәхет шул инде ул. Ә бәхетле кеше илһамланып иҗтиһат итә: балалар тудыра, иген үстерә, йортлар төзи, үлемсез әсәрләр яза. Адәм баласының яшәү мәгънәсе дә Үлемсезлеккә омтылышта бит! «Күңел һаман алгысына — Матурлыкның алгысына!»

Хәерле Яңа еллар Сезгә, кадерле укучыларыбыз, хөрмәтле каләмдәшләребез!

*2002, гыйнвар*

## ХӘЕРЛЕ БУЛСЫН БУ КӨН!

Хөрмәтле депутат иптәшләр!

Бу сессиядә халкыбыз өчен тарихи мөһим мәсьәлә — аның суверенлыгы, мөстәкыйльлеге мәсьәләсе хәл ителә. Бәйсезлеге, үз дәүләтчелеге булган халык кына чын мәгънәсендә тулы канлы халык дип исәпләнә ала.



*Равил Фәйзуллин — Татарстанның халык депутаты. 1990—1995*

Ихтимал, залда утыручы рус депутатларының күбесе өчен Татарстанның суверенлык мәсьәләсе иң әүвәл матди яки хокукый хәлнең ныгуы белән бәйле булса, безнең халык өчен бәйсезлек — киләчәгебезнең булу-булмавын билгеләүче төп шарт, тормыш алга куйган иң кирәкле хаҗәт, җан-вөҗдан эше. Чөнки күп миллионлы татар милләтенең (гәрчә халкыбызның фәкать чиреге генә бездә яшәсә дә) язмышы бүген бередә — Казанда хәл ителә... Ниһаять, безнең халык та, кайчандыр зур дәүләтчелеге булганын онытып, берничә гасырга сузылган сәяси йокыдан соң — һәрхәлдә, миңа шулай тоела — үзенең суверенлыгын урнаштырырга карар итте. Бу — һәр җитлеккән милләтнең табигый ихтыяры, аның мөстәкыйль үзбилгеләнүгә табигый хокукы. Бу — табигатьтән, кем әйтмешли, Ходайдан бирелгән хокук. Бу хокукны, тәрәккый кешелек кануннары буенча фикерләсәк, бәхәскә, бернинди тавышка-фәләнгә куймыйча гына танырга, кабул итәргә кирәк иде дә бит... Ләкин без үзенә бер төрле сәяси системада яшибез, һәрхәлдә, моңа кадәр яшәп килдек. Анда элементар демократик башлангычлар тоталитар структуралар белән бәйләп-төйнәп куелган иде. Һәм без әле күбебез хәзер дә искечә фикерләү рәвеше белән яшәп киләбез. Суверенитет турындагы Декларация проекты игълан ителгәч, бөтен халыкта давыллы реакция кузгалды. Матбугатта бигрәк тә. Мин татар һәм рус матбугатында

йөзләрчә мәкаләләр, аерым чыгышлар белән таныштым. Темасы бер үк булса да, проблема төрле яссылыкта яктыртылды. Кызганычка каршы, сүз фикерләр плюрализмы турында гына бармый. Еш кына фикерләрнең төрлелеге телләрнең төрлелегенә, милли психология үзенчәлекләренә, фикерләү рәвешенә бәйле иде. Татар матбугатындагы чыгышларны, милләттәшләремнең телдән чыгышларының эчтәлеге күпчелек русларның һәм рус телендә сөйләшүчеләрнең дә аңына барып җитә алмавы бик кызганыч. Ә татарларның абсолют күпчелеге русларның фикерен, нигездә, белә. Һәм кайвакыт үз сүзләренең рус иптәшләр тарафыннан укылмый да, ишетелми дә калуына үпкәлиләр дә. Мондый хәл үзара аңлашып җитмәүгә китерә. Һәр якның аргументлары белән җентекләбрәк танышканда, бер-беребезне яхшырак белә алыр идек. Ә бер-беребезне аңламыйча безгә бүген мөмкин түгел. Шунсыз үзара консенсус, килешү була алмый. Турысын әйтим, Декларация турында фикер алышулар барышында русча матбугатта кайбер шовинистик рухлы мәкаләләр дә күренде. Һәм алар республикада сәяси атмосфераны күпмедер дәрәҗәдә кискенләштерүгә китерде. Суверенитетка каршы чыгучыларны нәрсә куркыта соң?

Мин үзем өчен анализ ясадым һәм аларны якынча өч төркемгә аердым. Беренчесе — Татарстан, үзенең суверенитетын урнаштырган хәлдә, Федерациядән аерылыр дип курку. Икенчесе — суверенитет булганда, башка милләт халыкларының мәнфәгатьләре кысылыр дип шикләнү. Өченчесе — суверенитет урнашкан очракта, бүгенге партократия яңартылган дәүләт системасында үзе өчен яңа структура, җылы урыннар әзерләр, аппарат тагын да ишәер дип сагаю.

Хәзер шул өч моментка тәфсилләбрәк тукталып узыйк. Мөстәкыйльлеккә чыгу — кубарылып дөнья чынбарлыгыннан аерылу, япа-ялгыз гына үзбаш яшәү дигән сүз түгел. Без Федерациягә кердек-чыктык (сүз уңаеннан әйтеп узыйк: без Россия составына солых төзеп кергән халык түгел) дип керделе-чыктылы сөйләшә алмыйбыз. Биредә мәсьәлә андый яссылыкта куелмый да. Сүз «өлкән туган, кече туган» мәгънәсендә түгел, тигезлек, тигез хокуклылык (дуслыкның нигезе — тигезлек), мөстәкыйль булып, бергә-бергә ярдәмләшеп яшәү турында бара. Мәгълүм хакыйкать: рус халкы белән безнең мең елдан артыкка сузылган уртак тарихыбыз бар. Бер уйласаң, рус тарихы — ул байтак дәрәҗәдә рус һәм татар халкы тарихы лабаса. Моннан мең елдан артык элек булган вакыйга турында бер язма искә төшә. Милади белән 985 ел. «И заключил Владимир мир с булгарами и клятву дали друг другу, и

сказали булгары: «Тогда не будет между нами мира, когда камень станет плавать, а хмель тонуть» («Повесть временных лет»). Хикмәтле, гыйбрәтле сүзләр болар. Димәк, безнең бик борынгы бабайлар бүтән халыклар белән менә диган дуслык килешүләре төзи белгәннәр бит! Нәрсә, суверен Татарстан бүтән республикалар белән һәр якка да файдалы килешү-договорлар, шартнамәләр төзи алмас микәнни?

Тагын шуны да искәртеп узасы килә: бар «Русь», бар «Россия», бар «РСФСР»; онытмыйк — алар тәңгәл төшенчәләр түгел. РСФСР — ул рус халкының гына түгел, башка милләтләрнең дә тарихи территориясе. Хәзерге бу административ берәмлектә сан ягыннан руслардан гына калыша торган татар халкы өчен бу факт аеруча мөһим. Без үзебезнең тарихи җирлекләрдән керәбез-чыгабыз, дип әйтә алмыйбыз бит инде. Бу мәсьәлә хакында сүземне йомгаклап болай дип әйтәсе килә: татар халкы тулы суверенитет алса, тигез булсак — рус халкы белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре тагын да ныгыячак кына.

Икенче момент. Суверенлык алынгач, республикада яшәүче башка халыкларның мәнфәгатьләре кысылырмы? Болай дип шикләнүләр бөтенләй нигезсез. Татарстан суверенитет алгач, татарлар өчен кибетләр, шифаханәләр аерым булыр, шәбрәк йортлар төзелер яки квалификацияле кадрларны төп халыктан булган квалификациясезрәк кадрларга алмаштыру башланыр дип уйларга бернинди дә нигез юк. Нәрсә, әллә татар телен көчләп укыту башланырмы? Әллә рус мәктәпләре эшләүдән туктармы? Рус халкының, теленең йогынты сферасы тараермы? Юк, безнең реаль тормышыбыз моны расламый. Киресенчә, безнең — җирле халык рухи дөньясының бүгенге хәлләре күпкә хөрти әле! Гасырларга сузылган изүне кичергән халык икенче бер халыкны кимсетүче залимгә әверелә алмый. Тарихта Казан җире, киресенчә, бүтән халыкларның мәдәниятен үстерү бишеге булып килгән. Моны чуаш халкы мисалында да ачык күреп була. Заманында Казанда чуаш театры оеша, шагыйрьләр, язучылары формалаша, газеталар чыга... Татарстан ирек алса, бу анда яшәүче башка халыкларның да ирекле үсү булачак.

Һәм өченче. Суверенитетка каршы чыгучыларның бер ялгышы шунда: алар булачак үзгәрешне бүгенге партаппарат вәкилләренең гамәлләре белән генә бәйлиләр. Табигый, дәүләт булгач, идарә системасы да булыр. Әйтик, яшәү шартлары һәм рәвешләре безнекеннән күпкә яхшырак булган союздаш республикаларда да идарә аппараты булган һәм



*Татарстанның суверенитеты турында Декларация кабул иткән Татарстан депутатлары. 1990*

бар ич. Идарә аппаратының күләме дәүләтнең мөмкинлекләренә, хокукларына, вазифаларына бәйле. Хәзергә прогрессив һәм демократик саналган РСФСР Югары Советы да байтак яңа структуралар: министрлыклар, комитетлар һ.б. төзи бит. Хикмәт эш башында кемнәр, нинди акыл ияләре торуда! Анысы инде сездән, бездән — депутатлардан, халыкның үзеннән тора.

Кайберәүләрдән шундый сүзләр дә ишетелгәли: янәсе, шушы декларацияләр, неформаллар, җәмәгать оешмалары аркасында төрле борчулар, республика җәмәгатьчелегендә киеренкелек башланды, элек бөтенесе тыныч иде, диләр. Әйдәгез, иптәшләр, шунысын да истә тотыйк. Сталин заманында демократия мәсьәләсендә, гомумән, бик тыныч, хәтта артык тын, шомлы тынлык иде... Халыкның уянуы, үзаңы үсүе, үзенең дәрәҗәсен тоюы, үсү процессы — котылгысыз процесс. Моны онытырга ярамый.

Ә хәзер Декларация турында. Ике субъектлылыкның бернинди киртәгә кермәве турында кабатлап тормыйм, биредә чыгыш ясаучыларның күпчелегенә кушылып, мин проекттагы бу маддәне абсурд саныйм. Халыкларның хокуклары «Матрешка» (берсе эченә берсе урнашкан уенчык) системасына сыя алмый хәзер. Андый катлы-катлы буйсынуга инде кайту булмаска тиеш. Киләчәк, академик Сахаров әйтмешли, федерациянең горизонталь структурасы, ягъни һәр халык бертигез хокуклы булып, үзара килешүләр төзеп яшәү юлы.

Биредә үз сайлаучыларының мәнфәгатен якларга алынган кешеләр утыра. Безнең алар алдындагы вазифаларыбыз, җаваплылыгыбыз турында онытырга хакыбыз юк. Сайлау алдыннан сайлаучыларыбызга шактый күп вәгъдәләр бирдек без, республикада яшәүче халыкның материаль һәм рухи тормышын яхшыртуның бер юлы итеп союздашлык статусы алу дип аңлаттык. Беләсез, күпчелек халык бай яшәми, очын очка ялгап яшәүчеләр байтак, тормыш өчен иң кирәк әйберләр дә җитешмәгән замана... Бүгенге көннән, дөнья барышыннан разый булмаганнар да җитәрлек. Төп җирле халык суверенитетлыкка ышанып, киләчәк тормышы яхшыруын аңа бәйләп карый икән, әйдәгез, без аларның өметләрен сүндермик! Сессия исеменә, суверенитет таләп итеп, илнең төрле төбәкләреннән меңнәрчә телеграммалар килде. Урам-мәйданнарда «Азатлык!» дип оран салган ватандашлар бихисап. Шундый киеренке атмосферада, без депутатларга, нинди милләттән һәм нинди сәяси кыйблада булуыбызга карамастан, зирәк акыллы булып, үзара аңлашып, төп халык интересын чагылдыра торган Декларация кабул итү кирәк. Кайбер депутатларга, замана барышын тоеп, империячел фикерләүдән арынырга вакыт. Ленинның милли мәсьәләдә, биреп җиткермәүгә караганда, тулырак итеп бирү отышлырак, дигән хикмәтле сүзен дә онытмыйк. Азатлык, милли суверенитет мәсьәләсендә халык ихтыярына каршы килеп маташу әхлаксызлык булыр. Һәммәгезне дә, тигез хокуклы булуыбызны тоеп, чын дуслыкка, ихлас туганлыкка, нәтиҗәле хезмәттәшлеккә чакырам.

*1990, 30 август*

## ЯҢАЧА, ХУҖА БУЛЫП ЯШИК!

Бөтен татар дөньясы тарафыннан дулкынланып көтелгән август ае үтеп тә китте. 30 август — Татарстан Республикасы туу көне — милли бәйрәм көне дип игълан ителде. Сөендек, алкышладык, бөтен тән күзәнәкләре иркенрәк сулагандай булды, елмаюлы йөзләрдә шатлыклы күз яшьләре елтырады...

Болары инде — үткән көн, ул сәгатьләр, ул мизгелләр инде Тарих. Менә сентябрь дә керде. Яз-җәй эшләгәннең нәтиҗәсен белдергән, чәчкәнне урган, җыйган ай, укулар башланган ай. Кайбер илләрдә Яңа елны беренче сентябрьдән башлыйлар. Безнең халык өчен быелгы сентябрь башы Яңа Чорның башы булмагае әле.

Хәзер бездә кеше үз мәшәкатьләре, шөгыле белән никадәр генә мәшгуль булмасын, барыбер баш миенең бер почмагын зур сорау ялкынсытып тора: исеме мөстәкыйль булган бу ил киләчәккә ничек атлап китәр? Татарстан Республикасы цивилизация дөньясындагы илләр иш итәрлек урын алырмы? Балаларыбыз, оныкларыбыз безнең бүгенге гамәлебезгә киләчәктә нинди мөһер сугар, нинди бәя бирер?

Дөресен әйтик, сизенәбез: төрле кеше, төрле халык төрлечәрәк кабул итте Декларацияне. Эченә сумала йоткан шикелле кара көйгәннәр дә табылды. 30 август төнендә, сессия беткәч, мәйдандагы шатлыклы халык төркеме ягына күренмичә шыпырт кына арт ишектән чыгып киткән депутатлар да булмады түгел. Хәер, сессия барышын телевизордан күзәткән кешеләр күргәннәрдер: кайбер депутатлар төрле-төрле ысуллар белән Декларацияне, теге яки бу сәбәп табып, бу сессиядә кабул иттермәскә йә булмаса кичектерергә тырыштылар. Декларациянең кабул ителгән бу тексты да, яхшы варианттан кайтышка таба үзгәрә-үзгәрә, юна-юна торгач, хәйран гына юкарып калды. Шулай да таныйк: җиңү бар, шатлануның нигезе бар!

Хәзер күп нәрсә үзебездән тора, халыкның тырышлыгыннан, зирәклегеннән, алга таба фикер йөртеп, иҗтиһат итә белүеннән тора. Теге юк, бу юк, дип зарлану чоры үтте. Конкрет эш, гамәл көннәре килде. Загста язылышып чыгу бик тантаналы булса да, тулы бәхет өчен гомер кичү кирәк. Һай, күп нәрсә кирәк әле безгә мөстәкыйль Республика булып яшәр өчен! Иң әүвәле коллык психологиясеннән арыну кирәк!

Кабул ителгән Декларация, бүтән халыкларның мәнфәгатен саклаган хәлдә, иң беренче чиратта татар халкы өчен кирәк иде. Чөнки безнең халыкның йөрәге — Казан. Әгәр рус милләте мәсьәләсе Россиянең дистәләрчә шәһәрләрендә югары дәрәҗәдә хәл ителә алса, безнең хәлләр фәкать шушы Кол Гали, Тукай җирендә генә чишелеш таба ала. Декларациянең мәгънәсе бүгенге безнең административ чикләргә генә сыеша алмый, ул бездә һәм безнең белән чиктәш республикаларда, ерак төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә кагыла. Элегрәк, чит өлкәләрдә яшәүче кардәшләребез белән очрашканда, еш кына мондыйрак сораулар бирәләр иде: «Нишләп Татарстанда киностудия юк? Нишләп чит илләр белән бәйләнешләр юк? Без бит фәлән халыктан ким түгел? Һ.б.» Җавап бирү кыен була иде. Нәрсә әйтәсең? Эчтән генә уйлап куя идең: «Нишләп бу сорауны сез безгә бирәсез, без дә бит сездән нәкъ шулай дип сорый алабыз». Менә хәзер союздашлык статусы алынды, дөресрәге, алынып килә. Димәк, мөмкинлекләр ачыла. Әйдәгез, милләттәшләр, хәзер сез безгә булышыгыз! Сезнең, чит-ят җирләрдә яшәп, төрле милләтләргә хезмәт итүдә тәҗрибәгез зур. Хәзер шул тәҗрибәне, акылны үз халкыбызны күтәрүдә файдаланыйк! Татар халкының интеллектуаль генофонды Татарстан Республикасына хезмәт итсен!

Хәзер безне, безнең гамәлне бөтен дөнья күзәтеп тора. Берәүләр ихлас куана, берәүләр, «болар да мөстәкыйльлек алган булды, нәрсә кырырлар, поживем — увидим» дип, ярым саркастик кыяфәт чыгарып, читтән карап тора, берәүләр әле чын мәгънәсендә нинди үзгәреш, казаныш булганын абайлап җиткерми. Безгә, үзебезгә, бер нәрсәне ачык белү фарыз: безнең өчен беркем дә эшләмәячәк, без фәкать үзебезнең хәләл көчкә, хәләл хезмәткә генә таяна алабыз. Автономия кысасында чакта «эшләгән барыбер безгә түгел, үзәктән арткан тамчы гына өлешебезгә тия» дип, күңелне эленке-салынкыга көйләп яшәп булмый хәзер. Кайбер энциклопедияләрдә язылганча, без бүтән инде, «население» түгел, ә мөстәкыйльлеген яулап килүче зур халык! Икенче сорт халык хәленә кире кайтыр юл юк инде.

Суверенлык рухи һәм физик яктан тураеп басуны сорый.

Әмма шуны да белик: бер югалткан дәүләтчелекне кире кайтару — авыр, каршылыклы процесс. Казан җире әллә ничә гасыр колониаль политиканың зур бер үзәге, миссионерлык лабораториясе булып килде. Хәзерге вакытта хал-




кыбызның мөстәкыйльлегенә тискәре караштa торган төркем-партияләр (Русское собрание, ДРП — Россия демократик партиясе) митинглар уздыра торган урыннан — Үзәк парктан йөз метр чамасы гына ата карагруһ Ильминский җирләнгән. Эшли торган чиркәү ишеге янындагы кабере ташына «Великий просветитель инородцев» дип язып куелган. Көн саен йөзләгән кеше аңа табынып китә... Рухы һаман исән. Тарафдарларының сүзләре генә бүтән.

Атамалар бүтән... Кремльдә Изге Нургали мәчете нигезенә салынган чиркәү гөмбәзләрендә алтын тәреләрне ялтыратып кую күңелләренә биһуш килсә дә, кемнәрдер Сөембикә манарасына ай куюга да теше-тырнагы белән каршы. Кемнәрдер Казанны һаман да рус дәүләтенең бер өлкәсе — өяз үзәге итеп күрәсе килә. Кемнәрдер, суверенитет өчен көрәшкән безнең җитәкче лидерлардан йөз чөереп, Столыпин заманындагы түрәләр стилен — губернияләрне сагына...

Тагын берәр айдан Татарстан парламенты үзенең өченче мәҗлесенә җыелыр. Яңадан көрәшләр башланачак. Декларация, шиксез, зур сәяси-хокукый документ, тормышыбызга закон булып керәчәк Конституциянең нигезе. Шуңа күрә милли азатлык хәрәкәте, халык депутатлары яулаган Декларациядәге демократик хокукларны Конституциядә тагын да тулырак чагылдыру — безнең төп бурыч. Бу таләп-бурыч экономика өлкәсендәге союзара килешүләр мәсьәләсенә дә карый. Татар теленең Республикадагы статусы, функциясе, дәүләтчелек дәрәҗәсе турында бик нык уйланасыбыз бар. Алда депутатларны акыл көрәше көтә. Бу хакта безнең сайлаучылар да белергә тиеш. Сайлаучылар депутатка ышанган кебек, депутат та үз сайлаучыларына таянып, аларның ярдәмен тойганда гына җиңү яулый ала.

Әйе, көрәш котылгысыз. Азатлык көрәшсез мөмкин түгел. Шуңа күрә дә татлы диләр ул сүзне! Чыннан да татлы, сихәтле икән ул! Иртән, суверен республика кешесе икәнлегеңисеңә килеп, бер башка югары үсеп уянасың. Урам-мәйданнар бүтәнчәрәк күренә. Күз бүтән. Ауганны торгызасы, җимерекне төзәтәсе, пычранган урынны чистартасы килә. Чөнки бу җир, бу ил — минеке, безнеке! Хуҗа булу хисе бу. Бу хис тә бик татлы шул!

Җаны ирекле кешене авырлык куркытмый. Безгә дә авыр булачак. Әле байтак еллар авыр булачак. Шулай да эшебез уң булыр. Әле царизм законында да халыкның байтак вәкилләре, түбәннән күтәрелеп, сәясәттә булсын, сәүдә капиталында булсын, илкүләм мәшһүр шәхесләргә әверелгәннәр. Тырыш булган алар, сабыр булганнар, зирәк булганнар... Сабантуйлар булмый торып, көрәшчеләр каян чыксын ди. Мәйдан да ишәер. Күрәсез, сессия барышында гына да якты акыллы яңа шәхесләребез ачыкланды. Сәяси, дини, мәдәни җыңүләр шөбһәсез. Ирекле Ватан гына исән булсын!

*1990, сентябрь*

## БИТАРАФ КАЛА АЛМЫЙБЫЗ

Казанның Азатлык мәйданында (бу мәйданны күптән инде шулай атарга кирәк, «Свобода» сүзенең төгәлрәк тәрҗемәсе «ирек» түгел, «азатлык» бит. Милли азатлык өчен көрәш мәйданы буларак та исеме җисеменә туры килә) инде атнадан артык элек каләмдәшләрем Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов, Зәки Зәйнуллиннар, саулык-сәламәтлекләре белән исәпләшмичә, көндәлек яшәү шатлыкларыннан ваз кичеп, сәяси ачлык игълан иттеләр. Аларга тагын дистәдән артык кеше кушылды. Төрле шәһәрләрдән — Казан, Алма-Ата, Баку, Чаллы... Безнең милләттәшләрдән тыш, араларында тугандаш әзәрбайҗан халык вәкиле — депутат та бар. Механизатор, пенсионер, журналист, дин әһеле, актер... Әлегәчә бу рәвештәге мондый колачлы сәяси акциянең Казанда булганы юк иде әле. Ачлык тотучылар моңа кадәр берәм-сәрәм күренгәләсәләр дә, аларның таләбе, асылда, үз шәхесләренә бәйләнешле низаг-аңлашылмаучылыклар белән бәйле була иде.

Нәрсә телиләр, нәрсә таләп итәләр соң бу тынгысыз фидакарь җаннар? Аларның (һәм безнең дә, әлбәттә) теләкләре һәм таләпләре ачык һәм табигый. Татар халкының, илебездәге бүтән союздаш республика халыклары кебек үк, тигез хокуклы булуын, узган елның 30 августында суверенлык турында алкышлар белән кабул ителгән Декларация нигезенең какшамавын — Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеге ныгуын тели алар. Болар бик мәгълүм нәрсәләр, боларны бик күпләр тели ич, диярләр. Шулаен ул шулай да. Әмма... соңгы атна-ун көн эчендә ситуация шактый ук катлауланып китте. Мөстәкыйльлек юлында эшләр уңышлы гына алга барганда, Татарстан Югары Советында 13 май көнне, сессия ахырында, ашык-пошык дигәндәй, ТССР территориясендә РСФСР Президентын сайлау турында карар кабул ителде. Бөтен татар халкын сискәндереп җибәрде бу көтелмәгән карар. Күңелләргә шик, шом иңде. Халык аптырап һәм буталып калды. Ничек була инде ул: Татарстан Президентын булдыру турында көннәр буе бәхәсләшеп закон чыгарып утыр да һәм шунда ук үз җиребездә Россия Президентын сайлауны да рәсми таны, имеш. Аңлашылмый торган хәл бит бу! (17 мартта бездә РСФСР Президентын булдыру турында референдум да үткәрелмәгән иде ләбаса!) Дөрес булып чыкмас бит бу.




*Ачлык игълан итүчеләр арасында каләмдәшләребез: Ф.Бәйрәмова, З.Зәйнуллин, Р.Әхмәтҗанов...*

Бер казанга ике тәкә башы сыймас, ди бит халык. Бер гаиләдә берьюлы ике ата да булмас. 12 июнь көнне мин бер Президент, ә күршем икенчене сайлап кайтса... Бер йортта ишекләр төрле-төрле якларга ачыла башласа, бәрәкәт очар бит!

...Татарстан халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова әнә шул ялгыш карар кабул ителгән көнне сәяси ачлык игълан итте. 14 май кичен күпләр хәтерлиләрдер. Көзгә охшаган болытлы, салкын кич. Яңгыр сибәли. Сәгать 8 ләр тирәсендә сессия бетте. Биек йорт ишегеннән чыккач, күп кенә депутатлар, мәйдандагы халыкка илтифат та итмичә, ашыга-ашыга ак һәм кара төстәге елтыр «Волга»ларына, «джип»ларына таба чабуладылар. Яңгыр чылатыр дип тә уйладылар бугай. Бу иптәшләрнең күбесе әлеге карарны яклап тавыш биргән депутатлар — район җитәкчеләре, оешма башлыклары... Шулай итеп, өрлектәй таза, нык бәдәнле ир-егетләр «әһ» дигәнче мәйданнан юк та булдылар. Ә баскыч төбендә, суык яңгыр астында, көрәштәшләре белән бергә, дөнья гаменнән бөкрәеп, ак шәл ябынган ябык, бәләкәй Фәүзия утырып калды...

Ашыктыгыз сез ул көнне, депутат егетләр! Ашыктырдылар да бугай. Ашыкканда, кабаланганда ялгышасың да... Ә аек акыл белән төптәнрәк уйлап караганда, бу мәсьәләдә Фәүзия Бәйрәмова хаклы иде. Депутатлык эшчәнлегендә аның кайбер алымнары, фикерләре белән килешмәскә дә мөмкин — һәр кешенең үзенчә шәхси мөнәсәбәте булуы бар — әмма төп, хәлиткеч мәсьәләләрдә, әгәр кеше хаклы икән, аны аңлый һәм яклый да белергә кирәк.

Сессия утырышы ахырында 50 дән артык депутатның әлеге карар кабул ителүнең юридик дөреслеген ачыклар өчен конституцион күзәтү комитетына мөрәҗәгать итүе дә очраклы түгел бит. Ниһаять, комитет бу карар турында үзенең фикерен рәсми белдерде. Ахыр нәтиҗә, әлбәттә, депутатларның аңына, уяулыгына бәйле. Тиздән сессия утырышының чираттагысы якынлаша. Җибәргән ялгышны төзәтер вакыт җитте, хөрмәтле депутат-коллегалар!

Азатлык мәйданында минем каләмдәшләрем ачлык тота. Кил, күреп кит аларны, гыйбрәт алып китәрсең (хәтерегездәдер, моннан берничә ел элек америкалы Хайдерның ачлык тотуын бөтендөнья күзәтте, совет телевидениесе көн саен репортаж биреп барды). Кызык өчен, шөһрәт-мал өчен утырмыйлар алар, мәйданга аларны халыкка мәхәббәт һәм иман китергән. Алар — түбәннән, җирдән, тормыш эченнән килгән халыкның асыл кызлары һәм уллары. Күңелләре чиста, идеаллары ачык булгач, куйган максатларыннан чигенергә уйламыйлар. Хәтта шәхси фаҗигагә дә әзер кебекләр. Ләкин андый аяныч финалга юл куярга ярамый. Һәркемнең дә газиз гомере бер генә. Андый җаннарның саулыгына, талантларына, кешелеклелекләренә битараф калмыйк, кардәшләр!

*1991, май*

# ХӘЛИТКЕЧ КӨННӘР

Июнь (борынгы бабайларча әйтсәк, чәчәк ай, сөмбелә ай) — яшәүгә, җиргә һәм үзеңә ышаныч ае. Ни дисәң дә, җан тыныч: күңелдә генә булса да, үзенә күрә язгы бер «урак» урылган, туфракка орлык кергән, утыртасы утыртылган, чәчеләсе чәчелгән, җир гөлләнгән, терлек-туар иркендә, тамаклары тук, җиләннәрендә безгә дә тияр яшәү суты... Болар, әлбәттә, крестьян баласы психологиясеннән. Шулай ук шәһәр кешесе өчен дә июнь, төрекчә әйтсәк, чук гүзәл ай. Шәһәр кешесе көннәр буе комлы-измәле төзелеш мәйданнарында мәш килсә дә, тартма бүлмәле лаборатория-бюроларда утырса да, әче таңнан үзен һәм балаларын һәлак итәргә мөмкин кораллар чыгаручы хәрби заводларга, цех-ангарларга ашыкса да, машина гүләүләрен һәм таш урамнар ыгы-зыгысын онытып, барыбер ул да күрә, тоя июньнең ямен. Табигать җете яшел, һавалар саф, яңгырлар җылы. Җитмәсә, борынны кытыклап дигәндәй, алда Сабан туйлары тора... Кыскасы, шәп ай инде ул июнь ае!

Әйе, гомумән алганда, болары шулай. Ә менә безнең өчен, татар халкы өчен, июньнең бу көннәре шулай идиллик тыныч һәм ямьле генәме соң? Сабыйга, нарасыйга гына шулай тоелыр. Бәлкем, тыштан караганда кемнәргәдер сизелмәве мөмкин. Трамвайлар йөри, делегацияләр килеп-китеп тора, көтүләр үз вакытында үз урынында туплана, талоннар* товарланып тора... Ә төптә, дәресрәге, үзәктә, сәяси тормыш кайный, быгырдый, киеренкелек уйлыларның баш капкачын күтәрер дәрәҗәдә. Чөнки бу июнь ае безнең язмышны тарихи хәл итү ае булуы да ихтимал. Чөнки бу көннәрдә республиканың, дөньялыкта тоткан урыны нисбәтендә, ил-йортның төп хуҗа кешесен — Президентын сайларга тиешбез. Президент сүзе сәеррәк яңгыраса да, безнеңчә инде ул илнең аксакалы, баш кешесе дигән сүз. Ә йортта ничә баш кеше була ала? Акыллы булган һәркем әйтер: бер булыр андый кеше. Ә менә безгә, «татар бәхетенә» дигәндәй, берне генә түгел, берьюлы берничәне тәкъдим итәләр. Инде, шөкер, гамәлдә берсе — СССР Президенты бар. Аны үзенчә хөрмәт итәбез, сүзенә колак салабыз, санлашабыз. Юк, диләр безгә, ул гына аз, үзегезнең «местный» Президент өстенә тагын берәү Россия үзәгеннән кирәк, диләр. Шулай булса, нәрсә була инде? Бер башка өч түбәтәйме? Бер муенга өч кыңгыраумы? Бер авызга өч авызлыкмы?

Моны аллегория рәвешендә яки сүз уйнатып әйтү түгел.

---

* 90 нчы еллар башында азык-төлек әйберләренең күбесе кибет аша талоннар белән бирелә иде.

Ситуация гаҗәеп катлаулы. Үткән ел Татарстан үзен суверен дәүләт дип игълан итсә дә, без теләгән кешеләргә Россия Президентын үз территориябездә сайлау мөмкинлеге бирә торган карар кабул итәргә мәҗбүр булдык. (Нишлисең, әлбәттә, чарасыздан: без күпме генә үзебезне фәлән миллион дип йөртсәк тә, заманында Ленин сызып калдырган бәләкәй территориядә без азчылык — нибары 48 процент чамасы гына эләгеп калганбыз. Икенче төрле әйткәндә, бөтен татар халкының биштән бер чамасы гына. Биш бармагың булса гына кул кул була ала, бер бармак белән көрешеп тә булмый, йодрыклана да алмыйсың.) Май аеның икенче яртысында республикабызда сәяси киеренкелек моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җитте. Бу катлы-катлы сайлау хәлләре күпләрдә аптырау һәм ярсу кузгатты. Халык сискәнеп уянды. Россия Президентын сайлауга ризасызлык белдереп яше-карты мәйдан-урамнарга чыкты. Безнең кебек сабыр халык өчен бу уен эш түгел.

Татарстан халык депутаты буларак, әзрәк чигенеп булса да, Югары Совет утырышларында алган кайбер тәэсирләр белән дә уртаклашып узасым килә. Дөресен әйткәндә, депутат булып йөрүләре хәзер бер дә җиңел эш түгел. Әлбәттә, сүз Ш.Камал «депутаты» хакында түгел, ә С.Максуди, Й.Акчура кебекләр турында бара. Беренчедән, замана бүтән, таләпләр, критерийлар бүтән. Таләпләр артуын артты, ә, гомумән, ул таләпләрне үтәр өчен мөмкинчелекләр арттымы соң? Әйтик, бер сугыш ветеранына җиңел машина кирәк, кай-



*Казан. Азатлык мәйданы. 1991*

сыдыр мәктәп дистәләгән данәдә төсле телевизор сорый, фәлән авыл газ торбалары даулый, фәлән колхозның асфальт юл салдырасы бар... Кирәк эшләрме болар? Әлбәттә, кирәк. Кирәк кенә түгел, ихтыяҗ болар. Ә депутатка, бигрәк тә хуҗалык эшләреннән ерак торган кешегә, боларны башкару җиңелме? Әлбәттә, үзебездә дә булганлык, үҗәтлек, эш йөртә белү җитенкерәп бетми. Бу очракта, минем кебек, үз эшләреннән канәгать булмаган депутат иптәшләр, мөгаен, байтактыр. Бер өмет: хәзер инде билгеле бер тәҗрибә тупланды, хуҗалык механизмының серләренә төшенә башладык, сайлаучыларның гозерләрен максималь үтәү реальләшер.

Шулай да, парламентның төп вазифа-эшчәнлегенең берсе һәм иң зурысы — халык өчен файдалы законнар эшләү. Бу юнәлештә, миңа калса, безнең Югары Совет бер ел эчендә байтак эшләде. Сессия хәлләрен күзәтеп барган кешеләр аны бәялиләрдер. Моңарчы кабул ителгән күп законнарыбызның төп мәгънәсе шул: республикабызда үзебез хуҗа булып, халыклар дуслыгына тугрылыклы калып, үз хезмәтебезнең нәтиҗәсен күреп, бәхетле һәм мул яшәү (хәзергә, ни дисәң дә, без үз байлыгыбызга үзебез хуҗа түгел шул. Хуҗалыгыбыздагы мөлкәтебезнең фәкать ике процентына гына хуҗа булу — үзе дөнья хурлыгы бит. Кызганыч, безнең шул хәлдә калуны эчтән хуплап торучы депутатларыбыз да бар). Миңа калса, алга таба парламент эшебезнең иң мөһимнәре шул: Татарстан Конституциясен тизрәк кабул итү, гражданлык турында закон чыгару, милек һәм җир мәсьәләсен хәл итү, татар теленең дәүләти функциясен ныгыту.

Сессия вакытларында мәйданнарда халык гөр килә. Аларны бүтән милләт вәкилләре дә күрә, үзенчә нәтиҗә ясый. Ә менә бина эчендә, утырыш залларында ниләр бара? Халык сайлаган вәкаләтлеләр нишли? Ә бит ул залда утырган депутат дигәннәре дә төрле бит. Алар арасында бар гаҗәеп вөҗданлы, халык эше өчен фида китәргә әзер затлар. Андыйлар, дөрес, хәзергә күп түгел. Бар — иске гадәт буенча — аларның байтагы элек тә сайланып, депутат булып йөргән иптәшләр. Өстәгегә карап кул күтәрергә күнеккән иярчен өер. Алар — әлегә күпчелек. Бар — сирәк булсалар да — бер ел эчендә мыегын да селкетми, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит дип, утырышларда газет укып утыручылар. Шулай ук бар — җәмгыятьтә элек әллә ни урын тотмаган, ә хәзерге үзгәртеп кору кузгалышы вакытында очраклы рәвештә өскә күтәрелеп, бик тиз «көрәк» булып, үзләрен бик остага, әллә кемгә санаган амбицияле адәмнәр. «Менә мин кем идем дә кем булдым!» янәсе. Аның алдында дәүләт баш-

лыклары, министрлар җавап тота... Ул алардан теләсә нәрсә сорый, таләп итә ала... Андыйлар, гадәттә, бигрәк тә телевизор объективлары алдында, кирәксә-кирәкмәсә дә микрофонга үрелергә яраталар (дөрес, андыйларга халык урамнарда — үзем ишеткәнем бар — фикерләрен белдерә дә инде: «Кара сакалың белән бергә акылыңны да тарап кил, яки биеккә үрелгәндә кыска ыштаныңны үтүкләп кил»). Депутатлар арасында әле тагын бер хәтәр төркем бар: аларга Татарстанның суверенлыгы ошамый. Килмешәк һәм шовинистик рух аларны күнегелгән изге ызанга өстери (шунысы гаҗәп: төп җирле халык булган татарның теле, культурасы бетүгә, тарихы онытылуга барганда, шул процессны тизләтеп торучылар үзләрен ничек демократ дип саный алалардыр?). Болар — аңлы рәвештә безнең парламент эшчәнлегенә төп таяк тыгучылар. Алар өчен Татарстан үз байлыгын үзәккә — Мәскәүгә чыгарырлык дәрәҗәдә куәткә ия булса, шул җиткән. Төп җирле халыкның эчке рухи ихтыяҗы кадалып китсен! Инициативалары сессия утырышларында, нигездә, хупланмаса да, алар парламент эшенең байтак вакытын алалар, җитәкчеләрнең дә, гамьле гавамның да нервыларын байтак талкыйлар. Ташы нинди булса, мунча кызуы шундый дигәндәй, менә шундый кешеләр бергә җыелып утырабыз парламентта.

Кулыма каләм алырга мәҗбүр иткән төп мәсьәләгә кайтыйм. 12 июньдә булачак сайлаулар көнендә без нишләргә тиеш соң? Бу хакта Мамадыш районының Югары Сөн авылыннан сайлаучы Җәмил иптәш Заһитовның хаты кулыма килеп ирешкәч, фикерләремне уртаклашу теләге тагы да



*Коллыктан арынып чак җитте...*

көчәйде. Ул болай дип яза: «Район газетабызның 21 май санында «РСФСР Президентын сайлау — бүген гаять мөһим кампания» диелгән. Ә менә «Социалистик Татарстан» газетасының 15 май санында КПСС Татарстан рескомы бюросының сайлауларга мөнәсәбәте игълан ителде. Анда «КПСС Татарстан реском бюросы Татарстан республикасы РСФСР Президентын сайлауда рәсми төстә катнашырга тиеш түгел дип саный» диелгән. Мин үзем мондый позицияне тулысынча яклыйм. Ә менә матбугаттагы каршылыкны ничек аңларга? Бәлки, мин аңлап җиткермимдер?»

Әйе, гаҗәп, әмма гаеп түгел. Бүгенге хәлне кайберәүләр аңлап та бетермәс шул. Чөнки халыкның башын үзебез әйләндердек. «Кыз да булсын, буаз да булсын» дигәндәй, янәсе, сайлауның тегесе дә үтсен, монысы да үтсен. Әмма бер туйның зөфаф кичәсендә кияү бер генә була. Хәзер Казанда сайлаулар буенча хәл шактый болганчык. Ихтимал, республикабызның бүтән зур шәһәрләрендә дә хәл шулайрактыр. Берәүләр, бигрәк тә урыс кардәшләребез, Татарстан Президентыннан бигрәк, Россия Президентын сайларга ашкынып торалар. Голливудның Джеймс Бонды диярсең: Казан үзәгенең һәр почмагында диярлек Ельцинның зур форматтагы төсле рәсемнәре эленгән. Ул гүя әйтә кебек: «Әй, татарлар, нигә үз арагыздан президент эзләп маташасыз, әзер мин бар бит инде. Чиркәүләр өстендәге каргалардан башлап, үз маңкортларыгызга кадәр мине сайларга тели ич».

Әйе, Ельцин яклы көчләр Казанда җитәрлек. Әмма дөньяда халыклар хокукы, дәүләтчелек статусы, милли үзаң һәм, ниһаять, хакыйкать бар бит әле. Без үткән елның 30 августында (ул көн, һичшиксез, милли бәйрәм, республика көне булырга тиеш дип уйлыйм. Әгәр яңа Конституциябезне дә ул көнне кабул итә алсак — икеләтә бәйрәм булыр). Халык сайлаган вәкилләр бертавыштан суверенитет турындагы Декларацияне кабул иткән икән — бу документ республикада яшәүче һәркем өчен олы хакыйкать һәм катгый закон булырга тиеш. Димәк, бу — мөстәкыйль дәүләтнең үз президенты, фәкать үз президенты гына булырга тиеш, дигән сүз. Димәк, сайлау да фәкать бер генә президентны сайлау булырга тиеш. Бүген президентлыкка бердәнбер кандидатның исеме һәркемгә анык. Ул — Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Ул, политик эшлекле буларак, илкүләм киң билгеле шәхес. Аның эшчәнлеген артык шәрехләп торырга ихтыяҗ юк. Сәясәтне беркадәр чамалаган кеше аңлар: халыкара политикада Татарстан интересын алга сөреп бара торган аның дәрәҗәсен-

дәге әзерлекле бүтән кеше арабызда әлегә юк. Бер елга якын вакыт эчендә Татарстан республикасын дөньяда илдәүләт буларак телгә ала башлаганнар икән, монда М.Ш.Шәймиевнең, аның җитәкчелегендә эшләүче Югары Совет эшчәнлегенең роле ифрат зур. Аңа ышанырга кирәк. Чөнки ул Декларациябезне байрак итеп күтәрде, аның төп положениеләрен әкренләп, хәленчә тормышка ашыра бара. Бу — аның халык ышанычлысы икәнлегенә төп гарант.

Россия зур. Әлегә бик зур. Мурманскидан алып ерак Көнчыгыштагы Татар бугазына кадәр. Сайлана калса, рәхәт күрсәтсен Ельцин Россиягә. Россия бай һәм рәхәт яшәсә, без дә аралашып, сәүдәләшеп яхшырак яшәрбез. Ә хәзергә тарихи мөмкинлекне ычкындырмыйк, мөстәкыйль (анысы да аның бик чагыштырмача гына) булып яшәп карыйк. Үз президентыбызны сайлыйк. Тәхеткә сәнәк белән түгел, ышаныч белән күтәрик. Аннан соң ил башлыгыннан таләп итә дә алырбыз.

...Әй, кызык бу дөнья! Матур җәй айларында, кем әйтмешли, «яшәү матурлыгына сокланып» иҗат итеп ятасы урында, бар шөгылеңне ташлап, сәясәт-политика белән шөгыльлән, имеш.

Элекке заман булса, шулай тыныч кына иҗат итәр идек тә бит... Тигезсезлек бәбәгеңне тишеп торганда, сандугач тавышына изрәп торып булмый шул. Бүгенге көндә шигырь, җыр, гомумән, сәнгать — халыкның киләчәк язмышы белән бәйләнешле булганда гына актуаль була ала. Газеталар укыйсың, телевизордан тапшырулар карыйсың да хәйран каласың. Һай, каршылыклы бу хәят! Дөньяның нык алга киткән ил лидерлары СССРны үз сафларына алыргамы-юкмы дип уйланалар, бәхәсләшәләр. Ә СССРның үз эчендә булган берничә республикалар бу берлеккә керүдән бик теләп баш тарттылар. Ә бәгъзеләре, бер дистәдән артмыйча гына үзара берләшик, диләр. Ә берәүләр бу рәткә керер өчен тартыша... Халыклар арасында никадәр баскыч-баскыч төрлелек, никадәр дифференциация! Тарихка карасаң, имәнәсең: кемнәр кем иде дә кем булып алды, кемнәр кем иде дә кем булып калды... Ә барыбер, халыклар арасында тигезлек булмаса, җирдә тынычлык булмас шул. Моны күпләргә аңларга вакыт.

...Июнь. Җәйнең кыз вакыты. Яфракларның тулышкан чагы. Рәхәт чак. Тынгысыз чак. Шомлы чак... Үтәр бу җәй дә, терәлеп тормас. Утызынчы августка кадәр бу яшеллек саргылт төс алыр. Ә без ничекләр килербез бу көзләргә? Акыллы һәм җиңүче булыпмы, әллә...

*1991, июнь*

## ИҖАТКА ХОКУК

Иҗат иреген, гомумән, иҗатны хезмәткә булган хокукның иң югары чагылышы дип аңлыйм мин. Һәрхәлдә, иҗатны ирекле хезмәттән аерып карап булмый. Иҗат ләззәтен ирекле хезмәтнең хакыйкый асылын тирән аңлаган кеше генә бөтен тулылыгы белән тоя аладыр. Без, шөкер, күңел сайлаган, җан тарткан хезмәт белән шөгыльләнү хокукына ия кешеләр. Бу — зур бәхет. Бар илһамың белән, бөтен тырышлыгыңны куеп эшлә генә! Иҗат ит! Ил-халык күңеленә юл яр! Хезмәткә хокукны, иҗаттагы ирекне минем буын мисалында да ачык күреп була. Без — 60 нчы еллар урталарында шигырь язып әдәбиятка керергә ниятләгән бер төркем иптәшләр, әйтик, Р.Харис, Р.Мингалимов, Г.Рәхим, Р.Гатауллин, Ш.Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф.Яруллиннар — хәзер инде һәрберебез диярлек дистәләп китап чыгарган кешеләр. Ун-унбиш ел өчен аз түгел. Мөмкинлекләр булмаса, аларны бастыра алыр идекме? Нинди дәрәҗәдә, нинди сыйфатта, нинди талант югарылыгында дөньяга чыгардың аларны? — бусы инде икенче мәсьәлә. Сорауның җавабын үзеңнән эзләргә кала.

Фактик саннар, алар нинди генә булсалар да, һәрчак гыйбрәтле. Соңрак елларда татар әдәбиятының киңрәк мәйданга чыга баруы менә мондый саннарда ачык күренә: быел Мәскәү нәшриятларында гына да республикабыз язучыларының 20 исемдәге китабы рус телендә басылып чыгачак. Бу — күләм ягыннан 200 табак чамасы, тираж буенча — 900 меңләп данә (әле монда бүтән республикаларда — тугандаш халыклар телләрендә чыгачак китаплар турында мәгълүмат теркәлмәде). Рус телендә китап чыгаруны татар әдәбиятын дөньяга киңрәк таратуда реаль бер юл дип саныйм. (Бу очракта шуны искәртеп узасы килә: гадәттә, Мәскәү нәшриятларында рус телендә чыккан китапларның төп өлеше кире шул ук республикаларга җибәрелә, ягъни мәсәлән, татар язучысының әсәре рус телендә янәдән Татарстанга кайта булып чыга. Монда эчкә яшерелгән тирән сәясәт ята.)

Бүгенге әңгәмәдә тагын бер нәрсәгә тукталасым килә: соңгы унбиш егерме ел эчендә татар әдәбияты эчтәлек ягыннан бик нык тирәнәйде, формаларга баеды. Алыйк бүгенге прозадагы повестьларны. Нинди генә төрләре юк аның хәзер: классик сюжеттагыларымы, эпистоляр характердагыларымы, фәлсәфи уйлануларга корылганнарымы, монолог-хәтерләүләр рәвешендәгеләреме, ярым-документаль нигездәгеләреме... Эчтәлек һәм форма ягыннан эзләнүләр поэзиябездә тагын

да күбрәк булды. Эзләгән табар дигәндәй, эзләнүләр билгеле бер табыш-ачышларга да китерде. Һәрхәлдә, идея-художество эшләнеше ягыннан шактый камил һәм дөньяның теләсә кайсы почмагына барып күрсәтерлек шигъри әсәрләребез байтак безнең! Әдәбиятыбызның эчтәлеккә һәм формаларга байый төшүе дә иҗаттагы олы мөмкинлекләр турында сөйли түгелме соң?!

Иҗат ирege турында сөйләшкәндә, үз хезмәтеңнең иҗтимагый миссиясен ничек аңлавың һәм моны үз шәхси хезмәтеңдә ничек тормышка ашыруың белән берлектә карарга кирәк. Егет кешенең сүзе эштән аерылмас, ди халык. Фәкать хезмәтле кешенең генә ихтирамга хакы бар. Кайчакта безнең арада, бигрәк тә кайбер яшь каләмдәшләр арасында, азрак эшләп, күбрәк сөйләнеп, дәлилсез дәгъва кузгатып йөрүчеләр дә очрамый түгел. Төптәнрәк уйлап баксаң, бу — күп очракта, андый кешенең асыл гамәле үз рухи үшәнлеген ни беләндер акларга, сынbackка сылтау эзләүгә кайтып кала. Минемчә, алай нигезсез сәбәпләр эзләүгә караганда, Конституция белән ныгытылган хокуклардан тулырак файдаланып, халык-ил интересларына җавап бирерлек хезмәт-иҗтиһат итү дөрес булыр. Мисалларга ерак барасы юк. Әнә Г. Ибраһимовлар ничек актив иҗат иткәннәр! Ә Муса Җәлилнең таң калырлык эшләре!.. Ә бүгенге өлкән яшьтәге замандашларыбыз — Н.Исәнбәт, С.Хәким, Г.Әпсәләмовлар һәр минутның кадерен белеп иҗат итүчеләр. Урта буын вәкилләреннән Г.Ахунов, Н.Фәттах, А.Гыйләҗевләр дә шулар рәтендә. Үзен аямыйча янып эшләгән кеше генә иҗатның нинди бөек бәхет икәнен чын тулылыгында тоя аладыр.

*1978, март*

## ОЯТ БИТ!

«Казанда Болгар исемендәге урам бармы, юкмы?» дип сораган кешегә шәһәрдәшләребезнең бик азы гына анык җавап әйтә алыр. Күбесе, һичшиксез, «юк», «белмим» диячәк. Ә бар икән андый урам исеме! Мин үзем дә аны моннан ун еллар элек очраклы рәвештә «ачып», гаҗәпләнеп, кимсенеп, тетрәнеп калган идем. 1977 елны бу хакта куен дәфтәренә язып куйганмын:

БОЛГАР УРАМЫНДА. ЯҢГЫРДА.

Дүрт-биш өйле тыкрыкмы?
Исеме белән — урам...
Бетон коймага
ышыкланып,
дерелдәп бер көчек тора.

Бу дүртьюллык соңрак китабымда да чыкты. Эш, әлбәттә, бу юлларда, аларның кайчан, ничек язылуында түгел. Шулай да киная, тел яшеребрәк әйтә торган заманда ул урам кисәгенә мөнәсәбәт һәм күшеккән көчек — эт баласы символы аша шул тирәдә тереклек итүчеләр хакында да беркадәр әйтелгән сыман.

Әйе, урам исемлекләре кенәгәсендә бар ул Болгар урамы. Формаль гына түгел, чынында бар. Әле бу көннәрдә генә янәдән шул урам тирәләрен урап кайттым. Күңел тагын да боега төште, авыр тойгылар көчәйде генә. Шул ук пычраклык, фәкыйрьлек, тәртипсезлек... Элекке елларга караганда алабута, әрем үләннәре күбәйгән дә шешә ватыклары мулрак сибелгән... Оят булып китте, гади милләттәшләр өчен дә, эш башында утырган түрәләр өчен дә. Без нинди халык та, нинди холык бездә?! Шул Болгар «урамы»ннан бер 100 — 150 адым арырак китсәң, тарихи татар зираты башлана. Аның эчендәге һәм янәшә тирәсендәге «күркәм» күренешләр турында сөйли китсәң — анысы икенче бер зур мәсьәлә.

Борынгы бабаларыбыз безнең — болгарлар, дип күпме сөйлибез, горурланып язабыз, күпләребезнең шул исемгә рәсми рәвештә сыенып яшисе дә килә. Ә үзебез шул изге исемне — бер ягы Пләтән төрмәсенең (1937 елларда халкыбызның күпме акыл ияләре, асыл затлары череп юкка чыкмады анда!) биек бетон коймасы, икенче ягы ярым җимерек биш-алты иске агач өйдән торган тыкрык сыман урынга тагып, үзебезне хурлыйбыз, кимсетәбез, мәдәниятле халыклар

алдында үз-үзебездән көлдерәбез, маңкортлыгыбызны күрсәтәбез бит! Үзаңнары шактый үскән руслар «Русь», украинлылар «Славутич» кебек үзләренә газиз сүзләрне мәсхәрәле рәвештә әнә шундый ташландык урыннарга тагып йөртерләр микән?

Мин бу урамның аяныч хәле турында, Болгар исемендәге берәр зур проспект булдыру турында үткән ел шәһәр партия оешмасының XXVII конференциясендә ясаган чыгышымда да әйткән идем. Анда республика һәм шәһәр җитәкчеләре дә бар иде, фикеремне хуплаган да шикелле иделәр. Онытканнар, күрәсең. Телевидение кешеләренә дә әйтеп карадым, берәр «Үткен ракурс» кебек тапшыруда шул урам тирәләрен төшереп, халыкка күрсәтүләрен сорадым. Үзфинанслау һәм керем саный торган заманда мондый сюжетны файдалы тапмадылар, күрәсең...

Менә-менә Болгар дәүләтенә (кабатлап әйтәм, Болгар исемендәге дәүләткә!) ислам дине иңдерелүгә 1100 ел тулырга тора. Тарихи бәйрәмгә төрле тарафлардан, төрле илләрдән олуг кунаклар килер. Ул көннәрдә «болгар» дигән сүз телдән төшмәс. Ялгышып берәрсе шул безнең Болгар дигән «урамга» барып чыгар, йә булмаса сораштырыр. Уңайсыз, бик оят булыр бит! Хәер, кунаклар килер дә китәр. Ә үзебезнең күңелдә яткан әрнү ташы нишләр? Безгә бит әле бу җирдә яшисе, балалар, оныклар үстерәсе бар.

*1989, июль*

## «НӘРСӘ МӘГЪНӘЛЕ ДӘ, НИ МӘСЛИХӘТ?»

Милли басмаларыбызның саны, таралу рәвеше турында берничә сүз әйтмәкче булам. Журналлар арасында милли басмалар дип кайсыларын әйтә алабыз соң? Алар, мәгълүм булганча, «Казан утлары», «Сөембикә», «Мәгариф», «Ялкын», «Идел». Бу рәткә «Чаян»ны да кертәсе килсә дә, нихәл итмәк кирәк, тиражының уннан бере дә үз телебездә булмагач, аны милли журнал дип әйтү кыенрак шул. (Кызганыч, сәламәт кеше көлә-елмая белергә тиеш! Һәм күп итеп.)

Үткән елның башы белән чагыштырганда быелгы тиражларыбыз ничегрәк соң? Үстекме, кимедекме? Җавабы шул: бераз кимедек кимүен, әмма ныгыдык. Ягъни матбагада реаль контурлар ачыкланды, нинди басманың җәмгыятьтә ни бәя-дәрәҗә торганлыгы ачыкланды. Нигездә, үткән елгы тиражның уртача 60–70 процентын саклап кала алдык. Шунысын да онытмыйк: татарлар яши торган төрле төбәкләрдә яңа басмалар ачылды, алар да беркадәр укучыны үзенә тартты. Соңгы елларда, байтак уңай үзгәрешләр булса да, татарча матбугат белән ризыкланып тәрбия алган яңа буын да үсеп җитмәде әле. Әйтик, кемдер «Ватаным Татарстан»ны, кемдер «Татарстан хәбәрләре»н яки «Шәһри Казан»ны укый икән, нигездә, алар элеккеге «Социалистик Татарстан»ны укыган кешеләр.

Тагын берничә көннән Югары Совет сессиясенең көн тәртибендә республика бюджеты каралачак. Мине, язучы, журнал мөхәррире һәм депутат буларак, бюджеттан матбугатка биреләчәк өлеш мәсьәләсе бик борчый. Үзебезгә кирәк акчаны даулап ала алырбызмы, юкмы? Монда шунысы да бар: ул бирелгән финанс микъдары милли басмалар үсешенә җитәрме, әллә байтак өлеше урыс телендә безнең мәнфәгатьләрне кайгыртмаган басмаларны асрауга тотылачакмы? (Казанда һәм республиканың башка зур шәһәрләрендә гәҗит-журнал укучыларының 80 проценты чамасы урыс телендәге матбугатны укый. Шуны укып, сәяси, икътисади һәм әхлакый тәрбия ала.) Әлбәттә, республика бюджеты да «әндри казнасы» түгел, һәр мөмкинлекнең чиге бар. Хәзер һәр тармак, һәр оешма, хәтта аерым шәхесләр, кирәкме-кирәкмиме, дәүләттән күбрәк сорап, күбрәк үз мәнфәга-



*Язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышыннан бер күренеш. 29 гыйнвар, 1993*

тен даулап калырга тырыша. Шул уңайдан үтә еретик һәм кемгәдер парадоксаль тоелган сораулар да туа. Әйтик, бүгенге бөтен басмалар да халыкка кирәк микән? Хәзер рәсми лицензия алган нәшриятлар гына йөзләгән исәпләнә. Мәсәлән, моннан ике ел элек Югары Совет тарафыннан тәгаенләнгән «Казан» дигән журналның хаҗәте бүген ни дәрәҗәдә? Дөресен генә әйткәндә, ул әлегә кварталга бер тапкыр чыга торган альбом. Ә чыгымнары күпме?! Бүгенге шартларда «Татарстан» (элеккеге «Татарстан коммунисты» нигезендә корылган) журналының ике телдә чыгуы мәслихәтме? Тиражлары бик бәләкәй була торып та, икешәр телле ике редакция асрау республика өчен мәгънәлеме? Бәлки, вакыт

һәм халык тарафыннан күп дистә еллар сыналган төп милли басмаларыбызның матди-техник базасын ныгыту кулайрактыр?

Әдәби ел йомгакларына багышланган бу җыелышта, нигездә, «Казан утлары»нда басылган әсәрләр турында фикерләр әйтелде. Бу, әлбәттә, безнең өчен куаныч. Шулай да тынычланырга урын юк. Югары кимәлдәге талантлы әсәрләр теләгәннән күпкә азрак. Ашаган түгел, тураган белә дигәндәй, эш дәвамында моны ачык тоясың. Хакимиятнең фәлән съезды, фәлән карары «яктылыгында» язылган «актуаль» язмалар чоры үтте. Әсәрләр — шигырьме ул, хикәяме, пьеса яки романмы — тормышчан, хакыйкый һәм талантлы булып, милли үзаңны үстерүгә, рухи тераюга хезмәт итәргә тиеш.

*1993, гыйнвар*

# УЛ ҖӘЙДӘН БЕР ХАТИРӘ

1998 елның җәендә зур бер Сабантуй тамаша кылырга насыйп булды. Көрәштә үк булмаса да, чыгыш белән катнаштым да әле мин анда. Кайда булды соң ул Сабантуй — Арчадамы, Каенлыктамы йә Шәле кебек берәр зур авылдамы? диярләр. Юк, Үрнәктә. Кайсысында? (Мондый исемдәге авыллар да Татарстанда уннан артык.) Үрнәк дигән авылларның иң кечкенәсендәдер, мөгаен. Балык Бистәсе районындагы, Камадан ерак түгел, тирә-ягы урманнар белән уратып алынган кеп-кечкенә авыл ул. 17 йорт, 50 ләп кеше яши, хезмәткә яраклы яшь сау-тазасы 15 ләп, 17 се — пенсия яшендәге карт-коры, калганы — бала-чага... Авылның 400 ләп гектар җире, 4 тракторы (берсе шәхси), 2 җиңел машинасы бар. Тагын... 4 ат, 8 савым сыеры, 150 ләп сарык. Тагын... үтә күренмәле кыска бер урам, ике су колонкасы, һәм ... авылдан чакрым чамасы ераклыктагы 150 ләп гүр иясен үзенә сыендырган зират.

Менә шул авылда узды да инде әлеге Сабантуй бәйрәме. Әлбәттә, бәйрәм үзеннән-үзе була алмый, көчле теләк белән билгеле бер дәрман-чыгым тотып, оста итеп оештырганда гына барып чыга торган нәрсә бу. Димәк, сәбәп тә төпле, теләк тә көчле булган. Сәбәп — Үрнәк авылы оешуга 70 ел икән. Теләк дигәне, миңа калса, кечкенә авылларда тереклек итүчеләрнең күңелен күрү (берсенең мисалында булса да), аларны тормыш орбитасында итеп сиздертергә тырышу, инде бүтәнчәрәк әйтсәк, кече авылларга игътибарны юнәлтү, аларга ярдәм итәргә омтылу. Район хакимиятенең элеккеге башлыгы Хатип Газизов (ул хәзер Татарстан Эчке эшләр министрлыгында җаваплы вазифа башкара) бу мәсьәләгә аеруча нык игътибар биреп килде. Бу кечкенә авылда шундый зур бәйрәмне оештыруның баш кешесе дә ул булды. Бәйрәмгә бу авылдан чыккан яки аңа бәйләнешы булган байтак кешеләр җыелган. Арада Татарстан юл эшләре башлыгы да бар (юкка чакырмаганнардыр, юл төзү буенча файдасына өмет итәләрдер). Авылны үз канаты астына алган «Агроснаб» хезмәткәрләре, районның мәгариф һәм мәдәният җитәкчеләре... Казаннан чакырылган кунаклар, шулар арасында мин дә бар идем.

12 июнь. Җомга. Җәй чилләсенең бер көне. Эссе булса да, урман аланлыгы булгач, җиләс, күләгә урыннар да җитәрлек. Табигатьнең өлгергән кыз чагы. Үлән мул, чәчәкләр — бихисап. Авыл кырыендагы матур аланлыкта, классик әдипләребез әсәрләрендә сурәтләнгәнгә охшаш Сабантуй күре-

нешләре. Әлбәттә, заман атрибутлары белән. Агач күләгәләренә поскан кырык-илле җиңел машина, «бу безнең заман инде, агай!» дип, тәрәзләрендә кояш уйнатып елкылдап торалар.

Ә шулай да, балачакны хәтерләткән Сабантуй иде бу. Авыл тарихында күрелмәгән үзгә бер вакыйга буларак, һәркем моны үзенчә тойды, зурлады һәм үзенчә зурланды шикелле бу көнне. Халык үзебезчә матур киенгән, сәрхуш йөзле кешеләр юк, балалар күп. Алар тере чәчәкләр булып гөлүләннәр арасында мәш килә. Күңелле. Җанга рәхәтлек иңдерә торган манзара. Халык байтак. Күрше-тирә авыллардан килүчеләр күп. Артистлар да чакырылган, районнан да, Казанның үзеннән дә. Зур авыллардагы Сабантуйдагыча бөтен йола-шартларын туры китереп барды тамаша. Ул малайлар көрәше дисеңме, багана-колгага менү, чүлмәк вату, җыр-бию... Хәтта күрше Шомбыт авылыннан килгән үсмерләр көнчыгыш халыкларының милли көрәш — кун-фу алымнарын күрсәтеп көрәшеп тә алдылар. Мәйдан түрендәге президиум шикелле урыннардан торып, район, авыл хуҗалары, кайткан кунаклар котлау-тәбрик сүзләре әйттеләр. Кояш кыздыра, мәйдан кыза, халык бәйрәм итә...



*Тиздән Сабан туйлары...*

Аяк-билләрне бераз язып алыйм дигән булып, урындашларым янында кузгалып, берүзем авыл ягына юнәлдем. Якын инде — 50–60 адым гына. Авыл уртасында басып торам. Урам буп-буш. Уңга карасаң, 7–8 йорт, сулга карасаң, 7–8 йорт. Элек булган йорт урыннары да бар. Бүген шаулап үзенең 70 еллыгын бәйрәм итә торган юбиляр авыл — Үрнәк шушы була инде.

...1928 елда, элек Лихачев байныкы саналган бу җирләргә Югары Тегермәнлек авылыннан берничә гаилә күчеп килеп, өй җиткереп, беренче кышларын чыга. Авыл тарихы шулардан, бу эштә башлап йөрүче Габдрахман Сөләйманов һәм аның иптәшләре каккан казыклардан башлана. Икенче елны тагын биш-алты гаилә күченә. Районнан килеп һәр гаиләгә җир бүлеп биргәннәр...

Батыр йөрәкле кешеләр, уңган, булдыклы кешеләр булганнар бу күченүчеләр. Яңа җирдә тамыр җибәреп кара! Бура да күтәр, мич тә чыгар, итек тә бас, мал үрчет, иген чәч, өстәвенә әле, кирәк чакта, табиб та бул! Туган нигезләрендә тормыш итү җиңел булса, кузгалмаслар иде. Җирсезлектән интеккәннәрдер. Безнең якларда авыллар бик тыгыз урнашкан. Өстәвенә зурзур авыллар: Күгәрчен, Балтач, Югары һәм Түбән Тегермәнлек, Ямаш, Куки... Иркен көтүлекләр, болын-әрәмәлекләр аз. Мал-туар асрау бик читен. Шуңа күрә дә безнең як халкының кышкылыкка печән дигәндә өмет күзләре гел шул Кама буйларындагы иркен болыннарда иде. Ерак Болын дип тә йөртәләр иде ул тарафларны. 1977 елда «Ерак Болынны сагыну» дигән шигырь дә язган идем әле. Ул болай башлана:

Бәйрәм иде Болынга чыгулар!
Сөю сүзедәй хәтергә уелган исемнәр!
Изелчик,
    Төбе Тавы,
        Кызылъяр,
            Күгәрчен,
                Уракчы...

Балачакның төсле рәсемнәре —
    кыңгыраулы олаулар,
        покостагы ир-егетләр,
            ак яулыклы кыз-киленнәр,
                тезелеп киткән чыбылдыклар,
                    айлы кичтә җырлы уеннар,
                        казан аскан дәртле учаклар,
                            камыш баскан түгәрәк күлләр,
                                күмәк табыннар...

...Коры елларда Ерак Болын чыга
уйдык-уйдык атаулар булып.
Күңелемнән утлар ягып чыгам аларга
йокы алмаган төннәремдә.

Күченүче бу кешеләр тәвәккәл генә түгел, төптән уйлый белүче акыллы затлар да булганнардыр дип уйлыйм. Җир юк, яшәргә рәт юк, дип, ул чакта читләргә, бик-бик еракларга, әйтик, Себер якларына күченүчеләр дә байтак булган бит. Дөрес, вербовка, разнарядка дигән боерык-күрсәтмәләр дә үз эшен эшләгән. Әмма барыбер Тегермәнлектән Изелчик — Пүчинкә якларына (туган нигездән нибары 10 — 15 чакрым ераклыкка) күченү мәгънәлерәк тә, отышлырак та, нәсел саклау өчен файдалырак та.

...Ә Сабантуй гөрли. Кешеләр бәйрәм рухын тоеп, сеңдереп, үзләренчә һәркем «батыр» булып хис итә торган сәгатьләр. Сәгадәтле сәгатьләр! Үрнәк кайчан күргән әле бу тамашаны, һәм әле кайчан күрер?

Кайткан кунаклардан бер төркем булып зиратка барып килдек. Авылдан шактый ерак. Әйткәнемчә, бер чакрымлап булыр. Ә безнең авылларда зират (җир җитмәгәнгәдер инде) торак-йортлар белән тоташкан.

...Кояшлы, ямьле Сабантуй мәйданына кайтабыз. Янәшәмдә шушы авыл егете Сабирхан. Якташ инде. Өстәвенә башкалабыз Казанның үзәге — Вахитов районы хакимияте башлыгы да. Сабирхан Фәйзрахманович Мөхәрләмов. Арабызда тагын бер олпат ир-егет Ренат Гобәйдулла улы Сәләхов. Ул да бу як кешесе — элеккеге Кызыл Йолдыз районы үзәге — Котлы-Бөкәштән. Без басып торган җирдән 7–8 чакрым гына. Ренат ага укытучылар династиясеннән, затлы нәселдән. Башкаланың үзәге белән идарә итәрлек егетләр үсеп чыгасын 70 ел элек күченгәннәр, мөгаен, башларына да китермәгәннәрдер. Сабирхан Фәйзрахман улы* — Татарстан халык депутаты, Татарстанның атказанган төзүчесе, техник фәннәр кандидаты... Ярый, болары аның бүтән кешеләрдә дә булырга мөмкин. Ә менә төс-кыяфәте, үз-үзен тотышы, эш-гамәле белән интеллигентлык, затлылык каян килә? Күченүчеләрнең көчле геннарыннан, таза орлыктан киләдер ул сыйфатлар. Әйткәнемчә, Вахитов районы — күп

* Хәзер ул «Оргсинтез» заводы генераль директоры урынбасары *(Ред. искәрмәсе).*

югары уку йортлары булган, гомер-гомергә интеллигенция тупланган район. Төрле-төрле милләтнең мәшһүр кешеләре яши монда. Өстәвенә биредә иске шәһәр өлеше, урысча әйткәндә, «ветхое жилье» дигән бик тә авыр мәсьәләнең «кратеры» шушы районда. Шундый катлаулы хәлләрнең үзәгендә безнең Сабирханыбыз.

Күз алдына китерегез кышын Үрнәк авылын! — тайга тынлыгы, кар патшалыгы, бүреләр улавы, суыктан бүрәнәләр чатнавы, тәрәзәдәге бозны эреткән тишектән — Табигать илаһилыгы... Ә җәен? Гөрләвекләр белән башланган очсыз-кырыйсыз эш-мәшәкать: су ташу, бәбкә саклау, сумала-чәер җыю, тирес чыгару, мал көтү... Бәрәңге дигәннәре үзе бер җәй «рәхәте» — казу, утырту, утау, өю, алу, ташу... Ә урман-болын эчендә урнашкан җирдә чебен-черки... Монысын үзе күргән-кичергән кеше генә белә. Сыерларның тәненә күкәй салган кигәвеннең яралгысы — украны чыбыркы сабы белән сытып чыгарасың... Маллар рәхәтлектән ыңгырашып куялар... «Корыч менә шулай чынықты». Без балачакта укып үскән Н.Островский китабының исеме шулай иде. Үрнәк дигән сүз чыкса, мин Сабирхан якташымны искә төшерәм. Казан үзәгендә дә, ерак якындагы Үрнәк юлында да... Бу авылдан чыккан тагын бер башлык — Рәфыйк Рәшитов та



*Кама буе — туган як*

бар иде әле. Ул инде мәрхүм (авыр туфрагы җиңел булсын!). Заманында Балык Бистәсендә район башкарма комитеты рәисе, соңрак Чүпрәледә райкомның беренче секретаре, хәзергечә әйтсәк, хакимият башлыгы булган кеше. Кызык хәл: заманында минем абыем — Рафаэль Фәйзуллин әле әйткән шәхес — Рәфыйк Рәшитов белән бер сыйныфта укыган, ә мин исә аның энесе, соңрак Татарстанның атказанган уйлап табучысы булачак Мансур Вәлиев (ни кызганыч, инде ул да вафат...) белән бер партада укып үстек. Дөресен әйтим, көнләшеп, ярышып укыдык. Үрнәк егете белән бер-беребездән үрнәк алып укыдык. Икебез дә Котлы-Бөкәш мәктәбен алтын медаль белән тәмамларга тырыштык. Башлы егет иде дустым Мансур... Әлеге күчеп килүче көчле нәселдән иде.

Сабантуй, әлбәттә, зур бәйрәм, матур бәйрәм. Бәйрәмдә дә гамьле кеше уйлана инде ул. Үрнәк, аның кебек кечкенә авыллар язмышы уйландыра бит. Нишлисең, соңгы 40 — 50 елда әллә нинди метаморфозалар булып бетте алар белән. Берзаман, Үрнәк кебек авылларны бетереп, эрерәк авылларга беркетү сәясәте алып барылды, бер чорда андый авылларга мөстәкыйль-үзбаш идарә бирү хупланды. Кем кайда туган, шунда төпләнсен, шунда гомер кичерсен иде дә бит. Әмма егерме, утыз яки кырык йортлы авылга заман казанышларына тиеш бөтен корылмаларны (балалар бакчасы, мәктәп, мәдәният йорты, спорт бинасы һ.б.) ничек төзеп бетермәк кирәк, аларны тәэмин итәрлек кешесе булмагач, ни өчен дип бу юклык заманында егылып ярыласың, ди. Икенче яктан, андый бәләкәй авылларда яшәүче кешеләр заман яшәеше шартларына лаек түгелмени? Каршылыклы сораулар. Ә менә Үрнәк авылы мисалы уйланыр өчен бик тә гыйбрәтле. Халыкара сәясәттә геноцид дигән сүз бар. Күпмедер дәрәҗәдә Үрнәк тә шул афәткә дучар булган. Кәнизәк кыз кебек төрле кулларга күчеп (күчерткәннәр!) йөргән ул. 50 нче елларга кадәр мөстәкыйль хуҗалык булып яшәгән. Аннан киткән төрле-төрле күчешләр. Яңа Сала авылына кушканнар, аннан Урахчаның (Уракчы?) «Ленинская искра» совхозына, соңрак Биектау авылына... Һәр яңа хуҗа (хуҗалык), Үрнәк белән үзенчә идарә иткән. Күчкән саен нәрсәнедер югалта барган... Бер генә мисал: 90 нчы елларда әле әйтелгән «Ленинская искра» авылның 120 баш умартасын төп утар дигән җиргә төяп илтә. Ә Үрнәктә — 30 оя умарта кала. Эре дип йөртелгән Яңа Салага, Биектауга үз вакытында клуб, бала-

лар бакчасы биналарын сүтеп алып китәләр... Әкәмәт! Әле дә черәшеп, тырмашып яшиләр үрнәклеләр. Монда, әлеге дә баягы, гаярь йөрәкле күченүчеләрнең каны һаман уйный, яшәргә дәртләндерә бугай... Реалист булыйк: үткән 70 елда казаныш дип әйтерлек нәрсә бар? Авыл үсмәгән, эшче көчләр артмаган, яшь-җилкенчәк өйләнеп, балалар үстереп бу җиргә казык какмаган... Нинди үсеш? Нинди прогресс-тәрәккыят? (Дөрес, зират үскән, булган йортлар заман рәвешен алган, машина-техника булдырылган...)

Без дөньяның төрле ил-җирләрендә (бәлки, хакимият башлыклары күбрәк тә күрәдер) булган кешеләр. Аптырагач, уйлап әйтәсең: юллар кирәктер башта. Европа да, Америка да төп дәүләти эшен иң әүвәл юлдан башлады дип беләм. Бездә бит җир иркен, елга-сулар күп, табигый мөмкинлек зур. Тырыш, булдыклы кешеләр җитәрлек. Димәк, товарны да күбрәк җитештерергә һәм аннан тиешле файда күрергә мөмкин. Юл, кем әйтмешли, каядыр илтә инде ул... Яшиләр бит әле хутор булып Балтыйк буе илләрендә.



*Туган йортның ишегалдында шагыйрьнең әтисе — Фәйзуллин Габдрахман. 1993*

«Дөнья мәшәкатьләре бер безгә генәмени!» дигәндәй, Туган як, Үрнәк, гомумән, авыл хуҗалыгы проблемалары маңгайда яңа сырлар ясамый торсын әле бүген! Сабантуйда бит әле без. Үрнәк уртасында җыйнак йортка керәбез. Бу — Үрнәк авылын төзегән фидакарь затларның бер нигезе. Бүген анда хуҗа — Сәүдехан — Сабирханның бертуганы, йорт хуҗабикәсе — Гайнелхәят апа. Шунысы хәтердә калган: төп йортка керер алдыннан бер-беребезгә карашып алдык: затлы ботинкаларыбызны салып керәбезме өйгә, әллә Европача салмыйча гына керәбезме? Беркавым Сабирхан белән бер-беребезгә караштык та, башмакларны салып кердек. Дөрес эшләдек. Йоласы шул, тәртибе шул... Каен җиләге вареньесы белән чәйләү, телеңне йотарлык бәлешне авыз итү, авыл хәлләрен сөйләшеп алу — безне тәмам балачагыбызга кайтарды бугай ул көнне.

...Менә шулай үтте ул Сабантуй. Үрнәктә бер үрнәк күрсәтелде. Төптән уйласак, республика өчен дәдер. Мин бәян иткән сүзләр, күзәтүләр, кайбер анализлар үз шәхси фикерем. Бу җыенда байтак акыллы башлар бар иде. «Кечкенә авыллар» проблемасы мәсьәләсен чишүнең бүтән юлларын алар күбрәк беләдер...

Көн кичкә авышты. Бу авыл белән саубуллашып, бер зур савытка Үрнәк чишмәсе суы алып, юлга кузгалдык. Юл матур күренә! Сабантуйдан кайтабыз бит! Бу сәфәрдә юлдашым булган улым Алмаз белән киңәшкәч, туган авылым Балтач аша урап кайтырга булдык. Анда да Сабантуй икән. Без әллә ни күренеп йөрмәдек. Сабантуй мәйданыннан ерак түгел тау битендәге зиратта әнием каберен зыярат кылдык та, һәркем үз уен уйлап, Балык Бистәсе, Полянка, Имәнкискә кебек эреле-ваклы авыллар аша Казаныбызга кайттык.

*1998, декабрь*

## ЯЗУЧЫЛАР ӨЧЕН ДӘ МӘКТӘП БУЛДЫ

Казан университеты кемнең дә булса данлавына мохтаҗ түгел. Аның шанлы исеме бөтен дөньяга мәгълүм. Шулай ук өлкән яшьтәге кешегә «мин фәлән-фәлән уку йортында укыдым, фәлән вуз тәмамладым» дип күкрәк кагу да (яшьрәк чакта ярыйдыр да) бик үк килешеп бетмәс. Ил алдында кылган игелекле гамәлең булса, аның үзеңә дә, янәшә тирәлегеңә дә, туган йортыңа да, мәктәбеңә дә яктылыгы үзе төшә ул.

Университетка китап аша, китаплардан алынып тулышкан хыял аша килдем мин. Балачакта һәрберебезнең тизрәк үсәсе, үсәсе дә тизрәк зур кеше буласы киләдер. Ул вакытта минем өчен иң зур кеше — язучы. Алар гүя могҗизага ия тылсымлы кешеләр. Алар бөтенесен беләләр: нинди каһарманнар турында язалар, нинди гыйбрәтле хәлләрне сурәтлиләр... Яшермим, минем дә классташлар көнләшерлек, авылдашлар горурланырлык зур кеше, ягъни язучы буласым килә! Ә максатка ирешү юлы бер — зур белемле булу. Моның өчен тырышып укырга кирәк, вузга керергә кирәк! Барыр җир билгеле — университет. Казан университеты. Бу уку



*Казан университетының төп бинасы*

йорты турында күпме яхшы сүз ишетелгән дә, күпме матур җөмләләр укылмаган! Шик тә юк — дөньяның иң мәшһүр университетларының берсе инде ул! Ленин кадәр Ленин белән бәйле җирдә укып та хыялың тормышка ашмаса!

1960 елны тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Ул елларны вузларга, нәтиҗәдә берничә ел хезмәт стажы булган егет-кызларны алдылар, яңа мәктәп бетергәннәргә урын бик аз иде. Ялгышмасам, гомумсанның уннан бере чамасы. Шуңа күрә андый «яшел борынлы»лар группада, гадәттә, берничә генә була. Ниһаять, мин студент! Шунсы горурлык: бернинди танышсыз, ярдәм-мазарсыз үзебез керә алдык. Минемчә, сугыштан соңгы дәвердә фәкать үз көченә генә ышанган, идеалы һәм иманы булган буыннар җәмгыятьнең арка сөяге булып тора алды да.

Студентлык елларында эшкә бара торган сыман ике урыным булды: берсе — университет, анда белем алам; икенчесе — Матбугат йорты, анда «язучылыкка практика» үтәм. Газета-журналларда мәкаләләр, репортажлар, шигырьләр еш басылып тора. Димәк, хезмәтемә азмы-күпме ихтыяҗ бар. Димәк, университетта алган белемем иҗтимагый тормышта беркадәр чагылыш таба! Берничә ел университетның әдәби-иҗат берләшмәсенең җитәкчесе дә булырга туры килде. Ул вакытта университетта яшь иҗатчылар күп һәм көчле иде. Бездән әз генә алда укып чыккан Р. Кутуй, Р. Солнцевлар үзәк матбугатта шау килә. Болар — рус телендә иҗат итүчеләр... Безнең туган телдә язучылар да җитәрлек. СССР Язучылар союзы әгъзасы булган укытучылар — Х. Госман, М. Хәсәнов, И. Нуруллин, З. Мәҗитов... Соңрак бу төркемгә М. Мәһдиев, М. Госманов, Т. Галиуллин, А.Яхин, Х.Миннегуловлар килеп кушылды. Университетны элегрәк тәмамлаган язучыларның исемнәре дә гел искә алына: Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, М. Хөсәен... Безнең чорда һәм соңрак университеттан чыккан язучылар бихисап. Бүгенге Язучылар оешмасының алар, мөгаен, яртысын тәшкил итәләрдер.

Университет һәм әдәбият. Минем өчен бу ике сүз, аерылгысыз ук булмаса да, бик якын тугандаш төшенчәләр. Чөнки бу уку йорты башлангычтан ук язучылар исеме белән мәшһүр: С. Аксаков, Н. Ибраһимов, Л. Толстой, В. Хлебников... Димәк, нигезе үк әдәбият белән бергә салынган. Бу матур традицияләр гасырдан гасырга күчеп алга таба да уңышлы дәвам итәр дияргә ышаныч бар.



*Университетның әдәби берләшмәсе утырышы. Уртада — Н.Юзиев, Г.Кашшаф. Уннан өченче — Р.Фәйзуллин*

Моннан 200 ел элек ачылган университетның кодекс-уставы бар. Ул, әлбәттә, Россия империясе мәнфәгатьләрен кайгыртып ачылган уку йорты. Казан җирендә XIX гасырда оештырылган төрле уку йортларын беләбез: духовная семинария, духовная академия, ветеринария институты, керәшен-татар школасы... Алар, инородецларның, шул исәптән татарларның теле, мәдәнияте чәчәк атсынга ачылган дип уйлау беркатлылык булыр иде. Октябрь инкыйлабына кадәр — йөз елдан артык вакыт эчендә университетта безнең халыктан нибары берничә дистә кеше укыганлыгы күп нәрсә аңлата. Шөкер, XX гасырда бу данлы университет чын мәгънәсендә интернационал уку йортына әйләнде. Татарстан тормышының төрле мөһим тормышларын университет тәмамлаган белгечләрсез күз алдына китереп булмый хәзер.

Шәхсән үзем, әгәр яшьлек хыялымдагы омтылышларның шактые тормышка ашкан икән, моңарга Казан университетына бурычлымын.

*2004*

## УЗДЫ ШАУЛАП БӨЕК БӘЙРӘМ

Әйе, безнең өчен бөек бәйрәм булды бу. Соңгы дәвердә тарихыбыз тоныкланып, башкалабыз Россиянең өлкә шәһәрләре рәтенә кереп бара иде. Хәтта «Казань городок — Москвы уголок» гыйбарәсе дә онытылып килә иде бугай... Импер максатлы, шовинист рухлы даирәләр өчен Казанның зур тарихлы, дәүләт тоткан халыкның башкаласы булуын оныттыру хәерлерәк иде. Казанның яшен чикләүгә, кыскартуга, борынгылыгын шик астына алырга тырышу омтылышлары үзе бер тарих. «Ятимнәрнең туган көне кемгә кирәк!..» Бу сүзләр моннан чирек гасыр элек тикмәгә генә каләм очына килмәгән инде...

Казанга мең ел! Шөкер: нинди олуг тантана белән үтте ул! Моннан ун-унбиш ел элек, шәһәребез юбилее дөнья масштабында уздырылыр, бәйрәмгә дистәләрчә ил башлыклары килер, бу җирләрдә моңарчы күрелмәгән тамашалар, үзенчә халыкара сабантуй булыр дисәләр, мөгаен, ышанмас идек. Халык гыйбарәсендә әйтелгәнчә — «булмас димә, дөнья бу!»

Һәр гамәл, асылда, киләчәк өчен, киләчәк хакына эшләнә. Йолалар да шулай, бәйрәмнәр дә. Туйлар да шулай: бәби туе, кавышу туе, хәтта озату туе... Киләчәккә, яңа буыннарга гыйбрәт, сабак, үрнәк өчен. Казан бәйрәме дә шуңа мисал. Тантаналарның төбендә «без булган, без — бар, без — булачак!» дигән асыл мәгънә ята. Шунысы куанычлы: Казан



*Болак бәйрәм бизәлешендә*

бәйрәме, нигездә, татар бәйрәме, татар рухын күтәргән бәйрәм булып узды. Һәм күпләр тарафыннан шулай табигый кабул ителде дә. Чит ил башлыклары, килгән кунаклар Казанның данын, шул исәптән татар халкының үткәнен күтәреп сөйләделәр. Казан аша халыкны таныта алуда гаять хикмәтле ыргым булды бу.

Бәйрәм алдыннан Казан үзе дә нык үзгәрде — матурайды, баеды, көязләнде. Күк катларына менеп карыйсыңмы, Идел өсләреннән яки Арча яклары киңлекләреннән торып багасыңмы — шәһәр, билләһи, бер асыл мәрҗән инде! Шагыйрьнең «Сказаньем встает Казань!» дигән сүзләре бигрәк тә рас килә хәзер. Әүвәлге гасырларда Казанны күреп сокланган сәяхәтчеләр хәтергә килә. Аларның күбесе Казан турында сокланулы сүзләр әйтеп калдырган бит. Хәзерге сәяхләр дә шулай уйлыйлардыр.

Казан үзәгендәге манзараларны яхшырак күреп, шәһәрнең эчке җегәрен һәм рухын аңлар өчен тәүлекнең ике вакыты бик җайлы: берсе — таң белән, кешеләр әле уянмаган чакта буш урамнар, йорт-диварлар белән бергә-бер торып, «сөйләшеп» йөрү; икенчесе — кич вакыт, халык, бигрәк тә, яшьләр кайнаган чак. Төрле төстәге утлар, авазлар, исләр вакханалиясе... Бу вакытта инде Казан чын мәгънәсендә «кайный». Тәнең сау, дәртең сүнмәгән булса, син үзең дә шул «казан»да рәхәтләнеп быгырдарга риза... Соңгы елларда корылган сарай-биналарның күплеге һәм аларның грандиоз мәһабәтлеге таң калдыра. Казаннан 10–15 ел элек китеп, хәзер кайтып күргән кеше күп урамнарны танымас та хәзер. Яңа метро, яңа күперләр, яңа мәйданнар, яңа һәйкәлләр, яңа сарайлар... Гел яңа, яңа, яңа...

Ә искеләр, борынгылар? Яңа төзелешләргә бәйле рәвештә бик күп борынгы корылмалар вәйран булды. Бигрәк тә агач архитектура үрнәкләре юкка чыкты. Кирпеч-таш бер нәрсә, ә агач агач инде ул! Табигатьнең эчке җылылыгын сеңдергән, берсеннән-берсе кабатланмас, матур, яхшылап реставрацияләсәң тагын берничә гасыр торырлык уникаль биналар урамы-урамы белән кайтмаска югалды. Аларны бернинди акча бәрабәренә дә кайтарып булмый инде... Күрәсең, без әле борынгы яхшының хәзерге яхшыдан күпкә кыйммәтрәк икәнен аңлап бетермибез. Сәбәпләре ике: рухи ярлылык, матди фәкыйрьлек... Яңа, биек, бай йортларга карап, җырдагыча, «Яңа ярлар иске ярны оныттыра» дип юанырга кала. Шулай да күңелне төшермик: афәтләрнең ниндиләрен генә

күрмәгән ул Казан! Баскыннарның вәхши җимерүләрен дә, пожар-янгыннарның ялмап алуларын да... Булганына, торгызылганына (Кол Шәриф мәчетенең шәһәр символы булып яңадан калкуы үзе ни тора!) шөкер итәргә кирәктер.

Меңьеллык... Күптән язылган шигырь юллары искә төшә. «Безнең якта — борынгыдан хәрабәләр генә. Чын тарихны азлар белә, хәбәрдарлар гына...» Чыннан да, меңләп ел элек булган чын хәлләрне бик азлар чамалый. Чын тарих ерак яшерелгән. Үз тарихыңны ят телдәге чыганаклардан өйрәнеп, тулы хакыйкатькә чыгу кыен. Шунысын да искәртик: кышы күбрәк була торган якта яшибез бит. Безнең җирләр ел әйләнә җылы кояш иркәли торган Урта диңгез буйлары түгел, кыя ташлы диңгез ярларың юк... Чын нык ташлар Урал тауларында гына. Менә бу бина-корылма меӊ ел элек салынган дип төртеп күрсәтү кыен... Андыйлар бөтен Рәсәендә дә бар микән? Булса да, бик сирәктер. Дөрес, ерак төрки бабаларыбызның Азау-Тын (Азов-Дон) яки Алтай-Йәнәсәй яланнарында әлегә кадәр сакланып калган таш балбаллары бар барын... Идел-Чулман буйларындагыларыннан безгә якыннарыннан (чакрым үлчәве белән әйтүем) Алабуга янындагы «Шайтан каласы», Болгардагы корылмалар... Урал якларындагын исәпләсәк, серле Аркаим...

Меңьеллык — ул зур сан, биек сан. Безгә Казанның меңьеллык бәйрәмен күрү насыйп булды. Без һәм безнең балалар-оныклар горурлык белән «меңьеллык борынгы Казанда гомер кичерәбез!» дип әйтә алабыз, эчке тойгы белән Казанны дөньяның борынгы Рим, Истанбул, Афина, Сәмәрканд кебек шәһәрләре белән тиңләп чагыштырабыз. Таулар таулар белән сөйләшә, диләр бит... Шунысы да бар: биеклекнең үз кануннары. Биеклекне яулау — бер авырлык булса, биеклектә кала алу — аерым бер җегәр сорый торган вазифаи авырлык. Казанның яше, бәлки, мең елдан да артыктыр... Әмма булган меңен дә әлегә саклый һәм ул статусны һәрдаим ныгытып тору хәерле. XVI — XVII йөзләрдә Идел-Чулманның бай җирләренә килеп урнашкан баскынчыларның утар-чиркәүләрен торгызып кына Казанның борынгылыгы артмас. Шуңа да иң әүвәл әлегә азмы-күпме матди хәлебез бар чакта, мирасыбызның борынгы өлешенә — меңнең беренче өлешенә — күбрәк игътибар юнәлтергә тиеш булабыз. Бу очракта беренче чиратка, борынгы әдәби ядкәрләр алга чыга. Шөкер, аларның кайберләре исән-сау, шагыйрь әйтмешли, аларны «туплар да ватмады, уклар да кадамады». Әдәби

мирастан кала, әлбәттә, материаль ядкәрләр. Шул ук Биләр-Болгар корылмалары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик һәйкәлләр... Болар һәммәсе мәдәни борынгылыгыбызны, Казан юбилееның, тәрәккыятебез үсешен күрсәткән табигый бер дата икәнен раслаучы дәлилләр. Әмма аларны киң дөньяга белдертәсе: күпләргә, бик күпләргә аңлатасы, ирештерәсе, сеңдерәсе, киң дөньяга белдертәсе бар.

Казан, университетлы шәһәр буларак, гасырлар буе Россия империясенең иң алдынгы шәһәрләреннән саналган. Юбилей уңае белән Казан үзенең бу статусын яңадан кайтарды: Россия шәһәрләренең беренче өчлегенә керә ул хәзер. Матурлыгы ягыннан да, интеллектуаль дәрәҗәсе ягыннан да. Ә татар кешесе өчен дөньяда беренче шәһәр, иң кадерле шәһәр ул!

...Яңгыр явып үткәннән соң кичке Казан әкияти матур. Аяк астындагы җирдә — урам-мәйданнарда янә бер сихри күренеш — шәһәрнең чагылышы пәйда була. Болытлар таралып, күктә чалт йолдызлар да кабынса, бу илаһи сихрилек тагын да арта. Йолдызлар нуры аша ерак кыйтгаларда, читят илләрдә яшәүче кардәш-туганнарыбыз, сагыш һәм өмет белән безгә, шәһәребезгә сәламнәр юллый кебек: «Исән-сау бул, Казан! Яшә генә!»

*2005, сентябрь*

# *Каләм изгегә тартыр*





## ӘДИП ИСЕМЕ — ОЛЫ ИСЕМ

Соңгы 6—7 ел эчендә поэзиябезнең күзгә күренеп баюында, төрлеләнеп шәбәюендә, тирәнәюендә яшь каләм ияләренең дә сизелерлек өлеше бар. Бу өлеш, әлбәттә, әсәрләр күләме белән генә билгеләнми; яшьләрнең томнар чыгарырлык калын хезмәтләре юк әле. Бу өлеш, беренче чиратта, аларның яшьлеккә хас булган дәртле омтылышларны, саф кичерешләрне, мөкатдәс уй-теләкләрне садә һәм табигый хәлендә җырга, шигырьгә күчерүләрендә. Олы учак җилгә һәрчак сөенә, ялкын телләре аны кочагына ялмап ала. Болай да куәтсез булмаган татар поэзиясе учагына яшьләр иҗаты бер шифалы сулыштыр.

Ил һәм халык кичерешләрен шәхси кичерешләр белән берлектә тою, заман рухын ачык сиземләү, вакыт таләп иткән көйдә заманча җырларга омтылу, хакыйкатькә күз йоммыйча туры карау, үз уй-хисләреңне, башкаларга иярмичә, кабатланмас индивидуаль аһәңне бизәкләр белән тулы итеп кешеләргә җиткерергә тырышу — яшьләр иҗатына хас асыл сыйфатлар. Күрәсең, шушы сыйфатлар булу яшь көчләрнең иҗатларына игътибарны көчәйтте, аларның заманыбызга лаек хисләр яза алуларына ышанычны ныгытты. Әледән-әле булып торган семинарларда, конференцияләрдә, ел йомгаклары мәҗлесләрендә яшь язучылар адресына әдәби тәнкыйть һәм җәмәгатьчелек тарафыннан әйтелеп килә торган хуплау сүзләре, республикабыз һәм үзәк матбугат битләрендә яшь авторларның матур-матур гына әсәрләре күренгәләп тору, кайбер талантлы яшьләребезнең Бөтенсоюз шигырь фестивальләрендә призлы урыннар алып, шигырьләренең үзәк нәшриятлар чыгарган махсус җыентыкларда урын алулары әйткән фикеребезне раслый булса кирәк.

Бу беркадәр уңышлар, беренчедән, яшьләрнең язучылык эшенә җитди карап, әдәбият мәйданына шактый әзерлекле килүләре белән аңлатылса, икенчедән, иҗади оешмаларның һәм өлкән язучыларның үзләре артыннан килүче яшьләрдән лаеклы алмаш тәрбияләү турында өзлексез кайгыртып торуларының күркәм бер нәтиҗәсе.



*Әдәбиятның олуг әдипләре — Н.Арслан (сулдан уңга), С.Кудаш, Х.Туфан, С.Хәким. 1964*

Үткән елның җәй башында Казанда РСФСР Язучылар союзы инициативасы белән оештырылган Идел буе яшь язучыларының зур семинары уздырылган иде. Әле ике-өч ай элек кенә яшь язучыларның тагын бер күләмле конференциясе булып үтте. Берничә көнгә сузылган бу конференциядә катнашкан 100 дән артык яшь язучы әдәби остазларыннан үз иҗатлары турында кыйммәтле фикерләр, эшлекле, файдалы киңәшләр алып, рәхмәт хисләре белән таралышканнар гына иде, менә хәзер алда янәдән зур әдәби мәҗлес — Татарстан язучыларының VII съезды. Һичшиксез, бу съезд җыелышларында да яшьләр иҗаты турында да сүзләр, фикерләр булырдыр.

Шул зур вакыйга алдыннан әдәбиятыбызның киләчәге — алмашчылары турында тагын бер мәртәбә сүз кузгатып, үзләренә һәм иҗатларына күз ташлау артык булмас кебек. Кемнәр ул булачак әдипләр? Алар әдәбиятта нинди яңа сүз әйтергә телиләр һәм ничек әйтергә телиләр? Аларның потенциаль мөмкинлекләре күпме? Нинди традицияләрдә үсеп киләләр? Зәвыклары, стильләре ничек? Уңышлары, кимчелекләре нидән гыйбарәт? Аларны сөендергән һәм борчыган нәрсәләр ни? Үсү процессында мондый сорауларның тууы табигый. Хәрәкәттә туган сорауларны хәрәкәттә үк ачыклап бару — үзе үсү ул. Мүкләнеп яткан таш кына кыймылдамый, үгез үлсә — ит, арба ватылса утын дип караучы пошмасны гына сораулар, уйлар борчымыйдыр.

Иң элек шуны ачыклап китик: исемнәре азмы-күпме укучыга мәгълүм булган, телгә кереп йөри торган яшьләребез яшь ягыннан, чыннан да, яшьләрме алар? Карап, тикшереп баксаң, аларның 30га җитмәгәннәре берничәү генә икән!.. Менә кулыбызда — Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Беренче карлыгачлар» дип аталган коллектив җыентык. Кәгазь тартмачык эчендә шигырь язучы 14 авторның юка гына китапчыклары. Китапның алгы битләрендә һәр авторның автобиографик белешмәсе бирелгән. Дебютантлар сыйфатында чыгучы бу авторларның уртача яше — 32. Арада 40ка килеп терәлгәннәре дә бар. Санның зур булуы уңышлар турында сөйләгәндә генә күңелле, бу очракта борчылдыра торган зурлык бу. Бөек шагыйрьләрнең күбесе 30—40 яшьләрендә матди дөнья белән алыш-бирешен өзеп киткәннәр инде. Пушкинның гомере 38 дә киселгән, Байронның 36да, Есенинның 30да, Шелли белән Такташның 30да, Лермонтов белән Тукайның —27дә... 32 яшьтә, ир уртасы булып, балачагалары сабакка йөри башлагач, 10—15 шигырьле кош теле кадәр, очар-очмас беренче карлыгач булу әллә ни хозурлык түгелдер.

32 яшь. Поэзиядә башлап сүз әйтер өчен тормыш тәҗрибәләре юктыр дисәң, кеше бу яшьтә нәрсәнедер күргән, нәрсәнедер кичергән, дөнья турында кат-кат уйланган, «акыл утырткан» була инде. Хикмәт нидә соң? Әллә алар бу әсәрләрен күптән язып, ниндидер сәбәпләр буенча бастырмаганнармы яки аларның бу эштә табигый талантлары, булдыра алулары шулай гынамы? Ни генә булса да 32 яшь — олы яшь, мондый яшь шагыйрь өчен картлык башы инде. Уйландыра торган хәл бу! (Җәяләр эчендә генә булса да әйтеп үтик, Татарстан Язучылар союзындагы татар язучыларының уртача яше 50 чамасы, 100дән артык союз члсенының икесенең генә яше 30дан ким.)

Сабан туйларына бәйгеләрдә чабу өчен ашкынып, күкрәкләнеп торган яшь кырыкмыш атларны хәзерлиләр. Поэзия мәйданы белән бәйге арасында ниндидер бәйләнеш бар сыман.

Бәлки, Тукайларны, Мусаларны, Бабичларны, Фидаиларны мәктәп яшендәгеләрдән үк эзли башларга, бөртекләп үстерергә, талантлыларын, 30 га җиткәнне көтмичә, 20—25 ләрдә үк әдәбият мәйданына курыкмый, ышанып чыгарырга кирәктер?



*1966 әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыштан соң. Беренче рәттә сулдан уңга: Н. Дәүли, Х. Хәйри, Г. Кашшаф, Ә. Ерикәй, Г. Бәширов, М. Әмир, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Х. Госман, А. Әхмәт, С. Хәким; икенче рәттә: В. Юдин, А. Расих, Г. Ахунов, Х. Вахит, Р. Төхфәтуллин, Ш. Галиев, З. Нури, Г. Латыйп, Г. Бакир, Х. Ярми, Ә. Исхак, Ә. Юныс, Б. Гыйззәт; өченче рәттә: Г. Халит, Р. Мостафин, Н. Гайсин, Ш. Шаһгали, Ш. Зәйниморатов, Г. Минский, М. Фәйзуллина, М. Ногман, С. Сөләйманова, Ә. Маликов, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Р. Бикмөхәммәтов; дүртенче рәттә: Я. Халит, И. Салахов, М. Хәмитов, Э. Касыймов, М. Шәрифуллин, В. Ганиев, З. Мәҗитов, Н. Гыйззәтуллин, М. Рәфыйков, И. Юзеев, К. Фәсәхов, Г. Зәйнәшева, Н. Фәттах*

Без гаять кызык һәм каршылыклы, бай һәм киеренке заманда, тизлекләр гасырында яшибез. Кеше акылы, кичәге хыялларны сыза-сыза, яңа хыяллар тудыра, галәм киңлекләре яулана, кешелеккә хурлык тамгасы булган гаделсез системалар ава, барлык акылларны җәлеп итәрлек идеяләр колач җәя... Шушы бөек чорның илендә яшәп, аның әдибе булырга җыену — шәхеснең гаять тәвәккәл, ифрат җаваплы адымы ул.

Егерменче гасырның икенче яртысының яшь шагыйре, яшь язучысы, яшь әдибе. Шушы сүзләрнең ниләр йөкләгәнлеген, аларның чын тирән мәгънәләрен тиешенчә аңлап бетерәбез микән без, яшьләр?

Әдип, яше ягыннан олымы ул, кечеме, һәрчак үз чорының иң алгы сафында торган. Ул һәрчак үз дәверенең «Давыл хәбәрчесе», байракчысы, елъязмачысы, алдан күрүчесе булган. Бу тарихның буеннан-буена килә. Бу шулай булырга тиешле табигый гомумзакон булып киткән. Шундый югарылыктагы әдип булу һәр чорда да шәхестән титаник көч сора-

ган. Әмма безнең гасыр әдибеннән бу көч икеләтә, өчләтә таләп ителә. Чөнки хәзер әдип белән халык арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрде. Элек, төп хезмәт ияләре массасы торгынлыкта, караңгылыкта, ябылуда булганда, язучы яки шагыйрь алар өчен табынырлык бөек, изге кеше хисапланган. Мәгърифәт чырае күрмәгән халыкка аларның шытырдатып укый-яза белүләре генә дә әллә ни торган, ә калын-калын китаплары акыл ирешмәслек могҗиза саналган...

Хәзер исә хәлләр бөтенләй бүтән. Китап укучының һәр биштән бере югары белемле диярлек. Син алар өчен дөрес, матур җөмләләр оештыручы, калын яки юка китаплар чыгаручы буларак түгел, күпме уйландыргыч фикер, күпме дулкынландыргыч хис бирә алуың белән кызыклы. Хәзерге заман укучысының бик нәзберек зәвыкларын канәгатьләндерү, аларга рухи көч бирү белән бергә, элеккечә халык хөрмәт-ихтирам итәрлек, бөтен мәсьәләләр буенча да үз сүзе булган, киңәш алырлык әдип, җәмәгать эшлеклесе булып калу җиңел эшләрдән түгел. Ирексездән заман герое, замандаш кебек әдәбият фәнендә бик күп очрый торган тәгъбирләр искә төшә. Безнең заман героен әдәбиятта тудыру өчен, иң әүвәл үзеңә шушы вакытның алдынгы, киң карашлы олы кешесе булу, чын мәгънәсендә заманның герое булу кирәктер. Үзеңнең дөньяга карашың чикле, фантазияң ярлы, интеллектуаль дәрәҗәң түбән була торып, үз уй-хисләреңнең ниндилеген чамалый алмас борын, бүтән кешеләрнең хисләре белән идарә итәргә маташу, үзең дә бик томанлы күз алдына китергән ниндидер абстракт идеалларга башкаларны өндәү, үзең дә матурлыкны бик сай һәм беркатлы гына аңлаучы килеш, бүтәннәрне матурлыкка, гүзәллеккә өйрәтергә тырышу үз-үзеңне кызганыч һәм көлке хәлдә калдыру гына булыр.

Бу юлларны язганда, әле күптән түгел генә 60 яшь тулу уңае белән уздырылган бәйрәме кичәсендә хөрмәтле әдибебез Фатих ага Хөснинең үзенә карата әйткән сүзләре келт итеп искә төште: «Мин иҗади гомерем буе ике татлы борчылу белән яшим: мин кешеләргә чыпчык борыны кадәрле генә булса да шатлык китерә аламмы, аларны тормыш, кешелек турында әз генә булса да уйлануга этәрә аламмы?..» Бик гыйбрәтле сүзләр болар. Тыйнаклыкны һәм кешелеклелекне сакларга, ваемсыз канәгатьләнүдән котылырга, үз өстеңдә бертуктаусыз эшләргә, халыкка фидаиларча хезмәт

итәргә, чын әдип булырга өнди торган олы сүзләр. Өлкән әдипләребезнең мондый әйтемнәре безнең хәтер офыгыннан бер мизгелгә дә күмелергә тиеш түгелдер.

Әдәбиятка керергә омтылучы һәр йөз башлап язучының кимендә туксанлабы шигырьләр яза. Бу күренеш, беренчедән, шигырьнең күләм ягыннан бәләкәй булуыннан, язар өчен вакытның да чагыштырмача аз сарыф ителүеннән, тиз басылып чыгу ихтималының да күбрәк булуыннан килсә, икенчедән, башлап язучыларның шигырь язуны башка жанр әсәрләрен язуга караганда җиңелрәк дигән ялгыш карашларыннан килә, ахрысы. Газета һәм журнал редакцияләренә көн саен килеп тора торган әдәби язмаларның күбесенең шигырь булуы һәм аларның, кагыйдә буларак, дүрттән өч өлеше өлгермәгән шигъри әсәрләр булуы шуны күрсәтә.

Менә яшь автор дулкынланып-дулкынланып шигырь яза. Әсәр үзенә ошый, чөнки ул аны беренче тапкыр яза. Авторның нияте дә изге, язмасы да татлы һәм газаплы процесста туды, ди. Ә чынында яңа язма нәрсә соң ул? Яңа туган кеше хакында аның әле кем икәнлеге турында юрамадан бүтән берни әйтеп булмый, ә әдәби әсәргә исә: «Син дөньяга нәрсә алып килдең?» — дип терәп сорау куела. Яңа туган әйбер өчен бик кырыс сорау бу. Нишлисең, әдәбият өчен табигый һәм кешелекле сорау. Чөнки өлгергән, җитлеккән әсәр генә яшәргә хаклы. Яңа туган әйбер нindидер һәм үзенең кайсы ягы беләндер яңа да булырга тиеш. Әллә ничә гасырлар буе кешелек акылы тарафыннан җыйналып, тупланып килгән җәүһәрләр бар бит әле бу дөньяда, һәр чор сәнгатенең, әдәбиятының үз үсеш югарылыгы, үз критерийлары бар. Яңа туганга шул критерий, шул үлчәү белән килеп, бүгенге көн таләбен белдерсәк? Әйтик, шундый әсәр кешелек үсешенең элеккеге этабында да булган, хәтта яхшырак та булган, ләкин аның хәзерге кешеләр өчен бернинди яңалыгы юк, ди. Димәк, бу очракта яңа дигән әйбернең яшәү шанслары кечерәйде. Бәлки, әсәр үзе туган җирлек өчен, аның тарихы өчен күпмедер яңалык китерәдер? Китерсә ярый, хуп, яшәсен. Әгәр гомумкешелек әдәбияты күзлегеннән караганда да, таррак урынчалык-төбәк күзлегеннән караганда да бернинди яңалыгы, бернинди үзгәлеге булмаган әсәрнең дөньяда яшәргә ни хакы бар? (Гомумдөнья әдәбияты күзлеге кебек сүзләрдән, бәлки, кемнәрдер елмаер, безне сабый, дип куяр яки космополитизмда гаепләргә ашыгыр. Ләкин, нишләмәк кирәк,

бүгенге көннең алдынгы укучысы үз теле әдәбиятыннан башка рус һәм чит ил әдәбиятларын даими күзәтеп бара, аларның тарихын, бүгенге хәлен белә. Ул чит илләр әдәбиятын рус теле аша тәрҗемәдә укый йә турыдан-туры оригиналдан таныша. Язучы, теләсә нинди телдә генә язса да, хәзерге укучының бу сыйфатын онытa алмый.)

Ярый, без хәлне абсолют яссылыкка куеп фикер йөрттек, ди. Чынлыкта, шушы хакыйкатьне аңлап, әдәбиятны изге эш дип караучы яшь иптәшнең әсәрләре дә, әйтелгән югарылыкка менеп үк җитмичә, дөньяга күренгәләп куя. Күрәсең, үсү чорында андый хәлләр дә — яшьлек ашыгучанлыгы, иярү булгалый. Ләкин осталыкта төп кыйбла — камиллек, шигърилелек булырга тиеш. Хәзерге вакытта ил күләмендә хуҗалыкның барлык тармакларында набат булып яңгырый торган «советское, значит отличное» девизы күпмедер дәрәҗәдә язучыларга да, беренче чиратта яшь язучыларга кагыла.

Яшьләр иҗатына әдәби тәнкыйть һәм җәмәгатьчелек нигездә уңай бәя биреп хуплап торса да, кайбер кимчелекләрне дә — профессиональ осталыкның бик югары булмавын, тел чатаклыкларын, җирле әдәби традицияләрне начар үзләштерүне даими күрсәтеп килә. Бу дөрес тәнкыйть сүзләрен кабул итәргә кирәк. Чыннан да, борчылырлык, уйланырлык якларыбыз байтак. Яшь әдип өчен кирәк булган барлык сыйфатларыбыз да бар дип әйтә алмыйбыз әле. Моның бер өлеше эрудициянең җитенкерәмәвендә, әдәби телебезне һәм тарихыбызны җитәрлек дәрәҗәдә белмәүдә сизелә. Дөрес, әдәбиятка аяк басып килә торган яшьләребез барысы да диярлек югары белемле. Әмма рәсми белешмәләрдән, дипломнардан тыш, янәдән гомер буе өйрәнелә торган иң кирәкле тормыш белеме бар бит әле. Менә үз эшебезгә кагылышлы бер генә мисал алыйк: ә безнең кайсыбыз борынгы берәр татар шагыйренең әсәрен оригиналда җырлап укып бирә алыр икән? Татар әдәбиятының XII—XIII гасырлардан килгән тарихы турында без еш ишетәбез, еш укыйбыз. Әмма практик яктан алганда, без аны бик начар беләбез. Чынлыкта, сугыштан соңгы әдәбиятны һәм соңгы 10—15 ел эчендә басылган 5—6 классик язучыны гына юньләп беләбез дип әйтә алабыз. Димәк, безнең үсү традицияләре дә гасырлар түреннән үк түгел, ә шактый якыннан гына башлана булып чыга. Монда яшь язучыларны гына эрудициясезлектә гаепләү дөрес үк булып бетмәс, билгеле. Ул

әсәрләрнең кул астында булмавы, фәнни китапханәләрдә тапкан очракта да аларның без күнеккән имляда түгеллеге алар белән ныклап танышуга комачаулый. «Татар поэзиясе антологиясе»ндәге кайбер үрнәкләр, «Борынгы татар әдәбияты» китабы, Мөхәммәдъярның аерым чыккан берничә поэмасы һәм журнал битләрендәге сирәк кенә күренеп куя торган тарихи язмалар гына ун гасырлык әдәбиятны системалы итеп күз алдына китерә алмый. Әдәби мирас сериясе сыйфатында борынгы шагыйрьләрнең әсәрләре чыгарылып, алар белән төпле танышкан тәкъдирдә яшь шагыйрьләр күпмедер дәрәҗәдә осталыкка өйрәнә алырлар иде. Борынгы шагыйрьләрнең бүгенге көн өчен искергән карашларын тәнкыйтькә алып, кешелеклелек, гуманизм идеяләре көчле булганнарын алга сөреп, аларның фикерләү алымнарын, образлар системасын, тасвирлау һәм бизәк төшерү чараларын, стиль һәм форма якларын белү кызыксыз булмас иде. Чөнки үткәнне төпле белгәндә генә бүгенгене яхшы иҗат итеп була.

Икенче борчыган нәрсә — зур актуаль проблемаларны күтәреп чыкмавыбызда, күтәргән очракта да тиешле югарылыкта күрсәтә алмавыбызда, зур дөньяны аркылыга-буйга гизмичә, үз кабыгыбызда бикләнеп ятуыбызда, олы темаларга тотынырга куркуыбызда. Ә бит Шолохов 35 яшендә «Тын Дон»ны язып бетергән инде. Бүгенге көн хезмәт кешеләрен шундый ук көчле художестволы итеп күрсәтеп булмас идемени? Республикабыз үзе дә хезмәткә һәм вакыйгаларга бай тормыш белән яши. Дөньякүләм масштаблы төзелешләр дә, мәшһүр галим-белгечләр дә, тынгысыз студентлар да, фидакяр эшчеләр дә җитәрлек бездә. Яз гына, күрсәтә генә бел! Әйтик, беренче карашка бик үк зур күренмәгән бер генә мисал: 18—20ләрдәге бүгенге яшь кешенең рухи халәтен, мораль-әхлак йөзен сәнгать чаралары белән күрсәтү. Ни уйлый ул яшь кеше? Аның үз шәхесенә һәм җәмгыятькә карашы, үткәнгә һәм бүгенгегә мөнәсәбәте, сөю-мәхәббәтне аңлавы һ.б., һ.б. Әллә никадәрле проблемалар! Аларны дөрес чишәргә генә кирәк. Бүгенге яшь кешенең барлык сыйфатларын яхшы белергә, әгәр характерында чорыбызга лаек булмаган чалымнар бар икән, аларны бергәләп бетерешергә, күркәм якларын тагын да үстерергә тиешбез. Бу — җәмгыятебез алдында торган уртак бурыч. Киләчәк дөнья бит, фильм исеме белән әйтсәк, «бары да кешеләргә кала», яшьләргә кала.

Бүгенге көндә яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү мәсьәләләре бөтен җитдилеге белән куела. Бу — гаять олы һәм җаваплы мәсьәлә. Аны уңышлы хәл итү өчен, әдәбият һәм сәнгать кешеләреннән халык һәм җәмгыять куйган таләпләрне бер мизгелгә дә онытмау белән бергә, дөнья алдында торган олы проблемаларны яхшы белү, капиталистик һәм социалистик системалар арасындагы көрәшнең бөтен кискенлеген халыкча тою, ил язмышын йөрәгең аша кичерү, вакыйгаларның үзәгендә тору кирәк. Менә С. Хәкимнең ГДРда булып кайтканнан соң язылган шигырьләр циклын дулкынлану белән укыйсың. Чөнки шигырьләр чын белү белән язылганнар. Шагыйрь Туган ил, Халык турындагы кичерешләрен читтә, еракта тагын бер мәртәбә сынап караган. Үзең күргән, тойган, белгән нәрсәләр турында гына күңелдә калырлык итеп язып була. Бу җәһәттән яшь язучыларның республикабыздан читкә бик сирәк чыгулары, чит илләрдә бер генә мәртәбә дә булмаулары бер дә канәгатьләндерә торган нәрсә түгел. Тетрәндергеч публицистик шигырьләр урынына укыганнардан һәм кемнәрнеңдер сөйләгәннәреннән чыгып кына язылган, тирән булмаган, дулкынландырмый торган риторик характердагы язмаларның чыга торуы яшьләрнең җитәрлек кадәр йөрмәүләре, җитәрлек кадәр күрмәүләре, вакыйгаларның алгы сызыгында ук булып җитмәүләреннән дә килә булса кирәк.

Бүгенге замандашыбызның чын йөзен олы художникларча әдәбиятта һаман күрсәтеп җиткерә алмау күпләрне борчый. Киләчәк җәмгыять нигезләрен төзүче яшь кеше образларын өлкәннәргә караганда яшь язучылар үзләре тирәнрәк һәм дөресрәк күрсәтә алырлар иде. Бу өлкәдә яшьләрнең сүлпәнлекләрен аклаудан ерак торып, алар файдасына берничә сүз әйтеп китү дә дөрес булыр. Чөнки кайбер җитди сәбәпләр дә бар. Шуларның берсе — яшь язучыларның махсус әдәби органы булмау. Бу — яңа мәсьәлә түгел. Чөнки ул инде шактый озак еллар чишелмичә килеп, һаман да актуаль булып кала бирә. Яшьләр шигырьләр, хикәяләр, поэмалар, повестьлар язалар, ә басылырга урын юк диярлек, Татарстан Язучылар союзы органы «Казан утлары»нда яшьләр еш басыла алмыйлар, журналның күләме чикле булу сәбәпле, авторитетлы өлкән язучыларның әсәрләре дә чиратта тора. Ә газета битләрендә яшьләр иҗаты әллә ни зур урын алмый. Мисал өчен, 30 яшькә кадәр булган яшь

шагыйрьләрнең 1967 елда вакытлы матбугат битләрендә күпме басылганнарын карап үтик. «Казан утлары»нда — 800ләп юл, «Социалистик Татарстан» газетасында — 600ләп юл, «Татарстан яшьләре» газетасында 700ләп юл басылган. Татарстан Язучылар союзында хисапта торган, конференцияләргә, семинарларга чакырылып йөртелә торган, өметле дип саналган яшь язучыларның саны 150дән артык. Ә кулына яңа каләм алган, әдәбият белән чын-чынлап кызыксынучы яшьләр күпме! Шундый зур көч өчен бу күләм бик аз дигән сүз.

Съезд ул — олы җыелыш. Анда бүгенге әдәбиятыбызның торышын ачыклау юнәлешендә әдәбият белгечләре төпле докладлар, чыгышлар ясарлар. Поэзия турындагы чыгышларда 4—5 елдагы үсешне башка халык әдәбиятлары нисбәтендә карау, тикшерүләр булыр.

Безнең поэзиябез соңгы 4—5 ел эчендә күпмилләтле совет әдәбияты үсешенә күпме өлеш керткән? Бүгенге дөньяның иң актуаль проблемалары — тынычлык-иминлек мәсьәләләре, кешеләрнең рухи үзгәрү хәлләре дөнья әдәбиятында, илебез халыклары әдәбиятында ничегрәк хәл ителә икән? Шуларга җавап бирү процессында безнең әдәбиятның уңышлары һәм хәл итмәгән эшләре ныграк күренер, яшьләр алдында үсү перспективалары да ачыкланыр, алар ирешелгәннәр белән генә чикләнмичә, эзләнүләрен дәвам иттерерләр, әдәбият мәйданына тагын да кыюрак керерләр.

*1968, февраль*

# ҮР АРТЫНДА ЯҢА ҮРЛӘР

*(70 нче еллар татар шигъриятенә күзәтү)*

Берәү болай дигән: кешеләрнең үзләренә караганда, җырлары яхшырак, матуррак була. Мөгаен, дөрестер бу. Кеше җырга, дөньялыкта кылганына, ирешкәненә өстәп, тормышка ашмаган хыял-шатлыкларын, иң газиз хисләрен, иң яшерен серләрен дә куша шул. Чөнки кеше җырга, аның зурлыгына, бөеклегенә ышана. Җыр — мәңгелек юлдаш. Кешеләр белән җыр-шигырь дә дәверләр үткән, утлар-сулар кичкән, зәңгәр күк катларына менгән, шахталарга төшкән, данлы яки мәсхәрәле вакыйгалар шаһиты булган. Гади халык җырны үзенчә юлдаш иткән, хөкемдарлар аны үзенчәрәк иш иткән, табигый, җыр-шигырьне тудыручы шагыйрьләрнең үзләренә дә караш төрле дәвердә төрлечәрәк булган. Берәүләр шагыйрьләрне зур көч ияләре дип таныган, берәүләр, хезмәтләрен җитдигә санамыйча, аларга сабыйларга карагандай көлемсерәбрәк караган, берәүләр аларны күккә күтәргән, берәүләр үч алган...

Бүген дә һәммә кеше шигырьгә шул рәвешчәрәк карый, аңлый һәм бәяли дип уйлыйм. Ләкин шигъриятнең, гому-



*Әдип исеме — олы исем. Трибунада — Равил Фәйзуллин. 1970*

мән, әдәбиятның җәмгыятьтәге роле һәркемгә ачык, ул — зарури ихтыяҗ. Реалистик сүз сәнгатенең иҗтимагый тормыштагы олы урыны бездә элек-электән традицияләр белән расланып киленгән һәм бүгенге сәясәт белән дә ныгытылган. Дөрес, төрле контингент халык арасында, кайчак хәтта сәнгатьнең үз кешеләре арасында да, бүгенге шигърият һәм шагыйрьләр турында саерак, берьяклырак фикер йөртүчеләр очраштыргалый. Хәер, бусы инде кешенең тормышка карашына, эрудициясенә, эстетик зәвыгына һәм интеллектуаль дәрәҗәсенә бәйле. Шигъриятне аңлау — аны тудыручы халыкның үткәнен һәм бүгенге рухи тормышын нечкәләбрәк белү дигән сүз ул. Беләсең, өйрәнәсең, аңлыйсың икән — бик күркәм; белмисең икән, син халык күңелендәге нюансларны, тирбәлешләрне, тойгыларны тулы итеп күз алдына китерә алмаячаксың. Әлбәттә, бөтен кеше дә шигырьне бер дәрәҗәдә яратырга, аңларга тиеш, шигъриятне тирән тойган зат, һичшиксез, бәхетле, аерым бер дәрәҗәле дип расларга җыенмыйбыз. Шигырьләрнең бер ишләре кешене уйландырырга, гамьсез рәхәтен җуйдырырга, күңел кылларын авырттырырлык сагышландырырга, борчырга да мөмкин. Ләкин шунысы анык: намуслы шагыйрьнең, намуслы талантның иҗаты һәрвакыт прогрессив кешелеккә хезмәт иткән, кешенең кешелеген арттырган, аны рухи чистарткан, яктылыкка, алдынгы иҗтимагый идеалларга өндәп килгән. Дөрес, скрипканың үзе белән стенага кадак кагарга тырышу файдасыз. Әмма скрипканы чиертә белгәндә, кадак та кагылырга, яу да күтәрелергә мөмкин. Беркатлы диярләрме, хисчән, тәэсирләнүче диярләрме, әмма мин барыбер шигъриятнең тылсымлы кодрәтенә, тормышыбызның алга баруына ярдәм итәрлек зур көч булуына нык ышанып, борынгы һәм мәңге яшь булган бу нәфис сәнгатьнең торган саен кешеләр күңелендә күбрәк урын алачагына шикләнмим. Чөнки тормыш үзе шигъриятле, табигать, мәңгелек хәрәкәт, мәхәббәт, идеаллар шигъриятле, һәркемнең күңелендә җыр-шигырьгә урын бар, очкын гына сал — һәркем үзенчә шагыйрь бит! Заманалар үтәр, мөгаен, бүгенге калын романнар юкарыр, яңа жанрлар туар, бүгенгеләре нык үзгәрер, ә җыр-шигырь исә, хис һәм фикернең иң кыска, тапкыр, йөгерек, үзгә ритмлы формасы буларак, жанрлар арасында, чагыштырмача тотрыклы булып, кешеләргә һәрдаим зарури, кирәк, сүз сәнгатенең иң нәфис төре булып кала бирер.

Язучыларыбыз, аерым алганда шагыйрьләребезнең иҗаты да заманның төп проблемаларыннан, ил алдына куелган

бурычлардан аерылгысыз. Ил сулышы — әдипләр сулышы. Ил һәм халык язмышы — әсәрләрдәге геройлар язмышы. Халыкның һәм заманның улы, шул ук вакытта чын интернационалист булу — безнең язучыларның, шагыйрьләрнең төп мәсләге, төп тоткан юлы, эшләренең асыл эчтәлеге. Татар әдәбиятының барлыгын һәм зурлыгын бөтен дөньяга таныткан Тукай, Җәлилләр традициясе, аларның көрәшчән рухы бүген дә яңа буыннар иҗатында уңышлы дәвам иттерелә. Әдәбиятыбызны киңрәк аренада танытуда шагыйрьләр, мөгаен, киләчәктә дә иң алгы рәттә булырлардыр. Мин моны, прозабызның уңышлы үсүен таныган хәлдә, поэзиябезнең бүгенге торышын ассызыклап әйтәм, аның теләсә кайсы халык алдында йөз кызартмаслык әсәрләре барлыгына һәм булачагына, бүгенге шагыйрьләрнең көченә, потенциаль мөмкинлекләренә ышанып әйтәм.

Ә хәзер сүз шагыйрьләрнең үзләре һәм аларның 1971 елда басылып чыккан китаплары турында барыр. СССР Язучылар союзында әгъза булып торган татар шагыйрьләренең саны кырыкка җитә. Үткән ел нәшрият 40 табак чамасы яңа шигырьләр, 90 табак чамасы элек язылган шигырьләрне кабат бастырып чыгарды. Табаклар чагыштырмасы яңа, оригиналь әсәрләр файдасына түгеллеге ачык күренә. Кардәш халыкларның поэзия буенча чыгарган китапларын күз алдына китерсәк, бу бик аз. Бу күләм, асылда, зур бер китап дигән сүз. Әлбәттә, күзәтү ясарга алынган кешегә, «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян», «Ялкын» журналларында һәм «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталарында басылган шигырьләр һәммәсе туплангач, байтак кебек күренергә мөмкин. Ләкин ят күз белән читтән караганда, берьеллык басылып чыккан поэзия, әйткәнемчә, күп түгел. Дөрес, олырак яшьтәге бер төркем шагыйрьләрнең сайланма шигырьләр сыйфатында чагыштырмача күләмле китаплары чыкты. Бу — Н. Арсланов, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Г. Афзал, З. Нури, Ә. Маликов, Г. Латыйп, Ә. Баянов сайланмалары һәм Һ. Такташ, Ә. Исхак, С. Хәкимнәрнең рус телендә чыккан китаплары. Боларның байтагы юбилейлар уңае белән чыгарылды. Бу китаплар — шагыйрьләрнең утыз яки егерме еллык иҗатларын чагылдырган басмалар, димәк, әлеге авторларның иң әйбәт китаплары дигән сүз. Танылган шагыйрьләрнең тулырак басмалары укучылар кулына ирешү, әлбәттә, күңелле хәл. Бу китапларның авторлары кичерерләр дип уйлыйм, минем аларга тәфсилләп тукталырга мөмкинлегем юк. Ихтимал, аларны берьюлы дәр-

рәү анализлап чыгарга көчем дә җитмәс, чөнки бу әдипләрнең күбесе, иҗатларын чорларга бүлеп, аерым тикшерелергә лаек. Бу — әдәбият белгечләре эше.

Максатым үткән елда язылган поэзия әсәрләрен анализлау булганга күрә, мин фәкать яңа әсәрләргә генә, анда да поэзиябез үсеше тенденцияләрен, андагы сыйфат үзгәрешләрен характерлый торган шигъри әсәрләргә генә тукталырга булдым.

Сүзне өлкән шагыйребез С. Хәкимнән башлыйсы килә. Үткән ел әдәби җәмәгатьчелек зур күтәренкелек белән, бәйрәм рәвешендә аның 60 яшен билгеләп үтте. Була шундый юбилейлар, алар турында тантаналы кичәдә сөйләгән чыгышларны бүтән җирдә кабатлап булмый. Ничектер уңайсыз, дөреслеккә туры килеп бетми. Ә менә С. Хәким иҗаты турында юбилей кичәсендә сөйләгән докладны яки чыгышларны, анда әйтелгән фикерләрне биредә дә рәхәтләнеп кабатларга мөмкин. Моңа беркем дә гаҗәпләнмәс, күпсенмәс яки кызармас, гайре табигый дип санамас. Күрәсең, чын талант турында сүз кайда да бер, талант ул талант инде. Андый әдипнең үз мәктәбе, үз шәкертләре бар. Сибгат Хәким дә — әнә шундый бәхетле язмышлы шагыйрьләрнең берсе. Бу очракта Сибгат Хәкимне, олы шагыйрь яки илнең олы бүләкләренә лаек, хөрмәтле зур әдип булудан бигрәк, 1971 елда актив эшләгән шагыйрь буларак беренчеләрдән телгә алам. Үткән ел ул яшьләрчә зур дәрт белән аерым бер мәгънәгә ия әсәрләр язды, «Казан утлары»нда зур бер шигъри цикл һәм поэма чыгарды. Моннан тыш байтак публицистик мәкаләләр һәм, ниһаять, «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле проза белән язылган истәлек язмасы укучылар кулына барып иреште. «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы үткән елда басылган иң уңышлы поэтик әсәрләрнең берсе. Ул Тукайга багышланган. Уйлану рәвешендә язылган, бер караганда, шагыйрь тормышының аерым эпизодларын гына чагылдырган бу поэма үткәнгә карый сыман, асылда, ул — киләчәк турында, илнең, телнең, әдәбиятның киләчәге турында. Халыкның талантлы уллары турында, аларның рухи дөньядагы урыннары, язмышлары, батырлык һәм намусларына тугрылык дәрәҗәләре турында.

Өем тыныч, Аккош күле тыныч,
Тыныч түгел нигә бу җаным?
Чорны чорга якын куеп карыйм,
Вөҗданына аның — вөҗданым.

Өч гомерен аның яшәп җирдә
Чагыштырыр эшем бармы соң?
Җырны җырга якын куеп карыйм,
Намусына аның — намусым.

Шагыйрь нинди генә авыр чорда һәм нинди авыр хәлдә дә Тукай кебек бөек затны биргән халкының рухи көч чыганагын эзли, шуны таба, горурлана, бүгенгесенә сөенә, тормыштагы негатив күренешләр өчен борчыла, ваемсызларны кисәтә.

...Кем дә әйтмәс:
Улларыңнан син, дип, уңмадың,
Халкым, алда улларыңны сакла!..

Халык. Тукай. Без. Үткән. Хәзер. Киләчәк. Менә поэманы колонналар кебек тотып тора торган категория-төшенчәләр. Шагыйрь, ил улы булып, намуслы шагыйрь булып, бик күп нәрсәләрне эченә алган бу сүзләрнең үзара бәйләнешләрен һәм эчке мәгънәләрен эзли. С. Хәким үз гомерендә Тукайга багышлап тулы бер поэмалар циклы иҗат итте. Бу поэмалар аша аның шагыйрь буларак үсеш эволюциясен чамаларга мөмкин.

«Кырыгынчы бүлмә» белән «Шагыйрьнең бала чагы» һәм «Пар ат»лар арасында аерма зур. Аерма шунда — соңгы әсәрләре камилрәк, тирәнрәк. Әлбәттә, һәр әсәрне иң әүвәл язылган вакыты, үз чоры күзлегеннән карап бәяләү зарур. Әгәр кайчан да булса Тукай турында төрле әдипләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрне бөртекләп җыйнап, томлап чыгарсалар, бу поэма алар арасында күренекле урын алыр иде дип ышанам. «Казан утлары»ның беренче санында чыккан зур шигъри циклы да әдипнең актив эшләве турында сөйли. «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле истәлек-язма турында фикеремне матбугатта белдергән идем инде. Өстәп әйтәсем килгәне шул: беренчеләрдән, без анда бөек җиңүне тәэмин иткән солдатларның гади бөеклеген, шагыйрьнең үзе кичергән хәлләргә ирләрчә тугры мөнәсәбәтен күрдек, әсәр ышандыра, дулкынландыра, сугышка нәфрәт, Ватанга мәхәббәт тәрбияли; икенчедән, осталык, фикерләрне җыйнак, поэтик итеп бирә белү ягыннан бик тә озын язарга яратучы кайбер прозаикларга (һәм дә шагыйрьләргә дә) гыйбрәт алырлык нәрсәләр бар бу әсәрдә. Шагыйрьнең соңгы поэмасында «Вакыт, йомгакларга вакыт» кебек сүзләр очраштыргалады. Йомгакларга кайсы вакыт яхшырактыр, анысын әйтүе кыен. Әмма бер нәрсә анык: хәзерге вакыт — Сибгат ага

Хәким шагыйрь булган вакыт, халыкның аннан олы сүз көткән вакыт... Чөнки «үр артында яңа үрләр бар», Гыйльметдин куйган тәрәзәле өйләргә, таң нурлары белән бергә, рухи яктылыкны да әле бик күп иңдерәселәр бар.

Баштук, ахры, күзгә чалындым мин:
— Яшь, — диделәр, — яңа! — диделәр...
Ә картайгач: — Бу яшәгән саен
Гел яшәрә бара! — диделәр.
Таныдылар чынлап илле яшьтә,
Зурладылар фәкать алтмышта...
Берәүләргә ул да насыйп түгел,
Мин бик риза мондый язмышка.

Бу юллар икенче бер өлкән шагыйребез Н. Арслановның «Мин бик риза» дигән шигыреннән китерелде. Утызда булмаганнан, ихтимал, илледә шагыйрь чыкмас. Шагыйрь — һәрчак шагыйрь. Масштаблар, биеклекләр генә төрле. Нури ага егермедә дә, кырыкта да шагыйрь булган, ләкин зур шагыйрь итеп үзен соңгы ун-унбиш елда танытты. Шигърияттә үз биеклеген билгеләде. Шагыйрьдәге яңарыш шигъриятебездәге бер күркәм, шактый сирәк очрый торган күренеш дип кабул ителә. Шагыйрьнең осталыгы, тематик диапазоны, үзгә аһәңе турында үткән елда «Казан утлары»нда ике тапкыр чыккан шигырь циклларына карап хөкем йөртеп була.

Читтә каламыни Ил җанлы ир —
Шагыйрь урыны — алгы сафларда!
Алгы сафта барган кешеләрнең
Рухы төшми авыр чакларда.

Илне олылау, рух күтәренкелеге, тормышны, яшәүне сөю — шагыйрь иҗатының эчтәлеген билгеләүче төп сыйфатлар. Ул — гашыйк шагыйрь. Мәхәббәт шигырьләрен Н. Арсланов кебек, аныңча дәрт белән, рәтен белеп язган шагыйрь, белмим, арабызда тагын кем бар икән? Мәхәббәт турында шактый күп языла һәм язабыз. Кайчак шатлыктан башны югалтып язабыз, кайчак сыктап-сукранып, әрнеп язабыз. Нури аганың бүтәнчәрәк, егетләрчәрәк чыга: сөйгәнен дә данлый белер, үзен дә төшермәс, горур торыр, шунда ук кеше булып дөньяда яшәүнең олылыгын да раслар. Яшәргә өндәү, кеше булырга, ышанырга, гадел булырга өндәү һәм укучылар күңелендә мәгълүм бер дәрәҗәдә шуңа ирешү — бу шагыйрьлек түгелмени? Шагыйрьнең хәтта элегик строфаларында да арысланлыгы уянып китә.

И кыска гомер — дөньяга
Бер карап алу гына.
Алышыр идем җәннәтен
Дөньяның тәмугына.

Шәрекъ шигъриятен яхшы үзләштергән, төрки телләрнең нечкәлекләрен белгән шагыйрь оста тәрҗемәче буларак та хуплануга лаек. Тугандаш халыкларның байтак шигырь җәүһәрләре белән без аның тәрҗемәләре аша таныша алдык. Н. Арсланов — үткән елда актив эшләгән шагыйрьләрнең берсе. Аның «Язгы тамчылар», «Мэрцишор», «Сагышларым», «Далаларым» кебек шигырьләре 1971 елның иң яхшы әсәрләре рәтендә саналырга хаклы.

С. Хәким һәм Н. Арсланов. Бу ике әдипне, иҗатлары белән бер-берсеннән шактый ук аерылып торган ике шагыйрьнең исемнәрен рәттән китереп үтүем — аларның ел дәвамында актив иҗат итүләре өчен генә түгел, зур һәм уртак сыйфатлары өчен дә кирәк иде ул сыйфат — аларның яшьләргә якын була алуларында, кирәк чакта алардан өйрәнә дә алуларында. Өлкән шагыйрьләрнең яшьләргә йогынтысы, яшьләрнең алардан өйрәнүе табигый күренеш. Ә менә өлкәннәрнең яшьләр дәртен, тыелгысыз хисен, фикерләү стилен, индивидуальлеген нечкә тоеп, һәм шул сыйфатларны үз рухларына, үз күңел учакларына өсти алулары бу — егетлек, бу — яшәрә алу, киң күңелле була алу дигән сүз. Кызганычка каршы, моны һәркем булдыра алмый. Йә чыккан китаплар саны, йә тәкәбберлек, йә еллар комачаулый... Иҗатлары белән яшьләрне сокландырырлык, шул ук вакытта алардан да өйрәнә алучы өлкән шагыйрьләрдән мин шушы ике исемне генә атый алам: С. Хәким һәм Н. Арсланов.

Әдәбиятка 30 нчы елларда ук килеп, поэзиябезгә кырык еллап фидакяр хезмәт итүче өлкән буын шагыйрьләренең яңа әсәрләрен аеруча зур игътибар белән укыйсың. Осталыкларының серенә төшенәсе, шагыйрьнең теге яки бу теманы менә бүген ни өчен актуаль итеп алуын беләсе, фикер тирәнлеген ачыклыйсы, идея-художество кыйммәтен үзеңчә бәялисе килә. Ветеран шагыйрьләребезнең берсе Хәсән ага Туфанның «Кармәт эскизлары» исемендәге шигырьләр циклын әнә шундый уйлар белән, кызыксынып укыдым. Бу шигырьләр шагыйрьнең моннан илле биш ел элек аерылган туган җиренә — туган авылына кайтып зиярәт кылу тәэсирләре нәтиҗәсе. Кармәт кайчандыр зәңгәр сәдәпле киндер күлмәк кигән егетне озаткан булса, хәзер чал чәчле, дөньяның төрле җил-давылларын кичкән олы шагыйрьне каршы

ала. Дулкынландыргыч очрашу! Әйе, авыл үзгәргән, кешеләр үзгәргән. Бу үзгәрешләр шагыйрь күңеленә дә кучә. Үзгәрешләрнең яхшы якларын күреп, ул балалар кебек куана. Шагыйрь өчен яшьлеген хәтерләткән урыннар газиз, ул аларны эзли. Урманнарга бара, яланнарга чыга, чардуганнарга барып баш ия, каеннарга, талларга дәшә, йолдызларга сүз ката. Чагыштыра, уйлана, хыяллана, шагыйрьләр турында да, аларның тормыштагы хакыйкый бәяләре турында да хәтереннән чыгармый. «Әдипләр-шагыйрьләр гомере — илдәге гомуми милек ул», «Матур булса да торган җир, сагындыра туган җир» дигән җырдагы сыман, туган җирнең газизлеге, аның бер рухи таяныч ноктасы, кешенең кешелеген арттыру чыганагы икәнлеге турында бу шигырьләр циклы. Әнә якташ шахтерларын искә алып шагыйрь нәрсә ди:

Кайтканнар Геркулес кебекләр,
Ахырда төп йортка кайтканнар.
«Кыямәт көнгәчә»... дип кенә
Зиратта йокларга ятканнар.

Икенче бер урында шагыйрь болай ди:

Әллүле, бәллүле талларым! —
Тиккә дә тибрәлгән тирәгем! —
Нәкъ сезнең шикелле әле дә
Җилсез дә тибрәнә йөрәгем.

Йомасы идем мин, якташлар,
Күзләрне мәңгегә йомасы...
Коткарды илемнең, җиремнең,
Тирәкнең, талымның догасы.

Тулаем алганда, бу шигырьләр күңелдә якты эз калдыра. Шулай да без шагыйрьнең бик яхшы шигырьләрен байтак укыганга күрә, беркадәр чагыштыра да алабыздыр, бу — Хәсән ага өчен гадәти цикл.

Акыл белән Аллага тиң кеше
Табар микән тәкать үзендә?
Төкәнмәсме аның сабыр көче
Иң җаваплы
Авыр мизгелдә
Кагылмаска
Актык бер төймәгә?..
Ана кочагыдай шушы җирне
Ай шикелле үле итмәскә,
Үзе тапкан үлем көче белән
Үз башына үзе җитмәскә
Акыл табармы ул?..



*Язучылар җыелышыннан бер күренеш. 1970 нче еллар*

Бу юллар икенче бер өлкән шагыйребез Шәйхи ага Маннур шигыреннән. Аның ел ахырында журналда басылган шигырьләре әйбәт тәэсир калдырды. Алар — уйлану, борчылу шигырьләре. Уйлар зур, чөнки кешелекнең уе, гаме зур. Замана, Галәм, Табигать тагы — Кеше һәм аның кылган гамәле, мәхәббәт, шагыйрьнең шәхесе — шигырьләр менә шул хакта. Бик йөгерек укылмасалар да, шактый төшле шигырьләр алар. Өлкән шагыйрьләрнең без яшьләр өчен бер уртак гыйбрәтле ягы бар: алар үз шигырьләрендә, гомумән, иҗатларында, артык үгет-нәсихәтләмичә генә, яшәүнең бәхет икәнлеген, бар нужасы, бар авырлыгы белән яшьлекнең гүзәл икәнен, гомумән, гомернең газиз икәнлеген искәртеп торалар. Без моңарчы игътибар итмәгән яки гамьсез караган әйберләрнең, күренешләрнең күркәм якларын ачып бирәләр. Вакытның кадерен белергә, җай белән ашыгырга, ил куанырлык эшләр эшләргә өндиләр.

«Казан утлары»нда «Чирмешән якларында» исемле шигъри романның икенче кисәгеннән өзекләр басылды. Салих ага Батталның бу әсәре төрле елларда, төрле басмаларда, төрле күләмдә күренгәләгән иде инде. Болай чәчелеп чыгу зур әсәр турында фикерне үз вакытында төйнәп-җыйнап әйтергә комачаулады да шикелле. Романның беренче кисәге аерым китап булып чыккач та, ни сәбәптәндер аерым рецензия-мәкаләләр артык күзгә чалынмады. Ә тулаем алган-

да, әсәр кызык, гыйбрәтле, татар поэзиясендә шигырь белән язылган беренче роман, заманында шактый шаулаган «Олы юл буйлап» кебек эпик пландагы зур әсәр. Миңа калса, «Чирмешән якларында» — идея-эчтәлек ягыннан булсын, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан булсын — бик тә уңай бәягә лаек әсәр. Романда авылның революция алды һәм аннан соңгы еллардагы хәле, төрле сыйнфый катлаулар, алар арасындагы киеренке мөнәсәбәт, җир кешесенең, гади крәстияннең аңы уяну, яңа тормыш төзү омтылышлары сурәтләнә. Форма ягыннан әсәр гадәти халык җырларының сигез-җиделе үлчәве белән язылган. Ул йөгерек укыла, җиңел аңлашыла. Әмма бу җиңеллек — авыр иҗат процессы нәтиҗәсе. Сигез-ун сүздән генә торган куплетларга чор сулышын өрү, геройларны җанлы итеп күрсәтә алу, вакыйгалар барышының нечкә нюансларын ача алу һәм шуның барысын халыкчан формада укучыларга җиткерә алу — югары дәрәҗәдәге профессиональләр генә булдыра торган шөгыль. Яшь шагыйрьләргә бу җәһәттән романда өйрәнер, гыйбрәт алыр нәрсә күп. Әсәргә әдәби җәмәгатьчелек тиешле бәясен бирер дип ышанам. Хәзинәдәге байлыкның, кемнеке генә булса да, реаль кыйммәте танылырга тиеш.

Актив иҗат итүче шагыйрьләрнең тагын берсе: ул — Гамил Афзал. 50 яшь тулу уңае белән бу шагыйрь турында фикеремне әйтеп, матбугатта мәкалә белән чыккан идем, хәзер аларны кабатлап тормыйм. Шуны гына искәртеп үтәсе килә: 50—60 нчы елларда Г. Афзал үзен юморист, сатирик шагыйрь итеп танытса, 70 нче елларда үзен ул үзенчәлекле лирик һәм публицистик шагыйрь итеп тә күрсәтте. Әлбәттә, бербөтен шагыйрьнең иҗатын алып, чорларга кырт кисеп карау формальрәк эш булыр, шулай да лирик-фәлсәфи юнәлештәге шигырьләре аның соңгы еллардагы иҗатының йөзен билгели. Соңгы елларда язылган байтак лирик, публицистик шигырьләре, җырлары бу фикернең дөреслеген раслый.

Без урта буын дип йөрткән, ә яшьләре белән инде уртадан узып бара торган буын соңгы биш-алты ел эчендә нык активлашты. Сер түгел, беркадәр элегрәк алар турында «тәүфыйклы, йомшак» буын дигәнрәк фикер дә йөри иде. Утсыз төтен чыкмый дигәндәй, мондый фикернең тууына нигез дә бар шикелле. Чыннан да, ир уртасы булып килгән бу буынның байтак вәкилләре шактый вакыт тормышның алгы сызыгында ук бармадылар, җәмәгать эшләренә дә бик атлыгып тормадылар, һәрберсе диярлек ялгызаграк һәм тыныч-

рак юл сайлап, иҗатларында да тау-ташлар актармый, давыллар чыгармый, яшеннәр уйнатмыйча, ыспай гына, нарциссларча үз-үзләренә сокланып, алсу таңнарда, чыклы сукмакларда сандугачлар җырын тыңлап, таныш моңнарны кабат яңартып, үзләре олыгая барсалар да, өлкән әдипләр каршында һаман да тәртипле, гөнаһсыз яшьләр булып күренергә тырышып озак юандылар... Әлбәттә, аларның һәрберсе ихлас күңелдән, шактый ук үҗәтлек белән иҗат итте, әдәбиятта үз йөзен табарга, үз урынын дауларга тырышты. Индивидуаль иҗатың белән үз-үзеңә һәйкәл куярга тырышу начар омтылыш түгел, ләкин ул һәйкәлләрне кая куярга соң? Аның өчен уртак мәйдан кирәк, җирлек кирәк, халык кирәк бит әле! Шөкер, аларның билләре сыеграк бу чор үтте инде. Ниһаять, ирлек чоры килде, чын мәгънәсендә өлгерү чоры килде. Бу буынның озаграк өлгерүендә, әлбәттә, объектив (сугыш, авыр еллар, белем җитенкерәмәү, вакытында тиешле әдәби тәрбия күрмәү) һәм субъектив сәбәпләр бар иде. Ниһаять, алар гәүдәләрен турайттылар, тормыштагы җаваплылыкны һәм табигый миссияләрен тоеп, дөньяга хуҗаларча карый башладылар. Дөнья киң икән! Нужа күрү дөнья күрү белән тәңгәл үк килеп бетми икән! Булганлык белән әрсезлек, тыйнаклык белән мескенлек төшенчәләрен дә төгәлрәк ачыкларга кирәк икән! Эш күп, кирәк күп икән. Моннан меңәр ел элеккеге тарих белән сөйләшергә, аңлашырга кирәк, Мефистофельләр белән бәхәсләшергә һәм җиңәргә, туган җирдәге өч аршын җирнең бәясен ачыкларга, югалган яшьлекне эзләргә, яшьләй сугыш утында чыныккан фронтовиклар турында сөйләшергә, хәзинәләр табарга, тагын бик күп, бик күп эшләр башкарырга кирәк икән.

Артык имин көн кичермим микән? —
Булды шулай уйлап пошканым,
Кагылмый күк чорның тыгыз җиле,
Юк та бугай хәтта дошманым...

Туры сүзне ярып әйткән идем,
Җайланды да китте тормышлар —
Минем дә бар шәхси дошманнарым,
Явып кына тора орышлар!

Ш. Галиевнең бу юллары урта буындагы эчке сыйфат үзгәрешен беркадәр ача сыман. Әдәбиятның чисталыгы, рухи ныклыгы өчен көрәшкәндә, табигый, гел «песәем» диеп кенә тормаслар, ят күз белән караганнар да булыр, кеше җаны өчен көрәш заманында орышлар да булыр.

Шулай да, урта буынның, шагыйрьләргә караганда, проза өлкәсендә эшләүче өлеше активрак булды шикелле бу елларда, һәрхәлдә, басылып чыккан әсәрләр буенча шулай күренә. Х. Камал, Ә. Баян, Р. Гәрәй, С. Сөләймановаларның яңа шигъри әсәрләре күренмәде диярлек. Боларның күбесе бүтән жанрларда көч сынадылар, берәүләре, бәлки, күләмлерәк әсәрләр өстендә эшләгәннәрдер. Чагыштырмача актив эшләгән, аерым шигырь цикллары бастырган иптәшләрдән И. Юзеев, Ш. Галиев, М. Шабаевлар булды.

Әмер булсын иде, шигырьне тик
Ташка гына чокып язарга...
Буш сүз төзүчеләр бетәр иде!
Һәй, бер шуны сынап карарга!

*Ш. Галиев*

Бу буын инде хәзер сүзнең кыйммәтен, дөньяның «тоз»ын белә, дуслык-иптәшлекнең, кылган эшләрнең чын бәһасен белә.

Юк, мин яши алмыйм алай:
Күккә карап ятып,
Ялган алла ясап,
Сүзгә үрә катып...
Үзем — утлар ягам,
Үзем — дөрлим, янам.

*И. Юзеев*

Табигать. Машина. Алар арасындагы мөнәсәбәт. Тирәнрәк уйласаң, машина да, әлбәттә, табигать җимеше. Ләкин Кешегә машинаның хуҗасы һәм шул ук вакытта табигатьнең игелекле баласы була алу җиңел түгел. Марс Шабаевның «Җикән камыш» дигән исем астында оялап бирелгән шигырьләре Кешенең иң әүвәл Табигать баласы булганлыгын, булырга тиеш икәнлеген искәртә. Кешенең җисми тереклек итүе өчен тәгаен кирәк шартлар турында борчылу исәп арткан бу заманда мондый шигырьләрнең кирәге икеләтә зур. Бу җәһәттән М. Шабаевның «Салда сәяхәт» исемле китабы да игътибарга лаек.

Роберт Әхмәтҗанов. Холкы белән дә, иҗаты белән дә үтә үзенчәлекле шагыйрь. Аның үзенчәлеге, хәтта, әйтер идем, капризлылыгы каләмдәшләренә дә гел генә сөенеч китерми, кайчак сискәндерә, кәефне дә җибәргәли. Әмма ул — тумыштан шагыйрь, төгәл поэтик сиземгә, нечкә тоемга ия зур шагыйрь. 60 нчы еллар башында күпләрне өметләндереп, матур башлаган шагыйрь юл башындагы иҗади темпны тота

алдымы? Унбиш еллап гомер узды. Шагыйрь байтак китап чыгарды, яхшы шигырьләр, җырлар, поэмалар язды... Әмма ул күбрәк эшли ала һәм эшләргә тиеш иде. Тиеш дип әйтәм, чөнки талант — ул халык байлыгы. Шагыйрьнең язганнарын ихтирам иткән һәм талантлы дип санаган хәлдә, миңа калса, аның үзен чолгап алган мохиткә, кешеләргә ирләрчә киң күңелле дустанә карашы җитенкерәми шикелле. Язганнарына карыйм, диапазонын чамалыйм, бер характерлы як: аның темалары йә бик интим, йә космик. Бүгенге яшәешебезгә — үзебезнең шатлык-нужаларга, әдәби процесска, хәл итәсе теге яки бу конкрет мәсьәләләргә Роберт беркадәр битараф шикелле. «Сәнгать сәнгать өчен» дигән карашмы бу? Тормышның «вак-төягеннән» өстен санаумы, үзеңне-үзең артык яратумы? Мин киләчәк өчен сәламәт акыл белән борчылып яшәүче шагыйрьләр яклы. Роберт дөрес аңласын, әлеге әйткәннәр аның талантына ышанудан, аны һәм тормышта, һәм шигырьдә көрәшче-гражданин шагыйрь итеп күрәсе килүдән.

1971 елда М. Садри, М. Хөсәен, С. Шакир, чагыштырмача яшьрәкләрдән Е. Уткин, Б. Рафиков, П. Апушев иптәшләрнең дә шигырь китаплары чыкты. Бу җыентыкларга тәфсилләп тукталмавымның сәбәбе шул: алар миңа, кызганычка каршы, шигъриятебезнең бүгенге үсешен билгеләрлек яки авторларның үз иҗатларына карата яңа сүз әйтерлек материал бирмәделәр. Бу китаплар — авторларның чираттагы гадәти басмалары... Гомумән, әдәбиятта китап саны хәлиткеч нәрсә түгел! Дәрдемәнд үзе исән чагында бер генә китап та чыгармаган, Х. Туфан җитмешкә җитеп нибары өч-дүрт китап бастырды...

Үткән елдагы шигъри әсәрләрне барлап чыккач, шундый бер нәтиҗәгә киләсең: С. Хәким, Н. Арсланов кебек өлкән буын тудырган яхшы әсәрләр белән рәттән, 65 нче елларда мәйданга килгән шагыйрьләр бик актив иҗат иткәннәр икән. Яңа әсәрләренең саны һәм сыйфатлары ягыннан караганда да үткән ел шигырь оркестрында иң үзәк урынны алар алып торалар дисәм дә ялгышмамдыр. Мин моны Р. Харисов, Р. Мингалимов, Ш. Мәхмүдов, Г. Рәхим, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов һәм тагын башка кайбер иптәшләрнең китапларын, басылган әсәрләрен күз алдында тотып әйтәм. Бер елны тары, икенче елны бодай уңа дигәндәй, урта буын шагыйрьләренә караганда, 1971 ел яшьрәкләр иҗаты өчен уңышлырак булды.

Р. Харисов — узган елда иң актив иҗат иткән шагыйрьләрнең берсе. Ул «Казан утлары» журналында ике зур ши-

гырь бәйләме чыгарды. «Ак сөлге» дигән китабы укучыларга барып иреште. Мирсәет Яруллинның «Кеше» ораториясе иҗат ителде, сүзләрен Р. Харисов язды. Кылган эш, башкарылган хезмәт — икеләнебрәк караучыларга, өнәбрәк бетермәүчеләргә үзе үк җавап. Ренат — инициативалы һәм күп эшли торган каләмдәшебез. Язганнары арасында, табигый, төрлеләре бар: берише шигырьләре күпчелеккә ошый, беришләре аерым контингент кешеләргә ошый яки бөтенләй ошамый. Минемчә, моның сәбәбе ике нәрсәдә. Беренчедән, авторның кайбер очракта чын мәгънәсендә халыкчан итеп, гади итеп язмавында; икенчедән, бертөрлерәк вәзенгә һәм фикер агышына (әгәр булса!) күнеккән берише укучыларның шагыйрь иҗатын аңламавында яки аңларга «теләмәвендә», Ренатның шигырьләрен яратырга, яратмаска мөмкин, ләкин аларны инкяр итү, танымау мөмкин түгел. «Казан утлары» һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкалә авторлары (Ш. Әхмәдуллин һәм Ә. Баянов), асылда, аның иҗатына уңай бәя бирделәр. Моннан бер-ике ел элек Р. Харисовның тәнкыйть мәкаләләрен укып: «Их, ул тәнкыйтьче булып китсен иде!» — диючеләр бар иде. Шагыйрьме, тәнкыйтьчеме яхшы — әйтә алмыйм, тик шунысы хак — тәнкыйть, беренче чиратта, акылдан килә, шигырь иң әүвәл хистән, дулкынланудан килә. Бер үк кешегә бер үк вакытта икесе дә булуы авырдыр. Чыннан да, Р. Харисовның элегрәк язган шигырьләрендә бу авырлыкны тоярга була иде. Фикри үсеш ягыннан да, шигырь техникасының кануннары саклану ягыннан да шигырьләр дөрес, ә үзләре ничектер салкынрак. Шагыйрь танылсын өчен, аның дөньясы, фикер агышы, күз һәм тагын күңел күзе күргән күренешләр, детальләр халыктагы дөнья, фикер агышы белән, шул күренеш, детальләр белән тәңгәл килү кирәк. Бөтенләй үк тәңгәл булсаң да, син «эреп бетәсең», сине танымаячаклар, артык аерылсаң да, халык кабул итеп җиткерми. Ниндидер идеаль аралык, «чак-чак» аерымлык кирәк. Бу, әлбәттә, бөтенебезгә дә карый, шул исәптән Ренатка да. Ренатның соңгы шигырьләре аның бу «чак-чак»ны тою сәләтенең үсә төшүен күрсәтте. Ул, үз индивидуальлеген дә саклап, тыгыз фикерле, укылышлы, әйтелеше, кабул ителеше ягыннан да аңлаешлы байтак шигырьләр иҗат итте. «Ак сөлге» китабына кергән «Татарстаным минем», «Синең йөрәгең тибә», «Йола», «Агыйдел тугайларында», «Өянке», «Карама яру» һ.б. шигырьләре шундыйлардан. Ренат Харисов шигырьләрне махсус бер темага «оялап» язарга ярата. Фатих

Кәримгә багышланган шигырьләр, «Яфраклар», «Яралар» циклы. Композицион яктан алар һәрберсе аерым бүлекләрдән торган фәлсәфи поэмалар кебек. С. Хәким, Р. Харисов һәм тагын кайбер яшь шагыйрьләр турында мондыйрак фикер әйткән иде: «Кура җиләген учта шундый итеп кысасың, коры түбе генә кала, алар да материалның фәлсәфәсен шулай сыгып чыгаралар...» Болай эшләү, бәлкем, начар түгелдер. Ләкин көчең күпме дә, учыңдагы әйберең нәрсә? Кура җиләгенең суын чыгарып булыр, ә без кайчак учка имән чикләвеге куябыз да кысабыз, су да, май да чыкмый... Теоретик һәм практик яктан дөньядагы бөтен нәрсә турында да язарга була. Гөл чәчәге турында да, икмәк турында да, хирург кулындагы канлы мамык турында да... Кайсын сайлап уңышка ирешеп була, анысын һәркем үзе карар. Бу — һәр шагыйрьнең этик, эстетик принципларыннан килә. Ә, безнеңчә, халык күңеле кабул итәрлек предметлар, күренешләр, уй-хисләр дөньясында яшәп иҗат иткәндә отышлырак чыгачак. Гомумән алганда, Р. Харисов үсештә, яңа әсәрләре зурга өметләндерә.

Шагыйрь Ш. Мәхмүдов «Көтелмәгән очрашулар» исемле китап чыгарды. Кемнәргәдер көтелгән, кемнәр өчен көтелмәгән булгандыр бу очрашу, әмма күңелдә матур эз калдыра торган очрашу бу. Ш. Мәхмүдов — әдәбиятта яңа кеше түгел. Моңа кадәр Мәскәү, Уфа нәшриятларында дүртбиш китап чыгарган иде инде. «Көтелмәгән очрашулар» — Казанда басылган икенче китабы. Бу китап, минемчә, авторның моңа кадәр дөнья күргән китаплары арасында иң яхшысы. Шагыйрь зур фәлсәфи категорияләр белән эш йөртә, киң тематик диапазонда иҗат итә. Йорт, Җир, Ватан, Вакыт, Буыннар... Аеруча яхшы шигырьләреннән «Балбаллар», «Бар шундыйлар», «Ике тол», «Мәрхүм абзыйга элегия», «Күлмәк», «Олылан зиратында», «Көз» һ.б. Китапны төзү культурасы да күзгә ташлана. (Безнең кайбер авторлар китапның композицион төзелешенә игътибар итеп бетермиләр.) «Прага дәфтәре» циклында да күңелгә хуш килерлек шигырьләр байтак. Шәкли ягы да классик шигырьләрнекеннән аерыла: үзгә рифмалар, үзгә ритм. Беренче укып баккан кешегә башта сәеррәк тә тәэсир итәргә мөмкин. Ләкин болар формалистик экспериментлар түгел, ә телнең табигый әйләнмәләре. Авторның кечкенә генә бер шигырен мисал итеп китерергә телим. Бу шигырь аның үзе һәм язу манерасы турында фикер әйтергә, көчле һәм йомшак якларын чамаларга мөмкинлек бирә кебек.

Яшь тә түгел артык, алай карт та,
шулай да ярты гомер артта —
яшьлек юләрлеге, гөнаһлар —
күптән инде сәер кунаклар.
(Алар белән өзелгән ара!)
Чуарланмый әйберләр төсе,
үз урынында ак белән кара;
(әгәр әрнү булса йөрәктә,
ул тик күк күкрәве еракта;)
бизмәннәр чайкалмый, дөнья нык,
көнгә караш-фикерләр анык,
дошманга тупас эндәшмим,
куштанга ачмыйм кочак...
Кыскасы, килде бугай балигълык,
гүзәл әйберләр тудырыр чак.

«Дошманга тупас эндәшмим»... Мин мондый позиция белән килешеп үк бетмим. Бөек шагыйрь һәм көрәшче Назыйм Хикмәт шәкертләреннән берсе булган шагыйрьгә остазының мондый сүзләрен янәдән хәтеренә төшерәсе килә:

Әгәр мин янмыймын икән,
Әгәр син янмыйсың икән,
Әгәр ул да янмый икән,
Караңгыны кем таратыр!

Шагыйрьнең шигыреннән берәр юл алып кына аның иҗади позициясен билгеләү мөмкин түгел, диярләр. Килешәм. Шагыйрь шәхесе һәм аның иҗат лабораториясе катлаулы нәрсә. Диалектик каршылыклар, үзең теләмичә үк үз-үзеңә каршы килүләрне әдәби тормышта байтак күрергә мөмкин. Ш. Мәхмүдовның барлык китапларын һәм бу соңгысын күздән кичергәч, шундыйрак фикер калды: ул шактый оригиналь шәхес, гомумиләштерүләргә омтылучан талантлы шагыйрь, аның сизгер тоемы һәм чама хисе бар. Тормыштагы бихисап төрлелектән мәгънә әйттерерлек, детальләр сайларлык художниклык күзе бар, поэтик теле, зур тәҗрибәсе бар... Ләкин күп очракта язганына авторның үз мөнәсәбәте юк. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Ул теге яки бу трагик ситуацияне күрсәтә, сөйли, ачып сала... Ләкин үз шәхси мөнәсәбәтен белдерми. Авторның казанышымы бу? Укучыга ышануымы, мөнәсәбәтеңне үзең белдерт диюеме? Хакимлегеме, әллә кыюсызлыгымы? Әллә әйберләрнең, күренешләрнең эчке мәгънәләрен ачу — үзе мөнәсәбәтме? Нәтиҗәләр ясарга ашыкмыйк, һәрхәлдә, безгә дә, авторга да бу юнәлештә уйлану комачау итмәстер. Ш. Мәхмүдов — көнчыгыш, төрки, Европа шигъриятен яхшы белгән, заманында әдәби институт-

ларда укыткан, зур эрудициягә ия кеше, гаҗәп, шул кеше үзенең мәкаләләре, рецензияләре, чыгышлары белән безнең әдәби хәрәкәткә катнашмый. Ә ул әдәби тәнкыйть, бигрәк тә шигырь тәнкыйте өлкәсендә зур һәм кирәкле эшләр башкара алыр иде.

Ел ахырында гына, 1971 ел китабы булып калыйм дигәндәй, Рөстәм Мингалимовның «Алкын су» исемле җыентыгы чыкты. Бу китап күңелдә яхшы тәэсир калдырды, һәм анда, чыннан да, көнләшеп укырлык шәп шигырьләр күп. Бу басманың тагын бер күркәм ягы шул: китап тулысы белән диярлек өр-яңа шигырьләрдән, үткән елда язылган шигырьләрдән тора. Күпләр әле «Алкын су» белән танышырга да өлгермәгәннәрдер, укып чыккач шагыйрьне аңларлар, тиешенчә бәһаләрләр. Төрле китаплар чыга, арада язучыны яки шагыйрьне таныта торганнары була. Рөстәмнең бу китабы, миңа калса, моңа кадәр чыкканнары арасында иң яхшысы, 1971 елдагы шигырь китаплары арасында да иң уңышлыларының берсе. Ни өчен җылы сүз әйтәм: шагыйрьнең битараф булмавы, алган темаларының тормышчан һәм җитдилеге һәм, ниһаять, ирләргә хас сабырлык һәм саллылык белән язуы. Бу китапка кергән шигырьләрне тел, сурәтләү чаралары һәм тышкы фактура ягыннан карап та шагыйрьнең камилләшә баруын күрергә мөмкин. Шигырьне укыгач, шундый тәэсир кала: шагыйрь үзенең көчен калку итеп күрсәтергә тырышмый, эффектлы чаралар эзләми кебек, ә көч барыбер күренә, нечкәлек һәм ныклык барыбер тоела. Дөньяда бәхетлеләр күп. Һәркем үзенчә бәхетсез, һәркем үзенчә бәхетле. Шагыйрь дә өлешенә тигән үз бәхете турында сөйли, ышандырырлык итеп сөйли:

Минем бәхетем — Җиргә килүемдә,
Минем бәхетем — бөтен бәхетсезне,
Бөтен бәхетлене сөюемдә.

Китапка шулай ук инде матбугатта уңай бәя алган «Минем дәүләт» исемле поэмасы да кергән. Рөстәмнең барлык шигырьләре дә бер дәрәҗәдә яхшы дигән мөһер сугарга җыенмыйм. Әмма «Алкын су» — шагыйрьнең үсешен күрсәтә торган, шигъриятебезнең бүгенге таләпләренә җавап бирерлек китап.

Г. Зәйнашева яңа шигырьләр, җырлар китабын «Җырлап яшик!» дип атаган. Җырлап яшәргә өндәве очраклы түгел, шагыйрәнең моңа хакы бар, аның халык яратып кабул иткән җырлары күп. Бу китапта да күңелгә хуш килерлек

җырлары байтак. «Очрашу җыры», «Иң кадерле сүз», «Күрешербез» — болар инде көйгә салынган, илгә таралган җырлар. «Аулагөйләр», «Ана йөрәге», «Ничә кышы килде гомремнең», «Акбүз атым», «Тик бер тамчы кирәк» шигырьләре дә матур тәэсир калдыра. Тулаем алганда, шагыйрәнең бу китабын хуплаган, тематик яктан үз мөмкинлекләрен белеп, чама-хисен тоеп эш итүен, самимилеген, халыкчанлыгын таныган хәлдә, кайбер шигырьләрендә сиздерә торган примитивлыктан, «нинди матур брошка белән бизәлгән күк күкрәге» кебек зәвыксыз строфалардан котылуын телибез. Шагыйрьләребездән үткән ел актив эшләгәннәр рәтендә К. Булатова һәм башлап язучы Ф. Гыйззәтуллиналарның да исемнәрен атап әйтәсе килә. Болар икесе дә нефть районнарында чыныгу алган шагыйрәләр. Кларанының үткән ел аерым китабы чыкмаса да, безгә — Әлмәт бүлегенә тапшырган һәм вакытлы матбугатта чыккан шигырьләреннән чыгып хөкем иткәндә, үткән 1971 ел аның өчен шактый бәрәкәтле ел булды. Әлмәт районының Кәшер урта мәктәбендә татар әдәбиятын бик яхшы итеп укытуын әйтеп узу да артык булмас. Ул оештырган әдәбият түгәрәге гөрләп эшли, өметле яшь каләмнәр үсеп килә, Клара укыткан мәктәпне тәмамлаган укучылар гуманитар вузларга килә торалар. Гомумән, яшьләр иҗатына күчкәнче, инде берничә китап чыгарган, исемнәре укучыларга яхшы ук таныш булган К. Мостафин, Ф. Шәфигуллин иптәшләрнең дә «Казан утлары» журналында дөнья күргән уңышлы шигырьләрен әйтеп узу дөрес булыр.

Хәзер яшь һәм башлап язучылар иҗаты турында берничә сүз. Алар бездә шактый. Йөзләгән башлап язучының туксанлабы шигырь яза. Шуңа күрә аларның бөтен язганнарын, иҗади юл башларының бөтен индивидуаль үзенчәлекләрен, уй-теләкләрен, гадәт-холыкларын белеп, потенциаль мөмкинлекләрен чамалап бетерү дә кыен. Кыенлык тагын шунда, бу зур төркемдә, чын мәгънәсендә яшь һәм күзгә күренеп, яныл торган талантлар белән бергә, инде байтактан язып килүче, бик үк яшь булмаган, иҗатлары белән дә сокланырлык дәрәҗәдә кабынып китә алмаган, әмма әдәби хәрәкәттә һәм, гомумән, шигъриятә мәгълүм бер урын тоткан иптәшләр дә шактый. Кемнәр соң бу яшь һәм башлап язучылар дигәннәребез? Болар — З. Маликов, М. Әгъләмов, Е. Уткин, Н. Мадьяров, Р. Вәлиев, Х. Әюпов, Т. Камалиев, Ш. Маннапов, К. Сибгатуллин, Д. Сирай, Н. Хисамов, Ә. Рәшитов, А. Сәләхетдинов, Н. Гамбәров, З. Гомәрова, Э. Мостафин, П. Апушев, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Хәлиуллина, А. Вергазов, С. Гәрәева,

Р. Закиров, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, М. Галиев, З. Насыйбуллин, Р. Вәлиева, Х. Халиков, М. Газизов, Б. Сөләйманов, Ә. Гаязов, Ә. Синегулов, А. Хәлим, Ә. Исхаков, Р. Вәлиуллин, Р. Бәширов, Р. Низамиев, И. Ганиева, Х. Хөснуллин, Э. Шәрифуллина, З. Мансуров, Х. Мөдәррисова, Р. Идиятуллин, Р. Риян, Х. Гатин, Ә. Гайнуллин, М. Садыйков, Р. Фазлыев, Ф. Шиһапова, Ә. Сәйфетдинов, В. Туктарова... Менә 50дән артык исем. Яшьрәкләр хисабына исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин. Югарыда санаганнарның бөтенесе аерым мөстәкыйль китап чыгарган (кайберләре хәтта өч-дүрт китап авторы) яки «Беренче карлыгачлар»га табаклап шигырь бастырган иптәшләр. Бу — үзе бер әдәби армия. Әдәбиятның, аерым алганда шигъриятнең дәвамчылары булган бу көчнең зур булуы, әлбәттә, сөендерә. Шул ук вакытта иҗатларына тиешле ярдәм күрсәтү һәм юнәлеш бирү ягыннан, Язучылар союзы идарәсенә, консультация бүлегенә, гомумән, бөтен язучылар коллективына зур җаваплылык өсти. Кемнәргә таянабыз һәм аларны тәрбия итүдә күпме көч сарыф итәбез, киләчәк шуңа бәйле.

Үткән ел яшьләрдән кемнәр аеруча актив эшләде соң? Беренчеләрдән итеп Зөлфәт Маликов исемен әйтер идем. Аның, ниһаять, «Язмышлар ярында» дигән беренче мөстәкыйль китабы дөнья күрде. «Казан утлары»нда шигырь цикллары басылып чыкты. Х. Туфан яшь шагыйрьнең беренче китабына язган кереш сүзендә болай дигән: «Поэзиянең нинди җитди, җаваплы миссия икәнлеген күңеле белән тойган, аңлаган бу яшь егет тормышны малайларча түгел, ә ирләрчә фикер йөртеп күзәтә белә». Зөлфәтнең шигырьләре өлкән шагыйрь әйткән фикерләрне раслый, хәер-фатыйхасын аклый, ышаныч уята. Шигырьләрендә кайбер каршылыклы фикерләр, кабатлаулар, оешу чорына хас беркатлылык чалымнары булса да, мин Зөлфәтнең бөтен язганнарын диярлек шигырь дип таныйм, аның сәләтенә, киләчәгенә ышанып карыйм. Кем генә ни генә әйтсә дә, поэзиябездә үз тавышы булган, Язучылар союзы гаиләсендә торырлык, перспективалы Зөлфәт дигән яшь шагыйрь бар. Бу — иң мөһиме. Аның иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең уңай фикере, «Казан утлары» журналының махсус бүләгенә лаек булуы да фикеремә куәт булса кирәк. Шул ук вакытта мин Зөлфәтнең чынлап өлгерүен, формалашуын, үзе генә чыгасы юлны, үзе генә менәсе тауны тизрәк табуын теләр идем. Поэзиядә үз миссиясен ул никадәр тизрәк аңласа, төшенсә, аңа шулкадәр яхшырак булыр. Зөлфәт бер шигырендә: «Су-

гар өчен син тимернең зәгыйфьрәк җирен — йөрәк турын таба бел генә», — ди. Шуның сыман, аның үзенә дә көчне кая юнәлтәсен, шигырь көче белән кая сугасын төгәл билгеләү бик кирәк. Миңа калса, кайчак Зөлфәт көчен үзе хәл итә алмаслык яки бүгенге әдәби ихтыяҗыбыз өчен алай ук зарур булмаган яки үзе белмәгән нәрсәләргә дә сарыф итә кебек. Атакага баручы рота, Хемингуэй үлеме, Кабан күлендә йодрык сугышы... Без төрлелек һәм тематик диапазонның киңлеге ягында, шулай да үзең белгән нәрсәләр турында язуга ни җитә! Кайчак миңа Зөлфәт егерме-утыз йортлык авылда батыр булып калган егет төсле тоела. Биленә таянып офык фонына баскан, бөтенесен егар кебек... Ләкин дөнья зур! Әллә нинди пәһлеваннар бар, әллә нинди көчләр бар. Кызганычка каршы, көчнең дә коесы төкәнмәс түгел. Зөлфәт инде зур тормышта да, шигъриятьтә дә малай түгел, үзенең реаль мөмкинлекләре турында һәм булган сәләтен кирәккә файдалану юнәлешендә уйланыр чагы. Һәрхәлдә, аңа ышаныйк, ул үсештә.

Зөлфәтнең яшьтәше Разил Вәлиевнең дә «Зәңгәр кабырчыклар» исемле беренче китабы дөнья күрде. «Поэзияне яратам. Дөньяның үзе төсле катлаулы да, кешеләргә аңлаешлы да итеп язасы килә». Болары — авторның моннан берничә ел элек матбугатта басылып чыккан сүзләре. Мәскәүдәге Әдәбият институтын тәмамлап килүче яшь шагыйрьнең беренче китабын кызыксынып укыдык: мәркәзнең югары мәктәпләрендә уку, башкала язучылары, шагыйрьләре белән аралашу безнең егеткә ничек тәэсир иткән икән? Поэзиябезне баетырлык табышлары бармы? Китап болай кызык, тематик яктан төрле, яңа хис-тойгылар, яңа буяу-бизәкләр бар анда. Автор үзенчәлекле, әмма бу үзенчәлек кайбер укучыда, соклану белән бергә, сәерсенү тойгысы да уятырга мөмкин. Яшь авторның беренче китабында, «Әнкәйгә хат», «Дисбе», «Казан поезды», «Авылда туй» кебек яхшы шигырьләре белән беррәттән, гражданин-мин булып җитмәгән «мин»нең үтә интим тойгы-хисләрен чагылдырган шигырьләр күбрәк кебек. Кайчак автор укучыга тәкәбберрәк карап: шуны да аңламыйсыңмыни? дип әйтә сыман. Шагыйрь белән укучы арасында тулы аңлашу булмаса, һәр ике якка да кыен. Бу мөнәсәбәтнең дустанә булуы өчен, минемчә, ике генә юл бар: әгәр син көчле талант икән, дөньяны үзеңә җәлеп иттер, кешеләрне үзеңә иярт, күтәр! — әгәр шуңа көчең юк икән, киң катлам укучыларның ихтыяҗлары, зәвыклары белән исәпләш.



*Үткән гасырның 60 нчы елларында шигырь бәйрәме Казанның Куйбышев (хәзер Тукай) мәйданында уздырыла иде*

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.

Аңламыйлар җилне зәңгәр дисәң,
Тормышыбыз — сабантуй дисәң.
Һәр нәрсәгә минем үз атамам:
Айны Кояш диям, теләсәм.

Мөгаен, Разилнең үзенә күбрәк үзгәрергә туры килмәгәе. Минемчә, ул яхшы якка, халыкчан якка, ил-халык язмышын кайгыртучы шагыйрьләр ягына үзгәрәчәк. Аның сугышчан холкы, ил сөяр, ирек сөяр табигате, әдәбиятка кайнар мәхәббәте, нык омтылышы бар.

М. Әгъләмов 1968 елның ахырында «Еракка китеп кара» исемле шигырьләр циклы белән үзен зур мөмкинлекләргә ия шагыйрь итеп күрсәткән иде. Күпләр аны шунда танып, яратып калдылар. Шуннан соң өч елдан артык гомер үтте, кечерәк кенә булса да китабы чыкты, берничә тапкыр бәйләм-бәйләм шигырь бастырды. 1971 елда чыккан шигырьләре дә уңышлы цикллар белән рәттән саналырга лаек. Шулай да Мөдәррис турында уемны әйтми китә алмыйм. Кемгә

ничектер, миңа калса, Мөдәррис «Еракка китеп кара»сыннан узып китә алмый кебек әле. Хәзер бастырган шигырьләренең күбесе моннан дүрт-биш ел элек язылган. Бүгенге көндә ул нәрсәләр яза? Нинди уйлар белән яна, нинди коллективта кайный? Ахыр чиктә без иҗат кешесен аның язган әсәрләренең кыймметенә карап бәяләргә тиешбез. Ләкин бер хакыйкать бар: шәхес нинди генә сәләтле булмасын, ул ялгызак булып яши алмый, әгәр ул бүгенге иҗтимагый тормышка кендеге белән берекми икән, талантның фаҗигаи сүнүе бар.

Гомумән, соңгы өч-дүрт ел эчендә әдәбиятка килүче бу яшь буын көндәлек иҗтимагый тормышта, әдәби хәрәкәттә, җәмәгать эшләрендә катнашулары ягыннан 65 нче еллар тирәсендә күтәрелеп чыккан буыннан күпкә кайтышрак, пассиврак. Әдәби җәмәгатьчелекне беркадәр өметләндергән, яшьләре белән Тукай яшенә җитеп килә торган бу сәләтле буын вәкилләренең теге яки бу мәсьәлә буенча ни матбугатта, ни җыелышларда борчылып, йә сөенеп үзләренең теләк-уйларын белдергән чакларын хәтерләмим. Хәзер коеп куйган шагыйрь генә булып булмый. Заман бүтән, максатлар бүтән. Үзебезне кем генә дип санамыйк, Вакыттан, Заманнан өстен була алмыйбыз, без фәкать йә актив, йә пассив булып шушы Заманда, Тормышта катнаша гына алабыз. Шагыйрьләр, әлбәттә, матурлык җырчысы. Ләкин нинди матурлык? Гомум абстракт матурлык күп, кешелек дөньясы аны безгә чиксез күп дәрәҗәдә мирас итеп калдырган, китапханәләрдә, храмнарда алар белән танышу өчен генә дә йөз гомер җитмәс. Без шушы гомумкешелек тудырган рухи хәзинәгә шушы замандагы, шушы җирлектәге социаль эчтәлекле, тормышның алга барышына ярдәм итәрлек үзебез тудырган конкрет матурлыкны өстәргә тиешбез. Бу миссияне үтәүне иҗтимагый тормышның үзәгендә кайнаудан тыш күз алдына да китереп булмый. Тагын шуны да әйтәсе килә: кайбер яшь шагыйрьләр, даһи шәхесләрнең, даһи әдипләрнең иҗтимагый бөек эшләреннән, кылган хезмәт батырлыкларыннан гыйбрәт алудан бигрәк, аларның тышкы, яшәештәге кайбер сәерлекләрен үзләренә үрнәк итмәкчеләр! Ләкин бер нәрсәне генә оныталар: Маяковскийның соры кофтасы сиңа зуррак булырга да мөмкин бит әле! Иң әүвәл эш, иң әүвәл хезмәт! Некрасов әйтмешли, шагыйрь булу-булмау үз ихтыярыңда, ә гражданин булырга бөтенебез дә бурычлыбыз.

Узган ел актив иҗат итеп, вакытлы матбугатта матур тәэсир калдырырлык шигырь бәйләмнәре бастырган К. Сибгатуллин, З. Насыйбуллин, Р. Миңнуллин, Х. Әюпов, Ф. Са-

фин, М. Галиев һ.б. иптәшләрнең дә исемнәрен уңай яктан искә алып үтәсе килә.

Нәшрият берничә ел рәттән яшь шагыйрьләр иҗатын «Беренче карлыгачлар» дип исемләнгән коллектив җыентыкларда бастыруны практикага кертеп карады. Яхшы ният белән башланган бу эшнең уңай һәм кире яклары булды. Уңайлыгы шунда: байтак иптәшләр бер дәррәү басылып алдылар. Ләкин тормыш үзе искәртеп тора, шагыйрьләрне унлап-унбишләп, серияләп поэзия күгенә очыртып булмый. Коллектив җыентык уңае белән талантлылар да, уртакул иптәшләр дә бер үлчәүгә, бер хәлгә куелды. Берәр елдан сәләтле иптәш аерым китап чыгарса, аннан күреп, инде тартып-сузып «Беренче карлыгачлар»га кергән иптәш тә, минекен дә аерым китап итеп чыгарыгыз дип, шул ук чыккан шигырьләренә бераз өстәп, нәширләр өстәленә китереп салды. Асылда, иптәш әдәбиятка кереп җитмәгән, «Карлыгачлар»ы әле сатылып бетмәгән, инде кабат басыла булып чыга. Бу кәгазь аз дип әйтергә ярата торган нәшрият файдасына түгел. Менә бер мисал. Яшь автор Данис Хәбибуллинның бер үк шигырьләре диярлек 1965 елны «Дуслык» күмәк җыентыгында, 1968 елны «Беренче карлыгачлар»да, 1971 елны «Беренче адымнар» дип аталган китапларда чыккан. Уннарча елга сузылган нинди «беренче адымнар» бу? Яки бүтәнчәрәк мисал: яхшы шигырьләре байтак булган Рәшит Әхмәтҗанов нәни генә беренче китабын 1962 елда ук чыгарган иде, аннан соң ун ел буена коллектив җыентыклар, карлыгачлар «зона»сын үтә алмый йөрде, гәрчә авторның кулга тотарлык мөстәкыйль җыентыгын ике-өч ел элек үк чыгарып була иде. Соңгы елларда үзенең иҗтимагый әһәмияте булган, фикри яктан саллы, халыкчан шигырьләре белән актив күренә һәм танылa бара торган К. Сибгатуллин белән дә шундый ук хәл: 1969 елда ук «Беренче карлыгачлар»га чыкты, тагын коллектив җыентыкта чыгару планлаштырылган. Нигә аерым китап итеп чыгарылмый? Шуңа охшаш мисалларны тагын китерергә мөмкин. Әйтәсе килгән шул: әгәр яшь шагыйрь сәләтле, перспективалы икән, әсәрләрен әдәби җәмәгатьчелек хуплый икән, бер дә курыкмыйча, аерым китабын чыгарырга кирәк. Тартып-сузып йөрүдән автор да, укучы да, ахыр чиктә нәшрият үзе дә отмый.

Әдәби журналыбызның беренче санында тәнкыйтьче Р. Мостафинның «Җаваплылык хисе» дигән исем астында яшь шагыйрьләр иҗаты турында уйланулары чыкты. Төпле һәм тирән эчтәлекле бу мәкалә бүгенге яшь көчләр хакында

гына түгел, ә бәлки соңгы чорда татар шигъриятенә килгән көчләрнең төп асыл сыйфатлары, үзенчәлекләре турында да. Тәнкыйтьче әдәбиятка 65 нче елларда килгән шагыйрьләр турында аеруча киң туктала, аларның иҗатын анализлый, индивидуаль йөзләрен ачыклый һәм бу төркем шагыйрьләрнең чагыштырмача тиз һәм куәтле рәвештә күтәрелеп чыга алуларының сәбәбен, нигезен аңлата. Шигърияттәге үзгәрешләрне бәяләве белән, яңарышны тудырган тарихи-социаль факторларны күрсәтүе белән килешкән хәлдә, минем тәнкыйтьченең бер фикерен дәвам иттерәсем, булдыра алсам, ачыклабрак та китәсем килә. Ул болай ди: «Рус һәм күпмилләтле бөтен совет әдәбиятында 50 нче елларның икенче яртысында һәм 60 нчы еллар башында барган процесслар безнең яшь поэзиябезгә дә йогынты ясамый калмады... Рус поэзиясендә шул чорда ук хасил булган көчле поэтик дулкын безнең әдәбиятка бары тик җиде-сигез елдан соң гына килеп җитте...» Шунда ук: «Барыннан да бигрәк аны (яшь поэзияне. — *Р. Ф.*) туендырып торган туфрак баеды, традицияләр киңәйде», — ди. Болар һәммәсе дөрес, бәхәсләшер нәрсә юк та кебек. Әмма яңарыш, күтәрелешнең төп нигезе, фәлән елдан соң килеп җиткән йогынтылы җилдән бигрәк, үз җирлегебездәге үзгәрешләрдә, тәнкыйтьче әйткәнчә, традицияләр киңәюдә, классик мираска мөнәсәбәт үзгәрүдә, гасырлар буе чарланып килгән шигъри культураның югары булуында, заман сулышын сизгер тоярлык кешеләре булуында. Яңарыш ераклардан, дастаннардан ук килә. Әйтик, Евтушенко, Вознесенский, Рождественскийларның М. Әгъләмовка яки Р. Мингалимовка, яки Рәшит Әхмәтҗановка сизелерлек йогынтылары булгандыр дип уйламыйм. Чөнки безнең шагыйрьләрнең үзләренең матур исемнәре бар, башны горур йөртерлек сәләтләре бар. Ә инде Мәскәүдәге бик модалы һәм популяр бер төркем шагыйрьләрнең иҗатына килгәндә, аларның XX гасыр тудырган мөмкинлекләрдән иркен файдалануларын, материаль һәм рухи хәлләрен исәпкә алып (теләсәләр, аларга Нью-Йоркка яки Парижга барып шигырь кичәләре уздырып кайту проблема түгел. Ә безгә?..), реалист булып карасак, мин аларны уртача язалар дип саныйм. Хәзер милли әдәбиятлар шулкадәр үсте, хәзер алар үзләре совет әдәбияты хәзинәсенә сизелерлек өлеш кертәләр, әдәби үсешнең кайбер традицияләрен билгелиләр. Йогынтылар күп тармаклыга әйләнде хәзер.

Менә без бер елда чыккан байтак әсәрләргә, байтак авторларга тукталдык, мөнәсәбәтебезне, теләкләрне белдердек.

Күзәтү рәвешендә конкрет авторлар, конкрет әсәрләр турындагы фикерләрдән соң, табигый, гомумирәк сораулар туарга мөмкин. Шигърият башка жанрлар белән чагыштырганда нинди хәлдә? Үсеш нинди юнәлешләрдә бара, потенциаль мөмкинлекләр ничек, хәл итәсе нинди проблемалар бар?..

Йомгаклау алдыннан, соңгы еллар шигърияте материалларыннан чыгып, шул хактагы фикерләрем белән уртаклашмакчы, кайбер нәтиҗәләр ясамакчы булам. Беренчедән, татар әдәбиятында шигырь сугышчан позициясен ныгытты, аның рухи тормыштагы йогынты офыгы киңәйде. Хәзер бездә теләсә нинди телдә, дөньяның теләсә кайсы почмагында бастырып чыгарырлык, сөйләрлек, йөз кызартмаслык шигъри әсәрләр бар һәм алар гомум хәзинәгә өстәлеп тора. Икенчедән, татар поэзиясенең төп асыл сыйфатлары булып аның гражданлыгы, тормышчанлыгы, халыкчанлыгы саналып килә һәм бу сыйфатлар соңгы еллар әсәрләрендә тагы да үстерелде. Тукай, Такташ, Җәлил, Кәримнәр традициясе яңа эчтәлектә, яңа төсмерләрдә, яңа формаларда дәвам итте. Ил һәм халык язмышы — поэзиябезнең үзәгендә, икенче төрле әйткәндә, «җырларда — ил гаме». Тормышыбыздагыча, шигъриятебез интернациональ эчтәлекле. Тагын бер зур казанышыбыз — идея чатаклыклары булмау, чит идеология коткысына бирелмәү. Татар шагыйрьләренең, гомумән, язучыларның бу яктан ил йөзен кызартканнары юк. Поэзиядә горурлык хисе үсте. Чөнки республикабыз тормышында горурланырлык вакыйгалар күп. Ил экономикасына керткән өлеш, зур төзелешләр, иң зур байлыгыбыз — кешеләр, аларның хезмәте — горурлык чыганагы.

Бер горурлык хисе яши миндә,
Эчтән бәреп яна битләрдә.
Сөйләр идем аны дөньядагы
Барлык-барлык парламентларда!

*С. Хәким*

Тәнкыйтьче Р. Мостафин әйткәнчә, үткән буыннарның әхлакый тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү, халыкның тарихи барыштагы урынын һәм ролен аңларга тырышу артты, рухи хәзинәләрне тарихи чагыштырып карау көчәйде. Шигырь тематик яктан киңәйде, фикри яктан тирәнәйде, яңа образларга баеды. «Шигъриятгәге бүгенге яшь кеше образы бармы?» — дигән сораугa, мин «бар!» дип җавап бирер идем. Ул, әлбәттә, Такташның 30 нчы еллардагы Алсулары, Зөбәйдәләре түгел, хәтта теләгәндә дә бүгенге яшь герой алар була

алмас иде. Аның каравы үткән, бүгенге, киләчәк турында, ил, халык, дөнья язмышы турында аек уйлый алучы җитди яшь кеше образы бар, бүгенге көн герое була алырлык лирик «мин» бар. Ул ачышлар ясый, калалар төзи, алда әйткәнемчә, Мефистофельләр белән бәхәсләшә, җиңә. Бу яшь кешенең исәбе, гаме зур.

...Нигез чиста,
Дәүләт чиста булсын!
Чиста акыл булсын, чиста кул! —
Кылганнарым шулар, кануным шул,
Максатым шул минем, юлым шул.

*Р. Мингалимов*

Шагыйрь бар икән, шигырьдә шәхес, кеше бар дигән сүз. Бездә шагыйрьнең өлкәне дә, яше дә бар, димәк, шигырьдә дә тулы канлы бүгенге кеше бар! Юкса поэзиянең тормышта тәрбияви роле артмас, күпләр өчен ул ихтыяҗга әверелмәс иде. Икенчедән, шигырьдә фикер һәм хисне укучыга җиткерү формалары төрләнде. Кешеләрнең интеллектуаль дәрәҗәсе күтәрелү, шәхесләрнең кабатланмас үзенчәлеге, информация заманына хас фикерләү рәвешләре, ахыр чиктә кешенең төрлелеккә омтылучан табигый халәте сәнгатьтә дә яңа сурәтләү чаралары, яңа формалар таләп итә. Шунысы характерлы: бу яңа формалар традицияләр нигезендә үсә. Яңарак формаларда эшләүче шагыйрьләр классик мәгънәдәге формаларда да уңышлы иҗат итәләр. Эзләнүләр, кемнәрдер уйлаганча, классик формада эш итә алмаганнан түгел, бәлки, традицион рәвештә эшли һәм бик яхшы эшли алып, формаларны төрләндерергә, мирасны баетырга тырышудан. Бездә хәзер шигъри әсәрләрнең бөтен төрләре бар: роман да, сюжетлы яки сюжетсыз уйлану поэмалары да, драматик поэмалар да, патетик мәдхияләр дә, элегияләр дә, сонетлар да, юмор-сатира шигырьләр дә бар. Кыскасы, үсеш, төрләнү, баю күз алдында.

Шул ук вакытта, үсешне таныган хәлдә, шигърият алдында хәл итәсе мәсьәләләр, проблемалар, бурычлар да байтак. Минемчә, аларның кайберләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: шигърияттәге булган хәзинәләрне, классик җәүһәрләрне һәм бүгенге яхшы әсәрләрне гомумсовет әдәбиятына казаныш итеп, зур өлеш итеп күрсәтеп җиткерә алмыйбыз. Бу, беренче чиратта, тәрҗемә эшенә карый. Тагын бер җитешсезлегебез — заманга ияреп җитә алмавыбызда, оперативлылык җитмәүдә, вакытны, форсатны ычкындыруда. Вакый-

галар узгач, су тонгач кына язарга яратабыз. Халкыбызның фидакяр хезмәте, республиканың уникаль казанышлары әсәрләребездә үз вакытында тиешле чагылыш табып җиткерми. Янәдән — бүгенге дөнья әдәбиятлары белән бәйләнешебезнең тиешле дәрәҗәдә булмавы. Хәзер бер генә халыкның әдәбияты да фәкать үз кабыгында гына яши һәм үсә алмый. Еш һәм эшлекле аралашу — зарури. Күпмилләтле совет әдәбиятының максаты, идеалы, темалары, хәл итәсе мәсьәләләре уртак. Шуңа да теге яки бу халык әдәбиятында мәгълүм бер проблеманың ничек хәл ителгәнен, нинди чара-ысуллар ярдәмендә югары эстетик кыйммәткә, яңгырашка ирешкәнен өйрәнү — безнең өчен бик тә кирәк. Өченчедән, халтура шигырьләре әдәби продукциянең сизелерлек өлешен тәшкил итә әле. Күрәсең, ак белән караны, чын белән ялганны тәгаен аерып җиткерә алмыйбыз. Бу очракта таякның бер башы редакцияләрдә утыручы әдәби хезмәткәрләргә дә төшә. Бастыручы булгач, язучысы табылыр. Без күп вакыт чүп үләннең үзенә каныгабыз, ә аны үстерүчеләрне онытып җибәрәбез. Әлбәттә, халтура белән көрәшү җиңел түгел. Кыенлык шунда: кәсепче теманың актуаленә ябыша, сәясәттәге һәрбер үзгәрештән максималь файда алып калырга тырыша. Кәсепчеләрнең кайчан да булса эзе дә калмас дип уйламыйм, ләкин аңа карап алар белән көрәшүне дә туктатырга ярамый. Күрәсең, зур темаларны халтурачылардан саклый да белергә кирәк. Практик яктан моны талантларга игътибарны көчәйтү, аларның гражданлык тойгыларын үстерүдә ярдәм итү, ышану, социаль заказлар бирү, җәмәгать эшләренә активрак тарту белән эшләп булачак. Сүземнең төбе аңлашыла дип уйлыйм, талантларга таянырга кирәклек турында, аларны халык мәнфәгатен чагылдыра торган әдипләр итеп тәрбияләү турында.

Сүземнең ахырында шигырь китапларын бастырып чыгару һәм аларны тарату мәсьәләсенә тукталасы килә. Парадокс хәл: шигърият үсә, дибез, ә тиражлар кими бара. Борчылырлык, чаң сугарлык хәл бу! Моннан дүрт-биш ел элек китаплар 8—10 мең данә чыга иде. Хәзер уртача 3 мең данә. Миллионлап исәпләнгән татар халкы өчен бик аз сан бу. Хикмәт шигърияткә ихтыяҗ кимүдә түгел, әлбәттә. Сәбәпләрнең берсе китап пропагандасы эшенең йомшак булуында, китап сатуда эзлекле бер тәртип булмауда. Нәшриятның яхшы китапларны тиешле күләмдә, тиешле полиграфик югарылыкта чыгармавында. Күргәзмәләр өчен чыгарылган аерым басмаларны исәпләмәгәндә, тышкы кыяфәтләре ягын-

нан китапларыбыз шыксыз һәм кызыксыз булып чыгалар. Шигырь — нечкә, нәзакәтле жанр. Дөрес, соңгы елларда «Шигырь китапханәсе» сериясеннән классик һәм өлкән буын шагыйрьләрнең матур гына басмалары да дөнья күрде. Бу — бик яхшы. Бөтен китапларны зәвыклы бизәп, күзне иркәләрлек итеп чыгарырга кирәк. Һәр китап — нәшриятның очырган баласы бит ул. Китап язмышы. Без аның язмышын күп чак күздән югалтабыз. Очырабыз, югалтабыз. Тулаем алганда, китап сату, китапны пропагандалау эше бездә начар куелган. Республикабызның үз районнарында яки бүтән өлкәләрдә үтә торган әдәби атналыкларда, очрашуларда булган язучыларның китап сату оешмаларыннан канәгать кайтканнары юк диярлек. Нәшриятның да, Язучылар союзы оешмасы каршындагы пропаганда бюросының эше дә бу юнәлештә канәгатьләнерлек түгел. Гомумән, әдәби китаплар аша эстетик тәрбия бирү, китап пропагандалау эше — эшлекле сөйләшүне сорый торган аерым зур мәсьәләләрнең берсе. Китапны югалтсак, милләтебезне дә җуюыбыз бар.

*1972, гыйнвар*

## БЕЗ ӘЗЕРМЕ?

Алдымда Нәкый Исәнбәт кулы куелган бер белешмә-кәгазь ята. Ул моннан биш ел элек, аның 70 яшьлек юбилее мөнәсәбәте белән язылган. Белешмә болай исемләнгән: «Н. Исәнбәтнең бастыру планына кертелү сорый торган әсәрләре һәм гыйльми-иҗади хезмәтләре». Балалар әдәбияты буенча — 50 табак, фольклор буенча — 230 табак, татар теле һәм стилистикасы буенча — 300 табак, пьесалар — 30 табак... җыенысы — 900 табак!

Әле яңа гына 150 еллык бәйрәме билгеләнеп үтелгән Каюм Насыйриның басылып чыккан хезмәтләре 500 табаклап булган икән. О. Бальзак, А. Дюмаларның йөзәр томнардан торган иҗатларын искә төшерик. Бүген дә әле актив иҗат итә торган Ж. Сименонның да романнар саны өч йөздән артты шикелле инде... Мәшһүр исемнәр, тау хәтле хезмәтләр, көнләшерлек саннар!

Ни өчен бу исемнәрне атап үтәм әле? Гыйбрәт өчен. Уйланыр өчен. Яшьләребезгә дә, өлкәннәребезгә дә, һәммәбезгә дә. Югарыда саналган әдипләр мирасының иҗтимагый-эстетик кыйммәтенә керешеп тормастан (әлбәттә, бусы — иң мөһиме), хезмәтләренең күләме ягыннан гына карасаң да шаккатарлык! Язучы исемен йөртер өчен күпме көч, ихтыяр, түземлек һәм, ниһаять, күпме фидакярлек кирәк!

Кайчак, ыгы-зыгылы көндәлек мәшәкатьләрдән бер мизгелгә айнып, үзебезнең бүгенге әдәби мохиткә, үз-үзеңә, хезмәттәшләреңә, кылган эшләргә бер сынаулы караш ташлыйсың да ихтыярсыз уйлап куясың: классик мәгънәдәге язучымы соң без? Әгәр язучы икән, аның нинди? Өрсәң, очып китәрлек, кош теле кадәр китап чыгарып, шуның күләгәсендә (билгеле, күләгә бик бәләкәй!) хозурланып ятмыйбызмы? Әллә безнең кайберләребездә сәләт азмы, әллә рухи үшәнлегебезне таныргa егетлегебез җитмиме? Уңышларның булган кадәрен таныган хәлдә, мондый минор уйлар туарга да җирлек бар бит. Үзеңә тигән бурычларны арткы плангарак куеп, бүтәннәргә карата таләпләрне кискен һәм куертыбрак сөйләргә ярату, беренче чиратта, яшьрәк язучыларда очрый. Пассивлык һәм аз язу турында сүз чыкканда, андый иптәшләр акланырлык дәлилләр дә китерәләр: Дәрдемәнд, С. Рәмиев кебек әдипләрнең дә дөнья күргән шигырьләре бер табак чамасында гына, ә шигърияттә барыбер үз урыннарын алганнар бит! (Бу очракта андый оппонент Тукайны атамый, әлбәттә!) Хуш, әдәбият-сәнгатьтә бер-ике кыска әсәре белән дә ихтирамлы урын алган шәхесләр дә бар ди.

Ә синең берничә бөртек шигырең яки хикәяңнең, вакыт иләген узып, Тарих елъязмасына керүенә гарантия бармы соң әле? Бәлки... Кыскасы, әле көчең һәм сәләтең барда, киләчәккә ныклы иманың, халкыңа ышанычың булганда күңел байлыгыңны һәм саулыгыңны кызганмый иҗат итүгә ни җитә!

Кешелек киләчәк белән яши. Кешене иртәгесе көнгә ышанычы яшәтә. Бу — иҗтимагый тормышта да шулай. Әдәбият, бүгенгесе белән шау чәчәктә шикелле булып та, әгәр аның киләчәге юк икән, ул кызганыч әдәбият. Бу җәһәттән татар әдәбиятында, шөкер, эшләр алай ук балтасы суга төшкән кешенеке шикелле түгел әле. Яшь көчләр әдәбият мәйданына өзлексез килеп, киләчәкнең ныклыгына ышаныч биреп торалар, һәм, әйтергә кирәк, сәнгатьнең бүтән өлкәләре белән чагыштырганда, бу куанычлы процесс бездә шактый дәрәҗәдә көчле. Бу хәл, бер яктан, әдәбиятның спецификасы, беренче чиратта, тирән тарихы белән аңлатылса, икенче яктан, Язучылар оешмасының яшь алмаш көч тәрбияләүдәге кайгыртучан эшчәнлегеннән килә. Яшь язучыларны үстерү юнәлешендә күп төрле нәтиҗәле оештыру чаралары күрелә. Алар — индивидуаль консультацияләр, даими үткәрелеп килә торган семинарлар, әдәби берләшмәләр челтәре белән идарә итү, тематик киңәшмәләр, бүтән иҗат оешмалары белән берлектә, яшьләрнең халыкара «Идел» («Волга») лагерендагы очрашулар һ.б. Моннан ел ярым элек иҗат берлекләренең һәм учреждениеләренең яшь алмаш тәрбияләү эшенә багышланган берләштерелгән пленумындагы эшлекле сөйләшүләр, кабул ителгән планнар һаман истә, һаман көндәлек гамәлдә. Мәскәүдә яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсе ачылу — үзе яшь каләм ияләре турында ил күләмендә кайгыртуның ачык мисалы. Татарстаннан бу югары дәрәҗәле киңәшмәдә биш яшь язучы катнаша. Алар — прозаиклар Әхәт Гаффаров, Марсель Галиев, Разил Вәлиев, шагыйрь Равил Бохараев, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев. Профессияләре буенча төрлесе төрле җирдә эшлиләр: журналист, әдәби хезмәткәр, аспирант, офицер... һәммәсе югары белемле, һәммәсе Казан университетын тәмамлаган кешеләр. Тормыш юллары, үсү һәм тәрбия шартлары, хезмәт урыннары төрлесенеке төрлечә булса да, аларны берләштергән нәрсә — әдәбият. Болар — үзләренең язган әсәрләре белән әдәби җәмәгатьчелеккә беркадәр танылган, индивидуаль иҗат йөзләре белән ачыклана төшкән өметле яшь әдипләр.

Бүгенге көндә республикада 25 әдәби берләшмә эшли. Татар һәм рус телләрендә актив яза торган каләм ияләре

300дән артык исәпләнә. Бу — зур көч. Тиешле әдәби тәрбия һәм дөрес идея-политик юнәлеш биргәндә, алар арасыннан чын яхшы язучылар чыгарга мөмкин. Саннар, бер яктан, куанычлы булса, икенче яктан, сыйфат һәм перспектива ягыннан, уйланырлык, борчылырлык яклар да юк түгел. Башлап язучыларның күбесе чын мәгънәсендә бик үк яшь түгелләр. Күбесенең яше утыздан ашкан (сүз уңаенда әйтеп үтик: Язучылар оешмасының хакыйкый әгъзалары арасында да яшь язучылар аз, нибары ике генә иптәшебезнең яше утыздан ким).

Күңелне тынычсызлата торган тагын бер нәрсә шул: яшьләребезнең байтагы тормышта һәм әдәбиятта төп урыннарын, төп миссияләрен үз вакытында ачыклап бетерә алмыйлар. Ориентирлы максат — бөек нәрсә! Үз-үзеңне табу дистә елларга сузыла. Минемчә, язучы булырга карар кылган һәр кешенең, гражданин буларак, олы биографиясе, тормышта үзе бик яхшы белгән өлкәсе, үз дөньясы, шул нисбәттән үз темасы булырга тиеш. Талантың һәм сәләтең ягыннан кем син, бу дөньяда син нәрсәне ныклап беләсең, булган мирасыбызга нинди яңалык, кешеләргә нинди матурлык өсти аласың; нәрсәне инкяр итәсең, нәрсәне данлыйсың һәм куйган максатыңа ирешүне ничек раслыйсың?



*Иҗат яшьләренең республика семинарында катнашучылар. 1977*

Әйтик, унсигез яшьлек шагыйрь, Хозыр Ильяс сурәтенә кереп, фәлсәфи «карт» шигырьләр яза яки үзе киноларда гына күргән сугыш хәлләрен сурәтли башлый... Бер генә мисал: Әлмәт якларында туып үскән өметле яшь прозаик А. Ганиев XIX гасыр ахырларына караган күләмле әсәрнең бер өлешен язган (белүемчә, автор аны берничә китап итеп эшләмәкче була). Әлбәттә, беркемне дә, син ни өчен тарихи әсәр язарга керештең дип гаепләп булмый (ахыр чиктә тарихи әсәрләрне дә бүгенге заман кешеләре иҗат итәргә тиеш ләбаса!). Шулай да сорау туа: син ул заманны яхшы беләсеңме, кирәкле чыганакларны тиешенчә өйрәндеңме, шул чорда яшәгән кешеләрнең рухын тоюыңа ышанасыңмы? Ихтимал, бала чактан ук күзеңә һәм күңелеңә иңгән туган як турында (бу очракта нефть исе, факел балкышлары, җир-су фаҗигасе), үзеңә таныш кешеләр, аларның бу җирдәге гамәлләре, шатлык-кайгылары турында язу отышлырак һәм кирәгрәк булыр иде.

Шулай ук сүземнең башында ук башлаган гомумактивлык турында кайтып әйтми булмый. Минемчә, пассивлык — безнең яшьтәшләребезнең, һәм тагын да яшьрәкләребезнең иң йомшак ягы. Әдәбият тарихы һәм көндәлек тормыш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: җәмәгать эшендә — һәммәбез өчен дә кирәк эштә — кем актив, шул кеше үз иҗатында да актив, майтарган эш-хезмәте дә зуррак. Андый затлар бүтәннәр өчен дә, үзләре өчен дә эшләргә вакыт таба алалар.

Уйлап баксак, бу күркәм сыйфат үзе бер закончалык икән, аның традицияләре борынгыдан ук килә. Искә төшерик: Тукайлар, Ибраһимовлар, Җәлилләр җәмәгать эшендә дә, иҗатларында да үрнәк маяк булганнар. Н. Островский үзенең яшьлек гомерен яу-көрәшләрдә чыныктырып, соңгы бар көчкуәтен иҗатына салып яндырган. Бүгенге көн татар язучыларыннан С. Хәким, Г. Әпсәләмов, Г. Ахуновларны алыйк. Йә, кем аларны иҗатларында һәм җәмәгать эшләрендә пассивлыкта гаепли алыр икән? Моннан биш-алты ел элек беренче әсәрләре белән әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп иткән М. Әгъләмов, Зөлфәтләргә бу яктан нигә өлкәннәрдән, үз остазларыннан үрнәк алмаска? Яшьтәшләренең иҗатлары турында, үзләрен сөендергән йә борчыган проблемалар турында матбугатта йә җыелышларда нигә үз фикерләрен белдермәскә?

Безнең заманда «саф шагыйрь» генә булу, ихтимал, мөмкин дә түгелдер. Тукайларны, Бабичларны остаз санагач, аларның бөтен уңай сыйфатларын үзеңдә булдырырга тырышырга кирәктер ләбаса! Үз вакытында матур-матур гына хикәяләр

яза башлаган Фәрит Гыйльметдиновның ник бер дә тавыштыны чыкмый? Вакытлы матбугатта әйбәт шигырь цикллары чыгарган Эдуард Мостафин кайда? Талантлы шигырьләр иҗат итүче Зиннур Насыйбуллин нигә бик акрын кыймылдый?

Бәлки, шуңа күрә дә киләчәктә яшьләр журналы итәрбез дип хыялда йөрткән «Идел» альманахы да заман рухы белән сугарылган талантлы әсәрләр белән тулып чыга алмыйдыр. Шулай ук нәшрият киштәләрендә яшь шагыйрь яки прозаикларның томлап чыгарырлык шәп кулъязмалары да күренми диярлек.

Дөрес, әдәби хәрәкәттә үз сүзләрен әйтеп, хәл кадәрле катнашып килүче яшьләребез дә үсеп килә. Бу уңайдан Әхәт Гаффаров, Мансур Вәлиев, Марсель Галиев исемнәрен атап үтәсе килә. Шулай ук Разил Вәлиев, Әмир Мәхмүдов иптәшләр дә соңгы вакытта активлаша төштеләр. Бу — сөенечле хәл.

Кыйтга-континентлар, ил-дәүләтләр, мәдәни байлыклары белән актив аралашу заманында үз эстетик принципларыңны (шул исәптән күпмедер дәрәҗәдә халкыңныкын да) расслар өчен гаять зур талант һәм галәмәт ихтыяри көч кирәк.

Заманга иш булыйм дисәң, —
кем бер янса —
ун яшьнәргә, ун янарга
кирәк безгә!
Тормыш дигән Халыкара
Сабантуйда
батыр булып калалырга
кирәк безгә!

...Хәтерегезгә төшерегез: «Бер елның тугыз көне» дигән фильмның финалында төп герой болай ди: «Барысы да кешеләргә кала...» Димәк, яшьләргә кала. Ә соң без яшьләр дөньяны, өлешебезгә тигән бай әдәби мирасның лаеклы варислары булып, фидакяр даһи җаннар калдырган традицияләрне дәвам иттерергә әзерме, җаныбыз олымы, күңелебез баймы?

*1975, март*

## ШИГЪРИЯТЕБЕЗ ТУРЫНДА

Съезд — бөтен буын язучылары өчен дә уртак зур вакыйга. Безнең буынга — әдәбиятның чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләренә дистәләгән съездларда катнашырга туры килмәсә дә, Бөтенсоюз һәм республикабыз масштабында үткән соңгы ике-өч съезд һәм аларда булган сөйләшүләр ачык хәтердә. Ул узган съездларда ил күләмендәге әдәби процесска һәм шулай ук милли әдәбиятлар үсешенә турыдан-туры бәйле булган байтак актуаль проблемалар күтәрелгән иде. Әйтик, үзебезнең республика күләмендәге съездларда әдәби алмаш — яшьләр өчен махсус әдәби журнал яисә квартал саен чыга торган альманах булдыру, «Казан утлары» журналын РСФСР Язучылар союзы органы итеп үзгәртү яки безнең язучыларны чит илләргә чыгучы рәсми делегацияләр составында даимирәк катнаштыру, Язучылар союзының штат берәмлекләрен арттыру, әдәби музей ачу, Язучылар йорты салу һ.б. шундый мәсьәләләр куелган иде. Аларның кайберләре инде уңай хәл ителде, ә беришеләре исә көн тәртибендә кала бирә.

Татар язучыларының бу зур җыелышында, әдәбият башында М. Горький, А. Фадеевлар торган чорларда ук әдәби



*Тукай-Кырлайда шигырь бәйрәме. 1986*

мәйданга килеп, замананың күп съездларын һәм җәмгыятебез тормышының зур вакыйгаларын үз башларыннан кичергән өлкән буын язучылары да утыра. Янәшә куеп чагыштырып карарга һәм әдәбиятыбызның бүгенге тормышын төплерәк һәм төгәлрәк анализлауга ярдәм итәрлек мәгълүмат алар хәтерендә, һичшиксез, күбрәк. Кереш сүздә болай экскурс бирүнең мәгънәсе шунда — бу съездда да һәм иҗат мәсьәләләре буенча, һәм оештыру эшчәнлегебез турында, минемчә, шактый һәм кирәкле фикерләр әйтелде. Ләкин аларның байтагы үткән съездларда күтәрелгән мәсьәләләрнең үстерелеше юнәлешендә яңгырамады. Шуңа күрә алда булачак съездларда чыгыш ясар ораторлар бүген без монда ихлас күңелдән тикшергән мәсьәләләрнең үтәлү-үтәлмәүләрен «онытып» үтсәләр, ихтимал, безнең барыбызның да беркадәр хәтере калыр иде. Җәмгыять эшчәнлегенең теләсә кайсы өлкәсендә, шул исәптән әдәбиятта да, проблемаларны хәл итүдә төпле, нык эзлеклелек булганда гына чын тәрәккыят — прогресс булырга мөмкин.

Үткән съездларда Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе иҗади һәм оештыру эшләре буенча махсус чыгыш әзерләгән иде. Бу юлы андый ихтыяҗ юк. Делегатларга «Татарстан Язучылар берлегенең ике съезд арасындагы эшчәнлеге турында» брошюра таратылды. Күп кенә статистик материаллар белән бергә, ул китапчыкта иҗат секцияләренең эше турында да шактый мәгълүмат теркәлгән. Шуңа күрә дә төп сүзем үземә якын һәм аңлаешлы өлкә булган поэзия турында.

Борынгы һәм мәңге яшь шигърият турында, жанр буларак аның асыл сыйфатлары турында ниндидер яңа сүз әйтү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер. Ләкин шигъриятнең бүгенге җәмгыять тормышында тоткан роле хакында уйлану зарар итмәс. Шигърият барлык заманнарда хезмәтне һәм батырлыкны, сафлыкны һәм мәхәббәтне — табигатьтә һәм кешедә булган гүзәллекне данлап җырлаган. Рухы-табигате белән гөл кебек нечкә һәм нәфис шигърият кирәк чакта халык язмышының хәлиткеч сәгатьләрендә үткен кылыч булып та ялтырый алган. Шагыйрьләр заманында гаскәр башлыклары да, ил идарәчеләре дә булганнар, ач-ялангач, илсез-күзсез, хәерче, дәрвиш булып та йөргәннәр. Тарих андый байтак исемнәрне хәтерли. Шагыйрь илнең кайгы-шатлыкларын үз йөрәге аша үткәрүче табигатьнең җанлы бер инструменты — коралы ул. Шагыйрь халыкны җырлаган, халык исә шагыйрьне байракчысы итеп күтәргән. Шулай да шагыйрьләрне еш кына эзәрлекләгәннәр, үтергәннәр — моны гасырлар

һәм еллар хәтерли, — әмма шагыйрьләрнең җан кыючы булуларын тарих белми. Чөнки шигърият үлемне түгел, ә яшәүне җырлый, аның асылында бөек гуманистик хис — кешелеклелек ята. Олы шагыйрьләр, аларның шәхси язмышлары, яшәештәге урыннары нинди булуга карамастан, үзләре исән чакта ук яки үлемнәреннән соң халыкның рухи юлбашчылары булып танылганнар, халыкның намус һәм горурлык символына әверелгәннәр. Шушындый уйлардан соң безнең бүгенге шагыйрьләребезгә якынрак килик.

Без үзебез кемнәр соң? Бүгенге тормышта торкан урыныбыз һәм яңа җәмгыять төзелешенә керткән өлешебез ниндирәк? Үзебезгә-үзебез куйган таләп, бәя, чыннан да, объектив дөресме? Әлбәттә, җәмгыятьнең үсеш законнарын һәм үзебез яшәгән дәверне исәпкә алмыйча, социаль-техник прогрессны, сәнгатьнең үз эчендәге бүленешләрне күрмичә, тарихилык принцибы белән исәпләшмичә, абстракт артык зур хокукларга һәм миссияләргә дәгъва итү дөрес булмас иде. Ләкин кодрәтле вакыт та, тарихи-социаль үзгәрешләр дә шагыйрьне аның горур һәм бөек исеменнән мәхрүм итми, минемчә. Киресенчә, шагыйрьнең гражданлык активлыгын тагын да күтәрү турында бара сүз хәзер. Бу мәсьәлә, күрәсең, күпләрне дулкынландыра һәм уйландыра. Шагыйрь һәм тормыш. Быел СССР Язучылар союзы идарәсенең поэзиягә багышланган махсус пленум җыярга ниятләве, үзәк әдәби журнал һәм газеталарның шагыйрьләр иҗаты турында әледән-әле дискуссияләр оештыруы шул хакта сөйли булса кирәк. Халыкка яңа Пушкиннар, Тукайлар, Есениннар, Җәлилләр, Твардовскийлар кирәк. Шагыйрьләр хәзер болай да күп бит дип әйтүләре мөмкин. Язучылар союзында член булып торган профессиональ шагыйрьләр илебездә ике мең ярым чамасы, Мәскәүнең үзендә генә меңләгән шагыйрь исәпләнә. Татарстан Язучылар берлегендә дә «саф» шагыйрьләр иллегә якын. Ләкин бу саналган меңнәрнең, йөзләрнең барлык иҗатлары чын поэзия дип аталырга лаекмы соң? Бу сорауга өзеп кенә җавап бирү читен. «Шагыйрь» дигән төшенчә үз замандашыбыз уенда, дөресен әйтик, төрле тойгылар уята, шул исәптән ул тойгыларда ихтирам белән бергә берникадәр көлемсерәү төсмере дә юк түгеллеген онытмыйк. Нигә алай соң?

Тик шулай да укучыларыбызның бер өлешен мещанлыкта гаепләргә яки шагыйрьләр кавемен купшы респектабельлеккә чакырырга ашыкмыйк. Гади укучының да хәлен аңларга кирәк — шагыйрь саналган күп меңнәрнең тау-тау шигырь китаплары арасыннан яхшыны яманнан аеру жи-

җел эш түгел. Тигез хокуклы, басым ясап әйтәм, юридик тигез хокуклы шагыйрьләрнең шундый зур армиясе булу үзе генә дә билгеле бер дәрәҗәдә шигърияттнең девальвациясенә, очсызлануына алып бара. Тигезләү тенденциясе поэтик сәнгатькә зарар китерми кала алмый. Меңләп исәпләнми шагыйрьләр. Зур яки уртакул шагыйрь дип әйтү үзе үк, минемчә, дөрес түгел. Шагыйрь уртакул була алмый. Шагыйрь бар яисә ул юк. Кайбер тәнкыйтьчеләр әйткәнчә, әдәбиятка алар көтүләре белән дә килмиләр. Һәркем үз шигъри йолдызын табып, үз сукмагыннан ялгызы килә. «Әйдә, язсалар язсыннар, вакыт үзе талантларны гына сайлап калдырыр әле», — дип, үз-үзеңне юатудан яки сукранудан да әллә ни мәгънә юк. Кайбер нәрсәләргә менә хәзер, бүген төшенергә мөмкин һәм төшенергә кирәк булганда, нигә бөтенесен дә тарих җилкәсенә калдырырга?

Тере материяне фәнни тикшеренүдә кеше акылы фантастик уңышларга иреште, әмма кешенең художество талантын танып белү һәм ачыклауда без элеккечә үк көчсез әле. Бу мәсьәләдә бердәм һәм даими критерийларны алдан билгеләп кую, бәлки, мөмкин дә түгелдер. Ләкин талант табигатен өйрәнү кирәк һәм зарури нәрсә икәнлеге көннән-көн сизделә. Безнең эстетикада бик йомшак өйрәнелгән бу проблема әдәбиятның, гомумән, сәнгать теориясе һәм практикасының иң актуаль мәсьәләләреннән берсе саналырга тиеш. Талант турында фикер йөрткәндә, гадәттә, ике төрле караш барлыгы ачыклана. Кайберәүләр фикеренчә, талант ул иң мөһиме түгел. Белемле һәр кеше, теләге булып тырышса, янәсе, әдип булып китә ала. Икенчеләр, киресенчә, әдәбият-сәнгать кешесе булу өчен югары белем дә, махсус әзерлек тә, системалы рәвештә эшләү дә, ихтыяр көче дә таләп ителми, талантлы затка һәрнәрсә үзеннән-үзе бирелә дип уйлыйлар. Беренче «теория» тарафдарлары арасыннан коры рифмачылар, графоманнар төркеме барлыкка килә, һәм алар, ару-талуны белмичә, әрсез рәвештә нәшриятларга һәм иҗат союзларына зур дәгъвалар куеп тынгылык бирмиләр, әйтергә кирәк, еш кына максатларына ирешәләр дә — ярымфабрикат әсәрләрен дөньяга чыгаралар. Икенче «теория» исә беркадәр табигый сәләте, талант очкыны булган кешеләрдә, бигрәк тә яшь иптәшләрдә, тормыш өчен бик тә кирәк булган уку һәм хезмәт дисциплинасы кебек нәрсәләргә җиңел һәм җавапсыз карауга, рухи оешмаганлыкка, богемачылыкка этәрә. Шулай итеп, талант төшенчәсенең эстетика фәнендә тиешенчә эшләнмәгән булуы аркасында, без әсәрнең художество дәрәҗәсен билгеләүдә һәм поэтик хәзинәне бәяләүдә тәҗ-

рибәсез кешеләрне, аеруча яшь укучыларны кыен хәлгә куябыз. Дөресен әйтергә кирәк, без, әдәбиятчылар, кайчак теге яки бу кешенең иҗатын бәяләгәндә үзебез чама хисен югалтыбрак җибәргәлибез. Әйтик, күп китап чыгарган берәр шигырьчене җыелышларда атаклы яки күренекле дип әйтергә дә тартынмыйбыз, яки талантлы шагыйрьнең дә, союзга очраклы рәвештә алынган рифмачының да әсәрләрен, вөҗдан газабы кичермичә генә, бер үк күләм, бер үк тираж белән бастырып чыгаргалыйбыз.

Мәгълүм нәрсә, берише талантлы кешеләрнең кайбер сәер һәм йомшак яклары да булгалый. Кайбер талантлы кешеләр иҗатларында фидакяр хезмәт күрсәтсәләр дә, шәхси яшәешләрендә беркадәр инертрак булучан, тормышчан актив хәрәкәтләре белән гел күзгә бәрелеп тормыйлар. Ә әдәби эшкуар үзенең актив «гражданлык» сыйфатлары белән һәрвакыт күзгә ташлана. Аның һәрнәрсәсе алдан уйланган булыр, исәбендә ялгышмас, китабын бастыруда членлык хокукларыннан максималь файдаланыр. Ә күп санда китаплар чыгаргач, ул әдәби тәнкыйтькә гаеп ташларга тотыначак. Әлбәттә, аны вакытында язудан туктатмаган өчен түгел, ә иҗатын тиешле югарылыкта бәяләмәгән өчен гаепләячәк ул тәнкыйтьчеләрне. Күрәсең, кайчак без бик гади бер хакыйкатьне онытып җибәрәбез: хөрмәткә лаек биографиясе, гражданлык хезмәтләре һәм беркадәр әдәби грамотасы булган һәр кеше яхшы шагыйрь яки язучы булып китә алмый бит! Укытучы-остаз һәм дә аның шәкерте ничек кенә ихлас тырышмасыннар, талантлы булырга өйрәнү яки өйрәтү мөмкин түгел. Шулай итеп, укучыларыбызны примитивлыкта, шигъриятне аңламауда гаепләүдән элек, безгә әүвәл үз иҗат «цехыбызда» байтак нәрсәләрне үзара ачыклыйсы бар әле. Нәрсәнең яхшы һәм нәрсәнең начар икәнлеген һәрдаим ачыклап тору бик мөһим. Әгәр чын поэзияне халтура әсәрләреннән тиешенчә аралап бетерә алмыйбыз икән, аны гуманистик җәмгыять төзелешендә бөтен җегәрендә файдаланып бетермибез икән, бу — шигырьдә тигезләүчелекнең, «бер чыбыктан сөрү»нең, талантлы һәм сәләтсез кешеләр арасындагы законлаштырылган «бердәм» тигезлекнең ачы җимешләре булып саналырга тиеш. Гыйбрәтле хәл: шигырь культурасы чагыштырмача зур һәм телнең сафлыгын кайгыртучы күп миллионлы укучылары булган рус поэзиясендә дә вакыт-вакыт художество ягыннан йомшак шигырь җыентыклары күренгәли. Ә андый китапларның аз санлы халыклар телләрендә тагын да ешрак басылу ихтималы күбрәк бит. Ник дигәндә, азчылык халык укучыларының, бигрәк тә техник

интеллигенция вәкилләренең белемлерәк һәм әзерлеклерәк өлеше еш кына туган теленең нечкәлекләрен тиешенчә белеп бетерми. Димәк, шигъри сүзнең нәфислеген, тел байлыгының кадерен белүчеләр азрак булып чыга дигән сүз. Әгәр шагыйрьләрне нәшер итүдә катнашучы иптәшләр тема ягы белән нык кызыксынып та, әсәрнең художество сыйфатына игътибар биреп җиткермәсәләр? Кәсепче мондый хәлдән оста файдалана. Актуаль темага ул бик теләп тотына, аны рифма кысасына куып кертә һәм... теманы әрәм итә. Бу бик начар нәтиҗәгә — гражданлык темасын ваклауга, кадерсезләүгә китерә. Эстетика законнарын нык саклап, талантлы итеп язылган әсәрләр аша гына көнүелдәге мөкатдәс идеяләрне күпсанлы укучыларыбызга илтеп җиткереп, максатка ирешә алачагыбызны беребезгә дә онытмаска иде. «Талант — сирәк күренеш. Аның кадерен белергә кирәк», — дигән Ленин. Ә моның өчен иң әүвәл талантны аера һәм билгели белергә, һәрдаим яклый белергә кирәк. Бу урында әле күптән түгел генә булып узган съезд резолюциясендә әйтелгән сүзләрне тагын бер кат хәтеребезгә төшерү урынсыз булмас: «Безнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте партия линиясен актив үткәрергә, таләпчәнлекне тактлылык, художество кыйммәтләрен тудыручыларга сакчыл мөнәсәбәт белән бергә бәйләп зуррак принципиальлек белән эш итәргә тиеш».

Шигърият һәм шагыйрьләр турында сөйләгәндә, тагын берничә мәсьәләгә тукталып үтми булмый. Тәнкыйть мәкаләләрендә, чыгышларда яисә докладларда гадәттә әсәрләрнең үзләрен түгел, ә шагыйрь исемнәрен саныйлар. Әгәр шагыйрь поэмалар түгел, шигырьләр генә язса, аның теге яки бу шигыре, әйтик, кыска гына әйбәт шигырьләре, тәнкыйтьче чыгышларында телгә дә алынмый. Шул ук вакытта берәр прозаик нинди дә булса отышлы көндәлек темага повесть язса, әсәре бик үк уңышлы булмаган хәлдә дә, телгә кереп тәнкыйть әйләнешендә йөри башлый. Ә бит һәр шигырь юлы шагыйрьдән зур эмоциональ киеренкелек сорый, җан байлыгын, зур рухи көч салуны таләп итә! Шагыйрьләребез матбугатта, бигрәк тә «Казан утлары» журналында җитди шигырь цикллары белән еш кына чыгып торалар. Аларның кайберләре чыннан да әдәби вакыйга булырлык. Ләкин соңгы елларда мин теге яки бу яңа поэма яки шигырьләр циклы уңае белән дискуссия-бәхәсләр кабынганын яки янып сөйләүчеләрне хәтерләмим. Ә кайбер очракта югыйсә шагыйрьнең үзе өчен дә, укучыга да файдасы булырлык итеп, аерым бер цикл, хәтта аерым бер чын шигырь турында да фикер алышу комачауламас иде. Ихтимал, бераз арттырып җибәрә

диярләр, шулай да әйтергә батырчылык итәм: минемчә, әдәбиятның үсү дәрәҗәсен шагыйрьлек дәрәҗәсе билгели. Чөнки чын шагыйрь, кагыйдә буларак, башка жанрлар өлкәсендә дә уңышлы эшләп, әдәбиятка зур игелек күрсәтүчән. Моңа мисаллар күп. Шагыйрьдә зур потенциаль мөмкинлекләр яшеренгән. Шигърият — яшьлек һәм, димәк, кодрәт, көч символы да.

Ләкин шуңа карамастан безнең чорда, алда әйтелгән сәбәпләр аркасындамы (ихтимал, бүтән сәбәпләр дә бардыр), шагыйрьнең абруе, гомумән алганда, беркадәр төште дип уйлыйм мин. «Шагыйрь» дигән сүзнең мәгънәсе элекке классик югарылыгында тормый шикелле. Монда гаепнең бер өлешен шагыйрьләр үзләренә дә алырга тиеш. Без хәзер халык белән бик еш очрашабыз һәм һәр очракта да үзебез турында иң яхшы тәэсирләр калдырабыз дип әйтмәс идем. Шагыйрь исемен йөрткән кеше кайчак укучы яки тыңлаучы күз алдында көтелгән яки хыялда йөртелгән шагыйрь образыннан калыша, һәрхәлдә, безгә, кемнең кем булуына карамастан, укучының әдәбиятка һәм язучыга булган олы ихтирам хисен кадерләп сакларга кирәк, һәм бу урында үзебезнең тагын бер йомшак ягыбызны икърар итеп китәргә тиешбез. Булырдай дигән талантлы шагыйрьләребез дә еш кына үз эшләрендә тиешенчә оперативлык күрсәтеп җиткермиләр, бүгенге тормыш симфониясен, пульс тибешен тоеп әсәрләрендә чагылдыруда кирәк дәрәҗәдә өлгер түгелләр. Мисал өчен, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, шулай ук Казан шәһәре кебек республиканың индустриаль үзәкләрендә хәзер яңа тип яшь кеше формалаша. Аларның хезмәтләре, хыял һәм омтылышлары бүгенге поэзиябездә лаеклы чагылышын табып җиткерми әле.

Бүгенге татар поэзиясен тулаем алып караганда, мин аны интенсив үсештә, дип әйтер идем. Аның бүген югары таләпләрдән торып сөйләшерлек зур шигъри хәзинәсе бар. Шигъриятебез җәүһәрләрен тиешле биеклектә һәм яктылыкта күрсәтә белгәндә, алар — теләсә кайсы милләт укучылары алдында да йөз кызартырлык түгел. Бүгенге шигъриятебез төрле талантларга, төрле төсләргә, төрле авазларга бай. Менә бүгенге татар шигъриятендә актив һәм фидакяр эшләүче кайбер исемнәр: С. Хәким, Х. Туфан, Н. Арсланов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, М. Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, С. Сөләйманова, Р. Харисов, Р. Мингалимов, Зөлфәт, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, З. Насыйбуллин, К. Сибгатуллин һ.б. Эш — булган рухи поэтик байлыкны күпмилләтле социалистик культураның бер өлеше булырлык итеп Союз

һәм дөнья күләменә чыгара, күрсәтә белүдә. Бу яктан безнең эшләр артык мактанырлык түгел. Рус һәм башка телләрдә хәзинәдә булганның гел иң яхшылары гына чыга дип әйтеп булмый. Татарстан Язучылар берлегенең яңа идарәсенә бу юнәлештә күп эшләр башкарырга кирәк булачак.

Сүземне шагыйрьнең тормышта тоткан урыны турындагы фикердән башлаган идем. Ялгышмас өчен тарихка, халыкка, аның бәя бирү принцибына мөрәҗәгать итәсең. Ә халык ялгышмый, шәхесләргә һәм аларның кылган хезмәтләренә бәяне дөрес бирә. Кирәген җыр итеп йөртә, һәйкәл сала, кирәкмәсен — оныта. Чит җирләрдә, чит шәһәрләрдә йөргәндә, урамнарын урап әйләнгәндә, кайчак, көтмәгәндә, бөек шагыйрьләрнең һәйкәлләре янына килеп чыгасың. Ирексездән алар язмышы турында уйланасың. Бездә дә бар андый һәйкәлләр, ул — Тукай, Җәлил һәйкәлләре. Эштән бушаган араларда яки ял иткән чакларда, ул һәйкәлләр янына килеп, алар язмышы һәм ил язмышы турында бераз гына булса да уйланып тору һәркем өчен дә файдалы һәм гыйбрәтле дип уйлыйм.

*1974, май*

# СЪЕЗДДАН СОҢ...

Мәгълүм булганча, Татарстан Язучылар берлеге Россия Федерациясендә иң зур иҗат оешмаларының берсе. Бүгенге көндә аның сафларында 145 СССР Язучылар берлеге әгъзасы бар. Яшь һәм башлап язучыларның исәбе берничә йөзгә җитә. Зур корабка — олы диңгез, дигән сыман, зур оешмага, тиешле иҗади мөмкинлекләр тудырылу белән бергә, табигый ки, зур таләпләр куелган, зур җаваплылык та йөкләнгән.

«Совет әдәбиятының иң яхшы традицияләренә турылыклы калган хәлдә, татар язучылары алга таба да заманның актуаль мәсьәләләрен күтәргән яңа сәнгать әсәрләре язарлар, үз әсәрләрендә бүгенге көн кешеләренең масштаблы һәм тулы канлы образларын иҗат итәрләр». Әдәбиятыбызның киләчәгенә зур ышаныч баглаган бу сүзләр Татарстан язучыларының былтыр май аенда булып узган VIII съезды резолюциясендә әйтелгән иде. Язучыларыбызның идея-политик бердәмлеген һәм иҗат принципларының какшамаслыгын демонстрацияләгән бу съездның үткәненә дә инде шактый вакыт узды.

Съездда сайланган яңа идарә шушы вакыт эчендә байтак кына иҗади һәм практик эш башкарды. Әдәби хәрәкәтнең мөһим участокларына җаваплы итеп беркетелгән идарә членнарының күбесе үзләренең вазифаларын эшлекле рәвештә үтәүгә керештеләр. Безнеңчә, җәй, көз айларында үткәрелгән оештыру чараларының байтагы язучыларның иҗади активлыгын күтәрүгә уңай йогынты ясады. Мин моны «Казан утлары» журналында басылган яңа әсәрләрне тикшерү, язучыларның сәнгать эшлекләләре белән бергә КамАЗга барулары, бүгенге әдәбиятта җитәкче образы турында сөйләшү, районнарда әдәби атналыклар оештыру, аерым язучыларның иҗат отчетын тыңлау һәм башка чараларны күздә тотып әйтәм.

Язучылар коллективы башкарган кайбер эшләрне санарда да күрергә мөмкин. Соңгы айларда ике иптәш (Х. Хәйруллин, Г. Хәсәнов) СССР Язучылар берлегенә кабул ителде. Ярты ел эчендә Татарстан китап нәшрияты язучыларыбызның 70кә якын исемдә китапларын бастырып чыгарды. Шушы вакыт эчендә Мәскәү нәшриятларында татар язучыларының 11 китабы дөнья күрде. Алар арасында классиклардан Г. Тукай, М. Җәлил, бүгенге язучылардан Ә. Еники, Ш. Галиев, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, З. Нури, Ш. Бикчурин, Р. Мостафин, Р.Фәйзуллин һ.б. бар.



*Язучыларның Тукай клубында (Бауман урамы, 19 нчы йорт) татар зыялыларының күтеп алынган җыелышы — әдәби ел йомгаклары уздырыла иде. 70 нче еллар*

Татарстан Язучылар союзы органы булган «Казан утлары» журналының быелгы 6—12 саннарында бер роман («Ургыл» — Х. Хәйруллин), бер пьеса («Мәхәббәтең чын булса» — Х. Вахит), дүрт повесть («Алтын эзләүчеләр» — Ф. Хөсни; «Тозлы җил» — М. Юныс; «Язгы кәрваннар» — А. Гыйләҗев, «Тау ягы повесте» — Ә. Баянов), Х. Туфан, Н. Арсланов, Ә. Давыдов, Ш. Галиев, Г. Рәхим, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Харис, Г. Афзал, Ф. Яруллин, Р. Мингалимов һ.б. шагыйрьләрнең шигырь цикллары дөнья күрде. Шуларга өстәп, әдәби тәнкыйть, әдәбият теориясе һәм әдәбият тарихы буенча язылган мәкаләләрне, очеркларны күрсәтергә кирәк, һәммәсен бергә туплап исәпләсәң, байтакка җыела. Бу яңа әсәрләрнең кайберләре язучыларның гомуми һәм секция җыелышларында, көндәлек матбугат битләрендә билгеле бер бәя алдылар да инде, кайберләре турында, күрәсең, сүз соңрак булыр. Әмма, шикләнмичә, хәзер үк шуны әйтергә була: яңа чыккан әсәрләр әдәбиятыбызның эчтәлек ягыннан һаман үсә, тирәнәя, формаларга байый баруын күрсәтә.

Үзәк һәм җирле нәшриятлардан тыш, үзәк газеталарда һәм әдәби журналларда безнең язучыларыбызның беркадәр әсәрләре дөнья күрде. Бу урында үзәк матбугатта үзләренең публицистик чыгышлары һәм мәкаләләре белән катнашкан

С. Хәким, Ф. Урманчеев, Ф. Мусин, Р. Бикмөхәммәтов, М. Зарипов иптәшләрнең исемнәрен атап үтәсе килә. Шулай да, съездда хаклы рәвештә билгеләп үтелгәнчә, Бөтенсоюз әдәби хәрәкәтендә һаман да тиешле дәрәҗәдә актив катнашмавыбызны танырга тиешбез. Бу өлкәдә эш һәммәбезгә дә җитәрлек.

Идарә эшчәнлеге күпьяклы. Төп эшләребезнең берсе — язучыларга мөмкин кадәр яхшырак иҗат шартлары тудыру, яңа әсәрләр язуда булышлык күрсәтү. Шул максат белән ярты ел эчендә 73 язучы үз республикабызда һәм илнең төрле почмакларында иҗат командировкаларында булдылар. Тормышны өйрәнеп, «Казан утлары» өчен проблемалы очерклар һәм махсус тикшерүне сорый торган публицистик әсәрләр язу өчен дә байтак иптәшләргә авыл хуҗалыгы районнарында, промышленность предприятиеләрендә, эшчеләр коллективларында булып иҗат итү мөмкинлекләре тудырылды.

Халык купса, тау күчерер, ди мәкаль. Оешманың, коллективның көче — аның бердәмлегендә. Шигырь яки хикәя язу, гомумән, иҗат эше индивидуаль булса да, иҗат җимеше нәтиҗәсе күмәккә — халыкка килеп тоташа. Кайсы гына язучы үз әсәрен киң катлау укучыларның яратып укуын теләми икән! Һәр зур язучының, кагыйдә буларак, гомумҗәмәгать эшенең чын активисты булуын һәрберебез белә. Шуңа күрә дә идарә үз эшенә язучыларның бөтен контингентын тартырга тырыша һәм көндәлек җәмәгать һәм иҗат эшләрендә аларга таяна да. Шул максат белән Язучылар берлеге идарәсе каршында тагын ике яңа комиссия төзелде. Берсе — татар язучыларының әсәрләрен рус һәм тугандаш халыклар телендә чыгару буенча булышлык комиссиясе (рәисе — Г. Кашшаф); икенчесе — яшь һәм башлап язучылар белән эшләү комиссиясе (рәисе — Ш. Галиев). Язучылар берлеге идарәсе болай да күз уңында торкан бу ике зур мәсьәләгә әлеге комиссияләрнең дә кушылуы гомум уртак эшне яхшырта төшәр дип уйлыйбыз. Ә бу эшләрне яхшырту исә зарури ихтыяҗга әверелгән. Сүзне әлеге мәсьәләләрнең беренчесеннән башлап китик. Дөрес, әйтергә кирәк, татар әдәбиятының җәүһәрләре белән рус һәм башка тугандаш халыкларның укучыларын таныштыру һич тә канәгатьләнерлек түгел. Инде бүтән милләтләрнең дә уртак хәзинәсе булырлык байтак әсәрләр бүгенге көнгә кадәр рус теленә тиешенчә тәрҗемә ителмәгән. Борынгы әдәбият вәкилләреннән Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Кандалый, соңгы чордан — Һ. Такташ, Ф. Кәрим, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Ш. Маннур исемнәре әле хәзергә кадәр бөтенсоюз укучысына бик аз билгеле яки

бөтенләй диярлек билгеле түгел. Әдәби мирасны ныклы бер тәртиптә системалы рәвештә чыгарып бару бүген генә кузгатылган мәсьәлә түгел, әлбәттә. Моннан нәкъ 10 ел элек тә шушы юнәлештә галимнәр һәм язучылар составында бер комиссия төзелгән иде. Ләкин бу комиссиянең гамәлгә ашкан хезмәте авыз тутырып әйтерлек була алмады. Идарә әгъзаларыннан, нәшрият хезмәткәрләреннән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәреннән төзелгән яңа комиссиянең эш методлары эффектлырак, хезмәте нәтиҗәлерәк булырга тиештер. Хәзер бу комиссия, һәрьяктан җентекләп тикшереп, алдагы 5 елда рус теленә тәрҗемә итү өчен әсәрләр исемлеген төзеде. Идарә бу комиссиянең тәкъдимнәрен тормышка ашыру юнәлешендә конкрет эш алып барачак.

Яшьләр комиссиясенең дә эше гаять җаваплы һәм күптармаклы. Идарә белән берлектә, бу комиссия яшь һәм башлап язучы авторлар белән эшләүнең эффектлы формаларын эзли, әдәби талантларны үстерү юнәлешендә яңа чаралар билгели. Яшь авторларга төрле характердагы конкрет иҗади ярдәм күрсәткәндә, аларның беренче басма китапларын чыгарганда, Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим иткәндә һәм шулай ук башка бик күп очракларда әлеге комиссия үзенең абруйлы фикерен әйтергә тиеш булачак. Гомумән, яңа әдәби алмаш тәрбияләү эше бездә начар тормый. Иҗат берлекләренең шушы мәсьәләгә багышланган берләштерелгән пленумы (октябрь, 1973), Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган әдәби берләшмәләр һәм түгәрәк җитәкчеләренең ике көнлек семинары (апрель, 1974), яшь иҗат көчләренең Идел буенда урнашкан «Волга» халыкара яшьләр лагеренда узган республика семинары (июнь, 1974) һәм башка чаралар яшь язучыларны тәрбияләү эшендә, һичшиксез, зур роль уйнадылар. Бүгенге көндә республикада яшь һәм башлап язучыларның 25 әдәби берләшмәсе эшли. Аларның бишесе Казанда, калганнары республиканың бүтән шәһәрләрендә һәм районнарында. Аларның беришләре яхшы ук эшләсәләр дә, кайберләре, бигрәк тә район үзәкләрендәгеләре сүлпән эшли. Моның бер сәбәбе шунда — урыннарда тәҗрибәле җитәкче-язучылар юк. Шуңа күрә дә идарә барлык әдәби берләшмәләргә дә иҗади авторитеты зур булган язучыларны беркетергә карар итте. Шефлык итү йөзеннән өлкән әдипләр, язучылар берлеге штатындагы әдәби консультантлар белән берлектә, бу берләшмәләргә даими барып торсалар, яшьләрнең иҗатларын анализласалар һәм оештыру эшендә киңәшләр биреп торсалар, эш, шөбһәсез, алга китәр. Яшьләр

альманахы «Идел»дә Казаннан читтә яшәүче авторларга игътибарны арттырырга, гомумән, редколлегия членнары белән эшлекле мөнәсәбәттә булып, үз эшен бермә-бер яхшыртырга тиеш. Быелның март аенда Мәскәүдә яшь язучыларның чираттагы Бөтенсоюз киңәшмәсе үткәрелә. Яшь әдәби алмашның бу зур бәйгесендә безнең яшь язучыларыбыз идея-эчтәлеге һәм әдәби эшләнеше ягыннан югары сыйфатлы әсәрләр белән катнашырлар дип уйлыйбыз.

Язучылар берлеге каршындагы секцияләр — авторлар белән иҗади эш алып баруның төп формаларыннан берсе. Бездә 8 секция эшләп килә. Иҗат секцияләре һәр буын язучы өчен профессиональ осталыкны күтәрү, чыныгу мәктәбе булып тора. Татар әдәбиятының уңышы саналган әсәрләрнең күпчелеге үз вакытында иң әүвәл секцияләрдә каләмдәшләренең гадел хөкеме аша үтеп чарланган, тиешле бәя алган.

Быел яз барлык секцияләрдә отчет-сайлау җыелышлары үтеп, аларның яңа бюро составлары һәм җитәкчеләре сайланды. Съездан соң барлык секцияләр дә яңа бер күтәренкелек белән эшли башладылар. Секция бюроларына таләпчәнлек арту белән бергә, аларның иҗади мөмкинлекләре арттырылды, хокуклары киңәйтелде. Хәзер теге яки бу иҗади һәм практик мәсьәләләрне хәл иткәндә секция бюролары — төп сүзне әйтүчеләр. Яшәешнең һәр өлкәсендәге шикелле, иҗат эшендә дә тормыш безнең алга көн саен иң актуаль, кичектермичә хәл ителергә тиешле проблемаларны китереп куя. Шунысы куанычлы: иҗат секцияләре андый проблемаларны хәл итүгә кыю алыналар. Бу — көндәлек реаль тормыш ихтыяҗлары белән яшәү дигән сүз. Мәсәлән, октябрь аенда шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр секцияләренең берләштерелгән утырышы булып, сүз соңгы 4—5 ел эчендә рус һәм башка тугандаш халыклар теленнән тәрҗемә ителгән шигъри әсәрләр турында барды. Күренекле шагыйрьләр, тәҗрибәле тәрҗемәчеләр һәм нәшрият редакторлары катнашкан бу җыелышта шигырь тәрҗемәсе өлкәсендә кайбер уңышлар белән беррәттән, җитди кимчелекләр булуы да ачыкланды. Гаҗәп хәл: бүгенге татар шигърияте, гомумән югары, аның заман таләпләрен канәгатьләндерерлек көчләре бар, ә менә татар теленә тәрҗемә ителгән шигъри әсәрләрнең күбесенең сыйфаты начар. Конкрет әсәрләр җирлегендә узган сөйләшүнең нәтиҗәләрен секция бюросы нәшрият җитәкчеләренә җиткерде. Яки тагын бер мисал: шагыйрьләр секциясе үзенең киләчәктәге бер утырышында радиокомитет һәм филармония вәкилләре белән берлектә җырлар турында фикер алы-

шу оештырачак. Уебызча, шагыйрьләр, композиторлар катнашачак бу сөйләшү китап, газета-журнал битләрендә еш кына басылып килә, эфирда да әледән-әле яңгырап торган зәвыксыз җырларның беркадәр кимүенә китерергә тиеш. Яки тәрҗемәчеләр секциясен алыйк: соңгы вакытта бу секция теоретик мәсьәләләр белән беррәттән, М. Горький исемендәге әдәбият институтының тәрҗемә бүлегендә укучы татар студентлары белән элемтәне ныгыта төште. Тәнкыйтьчеләр секциясе исә КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарның өчьеллыгы алдыннан эшен аеруча җанландырып җибәрде. Бу юнәлештә соңгы еллардагы хезмәтләргә йомгак ясады, киләчәккә планнар билгеләде. Алдагы елларда секция бюросы, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр белән берлектә «Документаль әдәбият һәм аның бүгенге хәле», «Фән-техника революциясе һәм бүгенге әдәби хәрәкәт» кебек теоретик мәсьәләләр турында зур сөйләшүләр уздырырга җыена. Балалар әдәбияты, проза, драматургия, рус язучылары секцияләренең эшләре турында да уңай фикерләр әйтергә мөмкин. Гомумән алганда, секцияләр — Язучылар берлегенең төп эшен билгели торган иҗади учаклар. Аларда әдәби хәрәкәтнең иң кирәк һәм актуаль мәсьәләләре күтәрелә. Безнеңчә, тәнкыйть секциясе члennaры, үзләренең гыйльми тикшеренүләре профиленә һәм иҗат интересларына карап, бүтән секция утырышларында даими катнашырга тиеш. Иҗатчыларның үзләре белән нык аралашканда, аларның яңа әсәрләрен белгәндә, фикерләрен ишеткәндә генә һәр жанрның яңа үсеш этабын тоярга, белергә була. Шул очракта гына тәнкыйть әдәби процесста әйдәүче көч була ала.

Ихтимал, «Казан утлары» журналында «Иҗат секцияләрендә» дигән даими рубрика биреп бару кирәктер, юкса хроникада сирәк-мирәк бирелеп бара торган штамп-информация укучыда әллә ни фикер уятырлык яңалык китерми. Шулай ук моннан берничә ел элек журнал каршында оештырылган яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге дә соңгы вакытта эшен йомшарта төште. Идарә һәм журнал редколлегиясе яшь тәнкыйтьчеләр үстерү мәсьәләсенә игътибарын арттыра төшәргә тиешләр.

Татарстанның көньяк-көнчыгыш өлешендә сугыштан соң үсеп чыккан индустриаль төбәктәге хезмәткә бай тормышны әдәбиятта чагылдыру һәм шул яктагы яшь талантларны үстерү нияте белән оештырылган Әлмәт бүлеге үзенең 10 елдан артык яшәү дәверендә байтак игелекле эшләр башкарды. Дөньяга чыккан китапларның саны да байтак. Ләкин

соңгы елларда бүлекнең эшчәнлеге йомшара төште. Өлкән буын язучыларының кайберләре ирешелгән биеклекләр белән тынычланып калдылар, ә яшьләр, чын мәгънәсендә яшь дигәннәре, әдәбиятка бик аз килә. Яшьләр исемлегендә инде олыгаеп бара торган кайбер иптәшләрне исәпләмәгәндә, яшь яңа исемнәр соңгы елларда күренми диярлек. Бу якта яшәүче профессиональ язучыларның иҗат эшчәнлеген күтәрү, яшь алмаш үстерү юнәлешендә бүлек бюросына инициативалы зуррак чаралар күрергә кирәк. Әлмәт язучылары Чаллы, Түбән Кама әдәби берләшмәләренә игътибарны көчәйтә төшеп, аларга даими ярдәм итеп торырга тиешләр.

Инде 10 елга якын Язучылар союзы каршында Пропаганда бюросы эшләп килә. Исеменнән үк аңлашылганча, Бюроның максаты матур әдәбиятның иң яхшы үрнәкләре ярдәмендә киң халык массаларына эстетик тәрбия бирү, яшь буында заманча фәнни караш формалаштыру, хезмәт ияләрендә матурлык тойгысы тәрбияләү, кешеләрнең гармоник үсешен тәэмин итүдә булышу. Бу мактаулы һәм авыр бурычларны үтәү өчен бездә хәзер шартлар бар. Әдәбиятны пропагандалауның мөмкинлекләре зур, формалары күптөрле. Әдәби атналыклар, тематик чыгышлар, диспут-әңгәмәләр, аерым язучылар иҗаты буенча лекцияләр, укучылар конференцияләре, документаль әсәрләрнең геройлары белән очрашулар әдәбият үсешенең аерым этаплары турында теоретик докладлар, әдәби-музыкаль кичәләр, китап көннәре, нәшриятларның тематик планнары буенча фикер алышулар һ.б. Моңарчы Пропаганда бюросы җиңелрәк, бертөрле юл беләнрәк эш итеп килде. Практик эш берничә язучы һәм артисттан филармония бригадасы сыман группа оештырып авылларга чыгарып җибәрүгә генә кайтып калмаска тиеш. Хәзер Пропаганда бюросының составы яңартылды һәм идарә анда эшләүче иптәшләрдән үз эшләренә җитдирәк, җаваплырак карауларын таләп итә.

Әдәбиятны пропагандалау мәсьәләсе уңае белән тагын шуны да әйтәсе килә: халык арасында әдәбиятка булган ихтыяҗны өйрәнү, яхшы китапны, яхшы әсәрне вакытында укучыга җиткерү — бу эштә иң мөһим моментларның берсе. Республикада махсус китап сату оешмалары (Таткниготорг, Татпотребсоюзда китап сату бүлеге) бар, күптән түгел китап сөючеләр җәмгыяте оешты, Татарстан китап нәшриятында пропаганда буенча махсус редактор штаты исәпләнә. Безнеңчә, яңа китапларны пропагандалау, халыкка җиткерү эшендә бу оешмалар үзара киңәшеп, бер-берсенә ярдәм итешеп, күмәкләп эшләргә тиешләр. Шулай ук безнең Пропаганда

бюросына филармониянең лекторий бүлеге һәм язучыларның Г. Тукай исемендәге клуб советы белән дә ныклы элемтә урнаштырырга вакыт.

Табигый, хәл итәсе нәрсәләр күп, чөнки һәр яңа көн яңа шатлыклар, яңа мәшәкатьләр алып килә; биеккә менгән саен, офыклар киңәя, күзнең үткенрәк күрүе кирәк була; сәнгать камиллегенә якынайган саен, үз-үзеңә булган таләпчәнлек тә арткannan-арта бара. Бүгенге көндә Татарстан Язучылары берлеге — үз алдында торган катлаулы бурычларны үтәрлек, халык ышанычын акларлык сәләтле оешма. Аның составында талантлы язучылар күп, алар арасында иҗат һәм җәмәгать эшләрендә активлыклары белән абруй казанып, югары совет органнарына халык вәкилләре булып сайланган иптәшләр бар, СССР һәм РСФСР язучылары идарәләрендә вәкилләребез бар. Бөтенсоюз журналларының кайберләрендә редколлегия һәм редсовет составында кешеләребез бар. Язучылар оешмасы алдында торган зуррак проблемаларны уңай хәл итү аларның эшчәнлегенә дә нык бәйләнгән.

Тиздән язучыларның әдәби ел йомгагы дип йөртелә торган традицион җыелышы үтәчәк. Бу зур җыелышта 1974 елда кылган эшләр, язылган әсәрләр турында язучылар тагын бер кат дустанә шартларда, принципиаль рәвештә иҗади фикер алышырлар, әдәбиятыбызны тагын да үстерү юлында конкрет чаралар билгеләрләр.

*1975, май*

## ТАРИХИ МИРАС АША — КИЛӘЧӘККӘ

Сыйфат бишьеллыгының игелекле бер ае инде үтеп тә китте. Конвейерлардан яңа машиналар төшә, торбалардан яңа суырылган нефть ага, яңа тукымалар тукылып, яңа киемнәр тегелә, яңа космонавтлар күкләрне айкый... Киштәләргә яңа китаплар килә. Быелның беренче нәтиҗәләре, беренче күрсәткеч саннары...

Мәгълүм булганча, СССРда ел саен 9 меңгә якын исемдә 700 миллион данәдән артык матур әдәбият китабы басыла. Быелгы яңа китапларның бер өлеше укучылар кулына иреште дә инде. Китап сөючеләр, бездә — татар телендә чыккан китаплардан тыш, быел Татарстан язучыларының үзәк нәшриятларда чыккан нинди әсәрләре белән таныша алачаклар соң?

Шул ният белән нәшриятлар чыгарган аңлатмалы брошюра-китаплар, икенче төрле әйткәндә, тематик планнар белән танышып, аларның матур әдәбиятка кагылышлыларын өйрәнеп чыктык. Автор һәм китап исемнәреннән, аннотация һәм саннардан гына торган бу китаплар укыр өчен бертөрлерәк булса да, уйланыр, чагыштырыр өчен бик гыйбрәтле алар. Күңел тутырырлык сөенечле тойгылар белән бергә, кайбер уйлануларга да китерде ул темплан китаплары.

Без татар әдәбиятының киңрәк аренага чыгуын күрәсебез килү турында шактый күп сөйлибез, сөйләү генә түгел, бу юнәлештә беркадәр уңышларга да ирешеп киләбез. Илләр, халыклар үзара нык аралашкан чорда үз кабыгында, үз согында гына кайнау хәерле түгел икәнлеге хәзер инде һәммәбезгә мәгълүм хакыйкать. Кем әйтмешли, заман — космик кораблар һәм тәрҗемәләр заманы. Безнең шартларда киңрәк даирәгә чыгуның бер зур юлы — татар авторларының яхшы әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп бастыру, шул юл белән рус теле аша бүтән милләт укучыларына да юл яру. Бу юнәлештә безнең язучылар соңгы елларда шактый активлык күрсәтә башладылар. Әлбәттә, кылган эшең, кулга алырлык хезмәтең булмаса, коры теләк белән генә әллә ни ерак бара алмас идең. Күп гасырлык татар әдәбиятының мирас хәзинәсе олы, бүгенгесе нык, киләчәктәге потенциалы зур. Хикмәт — шунда. Үткән ел үзәк нәшриятларда безнең язучыларның 13 китабы басылды. Шуларның Ә. Фәйзидән калганнары, бөтенесе исән авторларның әсәрләре. 7 прозаик, 5 шагыйрь, 1 драматург. Классик мираска бәйләнешле монографик пландагы ике әсәр: И. Нуруллинның һәм Ә. Фәйзинең «Тукай»лары, Р. Мостафинның балалар өчен чыгарылган «Муса Җәлил»е.

Инде быелгы — 1978 ел хәлләренә килик. Быел, тематик планнардагы мәгълүматларга караганда, Мәскәү нәшриятларында 18 авторның китаплары чыгу планлаштырылган. Тукайның «Советская Россия» нәшриятында чыгарылачак бәләкәй күләмдәге «Су анасы»н исәпләмәгәндә, бөтенесе исән авторларның әсәрләре. 10 проза әсәре (Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, Ә. Баянов, Г. Паушкин, Ш. Бикчурин, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Ю. Белостоцкий, Р. Кутуй), 7 поэзия әсәре (Г. Тукай, Р. Мингалимов, С. Сөләйманова, И. Кәлимуллин, К. Сибгатуллин, М. Фәйзуллина, Р. Фәйзуллин), 1 монография — Р. Мостафинның «Сибгат Хәкимнең иҗат портреты». Чагыштырмача аз түгел бу. Табак исәбе ягыннан — 189 табак. Гомуми тираж — 845 мең. Күләм ягыннан бу саннар безнең нәшрият чыгарган нәфис әдәбиятның байтак өлешен тәшкил итә. Тираж ягыннан кайбер язучыларыбызның әсәрләре чыннан да ифрат зур саннар белән билгеләнә. Мәсәлән, Г. Әпсәләмов әсәрләренең гомуми тиражы 5 млн. чамасы. Г. Бәшировның соңгы 10 елда басылган әсәрләренең тиражы гына да 1 млн. 180 мең. Димәк, күләм, сан яклары яхшы, сыйфат турында ныграк уйлыйсы гына кала.

Тематик планнарны актарганда тагын шуңарга да игътибар итәсең. Чыккан һәм чыгачак китапларның күбесе «Современник» нәшриятына төшә. Үткән ел анда 6 китап чыккан булса, быел бу нәшриятта безнең 13 авторның китабы дөнья күрәчәк. Бу табигый дә. «Современник» — РСФСР дәүләте нәшрияты. Ә безнең Язучылар оешмасы — Россия Федерациясендә иң эреләрнең берсе.

Соңгы елларда шулай ук «Советский писатель» һәм «Советская Россия» (соңгысында быел безнең авторларның 4 китабы чыга) нәшриятлары белән дә эшлекле мөнәсәбәтләр урнашып килә. Ләкин кайбер, әйтик, «Художественная литература», «Молодая гвардия», «Малыш» кебек нәшриятлар белән безнең язучыларның бәйләнешен җитәрлек дип булмый әле. Димәк, бу юнәлештә алга таба нәтиҗәлерәк эшләү кирәк.

Тематик планнар белән танышканда иң әүвәл күңелгә килә торган нәрсәләрнең берсе шул: классикларыбызның әсәрләре азрак чыга түгелме соң? Чыннан да шулай бу: Җәлилне исәпләмәгәндә, байтак классик әдипләребезне тәрҗемә итеп бүтән халыкларга тиешле югарылыкта күрсәтә алганыбыз юк. Моның, әлбәттә, җитди сәбәпләре дә бар. Иң зур сәбәпләрнең берсе шул: нәшриятларга кем әзерләп бирергә тиеш аларны? Кайсы оешма? Һәм конкрет кемнәр? Язучылар союзымы? Тел, әдәбият, тарих институтымы? Әллә бүтән берәр дәүләт оешмасымы? Төгәл җавап бирү кыен.



*Татарстан Язучыларының VI съезды (1963). Алгы планда — Ә. Еники, Г. Галиев, Э. Касыймов*

Дөресен әйткәндә, үзәк нәшриятларда чыга торган китапларның бөтенесе диярлек Язучылар берлеге идарәсенең һәм аның аерым җитәкчеләренең даими кайгыртучанлыгы аркасында дөньяга чыгып киләләр. Бүгенге исән язучыларныкы да, шулай ук кайбер классик әдипләребезнеке дә. Штатында 4—5 кеше эшләгән иҗат оешмасы өчен югарыда әйтелгән китапларны әзерләп чыгару үзе инде милли культурабыз өчен гаять зур өлеш. Ә шулай да бүтән халыкларга да гыйбрәтле булырлык, күпмилләтле уртак культура хәзинәбезне баетырлык әсәрләрне мулрак чыгарырга тиештер бит без. Күрәсең, бу — республиканың югары органнары, иҗат оешмалары һәм фән учреждениеләре белән бергәләп хәл итәргә тиеш мәсьәлә. Ихтимал, иң башта классик әдипләребез әсәрләренең фәнни таләпләргә җавап бирерлек сүзгә-сүз тәрҗемәләрен эшләтергә һәм аларны күпләтү чарасын күрергәдер. Татарстан китап нәшрияты яки Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты каршында шушы эш белән шөгыльләнерлек махсус редакция яки штатлар булдырыргадыр? Кыскасы, безнеңчә, бу өлгергән, заман тарафыннан куелган һәм хәл ителергә тиешле җитди мәсьәлә. Юкса, әйтик, Г. Ибраһимов кебек зур әдипләрнең олы юбилейларын үткәргәндә, рус телендә 3—4 томлык сайланмаларын булдырырга тиеш идек бит! Яисә Бөтендөнья әдәбияты сериясендә чыккан 200 томлыкта, СССР халыклары әдәбияты өлешендә, коллектив антология өлешендә генә булса да, без-

нең Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал кебек язучылар урын алырга тиешләр иде ләбаса. Бүтән абруйлы басмаларда да безнең язучылар тиешле дәрәҗәдә чыгалар дип әйтеп булмый.

Әлбәттә, әдәби җәүһәрләрне мөмкин кадәр киңрәк даирәгә чыгару бүген генә көн тәртибенә куела торган нәрсә түгел. Бу юнәлештә 50—60 ел эчендә байтак эш башкарылган. 25—30 нчы елларда, Г. Ибраһимов исән вакытта, беркадәр әсәрләр рус телендә дөнья күргән. Шулай ук 50 нче елларда «Намус» һәм «Язгы җилләр» романнарына Дәүләт премияләре бирү уңае белән татар әдәбияты дөнья аренасында шактый ук матур күренеп алды.

Татарстан китап палатасы мәгълүматларына караганда, соңгы 5 елда рус һәм башка телләрдә чыккан татар әдипләренең хезмәтләре мондый саннарда чагыла: 150 исемдәге китап, гомуми тираж — 12 миллионга якын. Шуларның 70 исемдәгесе Мәскәү нәшриятларында чыккан. Әйе, эшләгән кадәресен танырга, булган уңай тәҗрибәне тулырак файдаланырга кирәк. 1962 елда тәрҗемәчеләрнең Казанда үткәрелгән Бөтенроссия күләмендәге киңәшмәсе өлкән һәм урта буын язучыларының яхшы хәтерендәдер. Л. Соболев, С. Липкин, Я. Козловский кебек зур тәрҗемәчеләр катнашкан бу киңәшмәдә бүген дә гаять актуаль булган байтак җитди мәсьәләләр күтәрелгән иде. Шушы киңәшмәнең бер нәтиҗәсе булып докладларны һәм чыгышларны бергә туплаган «Танышлыктан — туганлыкка» («От знакомства к родству») дигән китап та чыккан иде. Шушы киңәшмәдән соң бездә бу юнәлештә шактый җанлану булып алды. Тәрҗемә эшен юлга салу һәм классик әдәбиятны чыгаруны билгеле бер үзәккә туплау нияте белән галимнәр, язучылар, нәшрият вәкилләреннән республика комиссиясе дә төзелгән иде. Ул комиссия классик әдәбиятны татар һәм рус телләрендә чыгару буенча перспектив планнар да әзерләгән иде. Планнар үз вакытында шактый өметле ышанычлар уяткан булса да, кызганычка каршы, аларның зур өлеше кәгазьдә вакыт истәлеге генә булып калды. Шулай булса да 60 нчы еллар башында бу юнәлештә билгеле бер уңай хәрәкәт булып алды.

Шуннан соң 20 еллап вакыт үтте. Байтак сулар акты. Китаплар чыгып торды, аларның саннары ишәя төште... Шуңа да карамастан тәрҗемә мәсьәләләре һаман актуальләшә генә бара. Бу эштә билгеле бер эзлекле рәвештә өлеш кертү нияте белән моннан берничә ел элек Татарстан Язучылар берлеге идарәсе каршында нәшрият эшләре комиссиясе төзелгән иде. Җәмәгать тәртибендәге бу комиссия шушы ва-

кыт эчендә беркадәр эш башкара алды. Эш — бүгенге язучыларыбызның әсәрләрен Үзәк матбугатка әзерләргә булышу, тәкъдим исемлекләре төзү, чыккан һәм чыгачак әсәрләрне теркәү, һәрбер язучының библиографиясен булдыру юнәлешендә барды. Исән авторлар белән, әйтелгәнчә, эш канәгатьләнерлек диярлек була. Әмма әлеге дә баягы классиклар белән нишләргә соң?

Безнең комиссия классикларыбызның әсәрләрен чыгару буенча перспектив план төзеде. Татарстан китап нәшрияты өчен татар романнарының (үткәндәгедән бүгенгегә кадәргеләренең) исемлеге һәм библиографиясе эшләнде. Безнең исәпләүләр буенча, алдагы берничә ел эчендә рус телендә чыгарырга кирәк дип табылган классик әсәрләрнең күләме иң аз дигәндә 500 табактан артык… Кем чыгарырга тиеш тә аларны, кем басарга әзерләргә тиеш? Әйткәнемчә, бүгенге көнгә кадәр классик мирасны чыгару буенча бердәнбер инициатив үзәк булып һаман да Язучылар берлеге тора. Тәрҗемәче кадрларны әзерләү, туплау ягын да хәл кадәре кайгыртырга тырыша. Союз инициативасы буенча соңгы 20 ел эчендә ике мәртәбә Мәскәүнең Әдәбият институтында тәрҗемәчеләр группасы укып чыкты. Нәтиҗәләр көткәннән күпкә ким булса да, кайберләренең тәрҗемә эшендә игелекле хезмәтләре дә булмады түгел. Быел җәй башында Татарстан Язучылар берлеге РСФСР Язучылар берлеге идарәсе каршындагы тәрҗемәчеләр советы белән берлектә Казанда киңәшмә үткәрергә җыена. Бу чаралар куелган мәсьәләләрне кардиналь хәл итә алмасалар да, гомум уртак эшкә беркадәр җанлылык өстәр дип ышанабыз.

Әйе, 1978 елда Үзәк матбугатта нинди китаплар чыгуын белер өчен генә дип тематик планнар белән танышкан идек тә, ирексездән бүтән мәсьәләләргә дә, китапларыбызны чыгаруны пропагандалау мәсьәләләренә дә кагылдык.

Гомумән алганда, тематик планнар үзләре үк гыйбрәтле китаплар. Без әлегә аларны җитәрлек кадәр өйрәнеп, тиешле нәтиҗәләр ясый алганыбыз юк. Күп кенә укучылар аның әлегә нәрсә икәнен белеп җиткермиләр. Шуңа күрә дә китап сәүдәсенә бәйле оешмаларда, бигрәк тә авыл җирләрендә, тематик план белән тиешле дәрәҗәдә эшләп җиткермәү китапларга заказ биргәндә чагылыш таба, яхшы китап вакытында укучы кулына ирешми кала. Безнең язучылар, авылларда булсын, шәһәрләрдә булсын, укучылар белән әледән-әле очрашып торалар. Күп очракта алар барган җирләрендә китап сату эшенең куелышы белән канәгать булмауларын белдерәләр. Мондый хәлнең бер очы, һичшиксез, күпләрнең нәш-

риятлар тарафыннан яртышар ел алдан чыгарыла торган тематик планнар белән тиешенчә эш итә белмәүләренә килеп тоташа. Бу кимчелекне бетерүдә, республикабызда китап сату эшенә турыдан-туры идарә итә торган оешмалар белән берлектә, үзләренең функцияләре белән бу эшкә якын бүтән оешмалар — китап сөючеләр җәмгыяте, матур әдәбиятны пропагандалау бюросы һ.б. үзләреннән сизелерлек өлеш кертергә тиешләр.

Без бу чыгышыбызда үзәк нәшриятлар тәкъдим иткән тематик план хәлләре белән таныштырганга күрә, сүз рус телендә чыгачак китаплар һәм, гомумән, рус теленә тәрҗемә итү хакында булды. Үзебезнең китап нәшрияты асылда матур әдәбият әсәрләрен татар телендә чыгарганга күрә, бу юлы аңа махсус тукталмадык. Нәфис әдәбиятны чыгаруда, бүгенгесен булсын, үткән мирасны булсын, Татарстан китап нәшриятының эше аерым игътибарга лаек. Шулай ук, тәрҗемә эшенең икенче бер мөһим ягына — рус һәм башка телләрдән татар теленә тәрҗемәләү өлешенә дә кагылмадык. Кыскасы, бу юлы сүз үзебезнең мирасны һәм бүгенге байлыкны ни дәрәҗәдә, ни рәвешле дөньякүләм рәвештә күрсәтү, ягъни бүтәннәргә «бирү» турында барды, ә «алу» — бүтән халыкның әдәби җәүһәрләрен үз телебезгә күчерү эше — үзе бер зур проблема.

Әйе, бүгенге әдәби хәрәкәттә уйланырлык уйлар, эшлисе эшләр җитәрлек. Ахыр чиктә, Горький сүзләре белән әйткәндә, «һәр халыкның культура биеклеге аның нәшер иткән газета һәм китаплар саны белән билгеләнә» бит.

*1978, февраль*

# ЮЛЛАРДА ТУГАН УЙЛАР

Совет әдәбияты, мәгълүм булганча, җитмештән артык телдә иҗат ителә. Икенче төрле әйткәндә, илебез тарихы, бигрәк тә аның бүгенге көне җитмештән артык авазда, җитмештән артык аһәңдә, җитмештән артык бизәкләмәдә елъязма итеп тасвирлана. Безнең өчен шунысы да куанычлы: иҗатчыларның бу зур гаиләсендә татар язучылары да байтак, ирешелгән уртак казанышларда өлешләре аздан түгел. Ил буенча исәпләгәндә, бүгенге көндә татар телендә иҗат итүче ике йөзләп язучы бар. Болары — СССР Язучылар берлеге әгъзалары булган, хезмәтләре белән халык алдында азмы-күпме танылган кешеләр. Шулар янына тагын берничә йөз яшь һәм башлап язучыларны да өстәсәк, каләм ияләренең саны байтакка җыйнала.

Иртәгә Татарстан язучылары үзләренең зур җыелышына — нәүбәттәге съездына җыйнала. Бу дәрәҗәле форумда соңгы елларда башкарылган эшләр турында җитди сөйләшү булачак, әдәбиятыбызның алга таба үсеш юллары билгеләнәчәк. Чираттагы съезд алдыннан әдәби хәрәкәтебезгә караган кайбер уй-фикерләрем белән минем дә уртаклашып узасым килә. Ихтимал, аларны юлларда туган уйлар дип тә әйтергә мөмкиндер.

Кем ничектер, белмим, юл йөргәндә, мин үзебезнең эшебез турында, әдәбиятыбыз, каләмдәшләребез, уңышларыбыз һәм кимчелекләребез турында күбрәк уйланам. Күрәсең, шарты, мохите, атмосферасы шуңа этәрәдер. Ирексездән чагыштырасың, параллельләр үткәрәсең, теге яки бу хәлнең сәбәбен ачыкларга омтыласың. Бүтән халыклар белән уртаклашырлык нинди казанышларыбыз бар? Кайсы якларыбыз белән калышабыз? Көчләребез нинди? Перспективалар ничек? Совет культурасының гомуми хәзинәсенә керткән өлешебез ниндиерәк? Вөҗданың белән сөйләшкәндә, үз-үзеңә бирә торган сораулар күп туа. Әмма тәмам тәгаенләнгән, җавап булып оешкан хис-тойгы да юк түгел күңелдә: ул — әдәбиятыбызның үткәне белән горурлану һәм киләчәге өчен кайгырту.

Үткәннәрдән безгә Кол Галиләр, Мөхәммәдъярлар, Кандалыйлар, Тукайлар, Ибраһимовлар, Такташлар, Җәлилләр карап тора. Вакыт галиҗәнаплары безнең бүгенгедән киләчәккә кемнәрне алыр да, нинди әсәрләрне үзенең елъязмасы итеп таныр? Уйның шундые да күңелгә килә. Чөнки күңел алдагыны сиземләргә, ачыкларга омтылучан. Перспективаң барын тойсаң, стимулың да була. Ә ретроспектив яктан, узганнарга таянып, әдәби тарихыбызның зурлыгын, рухи ты-

лыбызның ныклыгын юлларда йөргәндә миңа күп мәртәбәләр тоярга туры килде. Дөресрәге, очраклы кавышкан юлдашлар, гадәттә, бүтән халык вәкилләре ул хисне тойдырырга булыштылар. Чөнки азмы-күпме әдәби белеме һәм аек карашы булган кеше безнең әдәбиятның тарихи зурлыгын, олылыгын таный, ихтирам итә.

Заманалар тиз үзгәрә хәзер. Егерменче йөз башындагы әдәби карта белән гасыр ахырындагы әдәби карта бер-берсеннән нык аерыла. Дөньяви масштабта карасаң да, үзебезнең ил күләмендә карасаң да. Соңгы дистә еллар эчендә Латин Америкасы язучылары үзләренең уникаль әсәрләре белән дөньяны таң калдыралар. Африка континенты әдәбияты да хәзер куәтләнеп, зур дөньяга юл ярып килә. Үзебезнең илдәге Урта Азия халыкларының сүз сәнгате гаҗәеп темплар белән үсә. Сөрелми, ял итеп яткан җирне эшкәртеп, көтелмәгән уңыш алган кебек, бу регионда хәзер зур әдәбият барлыкка килде. Ерак Себердә һәм Төньякта яшәүче аз санлы, әле яңа гына үз язуларын булдырган халыклар да дөньякүләм билгеле язучыларын тудырдылар. Халыклар аралашкан заманда кешеләрнең кешелеген уята торган рухи байлык, кайда гына тудырылса да, һәммәбез өчен дә уртак казаныш буларак кабул ителә. Чөнки континентлар аралаша, илләр аралаша. Безгә, гуманлы һәм интернациональ рухта тәрбияләнгән кешеләргә, бер-береннән өйрәнә алу дигән матур хокук та бирелгән бит әле! Әйтик, Урта Азия регионында тарихи романнарның шәп үрнәкләре бар икән. Балтыйк буе республикаларында геройларның психологик халәтләрен үзенчәлекле рәвештә күрсәткән әсәрләр күп икән, әгәр рус әдәбиятында хәзерге Себер рухы, аның киңлеге һәм масштаблылыгы оста тасвирлана икән, бу казанышлар безнең язучыларның да аңында булырга тиештер.

Татар әдәбияты, бүтән байтак әдәбиятлар шикелле, моңарчы, асылда, авыл әдәбияты булып килде. Аның төп укучысы да авылдан иде, язучысы да шул ук авылдан чыкты. Хәзер, ситуация дип әйтимме, хәл нык үзгәрде. Авыл шәһәргә тулды. Шул ук вакытта авыл да күпмедер дәрәҗәдә шәһәрләште. Халыкның психологиясе үзгәрде. Икетеллелек гамәлгә керде. Кичәге игенче — бүген эшче. Ләкин әле ул тамырлары белән авылга нык бәйле эшче. Ул әле, мөгаен, станок шавы тынып торган араларда иген шаулавын да ишетә торгандыр. Менә шундый авыл шәһәрләшкән, әгәр шулай әйтү дөрес булса, күпмедер дәрәҗәдә шәһәр дә авыллашкан чорда иҗатчының, бу очракта, язучының, вазифасы шактый катлаулы һәм четерекле. Нык үскән, нык индустрияләшкән,

фән һәм техниканың соңгы казанышларына ия булган дәрәҗәле республика. Галимнәре арасында дисеңме, эшче яки интеллигенциясе арасында дисеңме, илкүләм мәшһүр кешеләребез күп, кызыклы язмышлы, бай биографияле шәхесләр ничаклы! Шул җирнең язучысы, шушы заманның елъязмачысы булу — ифрат дәрәҗәдә мактаулы һәм җаваплы миссия.

Миңа калса, Татарстан Язучылар союзы оешмасы соңгы дүрт-биш ел эчендә байтак игелекле эшләр башкарды. Йөзәрләгән яңа китап дөнья күрде. Яңа романнар, повестьлар, поэмалар, пьесалар язылды, бик күп хикәяләр, шигырьләр дөнья күрде. Күбесен халык яратып кабул итте. Араларында илкүләм яңгыраш алганнары да булмады түгел. Шулай ук Бөтенсоюз радиосы дулкыннарында, телевидение һәм кино экраннарында безнең вәкилләрнең дә авазы ныграк яңгырый башлады. Әле хәтердә, моннан егерме еллар элек, Ибраһим Газилар, Мирсәй Әмирләр, Гази Кашшафлар исән-имин чакта, татар әдәбиятын ничектер лаеграк итеп Бөтенсоюз аренасына чыгару турында зур кайгыртучанлык белән сөйләнелә иде. Бу елларда рус телендә башкалада чыккан китаплар сирәк иде. Мәскәүдә иркен басылган язучыларыбыз Г. Әпсәләмов һәм Ә. Ерикәй генә иде шикелле. Хәзер исә хәл шактый ук уңайга үзгәрде. Ел саен дистә-дистә китап дөнья күрә. Һәм күп кенә язучыларыбызның исемнәре хәзер Бөтенсоюз укучысына да шактый ук мәгълүм булды. Сирәк кенә булса да, кайбер әсәрләребез чит илләрдә дә чыккалап куя. Тәрҗемә әсәрләре белән киңрәк дөньяга чыгу нәтиҗәләре, ихтимал, без теләгән дәрәҗәдә үк булмаса да, алар ике съезд арасында язучыларыбыз тарафыннан эшләнгән иң зур эшләрнең берсе булды. Бу урында мондый фикерне дә әйтеп китү урынлы булыр: уңышларыбыз бераз булса да, әле бүгенгә кадәр бер генә татар язучысының да подпискаларга, ягъни язылып алдырыла торган күптомлы басмаларга эләгәлганы юк. Күп гасырлы тарихы булган татар әдәбиятына «Художественная литература» кебек нәшриятларда күптомлы китаплар чыгармау бер дә мактаныч түгел. Хәтта рус телендә рәттән ике том чыгарган бер генә язучыбыз да юк бит. Күрәбез, бу серияләрдә милли әдәбият вәкилләре даими чыгып килә. Күрәсең, безнең яктан бу юнәлештә тиешле активлык җитенкерәми.

Татарстан китап нәшрияты соңгы елларда бик зур игелекле эшләр башкарып килә — әдәбиятыбыз классикларының күптомлыкларын туган телебездә чыгара. Байтак классик язучыларыбызның яхшы китаплары дөнья күрде. Полиграфик яктан да безнең шартлар өчен канәгатьләнерлек-

ләр. Шулай да чыккан басмалар арасында иң күркәме, мөгаен, Кол Галинең әле яңа гына дөнья күргән «Кыйссаи Йосыф» китабыдыр. Галимнәребез һәм нәширләребезнең уртак тырышлыгы белән чыккан һәм культура тарихында ифрат зур мәгънәгә ия булган бу басма — язучылар съезды алдыннан укучыларыбызга бәйрәм китергән зур бүләк. Ерак тарих офыгыннан бүгенгеләргә күренерлек, килер буыннар өчен дә маяк булырлык алтын казык кагылды! Әлегә ун мең данә генә чыккан бу китап, халык ихтыяҗын искә алып, нәшрият тарафыннан яңадан басылыр, безнең типографияләрдә чыккан М. Цветаевалар китабы шикелле, кабат-кабат 100әр меңләгән тираж белән дөнья күрер дигән өметтә калабыз.

Бүтән республикаларда йөргәндә, әлбәттә, китап кибетләренә, китапханәләргә керәсең, халыкның нинди әсәрләр белән «азыклануын» күрәсең. Табигый, китап киштәләрендә Татарстан язучыларының җыентыкларын да күбрәк күрәсе килә. Таныш исемнәрне күргәч, күңел сөенә, әдәбиятыбыз өчен горурлану хисе уяна. Китапсызрак җирләргә эләккәч, хис бүтән була, әлбәттә. Бигрәк тә татарлар күп яши торган кайбер якларда туган телдә китапларның булмавы яки юк дәрәҗәсендә аз булуы канәгатьсезлек уята. Халык сорый, ә китап юк. Шул ук вакытта шул ук кирәк китаплар Татарстанның нindидер бер районы




*Равил Фәйзуллин осетин язучысы Нәфи Джусойты белән. Пермь, 1982*

складында тузанга күмелеп ята... Китапларыбызны тиешле җиргә, тиешле күләмдә, тиешле вакытта тарату — безнең һәрберебез өчен дә бик мөһим мәсьәлә. Сәүдә оешмаларында эшләүче кайбер иптәшләр, китапка идеологик чара берәмлеге булудан бигрәк, товар күзлеге аша карап, пропаганда мәсьәләсенә тиешле игътибар биреп җиткермиләр.

Без соңгы елларда сан ягыннан да ишәйдек. Яшь авторлар белән даими эшләү язучылар оешмасының эш нормасына әверелде. Моңарчы булмаганча, Татарстанның бөтен төбәкләрендә яшь язучылар семинарлары, конференцияләре үткәрелде. Бу — килер көчләрне барлау, әдәбиятның киләчәк язмышы турында кайгырту. Күрәсең, табигатьнең үз законнары бар. Талант сирәк очрый. Чәчрәп, балкып торган яшь талантлар, кызганычка каршы, күп түгел...

Соңгы еллардагы позитив күренешләрнең берсе итеп әдәбиятыбызның көзгесе булган «Казан утлары» журналының да уңай якка яхшыруын әйтми китеп булмый. Дөрес, ике съезд арасында тиражы беркадәр кимеде кимүен. Кимүнең сәбәпләре дә булды. Әмма журнал үзенең абруен тагын да арттырыр дип ышанасы килә. Иң әүвәл, әлбәттә, үзебезнең анда яхшы әсәрләребез белән катнашуыбыз кирәк. Әдәби хәрәкәтне яктыртып бара торган, Язучылар союзының бердәнбер органы булган журналыбызны яхшырту, аны пропагандалау өчен һәр каләм иясе үзендә җаваплылык тоярга тиеш. Чөнки журналыбыз безнең республика чикләреннән тышта да бик күп тарала.

Ике съезд арасында халык күңелендә калырлык, бүтән халык вәкилләре дә игътибар итәрлек зур әдәби бәйрәмнәр дә аз булмады. Тууларына йөзәр яшь булган әдипләрнең юбилейлары гөрләп узды. (Мин монда Галиәсгар Камал, Шәриф Камал юбилейларын истә тотам.) Муса Җәлил исеме белән бәйле юбилейлар һәрчак илкүләм яңгыраш ала. Тукайның да йөз еллык бәйрәме якынлаша. Аның белән янәшә үк Галимҗан Ибраһимовның йөз еллыгы. Болар бит, бер уйласаң, һәммәсе рухи хәзинәбезнең никадәр бай булуы турында сөйли торган фактлар. Мәскәүдә уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә язучыларның актив һәм эшлекле сурәттә катнашулары хәтердә. Каракалпакстандагы әдәбият һәм сәнгать бәйрәмнәре һаман истә, республикабызда уздырылган совет әдәбияты көннәре дә хезмәт ияләренең күңелләрендә яхшы хатирә булып әле дә сакланадыр. Кол Галинең 800 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә уздырылган кичә дә әдәбиятыбызның зурлыгын раслауда бик күркәм эш булды.

Ихтимал, язучылар оешмасына да, активрак инициатива күрсәтеп, әдәбиятны пропагандалау юнәлешендә тагын башка чаралар да үткәрергә мөмкин булгандыр. Әйтик, бүтән республикаларда — татар әдәбияты көннәре. Мәсәлән, Башкортстанда, Ульяновск яки Әстерхан өлкәләрендә... Бу җәһәттән бүтән республика язучылар оешмаларының уңай тәҗрибәләрен кабул итү безгә дә комачау итмәстер.

Әдәбиятыбызның потенциаль мөмкинлекләре зур, чөнки халыкның тарихы зур, язмышы гыйбрәтле, хезмәте олы. Татар әдәбиятының тематик диапазоны, һичшиксез, тагын да киңәячәк. Республикабызның үз эчендәге геройлардан тыш, бөтен ил буенча сибелгән һәм хезмәт күрсәткән каһарманнарның да язмышы киләчәктә безнең язучыларның игътибарын җәлеп итәр. Әлегә файдаланып җителмәгән мондый мөмкинлек бөтен әдәби жанрларны да тулырак файдалануга китерәчәк, язучыларыбызны тагын да фидакяррәк эшләүгә этәрәчәк. Моңа шик юк.

*1984, май*

# СҮЗ КӨЧЕ

Мөхтәрәм каләмдәшләр!

Кадерле кунаклар!

Тарихи мәгънәсе, эчтәлеге белән без кичергән соңгы дүртбиш ел — элек яшәлгән әллә ничә дистә елларга тиң торырлык. Ни өчен шулай дим? Дәлилем шул: йотылуга, «совет халкы» дигән абстракт исем астында актив рәвештә руслашуга; милли йөзен югалтуга барган халык, «без уяндык Бишенче елны таң белән» дигәндәй, ниһаять, янә бер үзенең бар икәнлеген, элеккеге шәүкәтле чакларын бөтенләй үк онытмаганын, тарихи Хәтернең исән икәнлеген раслады. «Татар халкы», «Татарстан» дигән сүзләр дөнья халыклары телләрендә ешрак тибрәнә башлады. Төрле кыйтга илләре белән аралашулар көчәйде. Үзебез дә күзгә күренеп үзгәрдек. Халыкның бөтен катлауларында да сизелә бу үзгәреш. Фәкать дөнья көтү — җан асрау, өс-баш бөтәйтү белән генә мәшгуль булган миллионлаган милләттәшләребездә дә эчке уяну — үткән, бүген, киләчәк турында уйлану башланды. Дөрес, бу дүртбиш ел эчендә бүтән халыклар да йоклап ятмады, аларның да казанышлары җитәрлек. Әмма нәрсә бәрабәренә бит! «Пәри башка, җен башка» дигәндәй, безнең тарихыбыз да үзенә бер төрле бит әле! Без бит эстоннар яки грузиннар кебек империя читендәге халык түгел. Ни өчен Татарстан белән санлаша башладылар? Ни өчен байтак халыклар безгә игътибарлырак була башлады? Әллә җир-суларыбыз, территориябез үзгәрдеме? Юк! Әллә Израильдәге яһүдләр кебек, татарлар бер җиргә актив туплана башладылармы? Алай түгел шикелле. Әллә бөтен дөньяны шаккатырырлык гасыр ачышлары булдымы бездә?..

Хикмәт шунда: элек үзенең дәүләтчелеге булган халыкның генофонды үзенең әлегә тере икәнлеген белдерде. Кызулык белән түгел, сабырлык белән; корал белән түгел, акыл белән эш итү кирәклеген сиздерде тарихи Хәтер! Менә шуңа күрә дә без шаһитлары булган әлеге бишьеллык ара байтак дистә елларга тора дип әйтәм дә.

Бу рухи күтәрелештә безнең әдипләребезнең дә өлеше шактый дип уйлыйм мин. Халык язучысымы ул, әллә яңа гына Берлек әгъзасы булган каләм иясеме, язучы-депутатмы, әллә пенсионер әдипме, яшьме-картмы, ир-атмы, әллә хатын-кызмы, шагыйрьме, драматургмы, прозаик яки тәнкыйтьчеме, төп мәсләктә халкыбызга ирек кирәклеге мәсьәләсендә шактый ук бердәм була алдылар. Кемдер күбрәк көч куйды, кемдер — әзрәк, кемнеңдер эше Данко йөрәге януы шикелле бар халыкка күренеп торды, кемдер кызган торф кебек астан, эчтән янды һәм

кирәген яндырды... Ә инде әдәби-оештыру елъязмасын янә бер күздән кичерсәң, Язучылар оешмасы ягыннан да бу юнәлештә эшлекле инициативалар байтак булган.

Шулай да, миңа калса, бу соңгы елларда әдәби-нәфис сүзгә караганда, иҗтимагый-сәяси сүзнең куәте көчлерәк булып чыкты. Теләсә-теләмәсә дә, коеп куйган әдипләребезнең дә күпчелеге сәясәтчегә әйләнде. Күрәсең, тарихи ихтыяҗ, заман таләбе шундый. Бу күренешне закончалык дип, Азатлыкка, Бәйсезлеккә бару юлының бер авыр этабы үтелү билгесе дип тә карарга кирәктер.

Ә инде әдәби әсәрләргә — фәлсәфи мәгънәгә, эстетик тәэсиргә ия әсәрләргә конкретрак килгәндә, күрә белик — алар да аз язылмады бу чорда! Хәтерегездәдер: үткән съездда күләмле әсәрләрдән И. Салаховның «Тайгак кичү»е, М. Хәсәновның «Язгы аҗаган»ы һәм тагын кайбер романнарны уңай бәяләгән идек. Бу зур җыенда да без андый әсәрләрне саный алабыз. Әйтик, ел ахырында гына журналыбызда чыккан «Йәгез, бер дога» (А. Гыйләҗев) әсәре югары кимәлдә язылмаганмыни? Яки Ф. Садриевның «Таң җиле»?.. Ә тарихи романнар? «Казан утлары»нда гына алар бишәү басылды. (Мин биредә Ф. Латыйфи, Батулла, М. Хәбибуллин, Җ. Рәхимов, Р. Мөхәммәдиев әсәрләрен күздә тотам.) Төрле дәверләргә караганнары бар. Болгар чоры дисеңме, Казан ханлыгы еллары, соңрак чорлар... Әлбәттә, аларда бәхәсле моментлар да җитәрлек. Әмма мондый романнарның ишәюе әдәбиятыбыз өчен уңай күренеш.

Менә без аерым жанрлар буенча берничә кыска докладчыгышлар тыңладык. Әдәбиятыбызның үсеш тенденцияләрен ачыклаучы байтак кызыклы фикерләр яңгырады. Бер нәрсә бәхәссез: без заманнан арттарак калып барабыз. Заманны аңлау буенча да һәм, әлбәттә, аны язмада беркетеп калдыру буенча да. Тоталитар режим тәрбиясендә тибрәнеп, йокымсырап, оеп ятканда, кинәт ирекле хөр фикер стихиясенә керә алу уен эш түгел. Без югалып, хәтта куркыбрак та калдык шикелле. Шунсы гаҗәп: цензура кысалары үтә нык чакта да шактый гына саллы, хөр, хәтта ки, ул заман өчен еретик саналган кыю фикерләр әйткән язучылар ничектер тыныбрак калды. Кайчандыр авыз тутырып тын алырга да базмый торганнар үтә актив көрәшчеләргә, хакыйкатьнең мөгезеннән эләктерүчеләргә әверелделәр. Чөнки киртәләр җимерелеп, бөтен көтү-табун печәнле-үләнле җирне тойгач, күпләр гайрәтләнде... «Япунны мөселманлыкка чыгарган» Батыргали агайга әйләнде. Бу, бәлки, начар да түгелдер. Әмма кычкыру белән кычкыруның, әйтә белү белән әйтә белүнең,

яза белү белән яза белүнең аермасы бик зур шул. Ниятләкләре изге булып та, язу куәтләре чамалы булган авторларның әсәрләре матбугатны басып китте. Кыскасы, яхшыны уртачадан, уртачаны начардан аеру критерийлары югалды. Бәлки, болар күчеш, тетрәнү, катаклизмнар чоры өчен табигыйдер дә. Әмма вакыт узар, эстетик категория кануннары тулы яшәү хокукын барыбер алыр.

Югарыда әйтелгән нәтиҗәләргә китергән факторларның тагын берничәсен әйтеп узасы килә. Аларның берсе: классик мәгънәдәге асыл зат әдипләрнең сирәкләнүе, ягъни күркәм традицияләребезнең тотрыксызлануы... Гасырларыбызның беренче яртысында яшәп иҗат иткән әдипләр когортасын, әйтик, Дәрдемәнд, Г. Исхакый, С. Максуди, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов, К. Тинчуриннарны әйтеп тә тормастан, әле күпләребезнең хәтерендә булган И. Гази, М. Әмир, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан кебек чын мәгънәсендәге әдипләрнең безнең арада юк дәрәҗәсендә аз булуы күңелне сыкрата. Аларның иҗатлары, исемнәре, яшәү рәвешләре дә үзләреннән соң килгән каләм ияләренә — яшьләргә әдәпсез һәм әхлаксыз яшәргә мөмкинлек тә, ирек тә бирмиләр иде. Үз заманнарына хас ортодоксальлекләре булса да, принципиаль, компромиссларга бирешми торган олпат затлар иде алар. Кызганыч, бүгенге җитмеш яшьлекләребезнең кайберләренә әлеге сыйфатлар бик тә җитенкерәми шул.

Икенчесе: әдәбиятыбызның заманнан артта калуына тагын бер сәбәп: без соңгы елларда, нигездә (кайберәүләребезнең чит ил әдәбиятлары белән багланышны ныгытуларын инкяр итмичә), фәкать үз казаныбызда гына кайнавыбызда. Дөрес, бу хәлнең файдасы да юк түгел: үз тарихыбызны ныграк өйрәнә башладык, үзебезнең мәшһүр шәхесләребезне барлыйбыз, тарихыбызның җуелган чылбырларын ялгыйбыз. Әмма, икенче яктан, без үзебезнең рухи хезмәтләребезне бүтән халыклар ирешкән казанышлар белән чагыштырып караудан мәхрүмрәк хәзер. Элегрәк тугандаш халык әдәбияты вәкилләре белән очрашулар-декадалар, совет әдәбияты көннәре, төрле юбилейлар еш була иде. Һәм алар, мәгълүм бер дәрәҗәдә, әдәбиятыбызны үстерүгә уңай йогынты ясый иде.

Өченчедән, әдәбиятка яңа килгән, дөресрәге, Берлек әгъзалыгына яңа кабул ителгән каләм ияләренең яшь ягыннан шактый ук өлкән булулары. Картлар яки яшьләр әдәбияты булмаса да, бүгенге бу процесста әдәбиятта сыйфатый яңарыш була алмый. Карагыз, ике съезд арасында Берлеккә кабул ителгән язучы иптәшләрне. Алар җитмештән артык. Күбесенең яше илледән ашкан... Хәер, биредә хәзерге яшь-

ләрнең язучылык хезмәтенә реаль карашын да онытмыйк. Кызганыч: каләм хезмәте бу чорда нормаль яшәүгә гарантия була алмый. Талант бәяләнми торган чорда яшибез.

Һәм, дүртенчедән (монда тагын бишенчедән, алтынчыдан... унынчыдан дигән пунктларга кадәр барып җитәргә мөмкин), без — татар язучылары, хәзергә Татарстан җирлеге белән генә чикләнәбез. Гәрчә дүрт-биш татар кешесенең фәкать берсе генә Татарстанда яшәсә дә. Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә без халкыбызның реаль силуэтын тулырак итеп тойдык. Кая безнең бүтән төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез турында чын мәгънәсендәге киң масштаблы әсәрләр? Нижгар, Касыйм татарлары дөньяда юкмыни? Мәскәү, Урта Идел, Әстерхан, Оренбург, Чиләбе, Троицк һәм, ниһаять, Уфа ягы татарлары турында хезмәтләребез кая? Анда безнең халкыбыз юкмы? Әллә алар тормышын колачларлык әдипләр юкмы? Стратегик ялгышлар турында уйландыра бу фактлар. Зур кыенлык белән Башкортстанда ачылган татар язучылары оешмасына безнең реаль ярдәм бик кирәк. Тәҗрибәбез, киңәшебез кирәк. Иншалла, андый оешмалар бүтән регионнарда да ачылыр. Алар да өмет белән Казанга караячак бит.

Сүземнең ахырында үзебезнең «Казан утлары» турында да берничә сүз әйтеп китим. Журналның бүгенге тиражы 23 мең чамасы. Аны бер елга, ягъни 12гә тапкырласаң, 300 меңгә якын өр-яңа әсәрләрдән торган калын китап дигән сүз. Үзенә күрә бер нәшрият. Татарстан китап нәшриятының татарча чыгара торган китаплары өлешенә якынлаша безнең саннар.

Хәтерегездәдер, «Казан утлары» озак дистә еллар буенча Татарстан Язучылар союзы органы булып исәпләнде. Үткән съездда да журналның статусы әле шулай иде. Ә 1991 елның уртасыннан башлап журнал яңа юридик статус алды. Хәзерге көндә журналны оештыручылар ягъни гамәлгә куючылар булып Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы санала. Юстиция, матбугат һәм информация министрлыклары раслаган безнең үз уставыбыз бар. Һәм без андагы положениеләр нигезендә эшлибез дә. Журнал бүгенге көндә, нигездә, хөкүмәт биргән дотация акчасына яши. Һәр сан уртача 10 млн. сумга төшә. Әбүнәчеләрдән, ягъни подписчиклардан кергән акчага нибары икеөч сан чыгарып була. Спонсорлардан кергән керемебез дә бик аз микъдарда. Язучылар берлеге, табигый, үзе дә хөкүмәт акчасына яшәгәнлектән, безгә матди яктан булыша алмый. Журналны, асылда, югарыда әйтелгән өч оештыручының икесе чыгара: хөкүмәт акча бирә, редакция коллективы журналны әзерләп укучы кулына тапшыра. Шулай да без

Язучылар берлеген журналны оештыручыларның берсе булуын табигый саныйбыз. Чөнки безнең төп авторларыбыз — язучылар, талантлы әсәрләр никадәр күп булса, халык арасында безнең абруебыз да шул нисбәттә зуррак булыр, халыкның рух дәрәҗәсе дә үсә барыр.

Сүз уңаеннан соңгы елларда редакция эшчәнлегенә кагылышлы кайбер эшләребезне әйтеп үтү дә урынлы булыр. Иң мөһиме, бу авыр шартларда без тиражыбызны чагыштырмача канәгатьләнерлек дәрәҗәдә саклап кала алдык. Бу елларда журналның матди-техник базасы ныгыды. Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә тантаналы рәвештә журналның 70 еллык юбилеен уздырдык. Журналның үткән тарихын һәм бүгенгесен яктырткан, ике кисәктән торган докуметаль фильм эшләнде.

Хөрмәтле иптәшләр!

Төшенкелеккә бирелмик: талант ияләре өчен бу авыр еллар үтәр. Кешелек яшәгәндә Сүз кодрәтенең көче кимемәс. Әйдә, каләм хакы нәфес кузгатырлык булмаса да, күңел түреннән төшкән иң яхшы әсәрләребезне милли басмаларыбызда, «Казан утлары» кебек төп журналларыбызда ташка бастыра барыйк. Тарихи елъязма булып калсын алар. Язучыларның бу съезды аңлашу һәм туганлашу җыены булсын. Мөстәкыйльлеккә юл тоткан дәвердә милли бердәмлек иң мөһиме бит.

Кайбер талантлы каләмдәшләребезнең, әйтик, Т. Миңнуллин, Н. Фәттах, М. Юныс, Разил Вәлиев, Г. Рәхим, Р. Кутуй, Ш. Хөсәенов, И. Нуруллиннарның съездыбызда булмавы бераз уйландырды мине. Катнашмау өчен мөһим сәбәпләре булгандыр дип уйлыйк. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

*1994, июнь*

# РУХИ ТОРМЫШЫБЫЗ КӨЗГЕСЕ

*(«Казан утлары»ның 50 еллыгы уңаеннан)*

Балачакта, без, малайлар, яр ягасына җыелып, кулларны каш өсләребезгә куеп, озаклап, Кама дигән бөек елгага хәйран калып карап тора идек. Хыялларны үсендереп ак пароходлар уза, җыйнак катерлар үтә, балыкчы көймәләре төпкел урыннарда кайнаша. Кайчак, Кама-Чулманны урталай ярып (ул чак плотиналар юк, сулар бу кадәр галәмәт җәелмәгән иде), сузаеп, озын-озын баржалар таккан буксирлар уза. Алар салмак бара, озак уза, чөнки йөкләре авыр, юллары ерак. Кайсысына таш-күмер төялгән, кайсына — бодай, кайсына — агач, кайсына — кавын-карбыз... Ә буксир тарта да тарта, өстери дә өстери...

Мин үзебезнең «Казан утлары»н бик авыр һәм бик тә кирәк йөк сөйрәүче әнә шул буксирга охшатам. Ул — рухи дөньябызның бар мәшәкатьләрен хәл кадәре канәгатьләндереп торучы бердәнбер журналыбыз. Төп вазифасы — укучыларны әдәби хәрәкәтебез хәлен билгеләүче яхшы әсәрләр белән таныштыру белән бергә, журналыбыз сәнгатьнең бүтән өлкәләрен дә колачларга тырыша. Фәнни-тарихи хезмәтләр, театр, музыка, рәсем сәнгатьләренең үсеш тенденцияләрен чагылдырган мәкаләләр... Кыскасы, иҗтимагый, рухи тормышыбыз көзгесе ул «Казан утлары».



*«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзаларыннан бер төркем. Х. Вахит, Х. Туфан, З. Нури, Л. Ихсанова, М. Әмир. 70 нче еллар*

Инде журнал белән шәхсән минем бәйләнешка килгәндә, ун елга якын эшлекле мөнәсәбәттә торам дип исәплим. Бу дәвердә журнал битләрендә йөздән артык шигырем басылды. Алардан тыш мәкаләләр белән дә катнашкалап киләм. Беренче шигырьләрем дөнья күргәннән алып бүгенге көнгә кадәр (шәт, киләчәктә дә шулай булыр дип уйлыйм) бу журналда басылуны бер сынау мәктәбе узу һәм зур дәрәҗә саныйм. Татар әдәбиятының үзәген тәшкил итүче язучыларның күпчелеге шулай ук бу журналны чыныгу һәм үсү мәктәбе дип таныйлардыр, һәрхәлдә, соңгы ун елда әдәбиятка аяк баскан язучылар өчен «Казан утлары» чын мәгънәсендә старт мәйданы, күтәрелү ноктасы булды. Бер генә мизгелгә «Казан утлары»н юк дип фараз итик. Әкиятләрдәгечә, күкне җиде кат дибез икән, ихтимал, рухи күгебезнең берничә каты җимерелеп төшәр иде. «Талантлы — канатлы» дибез икән, бу тәгъбирне белү генә җитми бит, — канат бар икән, очарга да кирәк. Биеклек кирәк, күк кирәк!

Минем үземә дә, яшь вакытта, бу журнал редакциясендә берничә ел эшләп алырга насыйп булды. Баш редактор булып Рафаэль Мостафин эшләгән, тиражның бик нык үскән, журналның халыкта популярлаша барган чоры иде ул. Төрле бүлекләрдә вакытлыча вазифа башкарганга күрә, хезмәткәрләренең эшләре шактый ук таныш иде. Бүлекләргә ул вакытта да җиңел түгел иде. Хәзер язучылар ишәйгән, табигый, әсәрләр дә күбәя барган саен, эш тәртибе катлаулана; әсәрләр, авторлар, ниһаять, укучылар алдында җаваплылык арта булыр. Алыйк тәнкыйть бүлеген генә. Асылда ул — әдәби тәнкыйть бүлеге генә түгел бит, тарихыбызның һәм сәнгатебезнең барлык төрләрен барлап баручы, гомумән, әдәби-иҗтимагый фикер үсешен чагылдыручы бүлек. Журналның арттарак өлешендәге вак хәреф белән басылган материалларның күләмен, эчтәлеген күздән кичереп, хисаплап карасак, Фәрваз Миңнуллин җитәкләгән бу бүлек башкарган хезмәтне беркадәр чамаларга мөмкин. Әлбәттә, һәр бүлекнең үз спецификасы, үз миссиясе, үз җаваплылыгы. Журналыбызның 50 еллык бәйрәме уңае белән, күңелемдә йөрткән бер теләгемне дә әйтәсе килә: журналның үз архивын булдырырга иде! Мәдәниятка караган күпме кульъязма керә редакциягә! Бик күп бит алар! Әлбәттә, бар кергән кульъязма басыла алмый; күпмеседер кала, күпмеседер беркадәр үзгәртелә, кайберләре авторларга кайтарыла, кайберләре, еллар үтә төшкәч, агымдагы кирәксез бухгалтерия кәгазьләре кебек югала... Берзаман аларны кемнәрдер эзләячәк, кемнәргәдер бик-бик кирәк булачак бит алар!.. Әйтик, 50 еллык бәйрәмдә

журналның «Безнең юл»дан «Казан утлары»ның бүгенге юбилей санына кадәрге басмаларның тулы комплектлары булсын иде әле редакциядә! Күргәзмә оештыр идең, күрсәт идең, тотып, актарып кара идең! Ә бу бит әле хыялланыр ук нәрсә түгел, табигый, нәкъ шулай булырга тиеш, элементар нәрсә. Кыскасы, бу юнәлештә, гомумән, әдәби мирасның кыйммәтен аңлау һәм аны барлау юнәлешендә безнең һәрберебезгә уйларга, эшләргә кишәрлекләр җитәрлек.

«Журнал миңа нәрсә бирде?» дигән сорауга бик тә рәхмәтле сүзләр белән җавап бирәм. Журналда эшләүче хезмәткәрләр сөенеп басарлык, укучылар яратып укырлык әсәрләр язсак, бу — безнең иң чын рәхмәтебез булыр. Бәйрәм уңае белән, редколлегия әгъзалары, редакциядә эшләүче хезмәткәрләрне ихлас котлыйм, фидакяр эшләрендә уңышлар телим. Журналыбызның тиражы 100 меңгә, һәм аннан да арыга үссен! Шулай булсын, республикабыз тормышын хәзер зур саннар — миллионнар, миллиардлар билгели.

*1972, гыйнвар*

# ЖУРНАЛ ЯЗМЫШЫ — БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

Һәр басма китап минем өчен үзе бер җанлы җисем, үзе бер тере организм кебек тоела. Ул гүя синең якын бер әңгәмәдәшең. Ул сиңа кычкырмый-нитми, каршы сүз әйтми генә нәрсәдер аңлата, ниндидер гыйбрәтле хәлләр сөйли, нәрсәгәдер өнди... Син дөньяның матурлыгын һәм катлаулылыгын ныграк төшенә башлыйсың, кешелек тарихының мәңгелек категорияләре — Яхшылыкка һәм Яманлыкка, Мәхәббәткә һәм Нәфрәткә, Хаклыкка һәм Ялганга, Тугрылыкка һәм Хыянәткә, Тынычлыкка һәм Сугышка, Гүзәллеккә һәм Ямьсезлеккә... үзеңчә гадел мөнәсәбәтеңне ачыклый төшәсең. «Ташка» басылган һәр чын иҗат әсәре — мәңгелекнең дә, мизгелнең дә кабатланмас бер чагылышы бит. Исеме журнал дип аталса да, үзендә дистәләрчә әсәрләрне бергә җыеп, ай саен даими чыгып килә торган «Казан утлары» дигән китап та әнә шундый олы миссияне үтәүче басмаларның берсе. Шуңа күрә дә ул йөз меңләгән укучыларның якын дусты, ышанычлы фикердәше булып әверелде дә.

Минем китапханәмдә «Казан утлары»ның («Безнең юл», «Совет әдәбияты» исемендә чыкканнарын да исәпләп) биш йөзгә якын саны саклана. Төпләнмәләре күзләрне иркәләрлек ямьле булмаса да, миңа алар үзем өчен зур байлык булып күренә. Әдәбиятыбызның, гомуммәдәниятебезнең, юк, алай гына түгел, бөтен халкыбызның соңгы кырык-илле ел эчендәге тарихы бит аларда! Аерым фәннәр һәм сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмагач, киң мәгънәдәге рухи культурабызның хроникаль елъязмасын шушы журналдан укымыйча, бүтән нинди чыганактан беләсең?!

Үзенең туган нигезе яки әти-әнисе турында уйлаганда, һәркем үткәненә үз кү-




*Сибгат Хәким журналның 60 еллык юбилей кичәсендә чыгыш ясый. 1982*

цел тәрәзәсе аша карап, үзе генә белгән газиз хатирәләрне исенә төшергән кебек, мин дә «Казан утлары»ның бәләкәй генә иҗат дөньямда зур һәм якты эз калдыра башлаган вакытны үземнең саф һәм хыялый яшьлек елларым белән бәйләп хәтерлим. 1965 еллар. Журналның баш редакторы булып Рафаэль Мостафин эшләгән чак. Бүлекләрдә — Н. Арсланов, В. Нуруллин, Я. Халитов, М. Хәмитовлар. Университетны бетерер-бетермәс чагым. Вакытлыча киткән кеше урынына мине дә бүлек мөдире итеп эшкә алдылар. Нәкъ шул айларны журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары»на әйләнде. Журналның исеме алышынуы турында укучыларга, бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүчеләргә мөмкин кадәр тизрәк җиткерергә кирәк иде. Юкса нәкъ журналга язылу вакыты, буталышлар килеп чыгасын көт тә тор. Җитмәсә, «Совет әдәбияты» дигән исемдә тагын бер журнал — төрекмән язучылары журналы да чыгып килә. Баш редактор, бүлекнең төп эшләреннән бераз бушатып, мине шушы журнал тарату эшенә утыртты. Чит республикаларда һәм өлкәләрдә чыга торган газеталар өчен «сез яши торган өлкәдә фәлән мең татар яши, яңа исемдә чыгачак журналны сездә фәлән мең данә таратырга мөмкинлек бар» дигән мәгънәдәге ике йөздән артык хат җибәрелде. Ул мәкалә-хатларда шулай ук журнал турында — тарихы, бүгенгесе, актив язучылары, басылачак әсәрләре турында да шактый тәфсилле мәгълүмат бар иде. Баш редактор имзасы белән җибәрелгән ул мәкаләләрнең бик күбесе басылып чыкты, һәм әйтергә кирәк, нәтиҗә дә шактый матур булды. Тираж бер ел эчендә 20 меңгә артты. Бу күркәм нәтиҗәне без җибәргән хатлар гына китерде дип әйтеп булмый, әлбәттә. Ул елларда тиражларны арттыруга бик нык игътибар бирелә иде, шуңа күрә байтак язучылар һәм әдәбият сөючеләр матбугат таратуда җиң сызганып эшләделәр дә. Бу эшкә бөтен күңелен салган кешеләрнең берсе аеруча хәтердә калган: ул — Тәүфикъ Әйделдинов. Велосипедка утырып, биштәренә өндәмә материаллар асып, ул үз теләге белән берүзе берничә өлкәне урап чыгып, подписчиклар җыеп йөрде. Ул елларда арткан тиражның берничә меңе, һичшиксез, Тәүфикъның тырышлыгы аркасында булды. Китап киштәсендә минем дә ул чаклардан калган бер истәлек саклана. Ул — кечкенә генә портатив фотоаппарат. Кырыена исем-фамилиям уелган һәм «Казан утлары» журналын актив тараткан өчен» дип өстәлгән. Практик эш өчен әллә ни җайлы булмаса да, корпусы сузылып ачыла торган бу миниатюр аппарат күрер күзгә шактый матур, һәм шул сагындырып искә төшә торган елларның кадерле бер истәлеге булып саклана.

Журналда кеше күзенә күренерлек басыла башлавым да нәкъ шул елларга туры килә. Дөрес, аңарчы да аз-маз басылгаладым. Әмма берәгәйле басылуым шул 1965 елны булды. 11 нче санда, тулы тугыз биткә сузылып, «Нюанслар иле» дип исемләнгән кыска шигырьләр циклы чыкты. Баш редактор, үз өстенә шактый җаваплылык алып, шулай күләмле итеп бирергә тәвәккәлләгәндә, минем журнал тарату эшендәге беркадәр хезмәтемне дә искә алды булса кирәк. Элегрәк мин шигырьләрем яхшы булганга шулай басылып чыктым дип кенә уйлый идем, ә хәзерге исәп буенча бүтәнчәрәк уйлыйм. Ни булса да булды, «Нюанслар» чыгып калды. Бу цикл үз вакытында шактый зур шау-шу куптарды. Берәүләр — яңача, новаторлык, фәлән-төгән дип мактадылар, икенче берәүләрнең бик нык йоннары кабарды... Шуннан бирле журналда шактый язышып киләм. Ел саен диярлек, күп кенә каләмдәшләремнеке шикелле, шигырьләрем бәйләме чыга. Егерме елга якын дәвер эчендә басылган барлык шигырьләрне бергә җыйсаң, үзе бер биш-алты табаклык китап булыр иде. Моңа өстәп, журнал битләрендә төрле елларда, төрле рухта һәм күләмдә унлап әдәби-публицистик мәкаләм чыкты. Арада — моннан өч-дүрт ел элек профессор И. Нуруллин белән икәү әңгәмә рәвешендә язган күләмле мәкалә аеруча хәтердә. Ул — бүгенге поэзиянең үсеш тенденцияләре турында шактый ук кызыклы дискуссия кузгатырга сәбәп булды. Шуңа өстәп, журналда китапларыма карата тәнкыйтьчеләрнең, шагыйрьләрнең, гади укучыларның фикерләре әледән-әле күренеп тора. Әлбәттә, төрле кешенең төрле фикерен төрлечәрәк кабул итәсең, һәм шул ук вакытта мондый хәлнең бик тә табигый икәнен аңлап, канәгатьләнеп куясың. Журнал белән шулай язышып һәм аңлашып яшәү — күпчелек язучыларыбызның типик язмышы дип беләм мин. Кайчак уйлап куясың: әгәр дөньябызда мондый журнал булмаса? Дөресен әйткәндә, бу хакта уйларга да куркыныч. Әгәр шулай булса, күп кенә язучыларыбыз һәм әсәрләребез бөтенләй үк булмас иде.

Журналыбызга 60 яшь. Байтак гомер бу, Тибет календаре белән исәпләсәң — бер гасыр. Зур юбилей. Бу бер язучының бәйрәме генә түгел, бу йөз мәртәбә олырак бәйрәм. Гадәт буенча, юбиляр турында гел мактап сөйлиләр. Әмма дустанә рәвештә, эш тагын да яхшыга барсын дип әйтелгән теләкләр дә әдәп кагыйдәсенә сыя бугай. Алга таба журналның художество сыйфатын, бөтен язучылар коллективы, редакция хезмәткәрләре белән берлектә, бик нык үстерәсебез бар. Журналның хроника өлешен оештыруны да ныклы бер

тәртипкә саласы бар. Гадәттә бер-ике генә биттән торган ул язмаларның тарих өчен әһәмияте ифрат зур. Еш кына иҗтимагый әһәмияте юк дәрәҗәсендә булган (әйтик, фәлән язучы фәлән тулай торакта чыгыш ясады) информацияләр басылып та, ил күләмендәге әдәби процесс өчен кирәкле белешмәләр онытылып калгалый. Болары бер хәл. Минемчә, иң мөһиме, журналның ил күләмендә дәрәҗәсен бик нык күтәрергә кирәк. Анда басылган әсәрләр турында үзәк матбугатта фикер алышуларны күбрәк күрәсе, дөньяга шундый яхшы журналның барлыгын киңрәк белдерәсе килә. Ә без бу юнәлештә гафу ителмәслек дәрәҗәдә сүлпәнбез. Бер генә мисал: Зур Совет Энциклопедиясен ачып карагыз. Сез анда «Казан утлары» турында белешмә күрмәссез. Хуш, бәлки, бүтән журналлар турында да белешмә юктыр? Бар. Әнә казакъ телендәге «Жулдыз», башкорт телендәге «Агыйдел», бурят телендәге «Байгал» («Байкал»)... Ярый, ниндидер ялгышлык белән керми калган ди. Бәлки, 1980 елны чыккан, 80 меңләп сүз-белешмәне берләштергән Совет Энциклопедик сүзлегендә «Казан утлары» да бардыр? Монда да юк шул. Сүзлектә «Жулдыз» бар, «Агыйдел», «Байкал», «Ялав» һ.б. бар, ә безнең журнал юк... Ә бит энциклопедияләр — бөтен дөньяга таралып, миллионнар укый, өйрәнә торган югары дәрәҗәдәге документаль китаплар. Үз өеңдә «мин!» дип күкрәк кагу бер хәл, ә дөнья күләмендә үзеңнең барлыгыңны горур белгертә алу үзгә бер дәрәҗә. Сүземне тәмамлап, фикерләрне җыйнап болай дип әйтәсе килә: журналыбыз тарихи биографиягә ия, илебез үсеше казанышларына керткән өлеше шактый, аның бүген һәм киләчәктә талантлы әсәрләр иҗат итәргә сәләтле күпсанлы язучылар активы бар. Бәс, шулай булгач, аның киләчәктә тагын да колачлырак, тагын да мәгънәлерәк булачагына, миллионнарча әдәбият сөючеләрне сөендерәчәгенә һич шик юк!

*1981, декабрь*

## ХӘЛЛӘРЕБЕЗ, ШИКСЕЗ, ЯХШЫРЫР!

*(«Социалистик Татарстан» газетасы хезмәткәре белән әңгәмә)*

**— Көз айлары газета-журналларда эшләүчеләр өчен үтә дә җаваплы, киеренке чор. Алдагы елда үзең эшләгән газета яки журналны тагын да ничек кызыклырак итеп чыгарырга, укучыларга нинди әсәрләр тәкъдим итәргә?**

**«Казан утлары» үткән дәверләр белән чагыштырганда киләчәктә нindirәк булыр, укучыларны нинди яңа әсәрләр белән сөендерер, алда нинди мөһим милли мәсьәләләрне хәл итәргә булышыр — шулар хакында сөйләсәгез иде.**

— Ихтимал, кинәттән генә Сез куйган бөтен сорау-мәсьәләләргә җавап биреп бетерә алмам. Чираттан башлыйк. Янмыйча-көймичә булмый хәзер. «Новый мир»да С. Залыгин үзенчә янып сөйли, «Огонек»та В. Коротич үзенчә бәхәс тота, «Дружба народов»та С. Баруздинның үз кайгысы... Тиражлары һәм колачлары белән бу журналлар белән тиңләшмәсәк тә, күпмиллионлы татар халкының моңа кадәр бердәнбер журналы булып килгән «Казан утлары»ның да дөньядагы ролен һәм урынын кечерәйтәсе килми. Татар халкының рухи елъязмасы булып килде ул күп дистә еллар буена. Яңа әсәрләр бастырып чыгару буенча, күләме буенча үзенә күрә бер нәшрият без. Тагын ел ярымнан аның чыга башлавына 70 ел тула. Төрле чагы булды журналның (без, Татарстан Язучылар берлеге һәм редакция, хәзер журнал тарихы музее булдыру турында хыялланабыз), төрле хуҗалары, төрле башкаручылары булды. Әйе, дөрес, заманында Сталинга мактау сүзләре дә басылган журналда, коммунизмның җиңүе турында да язылган, Татарстан АЭСының безгә «файда»сы турында да сөйләнгән... Әмма 70 елга якын тарихы булган журнал йөзен мондый сәхифәләрдән бигрәк, халкыбыз язмышын, тормышын, аның яшәү импульсын тойдырган әсәрләр билгели. Булган андый әсәрләр. Бик күп булмаса да — бар. Һәрхәлдә, журнал елъязмасында мөхтәрәм шәхесләр — Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, С. Хәким... аларның үлмәс әсәрләре... Димәк, безгә шушы «олы юлның тузанын» йота-йота булса да, бүгенге катлаулы чорда намуслы, вөҗданлы замандаш әдипләр белән кулга-кул тотынып эшләргә кала. Татарстан мөстәкыйль, суверен дәүләт булып игълан ителгәч, бу бурыч икеләтә-өчләтә артты гына. Без моны бөтенебез аңларга тиеш. Халыкның ирекле халык булып яшәвенә стимул бирерлек

әсәрләр басарга тиешбез. Без хәзергә бай түгел. Шуңа күрә газетныңмы, журналныңмы һәр бите, юлы халык файдасына эшләргә тиеш. Шуны белгән хәлдә, исегезгә алыгыз: безнең журналда «Идегәй» (дөрес, төрле вариантта) 2 тапкыр басылды. Ярты гасырда берничә мәртәбә имля алыштырган халык өчен, бәлки, табигый дәдер. Кирәк икән, андый әсәрләр өч тә, дүрт тә басылыр! «Идегәй»ләр генә булсын! Аны укый, аңлый алырлык укучылар гына булсын.

Әнә шул эстафетаны, игелекле эшне үткән буыннардан киләчәккә илтү бурычы бүген безнең әдипләргә йөкләнгән. Бүгенге үтә дә катлаулы, яңарыш-күчеш заманында кыйблабызны югалтмау, укучыларыбызны үзебез инанган гуманистик иманга өндәү — изге ниятләребезнең берседер. Моңарчы халкыбызның үткәне, тарихы, аның әдәби мирасына кагылышлы язма-әсәрләрне калку күренерлек итеп тасвирлана киленгән һәм, шәт, киләчәктә дә шулай дәвам итәргә кирәк дип уйлыйм.

— **Киләчәк димәктән. Сезнең сүзләрне җөпләп, алда бирелгән сорауларымны ачыклап, бер фикеремне генә әйтеп узыйм әле.**

**«Чиратсыз дөнья сансыз» диләр бит. Иткә чират, тозга, шырпыга... (Санарга керешмим, барыбер очына чыга алмаячакмын.) Әмма заманында ул әйберләрне иркен генә сатып алырга мөмкин булган чакта да, «Казан утлары» чиратның ни-нәрсә икәнен белеп яшәде.**

— Сез инде журналда әсәрләрен бастырып чыгару өчен чиратка баскан әдипләребез турында әйтәсездер.

— **Нәкъ шулай...**

— Чиратларны өнәмәсәм дә, Сез әйткән мәгънәдәгесе белән хисаплашырга туры килә. Бездә чират кимемәде, киресенчә, артты гына. Ел ярым элек, хәзер инде укучыларның яраткан журналына әйләнгән «Идел»не чыгара башлаган вакытта, ай саен дөнья күрәчәк ике әдәби журналга әсәрләрне ничек җиткерерләр инде дип борчылу белдерүчеләр дә булган иде. Бер дә аптырарлык хәл булмады. Әдәби хәрәкәт шәбәеп, көчәеп кенә китте. Әдәбиятыбыз да яңа исемнәр туугa этәргеч ясады...

Болары сүз уңаеннан. Журнал тарафыннан хупланган, укучыларыбыз хөкеменә тапшырырга җыенган әсәрләр байтак. Алар һәр жанрга да кагыла.

Журналга яңа әсәрләр тәкъдим иткәндә, бүгенге әдәби хәрәкәтне объектив чагылдыру белән бергә, әйткәнемчә, әдәби мирасыбызны да күз уңыннан төшермәскә тырышабыз. Бу исә безнең генә түгел, илнең, дөньяның төрле төбәкләрен-

дә яшәүче милләттәшләребезнең игътибарын уртак бер ноктага тупларга мөмкинлек бирә. Әйтик, «Татар халкы төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә» дигән рубрика шуңа мисал.

Киләсе елда да моңа кадәр журнал битләрендә даими урын алган һәм укучылар тарафыннан уңай кабул ителгән матур башлангычларыбызны дәвам иттерергә ниятлибез. Моңа кадәр гарәп хәрефләре белән язу һәм уку күнекмәләре биреп килдек. Алар журналыбыз укучыларында һәм киң җәмәгатьчелектә яклау тапты. Бу хакта безгә килгән күпсанлы хатлар да сөйли. Алдагы елда да бу эшне дәвам иткән хәлдә, латин хәрефләре белән уку һәм язуга өйрәтүгә зур урын бирергә уйлыйбыз. Чөнки байтак вакыт безнең халык шул имля белән эш иткән. Кайчан да булса латин алфавитына кайтуга шигем юк минем. Бу рубрикаларны алга таба да дәвам итәчәкбез.

Без хәзер публицистиканы басмабызның үзәк жанрларының берсе дип таныйбыз. Әдипләребез үткәнебезгә, бүгенгебезгә багышланган язмаларын даими китерә торалар. Андый авторларыбыз арасында Ә. Еники, Г. Бәширов, Г. Ахунов, М. Зарипов, М. Юныс, Ә. Гаффар, А. Хәлим, М. Галиев, М. Мөлеков, Җ. Рәхимов, Ф. Латыйпов, Р. Хисмәтуллин, А. Хәсәнов, Р. Фәизов һ.б. бар. Инде килеп, ниһаять, хәзинәбездә булган кайбер чәчмә әсәрләргә әйләнеп кайтыйк.



*Журналның яңа саны турында фикер алышу. 1991*

Рабит Батулла «Сөембикә» дигән тарихи романын безгә тәкъдим итте. Мәшһүр язучы М. Мәһдиев исә истәлек-повестенда үзе кичергән шактый гыйбрәтле хәлләрне бәян итә. Җәмәгать эшлеклесе, язучы Р. Мөхәммәдиев зур тарихи шәхесебез М. Солтангалиев хакында романын тәкъдим итмәкче...

Әйе, әдипләребез элеккеге кебек уңай герой, чиста производство, авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланган әсәрләр өстендә генә «иҗат газабы» кичермиләр хәзер. Халык язмышы, кеше шәхесе турында уйланалар. Бу алдагы елларда дөнья күрәчәк башка әсәрләрдә дә — Г. Ахуновның «Гомер юлы» (сукырлар арасында), А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога», Н. Фәттахның «Хыял вә хәят», Ф. Садриевның «Адәм әүлиясы» исемле роман, повестьларында да ачык ук чагылыр дип уйлыйм.

Миңа калса, бу дәвердә — дөньяны рухи чистарту зарур заманда — поэзия аерым игътибарга лаек. Укучыларыбыз З. Мансурның «Хозыр Ильяс», Р. Зәйдуллинның «Матәм», Ә. Рәшитовның «Кол Шәриф» поэмаларын, танылган шагыйрьләр Н. Арслан, Г. Афзал, И. Юзеев, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Г. Моратов һәм башкаларның шигырьләрен укып уйланырлар.

Шулай ук киләсе ел журнал сәхифәләрендә М. Зәкиев, Ә. Кәримуллин, М. Мәхмүтов, Т. Галиуллин, Р. Мостафин, Ә. Хәйруллин кебек белгеч-галимнәрнең тарихка, әдәбият фәненә караган кызыклы һәм гыйбрәтле хезмәтләрен дә очрата алырсыз.

Әйткәнемчә, бүгенге әдәби үсеш-үзгәрешне күрсәтүгә йөз тоткан хәлдә, мирасыбызга да игътибарны арттырырга уйлыйбыз. Аерым алганда әдәбиятыбыз классигы Г. Исхакыйның «Көз» повестен, Г. Ибраһимовның хәзерге имляда дөнья күрмәгән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» исемле хезмәтен, С. Җәләлнең «Дим буенда» дигән әсәрен бастырып чыгаруны күздә тотабыз. Бу уңайдан шуны да искәртеп узыйк. Халкыбызның таралу нисбәтенчә, авторларыбыз да төрле кыйтгалардан: Татарстан, Россия, Үзбәкстан, Казакъстан...

**— Равил әфәнде, сезнең сөйләгәннәрдән күз алдыма китереп торам: әдәби журналыбыз алдагы елда да бик тә эчтәлекле, мәгънә ягыннан тирән әсәрләрдән торачак икән. Аларны укырга теләүчеләр, ягъни журналга язылучылар күп булырмы соң?**

— Әйе, бик тә актуаль мәсьәлә бу. Шулай да мин үзем күңелем белән тыныч: безнең халык бу сынауны да җиңеп чыгар. 4—5 гасыр эчендә безнең ыру-токым — халык мондыйларны гына кичермәгәнме? Шулай да гайре табигый вә-

газь булмасын, бу уңайдан минем мөхтәрәм кардәшләремә, журнал алдыручыларга, укучыларга чын күңелдән әйтер сүзләрем бар. Бу, илдәге гаять катлаулы икътисади һәм сәяси шартлардан һәм үзебезнең реаль хәлләрдән чыга. Белгәнебезчә, экономик әзләнү, базар мөнәсәбәтләренә күчү чоры бәяләрнең тотрыксызлыгына, акчаның кыйммәтсезләнүенә китерде. Бу хәл безнең журнал язмышына да тискәре йогынты ясамый калмады, әлбәттә.

1991 елдан кәгазь бәяләре, мәсәлән, уртача 80 процентка арта. Элемтә оешмалары шулай ук журналны тараткан өчен түләүне берничә мәртәбә арттыруны таләп итә. Шуның өстенә типография чыгымнары да сизелерлек күтәрелде. Болар барысы да безнең журналның финанс хәлен катлауландырды, аның язмышын куркыныч астына куйды. Эш шунда, әгәр без журнал бәясен гамәлдәгечә калдырсак, подпискадан кергән акча аны бастыру һәм тарату чыгымнарын каплауга да җитмәячәк. Почта чыгымнарына гына да якынча ярты миллион сум кирәклеге мәгълүм булды. Ә яңа шартларда үз-үзен финанс ягыннан тәэмин итә алмаган басмаларның яшәү мөмкинлеге шик астында.

Газиз кардәшләребез! 70 елга якын халкыбызга хезмәт итеп килгән, рухи дөньябызны баету, милли үзаңны уяту юлында армый-талмый эшләгән, юл башында Г. Ибраһимов кебек бөек шәхесләр торган журналыбызны исән калдыру өчен, киләчәктә дә аның утлары күңел йолдызы булып балкысын өчен, безгә сезнең ярдәмегез кирәк.

Тарихи язмыш тәкъдирендә безнең халык гомер бакый диярлек яшәештә, бигрәк тә мәгърифәт, мәдәният өлкәсендә, фәкать үз хәләл көченә таянган, үз иманына инанып, үз өмет йолдызына ышанып хәят кичергән. Хәзер, ниһаять, Татарстан үзенең дәүләт мөстәкыйльлеген игълан иткәч, изге максатыбызга ирешү юлында алга таба да нык һәм бердәм була алсак, хәлләребез күп тапкырга яхшырыр дип ышанабыз.

*1990, октябрь*

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — БЕЗНЕҢ ЮЛ

«Казан утлары»на 70 ел.

Үз вакытында аның 50 еллык юбилее уздырылды, 60 еллыгы... Менә хәзер — 70 еллыгы... Журналыбызның чишмә башы булып 1922 елда чыга башлаган «Безнең юл» санала. Соңгы елларга кадәр татар телендәге бердәнбер калын әдәби журнал булып килгән басмабыз тарихын, шулай итеп, гражданнар сугышы басылып, совет хакимияте ныклабрак урнашкан, әмма чын милли матбага сүлпәнәярәк төшкән бер дәвердән башлыйлар. Ә бит ныклабрак уйлап карасаң, татар халкының әдәби-сәяси журналлар чыгару тарихы еракка-рак — гасыр башына — «Әлгасрелҗәдид», «Шура», «Аң» кебек басмаларга барып тоташа. «Казан утлары» журналын аларның варисы, дәвамчысы итеп санасак, бәлки, 70 еллык урынына 90 еллык юбилеен үткәрү дөресрәк булыр иде. Ә инде милли журналлар яралгысы рәвешендә үткән гасырның икенче яртысында ук чыга башлаган татар календарьларын да игътибарга алсак, әлеге санны 100дән дә өскәрәк үстереп булыр иде. Хәер, юбилей санын түгәрәгрәк, саллырак күрү теләге үзмаксат түгел. Журналыбызның 70 еллык гомере дә халыкның иҗтимагый-эстетик фикер үсеше, әдәбият һәм мәдәниятебезнең үткән юлы турында анализ ясап җитди уйланырлык һәм, ниһаять, бәйрәми хис белән юбилей итеп үткәрерлек олы вакыйга.




70 ел тарих өчен бер мизгел генә булса да, адәм балалары хәятында өч буын алышынырлык озын гомер бит ул! Бер кояш астында янәшә-күрше яшәүче халыклар белән уртак язмыш үтеп, безнең татар халкы да ниләр генә кичермәде дә, нинди генә сынаулар үтмәде бу гомер эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; аклар, кызылларга аеры-

лып пычакка пычак килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләрендә нәсел-ыру белән кырылулар да; яңаны төзим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, диннәр белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имляларны кат-кат алыштыра-алыштыра кыйбласыз, имансыз калулар да; сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре «шөреп-винт» хәленә калып, миллионнарның яуларда, лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм халык мәнфәгате белән исәпләшмичә, җир-суны мәсхәрә итеп «бөек-бөек» төзелешләр, хәрби-промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял-коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кыла-кыла, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә... һәммәсе, һәммәсе булган бу дәвердә!

Әлбәттә, гел фаҗига-хаталардан гына тормаган дөнья. Тормышның нигез максаты барыбер — тәрәккыят. Хыял-өмет, сөю-сәгадәт, идеал яшәткән кешене. Гомер маягы булган әнә шул идеалын, мирас һәм васыять итеп, баласы күңеленә салырга тырышкан. Якты киләчәккә, ирекккә омтылыш, буыннардан буыннарга күчеп, һаман үскән, яңарган, көчәйгән генә.

Тарих — канлымы ул, шанлымы — барыбер халык хәтеренә чигелә барган. Телефон-радио яңа керә башлаган, телевидение дигәннәренең әле эзе дә булмаган ул ерак елларда әлеге тарих кайда чигелеп, чор-дәвер кардиограммасы кайда сурәтләнеп калган соң? Әлбәттә, беренче нәүбәттә, басма сүздә. Китапларда, гәзит-журналларда. Һәр басманың, һәр журналның үз биографиясе, үз язмышы. Мәгълүм нәрсә: гасыр башында — халык рухының көчле бер уяну чорында — татарча байтак журналлар чыгып алган. Өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә, хатын-кыз өчен дә... Диниләре дә, һөҗүлекөлкеләре дә... 20 нче еллардан соң да, бик нык идеологияләштерелгән булса да, милли матбугатыбыз тарихында янә бер күтәрелеш булып алган. Әмма бу хәл озакка бармаган шул. Репрессия еллары башланган, сугышлар кабынып киткән. Кайбер журналлар туктап кала, кайберләрен ябалар... «Казан утлары»ның бәхете шунда: язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды.

Архив исе сеңгән журнал төпләмәләрен карап утырам. «Казан утлары» 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. Утызынчы

елдан икегә бүленеп, «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет Язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат Язучылары ассоциациясе органы) исемнәре белән басылган. Ә 1933 елдан 1965 елга кадәр — «Совет әдәбияты», ә соңгы дистә елларда хәзерге «Казан утлары» атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма комитеты һәм халык комиссарлары Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКП(б)-ның Татарстан өлкә комитеты, Совет Язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты, редакциянең хезмәт коллективы...), титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да һәм редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торды. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып киленде — «әдәби» һәм «иҗтимагый». Ягъни иҗтимагый әһәмияткә ия булган иң яхшы нәфис әсәрләрне бастыручы әдәби журнал ул — «Казан утлары».

Әдәбиятыбызның, гомумән, мәдәниятебезнең елъязмасы, тарихи көзгесе. Алай гына түгел, журналыбыз язмышы халык язмышы белән тәңгәл булды диясе килә. Юкса ачлытуклы елларда да, илне «боз суккан» чорларда да халык аны саклап калыр идеме соң? Сугыш кырларында иң кадерле хатлар белән бергә поход сумкаларында йөртерләр идеме аны? Котып тарафларында яки чүлле Караком якларында, шахта баракларында яки тайга киңлекләрендә меңләгән укучылар, туган як сәламе һәм ана телебез аһәңе итеп, зарыгып көтеп алырлар идеме? Ә инде балачакта ук үзен әдәбиятка багышларга, гәзиттә йә журналда беренче нәни мәкаләсен яки шигырен бастырырга хыялланган яшь җаннар өчен «Казан утлары»ның бәһасен әйтеп тә торасы юктыр...

Сүз — изгелек кылыр өчен яратылган, диләр. Бәхәсле булса да, бу гыйбарәгә ышанасы килә. Кешелекнең бөек ядкәрләре — Коръәнме ул, Библия яки Инҗилме — «дөньяда яманлык кылма, изгелек кыл» дигән рух белән сугарылмаганнармыни? Әгәр Сүз, чыннан да, изге икән, төп коралы Сүз булган язучы кеше дә изге максатка — Хакыйкатькә, Әхлакка, Матурлыкка хезмәт итәргә тиештер бит. Язган һәр әсәр

дә, һәр китап та, күмәк әдипләр чыгарган әдәби басма да... Бүген без юбиляр журналыбызның абруен никадәр генә күтәрергә тырышсак та, нихәл итмәк кирәк, адәм хатадан хали булмаган кебек, аның да ялгышлары, хаклык юлыннан тайпылулары да булгалаган. Гуманизм критерийларына, эстетик идеалларга хыянәт иткән сәхифәләр дә очраштыргалый журнал битләрендә. Олы талант ияләрен буржуа ялчылары дип бәяләүләр дә, чын милләт хадимнәрен «халык дошманнары» итеп фаш итүләр дә, «оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көрәш»ләр дә, коммунизмга алып баручы «юлбашчы»ларга мәдхия укулар да, АЭСларга дан җырлаулар да... Әмма 70 ел эчендә шактый калын (үзенчә җыелма бер томлык китап!) басма булып дөнья күргән 835 санның (барлык тиражын җыйсаң, үзе бер зур тау булыр иде!) дәрәҗәсен һәм кыйммәтен әле әйтеп узган саташулар билгелиме соң? Һич юк, әлбәттә. Соңгы 60—70 ел эчендә бар булган иң күренекле әсәрләребез нәкъ менә шушы журналда дөнья күрде, укучыларга, халыкка барып ирешге. Сугыштан соңгы әдәби хәзинәбезгә карата бу фикер бигрәк тә рас килә. Йә, шушы журналга мөнәсәбәте булмаган яки әсәрен анда бастыруны дәрәҗә санамаган берәр татар әдибен табып була микән? Яки «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә иҗат мәйданында танылу алган берәр яшь язучы булдымы икән? Бу урында, бәлки, журнал тарихын бизәп калдырган әсәрләрне санап, авторларның исемнәрен тезеп үтү дә урынлы булыр иде. Дөресен әйтим, очына чыга алмам дип куркам. (Шунысы да бар: моннан 20—30 яки 10—15 ел элек классик саналган кайбер әсәрләр тоныкланып йә бөтенләй онытылып калды бу демократия чорында; яки киресенчә, тоталитар режим вакытында тыелган йә күләгәдә калганнары яңа яңгыраш, танылу алды. Һәрхәлдә, әсәр исемнәрен санау — шактый четерекле шөгыль.) Төрле жанрлардан, кечерәк күләмлеләрен дә кертеп исәпләсәң, меңәрләгән бит алар! Язышкан авторлар, табигый, тагын да күбрәк чыгачак. Шикләнмичә әйтә алам: и укучым, татар әдәбиятының нинди әсәре күңелегезгә яктылык һәм изгелек иңдереп калган булса, ул иң әүвәл безнең журналда басылган булыр.

Журнал — рухыбызның тарихи елъязмасы, дидек. Әйе, бу чынлап та шулай. 70 ел буена тоташ, сугыш елларында да өзелмичә чыгып килгән бердәнбер журнал, дидек. Әйе, бусы да шулай. Әмма бөтен бер халыкның гомуми мәдәнияте өчен бер генә басмасы булуы сөенеч түгел шул. Шуңа күрә дә журналга төрле тармакларга «таралып җигелергә» туры килә. Нәфис әдәбияттан тыш, мисалга фән дөньясын гына

алыйк: гуманитар өлкәдә, бигрәк тә әдәбият, тарих, тел белеме фәннәрендә берничә академигыбыз, йөзләгән фән кандидатлары һәм докторларыбыз бар икән, аларның күбесе шушы журналда язышып, хезмәтләрен бастырып гыйлем үрләрен яуладылар. Аяныч, әле моңарчы театр, музыка, рәсем сәнгате, гомумән, мәдәният тарихы буенча махсус басмаларыбыз булмады диярлек. Шуңа күрә рәссамнар, композиторлар, артистлар иҗаты турында да журналда шактый мул урын биреп киленде. Безнең республика шартларында бу вазифаны үтәүне журнал үзенең бурычы дип санады һәм хәзер дә шул фикердә тора.

Табигый ки, бер генә халык та фәкать үз кабыгында, үз биләмәсендә генә яшәп тәрәккыяткә ирешә алмый. Шуны истә тотып, журнал чит ил һәм күрше-тирә кардәш халыклар әдәбиятының гомумкешелеккә, гуманизмга хезмәт итә торган иң яхшы үрнәкләрен дә даими яктыртып килә.

Илнең тарихи үзгәрешләр кичерүе, ачыктан-ачык сөйләшү заманы килүе — күп гасырлык рухи мирасыбыз, аны тудырган мәшһүр талантлар турында курыкмыйча дөресен язарга мөмкинлек бирде. Татар тарихы бик бай, дөньялыкта тирән эз калдырган шәхесләр күп — әллә ничә басмаларга җитәрлек. Халык иҗаты үрнәкләреннән күпмедер дәвер онытылып торган җыр-бәетләр, поэма-дастаннар дисеңме; үз вакытында чит илләрдә басылып та, бездә дөнья күрмәгән гыйльми-тарихи хезмәтләр дисеңме; яшерен фондларда сакланган, әмма безгә әлегә мәгълүм булмаган архив документлары дисеңме... Боларны халыкка ирештерү — журналның киләчәктә башкарырга тиешле мөһим эшләренең берсе.

Даими укучыларыбыз белә булыр — моңарчы килгән күркәм традицияләрне дәвам итү белән бергә, яңа рубрикалар ачылды: «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы», «Мәдәниятебез тарихыннан», «Әдәби мирас», «Остаханә», «Тарихи шәхесләр», «Мәгърифәт төбәкләрендә» һ.б. Милләтебезнең бүгенге көне һәм киләчәге, гореф-гадәтләребез, туган телебез язмышы һәрвакыт игътибар үзәгендә. Журналда Коръәннән сүрәләр, гарәп һәм латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре, яшьләр иҗатыннан үрнәкләр, драма әсәрләре, сәнгать сәхифәләренә дә киң урын бирелә.

Журналның 1922 елда чыккан башлангыч саннарның берсендә редакциянең әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә юллаган мөрәҗәгатендә мондый юллар бар: «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә — Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзе-

нә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке Идел-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде... Эшче-крестьян гаммәсенең азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар иде».

Моннан 70 ел элек чыккан мөрәҗәгать, күрәсездер, бүген дә актуаль яңгырый. Шуны истән чыгармыйк: «Казан утлары» — бүгенге Татарстан җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең журналы гына түгел, ә бөтентатар халкы журналы. Тиражыбызның яртылабы Татарстаннан тыш төбәкләрдә һәм чит илләрдә таралуы шуны раслый. Соңгы елларда без кичерә торган сәяси һәм икътисади үзгәрешләр, дистә еллар буе үзенчә хәрәкәттә булган дәүләт структураларының тотрыксызлыгы яки җимерелүе — журналыбыз язмышында, бигрәк тә аның таралуы (яздырып алдыру) процессында чагылыш тапмый калмый. Республикалар тулы мөстәкыйльлек алып, аерымланган заманда, бәһа һәм акчалар төрлелеге чорында, шактый очсыз бәягә, элеккеге СССР территориясендәге теләсә нинди почта бүлегендә журналга җиңел генә языла алды булмастыр хәзер. Шулай да оптимист булыйк, «тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигәндәй, эштә тырыш, уйда зирәк, коммерциягә маһир халкыбыз бу авыр ситуациядән чыгу җаен тапмый калмас. Куйган ачык максат, журналга нык ышаныч булса — югалмабыз. Татарстаннан читтә ана телебездә милли басмаларыбызны укучы һәр кеше кадерле безгә. Әлбәттә, редакция үзе дә укучыларына тагын да якынаю юлларын эзләячәк, төрле регионнарда журнал тарату постларын булдырачак, рекламалауның нәтиҗәле чараларын күрәчәк.

Журналның үткәне турында зур сүзләр сөйләү, киләчәккә олы максатлар кую, алда торган проблемаларны хәл итү юлларын билгеләү һәм башка оештыру эшләре белән мавыгып, безгә кадәр журналны чыгарган фидакарь кешеләрне онытсак, алда әйтелгән 835 санны әзерләүдә катнашкан меңләгән хезмәттәшләребезне искә алмасак, без ихтирамга лаек булмабыз. Кем булып эшләсә дә — типографиядә хәреф җыючымы, әллә баш мөхәррирме, бүлек мөдире яки корректормы, машинисткамы, җаваплы сәркатипме, редколлегия әгъзасы йә хисапчымы, бүгенге яшь хезмәттәшебезме яки ветеранмы, исәнме, әллә гүр иясеме — барыбер — барчагызга-барчагызга олуг рәхмәт! Сезсез журнал тарихы булмас иде, Сезсез бүгенгебез булмас иде.

Журнал юбилее уңае белән үз-үзебезгә, ягъни әдипләребез колагына да, берничә сүз әйтми калып булмый. Яшермик, күбебез бүгенгә көнгә кадәр иске рух һәм күнегелгән алым белән, инерция белән язып ята. «Җаныңның ваклыгын заманга сылтап», денем өчен түгел, көнем өчен, дип язганнар белән халык тарихын язып булмый. Конъюнктур максат куеп, тема актуальлеге белән генә киң аренага чыгу көннәре үтте. Шикаятьләр яки «югарыдан» шылтыраттырып йогынты ясау заманнары бетте. Әгәр әсәрең талантсыз икән, «мин фәлән елдан язучылар таныклыгы йөртәм», «фәлән елдан бирле басылганым юк» кебек наив аргументлар көчсез хәзер. Моны һәммәбез ачык аңлыйк. Заман куйган таләп зур, югары. Гомумкешелек ирешкән фәлсәфи-эстетик югарылыкны яулап кына, үз халкыңа игелекле хезмәт итеп, милләтеңнең рухын, зурлыгын дөньяга күрсәтә алырбыз. Онытмыйк: без бүгенге көн һәм XXI гасыр кешеләре өчен иҗат итәбез.

Соңгы елларда без шактый ишәйсәк тә, сан сыйфатка күчте дип кистереп әйтә алмыйбыз. Әгәр авыз тутырып, «Казан утлары» — бөтентатарның төп калын журналы, дип әйтәбез икән, исеме җисеменә туры килергә дә тиеш. Ягъни бөтен дөньяга таралган татар халкы тормышын күбрәк чагылдырырга, милләттәшләрне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында татарның үзенә лаек урынын алуда булышырга тиеш булабыз. Дөресен әйтергә кирәк, без әле күбрәк үзебез яши торган Идел буе төбәге турында гына язабыз. Соңгы елларда даими чыгып килә торган «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә» дигән рубрика әле әйтелгән берьяклылыкны бетереп, талантлы яңа әсәрләр хисабына тагын да үсәр, шәбәер дигән өметебез бар.

Татарстанның дәүләт бәйсезлеген яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруга өлеш кертүне журнал иң җаваплы бурычларының берсе дип саный. «Казан утлары»ның 70 еллыгы — Татарстанның мөстәкыйльлеге — республикадагы халыкларның күмәк тавыш бирү, ягъни референдум белән ныгытылган, расланган елына туры килде. Якын көннәрдә Бөтендөнья татар конгрессы ачылачак. Референдум юлы белән бәйсезлек яулап алу, бөтендөнья татарлары җыены үткәрү — болар халкыбыз тарихында моңарчы булмаган тарихи вакыйгалар. Киләчәккә өметебез һәм ышанычыбыз зур. «Казан утлары» — зур тәҗрибәгә һәм якты сәхифәләргә ия булган мөхтәрәм басма — иншалла, халкыбызның XXI гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булыр.

*1992, март*

# РУХИ ЕЛЪЯЗМАБЫЗ

Гасыр ахыры җиткәндә төрле фаразлаулар күбәя, диләр. Моннан йөз ел элек — ул чор өчен милләт буларак тәмам формалашкан татар халкының зыялы акыл ияләре безнең бүгенге хәятны ничек күз алдына китергәннәрдер, тәгаен әйтүе кыен. Әмма шунсы билгеле: берәүләр татарга инкыйраз юраган, икенчеләре үсеш-тәрәккыяткә ымсындырган. XX гасырда безнең милләт бәддогалы махмырны да, хыялый өметне дә мулдан татып яшәде шикелле...

Журналыбызның нәүбәттәге юбилей бәйрәмен әзерләгәндә, архив исе сеңгән төпләмәләрне актарганда, каләмдәшләр һәм хезмәттәшләр белән үзара әңгәмәләшкәндә, безнең күңелләрдә дә еш кына сорау катыш шомлы уйлар өермәсе бөтерелеп ала. Тагын йөз елдан әдәбиятыбыз нинди хәлдә булыр? Ана телебездәге матбугат нишләр? Галәми катаклизмнар, «ахырзаман» гарасатлары чыгып, бүген без күз нурын түгеп чыгарган гәзит-журналлар, китаплар көлгә яки тузанга әйләнеп юкка чыкмасмы?..

Без, быел «Казан утлары» журналына 75 ел тулды, дибез. Әмма бу — шартлы дата. 75 саны татар әдәби журналларының тик совет дәверен генә үз кысасына ала. Әгәр дә без хисап өчын гасыр башында чыга башлаган «Әлгасрел-




*«Казан утлары»ның 70 еллык бәйрәменә багышлап уткәрелгән җыелыштан бер күренеш*

җәдид», «Шура», «Аң» басмаларыннан санасак, татар әдәби-иҗтимагый журналының чыга башлавы 100 елга якынлашыр. Ә инде милли журналлар яралгысы рәвешендә үткән гасырның икенче яртысында ук чыга башлаган татар календарьларын да игътибарга алсак, тарихи офык тагын бик күпкә ерагаер иде.

Гадәттә, «Казан утлары»н — татар халкының баш журналы дип әйтәләр. Төптән уйлап карасаң, дөрес бәяләмә бу. Ничә дистә еллар буе совет халыкларының әдәбияты һәм сәнгате көннән-көн чәчәк ата дип әйтелсә дә (дөрес, кайбер милләтләр өчен хосусан шулай булды да ул), безнең ни фән, ни сәнгать, ни музыка, ни тарих буенча аерым журнал-гәзитләребез булмады диярлек. (Гәрчә китап чыгару буенча инкыйлабка кадәр Рәсәй империясендә иң алдынгы урыннарда торсак та.) Шуңа күрә әдәбият-сәнгать, театр-музыка, фән һәм иҗтимагый фикер буенча ирешкән казанышларыбызны шушы журнал, хәл кадәри үзендә урын биреп, халкыбызга җиткерә килде. Тоталитар режимның «тимер пәрдәле» елларында да, алдыру мөмкинлеге бик чикләнгән булса да, чит төбәкләрдә һәм мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә шушы журнал аша татар халкының рухи тормышы турында беркадәр мәгълүмат ирешә алды. Шуңа күрә дә «Казаң утлары»н — XX гасыр дәвамында татар халкының рухи дөньясын: тарихын, әдәбиятын, сәнгатен чагылдырган энциклопедик басма дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Үткәне һәм киләчәге турында тулырак күзаллап булсын өчен, журнал шәҗәрәсенең бүгенгә караган кайбер контурларын анкета рәвешендә шәрехләп китик. Бу мәгълүматлар укучыларыбызның зиһененә кереп калса, аларның һич тә зыяны булмастыр:

— Журнал 16 басма табак күләмендә (400 битле уртача форматтагы китап чамасында) һәр ай саен даими чыгып килә. Журнал редакциясендә, техник хезмәткәрләрне дә кертеп, нибары дистә ярым кеше эшли.

— Журнал дөньяның барлык кыйтгаларында диярлек тарала (Россия, БДБ илләре, АКШ, Алмания, Финляндия, Төркия, Франция, Япония, Австралия һ.б.). Тиражы — элеккеге СССР, хәзерге Россиянең төп әдәби журналлары — «Новый мир», «Дружба народов» журналлары белән бер дәрәҗәдә.

— «Татар энциклопедиясенә кергән совет дәвере язучыларының һәммәсе диярлек «Казан утлары»нда иҗади хезмәттәшлек иткән. Бүген дә редакциядә күренекле язучылар, шагыйрьләр, әдипләр эшли.

— Бу елның ахырында журналның 900 нче саны дөнья

күрәчәк. Әгәр 75 ел буена уртача тираж айга 20 мең булган дип исәпләсәк тә (журналның тиражы 100 меңнән арткан чорлар да булды), җәмгысы 20 млн. данәгә якын булыр.

— Бүгенгесе көндә журналның дүрттән бере (элегрәк — өчтән икесе иде) Татарстаннан читтә тарала. Татарстанда «Казан утлары»н иң күп алдырган районнар — Актаныш, Саба, Арча, Әлмәт, Азнакай...

— «Казан утлары»н оештыручылар һәм чыгаручылар: Татарстан Министрлар Кабинеты, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы. Журнал Татарстан хөкүмәте биргән һәм әбүнәчеләрдән кергән акча хисабына чыгарыла.

— Матбугатка язылу мәгълүматларына караганда, быел «Казан утлары» журналына язылучыларның саны 2 меңгә артты.

Әйе, гомумән алганда, хәлебез бүгенгә шөкрана итәрлек. Журналның иҗтимагый абруе шактый югары. Редакция даирәсенә татар әдәбиятының төп интеллектуаль көчләре — иң талантлы әдипләре тупланган. Тиражы — алда әйтелгәнчә — чагыштырмача югары, димәк, яздырып алучылар, укучылар ишле. Редакциянең хезмәт коллективы да уртак максатны аңлауда бердәм, тырыш...

Һәм, мөгаен, иң мөһиме, кулъязма хәзинәбездә сайлап алырлык әсәрләр күп... Болары — бүген. Хәзерге юбилей елында. Миңа калса, һәр истәлекле дата, һәр тантана, шул исәптән безнең 75 еллык та, күкрәк сугып мактану яки канәгать тынычланудан бигрәк, киләчәк язмыш турында җитдирәк уйланыр өчен бер уңай форсат бит ул. Ә уйланыр өчен сәбәпләр җитәрлек. Елганың төп агымы — фарватерны яхшы белгән лоцман кебек, без дә үзенә күрә әдәби диспетчерлык вахтасында. Татар әдипләренең каләме эзе дә суынмаган өр-яңа әсәре иң әүвәл безгә керә. Әсәрләрнең «биографиясен һәм анатомиясен» өйрәнгәндә, анализ-күзәтүләрдән соң билгеле бер нәтиҗәләргә дә юлыгасың. Кайберләре белән уртаклашып узыйк.

— Татар халкы күпләп яши торган ерак төбәкләрдән ана телебездә иҗат итүче перспективалы яшь авторлар соңгы елларда килми диярлек. Авторларыбыз, нигездә, Татарстанда һәм Башкортстанда туып үскән кешеләр.

— Әдәбиятка килүче яшьләр туган телебез мөмкинлекләрен бар куәтендә файдалана алмый, дөресрәге, тел мирасын тиешенчә белми. Аларның күбесе халык авыз иҗатында тәрбияләнеп үсмәгән... Шиксез, 50–60 нчы елларда татар мәктәпләренең тоташ диярлек ябылып, урыс теллелеккә күчүнең «уңай нәтиҗәләре» бу. Соңгы 5–6 ел эчендә мәгариф

өлкәсендәге уңай үзгәрешләр күңелдә өметләр уята уятуын. Бәлки, халкыбыз яши торган ерак төбәкләрдән дә яңа талантлар калкып чыгар? Ир-егет яшьләрнең күбрәк килүен көтә әдәби мәйдан. Талантлы, булдыклы егетләрне әлегә коммерция «йотып» бара. Соңгы елларда каләм хезмәтенә күбрәк кыз балаларның гына тартылуы да табигый ук түгел.

— Әдәбиятның төп жанры саналган прозаның киләчәге дә уйландыра. Киң эпик планда «мамыклы» итеп яза белгән өлкән буыннар әкренләп арабыздан китеп бара... Сирәкләнгән сафларны тутырырлык лаек алмаш бүген үк бар, әзер, дип кистереп әйтү кыен.

— Гомумән, соңгы елларда әдәби хезмәтнең абруе кимеде. Язучы хезмәтенең түбән бәяләнүе бер күңелсез хәл булса, иң авыры — иҗатчының иҗтимагый бәясе төште, ягъни нәфис сүз сәнгатенә ихтыяҗ кимеде. Максатларны, хыялларны кискән рухи кризис шаһитлары без бүген.

Кыскасы, хәлләр бар Әдәби Йортыбызда. Хәер, бездә генә түгел, бүтән халык әдәбиятларында да шундый ук борчулы мәсьәләләр... Юбилеебыз турында янә искә төшереп, бу очракта алар турында әлегә җитеп торыр. Уйланган уйланыр.

Гомумән, уйлану-борчылу, сынау һәм сыналу чорында яшибез. Ныклыкта, максатка тугрылыкта, иманда сыналабыз. Заман нурланышында һәм хәрәкәтендә һәркемнең асылы — кемнең кемлеге бик ачык чагыла. Кемнәр кемгә генә әйләнеп бетмәде бу чорда! Матбугатта да шул ук хәл. Нинди генә гәзит-журналлар, нинди генә басмалар чыкмады бу соңгы елларда! Дөресен әйтергә кирәк: байтагы укучылар күңелен яуламак булып, искерәк атама белән әйтсәк, «бульвар яки вульгар» басмалар булып киттеләр... Бу яктан, шөкер, «Казан утлары», үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча, очсыз рекламадан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, халкыбызның әхлак кодексына лаек әдәби-академик журнал статусын саклап кала алды.

Тагын бер нәрсәне ассызыклап үтик: әдәби генә түгел, иҗтимагый һәм сәяси басма буларак, «Казан утлары»ның төп бурычларының берсе — Татарстанның дәүләт бәйсезлеген яклау, ныгыту, аны тормышка ашыруга өлеш кертү. Моны без уртак стратегик максатка хезмәт итү дип саныйбыз. Казан — бөтен дөньяга сибелгән татар балаларының өмет кыйбласы. Әгәр без «Казан утлары»н — бөтентатарның төп калын журналы дип әйтәбез икән, исеме җисеменә туры да килергә тиеш. Ягъни төрле кыйтгаларга таралган татар халкы тормышын объектив анализлап, активрак чагылдырырга,

милләттәшләребезне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында халыкның үзенә лаек урынын алуда булышырга тиеш булабыз. Моннан дүрт гасыр ярым элек үзенең дәүләтен югалткан безнең халык тарихында, аның рух дөньясында Әдәбият үзгә бер миссиягә ия булып килгән: ул, рәсми беткән, ә көнделә гомер бакый яшәп килгән ил-дәүләт эшләргә тиеш булган кайбер рухи функцияләрне үти алган. (Безнең шартларда әдәбиятны югалту халыкны югалтуга бәрабәр иде.) Чөнки Әдәбият эчтән кумерләнеп көйрәп яткан Милли Берлек идеясенә сулыш өреп килгән, аны сүндермәгән һәм сүндермәячәк. Җәй ахырында үтәчәк Бөтендөнья татарларының II Конгрессы да бу фикернең дөреслеген раслар дип ышанабыз. Бөек шагыйрь Мөхәммәдъярның 500 еллыгы һәм безнең журналның 75 еллыгы бәйрәмнәре дә әлеге Конгресс программасының табигый бер сәхифәләре булачак.

*1997, апрель*

## БУ ГАСЫРДА ДА БАЛКЫР!

«Казан утлары» — татар халкының төп әдәби журналы. Бу җаваплы сүзне әйтер өчен тарихи җирлек, ныклы дәлил бар: журнал үткән катлаулы юл, аны чыгарган язучы-әдипләрнең көндәлек хезмәте һәм иҗаты, иң мөһиме, рухи елъязмабызны тәшкил иткән меңләгән әсәрләр моңа тулы мөмкинлек бирә.

«Казан утлары»—татар матбугатында аналогы булмаган бердәнбер әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. Ул үзенең яшәү дәверендә халкыбызның яраткан, һәрчак көтеп алынган журналы булды. Тәкъдиребезгә тигән нинди генә каһәрле чорларда да журнал төрле кыйтга-төбәкләргә сибелгән газиз халкыбыз өчен элек тә, хәзер дә дуслык, туганлык, тупланганлык, аралашу һәм аңлашу мәйданы булып кала алды.

80 яшь. Үткән заманнарны ретроспектив планда искә төшергәч, журналның башында торган, шушы басмада эшләп чыныгу, әсәрләре белән танылу алган кадерле исемнәрне дә хәтерләп узыйк. Мәгълүм булганча, журналның совет чорындагы дәверендә аның юлбашчысы булып бөек әдип Галимҗан Ибраһимов торган. Шушы журнал тирәсенә әдәбиятыбыз елъязмасында алтын хәрефләр белән язылып калган Һади Такташ, Гадел Кутуй, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан кебек әдипләребез тупланган. Журнал белән җитәкчелек итү эстафетасын Г. Гали, Ф. Сәйфи-Казанлылар дәвам иткән. Журналның «Совет әдәбияты» һәм «Казан утлары» чоры (бу чор 70ләп елны эченә ала!) каһарманнары, журналда эшләгән яки актив язышкан язучылар, шагыйрьләр—(ни кызганыч, алар инде арабызда юк; без аларны өлкән буын вәкилләре дип йөри идек. Хәзер инде без — 60 нчы елларда әдәбиятка килгәннәр — үзебез дә олыгаеп, үткән гасыр кешеләре булып барабыз...) Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Салих Баттал, Нури Арсланов, Әнвәр Давыдов, Нәби Дәүли, Атилла Расих, Ибраһим Салахов... Саналган һәр исем, һәр шәхес артында күпме иҗат, күпме язмыш!.. Ә исемлекне шактый озынга дәвам итеп булыр иде.

Бу урында моннан 30 ел элек «Казан утлары»ның 50 еллык юбилее уңае белән язылган Гази Кашшаф (озак еллар журналның баш редакторы булып эшләгән) язмасыннан бер өзек китереп узыйк: «Анда (журналда. — *Р. Ф.*) халыкның рухы салынган. Анда—халыкның иҗтимагый аң үсеше,

анда — халыкның матурлыкны тану һәм аны бәяли белү осталыгы, анда—аның әдәби-сәнгать зәвыгы, образлы сиземләү осталыгын үзләштерү баскычлары. Шуңа күрә дә матур әдәбият тарихын тикшерәсеңме, театр, музыка тарихына күз саласыңмы, рухи культура тарихына материаллар эзлисеңме — бу журналны читләтеп узу мөмкин түгел. Журналда басылган һәрбер язма аерым китап яки җыентыкларда тупланып басыла алмый. Шулай булгач, журнал тарихчылар өчен бердәнбер башлангыч чыганак».

Әйе, үткән турында язу (әгәр үтелгән юл мәгънәле һәм шанлы булса, бигрәк тә!) җиңелрәк. Чөнки буласы булган, анализланасы анализланган, Вакыт бәясе алынган... Ә киләчәк турында? Яшермим, журналыбызның бу юбилей санын әзерләгәндә, архив төпләмәләрен актарганда, каләмдәш-хезмәттәшләр белән әңгәмәләшкәндә, укучылар белән очрашканда, япа-ялгызың калганда, күңелгә еш кына сорау катыш шомлы уйлар да килә. Бу гасырда татар халкын ниләр көтә? Кояш астындагы хәятта туган телебездә сөйләшүчеләр күпме булыр? Бай мираслы әдәбиятыбызны кемнәр укыр? Матбугатыбыз нишләр? Галәми катаклизмнар—«ахырзаман» гарасатлары чыгып, яки глобаль бүлгәләнүләр нәтиҗәсендә аз санлы халыклар тәмам эреп-«тәңгәлләштерелеп» бетеп, бүген без күз нурларын түгеп чыгарган китаплар, газет-журналлар



*Журнал үзенең 80 яшьлек бәйрәмен үткәрә. Милли-мәдәни үзәк, 2002*

көлгә яки төтенгә әйләнеп юкка чыкмасмы? Уйлата торган замана! Ясалма акыл, компьютерлар заманасы, кешеләрне клонлаштыру заманасы, тулы бер китапханә уч төбенә сыешлы дискетларга кереп бетә алган, электрон почта, электрон газеталар заманасы... Генетик инерция яки саклану инстинкты беләнме, үз һөнәрең-эшең, хезмәтең нәтиҗәсе булган әдәби әсәр, китап, журнал, элеккечә әйтсәк «ташка басылган сүз» турында бик нык уйланасың. Бүтәнчәрәк, бераз рәсмирәк әйткәндә, язучы хезмәтенең хаҗәте, аның җәмгыятьтәге урыны турында уйланасың. Миңа калса, бу табигый халәт. Һәр истәлекле дата, бу очракта журналыбыз юбилее, күкрәк сугып мактану яки канәгать тынычланудан бигрәк, киләчәк язмыш турында җитдирәк фикер йөртер өчен бер форсат бит.

Хәзер әллә нинди басмаханәләрдә төрле телләрдә чыккан газет-журналлар, китап-альбомнар, реклам-буклетлар бихисап. Укучы гына булсын! Сер түгел: халыкны үзенә җәлеп итү «ярминкә»сендә басмалар арасында үзара ярыш шактый кызу: «кеше җаны өчен көрәш бара!» Замана биргән мөмкинлектән чыгып, кем ничек булдыра! — кемнәрдер түбән зәвыкка юнәлтелгән, хайвани инстинктларны «кытыклый» торган ярымдетектив, ярымпорнографик язмалар чыгара; кемнәрдер бүген дөнья чыгырын әйләндерүче рәсми һәм рәсми булмаган түрәләрнең, бүгенге байларның сурәтләрен басып, аларның яшәү рәвешләрен мактап көн күрә; кемнәрдер реклама-игъланнар дөньясында сәүдәгәрләр кубызына бии... Нишлисең, дөнья бу! Әмма, шушы уртак мохиттә яшәсәк тә, безнең журнал «чуар базарчылык әхлагы»ннан өстен калып, матбугатыбыз тормышында аерым бер абруйлы урын тота дип уйлыйбыз. Академик басма саналырлык журналыбызның халык язмышында үз миссиясе бар. Үзенең башлангычында — үткән гасыр башында нинди төп максат куйган булса, нигездә, ул хәзер дә шул ук курста. Язучылар, сәнгать әһелләре, галимнәр, гомумән, акыл ияләре иҗат иткән әсәрләр белән халыкка хезмәт итү — аның үзаңын үстерү, дәүләтчелек идеясен ныгыту, милләтнең рухи үсешен тәэмин итү, һәм, әлбәттә, югары әхлаклы, иманлы яшь буын тәрбияләү... Еллар, чорлар, дәверләр алышынуга карамастан, замана җилләрендә уңга-сулга ташланмыйча, олы максатка ирешү юлында тотрыклы бер юл белән бару — һәр басма өчен бәхет һәм дәрәҗә ул.

Ныклы ышаныч, тотрыклылык, әлбәттә, курс-максатның анык, стратегик-тактик планнарның дөрес булуына бәйле. Киңәшле эш таркалмас, ди халык. Журнал даими рәвештә

редколлегия әгъзалары — күренекле язучылар, галимнәр, дәүләт хезмәткәрләре, сәясәтчеләр белән киңәш утырышлары җыеп, киләчәктә башкарылачак гамәлләрне билгеле. Рухи тормышыбызның төп тармакларын эченә алган, безнең өчен мәсләк саналган кайбер нигез-принципларны, юнәлеш-рубрикаларны тезис рәвешендә генә булса да укучыларыбызга искәртеп узыйк. Менә алар:

— тарихы мең еллап исәпләнгән татар әдәбиятының күркәм традицияләрен дәвам итеп, бүгенге татар язучыларының иң яхшы әсәрләрен бастыру, шулай ук әдәби мирасыбызның бүгенге көн өчен гыйбрәтле сәхифәләре белән таныштыру;

— Татарстанның дәүләтчелеген яклау, ныгыту юлында эзлекле эшчәнлек алып бару; дәүләт теле буларак татар телен киң кулланышка кертү;

— Татарстанның дөньядагы роле, икътисады, социаль халәте турында язмалар белән беррәттән, Россия биләмәләрендә һәм чит илләрдәге татар хәяты белән укучыларны даими таныштыру; «XXI гасырда — татар халкы» рубрикасында күренекле галимнәрнең, сәясәтчеләрнең, әдипләрнең фикерләрен бәян итү;

— сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмауны истә тотып, традицияләрне дәвам итеп, театр, музыка, сынлы сәнгать казанышларын яктырту; сәнгать өлкәсендәге олуг шәхесләрнең иҗатлары турында язмалар урнаштыру;

— халкыбызның әхлагын, гореф-гадәтләрен саклау юнәлешендә максатчан эш алып бару; дин тәгълиматы турында гыйльми мәкаләләр, ислам әхлагы, дини бәйрәмнәр турында мәгълүматлар бирү;

— укучыларыбызны дөнья әдәбияты классикасының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру;

—әдәби алмаш тәрбияләүне күз уңында тотып, «Остаханә», «Яңа исемнәр» рубрикаларында яшь язучыларның иҗат үрнәкләрен дөньяга чыгару; чит төбәкләрдә туган телебездә иҗат итүче талант ияләренә аерым игътибар бирү;

— әдәби процессны барлап, үсеш тенденцияләрен ачыклап, әтрафлы тәнкыйть мәкаләләре бастыру, «Яңа китаплар» сәхифәсендә төрле нәшриятларда чыккан яңа китапларга рецензияләр һәм күзәтүләр оештыру;

— күренекле әдипләрнең юбилейларын, гомумән, татар дөньясындагы атаклы шәхесләрнең истәлекле даталарын билгеләп үтү; гарәп һәм латин имлясында уку үрнәкләре бирү; «Хроника» сәхифәсендә иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгаларын объектив һәм оператив яктырту...

Әлбәттә, чын тормыш беркайчан да язма канун кысаларына сыеп бетмәгән шикелле, журнал эшчәнлеге дә, табигый, югарыда саналган бүлем-юнәлешләр белән генә чикләнми. Заман үзенең яңа таләпләрен, яңа проблемаларын, яңа идеяләрен өстәп тора. Әйтик, Казан шәһәренең 1000 еллыгы ачыклангач, махсус рубрика булдырылды, Казан турында язмалар элегрәк үзагымда чыгарылса, хәзер бу темага язылган материаллар системалы төс алды.

Бүгенге көнгә журналның 955 саны чыкты. Димәк, тагын берничә елдан бу сан 1000 гә җитәчәк. Уйлап карыйк: журнал 16 басма табак күләмендә (уртача форматтагы 400 битле китап чамасы) чыга, әгәр 80 ел буена ай саен уртача 20 мең тираж белән (берничә мең белән дә, йөз меңнән артык булып та чыккан еллары да булган) басылган дип уйласак, җәмгысы 20 миллион данәгә якын булыр иде ул! Хыял белән һәммәсен бергә өйсәң, үзе бер хикмәтле тау, дөресрәге Хикмәт тавы күз алдына килә. Баштарак әйткәнчә, әйе, шулай булган, үзенә күрә яхшы булган, әмма бу инде үткән «булган»... Алга таба ни булыр?.. Миләребезне бертуктамый бораулап торган бер генә мәсьәләгә (ә мәсьәләләр күп!) тукталып үтим. Ул — журнал тарату проблемасы. 60 еллар ахырында басмабызның яртысыннан күбрәге Татарстаннан читтә тарала иде, ә хәзер булган тиражның алтыдан бере генә бүтән төбәкләргә чыга... Ул алтыдан бер дигәне дә, нигездә, Башкортстанга туры килә. СССР таркалды. Чикләр хасил булды. «Тимер пәрдә»не геополитик «челтәр» алыштырды. Болай да бердәмлеккә җитмәгән татарны яңа барлыкка килгән дәүләти аерымлык-статуслар тәмам таркатты (халык саны алу мәсьәләсендәге әкәмәтләрне исәпләмичә әле!). Шунысы ап-ачык: Советлар Союзы таркалгач (яшермим, моны ностальгия тойгысы белән әйтәм), Россиядәге милли сәясәтнең төп асылы беренче чиратта татарларга карата мөнәсәбәттә чагыла. Хезмәтен файдаланып көн күргәч, налог-салымын түләткәч, ул халыкның рухи ихтыяҗын кайгырту бик тә лазем ләбаса! — Тукай әйтмешли, «шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? — хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!» Күп нәрсә, әлбәттә, үзәкләшкән сәясәттән тора. Вакыт үтү белән сәясәт тә үзгәреп тора, вазгыять алышына, әмма, дөньяда нинди генә үзгәрешләр булса да, Казан — бөтен җиһанга сибелгән татар кешесенең Өмет Кыйбласы булып кала. Ә «Казан утлары» исә балкышын еракларга сипкән төп рухи учак. Гасырдан гасырга күчеп ул төрле кыйтгаларда яшәүче халкыбыз тормышын сүз сәнгатендә чагылдырып, милләттәшләребезне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөнья-

сында үзләренә лаек урынны дауларга булышып килә. Иншалла, киләчәктә дә шулай булыр. Шулай дип юаныйк!

80 елның яртысына якыны журналның «Казан утлары» исеме белән чыккан дәверенә туры килә. Бу инде безнең чор, 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән һәр әдип үткән гасырның икенче өлешен «минем чор!» дип әйтергә хаклыдыр. Шәхсән, бу үземә бик туры килә. Журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары»на күчкән 1965 елда мин шушы редакциядә эшли идем. Шул еллардан бирле бөтен әдәби язмышым теге яки бу рәвешле «Казан утлары» белән бәйле. Шигырьләрем йә мәкалә-язмаларым чыкмый калган ел булмады шикелле. Кырык еллап гомер эчендә байтак нәрсәләр онытылса да, анда эшләгән кешеләр, әдәбият елъязмасын бизәрлек әсәрләр «истә, һаман да истә». Шушы дәвердә журналны җитәкләгән баш мөхәррирләр: Рафаэль Мостафин (1965–1968), Зәки Нури (1969–1971), (1975–1983), Гариф Ахунов (1972–1974), Ренат Харис (1983–1989), 1989 елдан — Равил Фәйзуллин... Журналда бүлек редакторлары булып эшләгән каләмдәшләр: Әхсән Баян, Ләбибә Ихсанова, Яхъя Халитов, Вакыйф Нуруллин, Нури Арсланов, Малик Хәлитов, Фәрваз Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Хәмзә Зарипов, Гәрәй Рәхим, Ринат Мөхәммәдиев, Кояш Тимбикова, Мөдәррис Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Мансур Вәлиев, Зиннур Мансуров, Әхәт Гаффар, Флүс Латыйфи, Солтан Шәмси, Рашат Низами, Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмал, Җәүдәт Миңнуллин, Шамил Маннапов, Марсель Галиев, Тәүфикъ Әйди, Марс Шабаев, Наис Гамбәр, Камил Сәгъдәтшин, Мәгъсүм Хуҗин, Шаһинур Мостафин, Алмаз Гыймадиев, Факил Сафин, Камил Кәримов, Марат Закир...

Тулылыкка һич тә дәгъва кылмыйча шушы чорда басылган кайбер әсәрләр: «Туган ягым — яшел бишек» (Г. Бәширов), «Әйтелмәгән васыять» (Ә. Еники), «Чирмешән буйларында» (С. Баттал), «Ямашев» (А. Расих), «Этил суы ака торур» (Н. Фәттах), «Яшьлегемне эзлим» (Ә. Баянов), «Фронтовиклар» (М. Мәһдиев), «Идел кызы» (Г. Ахунов), «Җиләкле аланнар» (Р. Төхфәтуллин), «Биектә калу» (М. Юныс), «Яшьлегем утравы» (Ә. Маликов), «Язгы аҗаган» (М. Хәсәнов), «Тайгак кичү» (И. Салахов), «Иртеш таңнары» (Я. Зәнкиев), «Әткәм һөнәре» (Х. Сарьян), «Кубрат хан» (М. Хәбибуллин), «Безне өйдә көтәләр» (Х. Камал), «Йәгез, бер дога» (А. Гыйләҗев), «Бозкра» (Т. Әйди), «Батырша» (Җ. Рәхимов), «Шинельсез солдатлар» (В. Нуруллин), «Яшисе килә!» (Р. Вәлиев), «Җилкәннәрне җил еккач» (Ф. Яруллин), «Хыянәт» (Ф. Латыйфи), «Сират күпере» (Р. Мөхәммәдиев),

«Афәт» (Г. Тавлин), «Сөембикә» (Батулла), «Каргышлы этаплар» (Р. Кәрами), «Таң җиле» (Ф. Садриев), «Тәүбә» (Т. Галиуллин), «Болын» (Ф. Бәйрәмова), «Дөя муены» (М. Әмирханов), «Фидая» (М. Маликова), «Утлы бөҗра» (В. Имамов), «Ат каракләры» (З. Зәйнуллин), «Догалы еллар» (М. Галиев), «Ялгызак» (Р. Сибат), «Ком сәгате» (К. Кәримов), «Игезәкләр» (А. Тимергалин), «Албастылар» (Г. Гыйльманов), «Татар вакыты» (А. Хәлим), «Саташып аткан таң» (Ф. Сафин), «Терсәк сутышы» (З. Хөснияр)... Шуларга өстәп, С. Сабиров, М. Хуҗин, Б. Камал, Р. Фәизов, К. Тимбикова, Җ. Дәрзаманов, Ф. Яхин, Р. Зәйдулла, М. Закир һ. б. повесть һәм хикәяләре... Татар прозасының үзгә бер антологиясе бит бу әсәрләр! Ә шагыйрьләр? Күп гасырлык татар әдәбиятының нигезен алар салмаганмы? «Әдәбиятның Әнкәсе – гомердән Шигърият» дип тикмәгә генә тәкърарламыйбыз югыйсә! Көчле шигърият һәрвакыт әдәбиятны күрсәтеп килгән. Журналыбыз тарихында да ул шулай. Күпсанлы бик яхшы шигырь-поэма исемнәрен санап китәргә мөмкинлегебез юк, шагыйрьләрнең үзләрен, аларның да кайберләрен генә (бәгъзеләр, шәт, үпкәләмәсләр) искә алып үтик: Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Г. Афзал, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Ш. Галиев, Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, К. Сибгатуллин, Р. Харис, Ә. Рәшитов, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, М. Әгъләм, Г. Зәйнашева, Ф. Гыйззәтуллина, Х. Әюпов, Зөлфәт, К. Булатова, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Л. Шагыйрьҗан, Г. Морат, Р. Газизов, И. Гыйлаҗев, Г. Мөхәммәтшин; яшь авторлардан – Р. Әмәт, И. Иксанова, С. Гаффарова, Л. Янсуар... «Казан утлары»ның актив авторлары – драматурглар Х. Вахит, Т. Миңнуллин, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Д. Салихов, Р. Сәгъди... Публицист язучыларыбыз – М. Зарипов, Р. Хисмәтуллин, Ф. Дунай, М. Әхмәтҗанов... Мәшһүр язучылар, шагыйрьләр белән беррәттән, журналның редколлегия әгъзалары булып торган яки үзләренең мәкаләләре, рецензияләре, бәяләмәләре белән әдәби хәрәкәттә актив катнашкан күренекле галимнәр: Р. Нәфыйгов, Х. Госман, Н. Юзиев, М. Хәсәнов, Ә. Кәримуллин, Ә. Борһанов, Ф. Хатипов, Ф. Урманчиев, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин... Бүгенге редколлегия әгъзаларыннан – М. Госманов, М. Мәхмүтов, Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Х. Миңнегулов... Үзем кәгазьгә җанга якын кадерле исемнәрне тезәм, үзем ирексездән кайчандыр язылган шигырь юлларымны кабатлыйм: «Кемнәр бар да кемнәр юк!..», «Искән җил, үткән гомер, калган хәтер...»

Тыелган яки онытылган әдәби мирасны халыкка кире кайтаруда журнал эшчәнлеген әйтми узсак, язмабыз тулы булмас иде. Бер генә исемне аерып әйтү дә күп нәрсәне аңлата

булыр: бөек әдип Гаяз Исхакый. Аның төп зур әсәрләре бүгенге укучыларга иң әүвәл безнең журнал аша ирештерелде. Бу бөек исемгә өстәп — С. Максуди, Й. Акчура, Г. Газиз, С. Җәләл кебек олуг затларның иҗат үрнәкләре. Борынгы мирастан — «Йосыф кыйссасы», «Идегәй» дастаны... Саный китсәң, алар күп томлыкларга җыелыр...

Журналны әдәби хәрәкәтне оештыручы бер үзәк дип тә, әдипләрнең профессиональ осталыгын билгеләүче мәйдан дип тә, әдәбиятның үзенә күрә бер «диспетчерлыгы» дип тә әйтеп буладыр. Кульъязмалар, шөкер, әлегә күп керә. Табигый, һәммәсе журналда дөнья күрә алмый. Әмма, сайланып, редакцияләнеп, әсәр сыйфатында басылып чыкканнары аша да, бүгенге әдәби тормышыбызда бара торган тенденцияләрне ачык чамаларга була. Әдәби Йортта уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Язучы хезмәтенең дәрәҗәсе яки әдәби алмаш турындамы, жанрлар язмышы яки тематик диапазон хакындамы, яки китап язмышы мәсьәләләреме... Әйтик, халык иҗаты традицияләрендә, милли тел стихиясендә тәрбияләнгән өлкән буын прозаикларын — Еники, Мәһдиев, Ахунов, Гыйләҗевләрне кемнәр алыштырыр? Шигърияткә килүче яшьләр арасында ир балалар нигә аз күренә? Чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйтьнең булмавы җәмгыятьнең гомумәдәбиятка ихтыяҗы кимүе билгесе түгелме? Бүгенге әдәбиятыбыз бөтен татар халкы әдәбияты булсын өчен ниләр эшләргә ?.. Сораулар күп. Берничәсенең болай очын чыгарып куюның хикмәте шул: шушы ай ахырында, безнең юбилей саны аенда, Татарстан язучыларының чираттагы корылтае узачак. Бу җыенда әдипләрнең милләт, әдәбият, гомумән, киләчәктәге рухи үсеш турында җитди сөйләшүләре булыр, әйтеләчәк фикер-тәкъдимнәр, карар-резолюцияләр язучыларыбызны активрак иҗат итәргә рухландырыр, шул исәптән журнал куйган олы максатларны үтәргә дә ярдәм итәр дип ышанасы килә.

«Казан утлары» — үзенең башлангычыннан ук дәүләти басма. Сәяси-мәсләк ягыннан да, масштаб-колач ягыннан да. Ул шулай булырга тиеш тә. Уйласаң, бу тиешлекнең тамырлары тирәндә. Әллә ничә гасыр буе безнең кебек дәүләтчелеген югалткан халыкның киләчәк буыннарга калдырган бар булган рухи байлыгы, хыял-максаты, иман-идеясе, нигездә, сүздә — кульъязмада, басмада, китапларда сакланган. Басма сүз, китап (бу очракта журнал да диик) күпмедер дәрәҗәдә татар өчен дәүләт тә, дин дә, гыйлем чыганагы да булып торды... Үткән гасыр башында Татарстан республикасы оешкач, җитәкчеләрнең язучыларга, язучыларның дәүләткә таянырга тырышуы, әлбәттә, табигый иде. Хәзер яңа гасыр ба-

шында татарның аннан башка да зәгыйфь дәүләтчелек нигезләре какшатылган елларда төп мәсьәләләрдә халыкның бердәмлеге аеруча мөһим. Каләм ияләре әдипләр дә милли мәнфәгатьләр сагында уяу һәм фидакяр булырга бурычлылар. Дөньяда сүзнең кодрәте кимегәне юк әле! Әйтелгәнчә, журналыбыз дәүләти басма. Аның төп оештыручысы — Татарстан Министрлар Кабинеты. (Озак еллар буе «Казан утлары» фәкать Язучылар союзы органы булып килде. 1991 елдан, устав нигезендә, журналны гамәлгә куючылар булып Министрлар Кабинеты, Язучылар берлеге, хезмәт коллективы санала). Иҗат оешмаларының иҗтимагый оешма хәлендә, дотациягә яшәгәннәрен истә тотсаң, журналның реаль кем органы икәнлеге ачык аңлашыла. Милли матбугат эше әбүнәчеләр һәм иганәчеләр хозурына гына калса, хәзерге чорда ерак барып булмас. Татарның үзгә бер гимни җырында әйтелгәнчә, «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә!»

«Казан утлары»на 80 яшь. Безнең өчен, әлбәттә, истәлекле зур дата. Журнал юбилее, ул, асылда, бәйрәмнән бигрәк, әдәбиятыбызның киләчәге турында күмәкләшеп бер җитди уйлану, яңа максатлар билгеләү гамәле, әдипләр сүзен халыкка пропагандалауның бер үтемле чарасы. Әдәбиятыбызның зурлыгын, тарихи миссиясен билдереп, аны яңа буыннар тәрбияләүдә файдалану бүгенге көндә бик мөһим дип исәплибез. Юбилей уңае белән, әдәби-мәдәни вакыйга буларак, республикабыз районнарында «Казан утлары» көннәре уза. Матбугат битләрендә журналыбыз турында сәхифәләр басыла, радио-телевидение тапшыруларында әдәбиятыбызның асыл әсәрләре, әдипләребезнең чыгышлары яңгырый. «Казан утлары» юбилеена багышланган тантаналы кичә Бөтендөнья татарларының III Конгрессы көннәрендә — август ахырында узачак.

Юбилеебыз уңаеннан редакциягә тәбрикнамәләр күп килә. Аларның берсендә мондый юллар бар: «Татар дөньясының бердәнбер саллы журналын, милләтебез рухының кабатланмас елъязмасын, халыкның әдәбе сагында торучы каләм әһелләренең төп иҗади мәйданы булган басманы һәм аның тырыш хезмәткәрләрен олуг бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез!»

Зур сүзләр, горурланырлык сүзләр, әмма зур җаваплылык та өсти торган сүзләр. Җавабыбыз шул: зур тәҗрибәгә, якты сәхифәләргә ия булган «Казан утлары» халкыбызның бу яңа гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булыр дип ышандырасы килә.

*2002*

# БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ

*(бәхәс-дискуссия уңаеннан)*

«Казан утлары» «Безнең заман герое»н эзләп чыккан, дип яздылар бер газетада. Сәеррәк яңгыраса да, танырга туры килә: әйе, без чыннан да моннан ике ел элек журналыбыз битләрендә шушы исем белән бәхәс-дискуссия ачып җибәрдек. Әлбәттә, юктан эш чыгарып, тиктомалдан тотынылмады бу эшкә. Эш-мәшәкатьләребез, иҗади проблемаларыбыз болай да хәттин ашкан. Бу сөйләшүне башларга безне бүгенге вазгыять, тормышыбыз ихтыяҗы мәҗбүр итте. Хәер, заман каһарманы мәсьәләсе элек-электән актуаль булган. Бөек рус әдибе М. Лермонтов та тикмәгә генә төп әсәрләренең берсен «Безнең заман герое» дип атамагандыр. Ахыр чиктә, сүз — исемдә түгел, җисемдә. Без чагыштырмача шартлы булган шушы сүзтезмәне өскә, калку итеп куеп, бүгенге әдәбиятыбызда бара торган процессларны, тенденцияләрне мөмкин кадәр анализлап, үзебез өчен мәгънәви максатлар билгеләп, сүз сәнгатенең, ягъни язучы хезмәтенең җәмгыятьтәге урынын, хаҗәт һәм тәэсир итү дәрәҗәсен ачыкларга тырышу иде. Юкса, соңгы дистә елларда, «бездә тәнкыйть юк, тәнкыйть бетте!..» дигән сүзләр дә еш ишетелә башлады. Утсыз төтен булмый дигәндәй, мондый катгый сүзләргә нигез дә бар. Матбугатта әдәби хәрәкәткә яки аерым бер әсәргә карата чыккан материалларны күздән кичерсәң, шуңа инанасың: аларның күбесе теге яки бу язучының юбилее яки әсәре берәр премиягә тәкъдим ителү уңае белән язылган, китап күзәтү — рецензияләрнең дә күбесе, нигездә комплементарьлеккә, мактауга корылган... Әгәр безнең бу сөйләшү уңае белән чыккан мәкаләләрне укып, җентекле анализ ясасаң, шундый нәтиҗәгә киләсең: юк, «бazda дары бетмәгән әле!», объективлыкка омтылган, дөреслеккә хилафлык кылмаска тырышып, кемнең кем булуына карамастан, йөзенә туры карап, үз фикерен әйтә алучылар бар әле, тәнкыйть исән әле!

Борын-борыннан, кешеләр җәмгыять булып оешып яши башлаганнан бирле, көч яки акыл үсеше ягыннан башкалардан аерылып торган индивидумнар булган, гадәттә алар шул ыруның башлыгы саналган. Аларны, мөгаен, шул заманның беренче каһарманнары дип атап буладыр, һәр чор, һәр халык үзенең көчле шәхесләрен тудырып килгән. Әйтик, колбиләүчелек чоры шәхесе, Рим гладиаторларын көрәшкә күтәргән Спартак шул дәвернең каһарманы түгелмени? Патша колонизациясенә каршы баш күтәргән Батырша? Салават Юлай, Муса Җәлил?.. Болары турыдан-туры көрәштә

корбан булып, яшәү финаллары җәзалы үлем белән тәмамланган каһарманнар. Үзләренең фидакярлекләре белән тыныч тормышта кешелек алгарышына гаять күп файда китергән мәшһүр галимнәр, бик күпләрнең гомерләрен саклап калган табиблар... Яшәешнең төрле сфераларыннан халык күңеленә кереп калган бихисап шәхесләрне искә алырга мөмкин. Алар теге яки бу заманның каһарманнары-геройлары бит.

Каһарман-герой өлгесе беренче нәүбәттә яшьләр өчен, яңа буыннар өчен кирәк. Тәрбия чарасы буларак кирәк. Әдәбият байтак гасырлар буе бу миссияне уңышлы үтәп килде. Китап тотмаган, матур әдәбият укымаган кеше моңарчы надан дип саналды, җәмгыятьтә аның урыны түбәндә булды. Талантлы әсәр, андагы персонажлар, автор үзе телиме-юкмы, укучыга тәэсир итми калмый. Димәк, әсәр, аның герое укучының аңын формалаштыруда билгеле бер роль уйный. Ул геройның гамәлләре нинди, максаты нидән гыйбарәт? Ахыр чиктә ул кемнәргә һәм нинди максатка хезмәт итә? Бүтәнчә әйткәндә, нинди идеяне алга сөрә? Төрле заманда, төрле җирлектә, төрле халыкларда кешеләрнең максатлары, тоткан мәсләкләре, идея-иманнары төрле булырга мөмкин. Әмма, кем генә булмасын — аерым бер кешеме, ыруг-җәмгыятьме, милләт-халыкмы, дәүләт-империяме — барыбер аларны бер нәрсә берләштерә: Кояш астында үзе теләгәнчә ирекле яшәүгә омтылыш. Бу омтылышның күп формалары, күп исем-билгеләмәләре бар.

Үзебезнең җирлектә соңгы гасырдагы вазгыятьне, идеологик катаклизмнарны гына искә төшерик. XX йөз башындагы революция-түнтәрешләр, аны бөтендөньяга җәелдерергә омтылышлар (мировая революция), хосуси милекне бетерү, берничә буынны гарипләндергән сугыш, җирне хуҗасыз калдыру, социалистик җәмгыять төзү, һәм ниһаять, коммунизмга «чыга язу»... Идеологик бу ыргымнарның үзәгендә йөзләрчә миллион кешеләр язмышы... Батырлыклар, фаҗигалар, шатлык һәм кайгы яшьләре һәммәсе бергә үрелгән, буталган... Хәкимдарлар үз идеологиясенең җиңүе өчен фәнни һәм иҗади интеллектуаль көчне максимум файдаланырга тырышканнар, билгеле. Халык массаларын тиешле юнәлештә хәрәкәтләндерү өчен үрнәк каһарман-геройлар кирәк булган. Әдәбият төп тәрбия чараларының берсе булган заманда, китап геройларының роле әйтеп бетергесез зур иде. Максатка ярашлы әдәби геройлар тудыру (яки ясау) өчен, иҗат ысулына фәнни төсмер биреп, социалистик реализм методы булдырылды. Шул заманның әдәби геройларын искә төшерик: Н. Островскийның Корчагины, М. Шолоховның Давыдовы... Бездә Г. Бәшировнең Нәфисәсе, М. Әмирнең Миң-

лекамалы, Г. Әпсәләмовнең Газинуры... Бу әдәби геройлар шул елларның сәяси кануннары тәэсирендә беркадәр ясалма булсалар да, аларның берничә буынны патриотик тәрбияләүдәге өлешләрен таныրга кирәк. Шул ук вакытта, партия заказы белән язылган меңәрләгән урта кул әсәрләрдә, төссез, бер-берсенә охшаш, артык «дөрес» бихисап уңай геройлар пәйда булды. Алар яшь укучыларга үрнәк булырлык заман геройлары итеп тәкъдим ителде. XX гасырның икенче яртысында «безнең заманның төп герое» — коммунизм төзүдә актив катнашучы булырга тиеш иде. «Коммунизм төзүче кодекс»н үтәмәгән кешене заман герое итеп күзаллау яки сурәтләү кыен иде...

Әмма... Вакыт дигәннәре һәммә нәрсәгә төзәтмә кертә икән! Ком таулары күчкән кебек, зур дәүләтләр, империяләр таркала, җимерелә тора. Алар белән бергә, табигый, шул империяләрнең җилеме булган идеологияләр дә юкка чыга бара. СССР таркалгач, партиянең унитар системасы җимерелде, какшамас кебек тоелган идеологик маяклар ауды, демократия белән анархия буталып күпмедер дәрәҗәдә хаос барлыкка килде, рухи кыйммәтләр девальвацияләнде... Төрле сәяси терминнар мишурасын җилгәреп, төптәнрәк уйласаң, төп үзгәреш шул: илдәге материал-җисми байлыкның хуҗалары алышынды, илнеке саналган мөлкәт тар бер даирә кулына күчте. Цивилизацияле капиталистик (онытмыйк, нигез сүз — «капитал») мөнәсәбәтләр булмау сәбәпле, «кыргый базар» күпчелек хезмәт ияләрен хәерчелектә калдырды; аз санлы бер төркем фантастик байлыкларны кулга төшерде, күпләр фәкыйрьлекнең чигенә терәлде.

Менә шул җәмгыятьтә геройлар-каһарманнар эзләп кара инде! Классик мәгънәдә без аңлаган геройлар урынына тормышыбыз мәйданында яңа антигеройлар яки куштырнаклар эчендәге «герой»лар пәйда булды. Аларга мисаллар бихисап. Әйтик, хөкемгә тартылган җинаятьче төрмәдән чыгуга парламентка депутат булып сайлана, һәм бераздан тагын төрмәгә ябыла... Җәмгыятькә үз хәләл көче белән берни дә бирмәгән япь-яшь кешеләр, төрле алдау-юлдаулар белән, дистә миллиард доллар байлык (тулы бер республика бюджеты!) үзләштерә... Яки — ачыктан-ачык фашистик рухлы яшьләр төркемнәре барлыкка килә, кайбер рәсми партияләр аларга эчтән теләктәшлек белдерә, өстәге хакимият күрмәмешкә салыша... Олигархмы, скинхедмы, законлы бурмы — алар да бит кемнәрдер өчен авторитет, кумир, темабыз терминологиясе белән әйтсәк, герой,каһарман.

Каһарман-герой өлгесе яшь буынга кирәк, дидек. Әйе, шулай. Яшь кешенең күңеле буш тора алмый: ул барыбер

нәрсә беләндер тулы һәм рухи корылган була. Хикмәт нинди максатка корылуында. Чыннан да, «кеше җаны өчен көрәш бара!» Җепнең очы, ахыр чиктә, яшь буынны тәрбияләүгә барып тоташа. Әдәбият, тапталганрак гыйбарә белән әйтсәк, тормыш көзгесе буларак, тәрбияви әһәмиятен югалтмады бит әле! Димәк, әхлакый кануннар шактый ук какшаган бу чорда, язучының җаваплылыгы тагын да арта булып чыга. Бу җаваплылык, әлбәттә, авторның персонажларны, әсәрнең умыртка сөяген тәшкил иткән төп геройларны сайлауда һәм аларны образлы сурәтләүдә, дөресрәге, нинди максат куеп, ничек сурәтләүдә чагыла.

Безнең әсәрләребезне укучылар, нигездә, авыл кешеләре. Авыл кешесенең хәлен, андагы матди һәм рухи проблемаларны күпләребез яхшы белә. Авыл яшьләренең киләчәге, икенче төрле әйткәндә, авылның киләчәге җәмгыятебезне иң борчыган мәсьәләләрнең берсе. Яшь кеше авылда җанына ятыш эш табамы? Өлкән сыйныф укучысы бик яхшыга укып бетереп, югары уку йортына керә аламы? Армия сафлары алга таба, да нигездә, авыл егетләре хисабына тулыланамы? Шәһәрдә белем алган белгеч туган ягына әйләнеп кайтачакмы? Сораулар, сораулар... Без, язучылар, үзебезнең әсәрләрдәге геройлар аша яшьләргә әнә шушы сорауларга дөрес җавап табарга булышырга, аяусыз һәм кырыс тормышта югалып калмаска өйрәтергә, аларга чыныгу һәм көрәш дәресләре бирергә тиешбез. Әгәр без ялган геройлар белән ымсындырып, ялган маякларга юнәлтсәк, өстебезгә зур гөнаһлар алып, әхлаксыз җаннар булырбыз.

Безнең заман герое. Кем ул? Нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Мең кешедән сорасаң, мең төрле җавап булыр. Шулай да, һәммә җавапта да кабатлану ихтималы булган сыйфатлар да юк түгел. Әйтик, безнең заман каһарманы, шиксез, киләчәк өчен җаваплылык тоеп гамәл итәргә тиеш. Аның кылган гамәле гомумкешелек мәнфәгатенә зыян салмаска тиеш. Андый зат гомумкешелек тудырган уртак әхлакый кануннарга ия булырга тиеш... һәм тагын әллә никадәр «тиешләр». Хәер, моңа кадәр булган дөнья әдәбиятында, шул исәптән безнең татар әдәбиятында да, әлеге саналган «тиешләргә» ия булган герой-каһарманнар шактый булды инде. Әгәр «безнең заман герое» дип, ясалма рәвештә «өр-яңа геройлар» калыплый башласак, көлке хәлдә генә калырбыз. Сүз — моңарчы киләчәк өчен кирәк-файдалы булган хәзинәгә яңа сыйфатлар, яңа төсмерләр өстәү турында гына булырга мөмкин.

Без озак дистә еллар герой төшенчәсен ил-халык күзенә ташланырлык ниндидер гайре табигый батырлык кылу белән

бәйләп аңлатырга күнектек. Алтын Йолдыз алса — герой, дзотка ташланса — герой, галәмгә очса — герой, рекорд куйса — герой... Әлбәттә, герой. Ә чын тормышта исә геройлар күбрәк. Алар гадәти тормышта, гадәти хаят кичеп, гомерләре буе тын гына чын мәгънәсендәге батырлык эшләп яшиләр. Әниләребезнең күбесе шул токымнан түгелмени? Үзебезнең бүгенге җирлектән бер генә мисал: гомерләрен, эшләп тапкан хәләл малларын ятим балалар тәрбияләүгә сарыф иткән замандашларыбыз фермер Әсгать Галимуллин, пенсионер Миңлегөл Рафиковаларны кая куясың? Күп булмасалар да, андый фидакяр җаннар да бар бит. Күптән түгел генә «XX гасырда татарның 100 мәшһүр шәхесе» дигән китап дөнья күрде. Алар арасында да яшь буынга үрнәк, әдәби әсәрләребезнең герое була алырлык исемнәр юк дисезме?..

Аксиома кебек тагын бер хакыйкать, нинди генә гаярь зат булмасын, үз халкыннан йөз чөергәннәр һичбер заман герое була алмый. Шуңа күрә, һәр халыкның үз милли геройлары бар. Йолдыз белән йолдыз сөйләшә дигәндәй, алар еш кына башка халыкларның да уртак геройларына әверелә. Хәзер «милли идея», «милли проект» дигән сүзләр еш ишетелә. Бу юнәлештә Россия күләмендә билгеле бер эзлекле гамәлләр башкарырга уйлыйлар. Уртак Ватан саналса да, күпмилләтле дәүләттә бер генә уртак милли идея була алмый. Һәр морҗаның үз төтене... Безгә дә ят нәрсә түгел ул милли идея. Әгәр соңгы 10–15 елдагы иҗтимагый тормышыбызга күз салсак, милли күтәрелеш нигезендә моңарчы без белмәгән күпме көрәшчеләр, чын мәгънәсендәге каһарманнар күтәрелеп чыкты. Алар безнең заман геройлары түгелмени? Казанның 1000 еллыгы үткән көннәрдә Президентыбыз М. Шәймиев, халык күзенә карап: «Булдырабыз!» диде. Милли идеянең бер формасы буларак, бу шигарь күп нәрсәне аңлата. Шушы «Булдырабыз!» шигарен әйтергә нигез биргән, халкыбыз алгарышына өлеш керткән кешеләр заманыбыз каһарманнары түгелмени?

Әйе, ике ел дәвам иткән дискуссия-сөйләшүгә әлегә нокта куябыз. Әмма йомгак ясамыйбыз. Заман героеның тәгаен моделен билгеләмибез. Теләгәндә дә билгели алмас идек. Заман аңа һәркөн яңа төсмерләр өстәп тора. Шунысына канәгатьбез: журнал битләрендә бүгенге әдәбиятыбыз турында ихлас сөйләшү булды. Кайбер уңышларыбыз белән бергә байтак кимчелекләребез дә ачылды. Үз-үзебезгә тәнкыйть күзе белән карый алу — рухи сәламәтлегебезнең бер билгесе. Димәк, киләчәккә өмет бар.

*2005, ноябрь*

# СҮЗ — БОЛЫН, ҖЫР — ЧӘЧӘК

*(Шигырьләргә кадәр берничә сүз)*

Сүзләр бик аз.
Санаулы.
Төренмәгәннәр
броняга, маск-халатка.
Кыска шигырь охшаш япан кырда
утка кергән ялгыз солдатка.

Бер-ике юллыклар... Иң озын дигәннәре дә сигез юлга сыеп бетә. Шигырьләрдә биш-ун сүз, күп дигәндә егерме-утыз сүз...

Берәүнең гыйбрәтле сүзләре хәтердә калган: «Гафу итә күр, дустым, — дигән ул, — хатым озынрак чыкты, кыска итеп язарга вакытым тар иде...» Бу яктан, шөкер, минем вакыт җитәрлек булды. Кыска шигырьләрне балачактан бирле язып киләм. Бу китапка кырыклап ел дәвамында язылган алты йөзгә якын кечкенә күләмле шигырьләр теркәлгән. Парчалар, мәкальгә тартым тәгъбирләр, этюд-картиналар, табышмак элементлары булган сентенцияләр, робагыйлар, берәр хикмәткә ишарә ясаган ассоциатив чагыштырулар, көтелмәгән контрастка яки ярымкинаяга корылган тапкыр тезмәләр... Шәкли яктан сыйфатлама сүзләре, югарыда саналганнардан тыш, бүтәнчә дә булырга мөмкин. Кыскасы, кыска шигырьләр. Хәтта бик-бик кыскалар.

Кайберәүләр, бәлки, нигә шигъриятнең мондый «вак» төрен сайладың да дистә еллар һаман энә белән кое казыйсың, диярләр. Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк: күңел таләбеннән чыккан эш, рухи ихтыяждан кылган гамәл бу.

Әгәр кеше җитсә бер чиккә...
саный башлар канындагы ак шарлар исәбен,
ышаныр бары күзләрдә язылганга.
Сапер кебек сагаеп, тын кысып,
васыятьтә әйтер сүзләр эзләр
Дөньялыктан.

Минемчә, чын шигырь һәр төр иҗаттагы кебек, җанның максималь киеренке чагында, уй-фикерне әйтми, бүтәннәр белән бүлешми кала алмау халәтендә, илаһи гаҗизләнү минутларында туа. Иҗатчының бу мәлдә күңеле, сабыйларныкы кебек саф һәм ихлас, ә фикере исә хөкемдар-хакимнәрнеке кебек төгәл һәм хикмәтле булырга тиеш. Шул чакта

гына Сүз, мәгънәсе һәм эмоциясе буенча, дөньяда беренче туып яңгыраш алгандагыга якын булырга мөмкин. Сүз кадәр Сүз бит ул! Сүзгә сакчыл булу — ул Аңа инану, табыну. Аның кодрәте алдында баш ию, «рәнҗешеннән» курку... Моны тоеп, аңлап эш иткән иҗатчының сүзе, һичшиксез, табигый яңгырар. Күзләрдән яшь китерерлек шатлык килгәндә, яуда атакага күтәрелгәндә, иң кадерлесен назлап иркәләгәндә, соңгы сулышларын алып васыять әйткәндә, Кеше, иң табигый сөйләшүдә булып, шул чакта иң кирәк, иң төгәл, бердәнбер мәгънә белән яңгырашлы сүзләрне тапмыймыни?.. Димәк, кыскалык — уйлый белүнең үзгә бер формуласы ул. Фәндә генә түгел, шигърияттә дә. Хөрмәтле укучым, бу китапны ачып кайбер юлларны укыганда, туктап тын калып, мин язгандагы хисләрне кичерсәң, авторга, әй, зур куаныч булыр иде! Укучылар димәктән, кыскалык ул бүтәннәргә ышану һәм ихтирам итү билгесе дә бит әле! Вакыт дигәннәре һәммәбез өчен дә бик кадерле һәм дефицит нәрсә. Эчпошыргыч озын һәм ни мәгънәсе, ни хисси көче булмаган тезмәләр белән кеше вакытын урлау үзе бер җинаятьтер, бәлки. Өстәвенә шагыйрь абсолют хакыйкатьләр ачып торучы пәйгамбәр дә түгел бит әле! Ул үзенең шигъри сүзе белән кешеләр күңелен кузгата гына, көрәш һәм каршылыклар тулы бу тормышны танып белүдә, аны яхшырту юлында үзенә җандашлар эзли. Ул аваз сала. Ул Яшәү һәм Тормыш турындагы мәңгелек бәхәскә чакыра... Дөрес, бу очракта, укучының интеллектуаль әзерлеге, күңелләр тәңгәллеге, шигырьләрне укыгандагы халәте, идеаллар берлеге яки үзгәлеге, тормышка караш принциплары да зур роль уйный. Синең үзең өчен бик тә газиз һәм бүтәннәр өчен дә бик тә кирәк һәм тансык дип санаган сүзеңне берәү-



*«Җил — вакыт ул» (кыска шигырьләр) — авторның кадерле китапларының берсе*

ләрнең кабул итеп җиткермәүләре дә ихтимал. Шулай да һәр кеше күпмедер дәрәҗәдә шагыйрь, тик бер-береңнең җан авазын тыңлый гына белергә кирәк!

Кыска шигырьләр... Менә инде икенче кат (бер өлеше 1978 елда аерым китап булып басылган иде инде) кыска шигырьләр җилкәнен күтәреп, зур Шигърият Диңгезенә чыгып барышым. Ихтимал, шигырьләрнең кешеләр күңеленә ирешү юлында каршы җилләр дә, давыллар, штормнар да булыр. «Кыскалыкта — осталык» дигән тәгъбир бар да барын, шулай да... артык тәвәккәллек түгелме соң бу? Бернинди җайланма-коралсыз диңгез төбенә чумучы гаувас хәлендә калмыйммы? Аз сүз аз сүз инде ул; берничә бөртек сүзне фәкать үз җегәрендә генә эшләтеп була. Өстәвенә гомумшигърият хәзинәсендә һәр халыкның меңәр еллардан бирле шомарып, үткенләнеп беткән тапкыр сүзләрен, мәкаль-әйтемнәрен, табышмак-сынауларын да онытмыйк. Шәрык шагыйрьләренең кыска хикмәтләре, бәет-робагыйлары; Ерак Көнчыгыш сүз осталарының өч-дүрт юллык миниатюралары... Кешелекнең дөнья кадәр байлыклары бит алар! Шулай да тәвәккәлләдек!

Дөрес, нинди генә олуг сәләткә ия булып, сүздән аркан ишә алсаң да, бер дистә сүз белән халык тормышының вакыйгалар үрелешендәге эпопеясын тудыру реаль дә түгелдер, бәлки... Әмма шунысына инанам: тиешле көч-кодрәткә һәм осталыкка ирешкәндә, шул ук сүзләр ярдәмендә берничә штрих белән халык язмышының үзәк моментларын, символик рәвештә генә булса да чагылдырырга мөмкин. Ә аерым кешенең шәхсән күңел халәте нюанслары турында әйткән дә юк! Әгәр шагыйрьнең иҗтимагый һәм эстетик идеалы үз вакыты өчен дөрес сайланып, максаты зур һәм кешелекле булса, шушы кыска шигырьләр белән дә замандашының рухи антологиясен, ул гына да түгел, Заман портретын, Кешелек панорамасын да күрсәтә алырга мөмкин.

Һәр шагыйрьнең чишмә башы, гомерлек таяну ноктасы ул — халык иҗаты. Халык, гомумән, образлы кыска сөйләргә ярата, сүзен мәгънәле, гыйбрәтле итеп әйтә һәм күңеле белән шундый формаларны теләп кабул итә дә. Халык әйткән хикмәтле сүзләрнең берничәсен генә искә төшереп узыйк. «Күз — дәрья», «Батырлыкта — матурлык», «Туган як — алтын бишек», «Йорт китсә дә, сөт калыр», «Сүз — басу, җыр — чәчәк»... Әлбәттә, бу сүзләрне күңелендә шагыйрь яткан аерым кешеләр чыгарган заманында. Исемнәрен генә

белмибез. Менә безнең буыннар хәтеренә яхшы ук сеңеп калган кайбер тәгъбирләр: «Март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җиргә кар ашый»; «Үзең турында уйлама, Илең турында уйла, Илең турында уйласаң, гомерең озын була»; «Очты дөнья читлегеннән, тарсынып, күңлем кошы»; «Җаныңның ваклыгын, сылтама Заманга»; «Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел»; «Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне!» Боларын инде безгә мәгълүм шагыйрьләр әйткән. Бу юллар, төп кыса-контекстларыннан аерылган хәлләрендә дә, аерым шигырь инде, кичереш-фикерләрнең үзенчә бер поэтик билгеләмәләре. Ахыр чиктә, без, шагыйрьләр, халык күңеленә берничә юл, берничә строфа белән булса да кереп калырга хыялланмыйбызмыни?

Бу китапка кергән шигырьләр арасында, традицион үлчәүдәге икеюллыклар, дүртьюллыклар, сигезьюллыклар белән бергә, рифмасыз, әмма төзек ритмлы «ак» шигырьләр дә, сөйләм ритмына якын интонацион шигырьләр дә, һәм шулай ук татар шигъриятендә инде гражданлык хокукы алган «иректе» шигырьләр дә бар. Гомумпоэтикабызга характерлы сурәтләү алымнарыннан тыш сезгә тәкъдим ителә торган кайбер шигырьләрнең бүтән үзгә сыйфатлары да бардыр. Җете күз күрер, сизгер күңел тояр. Һәрнәрсәнең, — зурмы ул, кечкенәме, — үз язмышы, үз биографиясе булган кебек, бу кыска юллыкларның да үзләренең туу тарихы бар. Аларның байтак өлеше нәкъ бу китапта бирелгән формада туса, мәсәлән: «Толымланып салынып төште Күк сагышы» «Яңгыр», «Көнемнең таҗы — Син китергән төн» «Бүләк», «Кыны тулы кан. Тышында чәчәк сурәте» «Тарих», «Өметемнең күзе шундый зур! Керфекләре генә ябылмасын!» «Очрашкач» һ. б., бер өлеше шактый озын, традицион стильдә язылган (кайберләре матбугатта басылгалады да) шигырьләрнең төшен, үзәген, эмоциональ «нерв»ларын алудан хасил булды.

«Берьюллыклар да булдымы шигырь!» — дияр кемдер... Пикассоның мәшһүр күгәрчен сурәтенә карап, рәссам эше бик җиңел эш тоелырга мөмкин. Хәер, Роденның «Фикер иясе» («Мыслитель») сынын ясавы да бик авыр түгелдер — мәрмәр таштан артык җирләрен уеп кына аласы... Халык мәкалендәгечә: «Йорт салуның ние бар — чутлыйсы да мүклисе!..»

Кыскасы, бу шигырьләрне һәркем үзенчә аңлар, җаны куш-

канча хөкем итәр. Ничек кенә хөкем итсә дә, иң мөһиме — чын күңелдән булсын!

Бер шагыйрь әйткән, «күкрәгемнән кошлар очырам». Мин дә үз укучыларыма күңелдә йөрткән кыска шигырьләремне очырам. Өстән авыр йөк төшкән шикелле, җанда нindидер бер җиңеллек. Ниндидер бер бушану. Күз алдында гүзәл күренешләр: алтын таҗлар белән тулы көнбагыш кырлары, күк зәңгәрлегендә өер-өер карлыгачлар, сабантуйлы яшел мәйданнарда гармун-җыр моңында тибрәнгән шат халык ташкыннары, диңгез ерып исән-сау кайтып килүче кораблар төркеме... тирә-юньдә сине аңлап, җылы караш ташлаган акыллы күзләр... Болай хыялланырга һәрберебезнең хакыбыз бар.

*P. S. Кыска — озын. Җылы — суык. Мәхәббәт — нәфрәт. Яхшы — яман. Гөнаһ — тәүбә... Болар — антонимнар. Янә кыска — озын... Парадокс: кыска шигырьләр турында озын язарга туры килде. Бигайбә!*

*1995, ноябрь*

# «МӘЙДАН»ГА КИҢ МӘЙДАН

Яшермим, Чаллыда янә яңа журнал оештыралар дигән хәбәр килеп ирешелгәч, күңелдә сөенү катыш гаҗәпсенү тойгысы да булмады түгел. Төбәк журналы бар иде бит… Булган иде бит… Булганны саклый алмаганнар яңаны яңадан югалтмаслармы?.. Безнең халык өчен чоры да яман катлаулы бит әле. Әйдәүче идеология юк, әдәбият-сәнгать шактый ук ятим хәлдә. Шулай да, өметсез шайтан, диләр, киләчәкнең бүгенгедән, килер буыннарның бездән яхшырак буласына ышанасы килә. Күрә белгәнгә, дөньяда ышаныч тудырырлык яктылыклар, күркәм эшләр дә җитәрлек. «Мәйдан» журналын дөньяга чыгарырга алынган егет-кызларны да әнә шул ышаныч-өмет әйди-эшләтә дип уйлыйм. Алар аңлыйлардыр: дуамаллык һәм популистик шигарьләр чоры узды, зирәк акыл һәм кыю гамәлләр заманы хәзер.

Журналның яхшы чыгуы өчен ныклы матди-материал база һәм талантлы авторлар даирәсе булу шарт. Бу очракта беренчесе Чаллы шәһәр хакимиятенә караса, икенчесе, һичшиксез, әдипләрнең, каләм ияләренең үзләренә бәйле. Минемчә, бүгенгесе көндә бу ике фактор-шарт бар, һәм шул форсатны журнал максималь файдаланырга тиеш. Чөнки миссия зур: халыкның милли рухын, аның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген тарихи перспектива белән күрсәтә алу, кояш астындагы бүтән халыклар алдында үзеңнең яшәүчәнлегеңне раслый алу.




«Мәйдан»ның матур киләчәгенә, ышанычыбызга төп дәлил шул: бу төбәктә талантлар җитәрлек. Алар әлегә бар, шартлар тудырып үстергәндә тагын да ишәерләр. Төбәк дигәндә бер Чаллыны гына түгел, Татарстанның бөтен көньяк-көнбатыш өлешен күз алдында тотам: Түбән Кама, Мөслим, Зәй, Алабуга, Актаныш… Бердәм коллективка (шулай булыр

дип ышанасы килә!) төп теләкләрнең берсе: тиражыгыз зур, укучыларыгыз күп булсын иде. Сер түгел, бүген йөзләрчә басма дөнья күрсә дә, аларның һәммәсенең җыйнама тиражы элеккеге «Азат хатын» («Сөембикә») һәм «Казан утлары» журналларының гомум саныннан кимрәк... Тикмәгә генә азанны югарыга, манарага менеп әйтмәгәннәр бит, иманлы сүзне күп халык ишетергә тиеш.

Без — гасырга якын дәвердә халкыбызның төп басмасы булып килгән «Казан утлары» журналында эшләүчеләр — «Мәйдан»ны үзебезнең әдәби туганыбыз дип санаячакбыз, кулыбыздан килгәнчә ярдәм итәргә әзербез. Көнләшеп укырлык әсәрләр генә чыксын, сөенербез генә. Татар дөньясында иҗат-иҗтиһад итәр өчен җирлек киң, иҗтимагый фикер үсешендә күтәрер катламнар җитәрлек. Фидакяр талантлар, милләтпәрвәрләр генә булсын!

Хәерле юл, сиңа, «Мәйдан»! Укучыларың ишле булсын! Егерме беренче гасырда татар халкының рухи елъязмачысына әверел!

*2001, сентябрь*

## КИЛӘЧӘК ӨЧЕН ЭШЛӘРГӘ ТИЕШБЕЗ

Язучылык эшен язмыш дип кабул итеп, кырык елдан артык татар әдәби хәрәкәтенең үзәгендә кайнаган каләм иясе буларак, табигый, үткәннәргә таянып, бүгенге вазгыять һәм киләчәк турында уй-фикерләрем күп. Кайберләрен үткән 2004 елда чыккан «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дигән китабымда бәян иткән идем инде. Корылтай трибунасыннан әйтергә ниятләгән бу кыска чыгышым ике өлештән булыр: берсе — Кабул итү Коллегиясе эше турында, икенчесе — «Казан утлары» журналы хакында.

Иҗади союзлар, ягъни берлекләр төзелгәннән бирле хәзергәчә кадәр яшәп килгән нигез-принцип: яшь буын әдипләрне тәрбияләп үстерү — Язучылар оешмасының иң төп бурычларыннан берсе. Үткән гасырның 30 нчы елларыннан башлап бу принцип нык сакланды. Традиция бүген дә дәвам итә. Әмма хәзер — күбрәк инерция буенча. Сәбәпләре җитәрлек. Шуларның берсе әлегәчә Россиядә иҗат оешмалары турында закон-канун булмавы. Без иҗтимагый оешмалар статусында бүген. СССР вакытындагы кебек дәүләт структурасында ныклы материаль базасы булмагач, иҗат оешмаларына «кем кайда, ничек булдыра ала» ысулы белән эшләргә туры килә. Россиядә Язучылар союзы карамагындагы нәшриятлар, басмаханәләр, газета-журналлар бетте диярлек. Ни кадрлар сәясәтендә, ни нәшрият эшендә, ни тәрҗемә өлкәсендә үзәкләштерелгән тәртип-система юк. Әгәр язучылык хезмәте иҗтимагый фикернең бер мөһим өлеше, тәрбия чарасы икән, ягъни идеология икән — анда анархия булырга тиеш түгел. Мантыйк буенча, ил язучыларын берләштерергә тиешле Мәскәүнең үзендәге әдәби мохитне аңлау кыен: таркаулык, төрле мәсләктәге оешмалар, төркемнәр... Шуңа күрә яшь һәм башлап язучыларны оешмага әгъза итеп кабул итү эшендә дә илкүләм уртак нормативлар юк (дөнья әдәбияты тарихы күзлегеннән караганда, андый кануни кагыйдәләр, әлбәттә, ясалма күренә). Безнең Коллегия корылтай сайлаган Идарә тарафыннан хупланган Устав кысаларында эш итте.

Өч ел эчендә 37 кешене Татарстан Язучылар оешмасына кабул иттек. Күпме? Бәлки, күбрәктер. Без эшкә каты таләпләр белән керешкән идек. Әмма заман һәр эшкә коррективалар кертә тора. Татар әдәбияты гомер-гомергә төрле төбәкләрдән чыккан каләм ияләре белән көчле булган. Беләсез, безгә Уралдан, Себердән, Урта Азиядән, Пенза, Астрахань



*Татарстан язучыларының XV корылтаен драматург Туфан Миңнуллин ачты*

якларыннан талантлар төркемләп килә торган заманнар үтте (барып кайткан кешеләр сөйлиләр: Такташ Сыркыдысында әдәби телдә юньләп сөйләшә белүче яшьләр бөтенләй юк ди, имеш). Шуңа да халык язмышы мәнфәгатеннән чыгып эш итәргә, Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләргә заманга хас ташламалар да ясарга туры килде. Корылтай делегатларына таратылган белешмәләр китабында әлеге кабул ителгәннәрнең исемлеген укып, аларның яшен һәм яшәү урыннарын белә аласыз. Теге яки бу кандидатураны тикшергәндә, хокукый критерийлардан бигрәк, әхлакый-профессионал критерийлар өстенлек итте. Әйтик, әгъзалыкка кандидатның әдәби таланты, сәләте, ягъни профессиональ әзерлеге бармы? Перспективалымы? Әдәбиятта яңа сүз әйтә аламы? Уртак милли идеягә хезмәт итәме? Иҗаты халкыбыз йөз тоткан сәясәт белән аваздашмы? Шәхес, гражданин буларак язучы-әдип исеменә лаекмы?

Гариза язучыларның күбесе өлкән яшьтәгеләр, фәнни исеме булган галимнәр, журналистлар... Яшьрәк дигәннәребезнең күпчелеге — кыз-кыркын. Дүрт кешенең гаризасын кире борырга туры килде, өч кешенең иҗатын яңа әсәрләре чыкканчыга кадәр кичектереп тордык. Коллегия составына

абруйлы язучылар сайланган иде (Ә. Баян, Г. Зәйнашева, М. Хәбибуллин, В. Корчагин, М. Галиев, Н. Хисамов, Җ. Дәрзаман, Р. Зәйдулла, Г. Морат, Ш. Мостафин, Р. Фәйзуллин — рәис). Без вазифаларыбызга җитди карап, булдыра алган кадәр әдәбиятыбызның киләчәге өчен эшләргә тырыштык. «Талантны балкып торган фәлән яшь кешене нигә күрмәдегез, нигә оешмага кабул итмәдегез?» дип беркем әйтә алмас.

«Казан утлары» турында сүзем тагын да кыскарак булыр. Сезнең куллардагы белешмә китабында журналның соңгы өч елдагы эшчәнлеге турында шактый тулы мәгълүмат бар. Өстәвенә, ишетеп торасыз, тыңланган докладларда сүз, нигездә, безнең журналда басылган әсәрләр турында бара. Реаль факт хакыйкатьнең үзе инде ул. Чыннан да, «Казан утлары»сыз татар әдәби хәрәкәтен күз алдына китерү кыен. Читләрдән дә, «Казан утлары»ның Россиядә иң абруйлы әдәби журналларның берсе икәнлеге турында еш ишетеп торабыз. Киләсе елның февралендә басмабызның 1000 нче саны дөнья күрәчәк. Без моны милли матбугатыбызның горурлык бәйрәме, әдәбиятыбыз бәйрәме итеп уздырырга ниятлибез. Безнең ниятебезне Республика җитәкчеләре хуплый, без моңа бик шат. Меңенче сан чыгу уңаеннан байтак конкрет эшләр планлаштырабыз: журналда чыккан иң яхшы әсәрләр антологиясен һәм фотоальбом чыгару, журналның тулы библиографиясен төзү, фәнни конференция үткәрү, милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә «Казан утлары» көннәре» дигән очрашулар оештыру һ. б.

Адәм баласы алдында һәр заман үз проблемаларын тудырып тора. Бездә дә юк түгел алар. Шуларның берсе — журналның таралу-таратылу мәсьәләсе. Сер түгел, милли басмаларыбыз моннан егерме еллар элеккеге белән чагыштырганда күп мәртәбәләр кимеде һәм кимүен дәвам итә. Татарстаннан читтәге төбәкләрдә безнең матбугатка язылучылар ифрат дәрәҗәдә азайды. Сәбәпләре аңлашыла. Объектив дип әйтерлекләре дә бар. Шулай да журналны тарату мөмкинлекләре, файдаланылмаган мөмкинлекләре бар дип исәплибез без. Әйтик, һәр мәктәп, һәр китапханә, һәр татар әдәбияты укытучысы язылган очракта гына да шактый түгәрәк сан килеп чыга. Кызганыч, моңа ирешә алган юк әле. Күп нәрсә җирле түрәләрнең үзаңыннан һәм мәсьәләне аңлавыннан да тора. Фәкать югарыдан килгән фәрманны гына үтәргә өйрәнгән чиновниклар күп. Журналның иң күп өлеше Татарстанда тарала, аннан кала, табигый, Башкортстанда... Рес-

публиканың үзендә дә таралу рәвеше үтә чуар. Әйтик, Сабада, Балык Бистәсендә, Мамадышта 200–300ләп таралса, Тау ягы районнарында – Кайбычта, Апаста – 25–50. Бу хәл быел гына түгел, байтак еллардан килә. Нәтиҗә дә озак көттерми шул: әдәби журналлар таралмаган, димәк, укылмаган төбәкләрдән әдәбиятыбызга яшь алмаш та килми диярлек. Үзен татар дип исәпләгән (хәтта исәпләмәгән!) кеше өчен уйланырлык нәрсәләр җитәрлек. Традиция буенча журналны гамәлгә куючыларның берсе булып Татарстан Язучылар оешмасы санала. Әйе, соңгы елларда чыннан да санала гына шул. Асылда, журнал хөкүмәт тарафыннан (редакция керемнәре белән фәкать берничә генә сан чыгарып булыр иде) финанслана, редакция тарафыннан басмага әзерләнә. Реаль хәл шул. Без алга таба Язучылар берлеге җитәкчелегенең журнал файдасына актив эшчәнлеген күрергә теләр идек. Әлеге дә баягы журнал тиражын арттыруда, чын теләк булганда, Берлек байтак эшләр башкара алыр иде. Әдәби журналың булу язучы өчен зур бәхет ул. Синең бит яңа язган әсәреңне җиде-сигез мең данә белән, көне-ае белән дигәндәй, киң катлам укучыларга ирештерү мөмкинлегең бар! Ә әсәреңне китап итеп чыгаруның, үзегез беләсез, юлы озын, чыккан очракта да кайчан укучысына барып ирешә әле...



*Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Мәдәният министры Зилә Вәлиева язучылар белән. 2005*

Мин, шәхсән, безнең язучылар турында югары фикердә. Күбесен фидакяр затлар дип атар идем. Уртак ил байлыгын оятсызларча талау заманында, ярым-йорты тормыш алып барган хәлдә, кулга каләм алып, илһам табып, якты киләчәк турында язып кара әле! Димәк, иман безне ташламаган әле. Гомумән, язучыларыбызсыз милләтнең рухи үсешен күз алдына да китерү кыен.

*P.S.*

Сүзләр күп, вакыт аз. Вакыт димәктән, өч-дүрт елга бер җыела торган корылтайны ике көн уздырырга кирәктер. Беренче көнне докладлар тыңлап, кабаланмыйча фикер алышырга, проблемалар турында сөйләшергә; ә икенче көнне оештыру эшләре — сайлаулар, санаулар... Юкса инде ничәнче тапкыр съезд-корылтайдан өйләргә ярты төн узгач таралышабыз... Хәлебез экстремаль хәл дәрәҗәдә түгел ләбаса! 30 нчы елларда да, 50 нче елларда да, соңрак та язучылар үз җыеннарында берничә көн фикер алышырга җай тапканнар бит!

Соңгы корылтайны алып баручыларның берсе буларак, җыелыш барышында тәфсиллерәк итеп сөйләргә әзерләнгән докладчыларга президиумнан «Вакытыгыз бетә!», «Регламентны саклыйк», «Тагын бер-ике минуттан тәмамлагыз!» кебек репликалар әйтергә мәҗбүр булынды (әлеге дә баягы шул каһәр регламент аркасында!). Хәзер исемә төшерәм дә, уңайсызлык кичерәм. «Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин!» дигәндәй, бигайбә. Каләмдәшләргә исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телим.

*2005, май*

# ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫРЛЫК ҮТКӘН ЮЛ

*Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар*

Татарстан Язучылар оешмасына 70 ел... «Мең еллап тарихы булган татар әдәбияты оешмасына җитмешме?» дип уйлап куяр кемдер. Әйе, нигезе совет чорында корылган һәм әле бүген дә структур асылы шул ук калган язучыларның рәсми оешмасына нәкъ 70 ел. Дөрес, бер Татарстанга гына килгән юбилей түгел: безнең күрше республикаларга да, элек союздаш саналып йөртелгән бүтән халыкларның күбесенә дә кагыла торган юбилей бу. Үткәннәргә мөнәсәбәтнең һәм тарихи хәтернең ниндилегенә карап төрле җирләрдә төрлечәрәк билгеләп үттеләр әлеге датаны. Әлбәттә, һәр халык тарихны үзенчә аңларга һәм аңлатырга хаклы.

Иҗат оешмалары хакында нинди генә фикерләр (иҗатчыларның үзләре арасында да андый берлекләргә скептик караучылар бар) булмасын, реаль фактны танымый мөмкин түгел: иҗат союзлары, ягъни берлекләре (төрле чорда төрлечә әйтелгән, сүз сөрешенә карап һәм синоним буларак, язмабыздагы бу сүзләр һәр икесе дә кулланылыр) соңгы җиде дистә ел эчендә әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынты ясаучы мөһим бер фактор булып торды. Әйтик, яңа заман татар әдәбияты елъязмасын Язучылар берлеге тарихыннан башка күз алдына китерү кыен. Оешма — XX гасырның байтак дистә елларында язучыларның иҗади хезмәтен оештыруда һәм бәяләүдә үзгә бер идеологик үзәк ролен үтәп килде.

Мәгълүм хакыйкать: иҗат эше күңел халәтенә—илһамга бәйле үтә индивидуаль хезмәт, хәтта аны интим шөгыль дип тә әйтеп буладыр. Оешма, сүзнең тамырыннан күренгәнчә, күмәклекне белдерә, ә иҗат итү дигәч, нигездә, ялгыз калып эшләү күз алдына килә. Бөек әсәрләрне — җырмы, көйме, рәсемме—исегезгә төшерегез — күбесен талантлы Шәхес ялгызлыкта—Дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән бит! Әсәр туу — үзе бер тылсым! Аны, өстән яки кырыйдан әмер биреп, кушып тудырып булмый. Андый очракта тудырганың да ясалма, гарип чыга. Попугайны нәрсәләрнедер кабатларга өйрәтә алсаң да, сандугачны көчләп сайратып булмас, бөркетнең канатларын сындырсаң да, күз карашын кисә алмассың. Иҗат — асылы белән ирекле шөгыль. Иҗат иреге дигән гыйбарә тикмәгә генә тумаган! Шулай да...

Әйе, шулай да, нинди генә индивид һәм индивидуалист булып, «Аллалар белән генә сөйләшә торган» ялгыз халәттә

калып, үзең өчен бөек тоелган нинди генә әсәр тудырсаң да, син аны үзең өчен генә иҗат итмисең. Күңел җимешен кемнәр беләндер бүлешәсе килә. Язучы икәнсең—әсәреңне китап итеп чыгарасы, кешеләргә ирештерәсе килә, рәссам икәнсең—эшләреңне җыеп, күргәзмә ясап күрсәтәсе, артист икәнсең—сәхнәне иңлисе килә... Менә шунда инде кешеләргә елышасың, аңлашуга өметләнеп, коллегаларыңа барасың, теге яки бу мәсьәләне чишәр өчен хакимнәргә, оешмаларга мөрәҗәгать итәсең... Ялгызың иҗат итеп булса да, ялгызың гына яшәп тормыш итеп булмый. Булса да бик кыен. Ә дөньялыкта адәм баласына, һай, күп кирәк!

Очрашу-аралашу урыны да, иҗатың турында кеше сүзен ишетү яки бүтәннәр турында үз фикереңне белдерү өчен трибунасы да, нәрсәгәдер дәгъва итеп белешмә-тәкъдимнамәсе дә... Ахыр килеп, яшәештә түбә-куыш та кирәк бит әле, үлем-каза килгәч—озату-саубуллашу мәшәкатьләре дә... Ә кая барасың?..

Озынга сузылырга охшаган бу язмамны нигә дип яза башладым соң әле? Акыллыга сабышып, бүтәннәрне нәрсәләргәдер өйрәтергә, сабак бирергә теләгем юк, кемнәрдер алдында кемлегемне күрсәтү ихтыяҗы юк. Хаҗәте дә юк. Яшьлектә максат итеп куелган үрләремнең күбесенә менелде... Нәрсә өчен язып, бастырып чыгарырга ниятлим соң алайса? Мөгаен, иң әүвәл, үзем куйган сорауларга үзем җавап эзләп азаплануымдыр бу. Алга таба әдәбиятыбызның язмышы ничек булыр? Без элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны алга этәр өчен кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Бу сораулар күпләрне борчыйдыр дип уйлыйм (шулай булса, димәк, язуым аклана). Язучылар оешмасының бу юбилей датасы уйлану-фикерләшү өчен бер сәбәп кенә. Төп мәсьәлә—безнең рухи киләчәгебез. Киләчәк турында төпле фикер йөртер өчен, үткәннәрне белеп, гыйбрәт алу, бүгенгене хәл кадәри анализлау фарыз. Алда әйткәнемчә, соңгы чор әдәбиятыбыз тарихы Язучылар оешмасы белән тыгыз бәйләнгән. Бу язманың авторы буларак искәртеп узыйм, минем дә бу оешма белән гомерем тоташкан, аның өчтән ике өлеше турыдан-туры аңа бәйле. 40 елга якын Язучылар союзында әгъза булып торып, шуның 37 ел дәвамында тоташтан шушы оешманың идарә әгъзасымын. Уйлап баксаң, үзе бер гомер. Шуңа күрә Язучылар оешмасы, аның эшчәнлеге турында уйланып фикер әйтергә хакым бар шикелле. Күрәсең, мемуар-истәлекләр язар чак та җиткәндер. Беркөн язучылар исемлеген актарып аптырабрак калдым: миңа

кадәр СССР Язучылар союзына кабул ителгән язучылар нибары 5–6 гына калган... Теләсәң-теләмәсәң дә, әдәби хезмәт вахтасында ветеран булып чыгам икән...

Иң әүвәл шуны ассызыклап узыйк: СССР дигән держава яшәгән чорда иҗтимагый әһәмияте зур булган иҗат берлекләре – иҗат союзлары эшләп килде. Шул оешмаларның иң зурысы һәм иң абруйлысы – Язучылар союзы булды. Саны ягыннан да, дәрәҗәсе ягыннан да дөньяның бүтән илләрендә андый оешма юк иде. Язучылар союзы әгъзасы булу иҗат кешесе өчен зур казаныш саналды. Югары гыйльми дәрәҗә алулардан бер дә ким түгел иде бу әгъзалык. Алай дөньяда тиңе булмаган нинди оешма соң бу, нинди максат белән төзелгән дә нинди идеалга һәм нинди даирәгә хезмәт иткән? Профессионаллар берләшмәсе дияр идең, мәдәният, шул исәпкә язучылар да кергән аерым профсоюз системасы бар иде, Союз эчендә аның бүлекчәләре бар иде әле... Үзара ярдәмләшү, социаль яклау берләшмәсе дияр идең, бу функцияләрне башкаручы, Россиядә тарихы XIX гасырга ук тоташкан Литфонд (Әдәби фонд) бар... Әйе, иҗат союзларының, бигрәк тә Язучылар союзының социаль функциясе бүтәнрәк, тирәнрәк. Аны аңлау, асылына төшенү өчен, объектны, мотлак, шул иҗтимагый чор идеологиясе аша, үтелгән Вакыт призмасы аша карап анализлау мөһим. Чишмә башын, тора-бара аңа кушылган бүтән чыганакларны белсәң генә, елганың зурлыгын, агышының куәт-көчен чамалый аласың.



*Профессиональ язучы саналырга хокук биргән рәсми документ*

СССР Язучылар союзы төзелү 1934 елдан саналса да, аның башлангычы 1932 елга – ВКП(б) Үзәк Комитетының 23 апрельдә чыгарган карарына тоташа. Язучылар союзын оештыру мәсьәләсе, нигездә, шул елны хәл ителә. 1934 елга кадәрле калган ике ел әзерлек эшләренә китә. Үзәктә һәм республикаларда бу юнәлештә кызу эшләр башлана. Шул ук елның маенда Татарстан совет язучыларының Бердәм союзын төзү буенча Г. Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты төзелә. Комитетның максаты – төрле төркемнәргә бүлгәләнгән (ТАПП, СУЛФ, «юлаучылар» һ. б.) язучылар-

ны бер максатка юнəлтеп берлəштерү. Сүз уңаеннан əйтеп узыйк: башлангычы «Безнең юл» булган җурнал да ул елларда бүлгəлəнеп «Яңалиф» «Атака» исемнəре белəн чыккан иде. Алар урынына «Совет əдəбияты» исемле журналның чыга башлавы əнə шул Берлəштерүнең бер чагылышы иде.

СССР Язучылар союзының нинди максат белəн, нинди социаль нигезгə салынуын аңлау өчен, əйткəнемчə, шул чорның атмосферасын күз алдына китерергə тырышыйк. Октябрь инкыйлабы үтүгə 15 лəп, СССР төзелгəнгə 10 еллап вакыт үткəн. Советлар Союзында моңарчы дөнья күрмəгəн хəл—сыйныфсыз җəмгыять төзелə. Шəхси милек юк дəрəҗəсендə: завод-фабрикалар күптəн национализациялəштерелеп дəүлəткə күчкəн, җирлəр башта алпавытлардан, соңрак крестьянның үзеннəн дə тартып алынып, күмəк хуҗалыклар-колхозлар төзелгəн. Авылның хəлле кешелəре сөрелгəн. Пролетариат, юксыллар, социализм сүзлəре гегемоник яңгыраш алган мохиттə милек, мөлкəт төшенчəлəре бөтенлəй контрсүзлəр булып кабул ителə. Олы-кечененңме, наданнынңмы, укымышлынынңмы колак төбендə яңгыравыклы шигарьлəр: «Иске Дөньяны штурмлау бара! Капитализм җəмгыяте бетəчəк!» (Шул заманда капиталистик мөнəсəбəтлəрнең 60–70 елдан соң СССР киңлеклəренə янəдəн кайтачагын, уртак байлыкның талап-урланып, халыкның аз сандагы бик байларга, күп сандагы бик хəерчелəргə аерылып бетəчəген күз алдына китерүчелəр булдымы икəн?!) Кешелек капитал изүеннəн азат ителəчəк! Яшəсен Бөтендөнья революциясе! Яшəсен коммунизм!.. Интеллигенция аптырашта! Дворян тəрбиясе, университет белеме алганнарның байтагы эмиграциядə, бер өлеше тавыш чыгармый, дəшми, сагаеп нидер көтə, бериш аумакайлар партия җырын җырлап көн үткəрə... Вазгыять бер дə көлке түгел. Европа, гомумəн, Тышкы Дөнья арасына «Тимер пəрдə» корыл-


ПРАВДА
24
О перестройке литературно-художественных организаций.

ган. Демократия сүзе архаик төшенчәгә әйләнгән. Аны кирәксенүче дә бик юк... Ни гаҗәп, бәлки, парадокстыр: дөнья җәмәгатьчелегенең СССРга игътибары гаять зур. Планетаның алтыдан бер өлешендә бөек социаль экспериментлар бара! СССРда һәркем тигез, сыйныфсыз, гадел җәмгыять төзелә. Кешелекнең хыялы бит бу! Капитализм — берәүләрнең хәләл хезмәте бәрабәренә икенче берәүләрнең череп баюына корылган капитализм, гасырлар буе байтак акыл ияләренең нәфрәтенә юлыккан строй. Советлар Союзына сирәк булса да дөньякүләм мәшһүр язучылар килә. Ромен Роллан, Анри Барбюс, Бернард Шоу һ. б. Алар Сталин һәм башка дәүләт җитәкчеләре белән очрашалар. Россия, Советлар Союзы турында гаять зур фикерләр, канәгатьлек хисләре белән кайталар туган илләренә. СССР турында матур-матур интервьюлар бирәләр, социалистик стройның өстенлекләре турында сөйлиләр, язып чыгалар. Зур талантлар икейөзләнмәс: алар күңелдәгеләрен ихлас сөйләгәннәрдер дип уйлыйм. Күрәсең, аларны чыннан да яхшы каршылаганнар: ул шәхесләр яхшыны гына күргәннәр, яхшыны гына ишеткәннәр дә. Дөньякүләм мәшһүр язучыларның СССР турындагы фикерләре ил башлыклары өчен, әлбәттә, зур сәяси отыш булган. Әгәр илдә яшәгән күпсанлы язучылар армиясен шундый рухта — максат итеп алынган идеологиягә хезмәт иттергәндә? Сүз — зур көч. Язучылар — «кеше рухының инженерлары». Безгә, без күрергә теләгән җәмгыятьтә без күрергә теләгән масса кирәк... Шулай уйлаганнар хакимдарлар. Менә шундый вазгыятьтә оеша башлый СССР Язучылар оешмасы.

* * *

**1934 ел. 17 август. Мәскәү. Союзлар йортының Колонналы залы. Әдәбиятлар тарихында моңа кадәр тиңе булмаган язучылар җыены. 52 милләт вәкилләрен тәшкил иткән 591 делегат. Кунак сыйфатында төрле континентлардан килгән 40 чит ил язучысы. Совет язучыларының I Бөтенсоюз оештыру съезды ике атнадан артык (!) дәвам итә. 17 августта ачыла, соңгы — 26 нчы ябылу утырышы 1 сентябрьдә була.**

Бу урында Мәскәүдә үткән грандиоз съезд турында беразга тукталып торып—алда бу хакта тәфсилләбрәк сөйләү булыр—шул чорның үзебезнең җирлектәге иҗтимагый-сәяси вазгыяте һәм әдәби мәйдан-мохит турында берничә сүз әйтеп узыйк.




Татарстанда солтангалиевчелекне «фаш итү» тәмамланган чор, татарның байтак акыллы башлары юк ителгән, зыялы катлам өркетелгән, куркытылган чор... Әдәбият дөньясы да таркау, чуар; өстәвенә зур фигуралар аренадан китеп бара... Г. Исхакый — эмиграциядә, Такташ инде юк, Г. Камал яңа гына вафат, Г. Ибраһимов — авыру, Казаннан еракта, Кырымда яши, Г. Газиз — Бакуда, Г. Кутуй, Н. Исәнбәтләр җидегәнчелектә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, Г. Бәширов, С. Баттал, Ә. Еникиләр — әле яшь, башлап язучылар санала... Шулай да шәхес буларак колоритлы язучылар шактый әле Казанда. Татарстанда туып үскәннәр дә җитәрлек, төрле төбәкләрдән килеп кушылганнар да байтак. 1934 елның беренче яртысында СССРның төрле почмакларында — республикаларда, өлкәләрдә — язучыларның

корылтай-съездлары үтә, җирле оешмалар төзелә, ил күләмендә узачак Зур Съездга вәкилләр — делегатлар сайлана. Татарстанда да башкарыла бу эш.

**Язучыларның беренче җыены рәсми рәвештә совет язучыларының Беренче бөтен Татарстан съезды дип аталган. Съезд Татар дәүләт академия театрында 1934 елның 25 июлендә ачыла һәм Мәгариф эшчеләре йортында дүрт көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла.** Беренче оештыру съезды шул заманнарга хас булганча тантаналы һәм патетик рухта үтә. Почетлы президиум, плакатлар, котлаулар, көчле кул чабулар... Съездны кыскача кереш сүз белән язучы Кави Нәҗми ача. Язучылар союзын оештыру комитеты председателе Г. Ризвановның өч сәгатьтән артыкка сузылган доклады тыңлана. Съездда иҗат мәсьәләләре буенча Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат, Фатих Кәрим докладлары тыңлана. Чыгыш ясауларда Гази Кашшаф, Хәбра Рахман, Гомәр Толымбайский, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов, Ибраһим Салахов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һ. б. катнаша. Съездның оештыру эшләре мондый нәтиҗә белән тәмамлана: Татарстан Язучылар союзының беренче идарә составына 9 кеше сайлана. Алар: Кави Нәҗми (председатель), Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский, Хәсән Туфан, Ләбиб Гыйльми, Г. Ризванов, В. Красный, Кәшшаф Төхфәтуллин (секретарь). Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына. Бу 12 делегатның 9 ы әле саналган идарә әгъзалары, калган 3 се идарә әгъзалыгына кандидатлар: Ибраһим Гази, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Сәйфи-Казанлы. Аерым исемнәрне искә алмаганда, нигездә, мәгълүм шәхесләр, татар әдәбиятыннан хәбәрдар булган кешеләр өчен билгеле язучылар. Ул вакытта алар әле яшь: 30–40 лар тирәсендәге гайрәтле ир-егетләр. Алдагы 10–15 елда нинди әсәрләр язарлар да, үзләренә нинди язмыш язылыр?..

Совет Язучылары союзы оешу турыдан-туры Максим Горький исеме белән бәйле. Ул—аның идея җитәкчесе, фактик оештыручысы. Бу грандиоз башлангычны күтәреп җибәрер өчен, әлбәттә, дөньякүләм абруйлы бер бөек шәхес кирәк булган. Ул — М. Горький. Язучылар арасында аңа тиң кеше юк ул заманда. Шуңа күрә дә, оештыру комитеты рәисе буларак, Совет язучыларының беренче бөтенсоюз съездын ул ачып җибәрә дә. Протокол тәртибе буенча, ВКП(б) ҮК секретаре А. Жданов нотыгыннан соң, төп докладны да М. Горький ясый.



*СССР язучыларының I съезды М.Горький чыгышы белән ачыла*

Ул көннәрнең язма рәвештәге иң ышанычлы шаһиты — съезд стенограммасы (Съездда катнашкан берәр кеше исән микән әле? Исемлектә миңа азмы-күпме таныш фамилияләрне барлап чыктым — очрамады. Бу җыенда яшь журналист яки язучы булып катнашкан берәрсенең исән булуы да мөмкин). 50 басма табакка якын күләмле документ. Үзе бер энциклопедия! Булмый ни, чыгыш ясаучыларның саны гына да 224 кә җитә. Котлау-тәбрикләүдә катнашучыларны да исәпләсәң, трибунадан 300 дән артык кеше нотык тота! Без бу стенографик язмалардан цитата рәвешендә кайбер чыгышлардан өзекләр, җөмләләр китереп узарбыз. Факттан да дөресрәк факт юк. Алар, нигездә, СССР Язучылар союзының Уставын тәшкил иткән тезислар. Ә Устав инде үзенчә бер канун дигән сүз.

М. Горький, съездны ачканда, беренче җөмләсендә үк мондый сүзләр әйтә *(кайбер цитаталарны съездда сөйләнгәнчә, рус телендә бирергә булдык. — Р. Ф.)*: «...разрешаю себе сказать несколько слов о смысле и значении нашего съезда. Значение это — в том, что прежде распыленная литература всех наших народностей выступает как единое целое перед лицом революционного пролетариата всех стран и перед лицом дружественных нам революционных литераторов».

М. Горький доклады һәркем өчен, бигрәк тә язучы өчен, бүген дә кызык һәм гыйбрәтле. Бөек язучы күтәргән кайбер мәсьәләләр бүген дә бик актуаль. Әйтик, ул Көнбатыш әдәбиятчыларының күп әсәрләрендә кешенең түбән инстинктларын уята торган мотивларны: үтерү, көчләү, талау, зина кылу фонында каһарман итеп сурәтләнгән персонажларны тәнкыйтьли (Дәрдеменд әйтмешли, «нә дәригъ» — бүген китап базарларыбыз шундый «әсәрләр» белән тулган!), дөнья барышының үзәген тәшкил иткән гади хезмәт кешесен олыларга өнди. Докладның иң төп тезисларының берсе — халык иҗатына игътибарны юнәлтү. Һәр әдәбиятның нигезендә фольклор ята дип саный Горький. Бу дөрес фикер, аксиома кебек хакыйкать, бик вакытлы яңгырап, язучылар өчен дистә еллар буена директива, үзенә күрә бер күрсәтмә булды. Бигрәк тә яңа туып яки тернәкләнеп килүче әдәбиятлар өчен файдалы булды бу девиз. Күп кенә халыклар рухи тарихларыннан — халык иҗатыннан — үзләренең мифик яки реаль геройларын «казып» чыгардылар, нәфис әдәбиятларына нигез салдылар.

М. Горький докладында күпләребез, бигрәк тә безнең өчен бик тә кадерле, чын мәгънәсендәге интернациональ рухлы фикерләр тагын бар. Ул, мәсәлән, болай ди: «Мы не имеем



*СССР язучыларының I съездында алынган рәсем. Беренче рәттә сулдан уңга: Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбайский, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти. 1934*

право игнорировать литературное творчество нацменьшинств только потому, что нас больше. Ценность искусства измеряется не количеством, а качеством. Если у нас в прошлом — гигант Пушкин, отсюда еще не значит, что армяне, грузины, татары, украинцы и прочие племена не способны дать величайших мастеров литературы, музыки, живописи, зодчества...».

Гомумән, «тормыш университетлары»н тирән үзләштергән, яшәешендә төрле милләт вәкилләренең төрле катламнарын яхшы белгән Горький җир йөзендәге халыкларга тирән ихтирам белән карый. Татар халкын аеруча якын күрүе аның һәм әсәрләрендә, һәм җәмәгать эшчәнлегендә ачык сизелә. Ул үзенең бу докладында да, милләтләр турында сөйләгәндә, татарларны гел искә ала. СССРдагы дүрт-биш милләтне санаган чакта татарны телгә алмый калмый. Бер татар язучысы менә нәрсә язган, дип, докладында өзек тә (ул үзе машинкада 1,5 бит булыр) укып күрсәтә. Йә, хәзер кайсы рус язучысы безнең хакта дөньякүләм трибунадан шулай әйтер микән? Солженицынмы? Распутин яки Беловмы?.. Юк, алар әйтмәсләр, бүтәннәре дә әйтергә охшамаган.

Бу съездда Татарстаннан 12 вәкил катнашканын искәртеп узган идек. Аларның тавышы ишетелгәнме бу җыенда? Гомумән, татар әдәбияты турында нинди сүз булган? Моңа җавап ачык: татар язучылары съезд эшендә актив катнашкан һәм татар әдәбиятының рейтингы югары булган. Дәлил рәвешендә шуны гына әйтү дә җитә: съездда милли әдәбиятлар буенча украин һәм белорус вәкилләреннән соң, өченче итеп сүз Татарстан Язучылар союзы рәисе Кави Нәҗмигә бирелә, һәм ул татар әдәбиятының торышы турында зур доклад белән чыгыш ясый (грузин, әрмән, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, таҗик әдәбияты вәкилләренә сүз әле соңрак бирелә. Гомумән, милли әдәбиятлар буенча, М. Горький докладын санамаганда, нибары тугыз халыкның әдәбияты турында гына махсус докладлар ясала. Кызык, 70 елдан соң, хәзер шундыйрак халыкара форум булса, безгә сүзне кайчан бирерләр, гомумән, бирерләр иде микән?). Шуңа өстәп тагын бер татар язучысы чыгыш ясый әле бу съездда. Ул — Кәрим Тинчурин. Бу хакта белүчеләр аз. К. Нәҗми һәм К. Тинчурин чыгышлары турында шәрехләп сөйләп тормыйм — аларны үзеңә уку кирәк — берничә сүз белән генә төп фикерләрен әйтеп узам. К. Нәҗми, Язучылар оешмасы рәисе буларак, татар әдәбиятының шул чордагы торышы турында тәфсилле сөйли, заманы, дөресрәге, партия кушканча, элекке тормышны, буржуазия вәкилләрен, милләтчеләрне, әлбәттә, яхшы ук сүгә. Шулай ук замандашлары Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Х. Туфан, Ш. Усманов, К. Тинчурин, М. Әмир, И. Гази, М. Җәлил, Ф. Кәрим һ. б. турында уңай фикерләр әйтә, иҗатларын югары бәяли. Кәрим Тинчурин съездда партиясез делегат сыйфатында чыгыш ясый, күбрәк татар драматургиясенең хәле, үсеш перспективалары турында сөйли. Һәр ике оратор да, партиягә бирелгәнлекләрен демонстрацияләүгә дәлил итеп булса кирәк, сыйнфый нәфрәт белдереп, Гаяз Исхакыйны каты тәнкыйть итәләр... Ничек кенә булмасын, зур трибунадан алар татар халкы, аның язучы вәкилләре булып чыгыш ясаганнар. Ялгышларын Алла ярлыкасын, әмма аларның файдалы гамәлләре дә сагынып искә алырлык.

Мандат комиссиясе белдерүе дә игътибарга лаек. Делегатларның милли составы ягыннан караганда, хәл болайрак: руслар — 201 (алар арасында яһүдләр дә шактый булган дип исәпләргә кирәк), украиннар — 30, грузиннар — 28, татарлар — 19 (бу санга бүтән өлкәләрдә яшәүче татарлар да кергән; мәсәлән, Габдрахман Теләш — Чиләбедән), әрмәннәр — 19, үзбәкләр — 12, төрекмәннәр — 5... Икенче бер мо-

мент—яшь ягы (бүгенге көн күзлегеннән караганда бу бик мөһим): съездда катнашкан делегатларның уртача яше — 35,5 яшь! Ә менә хатын-кыз депутатлар бу съездда аз булган: нибары 21 кеше. Эмансипация, күрәсең, әле уянып кына килгән чор...



*Кави Нәҗми*

Шулай итеп, август уртасында башланган съезд сентябрь башында эшен тәмамлый. Докладлар укылган, нотыклар сөйләнгән, котлаулар яңгыраган, Сталинга, партиянең башка җитәкчеләренә сәлам-антлар юлланган... Чыгышлар турында өстәп шуны гына әйтәсе килә: шул чорның иң күренекле язучылары катнашкан һәм сүз әйткән бу съездда. Совет чорының классиклары саналганнардан — М. Горький, М. Шолохов, С. Маршак, А. Толстой, К. Федин, А. Фадеев, Л. Сейфуллина, Н. Тихонов, А. Сурков, А. Серафимович, И. Эренбург, Б.Пастернак, К. Чуковский, И. Бабель, Л. Соболев, М. Шагинян...; милли әдәбият вәкилләреннән — С. Айни, М. Бажан, К. Нәҗми, Т. Табидзе, И. Кадыр, С. Стальский, С. Сәйфуллин, Я. Колас...; чит ил язучыларыннан — Луи Арагон, Жан-Ришар Блок, Рафаэль Альберти, Антал Гидаш, Андре Мальро, Мартин Андерсен-Нексе... Төп һәм кызыклы докладларның тагын берсе турында әйтми узсак, дөреслеккә хилафлык булыр; ул — Н. Бухарин доклады. «Поэзия, поэтика һәм СССРда поэтик иҗат проблемалары». Коммунистлар партиясенең югары эшелонындагы бүтән берәр кешенең шигырь турында шундый характерда доклад ясаганы, мөгаен, тарихта бүтән юктыр.

Әйе, съезд тәмамлана. М. Горький йомгаклау сүзе белән чыга (нишләптер стенограммадан берничә гыйбарә хәтергә нык сеңеп калды: «Мы живем и работаем в начале первого




акта последней трагедии трудового человечества». Монысы — сискәндергәне, икенчесе — күңелгә ятышлысы: «Не менее важно знание нами языков армян, грузин, татар, тюрков...» Съездда 101 язучыдан торган Идарә сайлана. Идарә әгъзасы итеп Татарстаннан Кави Нәҗми кертелә. Аерым докладлар буенча (М. Горький, К. Радек, С. Маршак) махсус резолюцияләр кабул ителә... Иң мөhиме — «бөтендөнья пролетариаты Ватаны» — СССРда рәсми рәвештә Совет Язучылары союзы оеша hәм аның төп кануны — Устав кабул ителә. Еллар узып, аз-маз үзгәрү-редакцияләнүләр кичерсә дә, бу Устав ким дигәндә ярты гасыр кагылгысыз булды, 1934 елда кабул ителгән маддәләр XX гасырның 90 нчы елларына кадәр язучылар өченканун булып яшәде.

Уставның асылын аңлар өчен аннан берничә маддә-өзек китереп узу мәслихәт булыр. «Писатели Союза Советских Социалистических Республик, стоящие на позициях Советской власти, желающие активно участвовать своим творчеством в классовой борьбе пролетариата и в социалистическом строительстве, решили объединиться в единый Союз советских писателей».

«Союз советских писателей ставит генеральной целью создание произведений высокого художественного значения, насыщенных героической борьбой международного пролетариата, пафосом победы социализма, отражающих великую мудрость и героизм коммунистической партии. Союз писателей ставит своей целью создание художественных произведений, достойных великой эпохи социализма».

Бу съездда шулай ук совет әдәбиятының үзәге, дөресрәге, принцибы саналган «социалистик реализм» дигән термин тәмам формалашып канунлаштырыла. Бу хакта Уставта болай диелә: «Социалистический реализм обеспечивает ху-

дожественному творчеству исключительную возможность проявления творческой инициативы, выбора разнообразных форм, стилей и жанров».

Менә шушы дөньякүләм идеологик акциядән соң язучылар мохитен — шул 70 еллык чорны — ничегрәк итеп системалаштырырга соң? Нинди принциптан чыгып, нинди периодларга бүләргә? Бу мәсьәлә галим-голәма өчен дә, әлбәттә, актуаль булып кала. Әйтик, «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 томлыгын карасаң, анда үзенчә бер тәртип: дистә елларны иҗтимагый-сәяси вакыт бердәмлегенә карап бүлү һәм бәһаләү күзгә ташлана. Ә әдәбиятның үз үсеш-торгынлык чорларын исәпләп системалаштырсаң, бүтәнчәрәк бүленеш килеп чыга. Чоры катлаулы һәм болганчык булгач, бернинди бүленеш тә фәнни объектив кысаларга сыеп бетә алмый. Шулай да үзем тоемлаганча һәм аңлаганча *дүрт периодка бүлеп карар идем бу җитмеш елны: 1934 елдан сугыш ахырына кадәрге еллар; сугыш соңыннан башлап 50 нче еллар ахырына кадәрге еллар; 1960–1990 еллар; 90 нчы еллардан бүгенге көнгә кадәрге еллар.* Әлбәттә, мондый бүленеш тә шартлы һәм ясалма. Ә миңа үз фикеремне белдерер өчен уңай булгач тагын нәрсә кирәк?

Әйдәгез, шул шартлы бүленеш кысаларында татар әдәби хәрәкәтен, шул нисбәттән яңа оешкан Язучылар союзы эшчәнлеген күз алдыннан кичереп карыйк.

## I

Әйе, зур тарихи съездан рухланып, канатланып кайта язучыларыбыз. Эшкә тотыналар… Ә алда? Фаҗигаи еллар, сугыш афәтләре… Шуны гына әйтү җитә: Зур Съездда яхшылар рәтендә макталган язучыларның яртысыннан күбесе репрессия корбаннарына әверелә?! Гарәпчә мантыйкка, грекча логикага сыймас хәлләр…

Шулай да Язучылар союзы оешу мөнәсәбәте белән әдәби хәрәкәттә җанлану нык сизелә. 1934 ел — тоташы белән Язучылар союзын оештыру елы. Әйтик, май аенда «Кызыл Татарстан»да СССР Совет Язучылары союзының уставы басыла. Июнь аенда Совет Язучылары союзына кабул итү Үзәк Комиссиясенең утырышы була. Союзның беренче әгъзалары кемнәр соң? Менә алар — Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, К. Тинчурин, Ш. Камал, Г. Гали, Г. Толымбай, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гали, И. Гази, М. Крыймов, Ә. Фәйзи, И. Туктаров, М. Максуд, Ф. Кәрим, С. Баттал, Т. Госманов (Хатип

Госманның абыйсы). Совет Язучылары союзына кандидат итеп Ш. Усманов, Р. Ишморат, Б. Зернит, А. Шамов, Галимҗан Мөхәммәтшин, Т. Гыйззәт, Ә. Ерикәй, Н. Баян тәкъдим ителә. Алда әйтеп үтелгәнчә, июль ахырында Татарстан совет язучыларының Беренче съезды үткәрелә... Соңрак Язучылар союзы инициативасы белән төрле секцияләр оештырыла, яшь язучылар белән эшләү буенча консультация бюросы төзелә. Язучылар төрле юбилей чараларында актив катнаша (Пушкинның үлүенә 100 ел, Тукайның тууына 50 ел, Горький, Г. Камал, Ш. Камал, Такташка багышланган кичәләр һ. б.)... Әлбәттә, җыелышлар (гомумиләре дә, партиялеләрнеке дә) үтә, мотивлары «татар совет әдәбиятының яңа үсеш баскычлары» дигән яки шуңа охшашлы формулировкадагы докладлар сөйләнелә... Союзның шул чордагы эшчәнлегендәге бер үзенчәлекне искәртеп үтү кирәк: тәрҗемә эшенә, нигездә русчадан татарчага тәрҗемә итүгә бик нык игътибар бирелә әлеге чорда. Бу аңлашыла да. СССР Язучыларының Беренче съездында ил халыкларының әдәбиятларын тәрҗемә аша пропагандалау төп мәсьәләләрнең берсе итеп куелган иде. Горький докладында да, башка чыгышларда да күп әйтелә бу хакта. 1934 елда ук Татарстан Язучылар оешмасы каршында тәрҗемәчеләр секциясе эшли башлый. Җитәкчесе — Ибраһим Гази. Бу вакытта Казанда инде Марксизм-ленинизм институты оешкан. Ул, нигездә, Ленин - Сталин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнде (бу җәһәттән татарлар, илдәге күп халыкларны уздырып, — милли республикалар арасында бердәнбер түгел микән әле? — Ленинның ул заманда русча чыккан бөтен әсәрләрен татарча бастырып чыгарды). Татарстан китап нәшриятында оператив рәвештә М. Горькийның татарча өчтомлыгы дөнья күрә. М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»е, Ф. Гладковның «Энергия» исемле романы, А. Корнейчукның «Эскадраның һәлакәте» дигән пьесасы, А. Гайдарның «Мәктәп» повесте басылып чыга... Тәрҗемәчеләре А. Шамов, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, С. Әдһәмова һ. б. «Совет әдәбияты»ның шул еллардагы саннарын алып карасаң да, журналның иң күп өлеше тәрҗемә әсәрләргә бирелгән. Күрәсең, директив күрсәтмә арттырыбрак үтәлгән. Бер яктан, татар укучысы рус әдәбиятын туган телендә укый алган. Әсәрләрнең идея-художество дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, телне саклау җәһәтеннән бу гамәл аклана да кебек. Әмма... Хәрәкәт бер яклы гына булган шул. Дөрес, «Огонек», «Лит. Газета» битләрендә татар язучыларының кайбер кечкенә күләмле әсәрләре басылу очраклары да булган...



*Әдип Фәтхи Бурнашның кулга алынган көннәрдә (1940) һәм төрмәдә утырганда (1942) төшерелгән рәсемнәре*

Болар, нигездә, 1934–36 нчы еллар, Язучыларның оештыру съездлары үткәннән соң беренче еллар. Ниһаять, ил тарихының шомлы 37–38 нче еллары. Әйткәнемчә, аңларга һәм аңлатырга авыр чор… Язучылар лидеры булып, Союзны оештырып йөргән яки бу башлангычны күңеле һәм гамәле белән хуплаган байтак әдипләр кулга алынып төрмәләргә утыртылган. Әле бер ел элек кенә 25 еллык иҗат бәйрәме үткәрелгән К. Тинчурин ябылуда, Г. Ибраһимов төрмәдә… Вакыт аралыкларында бераз аерымлыклар булса да, шул ук язмышка дучар булган И. Салахов, Ш. Усманов, Г. Толымбай, Г. Гали, М. Галәү, Г. Нигъмәти, Ф. Бурнаш, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими, С. Сүнчәләй, Ф. Сәйфи-Казанлы, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, М. Әмир, С. Рәфыйков, Л. Гыйльми, Х. Туфан… Исемлекне дәвам иттерергә була. Кайсылары юкка чыгарылган, кайсылары алтын гомерләре мәхбүслектә үткәч кенә кайта алган, кайсылары фәлән ай гына утырып, куркытылып, кушканны үтәүчеләр булып калган… Әдәби фигураларның байтагы кулга алынгач, көчләр таркатылгач, табигый, Союзның тулы канлы эшчәнлеге турында сөйләү кыен… Чор «таләбе» буенча оешма җитәкчелегендә дә яңа «лидерлар» пәйда була. Т. Имаметдинов, И. Вахитов, Х. Җәмил… Бу исемнәрне өлкән буын язучыларының да бик сирәге ишетеп кенә белә булыр… Архив тарихында бар саналсалар да, әдәбиятта алар юк. Шулай да еллар хроникасына күз салсаң, оештыру эшләре бер дә бармаган дип әйтеп булмый.

Әйтик, 1937 елның 28 апрель — 5 май көннәрендә Татарстан язучыларының гомуми җыелышы була (докладчы Т. Имаметдинов), июнь аенда Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» пьесасын укып тикшерү уздырыла, сентябрьдә иң яхшы опера либреттосына игълан ителгән конкурсның комиссия составына берничә язучы кертелә, «Совет әдәбияты»ның 6–7 саннары тулысы диярлек М. Горький иҗатына багышлана. 1938 елның апрелендә Тукайның үлүенә 25 ел тулуга багышланган зур кичә үтә, июньдә язучыларның гомумҗыелышы уздырыла (докладчы — Н. Баян). 1939 елның башында яшь язучыларның зур бер төркеме оешмага әгъза итеп алына (Ф. Хөсни, А. Шамов, Г. Бәширов, Г. Галиев, Г. Гобәй, А. Әхмәт, А. Алиш, Ә. Исхак, Р. Ишморат, Г. Хуҗи, И. Гази, Г. Кутуй, Н. Дәүли, Х. Госман, М. Бубеннов, С. Хәким, Г. Хәбиб, Г. Халит, Л. Җәләй, М. Вәдүт, М. Әблиев; ел ахырында бу төркемгә Н. Исәнбәт, Х. Садри, С. Урайский, Ә. Камал һәм тагын берничә айдан — З. Солтанов, Ә. Ерикәй дә өстәлә), Язучылар союзының фольклор секциясе әзерләгән «Халык иҗаты» дигән җыентык басылып чыга, СССР Верховный Советы указы белән Ш. Маннур — Хезмәт Кызыл Байрагы, Т. Гыйззәт «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнә, бер елдан соң Ш. Камалга СССРның иң зур ордены — Ленин ордены бирелә (соңрак «орденлы шагыйрь», «орденлы язучы» дигән сүзтезмә әлеге язучыларның исемнәренә озак дистә еллар синоним-тагылма булып йөриячәк). Язучылар оешмасы өчен бу елның иң мөһим вакыйгасы, мөгаен, Муса Җәлилнең Язучылар идарәсенең җаваплы секретаре, ягъни җитәкчесе итеп сайлануыдыр. Әдәби җитәкчелекнең очраклы кешеләрдән арынуы — бу инде репрессиянең бетүгә, илдә сәяси-рухи тормышның беркадәр савыгуга таба баруын күрсәткән фал иде. Гомумән, сугыш алдындагы ике елда татар җәмәгатьчелеге өчен күңел булырлык гамәлләр кылына башлый. Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла (беренче куелган тамаша Н. Җиһановның «Качкын» операсы. Ә. Фәйзи либреттосы). Татарстан хөкүмәте Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. СССР Халык Комиссарлары Советы карамагында Сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә татар сәнгате декадасын үткәрергә планлаштыра... Югалтулар табулардан күбрәк булса да, нинди дер стимул бар!

Шул чорда (яки беркадәр алданрак) язылган кайбер әсәрләрне хәтеребезгә төшермәсәк, сүз сөрешенең мәгънәсе тулы булмас. Алар — «Тапшырылмаган хатлар» (Г. Кутуй), «Агыйдел» (М. Әмир), «Мәрҗәннәр» (К. Тинчурин), «Хуҗа

Насретдин» (Н. Исәнбәт), «Флейталар» (Ә. Фәйзи)... Бу әсәрләрне язуда Язучылар оешмасының тәэсире никадәр булгандыр, аны гүр иясе булган ул язучылар үзләре генә белгәннәрдер, без фәкать фараз итә генә алабыз. Хронология буенча шул елларга туры килә үзләре... 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Идегәй» дастанының дөнья күрүе үзе бер вакыйга була. Бу бөек дастан әдипләр, бигрәк тә шагыйрьләр өчен бик озак еллар осталык мәктәбе булып хезмәт итәчәк әле.

* * *

Сугыш еллары... Бөек Ватан сугышы еллары. Сугыш сүзе алдындагы эпитетларга гасыр ахырында төрле кешеләрнең төрлечәрәк фикере булса да, барыбер илдәшләрнең илбасарларга каршы сугышы иде ул. Шуңа күрә «канга — кан, үлемгә — үлем» дигән сүз шигарь генә түгел, халык күңеленә иңдерелгән һөҗүмчән максат та иде. Менә шулай килеп чыга икән дөньяда: татар сәнгате декадасы уздырасы Мәскәү шәһәрен иң әүвәл үзен саклыйсы бар икән әле! Шул бәйрәмдә катнашырга тиешле башкала язучыларын Казан вокзалында каршылап, Казанның үзендә, яшәү өчен аннан да аулаграк Чистай, Алабуга шәһәрләренә күчереп урнаштырышасы бар икән! Үзебезнекеләргә шинель киеп Карелия, Волхов, Украина фронтларында карлы-бозлы окопларда ятасылар, атакаларга күтәрелеп ут астына керәселәр бар икән! Сөйлиләр бит: Свияжск станциясендә ике поезд очрашкан. Казан ягына баручы Мәскәү язучылары татар язучыларыннан сорыйлар икән: «Сез кая?» — «Фронтка!» — «Ә сез?» «Эвакуация белән Чистайга!..»

Шулай итеп, татар язучыларын 37 нче еллар бер «чабып» ташлаган булса, икенче бер афәт — сугыш янә байтагын кырып салды. Бүтән халыклар белән чагыштырганда, сан нисбәтендә язучылардан иң күп югалту татарда, диләр. Булгандыр, саный башласаң да байтакка чыга бит: М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй, Н. Баян, Х. Мөҗәй, М. Вәдүт, Р. Ильяс, К. Басыйров, М. Әблиев, Р. Саттар, Д. Фәтхи, Х. Кави... Өзтабар-журналист, язучы Шаһинур Мостафин язып чыкканча, Ватан сугышында 104 татар язучысы һәм журналисты (яшь һәм башлап язучыларны да кертеп) катнаша, шуларның 31е корбан була. Өчтән бере дигән сүз!

Исән булып кайтканнарның да күбесе фронт яраларыннан җәфаланып яшәде. Фронтовикларның кайберләре — Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, З. Мансур, С. Урайскийлар һ. б. —



*Фронтовик язучылар: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй*

50 яшьләренә дә җитми дөнья куйдылар. Гомумән, физик яктан сау килеш теге яки бу формада фронтта булмаган татар язучысы бик аз. Мин белгәннәрдән Гариф Гобәй белән Галимҗан Латыйп кына иде бугай.

Язучылар союзы эшчәнлегенә кайтыйк. Сугыш башланының беренче көннәреннән үк Союз идарәсе утырышларында оешманың эшен хәрби шартларга яраклаштыру мәсьәләсе карала. Тукай исемендәге кабинет (соңрак Клуб дип йөртелгән зал ул елларда шулай аталган, хәзер бу залда «Мәгариф» нәшриятының техник хезмәткәрләре — компьютерчылар, корректорлар эшли) үзенә күрә бер штабка әверелә. ПВХО төркеме оештырыла, Мәскәүнең качак язучыларын үзенә сыендыра, интернационал составтагы язучылар җыелышлары уздырыла (мәсәлән, бу залда А. Фадеев «Совет язучылары Ватан сугышында» дигән доклад ясый), оборона фондына акчалар җыйнала (Т. Гыйззәт, Ш. Камал — 1000 әр сум, Г. Кутуй 650 сум акча кертә), сугыш шартларында язучының барлык иҗат эшләрен яңача кору, бөтенләе белән фронт өчен хезмәткә буйсындыру һәм активлаштыру, шуларга җитәкчелек итү өчен язучылар идарәсе каршында агитация-пропаганда бүлеге оештырыла (җаваплылар — Ш. Маннур, Т. Гыйззәт, Р. Ишморат, Г. Кутуй)... һәм 1942 елның 8 гыйнварында Казандагы совет һәм чит ил язучылары катнашында Тукай клубында М. Җәлилне фронтка озату була (Мәңгелек Бөеклеккә озату! Җаны һәм бармаклары Ходай тарафыннан музыка өчен яратылган икенче бөек талантны — Фәрит Яруллинны, белмим, ничек озатканнардыр?!)

Татарстанга Мәскәүдән эшелонлап дигәндәй (ике йөздән артык язучы үзләренең гаиләләре белән килә безгә) олуг-олуг язучылар килеп төшкәч, Казаннан тыш, Чистай да үзенчә бер әдәби мәркәзгә әйләнә. Шулай булмый ни! — кемнәр

генә юк анда! К. Федин, Н. Асеев, М. Исаковский, Л. Леонов, Б. Пастернак, Л. Ошанин, К. Тренев, Д. Бедный, А. Сурков, В. Инбер, А. Тарковский, В. Боков… Тагын күп дистә исемнәр санарга мөмкин. Алар турында уйлаганда, сугыш чорында Чистайда яшәгән Л. Леоновның мәгълүм сүзләре искә төшкәли. «Если бы только и было суждено в жизни телом остановить пулю, летящую в сторону Родины, то и для этого стоило рождаться на свет».

1941 елның көзенә таба Чистайга Мәскәү язучыларының байтак гаиләләре дә күчеп килә. Аларның күбесе бирелә ике еллап яшиләр. Гаиләләре янына фронттан А. Твардовский, А. Сурков, С. Щипачев, И. Сельвинский һәм башка күренекле шагыйрьләр кыска сроклы командировкаларга кайтып йөриләр. Чистайда СССР Язучылар союзы җитәкчесе А. Фадеев та берничә мәртәбә була. Чистайда яшәүче язучылар мораль яктан булса да фронтка ярдәм итүдә үзләренчә байтак эш башкаралар. Әдәби кичәләр, коллективларда, мәктәпләрдә очрашулар, матбугатта һәм радио аша чыгышлар… Иҗат һәм оештыру эшләре дә тукталып тормый: Л. Леоновның «Нашествие» пьесасы буенча премьера булып уза, Б. Пастернак Шекспир әсәрләрен тәрҗемә итә, Л. Ошанин СССР Язучылар союзына тәкъдим ителә… Эвакуациядәге язучылар тормышы турында



*Муса Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәре»*

Г. Мухановның 1987 елда Казанда чыккан «Чистопольские страницы» дигән китабында тәфсилле язылган. Чистайдагы Б. Пастернак музеенда да бу хакта шактый материал бар. Эвакуациягә килгән язучылар бер Чистайда гына яшәмәгәннәр. Әйтик, сугыш алдыннан гына «Спи, младенец! Не то злому псу — татарину отдам!» дигән юллар язган шагыйрә М. Цветаеваның гомере Татарстан җирендә — Алабугада очлана… Дөнья бу!

Ил өстенә килгән уртак афәт, һичшиксез, кешеләрне берләштергән, туганлаштырган – максат бер, күңел ачык булгач, тар җирне дә киң итеп качакларны сыендырган татар җире. Кайбер Мәскәү язучылары татар язучысы гаиләләрендә дә сыену тапкан. Максат уртак — дошманны җиңү! Сугыш башында ук «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») «Бөтен көч — дошманны җиңүгә» исемле редакцион мәкалә бастыра. Анда мондый юллар бар: «Йөз миллионнарча кешеләрнең ирке, бәхетле тормышы, якты киләчәк һәм намусы өчен бара торган бу бөек көрәштә культура фронтының бөтен армиясе бердәм булып фашизмга каршы аяусыз сугышка күтәрелде. Туры сүз массаларда дошманга каршы ачы нәфрәт, каты ачу тудырсын, миллионнарга үзенең туган иле каршындагы мөкатдәс бурычын төшендереп бирсен… Шагыйрьләрнең шигыре сугышчыларны геройлыкка рухландыра торган көчле чаң булып яңгырасын!..» Сүз уңаеннан билгеләп узыйк: сугыш чорында шигырь чаң булып кына яңгырамады, меңләгән укучылары аша дошман йөрәгенә ук булып кадалды, бәгырен ут булып өтте… Дистәләгән шагыйрьләребез иҗаты, беренче чиратта М. Җәлил һәм Ф. Кәрим иҗаты шуны дәлилли.

Шул еллар хроникасына янә күз салыйк. Нинди генә шартлар булмасын, фронттагы, тылдагы тормыш барыбер дәвам итә, үлем-хәсрәт тә, кайгы-яшь тә кешеләрнең яшәүгә омтылышын туктата алмый. Язучылар оешмасында да эшхәрәкәт бара. Язучылар тарафыннан (К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Х. Ярми) күмәкләшеп «Татар халкының фронтовик татарларга сәлам хаты» языла. Соңрак миллионнан артык кеше кул куйган бу хат «Правда», «Известия» газеталарында игълан ителә (март, 1943), аннан соң республика һәм фронт газеталарында басылып чыга. Классикларның, бигрәк тә рус язучыларының төрле уңай белән (М. Лермонтовның үлүенә 100 ел, М. Горькийның тууына 75 ел; И. Крыловның үлүенә 100 ел, А. Грибоедовның тууына 150 ел һ. б.) юбилейлары уздырыла, апрель айларында Г. Тукайны искә алу кичәләре үтә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында «Татарстан

Язучылар союзы идарәсенең эше» турында карар кабул ителә. Шул чор хроникасыннан искә алырлык тагын бер мөһим вакыйга: 1943 елның октябрь аенда СССР Язучылар союзы президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы махсус тикшерелә. А. Фадеев рәислегендә үткән бу җыелышта Казаннан — Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Кашшаф; шуларга өстәп фронттан чакырып кайтарылган Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, М. Садри, Г. Галиев катнаша. Шул еллардагы татар әдәбияты турында Г. Кашшаф доклад ясый (сугыш елларында Г. Кашшаф Казан әдәби хәрәкәтендә иң үзәк фигураларның берсе була. М. Җәлилнең васыять рәвешендә язган язмасында аның исеме беренчеләрдән булып аталуы тиккә түгел!). Татар әдипләренә М. Горький кебек туганнарча караучы А. Фадеев язучылар делегациясен ВКП(б) Үзәк Комитеты пропаганда һәм агитация бүлегенең җаваплы хезмәткәрләре белән дә очраштыра. «Авыр сугыш елларында татар телендәге әдәби журналның («Совет әдәбияты») саклануын партия Үзәк Комитетында хупладылар гына түгел, бәлки югары бәяләделәр: «Бу — сезнең каһарманлык!» Партия Үзәк Комитеты безгә тиражны өч тапкырдан күбрәк арттырырга (ул елларда журналның тиражы уртача 4 мең) һәм 10 мең данәгә кадәр җиткерергә рөхсәт итте һәм кәгазь ягыннан ярдәм күрсәтте» дип язды соңрак журналның шул еллардагы редакторы Гази Кашшаф.

Фронтта да байтак язучыларыбыз, каләмне штыкка тиңләп, алгы сызыктагы сугыш операцияләрендә катнашу белән бергә, фронт газеталарын чыгаралар (ул газеталарның тарихы болай: 1942 елның башыннан Германия идеологлары инициативасы белән СССР халыкларының күп телләрендә газеталар чыгарыла башлый, аларны совет сугышчылары арасында таратырга тырышалар. Мәсәлән, татар телендә «Идел-Урал», «Хәбәрче» исемле газеталар, «Татар әдәбияты» дигән журнал чыгарыла. Шуңа каршы җавап итеп, ВКП(б) Үзәк Комитеты, ашыгыч рәвештә дигәндәй, «Матбугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары» дигән карар кабул итә һәм тиздән милли телләрдә газеталар чыга башлый. 1942 елның июленнән башлап, төрле фронтларда татарча уналты газета чыга. «Ватан өчен», «Алга, дошман өстенә!», «Сталин байрагы», «Совет сугышчысы» һ. б.). Үз вакытында аларда Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Х. Госман, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, Б. Рәхмәт, Г. Галиев, һәм башка язучылар эшләгәннәр. Шулай ук, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Иделле, Х. Хәйри һәм башка-



*Гази Кашшаф*

лар, озак вакытлы командировкаларга барып, бу газеталарда эшләп-эшләп алалар.

Сугыш чорының бер төере булып, зыялылар, шул исәптән язучылар аңына сеңеп калган тагын бер документ турында әйтми китеп булмый. Ул — 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитетында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» дигән карар. 1944 ел… Сугышның Советлар Союзы файдасына бетәчәге тәмам ачыкланган ел. Бөтен совет халкын, төрле милләт вәкилләрен рухландырып, уртак җиңүгә бер йодрык булып барасы иде дә… юк! — тагын репрессияләр — тулы бер халыкларны көчләп үз илләреннән куалар: балкарлар, калмыклар, Кырым татарлары, чеченнар, греклар, карачайлар… Бу карар — Идел буе татарларына да үзенчә бер мәгънәле «күз агы белән карау» иде. Карар, иң беренче чиратта, тарихчыларга, язучыларга юнәлтелгән, «тарихыгызны ныклап өйрәнеп, аннан каһарманнар эзләп маташмагыз! Тарихны кушылганча гына аңлагыз һәм аңлатыгыз!» дигән мәгънә ята иде бу документта. Карарның шаукымы шактый еллар барды. 60 нчы еллар башында без студентларга әдәбият белгечләре лекцияләрендә, сабак-нәсыйхәт рәвешендә, бу карардан цитаталарны бик мул китерәләр иде әле…

Гаделлек өчен 1944 елда булган позитив ике вакыйганы да искә алып үтик: шул ук август аенда Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештыру, Ш. Камалның квартира-музеен булдыру турында РСФСР Халык Комиссарлары Советы карары, һәм икенчесе — Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу. (Бу бүлеккә быел 60 ел. Татар әдәбияты-мәдәнияты тарихында бүлекнең әһәмияте әйтеп бетергесез. Бүгенге әдәбиятны тудыручылар, нигездә, университеттан, шушы бүлектән үсеп чыккан язучылар.)

Шул ук айда Берлинның Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең, Абдулла Алишның һәм тагын тугыз батырның башлары киселә. Берничә атнадан Дахауда Хәйретдин Мөҗәй мичтә яндырыла... Болары да сугыш чорының тетрәндергеч фактлары...

Менә без булдыра алган кадәр әдәби хәрәкәтнең, шул исәптән, Язучылар оешмасы эшчәнлегенең дә бик тә катлаулы чорын үзебезчә күзаллап, күзәтеп чыктык. Шәхес культы һәм сугыш елларын, күп дистә миллионнарның фаҗигасен эченә алган бу чор анализ өчен ифрат кыен чор. Кайбер нәтиҗәләрне, киләчәк хакына уйланулар рәвешендә, укучылар үзләре ясар. Күзәтү барышында аерым вакыйгалар яки факт-документлар нисбәтендә кайбер фикерләремне әйткәләдем. Бу чор әдәби хәрәкәтенә нәтиҗә ясап, берничә штрих кына өсти алам. Зур күтәренкелек, зур планнар белән төзелгән Язучылар союзы, яшәвенең беренче елларында ук бик нык сирәкләндерелсә, хәлсезләндерелсә дә, сугыш елларында авыр югалтулар кичерсә дә, барыбер оешма булып сакланып кала алды, иҗат көчләрен ниндидер бер мобилизацияләүче штаб ролен үтәде (бу очракта Язучылар союзының башында торган берничә шәхеснең исемнәрен атап үтү дөрес булыр: К. Нәҗми (1934–1937), М. Җәлил (1939–1941), Т. Гыйззәт (1942–1944)...) Автономик кысаларда, җитмәсә, экстремаль сугыш чорында, рухи терәк һәм бергәлекне тояр өчен генә булса да, татар язучыларының үз оешмалары, үз үзәкләре булуы уңай бәяләнергә хаклы.



*Татар шагыйрьләре Европада. Мөхәммәт Садри (сулда) һәм Гали Хуҗи. Вена. 1945*

Бу чорда «әдәбиятның әнкәсе» саналган поэзиянең көче, халыкчанлыгы, яшәүчәнлеге тагын бер мәртәбә расланды. Моңа дәлил итеп М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Ф. Кәримнең сугыш чоры әсәрләрен (әйтик, «Кыңгыраулы яшел гармун», «Идел егете») искә алу да җитә. Бүтән жанр-

ларда, бәлки, ул кадәр үк казанышлар булмагандыр (табигый, сугыш чорында — фронттамы, тылдамы — киң полотнолы зур романнарның тууы икеле), шулай да кайбер әсәрләр язылып калынган. Әйтик, «Миңлекамал» драмасы (М. Әмир), «Йөзек кашы» (Ф. Хөсни)... Сугыш елларында, ул чакта әле яшь, ә соңрак әдәбиятта зур урын тотачак байтак язучылар гыйбрәтле тормыш мәктәбе генә түгел, иҗади үсү мәктәбен дә үттеләр. Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ә. Фәйзи, А. Шамов, А. Расих, И. Гази, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов һәм башкалар шундыйлардан.

## II

Сугыштан соңгы елларга күчик. Алдан әйтелгән бүленеш буенча, бу чор 1945–1960 елларны (60 нчы еллар башын) үз эченә ала. Алдагы дистә еллар белән чагыштырганда аңлаешлырак, тотрыклырак чор! Сугыш беткән, ачлыкялангачлык хәттин ашса да (дистәләгән төрдәге салымнар, мәҗбүри заемнар...), кешеләр күңеленең өметле чагы: җимереклекне торгызабыз, илдә социализм — гадел җәмгыять төзибез, киләчәктә, һичшиксез, яхшы яшәячәкбез! Һәрхәлдә, күпче-



*СССР Язучылар союзы идарәсе урнашкан йорт. Мәскәү*

лек шулай уйлаган. Әмма шунысы бар: бу чор Сталин хакимиятенең иң «кикрикле» чагы, «генералиссимус доктринасы»ның халыкара дәрәҗәдә санлаштыра торган чагы... Әлбәттә, реаль тормыш шартлары, куелган максат-шигарьнең ясалма-декларатив булуы кемнәрдәдер протестлы тойгылар да уяткан. Юкса 50 нче еллар башында япь-яшь студентлар, башлап язучы талантлы егетләр — А. Гыйләҗев, Г. Тавлин, М. Рафыйков, А. Тимергалин һ. б. — төрмә-зинданнарга юлыгыр идеме?

Язучылар союзы эшчәнлегенең төп этапларын, гамәл-нәтиҗәләрен, максат-юлларын билгеләүче төп маяк-ориентир ул — съездлар, соңгы дәвердәгечәрәк әйтсәк, корылтайлар. Чөнки съезд — Язучылар оешмасының идарә органнарын сайларга вәкаләтле иң зур җыен. Съездлар аша әдәби хәрәкәт дисбесенең төп төеннәрен (бу очракта тенденцияләрен) тоеп, чамалап була. Әйе, алда тәфсилләп әйтелгәнчә, беренче оештыру съезды Казанда да, Мәскәүдә дә 1934 елны узды. Шул ук елны СССР Язучылар съездында кабул ителгән Устав нигезендә язучылар съездлары өч елдан өч елга уздырылырга тиеш диелгән. Ә ничек килеп чыкты? СССР язучыларының икенче съезды нәкъ егерме елдан соң — 1954 елда гына җыелды! Ирексездән русларның «закон как дышло...» дип башлана торган әйтеме искә төшә. Егерме ел бит! Сугыштан соң да ун елга якын вакыт үтә... Димәк, бу оешма табигый ихтыяҗдан бигрәк, хакимиятнең ихтыяр көче белән идарә ителә торган оешма булып чыга.

Шулай да Татарстан язучылары 1950 елда үзләренең II съездын үткәрәләр. (СССР Язучылар союзының II съездыннан дүрт ел элек!) Үзәк кушуы беләнме, әллә җирле инициатива өстенлек иткәнме? Мөгаен, соңгысыдыр. 1950 елның язында КПССның Татарстан өлкә комитеты «Татарстан совет язучылары союзының эше турында» дигән махсус карар кабул итә. Бу инде үзенә күрә съезд алды прелюдиясе дигән сүз. Конкрет съездлар эшчәнлегенә кадәр, сугыштан соңгы унбиш ел эчендәге кайбер факт, вакыйгалар белән танышып үтик. Тукайның 60 еллыгы зурлап билгеләнә (Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында тантаналы кичә үтә; Казан университеты һәм педагогия институты студентлары өчен Г. Тукай исемендәге стипендияләр билгеләнә; СССР Фәннәр академиясендә шагыйрьгә багышланган фәнни сессия уздырыла һ. б.). Татарстан мәгариф комиссариаты һәм Язучылар союзы балалар өчен татар телендә язылган иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итә. Шагыйрь Ә. Ерикәй СССР Верховный Советына (1946), К. Нәҗми Татарстан АССР Верховный Советына депутат итеп


СОЮЗ СОВЕТСКИХ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ РЕСПУБЛИК

ГЕРОЮ СОВЕТСКОГО СОЮЗА

Президиум Верховного Совета СССР

ПРИСВОИЛ

ЗВАНИЕ ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР

сайлана. Чистай шәһәре музеенда «Язучылар Чистайда» дигән яңа бүлек оештырыла. Рус телендә «Литературный Татарстан» дигән альманах чыга (1947–1958). 1951 елда К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус» романнары Сталин (соңрак аны Дәүләт премиясе дип тә йөрттеләр) премиясе белән бүләкләнә. 1953 елда М. Җәлил өстеннән «кара болытлар» алып ташлана, берничә елдан аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә, «Моабит дәфтәре» Ленин премиясенә лаек була. Сугыш елларында тукталып калган «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасы, «Чаян», «Пионер» («Ялкын») журналлары кабат чыга башлый. Хәзерге «Идел» журналының яралгысы саналырга тиеш «Үсү юлы» дигән альманах чыга (1950–1958). 1957–58 еллар әдәби-мәдәни вакыйгаларга бигрәк тә бай. 1957 елның 24 май–4 июнь көннәрендә Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгать декадасы гөрләп үтә (алда әйтелгәнчә, ул декада 1941 елның ахырына планлаштырыла, сугыш башлану сәбәпле булмый кала). 1958 елда «әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр өчен һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкарган өчен» Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе булдырыла. Шул ук елның 9 августында Казан үзәгендә Тукайга һәйкәл торгызыла (соңрак бу урын Тукай мәйданы дип йөртеләчәк). Бу еллар елъязмасының тагын

бер кадерле сәхифәсе — шәхес культы корбаннары аклана. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Галәү, Г. Газиз, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти һәм башкаларның әсәрләре кабат басыла башлый, зиндан-сөргеннәрдән исән калган Х. Туфан, И. Салахов, С. Рафиков кебекләр әдәби сафка кайта... 50 нче еллар ахырында, соңрак халык язучылары, халык шагыйрьләре булачак, әле ул вакытта өметле яшь язучылар саналган Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камаллар әдәбиятта яңа буразналар сала. 1957 елны беренче мәртәбә Татарстан язучылары турында белешмәлек — биобиблиографик китап чыга (анда 126 язучы турында мәгълүмат бирелгән. Соңрак мондый характердагы китаплар 1970 һәм 1986 елларда дөнья күрде). Медицина институты студенты (!) Шәриф Хөсәенов пьесасы буенча Г.Камал исемендәге Академия театрында «Профессор кияве» исемле спектакль куела...

Әйе, тыныч тормышка хас вакыйгалар хроникасы. Әйтергә кирәк, чагыштырмача матур хроника! Язучыларның төп җыены булган съездлар үткәрү дә билгеле бер тәртипкә салына башлый.

**Татарстан язучыларының II съезды 1950 елның 13–15 июнь көннәрендә үтә.** Съездда язучылардан тыш республика җитәкчеләре, СССР Язучылар союзы һәм үзәк нәшрият вәкилләре, фән эшлеклеләре, журналистлар, укытучылар, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче студент яшьләр катнаша. Татарстан Совет Язучылары союзы идарәсенең эше турында хисап докладын Гази Кашшаф ясый. Ревизия комиссиясе отчеты белән Гариф Гобәй чыга. Фикер алышуларда 29 кеше катнаша. Алар арасында — Г. Әпсәләмов, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Гулиа (Мәскәү), С. Баттал, Ш. Мөдәррис, С. Кирьянов (Мәскәү), З. Мансур, М. Хөсәен, М. Максуд, И. Нуруллин, Ә. Давыдов, М. Елизарова, Х. Рәхмәтуллин (ВКП(б) өлкә комитеты секретаре), Г. Насрый, А. Гомәр һ. б.

Съезд Татарстан совет язучыларының эшен канәгатьләнерлек дип тапмый һәм киләчәктә эшне яхшыртуга юнәлтелгән карарлар кабул итә. Съездда яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылары союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана: Гариф Гобәй (председатель), Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Гали Халит, Риза Ишморат, Константин Лебедев, Әхмәт Исхак, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Салих Вәлиди (җаваплы секретарь).

«Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп Гази Кашшаф раслана.



*«Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» шигаренең рәсми девиз булып яңгыраган чорлары. Рәсемдә: сулдан уңга — латыш Вилис Лацис, татар Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. Үткән гасырның 50 нче еллары*

Шулай итеп съездда Язучылар союзы идарәсе эше канәгатьләнерлек дип табылмый. Совет дәверендәге идарә механизмында болай бәяләнү сирәк очрак. Язучылар союзы эшенә, съезддан бигрәк, КПСС өлкә комитетының бәясе бу. Съездда әлеге бәя кабатлана, дөресрәге, кабатлаттырыла гына. ВКП(б) ҮКның 1944 елдагы алда әйтелгән карары, шул ук ВКП(б) ҮКның «Звезда» һәм «Ленинград» журналларын нык тәнкыйть иткән еллар бит (1946 елның 14 августында чыккан карар). Өстән директива бар! Каләм әһелләрен кысада тотар өчен, урыннарда да, бу очракта Татарстанда нигә аналогик карар чыгармаска? Алда телгә алынган ВКП(б) өлкә комитетының «Татарстан Совет Язучылары союзы эше турында» дигән карар тулысы белән тәнкыйтькә корылган («зур кимчелекләр бар», «тиешенчә җитәкчелек итми», «өйрәнүдән читтә торалар», «бер-берсен тәнкыйтьләмиләр», «үсеш юлларын дөрес чагылдырмый», «ярдәм күрсәтмиләр», «буржуаз язучының чын йөзен ачмыйлар», «зур хаталар җибәрелә», «тирән анализ ясалмый», «тикшерүләр аз үткәрелә», «канәгатьләнерлек түгел» һ. б.). Арада дөресләре дә бар, әлбәттә. Ә язучыга шәхес культы, сугыш елларында киң полотнолы, хакыйкатькә хилафлык китерми торган әсәрләр язарга мөмкинлек булдымы соң? Бу чор өчен доклад ясаган Г. Кашшафның хәлен аңлап була: югары оешмаларга да ярарга кирәк, каләмдәшләр иҗатын да булдыра алган кадәр дөрес бәяләргә кирәк! Бу съездда 1945–1950 елларда идарә рәисе булып торган Ә. Ерикәй нык тәнкыйтьләнә. «Идарә (Ә. Ерикәй А. Ша-

мов, М. Әмир, Б. Зернит, Х. Хәйри, Г. Кашшаф, Т. Гыйззәт), гомумән, язучыларның иҗат эшенә тиешенчә җитәкчелек итмәде» дип табыла.

**Тагын дүрт ел үткәч, 1954 елда, янә бер съезд — Татарстан язучыларының III съезды үтә.** Ике съезд арасында Союз эшчәнлеге шактый активлаша. Иҗат секцияләренең эше җанлана (проза секциясе җитәкчесе — Г. Әпсәләмов, поэзия секциясенеке — С. Хәким, драматургия — Р. Ишморат, тәнкыйть секциясенеке — Г. Халит), яшь язучыларның республика конференцияләре эшли, иң яхшы яңа әсәрләргә ябык конкурслар игълан ителә, җыелышларда конкрет әсәрләр тикшерү белән бергә, теоретик мәсьәләләр турында дискуссияләр дә оештырыла.

Съезд 24–26 июнь көннәрендә Казанда үтә. Съездда төп ике доклад тыңлана. «Татар совет әдәбиятының торышы һәм бурычлары» (Гомәр Бәширов), «Татар совет әдәби тәнкыйте һәм бурычлары» (Гали Халит). Көн тәртибенең калган мәсьәләләре нигездә хисап һәм оештыру эшләренә бәйле: ревизия комиссиясе эшен тыңлау, идарә һәм II Бөтенсоюз съездына делегатлар сайлау. Шунысы игътибарга лаек: моннан 50 еллар элек тә әдәби тәнкыйть мәсьәләсе актуаль һәм әдәби җәмәгатьчелекнең күз уңында булган (ирексездән Тукайның «тәнкыйть кирәкле шәйдер» дигән сүзләре хәтергә килә). Докладлар буенча фикер алышуда С. Хәким, М. Дудин (Ленинград), Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ю. Лебединский (Мәскәү), Ф. Хөсни, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Мөсрепов (Казакъстан), М. Максуд, Х. Хәйри, Ә. Давыдов һ. б. (барлыгы 28 кеше) катнаша. Яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылар союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана: Гомәр Бәширов (председатель), Сибгат Хәким, Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри, Фатих Хөсни, Таҗи Гыйззәт, Әнвәр Давыдов (җаваплы секретарь), Габдрахман Әпсәләмов, Бруно Зернит.

Игътибар иткәнсездер: хисап докладын алдагы съездда рәис булып сайланган Г. Гобәй түгел, ә 1953 елда аны алыштырган Г. Бәширов ясый. Г. Гобәй шул чордан идарә даирәсеннән китә, фәкать профессионал иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Үз вакытында «Маякчы кызы», «Замана балалары», «Без үскәндә» кебек әсәрләре белән танылган язучы, соңрак «Коръән серләре» исемле «трактат» язып, дин тотучыларның бәддогасына юлыкты. Киң катлам укучылар арасында каршылыклы фикерләр тудырган бу әсәр заман идеологиясенә ярарга тырышып иҗат итүнең бер гыйбрәтле сабагы булып тора.

Бу съездда 1954 елның декабрь аенда үтәчәк Совет язучыларының II Бөтенсоюз съездына делегатлар да сайлана. Унбер кешелек делегация арасыннан Татарстан исеменнән чыгыш ясау янәдән К. Нәҗмигә йөкләнә. I съездда да татар әдәбияты турындагы докладны ул ясаган икәнне искә төшерсәк, нинди генә катлаулы чорда да К. Нәҗминең үз биеклеген саклап калуын, ныклыгын таныырга туры килә.

**Чираттагы IV съезд 1958 елда уза. 16 июнь көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм, балет театры бинасында ачыла һәм дүрт көн дәвам итеп, 19 июньдә тәмамлана.** Съездны Нәкый Исәнбәт (стенографик язмада ул күренекле карт язучыбыз дип теркәлгән. Аңа ул вакытта 59 яшь) ача. Съездда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше турында Гомәр Бәширов, татар поэзиясенең торышы турында Сибгат Хәким, проза әсәрләре турында Хәсән Хәйри, драматургия турында Гази Кашшаф, Татарстанда яшәүче рус язучылары турында Геннадий Паушкин докладлар белән чыгалар. Татар язучыларының съездын котлап килгән кунаклар В. Кожевников (Мәскәү), Б. Кербабаев (Төрекмәнстан), С. Смирнов (Мәскәү), С. Кудаш (Башкортстан), Ә. Мохтар (Үзбәкстан), Ж. Мулдагалиев (Казакъстан) һ. б. чыгыш ясый. Докладлар буенча фикер алышуларда Ф. Хөсни, Н. Дәүли, Х. Госман, И. Пехтелев, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Н. Фәттах, М. Максуд, Г. Ахунов, Х. Якупов, Ж. Фәйзи, Ш. Хөсәенов һ. б. катнаша. 19 июньдә Татарстан язучыларының IV съезды яңа идарә, ревизия комиссиясе һәм РСФСР язучылар съездына делегатлар сайлый. Идарә составына түбәндәге язучылар кергән: Афзал Шамов (председатель), Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури (җаваплы секретарь), Гази Кашшаф, Геннадий Паушкин, Гариф Ахунов, Абдулла Гомәр.

Шул ук көнне яңа сайланган идарәнең беренче утырышы була, «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп Абдулла Гомәр раслана.

Хроникаль рәвештә съездлар турында сөйли киткәч, бу урында янә бер җыен — РСФСР Язучыларының I оештыру съезды турында аерым әйтеп үтү кирәк. Моңарчы әле үзәкнең бер югары җыены — СССР Язучылар съезды гына бар иде. 1958 елдан соң ул ике Үзәклегә әйләнде: русның атаклы уенчыгы «матрешка» принцибы барлыкка килде. СССР оешмасы, РСФСР оешмасы, ТАССР оешмасы. Кыс-

касы, күкәй эчләрендә күкәй... Бер караганда, Россиянең үз оешмасы булу кирәк тә булгандыр. Бу гамәл белән үзәктәге рус язучылары мәнфәгатен кайгыртуда яңа мөмкинлекләр ачылды, шулай ук аз санлы дистәләгән халыкларның әле яңа формалашып килгән профессиональ әдәбиятларын аякка бастыруда реаль адымнар ясалды. Әйтик, Төньяк Себер (эвенк, чукча һ. б.) яки Кавказ (карачай, авар, ногай һ. б.) халыкларының профессиональ язучылары барлыкка килде, җирле милли колорит белән сугарылган кызыклы әсәрләр язылды.

Россия Язучылар оешмасы төзелү мең еллык тарихы, ике гасырдан артык басма китап традицияләре булган татар әдәбиятына ни бирде соң? Уңай җавап әйтергә кыенсынам. Чынлыкта, без Зур союздан (СССР Союзыннан) Кече союзга (РСФСР) күчтек. Күчерделәр. Безнең рәсми статус — автономия, ягъни союздаш республикалар рәтендә тормый булып чыкты. Гәрчә зур Союз белән багланышлар өзелмәсә дә (кайбер абруйлы язучыларыбыз СССР язучылар дәрәҗәсендәге чараларда катнашып килде, хәтта югары органнарга да сайланды), һәммәбез СССР Язучылар союзы әгъзасы дигән таныклык йөртсәк тә, без инде рәсми рәвештә туры-



*Бауман урамындагы Матбугат йорты балконында бер төркем язучылар. Сулдан уңга — Нәби Дәүли, Сәрвәр Әдһәмова, Баян Гыйззәт, Хәсән Хәйри, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов (Ибраһим Гази белән сөйләшеп тора), Әнвәр Давыдов. 1965*

дан-туры РСФСР язучылар оешмасына беркетелдек. СССР язучылар съездларына РСФСРдан делегатлар булып бардык. Зур съездларда безнең Язучыларыбызның тавышы тоныграк, әсәрләребез турында сүзләр сирәгрәк ишетелә башлады. 1934 елдагыча, язучыларның илкүләм җыенында татар әдәбияты турында махсус докладлар тыңлау, тәфсилле чыгышлар ясау татлы истәлек булып калды. Зур съездлардагы төп докладларда татар әдәбияты чуаш, башкорт, якут, бурят кебек әдәбиятлар белән бер яссылыкта телгә алына башланды.

РСФСРның бу беренче съездына Татарстаннан 11 кеше делегат булып бара (Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Г. Гобәй, Ә. Еники, Т. Журавлев, Н. Исәнбәт, Л. Ихсанова, Г. Кашшаф, И. Гази, З. Нури, А. Шамов. Бу төркемнән бүгенгә берднбер исән кеше—Ләбибә апа Ихсанова. Хәзер аңа 81 яшь, ул чакта аңа 35 булган). Бу съездда Татарстан вәкилләре сыйфатында ике язучы чыгыш ясаган — Ф. Хөсни, А. Шамов. Ф. Хөсни чыгышы (стенографик язма буенча әйтүем) укыр өчен әле дә кызык, фикере искермәгән. А. Шамов Язучылар союзы рәисе сыйфатында чыгыш ясый, түрәләргә хас пафос, реверанс, рәсмилек... Шулай да чыгышта заманы өчен бик тә мөһим мәсьәлә—яшь язучылар өчен журнал кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга (ә мәсьәлә утыз еллап гомер үткәч, партия диктаты йомшап, демократик үзгәрешләр булгач кына — 1989 елда хәл ителде. Мәскәү йогынтысыннан тыш республика җитәкчелеге «Идел» журналын чыгаруны үзе хәл итте).

Татарстан язучыларының 1958 елда үткән IV съезды да, шулай ук РСФСР язучыларының I оештыру съезды да элгәреге җирле һәм бөтенсоюз съездларыннан үзләренең рухлары белән шактый ук аерылалар иде инде. «Алга! Коммунизмга!» кебек шапырынулы шигарьләр күп булса да («член СП СССР обязан всей своей творческой и общественной деятельностью активно участвовать в строительстве коммунизма»), шәхес культы елларына хас шомлылык, куркынулык, «урра, Сталин!»лык юк иде. Җәмгыятьтә эмбриональ хәлдә булса да, демократик чалымнар барлыкка килде. Партиянең ике ел элек (1956) үткән XX съездының нәтиҗәләре, «Хрущев җепшеклеге» рухи тормышта сизелә иде инде... Әмма... СССРның «Тимер капкасы» әле ачылмаган диярлек (чит илләргә бик сирәк язучы чыга!). Сәясәттә ике идеология (берсе, әлбәттә, буржуаз идеология) бугазлаша. Кариб кризисына да ерак калмый... Рәсми иҗади оешмалар Пастернак һәм аның ише «декадент интеллигентлар»ның тетмәсен тетә...

Хуш, без үзебезнең хәлләргә кайтыйк. Үзебезнең җирлектә, үзебезнең әдәби хәрәкәт нисбәтендә сугыштан соңгы унбиш елга (шартлы рәвештә үзебез бүлгән классификация буенча) беркадәр гомумкүзәтү ясаганнан соң, кайбер йомгак-нәтиҗәләргә дә килик.



*Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Минский. 1958*

Әйе, үзенчә авыр чор бу! Бигрәк тә сугыштан соңгы еллар... Әмма халыкның рухы сынмаган, киләчәккә ышанычы ныгыган чор. Җиңү, шиксез, ышанычны ныгыткан. Ә уйласаң, ач-ялангач чор бит, авыл халкы «таяк»-ка эшләгән чор, чабаталы чор, черек (туңган) бәрәңге чоры (соңрак бу еллар турында Н. Фәттахның «Артта калган юллар», А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» кебек әсәрләрендә ачык язылачак)... Әмма — китаплы чор! Шул чорда ачлы-туклы яшәп, тырышып белем алган, китаптан аерылмаган буын XX гасыр ахырына кадәр дөньяның тоткасы булып тора алды да.

Алдарак бу чордагы (1945–1960 еллар) мәдәни-әдәби хроникадан вакыйга саналырлык кайбер фактларны күрсәтеп узган идем инде. Шуларга өстәп әйтергә була: «Татар поэзиясе антологиясе» чыга (1956), дөнья һәм рус әдәбияты классикасыннан йөзләрчә әсәрләр татар теленә тәрҗемә ителә (татар авылларында берничә буын, шул исәптән безнең буын да, шул китапларны укып үсте дә инде! Сүз уңаеннан әйтеп үтик: 60 нчы еллар башында башка телләрдәге матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча Татарстан — СССРда дүртенче урында, ә татар теленнән башка телләргә тәрҗемә ителү ягыннан бишенче урында торган).

Әдәбиятның, гомумән, язу эшенең дәрәҗәсе югары заман бу. Әдәбиятыбызның халыкара танылуына ике зур форсат



*Язучыларның иҗат һәм ял йортлары урнашкан «Аккош күле»ндә 60 нчы елларда яшәгән язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Нәби Дәүли һәм Зәки Нури (улы белән)*

чыккан еллар. Беренчесе, алда әйтелгәнчә, К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус» романнарының Сталин премиясе алуы. Заманы өчен ифрат зур вакыйга. Шушы премия уңаеннан бу әсәрләр дөньяның байтак телләренә тәрҗемә ителделәр, татар әдәбиятының данын еракларга тараттылар. Икенчесе — М. Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме һәм Ленин премиясе бирелү. Җәлил поэзиясе татар шигыре данын тагын да югарырак күтәрде. Соңрак — 40–50 ел эчендә талантлы әсәрләр байтак язылса да, аларның авторлары халыкара масштабта алай ук яңгырый алмадылар. Субъектив һәм объектив сәбәпләр булды бугай. (Хәер, соңрак, 60–70 нче елларда Г. Әпсәләмов әсәрләре шактый ук популяр булып алды.) Без тикшерә торган сугыштан соңгы бу унбиш ел эчендә, табигый, әдәбият мәйданын ир уртасы егетләр, сугышта катнашкан фронтовиклар тотты. Төп әсәрләрне дә алар язды. «Тукай» (Ә. Фәйзи), «Онытылмас еллар» (И. Гази), «Газинур» (Г. Әпсәләмов), «Суд залында» (С. Хәким), «Яшәү белән үлем арасында» (Н. Дәүли)... Һәр чор әдәбиятының лидерлары була. 50 нче еллар әдәби

хәрәкәтенең иң эре фигурасы, һичшиксез, Гомәр Бәширов. Сталин премиясе лауреаты. СССР Верховный Советы депутаты, Язучылар союзы рәисе... Тел остасы, фольклорчы, гомумән, аксакалларга хас зирәк кеше. Язучылыгыннан тыш, оешма хуҗалыгын ныгыткан шәхес. Ярты гасырдан артык тарихы булган язучылар дачаларын — Аккош күле иҗат йортын оештырган, нигезләгән кеше дә шул ук Гомәр ага Бәширов («Аккош күле»ндәге иҗат йорты аерым бер язмага, андагы табигать күренешләре аерым альбомга лаек. Ярты гасырлык тарихы булган бу «Әдәбият бишеге»ндә кемнәр генә яшәмәгән дә, нинди генә әсәрләр иҗат ителмәгән! «Аккош күле»нә бәйле кайбер исемнәрне генә атап узыйк: Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким, И. Гази, А. Шамов, Ф. Хөсни, Р. Ишморат, Ш. Мөдәррис, Н. Дәүли, З. Нури, М. Рафиков, Х. Хәйри, И. Нуруллин, Г. Латыйп, Н. Юзиев, Г. Сабитов, Ф. Шәфигуллин, Г. Шәрәфетдинов, Ф. Сафин... Болары яшәп киткән язучылар. Әле исәннәрдән янә дистәләгән исемнәр санарга мөмкин. Бүгенге көндә дә биредә дистәдән артык күренекле язучылар яшәп иҗат итә). Ходай Гомәр аганың үзенә дә мәрхәмәтле булды: ул озак яшәп, 98 яшендә (1999 елда) иҗатының кадерен, халыкның ихтирамын тоеп дөньядан китте. Бу чордагы Язучылар оешмасының җитәкчеләрен дә янә искә төшереп үтик: председательләр — Ә. Ерикәй (1945–1950), Г. Гобәй (1950–1953), Г. Бәширов (1953–1958), А. Шамов (1958–1961), рәисләрнең урынбасарлары — җаваплы секретарь вазифаларын фронтовик шагыйрьләр Ә. Давыдов, З. Нурилар башкарган.

Сүз уңаеннан шуны да билгеләп узыйк: 50 нче еллар ахырында, дөресрәге, 1959 елның 18–23 май көннәрендә, Зур съезд — СССР язучыларының III съездында Татарстаннан делегат булып җиде язучы (Г. Бәширов, М. Әмир, А. Шамов, Р. Ишморат, С. Хәким, З. Нури, Ш. Галиев. Араларыннан бүген исәне — Ш. Галиев, аңа хәзер 76 яшь) бара. Бу съездда татар язучылары исеменнән М. Әмир чыгыш ясый. Шул чорның, шул зур җыеннарның тагын бер характерлы ягы: СССР күләмендәме, Россия яки республикалар күләмендәме, язучылар съездына илнең иң югары постында торган җитәкчеләр төркеме белән киләләр иде, чыгыш-докладлар ясап, банкет-приемнарда да утыралар иде. Әдәбиятның, язучыларның дәрәҗәсе югары икәнен дәлилләүче күренеш. Әдәбиятка ил башлыкларының мөнәсәбәтен, игътибарын күреп, гади халык та, әлбәттә, язучыларны зурлый, олылый иде...

## III

Бу өченче бүлектә инде үзебез дә шаһит булган, шул мохиттә үзебез дә беркадәр әвәрә килгән елларга күчеп, 1960–1990 нчы еллардагы әдәби хәлләргә күз салыйк. Әдәби хәрәкәтне шартлы рәвештә шәкли периодларга бүлүебез буенча, 1934 елдан сугыш ахырына кадәр 10 нан артык ел булса, икенче чор дигәнем сугыш соңыннан алып 60 нчы еллар башына кадәр — 15 ләп елны, бу өченче чор исә, чагыштырмача озын — 30 еллап вакытны эченә ала. XX гасыр икенче яртысының саллы төп өлеше дигән сүз. Киләчәктә бу чорның бер-ике сүз белән генә әйтелә торган төгәл билгеләмәсе дә табылыр. Хәер, әйтә дә башладылар инде: «торгынлык» чоры (бу билгеләмә, минемчә, бер яклы)...

Әлеге чорны характерлый торган кайбер вакыйгаларны, тарихи фактларны, лозунг-шигарьләрне искә төшерик. Шул еллар әдәби хәрәкәтенең асылын аңларга җиңелрәк булыр. 60 нчы еллар башларында Хрущев вәгъдә иткән «коммунизм»ның төзелеп бетәргә тиешле чоры бу. 30 нчы елның 20 ләбендә Брежнев стабиль идарә иткән чор. СССРның, АКШ лидерлары тарафыннан «явызлык империясе» дип тамгаланса да, дөньякүләм мәйдан тоткан, табигать байлыкларын, бигрәк тә нефтьне ифрат күп чыгарып, нигездә, шуның хисабына милитаристик державага әверелгән чагы. Идеологик яктан да шактый катлаулы чор: тышкы сәясәттә — көч-тырышлык ике системаның көрәшенә (беренче чиратта хәрби потенциалны арттыру юлы белән) сарыф ителсә, эчке сәясәттә — төп игътибар халыкларның милли үзенчәлекләрен бетереп, бердәм совет (рус дип аңларга да була) халкы ясауга бирелде (мәсәлән, Казанда татар мәктәпләре бөтенләй диярлек бетерелде, авыл мәктәпләренең күбесендә уку-укытылу русчага күчерелде). Әдәбият хәлләренә килсәк, аның әле абруйлы чагы. Иң күп китап укучы халык СССРда дип әйтәләр иде. Дөрес тә булгандыр — өйдә-китапханәдәме, юлда-пляждамы дигәндәй, олысының да, кечесенең дә кулларында китап булыр иде. «Китап — белем чишмәсе» дигән канатлы сүзләр күпчелекнең аңында, күңелендә иде. Әдәбиятның дәрәҗәсе халыкның шигъриятькә мөнәсәбәтендә бигрәк тә ачык чагылды. Халык, ташкын булып, мәйдан-стадионнарны, мәдәният сарайларын тутырып шигырь тыңларга җыелсын әле! Кабатланмас еллар! Без дә — 60 нчы еллар башында әдәбиятка килеп, хәзер 60 яшькә җиткән буын — шигырь язып, иҗат итеп, дөньяны яхшыга үзгәртәбез дип нык ышандык ул елларда! Һәм шул ышаныч илһамландыр-

ды да, эшләтте дә, яшәтте дә. Кызыклы чор, парадоксларга бай чор. Бер яктан, «нык үскән социализм» илендә иҗат иреге турында тәкрарланса, икенче яктан, мәгълүм канун-кысаларга яраклы партияле иҗат таләп ителде. «Без йөрәгебез кушканча язабыз, ә йөрәкләребез партиягә бирелгән» дигән сүзләр еш яңгырый иде. Ялгышмасам, бу сүзләрне партия съездында М. Шолохов әйтте шикелле. Әдәбият белән җитәкчелек итүне партия, беренче чиратта, Язучылар оешмасы аша башкарды. Тулысынча партия идеологиясенә хезмәт иткән оешманың эш стиле дә, табигый, партия дисциплинасына буйсынган булды. Ул стиль шул система өчен уңайлы һәм шактый ук мөкәммәл дә иде. Язучылар съездлары, пленумнары Устав буенча төгәл вакытында үткәрелә (1960–1990 нчы елларда V–XI съездлар, җәмгысы җиде съезд), партия оешмасы җыелышлары вакытында уздырыла, әдәби ел йомгаклары утырышлары зур вакыйгага тиң була (андый җыелышлар үткәрелә башлауга быел 40 ел тулды, ел йомгакларына багышланган беренче җыелыш 1964 елда үтте)... Булдыклы, талантлы язучыларның (дөрес, сирәк-мирәк кайбер әсәрләрдән идеологик «ялгыш» табып, басылмау очраклары булгалады) әсәрләре даими чыгып килде. Каләм хакы бәрабәренә заманы өчен яхшы гына яшәп, гаилә тотып була иде. Язучыларның китапларын бастырып чыгаруда Язучылар союзы реаль булыша алды. Оешма әгъзалары, аларның гаилә әгъзалары иҗат йортларына, курорт-санаторийларга барып иҗат белән шөгыльләнә, ял итә һәм дәвалана ала иде... 50–60 ел эчендә язучы халкы өчен Әдәби фонд аша меңләп путевка-юллама алынгандыр дип уйлыйм.

* * *

Янә съезд хәлләренә кайтыйк. Үземнең беренче мәртәбә Язучылар съездында катнашуым да шул чорда — 60 нчы еллар башында булды. Ул — Татарстан язучыларының V съезды. (Шуннан соңгы 40 елдан артык вакыт эчендә Татарстан язучыларының 10 съездында, СССР, РСФСР язучыларының 12 съездында катнашырга туры килде. Хәтер офыгында һәммәсе дә стенографик эзлеклелектә сакланмаса да, күбесендәге төп чыгышлар, шәхесләр, кызыклы эпизодлар әле һаман истә. Шуңа күрә соңгы берничә дистә еллар әдәби тормыш хәлләрен шәхси күзәтүләрем белән «сипләп» баруым табигыйдер. Тик шунысы бар: күбрәк белгән саен, белгәнеңнең асылын, төшен төгәл итеп кәгазьгә

төшерү кыенлаша гына икән; берсе онытыла, икенче берсе төшеп кала кебек).

**V съезд 1963 елның 7 февралендә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында** (бу—театр бинасында үткән соңгы съезд, калган җыеннар кечерәк — бүтән биналарда үткәрелә башлады) **ачылды.** Татарстан язучылары белән бергә, кунак сыйфатында союздаш һәм автономияле республика вәкилләре, республиканың партия-совет җәмәгатьчелеге, сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнашкан бу җыен 8–9 февральләрдә үз эшен КПСС өлкә комитетының конференцияләр залында дәвам иттерде. Съездда «Татарстан Язучылары союзының идарәсе эше» (Мирсәй Әмир), «Бүгенге татар поэзиясе» (Нил Юзиев), «Татар балалар әдәбияты» (Җәвад Тәрҗеманов), «Әдәби тәнкыйтебезнең торышы» (Гали Халит), «Татарстандагы рус язучылары иҗаты» (Геннадий Паушкин) турында докладлар тыңланды. Чыгыш ясауларда Г. Бәширов, С. Баруздин (Мәскәү), Г. Әпсәләмов, М. Кәрим (Уфа), С. Хәким, Г. Ахунов, Ш. Маннур, Ә. Давыдов, А. Шамов, Я. Ухсай (Чабаксар), Р. Мостафин, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин һ. б. катнашты. Съездның 10 февральдә үткән соңгы утырышында 17 кешедән торган яңа идарә составы сайланды. Алар: Мирсәй Әмир (председатель), Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Зәки Нури, Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин (җаваплы секретарь), Ләбибә Ихсанова, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Хәй Вахит, Хатип Госман, Александр Булгаков, Шәүкәт Галиев, Гали Халит, Геннадий Паушкин.

Театр залында съездда катнашкан атаклы язучылар, кунаклар арасында Р. Харисов, Г. Рәхим (Г. Родионов), Р. Мингалимов, Ә. Синугыл, Х. Хөснуллин, Р. Гатауллин (Р. Гаташ) кебек яшьләрнең дә «өлкән» йөзләре хәтердә калган. Халыкча әйтсәк, кеше арасына керә башлаган чаклар...

Шул ук 1963 елны Татарстан Язучылар союзының филиалы рәвешендә Әлмәттә Язучылар бүлеге оештырылды. Шул вакыттагы әдәбият үсеше өчен зур вакыйга. Бу төбәктә моның өчен җирлек һәм инициатива булган, димәк, югарыдан да тиешле булышлык-ярдәм күрсәтелгән. Әлмәт бүлегенең җитәкчесе, ягъни җаваплы секретаре итеп язучы Гариф Ахунов билгеләнә. Бу бүлек, Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче шактый күпсанлы талантлы каләм ияләрен туплап, иҗади рухландырып, шул регионның үзгә бер мәдәни-әдәби үзәгенә әйләнде. Әлмәт ул ва-

кытта нефть башкаласы саналды. Илкүләм масштабтагы төрле чаралар — киңәшмәләр, слетлар, фестивальләр еш үтә иде анда. Татарстанга килгән атаклы язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре Әлмәткә сугылмый калмадылар. Алар, чыгышлар ясап, җирле язучылар белән аралашып, Әлмәт оешмасының ныгуына уңай йогынты ясадылар. Язучыларның Әлмәт бүлеге саны һәм әдәби куәте ягыннан кайбер өлкәләрдәге язучылар оешмаларына караганда көчлерәк саналды. 70 нче елларны бүлектә СССР Язучылар союзы әгъзасы булган каләмдәшләрнең саны 25–30 га җитте, ә яшь һәм башлап язучылар йөзәрләп исәпләнде. Нефть төбәге җирлегендә укучы яратып укырлык байтак күренекле әсәрләр — романнар, поэмалар, повестьлар, пьесалар язылды, күпсанлы җырлар туды. Ул әсәрләрне язган берничә язучы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, соңрак Татарстанның халык шагыйре, халык язучысы исемнәренә лаек булды. 40 ел эчендә бу оешма белән Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Ә. Маликов, Ә. Гаффар, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллин җитәкчелек итте. Хәзер Әлмәт язучылар оешмасында вазгыять бүтәнрәк: иҗади ялкынның сүрелә төшүе сизелә. Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ә. Маликов, Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, М. Хәсәнов, Ю. Әминов, Җ. Рәхимов, Ф. Гыйльми һ. б. эстафетасын дәвам итеп, татар әдәбиятын яңа үрләргә күтәрерлек яшь көчләр, кызганыч, бик аз... Өлкән буыннан да бүген дә актив иҗат итүчеләрдән К. Булатова, Ә. Сәлахов һәм А. Хәсәнов кенә калып бара бугай...



*Журналның «Казан утлары» исеме белән чыккан беренче саны*

Шул чор әдәби елъязмасында мөһим бер сәхифә булып калган факт: ул — «Совет әдәбияты»ның бүгенге исемдә — «Казан утлары» булып чыга башлавы (июнь, 1965). «Совет әдәби-

яты» дигән гомуми исемне алыштыру өчен формаль сәбәп тә бар: ул заманда төрекмәннәрдә дә «Совет әдәбияты» дигән әдәби журнал чыга иде. СССР күләмендәге каталогта икесе дә бер исемдә чыккач, төрле төбәкләрдә журналны яздырып алучылар арасында буталу очраклары булгалый иде. Язучылар арасында берәр ай журналга яңа исем эзләү мәрәкәләре булып үткәч, идарәдә (рәис М. Әмир) «Казан утлары» исеме кабул ителде. Нәкъ шул айда журналның баш редакторы итеп Рафаэль Мостафин билгеләнде (ул Газиз Мөхәммәтшинны алыштырды). Баш редактор эшне бик актив башлап җибәрде (тәмамланган фигыль белән сөйләвем шуннан: үзем дә бу журналда эшли башлаган идем инде). СССРның татарлар яши торган регионнарына – республика, өлкә газеталарына журналның исеме алышыну турында мәкалә-хәбәрләр җибәрдек. Шунда ук «сезнең өлкәдә фәлән мең татар яши, безнең журнал фәлән данә тарала ала» дигән күрсәтмә-аңлатма да бирергә онытмадык. Редактор кушуы буенча турыдан-туры шушы эш белән шөгыльләнгәч, хәтердә: 100 дән артык хат җибәрелде, шуның күбесе СССРда чыга торган республика, өлкә газеталарында басылып чыкты. Һәм... нәтиҗә дә яхшы булды. 1965 елда тираж 19246 булса, бер ел эчендә 18 меңгә якын артып, 1966 елны «Казан утлары» 36800 булып чыкты. Ә 1968 елны 64000 данәгә җитте. Ул елларда журнал тарату белән Тәүфикъ Әйди бик нык шөгыльләнде. Велосипедка утырып, үз теләге белән күрше республикаларга чыгып йөргәне хәтердә калган. Яшь язучы Тәүфикъ Әйди ул чакта ук күпләргә үрнәк зат иде инде. (Юкса үзе ул вакытта редакциядә дә эшләми иде.) Журнал исеме алмашу уңаеннан күңелдә калган матур хатирәләр, матур нәтиҗәләр...

**Шул ук 1965 елны (14–15 гыйнварда) Татарстан язучыларының чираттан тыш тагын бер җыены — сан буенча VI съезды булып үтте.** V съездан соң ике ел үтүгә яңадан съездга җыелуның төп сәбәбе: РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлау. Без бит инде хәзер РСФСР Язучылар оешмасына буйсынабыз. Шуңа күрә аның Устав кагыйдәләрен үтәргә туры килә! Съездда Союз идарәсе председателе Мирсәй Әмир татар әдәбиятының торышы һәм бурычлары турында доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Әпсәләмов, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Җ. Тәрҗеманов, И. Гази, А. Булгаков, Г. Ахунов, З. Мәҗитов, съездга кунак булып килгән Мәскәү язучылары Л. Соболев, С. Михалков, Б. Дубровин, чуаш язучысы Н. Ильбеков һ. б. катнашты. Съездда шулай ук КПСС өлкә комитеты секре-

таре З. Тутаев чыгыш ясады. Аннары съезд РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлады. Алар — М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Р. Ишморат, Л. Соболев, Ф. Хөсни, С. Хәким, Ә. Исхак, Г. Ахунов, З. Нури, Г. Минский, С. Радзиевская, А. Расих.

Язучыларның VI съездында, саналган кунаклардан тыш, күренекле язучылардан А. Алексин, Л. Андреевская, М. Львов, Р. Моран һәм М. Кәрим катнашты.

РСФСР язучыларының II съезды алдыннан чираттан тыш үткәрелгән җыенда яңа идарә сайланмады, үткән V съездда сайланган Идарә үз эшчәнлеген дәвам иттерде.

Бу съезд көннәре минем хәтергә тагын бер сәхифәсе белән сеңеп калды әле. Күптәннән килгән традиция буенча, Казанга килгән исемле шәхесләр, гадәттә, Казан университетына килми калмыйлар иде. Бу юлы да шулай булды: съезд кунакларын (Л. Соболев, С. Михалков, М. Кәрим, М. Львов, А. Алексин һ. б.) студентлар белән очрашуга чакырдылар. Бу әдәби кичә актлар залында узды. Студент яшьләр исеменнән кунакларны котлауны миңа йөкләделәр. Күрәсең, әдәби түгәрәк җитәкчесе, яшь шагыйрь саналып, инде китап авторы булуымны искә алганнардыр. Университет парткомы наказы бу! Русча-татарча котларга тиешмен. Йөкләвен йөкләделәр, әмма чыгышым гына үзем теләгәнчә булып чыкмады бугай: артык дулкынланудан каушадым, тирләп чыктым, җитмәсә, кәгазьсез-нисез сөйләп азапланам... Татар әдәбияты вәкиле булып, үзебезне тиешенчә күрсәтә алмадым дип, бик нык битәрләдем үземне. Кул чаптылар чабуын. Яшьлеккә ташлама ясаганнардыр инде... Хәзер дә, бу хәл искә төшкәч, сәер бер хис кичерәм.

* * *

Съездлар, корылтайлар — театр биналарында, зур залларда үтә торган рәсми һәм күпмедер дәрәҗәдә тантаналы җыелышлар алар. Шуңа күрә (кәбисә елы кешеләренең туган көннәре кебек) сирәк, гадәттә 4–5 елга бер тапкыр үткәреләләр дә (күзәтүләр шуны күрсәтә: билгеле бер чиге була ул съезд саннарының. Партияләрнекеме яки оешмаларнныкымы, XXXX яки XXXXX съезд дигәнне тарихта ишеткән юк әле. Кем белә, бәлки, язучылар оешмасының да корылтайлары фәләненче санда тукталып калыр?). Ә бит көндәлек иҗади хәрәкәт бүтән җирләрдә бара: эш бүлмәләрендә, газет-журнал редакцияләрендә, нәшрият кабинет-



*Әдәбият-сәнгать вәкилләреннән бер төркем. Беренче рәттә сулдан уңга — Зәки Нури, Маннур Саттаров, Заһид Хәбибуллин, Сафа Сабиров, Зәйнәп Хәйруллина, Гариф Ахунов; икенче рәттә — Екатерина Соколова, Әхмәт Ерикәй, Мәрьям Рахманкулова, Мансур Мозаффаров, Фатих Хөсни; өченче рәттә — Мөхәммәт Садри, Илһам Шакиров, Рәисә Билалова, Фәхри Насретдинов, Хава Хөсәенова, Мәрфуга ханым (Ф. Хөснинең хатыны), Мөршидә ханым (С. Хәкимнең хатыны), Салих Вәлиди, Сибгат Хәким. Матбугат йортындагы Тукай клубы бинасында. Узган гасырның 60 нчы еллары*

ларында... Каләм ияләрен җыя торган бер үзәгебез дә бар безнең. Кемнәрдер өчен «бар иде» дип тә әйтеп була... Ул — әлбәттә, атаклы Матбугат йорты. 30 нчы еллар уртасында архитектор С. Пэн проекты белән төзелгән бу бина 70 еллар буе чын мәгънәсендә татар матбугаты, татар китабы, татар әдәбияты учагы булды. Аның таш баскычларын таптамаган зыялылар сирәк булгандыр. Элегрәк Татарстанда чыккан бөтен газет-журналларның редакцияләре шунда тупланган иде. Гомер-гомергә дигәндәй, дүртенче катны Татарстан китап нәшрияты биләде. Язучылар оешмасы штабы — Союз да ярты гасырдан артык шушы бинада булды. Икенче кат. Баскычтан менү уңаеннан сулга борыласың, якты тәрәзәле коридор буйлап 10–15 адым атлаганда «Азат хатын», «Ялкын» редакцияләре кала... Коридор төпкелендә — Язучылар союзы, Әдәби фонд. Шундук «Совет әдәбияты» («Казан утлары») редакциясе. Ничек сыйганнардыр! (Хәзер бинаның икенче катындагы бу канатын бер «Мәдәни җомга» газетасы били.) Дөрес, дүртенче катта җыйнак кына, йөз

иллеләп кеше сыешлы атаклы Тукай клубы бар. Безнең буынның (бездән алдагы буынның да) әдәбиятка чынлыклап аякка басуы шушы клубтан башланды да инде. Шәхсән үзем 1960 елдан — студентлыкның беренче айларыннан ук таптый башладым мин бу клуб баскычларын. Әдәби кичәдә шигырьләр укып беренче тапкыр чыгыш ясаулар да шушы клубта булды. Әсәрләрен дәресләрдә өйрәнгән язучыларны шушында күрдек. Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким... Болары XX гасырда туган шәхесләр. XIX гасыр ахырында туган өлкән затлар белән дә беренче тапкыр бирердә таныштык: Нәкый Исәнбәт, Исмәгыйль Рәми, Риза Газизов, Госман Бакир... Аларның замандашлары — солтангалиевчелектә гаепләнеп, теге заманнарда төрмә-сөргеннәр кичкән Бакый Урманче, Мәхмүт Бөдәйлиләрне дә шушы бинада күрдек. Аена бер-ике мәртәбә булына иде Тукай клубында. Традицион җомга кичәләре,



*Мәшһүр сынчы Бакый Урманче 60 нчы еллар башында мәрмәр таштан Тукай сынын ясаган иде. Ул сын берничә дистә ел Язучылар берлеге бинасында (Бауман урамы, 19 йорт) торды. Шул бюст-сынны урнаштырган көнне бер төркем язучылар фотога төшкәннәр. Утырганнар (сулган уңга) — Зыя Мансур, Әхмәт Исхак, Мирсәй Әмир, Бакый Урманче, Исмәгыйль Рәми, Сибгат Хәким, Нури Арсланов; басып торучылар — Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гали Хуҗи, Нурихан Фәттах, Мәҗит Рафиков, Салих Баттал, Нур Гайсин, Галимҗан Латыйп, Хәсән Сарьян, Нәби Дәүли, Котдус Дәүләтшин, Габдрахман Әпсәләмов, Самат Шакир. 1964*

Казанга кунак булып килгән атаклы язучылар белән очрашулар, студент яшьләрнең концертлары, юбилей кичәләре... Без яшь язучыларны иң кызыктырганы (тизрәк зур шагыйрь, язучы буласы килә бит!), әлбәттә, язучыларның җыелышлары иде. Бигрәк тә ел йомгакларына багышланган җыелышларны калдырмаска тырыша идек. Икешәр көн бара иде ул «йомгак»лар. Күпме шәхесләр күрәсең, күпме чыгышлар тыңлап, күпме кызыклы фикерләр ишетәсең! Чыннан да, әдәби җәмәгатьчелек өчен вакыйга иде ул җыелышлар. Яшьләр дә, зыялы өлкәннәр дә көнозын йотлыгып тыңларлар иде чыгышларны, тәнәфесләрдә чама белеп кенә бәхәсләшерләр, алган тәэсирләрен күңелләрендә озак йөртерләр иде. Күрәсең, ул заманда татар әдәбияты һәм сәнгате турында авыз тутырып ана телендә сөйләү, иркенләп фикер алышу өчен бүтән урын да булмагандыр...

Мәшһүр Матбугат йорты! Җитмеш ел эчендә дөньяның бик күп атаклы кешеләрен (сугыш вакытында бигрәк тә) күргән истәлекле бина. Хәзер дә син әле исән. Әле хәзер дә синдә ике нәшриятыбыз (Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф»), Китап палатабыз, «Мәдәни җомга» газетабыз гомер кичереп ята. Бирегә хәзер дә килгәләп йөрибез, фикер-



*Мәшһүр язучы ханымнар. Сулдан уңга: Сәрвәр Әдһәмова (Кави Нәҗми хатыны), Гөлсем Мөхәммәдова (Галимҗан Ибраһимов хатыны), Ләбибә Ихсанова (Шәрәф Мөдәррис хатыны). 1958*

дәшләр, наширлар белән көрешәбез. Шулай да күңелне тырнаган сорау бар: киләчәктә бу диварларда элеккеге милли рух, китап рухы сакланып кала алыр микән? Акшарлары купкан түшәмнәргә, тузган тәрәзә өлгеләренә, күгәргән торбаларга карап күңелгә моңсулык иңә... Кемнәр кулына калып, киләчәктә кемнәр хуҗа булыр бу тарихи Үзәктә!..

* * *

Татарстан язучыларының чираттагы (ул вакытта СССР Язучылар союзының яңартылган Уставы нигезендә съездлар биш елдан биш елга үткәрелә иде) съезды 1968 елны үтте. Бу съездны да яхшы хәтерлим. Инде СССР Язучылар союзы әгъзасы булынган, берничә шигырь китабы чыгарылган, шигырьләрем турында байтак бәхәс-низаглар, мактаутиргәүләр ишетеп шактый ук чыныгылган, гаилә корылган, солдат хезмәте үтелгән... Президиумга ук утыртып, идарә әгъзасы итеп тә сайладылар мине бу съездда. Гармоник фон тудырыр өчен өлкәнрәкләр арасына бер яшь кешене сайлау гадәте бар инде ул!.. Әйе болай, тәртип белән сөйләгәндә **VII съезд, 1968 елның 25–26 март көннәрендә Г. Камал исемендәге (хәзерге Тинчурин театры) Татар дәүләт академия театрында узды.**

Съездны аксакал язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов ачты. Идарәнең ике съезды арасындагы (1965–1968) эшчәнлеге турында хисап докладын, идарә рәисе буларак, Мирсәй Әмир ясады. Ул язучылар ирешкән уңышлар һәм алда торган бурычлар турында сөйләп, язучылар оешмасының 25 кешегә артуын әйтте, СССР Язучылар союзы әгъзасы булган язучыларның саны 111 кешегә җиткәнен белдерде. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Ахунов, Л. Татьяничева (Мәскәү), Л. Ихсанова, Ф. Хөсни, Г. Камалиев (нәшрият директоры), Р. Мостафин, Х. Гыйлаҗев (Уфа), Р. Харисов, В. Ганиев (Мәскәү), Ш. Рәкыйпов, Ә. Давыдов, А. Калган (Чувашстан), А. Расих, М. Сәлимҗанов (режиссер), Сәхип Җамал (гарәп язучысы), Җ. Тәрҗеманов һ. б. катнашты. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев нотык сөйләде. 26 мартта яңа идарә сайланды. Аның составына түбәндәге язучылар керде: Ибраһим Гази (председатель), Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов (җаваплы секретарь), Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Равил Фәйзуллин, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Хатип Госман, Гази Кашшаф, Илдар Юзеев, Валерий Синев, Ләбибә Ихсанова, Рафаэль Мостафин.

Шушы 17 кешенең бүген инде 4 есе генә (Л. Ихсанова, Р. Мостафин, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин) исән (И.Юзеев 2004 елда вафат булды. — *Ред.*). Безнең замандашлар булган нинди олпат затларыбызны югалтканбыз! Ирексездән шигырь юлларын кабатларга туры килә: «Кемнәр бар да, кемнәр юк!»

Бу съездан тагын ике нәрсә күңелдә җуелмас булып хәтердә калган. Берсе — тәнкыйтьче, М. Җәлил иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафинның чыгышы. Чыгышның төп бер тезисы шул иде: 1913 елда татар китаплары сан буенча хәзергедән күбрәк чыккан. Әдәбият әһелләре арасында сөйкемле сөяк саналган, русча-татарча иркен сөйләшә һәм яза алган, дәрәҗәле Р. Мостафинның бу чыгышы партия түрәләре өчен һич тә көтелмәгән хәл булды. Ничек инде революциягә кадәр шулай булырга тиеш ди (гәрчә тәнкыйтьче конкрет статистик саннар китереп, дәлилләп сөйләгән иде!)? Әнә бит республика җитәкчеләренең берсе, татарлар революциягә кадәр тоташ грамотасыз булган, дип бара! Нинди каршылык! Дөресрәге: партия линиясенә каршылык!.. Бу чыгышка рәсми реакция катгый булды: бер айдан Р. Мостафин «Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазифасыннан азат ителде... Икенчесе (монысын ул заман өчен инцидент дип әйтеп була) — бер төркем яшьләрнең театр балконыннан татар яшьләре өчен әдәби журнал кирәк дигән эчтәлекле листовкалар очыруы. Зал өстеннән ак яфраклар кебек листовкалар очып әйләнгәндә президиумда — янәшәмдә утырган югары урын биләгән түрәләрнең чырайлары ничек үзгәргәне һаман күз алдында. Каушау һәм аптырау! Нәрсә бу?

Листовкалар очырткан студент егетләрне (Разил Вәлиев, Зөлфәт, М. Мансуров) КГБ бүлмәләренә байтак йөрттеләр. Бу хәл (хәзерге күзлектән караганда гап-гади таләп) үзе һәм аңа булган реакция—шул заман иҗтимагый тормышын характерлап торган бер күренеш иде.

* * *

1960–1990 нчы еллар. Бу чор татар әдәбиятының алтын чоры булды бугай. Еллар ераклыгыннан шулай күренә. Р. Мингалимов әйтмешли, «ул шулайдыр әле, уйласаң». Әдәбиятның кадере булган чор. Язучы да үзен җәмгыятьнең кирәк һәм хөрмәтле кешесе санап, чагыштырмача иркен тоеп, көченә һәм киләчәккә ышанып иҗат итте. Нигә язмаска? Максатың бар, хезмәтеңнән ләззәт тою бар, иң мөһиме — әсәрләреңне көтеп торган күпсанлы укучылар бар. Әзме-



*60 нчы елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр. Сулдан уңга — Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим. 1971*

күпме белемле кеше кибетләрдән яхшы китап эзли, күптомлы басмаларга берәр ел алдан язылып куя, таныш-белеш аша берәр дефицит китап юнәтсә, төлке тоткан кебек сөенә... Атаклы язучыларның яңа әсәрләрен вакытында укып бару зыялылык билгесе санала. Айтматовның «Ак пароход»ына фикерең ничек? Хемингуэйның соңгы романының русча тәрҗемәсе чыккан! Неруданың мемуар китабы кемдә бар икән? Исхакыйның «Зөләйха»сын берәү машинкадан чыгарган!.. Кызыксына, укый иде халык! 80 нче еллар башында «Казан утлары» журналының 100 меңнән артык данә белән таралуы күп нәрсәне аңлата (заманында трамвай бәясе дә 3 тиен иде дигән шикелле, ул елларда миллионга якын тираж белән чыккан бөтенсоюз журналлары — «Новый мир», «Дружба народов», «Знамя» кебек журналлар хәзер тиражлары безнең «Казан утлары»ннан ким булып — нибары 3–6 мең данә чыга). Әйе, укый иде халык. Татар телендә чыккан китапларның тиражлары да шактый югары: шигырь китаплары — 3–10 мең, проза китаплары — 10–30 мең, балалар китаплары — 10–100 меңнәр була иде. Татар язучыларыннан, бездә генә түгел, илкүләм популярлары мәйданга чыкты. Шуларның иң күренеклесе, алда әйтелгәнчә, Г. Әпсәләмов булды. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы шикелле, Г. Әпсәләмов романнарын, беренче чиратта «Ак чәчәкләр»не,

миллионлаган төрле милләт вәкилләре йотлыгып укыды... Татар-башкорт укучылары арасында Ә. Еники дә аерым бер урын тотты; аның «Әйтелмәгән васыять»ен укымаган зыялы зат калмагандыр... Саный китсәң, бар иде популяр әсәрләр. Ш. Хөсәеновнең «Мәхәббәт сагышы», И. Юзеевнең «Таныш моңнар»ы, Х. Вахитнең «Беренче мәхәббәт»е... Х. Туфан, С. Хәкимнәрнең шигырь, поэмалары, Г. Афзал, Ш. Галиевләрнең юмор-сатира, Роберт Әхмәтҗановның лирик шигырьләре... «Давыл хәбәрчеләре» сыман 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләр иҗатына игътибар аеруча зур булды. Республика газеталарында атна саен диярлек дискуссион характердагы зур-зур мәкаләләр чыкты. Традицияләр, новаторлык, формализм, «ирекле шигырь»... Мәш килде әдәби мохит!

Чорлар турында сөйләгәндә, табигый процесс – әдәбиятта буыннар алышынуы турында да искәртеп узу кирәктер. Чыннан да, өлкән язучылар (XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында туганнар) 70–80 нче елларда үзләренең дөньялыктагы гамәлләрен йомгаклап киләләр иде инде... Төп әдәби мәйданны исемнәре 50 нче еллар урталарында һәм бераз соңрак күренә башлаган буын яулады. Алар: прозада – Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, М. Рафиков, Ә. Баян, Ш. Бикчурин, Б. Камал, М. Мәһдиев, Х. Камал, А. Тимергалин, Х. Сарьян, Э. Касыймов, М. Хуҗин, М. Юныс, Ф. Шәфигуллин, Т. Әйди, М. Маликова, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Ә. Гаффар...; шигърияттә – алдагы абзацта әйтелгәннәрдән тыш, Р. Гәрәй, М. Шабаев, Ш. Анак, С. Сөләйманова, Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, К. Булатова, Рәш. Әхмәтҗанов, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, К. Сибгатуллин, А. Хәлим, М. Әгъләмов, Зөлфәт...; драматургиядә – Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Батулла, Р. Хәмид...; әдәбият гыйлеме һәм тәнкыйтьтә – Мансур Хәсәнов, И. Нуруллин, Ә. Кәримуллин, И. Ахунҗанов, Н. Юзиев, М. Госманов, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Ф. Урманче, Х. Миңнегулов...

* * *

Бу урында сугыштан соңгы шактый дистә еллар буена татар әдәбияты барышына нык тәэсир иткән берничә фактор турында әйтү мөһим. Алар – **Ватан сугышы, Татарстанда нефть чыгару,** соңрак **КамАЗ төзелү**. Ватан сугышы, дөньякүләм фаҗига буларак, күп халыклар яшәешендә ча-

гылыш тапса, ә нефть белән КамАЗ турыдан-туры Татарстан, бигрәк тә татар халкы язмышына кагылды. Республиканың йөзе, кешеләрнең кальбе үзгәрде. Татарстанда читтән килгән халык күбәйде, яшь һәм көчле килмешләр армиясе хасил булды. Рәсми идеология индустриаль казанышларга дан җырларга өндәде. «Хезмәт кешесе образы» дигән ясалма термин туды (безнең әдәбиятның каһарманы гомер гомергә хезмәт иясе булды лабаса!). Социалистик реализм методы алымнарына тугрылыклы булып, эшче сыйныфын, хезмәт романтикасын сурәтләгән (яки сурәтләргә тырышкан) байтак әсәрләр, китаплар чыкты. «Гади кешеләр» (И. Гази), «Хәзинә» (Г. Ахунов), «Томан аша» (Э. Касыймов), «Зәй энҗеләре» (А. Гыйләҗев), «Каты токым» (Ш. Бикчурин), «Ут һәм су» (Ә. Баянов), «Тау белән тау очрашмаса да» (М. Хәбибуллин)... Саналганнар — проза әсәрләре, бүтән жанрлардан да мисалларны китерергә була. Болар, нигездә, социаль заказ белән язылган әсәрләр. Бу күренешне яңа дип тә әйтеп булмый. 30 нчы елларда, бигрәк тә СССР язучыларының I съездыннан соң булган иде инде андый хәлләр. Язучылар иң әүвәл завод-фабрикалар тарихын язарга, «металл җыры»н яңгыратырга, «мотор гиганты»н сурәтләргә, «миллионнарның энтузиазмы»н күрсәтергә тиеш иде. Бу чорның ядкарьләре — Ш. Камалның «Матур туганда», Р. Ильясның «Горизонт» кебек әсәрләре...

Әлбәттә, республикадагы баш әйләндергеч үзгәрешләр, нефть һәм КамАЗ индустриясе белән бәйле контрастлар, уңай (заман технологиясен үзләштерү, халыкара бәйләнешләр ныгу, техник интеллигенция оешу, юллар салу, торакларны газлаштыру һ. б.) һәм тискәре (авыллар бетү, экологик кризис, миллилекнең асылы тоныклану, әхлаксызлык, ассимиляция, татар теленең кысрыклануы һ. б.) күренешләр язучылар иҗатында чагылыш табарга тиеш иде. Һәм ул шулай булды да. Әмма... Хикмәт шунда: чагылыш нинди дәрәҗәдә һәм нинди тирәнлектә булды соң? Дөресен әйтик, нигездә, авылдан чыккан татар язучысы ФТР (фәнни-техник революция) тудырган бу хикмәт-тамашалар алдында, табигый, югалып та калды. Югалырсың да, фантазия белән күз алдына китерик: идиллик-патриархаль тормыш белән яшәп ятучы авылның су тегермәне янына НЛО корабы төшсен дә, шуны аңлап-белеп кара әле! Вазгыять, халәт, әзерлек шулайрак иде. Әйткәнемчә, тырышмады түгел, тырыштылар язучыларыбыз. Алар — командировкаларга барып, буровойларда, кыр вагоннарында, тулай торакларда, баракларда булдылар, бораулаучылар, ташчылар, шоферлар, торбачылар

белән (өстән юнәлтелгәнчә, нәкъ чын хезмәт кешеләре белән) аралаштылар һәм шулар тормышы турында яздылар да. Нишләтәләр бу җирне? Байлык кая китә? Бу гамәлләрнең ахыры ни белән бетәчәк? Бу хакта дөнья танырлык итеп язылмады, һәрхәлдә, язылып та дөнья күрә алмаган берәр зур әсәрне белмим мин.

Төзелешләр мәйданын хәтерләткән республика тормышында майлы киемле хезмәтчәннәрдән тыш, идарәчеләр, югарыдан куелган стратегик максатны тормышка ашыручылар катламы — Табеевлар, Шмаревлар, Васильевлар, Шашиннар, Мингәрәевләр, Лемаевлар, Бехлар һәм тагын күпләр бар иде. Татар язучылары алар белән якыннан аралашып, якындагын гына түгел, ерак офыктагы булачакны фаразлап, җитәкчеләр белән бер дәрәҗәдә яки хәтта өстәнрәк торып иҗат итә алмадылар. Берәүне дә гаепләргә җыенмыйм. Әлеге әфәнделәр туры һәм күчерелмә мәгънәдә дә бүтән телдә сөйләшәләр иде шул...

* * *

Ватан сугышы 60–90 нчы елларда да әдәбиятыбызның төп темаларыннан берсе булып кала бирде. Фронтта катнашкан язучылар, хәтерләрен яңартып, яңа әсәрләр яздылар («Мәңгелек кеше» — Г. Әпсәләмов, «Дуга» — С. Хәким, «Муса» — Ш. Маннур, «Җимерелгән бастион» — Н. Дәүли, «Йолдызлар шаһит» — Ә. Галиев, « Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» — Х. Камал, «Без дә солдатлар идек» — Ә. Еники, «Яшьлек утравым» — Ә. Маликов...). Сугыш чорын күреп үскән кайбер яшьрәк язучыларыбыз да, өлкәннәр үрнәгендә, хәрби-патриотик тәрбиягә өлеш кертәбез дип иҗат иттеләр («Кайдан син, Жан?», «Кызлар — йолдызлар» — Ш. Рәкыйпов, «Легенда егетләре» — С. Шакир һ. б.). Бу әсәрләрнең күбесе сугыш темасына 50 нче елларда язылганнардан шактый ук аерылалар иде. Элгәргеләрендә сугыш (без яшь чакта күргән «Взятие Берлина», «Смелые люди» кинофильмнарындагы шикелле), күбрәк батырлык мәйданы кебегрәк күрсәтелсә, соңгыларында, кешелек фаҗигасе буларак, кеше язмышлары аша реаль чынбарлыкта чагылдырыла башлады. Башкача мөмкин дә түгел иде. Әдәбият сөючеләр бүтән халык язучыларының сугыш турында язылган әсәрләре белән дә яхшы ук таныш иде. Әйтик, В. Быковның «Сотников», К. Симоновның «Живые и мертвые», Й. Авижюсның «Потерянный кров», В. Астафьевның «Плацдарм», «Последний поклон» һ. б... В. Ажа-

евның «Мәскәүдән еракта», С. Бабаевскийның «Алтын йолдыз кавалеры», М. Бубенновның «Ак каен»нарын уку заманнары үткән иде шул... Безнең буын яшь чакта сугыш турында күп укыды. Ялган пафос, ялган батырлык күп булган ул әсәрләрдә, ә кешеләргә дөреслекне белү кыйбат. Шәхсән мин үзем Х. Мөҗәйнең «Сугыш көндәлекләре» дигән документаль язмаларын сугыш турында язылган бик күп ясалма әсәрләрдән өстен саныйм.

Бу чорда, әлбәттә, татар әдәбиятының җанын тәшкил иткән авыл дөньясын, аның кешеләрен тасвирлау тагын да җанлана төште. Бу хакта дәлилле итеп күп сөйләп булыр иде, кайбер әсәрләрне атап китү белән генә чикләнәм. «Әйтелмәгән васыять» — Ә. Еники, «Артта калган еллар» — Н. Фәттах, «Берәү», «Язгы кәрваннар» — А. Гыйлаҗев, «Шинельсез солдатлар» — В. Нуруллин, «Тау ягы повесте» — Ә. Баян, «Бер ананың биш улы» — Х. Сарьян... Сугыштан соңгы чордагы авыл турында язылган әсәрләрнең иң характерлыларын Мөхәммәт Мәһдиев иҗат итте дип беләм. Аның әсәр-



*А. Гыйләҗев, Р. Ишморатова, М. Ногман, Г. Афзал язучылар китапханәсендә. 1972*




ләрендә сугыштан соңгы авыл рухы бөтен нечкәлекләре белән чагылыш таба. Әсәрләренең берсен генә аерып искә алу килешми кебек. «Без—кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә»... Гомумән, М. Мәһдиевнең әдәби иҗатта үзен, «мин 60—90 нчы еллар язучысы» дип тә әйтерлеге булды. 60 нчы еллар ахырында әдәбиятка килеп, утыз еллап иҗат итеп, ни аяныч, 90 нчы еллар уртасында, үлмәс әсәрләр калдырып, китеп тә барды...

Татарның бар дөньяга шауларлык тарихы булса да, дөресен әйтик, аны юньләп белгәннәр бик сирәк. Җиңелгәннәр үзенең чын тарихын яза алмый. Җиңгәннәр үзләренең үткәнен бөекләтеп язганда, аста калган халык тарихы юкка чыгарыла... Шулай да... халык тәне суынмаган бит әле! XX гасырның беренче чирегендә тарихи әсәрләр язу беркадәр башланса да, 30—50 нче елларда бу хәрәкәт туктап кала. Ниһаять, 60 нчы еллар башында әкренләп «боз кузгалды», «беренче карлыгачлар»дан — Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» әсәре булды. Бераздан шул ук авторның — «Сызгыра торган уклар»ы язылды. Соңрак бу эшкә М. Хәбибуллин («Кубрат хан»), Җ. Рәхимов («Батырша»), Р. Батулла («Сөембикә кыйссасы»), Ф. Латыйфи («Хыянәт») кебек язучыларыбыз алынды.

Әдәбияттагы төп казанышлар турында сөйләгәндә, бу дәвердә Республиканың (соңрак Дәүләт дип әйтелә башлады) Г. Тукай премиясен алган әсәрләрне һәм аларның авторларын искә төшереп үтсәк, әдәби хәзинәбез тулырак күз алдына килер. Кырыктан артык лауреат язучының утызга якыны бу дәрәҗәле исемне 60—90 нчы елларда алган. Укучыларыбыз өчен мәгълүмат тулы булсын өчен, еллар исәбен чигендереп, бүгенге көнгәчә булган лауреатлар

исемлеген хронологик тәртиптә тулысынча санап китик: Әхмәт Фәйзи — «Тукай» романы өчен (1958) (Тукай премияләрен бирә башлау шушы елдан башлана), Габдрахман Әпсәләмов — «Сүнмәс утлар» романы (1959), Сибгат Хәким — «По зову Ленина», «Җил исми — яфрак селкенми» исемле шигырь китаплары өчен (1960) (1961–1965 елларда премия бирелү туктатылып торылды), Хәсән Туфан — «Сайланма әсәрләр» китабы (1966), Нәкый Исәнбәт — «Татар халык мәкальләре» дигән өч томлы хезмәт (1968), Ибраһим Гази — «Онытылмас еллар» роман-трилогиясе (1969), Фатих Хөсни — «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повесте (1972), Шәүкәт Галиев — «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле йорт» китаплары (1972), Гариф Ахунов — «Чикләвек төше» повесте (1973), Мирсәй Әмир — «Агыйдел» пьесасы (1974), Нил Юзиев — «Шигырь гармониясе», «Хәзерге татар поэтикасы» китаплары (1974), Диас Вәлиев — «Дарю тебе жизнь» пьесасы (1976), Марс Шабаев — «Җикән камыш», «Онытма», «Сине эзлим» дигән шигырь китаплары (1976), Гамил Афзал — «Айлы кичләр» китабы, «Борылам да карыйм» исемле шигырь циклы (1977), Равил Фәйзуллин — «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1978), Туфан Миңнуллин — «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы (1979), Илдар Юзеев — «Таш диварлар авазы», «Өзелгән кыллар» поэмалары (1980), Атилла Расих — «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Ямашев» ро-



*Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулган көннәрдә Казанда аның исемендәге музей ачылды. 1986*

маннары (1981), Ибраһим Нуруллин — «Тукай турында китаплар» (1982), Аяз Гыйләҗев — «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән киртәгә» повестьлары (1983), Әмирхан Еники — «Повесть һәм хикәяләр» (1984), Гәрәй Рәхим — «Кара йөзләр» операсы өчен либретто (1984), Нури Арслан — «Иделем — Илем» исемле шигырь һәм поэмалар китабы (1985), Хисам Камал — «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» китаплары (1986), Марсель Зарипов — «Поступь моей республики», «Выгодный оборот» исемле публицистик китаплары (1987), Мәхмүт Хәсәнов — «Язгы аҗаган» романы (1988), Мөхәммәт Мәһдиев — «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» повестьлары (1990), Әбрар Кәримуллин — «У истоков татарской книги», «Татарская книга XX века» һ. б. китаплары (1991), Гөлшат Зәйнашева — «Илле җыр» китабы (1991), Мөдәррис Әгъләмов — «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» исемле шигырь китаплары (1992), Ринат Мөхәммәдиев — «Сират күпере» романы (1993), Нурихан Фәттах — «Сызгыра торган уклар» романы (1994), Фәнис Яруллин — «Җан авазы» шигырь китабы (1995), Гомәр Бәширов — «И язмыш, язмыш» китабы (1996), Ренат Харис — «Хисемнең җиселе» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы (1997), Роберт Миңнуллин — «Күчтәнәч» исемле китап (1998), Әхсән Баянов — «Урланган ай» китабы (1999), Зөлфәт (Маликов Дөлфәт) — «Ике урман арасы», «Йөрәгемне былбыл чакты» шигырь китаплары (2000), Роберт Әхмәтҗанов — «Тургай тәрәзәсе», «Кечке кошлар» исемле шигырь китаплары (2001), Якуб Зәнкиев — «Иртыш таңнары» романы (2002), Мөсәгыйт Хәбибуллин — «Кубрат хан» китабы (2003), Миргазиян Юныс «Альбатрос язмышы», публицистик язмалар (2004). Җәмгысы — кырык дүрт язучы, илледән артык әсәр. (Бу исемлекне җентекләбрәк укыган кеше аңларга кыен моментларны да искәртер: әйтик, бу премияне Д. Вәлиев 1976 елда алса, Ә. Еникигә 1984 елда; М. Зариповка — 1987 елда булса, Г. Бәшировка 1996 елда бирелә... Милли әдәбият зарурияттеннән караганда, бу язучыларның «авырлык категорияләре» төрле, бүтәнчәләп әйтсәк, пәри башка да, җен башка! Мондый алогизмнар тагын бар әле бу исемлектә. Гомумән, Тукай премияләре тарихы — үзе бер патетик драма ул. Әгәр кырык дүрт язучы лауреат булса, иң киме тагын шул чама санда башка дәгъвачылар да булган бит әле, арасында лаеклылар да... Күпме эмоциональ киеренкелек, дулкынланулар, тетрәнүләр, сөенечләр, үпкә-рәнҗүләр! Язар өчен аерым бер тема.) Тукай премиясенә лаек булган әсәрләрне иҗат итүдә

Язучылар оешмасының тәэсире яки файдасы күпмедер, аны-сы бәхәсле, әмма өләшүдә, ягъни бирелү процессында роле шактый (тәкъдим итү, премияләр комитетында яклау), һәрхәлдә, моңарчы шулай булып килде. Дөрес, соңгы елларда Язучылар берлеге тәкъдим иткән кандидатлар лауреатлыкка бик «үтми» башладылар әле...

* * *

«Торгынлык» еллары... Кем ничек кенә бәяләмәсен, «җитлеккән социализм» чорының үз тәртибе хөкем сөргән тотрыклы да иде ул еллар. Коммунистлар партиясенең кайбер демократик алымнарны үзләштереп идарә итүенең үз апогеена җиткән еллары. Язучылар союзлары да, партиянең ышанычлы таянычы буларак (дөрес, язучы халкы арасында да төрлесе бар: диссиденты да, эзоп телендә язучысы да...), үз функциясен төгәл үтәп килә. Партҗыелышлар да, политукулар да, семинар-пленумнар да планлы рәвештә бара. Әлбәттә, язучыларның иң югары органы булган съездлар да. Мозаик пландагы язмамны бер үзәккә җилемләп торучы әнә шул съездларга янәдән кайтыйк. Бу дәвердә язучыларыбыз делегат булып өч төрле дәрәҗәдәге съездларда катнашалар: СССР, РСФСР, ТАССР съездларында (бу елларда СССРның биш — IV–VIII съездлары, РСФСРның биш — II–VI съездлары, Татарстанның җиде — V–XI съездлары үтте). Безнең әдәби хәрәкәт тарихы — үз съездларыбызда. Аларның байтагы турында информацион характерда гына булса да язып уздым инде. Хәзер чираттагылары турында да әйтеп үтим (бәлки, кемнәргәдер бу кадәр саннар, исемнәр, даталар санап китү ошап та бетмәс, әмма социологик эссе характерындагы язмамдагы фактик материалның әдәбият тарихын өйрәнүчеләр өчен киләчәктә кирәк булуы ихтимал).

**Татарстан язучыларының VIII съезды 1974 елның 24–25 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында үткәрелде.** Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 1968–1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын Зәки Нури ясады. Моннан тыш проза турында Гариф Ахунов, поэзия турында Илдар Юзеев, драматургия буенча Туфан Миңнуллин, тәнкыйть турында Рафаэль Мостафин, балалар әдәбияты буенча Ләбибә Ихсанова, рус язучыларының иҗаты турында Тихон Журавлев докладлары тыңланды. Ревизия комиссиясенең отчетын комиссия председателе Гариф Гобәй ясады. 25 май көнне доклад-



*Съезд президиумыннан күренеш*

лар буенча фикер алышуларда Р. Ишморат, Ә. Баян, Ү. Саттаров, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Н. Җиһанов (композитор), Ф. Миңнуллин, Ш. Хамматов, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, Ә. Маликов, Р. Җиһаншина (артистка), Ә. Тумашев (рәссам) һ. б. катнашты. Съездга килгән кунаклардан С. Михалков (Мәскәү), О. Савицкий (Минск), Ф. Гарин (Киев), Б. Байкабулов (Ташкент), А. Алиев (Ашхабад), А. Аетбаева (Фрунзе), И. Араз (Баку), Н. Дедушкин (Чабаксар), И. Пеняев (Саранск), С. Вишневский (Йошкар-Ола), Г. Сабитов (Ижевск) котлау чыгышлары ясадылар. Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев речь белән чыкты. Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итте, Союзның җитәкче органнарын сайлады. Идарә составына түбәндәге язучылар сайланды: Гариф Ахунов (председатель), Равил Фәйзуллин (җаваплы секретарь), Мирсәй Әмир, Азат Әхмәдуллин, Гомәр Бәширов, Әхсән Баянов, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Әдип Маликов, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Шамил Рәкыйпов, Гәрәй Рәхим, Хәсән Туфан, Мөсәгыйт Хәбибуллин (оештыру эшләре буенча секретарь), Сибгат Хәким, Марс Шабаев, Илдар Юзеев.

Ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайланды.

Бу рәсми хроникага тартым белешмәгә тагын нәрсә өстәргә? Шул елларны характерлый торган кайбер фактлар, вакыйгалар. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулган еллар бу (VII белән VIII съезд арасын әйтүем). Шуңа күрә бу даталар уңае белән Казанда да, Мәскәүдә дә бик күп чаралар үткәрелгән. Конкрет язучылар тормышына караган вакыйгалардан — Муса Җәлил турында «Ленфильм»да «Моабитская тетрадь» исемле кинофильм чыга; өлкән язучыларыбыздан Н. Исәнбәт, Х. Туфаннарның 70 яшьлек юбилейлары үтә; С. Хәкимгә РСФСРның М. Горький исемендәге премиясе бирелә; татар язучылары Донбасска барып әдәбият көннәре үткәрәләр, шул ук җәйне (1972) Ворошиловград өлкәсеннән җавап визиты белән украин язучылары Татарстанга килә... Бу елларда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре булдырыла. Язучылардан беренче лауреатлар: И. Юзеев (1970), Р. Фәйзуллин (1972). Гомумән, ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк, 70 нче еллар башында яшь иҗат көчләренә хакимият тарафыннан игътибар зур булды. 1969 ел ахырында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында «Иҗади яшьләр оешмасы» төзелде, җитәкчесе итеп Р. Батулла билгеләнде. Шул елларда Актерлар йортында үтә торган «Ядкарь» кичәләрен өлкәнрәк буын иҗатчылар яхшы хәтерли булыр. Халыкара яшьләр лагере — «Волга»да («Идел»дә) һәр ел саен яшь язучылар, рәссамнар, композиторлар, актерлар катнашында бер атнага сузыла торган республика семинарлары...

VII–VIII съездлар арасында идарә җитәкчелегендә дә үзгәреш булды. 1968 елда Язучылар союзы җитәкчесе итеп И. Гази сайланган иде. Рәис статусында ул СССР Верховный Советы депутаты, РСФСР Язучылар союзы секретаре, КПССның өлкә комитеты члены, КПССның чираттагы съезды делегаты булды. Әмма... 1971 елның февралендә И. Гази көтмәгәндә вафат булды. Аның урынына З. Нури билгеләнде. Шуңа күрә Союз идарәсенең 1968–1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын ул ясады да. Рәислек елларында З. Нури да СССР Язучылар союзы секретаре булып эшләп алды.

**Татарстан Язучыларының IX съезды 1979 елның 23–24 май көннәрендә үтте.** Анда өч йөзгә якын язучы, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунак-

лар, Татарстанның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура хезмәткәрләре катнашты. Съездны шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Республика язучыларының иҗаты һәм идарә эшчәнлеге турында хисап докладын Гариф Ахунов ясады. Ревизия комиссиясенең бишьеллык эше белән Рәис Даутов таныштырды. Өстәмә докладлар — Атилла Расих (проза), Нил Юзиев (поэзия), Азат Әхмәдуллин (драматургия), Мөхәммәт Мәһдиев (тәнкыйть), Шәүкәт Галиев (балалар әдәбияты), Марсель Зарипов (очерк һәм публицистика), Геннадий Паушкин (рус язучылары иҗаты), Илдар Юзеев (яшь язучылар белән эшләү), Әдип Маликов (Әлмәт оешмасы эшчәнлеге) тыңланды. Фикер алышуларда З. Нури, Р. Мостафин, Ә. Гаффар, Ф. Мусин, К. Тимбикова, Ә. Тумашев (Рәссамнәр союзы), В. Нуруллин, Ш. Хамматов (Журналистлар союзы), Ф. Газизуллин (комсомолның Татарстан өлкә комитеты секретаре, соңрак Россиянең дәүләт милке министры булды), Ф. Әхмәтов (Композиторлар союзы) һ. б. катнашты.

Съезд кунаклары С. Михалков (Мәскәү), Ә. Мирзаһитов (Башкортстан), А. Мороз (Украина), Ш. Муртазаев (Казакъстан), Л. Прокша (Белоруссия), А. Емельянов (Чувашстан), О. Абдрахманов (Каракалпакстан), Н. Нефедов (Мәскәү), татар әдәбиятын олылап, коллегаларына тәбрик һәм киңәш сүзләрен җиткерделәр. Съездда шулай ук КПСС



*Яшь шагыйрьләр «Волга» лагеренда. Сулдан уңга — Рөстәм Акъегет (Фәйзуллин), Зөлфәт, Марсель Галиев. 1972*

өлкә комитетының идеология буенча секретаре М. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсен түбәндәге составта сайлады: Гариф Ахунов (председатель), Азат Әхмәдуллин, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Тәлгат Галиуллин, Әдип Маликов, Мәдинә Маликова, Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин (җаваплы секретарь), Мөхәммәт Мәһдиев, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харис, Илдар Юзеев. М. Хәбибуллин оештыру эшләре буенча секретарь итеп билгеләнде.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Рәис Даутов, Әдәби фонд председателе итеп Азат Әхмәдуллин сайланды.

Рәсми белешмә стилендә тагын бер съезд — X съезд турында да информация биреп узыйк. Алай эшләгәндә, бу ике съезд хисап биргән унъеллык (1974–1984) турында кайбер фикерләр әйтеп, гомумкүзәтүләр ясау җиңелрәк булыр. Ул елларны күз алдына китерү өчен анык ориентирлар: бу — Язучылар союзында рәис булып Гариф Ахунов торган еллар. Партия өлкә комитетында идеология буенча җаваплы җитәкчеләр — секретарь (өченче секретарь дип йөртелә иде) Мөҗәһит Вәлиев, культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин, куратор-инструктор Илгиз Хәйруллин. Минем үземә дә бу чорда — 1973–1977 еллар аралыгында Язучылар союзында җаваплы секретарь (рәис урынбасары) булып эшләргә туры килде. Шуңа күрә байтак вакыйгаларның турыдан-туры шаһитымын.

**Татарстан язучыларының X съезды 1984 елның 21–22 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында үтте.** Съездны шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм идарәнең ике съезд арасындагы бишьеллык эше турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе Гариф Ахунов ясады. Съездның беренче көнендә өстәмә докладлар да тыңланылды: поэзия (Илдар Юзеев), проза (Мөхәммәт Мәһдиев), драматургия (Туфан Миңнуллин), тәнкыйть (Тәлгат Галиуллин), балалар әдәбияты (Шәүкәт Галиев), очерк һәм публицистика (Марсель Зарипов), рус язучыларының иҗаты (Нонна Орешина), тәрҗемәчеләр эшчәнлеге (Кыям Миңлебаев).

22 майда съезд эшен дәвам иттерде, докладлар буенча фикер алышулар булды. Чыгыш ясаучылар — С. Михалков (Мәскәү), Р. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мингалим, Р. Миң-

нуллин, Н. Доризо (Мәскәү), Р. Харис, Г. Шәрәфетдинов (Татарстан китап нәшрияты директоры), Б. Мөлеков (композитор) һ. б.

Татарстан язучылары форумын Ә. Мирзаһитов (Башкортстан) А. Емельянов (Чувашстан), Г. Имамвердиев (Азәрбайҗан), В. Карамазов (Белоруссия), К. Укаев (Кыргызстан), Т. Тула (Үзбәкстан), Н. Бәйрәмов (Төрекмәнстан), Т. Җумаморатов (Каракалпакстан), Н. Рыбаков (Мари-Эль), С. Самсонов (Удмуртия) тәбрикләде. Съездда шулай ук КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады. Съездда сайланган идарә әгъзалары: Туфан Миңнуллин (председатель), Азат Әхмәдуллин, Гариф Ахунов, Николай Алешков, Әхсән Баянов, Разил Вәлиев (председатель урынбасары), Шәүкәт Галиев, Тәлгат Галиуллин, Әхәт Гаффар, Аяз Гыйләҗев, Зөлфәт Маликов, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәдинә Маликова, Роберт Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин, Флүн Мусин, Ринат Мөхәммәдиев, Вакыйф Нуруллин, Нонна Орешина, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин (җаваплы секретарь), Сибгат Хәким, Ренат Харис, Илдар Юзеев.

Ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Рәис Даутов сайлана. «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Ренат Харис расланды.

Еллар агышына, эш барышына карап дигәндәй, тора-бара идарә составында да үзгәрешләр булды. Р. Вәлиев Республика китапханәсенә (хәзер Татарстан Республикасы милли китапханәсе дип атала) директор итеп билгеләнгәч, рәис урынбасары вазифаларын Ризван Хәмид башкарды, соңрак аны Гәрәй Рәхим алыштырды.

* * *

1970–1980 еллар (үзгәртеп кору чорына кадәр), мөгаен, күпмилләтле совет әдәбияты дип йөртелгән әдәбиятның иң югары биеклегенә ирешелгән еллары булгандыр. Иң яхшы дип саналган әсәрләр Ленин, СССР Дәүләт премияләре белән билгеләнделәр. 80 нче еллар ахырында илкүләм танылган дистәләгән язучыга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирү хәлләре дә булып алды. Бөтенсоюз, хәтта бөтендөнья масштабындагы дан-хөрмәткә лаек булганнар арасында, руслардан тыш, бүтән халыкларның әдипләре дә бар иде. Гадәттә һәр республикадан берәр зур шәхес күтәрелде яки күтәрделәр



*Язучы Габдрахман Әпсәләмовны соңгы юлга озату. Табут янында басып торалар — Фикрәт Табиев (КПСС өлкә комитетының беренче секретаре), Салих Батыев (Татарстан Югары Советы рәисе). 1979*

(Ч. Айтматов — Кыргызстан, Э. Межелайтис — Литва, Р. Гамзатов — Дагстан, М. Кәрим — Башкортстан, Д. Көгелтинев — Калмыкстан, С. Капутикян — Әрмәнстан, К. Кулиев — Кабарда-Балкар)...

Совет әдәбиятының балкыган чорында бу когортада татар әдәбиятыннан да берәр вәкил булуы көтелгәндер. Табигый хәл. Төрле тарафларга таралып, әле татарлыгын җуймаган милләттәшләргә дә горурлык хисе тудырыр өчен дә кирәк булгандыр әле андый шәхес. Әмма популярлыклары һәм рәсми танылуы буенча Р. Гамзатов яки Ч. Айтматовлар дәрәҗәсендәге шәхес бездә пәйда була алмады. Дөрес, заманында Г. Әпсәләмовны, Н. Исәнбәтне Социалистик Хезмәт Герое ясарга дигән фикерләр булгалады, С. Хәким Ленин премиясенә тәкъдим ителеп каралды... Барып чыкмады, шул заман өчен бездән «символ» табылмады. Юкса, яхшы әсәрләр тудырган һәм перспективасы булган әдипләребез бар иде шикелле. Берәү дә классик булып тумый. Биюченең итәкләре бии-бии кыскара дигән шикелле, әдип кеше дә шартлар, мөмкинлек һәм терәк булганда гына үсә ала. Бәлки, үзебезнең «милли менталитет»ыбыз — бер-беребезнең үсүен күпсенүебез комачаулагандыр; бәлки, биек сәяси Олимптан — та-

тарларга бу чор өчен Муса Җәлил дә җитеп торыр, дип исәпләгәннәрдер... Әмма ул чорда «бөтенсоюз аренасы»на чыгып, татар әдәбиятын бүтән халыкларга да белдерү нияте белән иҗат итүчеләр дистәләгән иде. Бу — нормаль хәл, һәрхәлдә, ул еллар өчен табигый хәл. Әсәреңне дөнья базарына чыгарып сынау теләге хәтта хуплауга лаек. Әмма бу ярышның үз тәртибе, үз кануннары бар: әсәрең дөнья телләренә, безнең шартларда, беренче чиратта, рус теленә тәрҗемә ителү мөһим иде. Бу чорда, чыннан да, байтак татар язучыларының әсәрләре Мәскәү нәшриятларында русча тәрҗемәдә чыкты да. Бер елда Үзәкнең төрле дәүләт нәшриятларында ун-унбиш, кайбер елларны егермеләп китап чыга иде. Араларында, урта кул авторларныкы очраштыргаласа да, нигездә, хәзинәбездә булганның иң яхшы дигәннәре чыкты. Әгәр тәрҗемә булмаса, шул ук Җәлилне яки Әпсәләмовны дөнья халыклары белә алыр идеме?

70–80 нче еллардагы әдәби хәрәкәтнең бер уңай күренеше (күрсәткече дияргә дә ярыйдыр) — язучыларыбызның бүтән әдәбият вәкилләре белән даими аралашуы, үзара йөрешүе. Әдәбият көннәре, әдәбият-сәнгать декадалары, бөтенсоюз яки региональ семинарлар, иҗади-фәнни конференцияләр, теге яки бу әдипнең юбилейлары... Аларның һәрберсенә диярлек Татарстаннан вәкил булып кемдер барды. Әлбәттә, андый җирләргә республика исеменнән сөйләрлек, әсәрләре киң җәмәгатьчелеккә билгеле, язучы буларак дәрәҗәлеләр бара иде. Заманында төрле республикаларга З. Нури, Г. Ахунов, С. Хәким, Р. Мостафин, Р. Харис һәм тагын кайберәүләр күп йөрделәр. Минем үземә дә СССРның бөтен республикаларын диярлек гизеп чыгарга туры килде, сирәгрәк булса да рәсми делегацияләр составында чит илләргә дә чыгылды, 1985 елда СССР Язучылар союзы делегациясенең җитәкчесе сыйфатында Италия кебек илләргә дә барып җителде. Чит ил димәктән, бу елларда татар язучылары төрле илләргә шактый еш чыга башладылар. СССР һәм РСФСР Язучылар союзларында чит ил эшләре комиссияләре язучылар өчен махсус туристик сәяхәтләр оештыра иде. Бүгенге белән чагыштырганда, символик бәягә атна-ун көн дәвамында Европа, Азия илләрен гизеп кайта иде язучыларыбыз. Ул елларда безнең байтак каләмдәшләр бу мөмкинлекләрдән даими файдалана белделәр. Язучы халкының кадере һәм мөмкинлекләре шактый иркен булган, димәк! Бу чорда драматургларның эшләре бигрәк тә яхшы барды (хәер, матди яктан алар һәр чорда да чагыштырмача яхшырак яшәделәр), төрле республикаларда, өлкәләрдә алар-

ның пьесалары буенча спектакльләр еш куелды. Безнең театр коллективлары да бөтен СССР киңлекләрен гизделәр, аеруча Казакъстан, Урта Азия якларында җәй саен гастрольләрдә булып, халыкны туплау, рухи берләштерү юлында тарихи миссия башкардылар.

* * *

1980 елны Чаллыда Язучылар бүлеге ачылды. 60 еллар башында Әлмәттә Язучылар оешмасы ачылуга Татарстанда зур нефть чыгу сәбәп булса, Чаллыдагы бүлек оешу КамАЗ төзелешенә бәйле. Бу ике оешманың төзелү-оешу тарихы Гариф Ахунов исеме белән аерылгысыз. Әлмәттәге язучылар оешмасының беренче җитәкчесе ул булды, ә Чаллы оешмасы — аның Язучылар союзы рәислеге чагында ачылды. Әлбәттә, җирлек, тиешле зәмин юк җирдә оешма кадәр оешма төзеп булмас иде. Чаллы бүлеге шул төбәктә актив эшләгән ике төп әдәби берләшмә нигезендә барлыкка килде: берсе — Чаллыдагы «Ләйсән» (җитәкчесе — Р. Лотфуллин), икенчесе — Түбән Камадагы «Кама таңнары» (җитәкчесе — Р. Хисмәтуллин). Соңрак Зәйдәге «Зәй энҗеләре» (җитәкчесе — Р. Сәлимҗанов) берләшмәсе дә килеп кушылды. Чаллының җыелма халкы шикелле, Язучылар оешмасы да,



*Чаллы Язучылар оешмасы әгъзалары. Сулдан уңга: Равил Лотфуллин, Хәниф Хөснуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Вахит Имамов. 80 еллар башы*

нигездә, төрле тарафлардан килгән төрле язучылардан хасил булды. Берара җитәкчеләрне дә, Әлмәт мисалынчарак, Казаннан китереп кую хәлләре дә булды (Разил Вәлиев). Киләсе елга бу оешманың төзелүенә 25 ел тула. Үзенә күрә бер юбилей. Шул чакта күбрәк, тәфсилләбрәк сөйләрләр әле. Зур югалтуларны да кичерергә өлгерде инде бу оешма: төрле елларда бүлек эшен җитәкче булып җигелеп тарткан Э. Касыймов, Г. Кашапов, Я. Игәнәйләр инде гүр ияләре... Шулар рәтендә — С. Рафиков, Х. Хөснуллин, К. Сибгатуллин, А. Сафин, Н. Мадьяров, Р. Хисмәтуллин, З. Гомәрова... Шулай да әлегә шактый көчле каләмдәшләребез яши Чаллыда (А. Хәлим, Ф. Әмәк, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, Р. Бәшәров һ. б.). Әдәби хәрәкәтне берләштерүдә Чаллы язучыларының үз әдәби басмасы булу да бик мөһим. 1991 елдан гасыр ахырына кадәр «Аргамак» журналы чыкты, соңрак аны «Мәйдан» алыштырды. Бу журнал хәзер татар матбугатында чыннан да үзенең абруйлы мәйданын яулап килә.

* * *

Ул чорларда Язучылар союзы каршындагы партия оешмасының бик актив эшләвен әйтергә кирәк. Ай саен бер тапкыр тәгаен уза торган партия җыелышлары язучыларны үзенчә туплау, берләштерү ролен үтәп килде. Көн тәртибенә рәсмирәк мәсьәлә (әйтик, фәлән «съезд яки пленум карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар») куелса да, язучылар, партиялеме, партиясезме, барыбер, әдәбият турында, актуаль проблемалар турында җитди итеп сөйләшәләр, киңәшләшәләр иде, ниндидер проблемаларны хәл дә итәләр иде. Хәзер өлкәннәр үзгә бер ностальгик хис белән искә алалар ул елларны, ул җыелышларны. Язучыларның партия оешмасы бездә, күрәсең, шактый демократик булган. Мәсәлән, безнең оешмада композитор Сара Садыйкова, библиограф Асия Гыйниятуллина һәм башка тармакта эшләүче кайбер пенсионерлар да әгъза булып тора иде. Оешма булгач, аның җитәкчеләре — партоешма секретарьлары да бар, әлбәттә. Комиссарлар кебегрәк булып чыга инде. Ул елларның парторглары — Г. Гобәй, Г. Минский, Л. Ихсанова, Р. Мостафин, В. Нуруллин, Т. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кәрамиләр яхшы хәтердә. Партия таркалыр алдыннан соңгы парторг К. Латыйп булды.

Әлбәттә, төрлесе булды ул җыелышларда. Партия өлкә комитеты даирәләренең таләпләренә туры килеп җитмәгән әсәрләр басылган яки басылырга әзерләнгән очракта, парти-



*Чуаш язучыларыннан бер төркем. 70 нче еллар*

яле каләмдәшләр, ишарә булу белән дигәндәй, андыйларны оператив рәвештә тәнкыйть итәргә һәрвакыт әзер иделәр. Ул елларда иң күп «тукмаклар» алган кеше, мөгаен, шагыйрь Салих Баттал булгандыр. Аның «Батый ханга хат» дигән поэмага тартым озын шигыре тирәсендә генә дә сүз куертулар дистә елларга сузылды... Шулай ук Әмирхан Еники («Саз чәчәге»), Нурихан Фәттах («Сызгыра торган уклар»), Мөхәммәт Мәһдиев («Фронтовиклар»), Аяз Гыйләҗев («Өч аршын җир») әсәрләре дә үз вакытында актив коммунист иптәшләр тарафыннан шактый ук «чыбыркыландылар».

Партия заманында интернационализм дигән сүз киң кулланууда иде. Кызганыч, бу сүз сирәгрәк ишетелә башлады. Күпләр өчен интернациональлекнең иң яхшы билгесе — доллар яки евро хәзер. Интернационализм, минемчә, бөек төшенчә. Дөньяда халыклар дуслыгы дигән нәрсә булса, аның нигезе шушы төшенчә белән бәйле. Татарстан Язучылар союзы гомер-гомердән яхшы мәгънәдәге интернациональ оешма булды. Татар телле язучылар да, рус телле яки башка бүтән телдә язучылар да бердәм, тату иҗади хезмәттәшлектә яшәделәр. Татарстанда һәрвакыт рус язучыларының зур төркеме яшәде. Кайбер исемнәрне генә искә төшерик: М. Бубеннов, Т. Журавлев, А. Салмин, С. Радзиевская, Г. Паушкин, М. Скороходов, Я. Винецкий, Ю. Белостоцкий, Н. Орешина,

В. Корчагин... Шулай ук милләте белән татар, әмма рус телендә иҗат итүчеләр — И. Кәлимуллин, Р. Кутуй, И. Ахунҗанов, Д. Вәлиев, Р. Бохараев, М. Зарипов, Ә. Мушинский, Р. Кожевникова, Л. Газизова... Безнең оешма җирлегендә чуаш язучылары секциясе дә уңышлы эшләп килде (шунысы игътибарга лаек: бүтән республикаларда һәм өлкәләрдә яшәгән татар язучыларының беркайчан да диярлек ни оешмалары, ни иҗади секцияләре була алмады. Соңгы елларда Башкортстанда татар язучылары оешмасы борынлады борынлавын...). Дөрес, республикада чуаш телендә язучылар сирәкләнде хәзер. Шулай да без үз сафларыбызга кардәш халык вәкилләрен алуны дәвам итәбез. Мәсәлән, үткән ел чуаш Евгений Турханны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алдык.

Сүз төрле телләрдә иҗат итүчеләр турында баргач, бу урында рус телендә яза торган милләттәш язучылар хакында янә берәр җөмлә язып узыйк. Күрәсең, чынлыклап үз дәүләтең булмагач, гамәлдәге дәүләт телендә язарга омтылуны аңлап була. Дәлилле фактлар да җитәрлек. Еракка барасы юк, үзебезнең татар язучыларының иҗат сәләтенә ия балаларның кайберләре рус телендә язалар. Г. Кутуйның улы — Рөстәм Кутуй, Г. Әпсәләмовнең оныгы — Альбина Әпсәләмова, А. Расихның кызы — Фәридә Рәсулова, И. Юзеевнең улы — Салават Юзеев... Шуларга республикадан читтә яшәүче бүтәннәрне өстик: Роман Солнцев (Ренат Суфиев), Раул Мирхәйдәров, Камил Таңгалчиев... Аларны татар язучысы итеп санаргамы? Бәхәсле нәрсә. Күбесе Татарстан Язучылар оешмасы әгъзалары булып тора. Иҗади потенциаллары зур булган актив шәхесләр. Минемчә, аларны татар әдәбияты хәрәкәтенә мөмкин кадәр ныграк тартырга кирәк. Әйтик, тәрҗемә эшендә, мөхәррирлек вазифаларында... Бу каләмдәшләребезгә читсенеп, үгисетеп карау әдәбиятыбызны тарайту булыр иде. Тараю ул үзе дә килә, ә менә киңәю, тирәнәю...

* * *

...Алдарак әйтелгәнчә, 1984 елны Язучылар союзы рәисе итеп драматург Туфан Миңнуллин сайланды. Торгынлык еллары дип йөртелгән олы бер чорның соңгы рәисе Гариф Ахунов җитәкчелек аренасыннан китте. Үзгәртеп кору еллары якынайган иде инде... Миңа калса, Г. Ахунов белән бергә әдәбиятның тулы бер чоры китте, ул гына да түгел, тиздән тарихи Матбугат йортыннан Язучылар оешмасы да күчеп китте...



*Төрле елларда Әдәби фондта эшләгән язучылар: сулдан уңга — Хәсән Сарьян, Гәрәй Рәхим, Лирон Хәмидуллин. 1978*

Һич шик юк, Т. Миңнуллин җитәкче чагында Язучылар союзының Казандагы иң матур биналарның берсенә күчүе үзе бер тарихи вакыйга (дөрес, яңа бинага күчү мәсьәләсе егерме еллар элек үк күтәрелгән, һәм ул хәл ителергә тиеш иде). Ул мәһабәт бинаның адресы — Мөштәри урамы, 14. (Ул вакытта Комлев урамы дип йөртелә иде.) Яңа җир, борынгы булса да яңа йорт, яңа хуҗалар, яңа тәртипләр... Язучылар оешмасының соңгы 15 елы шушы бина белән бәйле. М. Галиевнең «Өмә» исемле юмор әсәрендә бу бинага яңа күчкән елларның бер хатирәсе бик матур сурәтләнгән.

Әйе, Язучылар оешмасына йомыш төшкәндә, без хәзер яңа бинага йөрибез. Ә Баумандагы (бу үзәк урам үзенең җисеменә туры килгән берәр исемгә кайчан алыштырылыр икән инде, бу хакта сүз күп булды бит!) Матбугат йортының күңелдән чыкканы юк. Нишлисең, хәтердән китеп булмый: яңа заман татар әдәбиятының, татар совет әдәбиятының дисәм дә була, яшьлеге, олпат тулы чагы шушы бинага бәйле шул. Соңгы дистә еллардагы хәлләргә күчкәнче, Матбугат йортына бәйле берничә оешма турында берәр кәлимә сүз әйтеп узыйм.

Андый оешмаларның берсе — Әдәби фонд, дөресрәге, СССР Язучылар Әдәби фондының Татарстан бүлеге. Икенче катта коридор өлешен такта белән генә бүлеп алган кечкенә генә бер бүлмә. Кечкенә булса да, мәгънәсе белән төш кенә

бүлмә! Язучының тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә караган байтак эшләр хәл ителә иде анда! Кайбер яшь һәм башлап язучылар оешмага кабул ителгәнче (ә бу процесс бик озак — дистә елларга сузылырга, сузылып та, кабул ителмәскә мөмкин), Әдәби фондка кереп, анда әгъза булырга тырыштылар. Чөнки Әдәби фонд әгъзасы язучыларга бирелгән ташламалардан (путевка-юлламалар, төрле пособиеләр, поликлиникаларга билгеләнү, ярдәм акчасы алу һ. б.) файдалана ала иде. Үз вакытында С. Сабиров, Ә. Шамин, М. Хөсәен, И. Рәми, Р. Ишморатова һәм тагын кайберәүләрнең язучылар тирәлегендә шул сыйфатта йөрүләре истә калган.

60 нчы еллар башында Әдәби фонд башлыгы Сөнгать ага иде. Фамилиясе Сафиуллин булганын соңрак белдек. Какча гына гәүдәле, ипле, тыныч кына сөйләшә торган, эшлекле, сабыр кеше булып хәтердә калган. Соңрак (1964–1967 елларда) бу җаваплы урында язучылар Хәсән Сарьян, Мәсгут Шәрифуллиннар (икесе дә Башкортстаннан иделәр, икесенең дә гомерләре кыска булып чыкты: берсе 1978 елны 48 яшьтә, икенчесе 1966 елны 38 яшендә вафат булдылар) эшләп алды. Әдәби фонд җитәкчесе булып иң озак (1967–1983 еллар) һәм нәтиҗәле эшләгән кеше — язучы һәм тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин булды. Соңгы егерме ел эчендә Әдәби фонд башлыгы булып тагын 5–6 кеше эшләде. 1996 елдан бирле директор — Данил Салихов, җәмәгать тәртибендә Әдәби фондның хәзерге рәисе — шагыйрь Гәрәй Рәхим. Гомумән, Әдәби фонд тарихы һәм эшчәнлеге язучылар тормышында үзе бер аерым хезмәткә лаек сәхифә. Язучыларның кавышу-туй хәлләреннән башлап үлем-китем мәшәкатьләренә кадәр Әдәби фондның катнашы булды. Заманында язучылар һәм аларның гаиләләре өчен махсус сабантуйларга кадәр оештыра иде Әдәби фонд егетләре!

Матбугат йортында урнашкан, заманында уңышлы гына эшләп килгән тагын бер оешма — Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау Бюросы. 60 нчы еллар ахырында, М. Әмир рәислек иткән чорда оешты ул. (Дөрес, әдәбиятны пропагандалау гел актуаль булып килгән, язучыларның беренче съездларында ук күтәрелә бу мәсьәлә. 1953 елда җәмәгатьчелек тәртибендә берничә язучыдан торган (М. Садри, М. Хөсәен, Г. Шамуков) махсус бер бюро да оештырыла. Әмма аның юридик статусы булмаган, әлбәттә. Соңгы вакытта бу фактны, оешма төзелүнең башы санап, ясалма юбилей да билгеләп йөрделәр әле.) Чынлыкта штатта кешеләре, реквизиты, тиешле бүтән атрибутлары булган оешма



*Язучыларның Матбугат йортындагы Тукай клубы. 50 нче еллар*

1967 елда төзелде. Бер ел элек Мәскәүдә, СССР Язучылар союзында Бөтенсоюз пропаганда Бюросы оешкан иде. 70–80 нче елларда Советлар Союзының күп республикаларында һәм өлкәләрендә бик тантаналы һәм рәсми рәвештә үтә торган Совет әдәбияты көннәрен (заманында Татарстанда да узды), нигездә, шушы Бөтенсоюз бюросы оештырды да.

Безнең пропаганда Бюросының штаты өч кешедән гыйбарәт иде: директор, әдәби хезмәткәр, бухгалтер. Конкрет эшкә килгәндә, Бюро төрле оешмалар, предприятиеләр, колхозлар белән хезмәттәшлек договорлары төзеп, шул килешү нигезендә берничә язучыдан (арада берәр популяр җырчы белән баянчы да була иде) торган бригада төрле аудиторияләр алдында чыгышлар ясый иде. Бюроның җитәкчеләре булып Мөнип Шәймөхәммәтов (сәнгать буенча аспирантура үткән Сарман ягы кешесе. Мөнип Газар псевдонимы белән шигырьләр дә яза иде), Мансур Шиһапов, Эльс Гаделов, Рәфкать Кәрамиләр, әдәби хезмәткәр булып төрле елларда Марсель Галиев, Фәннур Сафин, Хәкимҗан Халиков, Камил Кәримов, Нурислам Хәсәновлар эшләде. Үзгәртеп кору дигән елларда 6–7 ел Бюроның эше тукталып та торды. 2000 елдан яңадан торгызылган бу оешманы хәзер Рәдиф Сәгъди җитәкли.

Сүз дә юк, пропаганда бик кирәк нәрсә. Хәзерге заманда бигрәк тә. Реклама индустриясенең көннән-көн колачлана баруы тикмәгә түгел. Татар китабы (300 елга якын тарихы бар үзенең!) яклауга, пропагандага аеруча мохтаҗ. Пропаганданың ысуллары күп: радио, телевидение, газета-журнал, буклет-проспектлар, афишалар, төрле видео-аудио кассеталар... Әмма язучының үз укучылары, бигрәк тә мәктәп балалары белән очрашулары бөтенләй үзгә эффектка ия. Тере язучыларны күрү, алар белән аралашу бала күңелендә гомерлеккә калучан. Әлбәттә, сүз — чын, зыялы язучының югары дәрәҗәдә үткән очрашулары турында бара. Зур мәгънәдә әдәби-әхлакый дәрес булган кичәләр, шөкер, бихисап булды. Шулай да әдәбият файдасына булмаган аралашу фактларын да таныйк. Берзаман әлеге бригадаларда урта кул яки үзешчән дәрәҗәдәге каләм ияләре күбәеп китте (чөнки зур язучылар очрашуларга бик еш чыга алмый, талант иясенең һәр сәгате исәпле). Урта кул каләм ияләре артыннан гөл үсеп калмый, әлбәттә. Минемчә, язучының төп вазифасы артык күренеп йөрү түгел, иҗат итү. Гарәпләрдәге бер әйтемне дә онытмыйк «Мөгәйдинең үзен күргәнгә караганда шигырьләрен ишетү хәерлерәк».

Матбугат йортындагы Тукай клубы! Алда аның турында әйтеп үткән идек инде. Тагын берничә сүз өстисе килә. Үзенең 50 елдан артык тарихында кемнәрне генә күрмәгән дә, кемнәрне генә мөнбәреннән сөйләттермәгән ул! Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге үзебезнең бөек затларыбыз булган бу бинада: С. Сәйдәшев, Б. Урманче, Н. Җиһанов, Х. Әбҗәлилов... Үзебезнең классик язучыларыбызны әйткән дә юк! — Ш. Камал, К. Тинчурин, К. Нәҗми, Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким... Казанга килгән бик күп атаклы шәхесләр дә язучылар белән очрашырга шушы клубка килгәннәр. Итальянлы Дж. Родари, композитор А. Хачатурян, артист А. Райкин, космонавт В. Терешкова, диңгезче Ә. Җиһаншин, атаклы шагыйрьләр М. Кәрим, К. Кулиев, С. Кудаш, Д. Көгелтинов, Е. Евтушенко, Б. Әхмәдуллина... Төрле елларда клуб директоры булып унга якын кеше эшләде. Алар арасында аеруча эш күрсәткәннәре: 60 нчы елларда фронтовик шагыйрь Маннур Саттаров, 70–80 нче елларда шагыйрь Әхмәт Рәшитов булды. Хәзер Тукай клубының адресы бүтән: Язучылар берлеге бинасының янкормасында ул. Хәзер анда бүтән кешеләр, бүтән рух... Дөрес, анда да атаклы кешеләр булмый түгел, хәтта 1991 елда Россия Президенты Б. Ельцин да булып, язучылар белән очрашып китте.

Язучылар союзының шактый бай фондка ия үз китапханәсе дә бар иде әле. Ул әле дә бар исәпләнә. Хәзер яңа китаплар белән бик тулыландырылмый шикелле. Ул китапханәдә Брокгауз һәм Эфрон исемнәре белән йөртелә торган, алтын йөгертелгән фолиант томнар да барлыгы истә. Кстати, дип әйтик, яңа Союз бинасында, икенче катка менә торган баскыч култыгында — бер сәнгать әсәре — хатын-кыз сурәтләнгән матур бронза сын да бар иде...

Шул ук Матбугат йортында 80 нче елларда республикакүләм дәрәҗәдә китап сөючеләр җәмгыяте дә эшләп килде. Хәзерге яшьләр өчен сәеррәк яңгырыйдыр бу сүзтезмә... Бу язмамны әзерләгәндә яшьләр газетасында бер кечкенә генә хәбәр укыдым да сискәнеп киттем. «Россия халкының 40 проценты бер дә китап укымый. 80 нче елларда илдә андыйлар 10 процент кына тәшкил иткән. 1990 елда Россиядә 18 мең китап кибете эшләгән булса, бүген алар 3 меңгә калган. Көндәлек газеталарны исә ил халкының 24 проценты гына укый. Чагыштыру өчен: финнарда бу сан 87 процентка тиң». Хәтердә: бу оешмада ул вакыттагы яшь язучылар Н. Акмал, А. Хәсәновләр эшләп йөрде... Менә хәзер — халык китаптан бизеп барган чорда кирәктер ул Китап сөючеләр җәмгыяте!

* * *

Хроникаль күзәтүнең «җеп очын» җуймыйча, X съезддан соңгы әдәби хәлләргә кайтыйк. 1984–1989 елларда, шиксез, байтак иҗади-оештыру эшләре башкарылды. Агымдагы эшләрдән тыш, хәтердә җуелмаслыклары — Башкортстанда һәм Чуашстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Шул заманга хас колачлылык, патетик рух, бәйрәмчә тантаналар. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы, табигый, моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә яхшы үтте. Тугандаш республикалардан да байтак кунаклар килгән иде (1986 елның 26 апреле — Тукайның тууына 100 ел тулган көн — Чернобыльдәге көточкыч фаҗига көне белән дә тарихка кереп калды).

Туфан Миңнуллин җитәкчелек иткән чорда, «халык шагыйрьләре», «халык язучылары» дигән мәртәбәле исем булдырылды. 1985 елда бу исем турында Татарстан Верховный Советы Указы игълан ителгәннән соң (хәзер ул Президент Указы белән бирелә), бүгенге көнгә кадәр халык шагыйре, халык язучысы исемен йөрткән әдипләрнең саны 17гә җитте. Күбрәк тә бугай бу сан. Шуларның 10сы мәрхүмнәр.



*Татарстанның халык язучылары, халык шагыйрьләре. Сулдан уңга — Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев. Абрек Абзгильдин картинасы*

Әдәбият тарихы белән кызыксынганнар өчен тулы исемлекне санап үтәм: халык шагыйрьләре — Сибгат Хәким (1986), Гамил Афзал (1991), Илдар Юзеев (1993), Шәүкәт Галиев (1995), Равил Фәйзуллин (1999), Фәнис Яруллин (2001), Ренат Харис (2004), Әхсән Баян (2004); халык язучылары — Гомәр Бәширов (1986), Нәкый Исәнбәт (1986), Әмирхан Еники (1989), Фатих Хөсни (1993), Гариф Ахунов (1993), Аяз Гыйләҗев (1993), Мөхәммәт Мәһдиев (1993), Нурихан Фәттах (1998), Хисам Камалов (2001).

1986 елның җәендә (24–28 июнь) СССР Язучылар союзының чираттагы һәм соңгы съезды булып үтте. Бөтенсоюз съездының I нчесе турында шактый тәфсилле язган идек, мантыйк буенча соңгысы турында да берничә сүз әйтеп узыйк. Татарстаннан делегат булып бу съездда түбәндәге язучылар катнашты: Ә. Еники, Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, М. Госманов, И. Юзеев, Р. Харис, Н. Орешина, Т. Галиуллин, Р. Гатауллин. Делегат булып сайланылсалар да, С. Хәким — каты авыру, Р. Фәйзуллин, ерак командировкада булу сәбәпле, бу съездга бара алмадылар.

I Бөтенсоюз съезды белән VIII арасында 50дән артык ел. Бу еллар эчендә әдәби вазгыять, әлбәттә, нык үзгәргән. 50 ел эчендәге идеологик сәясәтнең нәтиҗәләре ярылып ята. Милли әдәбиятлар турында сөйләгәндә сүз, нигездә, союздаш республикалар әдәбияты турында. I съездда, М. Горький докладында булсын, чыгышларда булсын, татар әдәбияты СССР халыкларының әйдәп баручы әдәбияты итеп тәкърарланды. Ә бу съездда? Дөрес, СССР Язучылар союзының беренче секретаре Г. Марков ясаган төп докладта бер исем (тыйнаксызлык саналмасын, ул Р. Фәйзуллин исеме иде. Әмма моннан, миннән гайре, бүтәннәргә ни юаныч!) башка халыкларның кайбер язучылары белән бергә саналып китә китүен. Ә тагын? Татар әдәбияты кадәр татар әдәбияты бит ул! Съездның пленар утырышларында (жанрлар буенча секция утырышлары аерым да булды) җәмгысы 73 кеше чыгыш ясаган. Иң соңгы оратор булып, сүз Т. Миңнуллинга бирелә... Ахырга иң яхшы җырчыны чыгаралар, дияр кемдер. Бу очракта, рус сүзен кыстырып әйтсәк, случай другой. Туфанның чыгышы яхшы булган булуын: стенография язмасыннан шулай күренә. Хәер, съездда катнашкан язучыларыбыз кулуарларда югалып калмаганнар калуын: «патша хатыны» (Генсек М. Горбачев хатыны Раиса Максимовна) белән фотога төшкәннәр. Бу хакта безнең матбугатта матурлап язып та чыктылар...

VIII съездны СССР язучыларының соңгы съезды дип язсам да, кемдер, бу бит дөреслеккә туры килми, дияр. Һәм, чыннан да, ул — үзенчә хаклы булыр. Формаль яктан тагын бер съезд җыелды әле. Бу хәл 1992 елның июнь аенда булды. Әмма аны инде элеккеге мәгънәдәге СССР совет язучылары җыены дип әйтеп булмый. Партиянең беткән, СССРның тәмам таралган чагы. Советлар Союзы җирлегендә дистәләп мөстәкыйль, яңа дәүләтләр оешкан. Кая ди анда, коммунистлар партиясе җитәкчелегендәге, социалистик реализм нигезендәге күпмилләтле совет әдәбияты турында сөйләүләр!.. Өстәвенә бу съездда Латвия, Литва, Эстония, Молдова, Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗан язучылары бөтенләй катнашмады. Украина һәм Беларусь вәкилләре күзәтүче сыйфатында утырдылар. Шулай булгач, нинди СССР Язучылары Съезды була инде ул! Дөрес, Казакьстан, Үзбәкстан, Татарстан, Төрекмәнстан, Таҗикстаннан килгән язучылар кызып-кызып шактый сөйләделәр бу съездда. Төрки халыклар һәм рус язучыларының (Евразия тәгълиматына саллы мисал!) активлыгы белән үткән бу съездны үзбәк Т. Пулатов ачты, һәм Язучылар союзларының Халык-

ара берлеге (МСПС — Международное сообщество писательских союзов) рәисе итеп ул сайланды да. Биш-алты ел үткәч, бу шәхес язучылар Олимпыннан төшерелде, каядыр юкка чыкты... Кыскасы, СССР язучыларының чын мәгънәсендәге съезды 1992 елда түгел, ә 1986 елны узган булып чыкты. 1934 елда старт алган Бөек башлангычның ахыры шулай тәмамланды.

(Язмамның беренче өлешендә, үз-үземә дигәндәй, сорау куйган идем: 1934 елдагы I Бөтенсоюз язучылар съездында катнашкан берәр исән кеше бар микән? Күптән түгел «Лит. Газета» аша ачыкланды — бар икән! Ул — Екатеринбургта яшәп ятучы 95 яшьлек шагыйрә Елена Хоринская. Съездда яшь шагыйрә сыйфатында Бурят-Монголия вәкиле булып катнашкан. Татарстаннан делегат булып катнашкан Хәсән Туфан 1981 елны вафат булды. Калганнары — яшьли диярлек һәлак булдылар, югалдылар...)

Фикер агышына ияреп, без берничә елга алга сикердек шикелле. Хроникаль эзгә төшеп, үзебезнең хәлләргә янә кайтыйк.

**Татарстан язучыларының XI съезды 1989 елның 17 маенда В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында (хәзер Милли-мәдәни үзәк) ачылды, икенче көнне Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында дәвам итте** (шул ук көнне Н. Дәүлине дә соңгы юлга озату булды). Съездны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники ачты. Республика язучыларының иҗаты турындагы отчет-хисап докладын идарә рәисе Туфан Миңнуллин ясады. Аннары, жанрлар буенча өстәмә докладлар — проза (Фәрваз Миңнуллин), поэзия (Тәлгат Галиуллин), драматургия (Азат Әхмәдуллин), рус язучылары иҗаты (Михаил Скороходов), балалар әдәбияты (Роберт Миңнуллин), очерк һәм публицистика (Газиз Кашапов), «Казан утлары» журналы эшчәнлеге (Ренат Харис), тәрҗемә (Солтан Шәмси) тыңланды.

Фикер алышуларда Р. Мөхәммәдиев, Н. Әхмәдиев, Разил Вәлиев, Р. Кутуй, С. Наметбаев (Кыргызстан), Р. Фәйзуллин, Ә. Рәшитов, Ә. Мәхмүдов, Ф. Мусин, И. Салахов, Ә. Гаффар, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ш. Янбаев (Башкортстан), Мансур Вәлиев, И. Нуруллин һ. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре (хакимияттәге соңгы рәсми секретарь!) Р. Идиятуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе рәисе С. Михалков чыгыш ясадылар.



*Язучылар һәм дәүләт эшлеклеләре Кырлайда. Сулдан уңга — Р. Миңнуллин, М. Таишев, А. Гыйләҗев, И. Әхмәтҗанов. 1997*

Съезд яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе итеп Ринат Мөхәммәдиевне, «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Ренат Харисны сайлады. XI съездда сайланган 23 кешелек идарә составы: Ринат Мөхәммәдиев (рәисе), Роберт Батулла, Әхсән Баянов, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Аяз Гыйлаҗев, Әмирхан Еники, Фәиз Зөлкарнәев, Ркаил Зәйдуллин, Газиз Кашапов, Владимир Корчагин, Рәфкат Кәрами, Мәдинә Маликова (рәисе урынбасары), Зиннур Мансуров, Рөстәм Мингалимов, Роберт Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин, Ибраһим Нуруллин, Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Нур Әхмәдиев (соңрак, идарә карары белән бу составка Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев тә кертелде).

Кызык, гыйбрәтле җыен булды бу съезд. Үзгәртеп кору дигән чорның үз пигына җиткән еллары. Партия дигән атарбаның дирбияләре тугарылып бетеп барса да, кемнәрнеңдер әле дилбегәне нык итеп тотарга тырышып тырмашкан чаклары... Шул ук вакытта җәмгыятькә демократик үзгәрешләр кергән еллар. Инде ничә ел рәттән халык ихластан шаккатып кәгазьсез сөйләүче түрәләрне күрә, халык депутатларының һәр чыгышын йотлыгып тыңлый. Килешә, ярсый, бәхәсләшә... Безнең бу съездда да демократик шытымнар чагылды, әлбәттә.

Съезд кабул иткән резолюциядә, мәсәлән, Татарстанга союздаш республика статусы бирү, татар телен дәүләт теле итеп игълан итү, татар язучыларының Бөтенсоюз ассоциациясен оештыру кебек мөһим проблемалар күтәрелде. Шулай ук бу съездда беренче мәртәбә рәис берничә кандидатура арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайланды.

## IV

Ниһаять, язмамның соңгы бүлегенә килеп җиттек. 90 нчы еллардан башлап XXI гасырның беренче еллары, ягъни бүгенгегә кадәрге әдәби хәлләр. Өр-яңа тарих булып чыга инде. Чыннан да, хәзер генә кайнап-пешеп чыккан ризык шикелле кабаланып йотсаң... Суыныр өчен вакыт кирәк. Шулайдыр, юкса 2001 елда чыккан «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы VI томы 90 нчы еллар белән тәмамланмас иде. Шулай да соңгы 10–15 еллардагы әдәби хәрәкәт турында сөйли башларга, анализлап, сабак алып, кайбер нәтиҗәләр ясый башларга вакыт җитте кебек. Бу еллардагы җәмгыять тормышын бирәү дә тулы итеп объектив бәяли алмас әлегә. Ә еллары нинди диген! Революцион үзгәреш, хөррият еллары диикме, халык милкенең бәгъзеләр тарафыннан үзләштерелү еллары яки ачыклык һәм болганчыклык еллары диикме?.. Бу елларга эпитетларның кайсы да — уңае да, тискәресе дә бик ипле ябыша ала... Бу еллардагы иң зур үзгәреш, хәтта сенсацион үзгәреш, әлбәттә — СССРның таркалуы булды. Күпләр өчен көтелмәгән тетрәнү. Төп йорт таркалгач була торган хәлләр башланды илдә. Аерымланулар, бүлгәләнүләр, мал бүлешүләр... Бу процесс иҗат оешмаларын да читләтеп үтмәде. Иҗат оешмаларының иң көчлесе саналган Язучылар союзларында бу процесс бигрәк тә ачык күренде. Үзәк Әдәби фонд карамагында булган мөлкәт тирәсендә шау-шулар, суд-низаглар аеруча көчле булды. Чөнки байлык та бар иде шул! Атаклы иҗат йортлары гына күпме иде! — Пицундада, Ялтада, Дубултыда, Переделкинода... Мал-мөлкәт тирәсендәге ыгы-зыгы (Мәскәүдә аның әле хәзер дә тынганы юк) бер хәл, язучылар үзләре дә бүлгәләнеп бетеп, төрле төркемнәр булып оештылар. Башкаладан үрнәк алыпмы, үзләренең ихтыяҗы булыпмы, мондый хәлләр регионнарга да күчте. Мисалга ерак барасы түгел, күрше чуашларда язучыларның берничә оешмасы хасил булды... Ә бездә? Бездә андый бүлгәләнүләр булмады дип әйтеп була. Дөрес, 80 нче еллар ахырында Язучылар оешмасының кирәклеген шөбһә астына куйган фикерләр булгалады. «Язучылар колхозы»н

тәнкыйтьләгән мәкаләләр күренгәләде. Әмма, сүз, нигездә, оешманы бетерү турында түгел, оешманы яңача үзгәртеп кору, камилләштерү кирәклеге хакында барды. Язучылар оешмасының безнең өчен зарур булуы хакында XI съездда Т. Миңнуллинның хисап докладында да кистереп, дәлилләп әйтелде. Оешмабызның таркалмый-бүлгәләнми тотрыклы булып калуы, минемчә, бердәмлегебез, эчке көчебез билгесе. Дөрес, 1995 елда Татарстанда, халыкара язучылар оешмасының бер тармагы буларак, ПЕН-үзәк төзелде. Әмма ул — үзебезнең төп оешмадан аерымлануны түгел, киресенчә, язучылар коллективының иҗади-сәяси мөмкинлекләренең зурлыгын гына күрсәтте. Чөнки ПЕН-үзәктә шул ук абруйлы язучылар, байтагы Татарстан Язучылар оешмасының идарә әгъзалары...

СССР таркалу белән, сәяси вазгыять тә бик нык үзгәрде: милли үсеш максатлары шул ук калса да, ориентирлар алышынды. Әйтик, союздаш республика статусы алу максаты мәгънәсен югалтты. Үзбилгеләнүдә грузин, үзбәк, латышлар һәм башка халыклар дәрәҗәсен аласы булса, аерым мөстәкыйль дәүләт булырга омтылырга кирәк булып чыкты... Әгәр теге яки бу басма ачуга дистә еллар буе ялынып дигәндәй йөреп Үзәктән рөхсәт алу кирәк булса, хәзер андый рөхсәт-карарларның хаҗәте бетте. Оештыр үз республикаңда, үз өлкәңдә; канунлаштыр, чыгар — бернинди каршылык юк. Һәм... кем әйтмешли, «процесс башланды!», буа ерылды... 1989 елның июленнән яшьләр журналы «Идел» (ярты гасырлап хыялда йөргән басма!), 1990 елның мартыннан «Салават күпере», 1991 нче елның сентябреннән «Мирас», шул ук елның октябреннән «Аргамак» чыга башлады... Мөгаен, мәдәният-мәгариф өлкәсендә иң зур казанышларыбызның берсе — 1991 елда «Мәгариф» нәшриятының оештырылуыдыр (дөрес, мондый исемдәге нәшрият XX гасыр



башында ачылып, 1922 елда ябылган булган). Бөтентатар дөньясын дәреслекләр, төрле методик әсбаплар белән тәэмин итеп торучы бу зур «рухи завод»ның башында безнең язучыбыз Мөдәррис Вәлиев торды. Цензура бетерелде. Гомумкешелек гуманизмына каршы килмәгән теләсә нинди әсәрнең дөньяга чыгуына юл ачылды. Кайчандыр басылган булып та, совет заманында тыелган әсәрләр янәдән халыкка кайтты. Моңа Г. Исхакый иҗаты ачык мисал. (Хәзер Г. Исхакый иҗатына елышкан галим-голәмә җитәрлек; классикны дөньяга янә танытучы — «мин!», диеп йөрүче мөтәпионерлар да табыла. Асылда, бу эшнең башында Ибраһим Нуруллин, Лена Гайнановалар торды. Г. Исхакыйның күләмле әсәрләрен беренче булып яңадан чыгаручы журнал «Казан утлары» булды. «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Сөннәтче бабай» әсәрләре И. Нуруллинның кереш сүзе белән журналыбызда 1990 елның 1 нче санында басылып чыкты.) Әйе, хакимият органнары тарафыннан чикләү, тыюлар бетерелде. Моны мин, журналда эшләү тәҗрибәсенә таянып, белеп-инанып әйтәм. Эш дәверендә, идеологик караштан чыгып, әдәби-эстетик кыйммәткә ия бер генә әсәр дә читкә тибәрелмәде. Киресенчә, безнең заман язучыларының элекке елларда басылмыйча калган шәп әсәрләре юк дәрәҗәсендә булып чыкты. Чыгарма булып, бәлки, С. Батталның «Я — Иванов Иван Иванович» дигән күләмле памфлеты гына санала аладыр... Күрәсең, безнең язучылар — конъюктура законнарын яхшы үзләштергән прагматиклар, һәм алар, «баш китәрлек» әсәрләр язып, киләчәк буыннарны «бимазаламаска» булганнардыр...

* * *

«Атай үлде, хөррият килде!» дип әйткән ди, имеш, бер малай. СССР таркалып, демократия дигән хөррият килеп алды алуын (Казансу ярында хәтта «Хөррият» исемле биек сын-стела да калкып чыкты!), әмма аның «ләкин»нәре дә безнең өчен күп икән шул! Чәчелгән, сибелгәнлекнең тагын бер «татлы» җимешен татыдык: байтак милләттәшләребез тарихи Ватаныннан тәмам өзелеп, чит дәүләт-мәмләкәтләрдә калды... Үз туфрагында берегеп күмәкләшеп яшәгән халыклар үз дәүләтләрен корды, ә без — татарлар, тагын да азаеп, Россия карынында калдык... Казакъстан һәм Урта Азиядә күпләп яшәүче милләттәшләребез белән рухи аралашу бөтенләй диярлек бетте. Кая ди ул театрларыбызның ел саен

Урта Азиягә чыга торган гастрольләре? Газета-журналларыбыз, китапларыбызның юлы кырт киселде. Элек «Казан утлары», «Азат хатын» («Сөембикә») журналларының өчтәндүрттән бере (ул 15–20 мең дигән сүз!) шул якларда таралса, хәзер алар өч-дүрт дистә данәгә калды... СССР таркалгач, татар матбугатының (бу хәл башка халыкларга, шул исәптән русның үзенә дә кагыла) тиражлары катастрофик дәрәҗәдә кимеде. Дөрес, Россиянең татарлар яши торган төбәкләрендә татарча газеталар ачылды ачылуын. Әмма алар, безнең район газеталары сымак, әдәбият-сәнгать үсешенә әллә ни тәэсир итәрлек дәрәҗәдә була алмадылар. Казанда чыга торган төп басмаларның таралуына да әллә ни булышлы тәэсир итмәделәр шикелле. Бәлки әле киресенчәдәдер: чөнки татарча укучылар катламы бик «юка», гомумтатар укучысының матди яклары кысынкы икәнлекләрен дә исәпкә алсак, әбүнәчеләр, гадәттә, берәр басмадан артыкка языла да алмыйлар. Кайберләре, бәлкем, әнә шул җирле газетаны алдырадыр... Кыскасы, татар телендәге басмаларның тиражы кимүе безгә — язучыларга бик «кырын сукты», укучыларыбызның кискен кимүенә китерде. Ә язучының укучысы булмаса...

Газета-журналларның таралышы һәм иҗтимагый әһәмиятләре турында абстракт сөйләү бер хәл, аларны чыгарыр өчен иң мөһиме — матди җирлек, финанс чыганагы кирәк бит әле! 90 нчы еллар башында газета-журналларыбызны нәшер итү мәсьәләсе бик катлаулы һәм киеренке булды. Элек



*«Казан утлары» журналы коллективы. 2002*

керем китергән басмалар, тиражлар нык кимегәч, үз чыгымнарын каплый алмый башладылар. Яңа чыганаклар эзләү ихтыяҗы туды. СССР таркалып, Россия үзенә үзбаш булып калгач, экономик, шуңа бәйле финанс яктан, бизгәк тоткан кешедәй, калтыраулы хәлдә иде. Элек сүзлекләрдән генә ишетеп белгән инфляция, дефолт кебек терминнар актив сүзләр булып китте... Хезмәт коллективларында киеренке хәлләр туды. Хезмәткәрләргә вакытында хезмәт хакы түләп булмый, авторлар символик гонорарларын да яртышар ел көтәргә мәҗбүр. Мәскәүдә әдәби журналларның бөтенесе диярлек Язучылар союзы органы булудан туктадылар. Чөнки иҗтимагый оешма статусындагы (үзләре дотациягә, ярдәмгә мохтаҗ) Язучылар союзлары теге яки бу басма өчен бернинди финанс ярдәме күрсәтә алмый. Безнең «Казан утлары» журналы каршына да килеп басты бу проблема. Дистә еллар буе дәүләткә керем китереп, традицион рәвештә Татарстан Язучылар союзы органы саналып, җай белән генә чыгып килгән журналга базар мөнәсәбәтләре чорында нишләргә иде соң? Әбүнәчеләрдән җыелган акчага нибары берничә сан гына чыгарып була... Җир кемнеке булса, җыр шуныкы дигәндәй, кем түли, шул гамәлгә куючы була. 1991 елны Татарстан Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгы тарафыннан журналның оештыручылары булып Газета-журналлар нәшрияты, Татарстан Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы расланды. Ә ярты елдан соң журналның төп оештыручысы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты булуына ирешелде. Шулай итеп, 1992 елның башыннан бүгенгә кадәр «Казан утлары»н оештыручылар — гамәлгә куючылар булып Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы санала. Күрәсез, оештыручылар үзгәреп торса да, Язучылар берлеге алар арасында гел сакланып килende. Моны журналның традицияләргә тугрылык билгесе, Язучылар берлегенең бердәмлеген саклауда өлеше дип санарга кирәк. Бу очракта шуны да әйтеп узу урынлы булыр: гамәлгә куючыларның берсе саналу бер нәрсә, ә чын гамәли эш икенче нәрсә. Язучылар берлеге «Казан утлары» эшчәнлегенә сизелерлек ярдәм дә итә алыр иде. Әйтик, журнал таратуны активрак оештыруда гына булса да... (Милли матбугатны, бу очракта төп әдәби журналны укучыларга җиткерү зур проблема хәзер. Халык дәррәү китап-журнал укыган заманда да Язучылар союзы җитәкчелеге бу мәсьәләне гел күз уңында тота иде. Язучылар коллективына, бигрәк тә идарә әгъзаларына махсус бурычлар йөкләнә, соңыннан аларның хисап-отчетлары

тыңлана, тикшерелә иде. Хәзер бу гамәлләр онытылып бара... Ә бит, төптән уйласаң, хезмәте булган язучыларга һәм мораль, һәм матди, бүтәнчә әйтсәк, социаль яклау ягыннан хәйран гына булышып килә журнал. Гомумән, «Казан утлары»ннан башка татар әдәбиятын күз алдына китерү кыен.)

Бер ел элек республикада «Татмедиа» дип аталган массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оешты. Без әлегә шул агентлык канаты астында. Туктаусыз реформалар заманында алга таба журналны гамәлгә куючылар кемнәр булыр, нинди үзгәрешләр кичерелер, кистереп әйтү кыен.

Шулай да оптимист буласы килә: соңгы 15 ел эчендә Татарстан хөкүмәте ярдәме белән журналыбызның өч юбилеен — 70–75–80 еллыкларын зур итеп үткәрә алдык, җитәкчелекнең әдәби җәмәгатьчелек белән берлеген тойдык. Вакыйгага әверелгән бу күңелле фактлар безгә алга таба да яшәячәгебезгә ышаныч тудыра.

* * *

Нинди генә икътисади кыенлыклар булмасын, 90 нчы еллар — Татарстан, гомумән татар тарихында кабатланмас бөек еллар! Халыкның үзаңы уянган еллар, Татарстан дөньяга ныклап танылa башлаган еллар! Суверенитет турында Декларация кабул итү, Татарстанның Президентын сайлау, Референдум уздыру, чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә Татарстанның вәкиллекләрен булдыру... Җиңүгә тиң бу казанышларда безнең каләмдәшләребезнең дә өлеше бар дип саныйм мин. Матбугатта чыгыш ясапмы, җыелыш-митингларда катнашыпмы, ачлык акцияләре оештырыпмы, депутат мөнбәреннән сөйләпме, бик күпләр ихластан Татарстанның киләчәге, аның бәйсезлеге өчен җан атып йөрделәр. Депутатларыбыз да күп эшләде ул елларда. Мандатлы вәкаләте булгач, табигый, эшләргә тиеш иделәр дә. Элегрәк язучылардан бер кеше, гадәттә идарә рәисе югары органнарга (СССР, РСФСР, ТАССР Югары Советларына) сайлана иде. 90 нчы елда депутат булып алты кеше үтә алды (Р. Мөхәммәдиев — РСФСР Югары Советына, Ф. Бәйрәмова, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис — Татарстан Югары Советына). Шул еллардан башлап бүгенгә кадәр язучылардан дүрт-биш кеше депутат булып Татарстан парламентына сайланып килә. Әгәр парламентта язучыларның көчле төркеме булмаса, милли мәнфәгатьләрне кайгырткан кайбер законнар, карарлар, мөрәҗәгатьләр, мөгаен, дөньяга чыга да алмас иде.

1989 елдан (язмадагы бүленеш буенча 90 нчы еллар башы дип алыйк) бүгенгә кадәрге унбиш ел эчендә идарә рәисе вазифаларын Р. Мөхәммәдиев (1989–1999) һәм Ф. Галимуллин (1999 елдан) башкарды (соңгысы — башкарып килә). Идарәнең, гомумән, Язучылар оешмасының эшчәнлеге күпмедер дәрәҗәдә рәиснең шәхесенә, аның әдәбияттагы абруена, оештыру сәләтенә, фидакарьлегенә бәйле. Р. Мөхәммәдиев Союз рәисе булуы дәверендә, Россия Югары Советына сайланды һәм анда даими эшли торган комиссия җитәкчесе булды. Мәскәүдә йортлы-җирле булып дигәндәй, төп вакытын башкалада үткәрде. 1990–1993 елларда кайтып-килеп җитәкчелек итте. Оешмадагы төп оештыру эшләрен аның урынбасарлары З. Мансуров, М. Шиһапов алып барды (берара урынбасар вазифаларын Г. Гыйльманов, М. Маликова, Ә. Гадел, Р. Аймәт, Д. Салихов башкарды).

Иҗади һәм оештыру эшләре ничек кенә бәяләнмәсен, оешманың 90 нчы еллар башындагы эшчәнлегенең бер характерлы моментын искәртеп үтәргә кирәк: ул — Татарстан Язучылар оешмасының мөстәкыйльлеген тәэмин итеп, аны Халыкара Язучылар бердәмлегенә кертү. Шул максатны күздә тотып, 1991 елның 15 мартында язучыларның съезд дип аталган бер җыены булды. Ул, асылда, ел йомгакларына багышланган җыелыш иде. СССР (?) Язучылар союзының, алда әйтелгән IX — соңгы съездына вәкилләр сайлау өчен, Устав кушканча, бу җыелышның съезд дип аталуы кирәк иде. Шуңа да бу җыелыш-съезд, чираттан тыш саналып, фәләненче санлы съезд булып исәпләнмәде дә. Шулай да бу җыелышта әле хәзер дә гамәлдә булган Татарстан Язучылар берлегенең Уставы кабул ителде. Шул ук елның октябрендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлеге арасында хезмәттәшлек килешүе» төзелде. Килешүнең беренче җөмләсендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан




РСФСР Язучылар берлеге белән ТССР Язучылар берлеге арасында төзелгән хезмәттәшлек

КИЛЕШҮЕ

Республикасы Язучылар берлеге, тигез хокуклылык шартларында һәръяклап хезмәттәшлек итәргә килешенделәр» диелә. Тарих өчен кызык, гыйбрәтле документ. (Соңгы вакытта бәгъзе иптәшләрнең Татарстан оешмасын янә Россия Язучылар оешмасына буйсынулы итәргә омтылышлары булды. Безнеңчә, ашыгырга ярамый. Россия язучылары әлегә үзләре берничә үзәккә бүленеп беткән. Икенчедән, иске үзәккә кайтуның безнең өчен әлегә бернинди файдасы күренми. Чөнки Мәскәүдәге нәшриятлар һәм басма органнар Язучылар союзына карамый, элеккечә үзәктә китаплар чыгару мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Киресенчә, кайбер Мәскәү журналлары үзләре ярдәм сорап Татарстанга мөрәҗәгать итәләр... Иҗат эше — сәнәгать тармагы түгел (анда чыннан да интеграциясез булмый!), безнең эш иреклеккә, демократик тигезлеккә корылган. Гомумән, чын дуслык, хезмәттәшлек тигезләр арасында гына була ала. Бу — аксиома).

Язучылар берлеге тарихына кагылышлы бу хезмәттә Союзның төрле еллардагы составы, сан-исәбе турында берничә сүз әйтмәсәм, язмам тулы булмастыр. Сүз Язучылар союзы әгъзасы саналган каләмдәшләр турында бара. Күптән түгел бер каләмдәшебезнең газетада чыккан мәкаләсендә

мондый юлларына тап булдым: «Хәзерге көндә Язучылар берлегенә каләм тибрәтүчене алу кемне дә булса комсомолга алуны хәтерләтә. Таләпләр түбән дәрәҗәдә, шул сәбәпле Союз әгъзасы булып ни язганнары беркемгә дә мәгълүм булмаган каләм тибрәтүчеләр йөри, аларның күбесе хәзерге иҗтимагый тормыштан гына түгел, хәтта әдәбияттан да (әдәбият үзе иҗтимагый тормышның бер өлеше инде ул — *Р. Ф.*) бик ерак тора». Бу юллар гаҗәпләнү яки берәр этәргеч реакция тудырды димим, шулай да көлемсерәү тойгысы уятты. Соңгы биш елда Татарстан Язучылар каршындагы Кабул итү Коллегиясе рәисе буларак, әлбәттә, мондый карашка үз фикерем, үз җавабым бар. Бу хакта бераз соңрак.

Алда әйтелгәнчә, әдәбиятны бернинди оешмалар тудырмый, әдәбиятның сыйфатын оешмадагы әгъзаларның саны билгеләми. Әдәбиятны талантлы аерым шәхесләр тудыра. XIX гасырда русларда махсус дәүләти әдәби оешмалар булмаса да, бөек әдәбият бар. XX гасыр башында Тукай, Исхакый, Ибраһимовлар мисалында бөек татар әдәбияты бар. Шагыйрь әйтмешли, әдәбиятның зурлыгын билгеләр өчен «бер Толстой җитә, бер Тукай»! Үткән гасыр башында, ягъни йөз ел элек, татар мохитендә язучы-мөхәррирләр, бердәм иҗади оешмада әгъза булып тормасалар да, бүгенгедән ким булмаган дип уйлыйм.

1934 елда, Татарстан Язучылар союзы оешканда, утызлап язучы оешма әгъзасы саналган. Сугыштан соңгы елларда СССР Язучылар союзы таныклыгын йөрткән кешеләр иллеләп исәпләнгән. Алда әйтелгәнчә, 1968 елда бу сан 111гә җитә. 1990 елларда Союзга алу артыгы белән активлаша. Ун ел эчендә (1989–1999) 126(!) кеше әгъза итеп кабул ителә (XI–XII съезд арасында 72 кеше, XII–XIII съезд арасында 54 кеше). «Кояш» сүзен язганда биш хата җибәрүче кешеләр Союзга керә» дигән төртмәле сүзләр шул елларда чыкты шикелле. Шулай итеп, XXI гасыр башына гомумсан 280гә җитә. Хәзерге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 302 әгъза. Уртача яшьләре — 59,7 яшь. Искә төшереп чагыштырыйк: СССР Язучыларының беренче съездында катнашкан делегатларның уртача яше 38,5 булган. Без — пенсионерлар оешмасы булып чыгабыз түгелме соң?

«Кадрлар һәммәсен дә хәл итә» дигән бер искерми торган гыйбарә бар. Бу гыйбарә безнең эшкә дә кагыла. Язучылар берлегенә алганда төп роль Кабул итү Коллегиясенә (Комиссиясенә) йөкләнгән. Коллегия карарын идарә, гадәттә, хуплап раслый. Кире кагылган фактлар, гайре табигый хәл саналып, бик сирәк була. 90 нчы елларга кадәр соңгы мөһерне



*Кабул иту Коллегиясе утырышы. Сулдан уңга—Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рөстәм Кутуй, Шаһинур Мостафин, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин, Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Марсель Галиев. 2003*

Мәскәү — СССР Язучылар союзы секретариаты суга иде. Соңгы 10–15 ел эчендә бу мәсьәлә үзебездә — Татарстан Язучылар берлегендә хәл ителә. Кабул ителгән каләм иясенә «Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы» дигән таныклык тапшырыла. Бар иде заманнар: теге яки бу халыкның, республиканың әдәби потенциалын, дөресрәге, оешма потенциалын саннар да билгели иде. Әле хәтердә: 60–70 нче елларда өлкән язучы агайлар: «Кара, үзбәкләр язучылар санын 300гә җиткергәннәр, украиннар — 400 гә... Безгә дә арту кирәк», — диләр иде. Чыннан да, сан арттыруда мәгънә дә бар иде: язучылар исәбенә карап җирле союзларга Үзәктән акча җибәрелә, торак төзелешләренә өстәмә чыганаклар бүлеп бирелә, санаторийлар, иҗат йортларына юлламалар күбрәк килә... Хәзер вазгыять бөтенләй бүтән: җирле бюджет хозурына һәм үз тырышлыгыңа карап үз көнеңне үзең күрәсең.

Ә инде «беркемгә дә мәгълүм булмаган (укып барырга да кирәк! Язучыларның күбесе бер-берсенең иҗатын игътибар белән күзәтеп бара дип әйтә алмыйм) каләм тибрәтүчеләр»не Союзга — берлеккә алу мәсьәләсенә килсәк, җавап мондый: Кабул иту Коллегиясе әзме-күпме әдәби сәләте булганнар арасыннан, булган хәзинәдән иң яхшыларын сайлап

алырга тырыша һәм шулай эшли дә. «Балкып торган 20–25 яшьлек фәлән иптәшне нигә һаман берлеккә алмыйсыз?» дип беркем дә әйтә алмас. Бүгенге Коллегиядә түбәндәге иптәшләр эшли: Равил Фәйзуллин (рәис), Әхсән Баян, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Владимир Корчагин, Нурмөхәммәт Хисамов, Марсель Галиев, Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Шаһинур Мостафин. Орлыктан кибәкне генә аера белә торган иптәшләр дип беләм мин бу язучыларны. Элек тә Кабул итү Комиссиясендә зур абруйлы язучылар эшләде — Г. Бәширов, С. Хәким, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев... Шуны аңларга кирәк: вазгыять элекке белән чагыштырганда нык үзгәрде, язучының җәмгыятьтәге роле тоныкланды... Чит төбәкләрдән түгел, үз республикабызда да яшьләр әдәбиятка ургылып килми. Сер түгел, бүтән өлкәләрдә яшәүче авторларга игътибарны күбрәк бирергә тырышабыз, аларга кайчак ташламалар да ясарга туры килә... Шунысы да бар: артык чикләүләр куеп, иҗади оешманы алып булмаслык крепость-кирмән дә ясарга кирәкмидер. Фикеремне ачык әйтеп бетерим: әйе, бездә 300 язучы юк, бездә оешмада саналган 300ләп әгъза бар. Таныклык йөртү — син әле коеп куйган язучы дигән сүз түгел. Әнә Зөлфәт Хәкимгә язучылар таныклыгы йөртмәү драматурглар ярышында җиңүче булырга комачауламады бит әле! Язучылар оешмасы — демократик характердагы ирекле иҗтимагый оешма. Бу оешмага керергә теләүчеләр бихисап булса да, аннан гариза биреп чыгарга теләк белдергән кешеләр дә бар. Хәтта идарә составыннан да...

Язучылар оешмасына кабул итүдә соңгы ун-унбиш ел эчендәге тагын бер тенденцияне ассызыклап узу мөһим: ул — Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләрне Казанга сыендыру, ягъни әгъза итеп алу. Андый хәл элегрәк тә бар иде, әмма хәзерге шикелле максатчан түгел иде. Бүгенге көндә, бүтән төбәкләрдә яшәп тә, бездә хисапта торган язучылар ике дистәгә якын. Кайберләрен санап үтик: Халисә Мөдәррисова, Рим Идиатуллин, Рамил Чурагулов (Башкортстан), Рауль Мирхәйдәров, Нәзифә Кәримова, Вахит Юныс, Галия Хантимерова, Зөфәр Фәтхетдинов, Әхмәт Саттар (Мәскәү), Иделбикә (Лена Садыйкова), Рифкат Хисмәтов (Ульяновск), Ирек Сабиров (Чиләбе), Һидият Аширов (Пермь), Диләвер Османов (Кырым), Рөстәм Сүлти (Төркия), Равил Бохараев (Англия)... Табигый: әгәр Казан бөтен татарлар өчен уртак башкала саналса, Татарстан Язучылар оешмасы да бөтентатар язучылары өчен тартылу үзәге булып тора.

* * *

**Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды 1994 елның 3 июнендә Казанның Актерлар йортында узды.** Аны кыскача кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов ачты.

Идарә рәисе Ринат Мөхәммәдиев Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 1989–1994 еллардагы эшчәнлеге турында доклад ясады.

Язучылар корылтаенда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясады. Иң элек ул Татарстандагы бүгенге сәяси һәм икътисади хәлләр турында сөйләде. Аннары Президент Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамәгә һәм Б. Н. Ельцинның Татарстанга визиты йомгакларына кагылышлы фикерләре белән уртаклашты, татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру, татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре санын арттыру, газета-журналлар нәшер итү, китап бастыру, язучыларның матди хәлләрен җиңеләйтү турында сөйләде. Аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру мәсьәләләренә дә киң тукталды.

Аннары ревизия комиссиясе отчеты (Р. Даутов), төрле жанрлар буенча докладлар — поэзия (Г. Морат), драматургия (Р. Мингалим), балалар әдәбияты (Р. Миңнуллин), әдәби тәнкыйть (Ф. Зөлкарнәй), тәрҗемә (К. Миңлебаев), рус әдәбияты (В. Корчагин) тыңланды. Проза (Ә. Гаффар) һәм публицистика (М. Зарипов) буенча докладлар тыңлаучылар таләбе буенча тулысынча яңгырамады. Фикер алышуларда Р. Фәйзуллин, С. Михалков (Мәскәү), Ә. Баян, Ә. Еники, Ф. Баттал, Г. Ахунов, С. Баттал, Т. Галиуллин, Р. Хисмәтуллин, М. Нәзиров (Уфа), Р. Вәлиуллин, З. Зәйнуллин, М. Маликова, Т. Пулатов (Мәскәү), Х. Әшрәфҗанов катнашты.

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең төзелешен үзгәртеп кору хакындагы декларация кабул ителгәч, ачык тавыш бирү юлы белән яңа идарә әгъзалары сайлау булды. Алар: Ринат Мөхәммәдиев (идарә рәисе), Гариф Ахунов, Рабит Батулла, Мөдәррис Вәлиев, Әхсән Баян, Фәүзия Бәйрәмова, Разим Вәлиуллин, Әхмәт Гадел, Шәүкәт Галиев, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Аяз Гыйләҗев, Вахит Имамов, Владимир Корчагин, Рәфкать Кәрами, Мәдинә Маликова, Зиннур Мансуров (рәис урынбасары), Рөстәм Мингалим, Роберт Миңнуллин, Рашат Низамиев, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Зиннур Хөснияр, Мансур Шиһапов (рәис урынбасары), Илдар Юзеев, Азат Әхмәдуллин, Харрас Әюпов.

90 нчы еллар башына туры килгән XI һәм XII съездлар арасы, ягъни 1989–1994 нчы еллар Татарстан, гомумән, татар халкы тарихында онытылмас еллар! Авыр, киеренке, әмма халык рухының күтәренке еллары. Суверенлык, мөстәкыйльлек турында хыялланып һәм ышанып авыз тутырып сөйләнгән еллар. Урамнарда халык ташкыны. Митинглар, Югары Советта кайнар бәхәсләр. Ниһаять, Татарстан Суверенлыгы турында Декларация! Президент сайлаулары, Референдум үткәрүләр... Бөтендөнья татарларының I Конгрессы. Болгар җирендә ислам динен кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган тантаналар. Татар энциклопедиясе әзерләнә башлау... Татарстан белән Россия арасында төзелгән тарихи Шартнамә...

Бу елларның рухи елъязмасында, кабатлап әйтәм, язучыларның өлеше зур. Татар халкы өчен хәлиткеч көннәрдә язучыларыбыз көрәш мәйданының уртасында булдылар. Кирәк чакта меңләгән халык алдында яндырып сөйләделәр, мәйданнарга чыгып ачлыкта утырдылар, шигарь булырлык кайнар шигырьләр яздылар, күпләргә фидакарьлек үрнәге күрсәттеләр.

XX гасыр ахырында чираттагы янә бер съезд булып узды. Анысы санау тәртибе буенча XIII. Әнә шул уникенче белән унөченче арасындагы (1994–1999 еллар) кайбер мәдәни-әдәби вакыйгаларны, фактларны искә төшерик. Г.Камал театрында Татарстан Язучылар оешмасы төзелүгә 60 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды (ноябрь, 1994), Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде.



*Татарстан язучыларының XII съездында сайланган идарә составы. 1994*

Анда язучыларның зур төркеме катнашты (июнь, 1995), атналык «Мәдәни җомга» газетасы чыга башлады (июль, 1995). Баш мөхәррире — З. Мансуров. Г. Ахуновның 70, Т. Миңнуллинның 60 (1995), Г. Тукайның 110 (1996), Мөхәммәдъярның 500, Г. Кандалыйның 200 (1997), Г. Исхакыйның 120 (1998), Ә. Еникинең 90 (1999) еллык юбилейлары киң билгеләнеп үтелде. Шулай ук, Бөтендөнья татарларының II Конгрессы көннәрендә «Казан утлары» журналының 75 еллыгы бәйрәм төсендә үтте... Тарих булып калган хрониканы дәвам итәргә дә була...

* * *

**Татарстан язучыларының чираттагы XIII съезды Казанның Актерлар йортында 1999 елның 28 маенда башланды.** Корылтайны татар әдәбияты аксакалы — 90 яшьлек әдип Әмирхан Еники ачты. Ике корылтай арасында идарә тарафыннан башкарылган эшләр турында хисап докладын Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев ясады.

Корылтай эшендә катнашкан Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, җыенны котлап, җәмгыятебезне үзгәртеп коруга, әдәбиятыбызны баетуга керткән өлешләре өчен язучыларга рәхмәт белдерде һәм әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Корылтайда катнашучылар әдәбиятыбызның бүгенге прозасы, очерк һәм публицистикасы, шигърияте, драматургиясе, балалар әдәбияты һәм рус әдәбияты турында Фоат Галимуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәрит Яхин, Юныс Сафиуллин, Галимҗан Гыйльманов, Владимир Корчагин докладларын тыңладылар. Фикер алышуларда Ә. Баян, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, Р. Зәйдулла, Р. Батулла, Л. Ихсанова, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, К. Булатова, Р. Җамал (Корбанов), М. Маликова, А. Хәсәнов, Ә. Гадел, Д. Салихов һ. б. чыгыш ясады.

Гадәттәге сценарий белән барырга һәм тәмамланырга тиеш булган бу съезд финиш алдыннан көтелмәгән «борылмалар һәм сикәлтәләр» үтәргә дучар булды. Җыен барышында идарә һәм аның җитәкчесе адресына тәнкыйть фикерләре байтак әйтелсә дә, «мунчаның чын пары» яңа җитәкчелек сайлаганда чыкты. Залдагы тамаша — сүз һәм хәрәкәт накалы трагикомик спектакльләрдәге кайбер күренешләрне хәтерләтте. Съездга нинди нокта (яки — өндәү билгесе) куеласы анык булмаганга күрә, Президиум, съездны

вакытлыча өзеп, Язучылар берлеге идарәсен соңрак сайларга дигән нәтиҗәгә килде; һәм бу сайлаулар ике айдан соң, 27 июльдә узды. Идарә рәисе итеп, бик үк фараз ителмәгән, җәмәгатьчелек арасында язучылыктан бигрәк, беренче чиратта радио дикторы һәм пединститут укытучысы буларак билгеле филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин сайланып куелды. Яңа идарә составына түбәндәге язучылар керде: Харрас Әюпов, Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Әхмәт Гадел, Марсель Галиев, Фоат Галимуллин (рәис), Галимҗан Гыйльманов (рәис урынбасары), Җәүдәт Дәрзаманов, Вахит Имамов, Рәфкать Кәрами, Владимир Корчагин, Ләбиб Лерон, Зиннур Мансуров, Газинур Моратов, Шаһинур Мостафин (рәис урынбасары), Рашат Низамиев, Гәрәй Рәхим, Равил Рахмани, Данил Салихов, Нәҗибә Сафина, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Айдар Хәлим, Солтан Шәмси, Фәрит Яхин.

Контроль-ревизия комиссиясе рәисе итеп язучы Лирон Хәмидуллин, Кабул итү комиссиясе Коллегиясе рәисе итеп Р. Фәйзуллин сайланды.

Иҗат остаханәләре җитәкчеләре итеп Солтан Шәмси (проза), Зиннур Мансуров (шигърият), Равил Рахмани, соңыннан Җәүдәт Дәрзаманов (балалар әдәбияты), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Кыям Миңлебаев (әдәби тәрҗемә), Владимир Корчагин (рус әдәбияты), яшь каләм ияләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе итеп Фирдәвес Әһлия билгеләнде.

Идарәдә Әлмәт язучылар оешмасына Разим Вәлиуллин, Чаллы Язучылар оешмасына Вахит Имамов җитәкче итеп сайланды.

«Тамгалы» бу XIII съезд узганга да биш елдан артык вакыт үтте. Анда катнашкан кешеләр өчен гыйбрәт һәм сабак алырлык съезд булды ул. Кайбер чыгышларда әдипләргә килешеп бетмәгән дорфалык, субъективизм чалымнары булгаласа да, каләмдәшләр, күңелендәгеләрен яшермичә, ачыктан-ачык ихлас сөйләделәр, татар әдәбиятының киләчәге өчен борчылып чыгыш ясадылар. Демократиянең, сүз ирегенең безнең җәмгыятьтә дә беркадәр урнаша башлавына дәлил иде инде бу. Дөрес, бериш чыгышларда, «яхшы патша» кирәк дигән шикелле, шәп рәис сайласак, эшләребез гөрләп алга китәр, китапларыбыз тоткарлыксыз чыгып килер, каләм хаклары артыр, матди яклар яхшырыр дигән наив ышаныч мотивлары байтак яңгырады. Табигый хәл. Киләчәккә ышаныч булмаса, ничек язмак кирәк?!

Әмма... вазгыять бүтән: дәүләт күзенә карап торган, иҗтимагый оешма саналган иҗат берлекләренең мөмкинлекләре хәзер бик чикле шул... Бу съездда, өстә ярылып ятмаса да, тагын бер хәлне күзәтергә мөмкинлек булды, ул — язучылык хезмәте һәм агымдагы сәяси эшчәнлек. Язучы иҗтимагый тормышта актив катнашырга тиеш (мәҗбүр) булса да, сәясәткә ул башы-аягы белән кереп йотылырга тиеш түгелдер. Язучының хезмәт җимеше — күңел аша үткәрелгән акыл һәм хис квинтэссенциясе. Ә сәясәттә кануннар катгый, анда күңел кичерешләренә, чын хисләргә урын тар... Уен тәртипләре бүтән. Элеккеге берлек рәисенең эшчәнлеге әнә шундый уйлануларга этәрде. Шулай, съездлар, кайберләре кара төнгә кадәр утырып, бер көн эчендә йомгаклана, йә икешәр айлык тәнәфес ясап тәмамлана да ала икән.




*Лондонда чыккан татар поэзиясе антологиясе. 2000*

* * *

**Соңгы (әлегә) — XIV съезд, яңартылган Устав нигезендә, гадәттәгечә биш елдан түгел, өч елдан соң үткәрелде. Ул 2002 елның 31 маенда Казанның К. Тинчурин исемендәге театры бинасында узды.**

Корылтайда катнашучыларны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлады. «Язучыларның зур җыелышы — Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга», — диде ул үзенең чыгышында.



*Татарстан язучыларының XIV съезды президиумы. 2002*

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турындагы хисап доклады белән идарә рәисе Фоат Галимуллин чыкты. Ревизия комиссиясе хисабын Лирон Хәмидуллин ясады. Әдәби жанрлар буенча Резеда Әхтәмова (шигърият), Факил Сафин (проза һәм публицистика), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Дания Гыймранова (драматургия), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Флера Сафиуллина (әдәби тел мәсьәләләре), Лилия Газизова (рус язучылары иҗаты) өстәмә докладлар ясадылар.

Докладлар буенча фикер алышуда Г. Зәйнашева, Г. Рәхим, В. Имамов, Р. Вәлиуллин, З. Мансуров, М. Маликова, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, Җ. Дәрзаман, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, А. Хәлим, В. Лавришко, И. Хөснетдинов һ. б. чыгыш ясады.

Корылтайда альтернатив нигездә күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп янә Фоат Галимуллин сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар керде: Харрас Әюпов, Фәүзия Бәйрәмова, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Лилия Газизова, Фоат Галимуллин (рәис), Галимҗан Гыйльманов (рәис урынбасары), Җәүдәт Дәрзаман, Вахит Имамов, Рәфкать Кәрами, Зиннур Мансуров, Хатип Миңнегулов, Газинур Морат, Шәһинур Мостафин (рәис урынбасары), Ра-

шат Низами, Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Зиннур Хөснияр, Солтан Шәмси.

Язучылар корылтаенда Ф. Зыятдинов җитәкчелегендә ревизия комиссиясе сайланды.

Вакыт котылгысыз алга ыргыла, еллар бер-берсен алыштырып кына тора. («Гомерләрне талкып еллар үтә!»)... XIV съездан соң да ике ел ярымга якын вакыт үткән. Бу вакыт аралыгындагы әдәби хәлләр турында сөйләүгә әлегә хаҗәт юктыр. Алар күз алдында, хәтер офыгына күчәргә өлгермәгәннәр әле. Устав буенча, киләсе елның җәй башларында яңа съезд җыйналыр, язучылар оешмасының эшчәнлеге турында тәфсилле сүз булыр.

* * *

Шулай итеп, чакрым баганаларын санагандай, без чорлардан чорларга, съездлардан съездларга «тотынып барып» дигәндәй, язмабызның ахырына җиттек. Гадәттә, мондый очракта нәтиҗәләр сорала. Юк, катгый нәтиҗәләр үк ясарга җөрьәт итмим. Үземә андый бурычны куймадым да. Күзәтүче сыйфатында билгеле бер чордагы әдәбиятыбыз дөньясындагы хәлләрне үземчә барлап кына чыктым (укырга җиңелрәк булсын дип, язмамда кулланылган әдәбият һәм архив материалларының төрле чыганакларның исемлеге күрсәтелмәде). Шулай да, билгеле бер үргә менеп, ерактагы офык-манзараларны күзәткәндә, аерым бер урыннарга озаграк карап торасың, алар — биеклекме, агачлар куелыгымы яки шәрә тау итәгеме — карашыңны күбрәк җәлеп итә, уйландыра. Әлбәттә, еллар теземнәре аша артта калган әдәбият киңлекләрен күзәткәндә, минем дә теге яки бу вакыйга яки әсәр нисбәтеннән тукталып, уйланып калган чакларым булмады түгел. Алай гына да түгел, ул уйларның беришләре фикер төеннәре булып күңелдә утырып та калдылар. Кайберләрен укучылар белән бүлешсәм дә ярыйдыр.

Иң әүвәл шуны ачык итеп әйтергә кирәк: әдәбиятыбыз, шөкер, бай әдәбият. Гомумкешелек мәдәнияте мирасына керерлек әсәрләр бар. Теләк җимеше итеп әйтелгән сүз түгел, бу — хакыйкать. Әмма... бу хакыйкатьне беләләрме? — бүтәнчәрәк әйтсәк, дөньяда моны белүчеләр күпме? Кызганыч, күп түгел, һәрхәлдә, без теләгән дәрәҗәдә түгел. Өстәвенә белүчеләрдән танучылар һәрчак ким чыга бит әле!.. Минемчә, татар әдәбияты тарихын объектив өйрәнү һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Борынгысын әйткән дә юк (аны бармак

белән генә санарлык кешеләр яхшы белә булыр), соңгырак чор әдәби мирасны да юньләп белмибез, һәм шуңа күрә дә әдәбият белемендә моңа кадәр булган критерийлар күп сораулар тудыра да. Татарстан Фәннәр академиясе призеденты Мансур Хәсәнов (ул безнең Язучылар оешмасы әгъзасы да) моннан ун еллар элек үк тикмәгә генә мондый сүзләр язып чыкмады: «Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменең, гомумән, татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Аның төп принцибы — фәлсәфи категорияләрне турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятның, сәнгатьнең, кеше рухи эшчәнлегенең мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш». Чыннан да, әдәбият тарихы буенча үткән гасыр ахырларына кадәр чыккан хезмәтләрнең абсолют күпчелеге сыйнфый караштан чыгып, сәяси күрсәтмәләр тәэсирендә тегe яки бу идеологик схемаларга туры китереп язылганнар. Хәзер аларны уку кыен, чөнки алар тарихи аңны рәнҗетә, эстетик тоемны боза, чын әдәбияттан биздерә... Ә бит бер гасырга якын диярлек, методологик кулланмалар булып, алар берничә буынның әдәбиятка караш-мөнәсәбәтен формалаштырган... Хәзер, бәлки, хәлләр бик нык үзгәргәндер? Кызганыч, алай ук түгел шул, әзер шаблон схемалар белән эш итүне дәлилләгән күп мисаллар китерергә булыр иде. Язмамның тәмен җибәрәсем килми... Шулай да «Татар энциклопедиясе сүзлеге»ннән берничә цитата китерергә җөрьәт итәм. Коръәннән (энциклопедияне Коръән белән чагыштыру бик үк урынлы булмаса да, җитдиләрнең дә җитдие булган академик басма ул) ялгыш эзләп азаплануым түгел, мисалның да бик өстә ятканын, күзгә ташланганын гына китерәм, анда да сүз конкрет бер мәкалә турында гына булыр. Сүзлекнең 622 нче битен ачып, «Татарстан Республикасы» дигән мәкаләдән әдәбиятка багышланган кайбер юлларны укыйк: «60 нчы еллардан үткәннәргә яңача карарга, бүгенгене тасвирларга мөмкинлек туа (андый мөмкинлек элек тә булган, күрәсең, тулырак яки объективрак тасвирларга мөмкинлек туа дип әйтергә теләгәннәрдер инде — *Р. Ф.*). Татар әдәбиятының бу этабында Р. Төхфәтуллин, Ә. Давыдов, А. Гыйләҗев, Ш. Мөдәррис, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Х. Камал, Ә. Баян, Г. Афзал, Э. Касыймов, Ш. Бикчурин, М. Шабаев, Ш. Галиев, И. Юзеев, Ш. Хөсәенов, Б. Камал кебек «алтмышынчы елгылар» үзләре яшәгән заманның

мөһим иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрен күтәреп чыгалар». Бу саналган исемнәрнең берсен дә диярлек «60 нчы елгылар» дип санап булмый. Гадәттә, «фәләненче елгылар» дип, әдәбиятка килү чоры белән бәйләнештә әйтәләр. Бу язучыларның беришләре әдәбиятка сугыш чорында аяк баскан, күбесе — 50 нче елларда күтәрелеп чыккан шәхесләр (Г. Ахунов, Г. Афзал, Ш. Галиев, Х. Камал, Р. Төхфәтуллин, Ш. Хөсәенов һ. б.). Чынында, 60 нчы еллар буыны дип безнең буын (Р. Мингалим, Р. Харис, Рәш. Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Р. Гатауллин һ. б.) санала ала. Энциклопедиягә мәкалә язган авторларның яки авторның исенә төшерик: сез «60 нчы елгылар» дип санаган кайбер шагыйрьләр 60 нчы елларда инде дөньяви тормышларын һәм иҗатларын тәмамлап мәңгелеккә китеп тә бардылар (Ш. Мөдәррис — 1964 елда, Ә. Давыдов — 1968 елда вафат). Шунысы да игътибар иттерә: «Татар энциклопедия сүзлеге»нең русчасында (1999) бу абзацта 9 язучы саналса, шул ук Сүзлекнең (2002) татарча вариантында инде 16 исем. Аерма шактый! Бер үк материал нинди телдә бәян ителсә дә, тәңгәл булырга тиештер. Хәер, бу ишәю, шул ук белешмә-мәкаләдә әйтелгәнчә, шуннан килеп чыгадыр: «әдәбият белеме исә бер яклы идеологик ысуллардан арына бара, әдәби күренешләргә һәм тенденцияләргә фәнни һәм объектив бәя бирергә омтыла». Гомумән, яхшы омтылыш... Дәвам итик, шул ук мәкаләдә «...1970–1980 елларда И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, Ф. Яруллин, М. Юныс, М. Хәбибуллин, Ә. Галиев, С. Сөләйманова, Мәхмүт Хәсәнов, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, В. Нуруллин, Р. Батулла, М. Галиев, Ә. Гаффар, З. Хәким, Ә. Рәшитов, Л. Шагыйрьҗан,



*Күптән көтелгән бу уникаль тарихи басмада бик күп татар язучылары турында мәгълүмат табып була. Сүзлек 2002 елда басылган*

Х. Әюп, М. Маликова, Р. Гатауллин һ. б. (русча Сүзлектә исемнәрнең бу блогында 13 язучы санала, татарчасында — 25) иҗади активлык күрсәтәләр». Нигездә, дөрес. Ә тәгәлсезлекләр? Әйтик, З. Хәким әдәбиятта 90 нчы еллар башында күренә башлады, Роб. Әхмәтҗан һәм башкалар инде билгеле шагыйрьләр булып йөргәндә, З. Хәким әле тумаган да иде бугай... Саный белеп санауның да үз тәртибе бар бит. Әйе, саналганнар активлык күрсәткәннәр. А. Хәлим, Ф. Садриев, Р. Мингалим, Г. Рәхим һәм тагын кайберәүләр иҗади активлык күрсәтмәделәрме? 1990 еллар әдәбияты турында сүз барганда, ни өчендер тарихи темаларга язучы 3 каләмдәш кенә телгә алына (анда нигәдер Ф. Латыйфи төшеп калган). 90 нчы елларда өч кенә кеше актив иҗат иткән булып чыга түгелме... Ул елларда бүтән язучылар да күп хезмәт куйдылар бит: З. Мансуров, Ф. Бәйрәмова, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин (Ф. Әмәк), Р. Зәйдулла, Г. Морат... Һәммәсен кертеп бетереп булмый диярләр. Алай дисәң, шул ук бик чикләнгән урында кайбер исемнәр икешәр мәртәбә кабатлана. Әйтсәң — сүз, төртсәң күз дигәндәй, җитеп торыр. Язучыларны шәкли рәвештә «вакыт ояларына тәгәл утырта» да алмагач, аларның иҗатларына иҗтимагый бәя биргәндә, конкрет әсәрләренә фәнни-эстетик анализ ясаганда нинди «чытырманлы карурманнар» барлыгын чамаларга була. Бу фикерне очлап шуны әйтәсе килә: язучы исеме галим-голәмәгә, кайбер очракта мөтәгалимгә, уңайлы ясалма кысалар өчен иллюстратив рәвештә генә файдаланылмаска тиеш. Үткән тарихыбызны, бүгенгене үзебез өчен дә дөрес һәм ачык итеп аңлый алмасак, аны бүтәннәргә ничек аңлатмак кирәк?!

Без съездлар, юбилейлар, лауреатлыклар турында сөйлибезме, оешманың көндәлек эше турында сүз алып барабызмы — барыбер уйлануларыбызның төп мәгънәсе язучы хезмәтенең асылына — аның әсәрләренә барып тоташа. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Җитәкчеме син, урын биләмәгән каләм иясеме, язучы саналасың икән, байрак булып иң алдан әсәрең барырга тиеш. Укучы өчен, язучының шәхесеннән бигрәк, аның әсәре кадерле (бала чакта китапханәдән китапның, авторыннан бигрәк, исемен сорап ала идек; күрәсең, яшь чакның логикасы хакыйкатькә күбрәк якын булган). Миңа калса, хәзер, бигрәк тә соңгы 10–15 елда хәл бүтәнрәк: игътибарыбыз күбрәк беренчелгә караганда икенчел факторлар тирәсенәрәк юнәлгән. Гадәттә, без фәлән әсәрнең язылуына (чыннан да, «Туган тел»нең яки «Моабит дәфтәре»нең вакыт-вакыт кайчан язылуларын җәмәгатьчелеккә белдереп торсак, тарихи хәтер өчен зыян булмас,



*Язучыларыбыз — ПЕН-үзәк әгъзалары Финляндиядә үткән Бөтендөнья язучылары Конгрессы көннәрендә. Сулдан уңга — Вахит Юнысов, Әхәт Мушинский, Разил Вәлиев, Тәлгат Бариев, Ркаил Зәйдулла, Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мөдәррис Вәлиев, Марсель Галиев. 1998*

һәрхәлдә, ниндидер графоманның фәлән елда туганлыгын белгертүгә караганда файдалырак булыр иде), фәлән китапның чыгуына фәлән ел димибез, фәлән язучы яки шагыйрьгә фәлән яшь, дибез. Без теге яки бу язучының яңа әсәрен укып тикшерү утырышында яки китап укучылар конференциясендә булдык дию урынына, күбрәк, фәлән язучының юбилеенда яки банкетында булдык, дибез. Юбилей димәктән, аларның иге-чиге юк. Хәер, уртача яше 60 тирәсе булган оешмада юбилярлар күп була инде ул — ел саен йөзәрләп җыеладыр. Шуңа өстәп, әдәби мирастан классик әдипләрнең истәлекле даталары (боларын чыннан да әдәбият файдасына дип әйтик)... Ә юбилейлардагы пафосның ниндилеген барыбыз да яхшы беләбез. Бу ыгы-зыгылы чаралар язучылар коллективының, бигрәк тә оешма аппаратының күпме җегәр-энергиясен ала! **Әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт** килеп чыга. Ә әсәрләребез турында кайда сөйлибез соң? Газета-журнал битләрендә. Табигый, беренче чиратта, «Казан утлары»нда (китап күзәтүләр, рецензияләр, дискуссияләр һ. б.). Әмма бу гына аз. Әгәр көндәлек матбугатта чыккан матери-

алларны анализласаң, аларның күбесе әлеге дә баягы юбилейлар, премияләргә тәкъдим ителү уңаеннан булыр. Әлбәттә, алар инде мактау, зурлау рухында... Иҗат секцияләрендә (хәзер аларны остаханә дип йөртәләр) дә яңа әсәрләрне укыптикшереп анализ ясауга корылган җыелышлар сирәк үтә. Бу остаханәләрнең соңгы еллардагы төп эше теге яки бу авторны Язучылар берлегенә тәкъдим итү булды дип әйтергә ярыйдыр. Дөрес, хәзер хәл беркадәр үзгәрде: каләмдәшләрнең иҗатларына караш җитдиләнә төште, шул сәбәплеме, җыелышлары да сирәгәйде бугай... Язучылар үзләре (бигрәк тә рәис үзе) өзлексез йөреп торалар. Җыелышлар, конференцияләр, сабантуйлар, юбилейлар, сайлаулар яки бүтән сәяси вакыйгалар уңаеннан агитбригада рәвешендәге «десант»лар... Чыннан да, хәрәкәт шактый көчле... Теләк шул: бу хәрәкәт, әйткәнебезчә, әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт кенә түгел, конкрет әдәби әсәрләр нисбәтендә укучыларга, шулай ук язучыларның үзләренә дә кирәк һәм файдалы хәрәкәт булсын.

Әйе, татар әдәбияты зур (аны белү өчен Мәскәүгә яки Орелга бару хаҗәт түгел), әмма аны дөнья без теләгәнчә танымый әле, дидек. Сүз, мантыйк буенча, үзеннән-үзе әдәби



*Язучылар, рәссамнар, композиторлар, актерлар өчен Васильево ял йортында яңа ачылган иҗат йорты бинасы. 2004*

багланышларга, мирасыбызны пропагандалау мәсьәләләренә кайтып төшә. Алда әйтелгәнчә, үткән гасырның икенче яртысында ул багланышлар шактый нык иде. Соңгы дистә еллар эчендә, һәммәбезгә мәгълүм сәбәпләр аркасында (СССР таркалу, глобализм факторы һ. б.), әдәбиятлар, бигрәк тә гадәт буенча әйтелә торган милли әдәбиятлар (дөреслектә һәр әдәбият милли) беркадәр изоляциядә, үз кабыгындагы йомылуда калды. Билгеле бер вакыт аралыгы өчен бу хәл дә ярыйдыр. Бай тарихлы, бай мираслы әдәбият берара үзенең асылын ныграк өйрәнә, үзләштерә ала, үзенең эчке потенциалы хисабына яши ала. (Бу вазгыятьтә тарихи, тамыры булмаган «яшь» әдәбиятлар, гадәттә, «киселеп» кала.) Укучылары беркадәр кими төшсә дә, татар әдәбияты әдәбият буларак бу елларда әллә ни оттырмады дип уйлыйм. Кызыксынган кеше онытылган яки әле моңарчы күпләргә бөтенләй мәгълүм булмаган мирас белән таныша алды. Дөрес, бу заманда үзеңнең «эч мае»ң хисабына гына озак яшәп булмый. Гомумкешелек цивилизациясенә кушылып, бердәм хәрәкәттә катнашып кына, заманча әсәрләр язып, эстетик кыйммәтләр тудырып була. Димәк, бүтән халык әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнеш зарурият булып чыга. Тик шунсы бар: бер кергән агымсуга икенче кат кереп булмаган кебек, әдәби багланышларда совет заманындагы ысуллар бик үк ярап бетмәс шул хәзер. Күпмилләтле совет әдәбиятына лаеклы өлеш кертәбез дигән заманнар үтте. Күпмилләтле Россия әдәбияты дигән сүзләр бик ишетелми. Безнең өчен багланышларның иң ышанычлы һәм дәлилле күрсәткече булган тәрҗемә эшенә дә бүген беркадәр бүтән яссылыкта карарга мәҗбүрбез. Элек тәрҗемәләр ике яклы иде: русчадан татарчага, татарчадан русчага. Хәзер күренекле әдәби әсәрләрне татарчага тәрҗемә итү юк дәрәҗәсендә. (Рус һәм чит ил әдәбияты үрнәкләрен берничә буын татарча тәрҗемәдә укып үсте. Бу — факт.) Ә татарчадан русчага? Бу процесс әзме-күпме бара әле. Барса да элеккегечә эффектлы дәрәҗәдә түгел. Чөнки бүген атаклы рус язучыларының яки шагыйрьләренең дә китап тиражлары — 2–3 мең данә (тиражлары зур булган детектив жанрындагы бестселлерларны чын әдәбиятка санамыйм). Ә аз санлы халыклар әдәбиятыннан тәрҗемә үрнәкләренә ни сан? Россиядә яңа Гамзатовларның мәйданга килүе бик шикле... Димәк, зур дөньяга чыгуның бүтән юлларын эзләргә кала. Рус кириллицасыннан тыш бу кояш астында бүтән имлялы телләр дә бар. Әйтик, инглиз теле, гарәп, испан теле... Бар компьютер, интернет теле... «Тимер пәрдәләр» заманы түгел. Әлбәттә, традицион рәвештә, үзебезнең тирәлектәге,

элеккечәрәк әйтсәк, тугандаш әдәбият вәкилләре белән тыгызрак элемтәләр урнаштыру бик мөһим. Безнең республикада уза торган дәрәҗәле поэзия бәйрәмнәрендә (Тукай, Пушкин, Державин), сабантуйларда, классикларның юбилейларында, съезд-корылтайларда мөмкин кадәр күбрәк эшлекле кунаклар чакырырга кирәктер. Шулай ук, Язучылар оешмасының 70 еллык тантанасына да... Мәхәббәт белән дуслыкка чикләр юк. Олы максат булсын да, зур теләк булсын! Даими рәвештә инглиз телендә китаплар чыгарып килүче ПЕН-үзәк тә бу юнәлештә эшен тагын да активлаштырыр дип ышанырга кирәк. Һәрхәлдә, бу мөһим проблеманы чишү юлында һәммәбез өчен эшлисе гамәлләр тау кадәр.

Иң зур проблемаларның берсе, әлбәттә, яшь язучыларны үстерү. Оешманың төп бурычы дип тә әйтеп була моны. 70 ел элек, ягъни Язучылар оешмасы төзелгәч кабул ителгән Уставта да төп матдә итеп язып куелган ул. Яңартылган хәзерге Уставта да шулай. Табигый хәл. Дөнья шулай яратылган, киләчәгең — дәвамчыда. Без әдәбиятка килгәндә, артта, үкчәңә басып килерлек яшьләр бар иде. Хәзер инде аларны яшьләр дип куштырнаклар эчендә генә әйтеп була, үзләре остаз булырлык, 40 яшьне узган ир уртасы кешеләр. Алар артыннан кемнәр килә, кемнәргә өмет баглыйлар алар, кемнәрне нинди традицияләрдә тәрбиялиләр? Татарстан Язучылар оешмасы яшь иҗатчыларны үстерү юнәлешендә байтак эш башкара: яшь язучылар конференцияләре үткәрү, күмәк җыентыклар чыгару, районнарда семинарлар оештыру һ. б. Шулай да, реаль вазгыятькә карап, оештыру эшләрен тагын да колачлырак итү, эш алымнарының яңа ысулларын табу ихтыяҗ икәнлегенә инанасың.

Татар әдәбияты дигән зур дәрья турында фикер йөрткәндә гыйбрәтләр алып уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Кайчак шундый сорау да туа: бүгенге әдәбиятыбыз гомумтатар



*Татарстан Язучылар берлеге әгъзалыгын раслаучы документ*



*Татарстан Язучылар берлеге бинасы*

әдәбиятымы, әллә Идел-Урал регионының мәдәни үзәге булган Татарстан әдәбияты гынамы (онытмыйк: заманында яңа татар әдәбиятында беренче проза әсәрләрен Ростов, Пенза якларыннан чыккан шәхесләр язды бит. Әйтик, безнекеләр хәзер еш кына баргалап торган Зур Әләзәнлеләр тормышы татар әдәбиятының берәр сәхифәсе була алмас идеме? Бу җәһәттән, бүтән төбәкләрнең исемнәрен әйтеп узарга була. Түбән Идел — Сарытау, Астрахань..., тоташ Урал — Пермь, Чиләбе, Җаек..., Урта киңлекләр — Рязань, Касыйм...). Без еш кына, әдәбиятыбыз берничә гасыр буе, югалган дәүләт институтларының кайбер функцияләрен (мәгърифәт, мәдәният) башкарып килде, дибез. Бу хәл хәзер ничек? Милли аңны, милли идеяне халыкка җиткерүдә язучыларыбызның бердәмлеге бармы, (әгәр язучылар, галимнәр арасында, сүз көрәштерүдән бигрәк, бердәмлек булса, имля мәсьәләсендәге дискриминацион хокуксызлыклар килеп тә чыкмаган булыр иде).

Язмамның баштагы өлешендә сораулы җөмләләрем инде булган иде: әдәбиятыбызның язмышы алга таба ничек булыр? Элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Алдан ук куелган сорауларым күңелемдә, сөттә йөзгән елан кебек, язмам буе шомлы уй булып барды. Чыннан да, безне ниләр көтә? Әдәбият язмышы белән оешма язмышын да күз алдында тотып әйтүем (оешмасыз да әдәбият бетмәс бетүен).

Уйланырлык сәбәпләр бар. Язучылар берлеге — иҗтимагый оешма. Ә әлегә андый оешмаларның яшәешен билгеләүче канун юк. Димәк, юридик хәят — бар белән юк арасында. Бүгенге көндә язучы хезмәтен социаль яктан гаран-

тияләгән законнар юк (шуңа күрә дә Россиядә бик күп язучылар фәкыйрьлек дәрәҗәсендә. Бу уңайдан бездә дә матди яктан иркен яшәгән язучыларны бармак белән генә санарлык). Димәк, хәзерге прагматик яшьләр өчен әдәби иҗат өлкәсендә гарантияле тормышчан перспективалар күренеп тормый (шуңа күрә дә бүген шигъриятькә Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Җәлилләр урынына, үсмер егетләрдән бигрәк, кызкыркын килә дә инде). Ә оешманың гомум уртача яше — 60. Фәкыйрь карт-корыны кайсы җәмгыятьтә үлеп яраталар икән? Дөрес, бездә Россиянең бүтән регионнары белән чагыштырганда хәлләр әлегә шөкер итәрлек. Әгәр республика булмаса, борынгыдан дәүләт тоткан хисне йөрткән затлы катлам булмаса, татарның ил-көн хәлен тойган Илбашы булмаса, эшләр бик мөшкелгә әйләнер иде.

Хәер, гомумән, нигә мөшкел булырга тиеш ди әле! Талантлы булу фаҗига булырга тиешме? Талант — Күкләрдән иңдерелгән илаһи байлык, ил-халык байлыгы, дәүләт байлыгы. Без әлегә ил-дәүләтле булудан ваз кичкән халык түгел. Миңа калса, бүгенге көндә меңьеллык татар әдәбиятының бөек традицияләрен дәвам итәрлек, ким дигәндә биш дистәләп талантлы язучыларыбыз бар. Бу — зур байлык. Язучы кеше — тел сакчысы. Ә тел — милләтнең төп билгесе. Халык, милләт булып сакланып калырга телибез икән — иҗат кешеләренең, шул исәптән заман елъязмачылары — язучыларның кадерен белик! Алар булганда, шәт, нинди генә рәвештә булмасын, иҗат оешмасы да яшәр.

*2004*

# *Кемнәр бар да, кемнәр юк...*






## ГОРУРЛЫГЫБЫЗ

Ил хадимнәребез арасында 90 яшькә җитеп исән-имин йөрүче, актив иҗтимагый тормыш алып баручылар бик сирәк. Белгәннәремнән — Мәскәүдә генерал Я.Чанышев, Уфада шагыйрь С.Кудаш, бездә — рәссам һәм сынчы Бакый ага Урманче... Ихтимал, мондый олуг яшьтәгеләрнең юбилей тантаналарын уздыруда безнең оештыру һәм этик тәҗрибәбез дә җитенкерәмидер. Инде күптән дөнья куеп, хәзер генә 70 яки 80 яшьләре, сирәгрәк булса да 90, 100 еллыклары җиткән классикларыбызның туган көн бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә, шәт, өйрәндек шикелле. Сәхнә түрендә портретлары булыр, халык алдында доклад-нотык сөйләнер, истәлекләр... Сүз, гадәттә, бер юнәлештә, портретка карап дигәндәй, җавап кайтара алмый торган үткәнгә төбәп сөйләнелә. Ә менә исән-сау юбиляр, 90 яшьлек егет алдында, үзе алдында ни сөйләргә?

Кыскасы, халык улы, халык рәссамы Бакый ага Урманчега 90 яшь! Һималай тавына ымсынып карап торучы яшь альпинист халәтендәге бер хис миндә. Ни дисәң дә, арада ярты гасырдан артык гомер ята! Аның хакында моңарчы чыккан язмаларны караштыргалыйм, төрле буын рәссамнарының сүзләренә колак салам, замандашларын тыңлыйм. Әнә бит, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе буенча сабакташы, 88 яшьлек Нәкый ага Исәнбәт Урманче турында ни дигән: «Яңа татар поэзиясендә һәм татар музыкасында нигез салучылар кемнәр?» — дип сораганда, беренчесе — Тукай, икенчесе — Сәйдәш, дип җавап бирсәк, «Татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем?» дигәндә: «Бакый ага Урманче!» — дип, бүген хаклы рәвештә әйтә алабыз.

Бу сүзләр әйтелгәннән соң егерме еллар үткәч, икенче бер зур әдибебез Ә.Еники дә шул ук фикерләрне янәдән тәкърарлап язып чыкты. Димәк, бу фикер — очраклы рәвештә әйтелгән эффектлы тәгъбир генә түгел, ә халык күңелендә төенләнеп килә торган фикер. Чөнки, өлкән әдип Гомәр ага Бәширов әйткәнчә, «Бакый Урманче үз әсәрләрендә татар халкының бай мәдәниятен, аның эстетик карашларын озак еллар буенча гәүдәләндереп килде».



*Бакый Урманче. 1980*

Бакый Урманченың 90 еллыгы — сәнгатебез тарихында, һичшиксез, уникаль бәйрәм, һәр җәһәттән кызыклы һәм мәгънәле бәйрәм. Юбилярның, шәхес буларак, үзе һәм иҗаты — мәдәниятебез тарихы, аерым алганда, сынлы сәнгатебезнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйландыра. Мәгълүм: вак нәрсәгә юлыксаң, үзең дә бәләкәйләнәсең, булган фикерләрең таркалып кечерәя, ә зурлыкка тап булсаң, ныклы нигез сизсәң, уйларың да үзеннән-үзе зурая, колачлана, киләчәккә төбәлә. Иңкүлектә килгән уй белән мәгърур тау башында торып уйланганнар шактый аерыла шул! Феноменаль күренеш дип санарлык Бакый Урманче шәхесе һәммәбез өчен, бигрәк тә яшь иҗатчылар өчен ифрат кызык һәм гыйбрәтле. Иң әүвәл, шундый олы яшькә җитеп (ирексездән хәтергә Б.Шоу, С.Коненков, П.Пикассо, М.Сарьяннар хәтергә килә), аек акылда булып, һәрдаим иҗади халәттә тора алу — үзе бер батырлык, үзе бер егетлек. Егетлек, бәлки, эстетик категория саналмый торгандыр, әмма зур әхлакый мәгънәгә ия тормышчан төшенчә ул. Икенчедән, Бакый ага Урманче таланты гаять күпкырлы: ул — рәссам, сынчы, педагог, публицист, тарихчы, филолог-полиглот, җырчы, шагыйрь... Һәм, ниһаять, җыйнап әйткәндә, киң мәгънәдәге җәмәгать эшлеклесе, халык ихтыяҗларын кайгыртып яшәүче. Өченчедән, классик мәгънәдә чын интеллигент. Ул синең белән үз итеп

шундый ихлас һәм гади сөйләшер, яшь аерымлыкларын һич сизмәссең. Безнең даирәдә югары белемле, рәсми рәвештә фәнни дәрәҗәләргә ирешкәннәр шактый күп, әмма чын зыялылар, интеллигентлар алай ук ишле түгел. Кешелеклелек белән интеллигентлык бик дефицит нәрсә ул хәзер. Һәм, ниһаять, Бакый ага эшкә бирелгәнлек үрнәге дә. Дан Тулпарын тырышлык дигән көмеш йөгән белән авызлыклаган Ир ул.

Уйлап баксаң, бик күп асыл сыйфатларны үзенә туплый алган бит бу шәхес! Андый сыйфатларны үзендә булдырган хәлдә дә, аларны гомер буе саклап, һаман үстереп бара алу, ай-һай, җиңел түгелдер!.. Табигать бүләге — талантттан тыш корыч ихтыяр, ныклы иман, максат ноктасына бара белү, тән һәм җан җегәре, һәм тагын байтак нәрсәләр дә кирәктер! Бу җәһәттән Бакый ага Урманче яшьләр өчен тормыш итә белү, яшәү һәм иҗат итә белү мәктәбе бит! Иҗат итә алу, кеше нинди яшьтә генә булмасын, ул — яшьлекне җуймау дигән сүз. Моның сере нәрсәдә соң? Бу серне белү безгә, иҗатның нинди төре белән шөгыльләнсәк тә, бик тә, бик тә кирәк бит! Моңа өлешчә җавапны Останың Гомәр ага Бәширов белән әңгәмәсендә («Казан утлары», 1987, 2 нче сан) укып, аны үземә бер ачыш дип кабул иттем. Ул болай ди: «Шәхес буларак, үзеңнең кадереңне белеп, вакытыңны һәм көчеңне вактөяккә сарыф итмичә, зур максатларга омтылып яшәргә кирәктер...» Әйе, кадерсез булмыйк, бүген үк кадерсез булсак, киләчәк буыннарның да исе китмәс. Әйе, вакытны һәм көчне юкка сарыф итмик, юкса ил өчен зур эшләр майтара алмабыз... Бу уйлар бигрәк тә бүген, җәмгыятебездә зур үзгәрешләр барган чорда, бигрәк тә актуаль яңгырый. Ахыр чиктә җәмгыятьтә талантның, иҗат интеллигенциясенең абруе — халыкның рухи климатын да билгели бит әле!

Бакый ага Урманченың иҗат хәзинәсе бик бай. Белгечләр язуынча, аның берничә мең график, өч йөздән артык нәкыш әсәре, йөздән артык скульптура сыннары бар. Бу мәгълүматлар дүрт-биш ел элек игълан ителгәннәр иде. Хәзер бу саннар тагын да ишәйгәннәрдер. Хикмәт, бәлки, саннарның ничә урынлы булуларында да түгелдер, халык күңеленә керер өчен дистәләгән чын әсәр дә җитә. Дөресен генә әйткәндә, без Бакый ага иҗат иткән әсәрләрнең байтагын белмибез дә. Кайберләре инде аның җыелган, кайберләре ил буйлап сибелгән. Үзеннән башка ул эшләрнең һәммәсен күргән кеше, ихтимал, дөньяда юктыр. Идел буенда яшәүче замандашлары, асылда, аның соңгы утыз елдагы иҗатын гына белә. Дөрес, 30 нчы еллардагы яки сугыш чоры әсәрләрен альбомнарда-



*Тукай бюсты янында. Сулдан — Н.Арсланов, М.Әмир, Б.Урманче, Г.Әпсәләмов. 1964*

гы репродукцияләр аша бераз чамалыйбыз, хәтта әле кайберләребез аларны анализлап мәкаләләр дә яза. Әмма оригиналларын күрмәгәч, бу омтылышлар тәрәзә аша табигать белән хозурлану шикеллерәк булып чыга. Минем өчен шәхсән Бакый ага иҗаты — киндергә яки картонга төшерелгән рәсемнәре, портретлары һәм мәрмәрдә, бронзада, бетонда, агачта уелган сыннары белән кадерле. Ул — Кол Гали, Тукай, Җәлил, Ямашев, Кариев, Мәрҗани, Насыйри, Дәрдемәнд, Ибраһимов, Көгелтинов сыннары. Ул — «Сагыш», «Язгы моңнар», «Сөембикә», «Наз»лар... Ул — композитор Н.Җиһанов, шагыйрь Х.Туфан, художник Ч.Әхмәров, архитектор И.Гайнетдинов, язучылар Г.Бәширов, М.Әмир, табиб Г.Терегулов, генерал Г.Сафиуллин портретлары. Ул — майлы буяу белән язылган «Салтык болыны», «Уралтау эргәсендә» дигән күренеш-картиналар... Тагын, боларга өстәп, Урта Азия җирлегендә язылган дистәләрчә сыннар, портретлар, пейзаж-этюдлар... Бу соңгылары ир уртасы дәверендә, иҗат дәрте аеручы ташып торган елларда иҗат ителгәннәр. Хәтта репродукция сурәтләре аша танышканда да, алар көчле тәэсир итә. Ә Тукай-Кырлайдагы мемориаль музей комплексы да тулысы

белән диярлек Б.Урманченың иҗат җимеше бит. Бу комплекстагы хезмәтләре генә дә аның халык алдында үзенең рәссамлык бурычын үтәве булып саналырга мөмкин. Татар мәдәниятенең күренекле шәхесләренә багышланган сыннар галереясы һәм Тукай-Кырлай музее комплексы, ихтимал, Оста гомеренең төп хезмәтләредер. Һәрхәлдә, туган төбәк, туган халкы өчен бу шулай.

Бәхәссез, татар милли сынлы сәнгатен ныклы нигезгә салган кеше — Бакый Урманче. Әмма шушы тарихи миссиянең Урманче тарафыннан гамәлгә ашырылуына алшарт булып торган кайбер хезмәтләрне һәм аларның ияләрен дә онытып бетермик. Әйтик, инде 1893 елны ук Петербургта махсус художество белеме алган, гомере буе диярлек Эрмитажда скульптор-реставратор булып эшләгән М.Байкеев 20 — 30 нчы елларда ук Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Вахитов сыннарын ясаган булган. Шулай ук Бакый ага белән бер чордарак югары белем алган С.Ахунның да 30–40 нчы елларда эшләгән скульптура эшләре мәгълүм (С.Ахун — 1958 елны Казан үзәгендә ачылган Тукай һәйкәле авторларының берсе). Инде ераккарак, Болгар чорларына китеп карасак, безнең борынгы бабайларның да ташка бизәк, орнамент ую сәләте шактый ук югары булуына инанасың. Аларның кайберләре борынгы корылмаларда һәм эпиграфик һәйкәлләрдә безнең көннәргәчә сакланган. Әмма тарихи сәбәпләр аркасында озак дәверләр буе бу традицияләрне тергезүче, яңа шартларда дәвам итүчеләр булмаган. Һәм, ниһаять, Вакыт, Замана үз кешесен тудырган. Бакый ага, үзенә багышланган тарихи миссияне тоеп, анда-монда сибелеп яткан ташларны җыйды да, билгеле бер тәртипкә китереп, милли сынлы сәнгатьнең гаҗәп диварын корды... Бер уйласаң, гаҗәп: без белгән скульптура сыннарының күбесен, асылда, пенсия яшенә җиткәч, соңгы 30 ел эчендә ясады бит! Туган җир туфрагы аның икенче яшьлеген кайтарды шикелле. Бу феноменаль хәл аның шәхесенә замандашларының тирән ихтирамын тудырды. «Гаҗәпләнәм безнең Бакыйга! Һәр әсәре аның вакыйга!» — дип язып чыкты Сибгат Хәким. Әйе, болары шулай. Соклану бу очракта Бакый ага мисалында аклана, чөнки горурланырлык ныклы нигез бар. Ә гомумән алганда, безнең рәсем сәнгатендә, бигрәк тә сынлы сәнгать өлкәсендә, тынычланырга, бик югары биеклекләргә ирештек дип әйтергә иртә әле. Дөньяда Луврлар, Прадолар, Уффицилар, Эрмитажлар, Ватикан музейлары бар, төрле кыйтгаларда меңәр еллап тарихлары булган гүзәл сыннар бар...

Бакый ага үзен бәхетле язмышлы кеше дип саный торгандыр. Тәгаен, шулайдыр. Яшәү шатлыгы, хезмәт ләззәте белән, халык мәхәббәтен тою белән... Күпме җир-су күрелгән, күпме кешеләр белән аралашылган, хәят чишмәсеннән ачысы да, төчесе дә күп татылган. Күрәсең, гомер яланын үткәндә сибелү-чәчелүләр дә булган. Бу аның урын алыштырып төрле-төрле җирләрдә яшәвендә дә, һәрберсенә кимендә берәр гомер кирәк булган жанрларга алынуында да чагыла. Сәнгатьнең бер төренә нигез салырга алынган кешенең шул нигез тирәсендә гомер буе басылып эшләве дә табигый булыр иде. Нишлисең, «Сибелә чәчәк» җырындагы шикелле, сибелү-чәчелүгә дучар булган халык язмышы аны да читләтеп үтмәгән... Кызганыч, кайбер фундаменталь хезмәтләре инде кайтмаска югалган. Әйтик, заманында Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе павильоннарындагы монументаль композицияләр, диарамалар, рельефлы бизәкләр. Балхаш бакыр заводы сарайларындагы бизәкләр һәм сыннар да нык таушалганнардыр инде... Ата кеше үзенең ишле балалары белән бергә булганда аерата горур һәм мәһабәтле күренгән кебек, иҗатчы да үз «балалары» — әсәрләре исән-имин бер ышанычлы төштә тупланган очракта көчлерәк. Һәрхәлдә, Бакый аганың замандашлары булган Пикассо, Сарьян, Дали, Эрьзялар мисалы шул хакта сөйли. Әлеге бөек художниклар нәселеннән булган Бакый ага Урманченың да меңләгән әсәрләрен сыйдырырлык, аңа һәрвакыт халык килеп йөрерлек берәр бина табылыр әле Казанда. Әйтик, Кабан күле тирәсендә җыйнак кына берәр бина калкыр. Моның чынга ашуына бик тә ышанасы килә.

Һәр зур иҗатчы Мәңгелек белән әңгәмәләшергә омтыла. Халыкка хезмәт итү ул — Мәңгелеккә омтылу дигән сүз дә. Остага исемне дә Бакый — «мәңгелек» дип кушканнар. Бик белеп кушканнар. Һәм ул гомере буе шушы исемгә лаек булырга тырыша. Без, Бакый ага, Сезнең талантыгызга сокланучылар, гомер һәм иҗат бәйрәмегез белән котлап, инде ерак калмаган 100 еллыгын да бергә-бергә үткәрү уе белән яшибез, дөньяда яшәвегез, хезмәтләрегез өчен рәхмәт әйтеп, замандашыгыз булуыбыз белән горурланабыз.

*1987, февраль*

# САГЫНДЫРА ТОРГАН ШӘХЕС



*Мәскәүдә С.Сәйдәшевнең туусына 100 ел тулуга багышлап уздырылган тантаналы кичәнең чакыру билеты. 2001*

Халык үзенең Сәйдәшен сагына. Бердәнбер баласын җуйган анадай юксына, өзгәләнә... Композиторны ярату, сагыну хисе халык күңелендә һәрдаим булса да, бөек затның туган көннәрендә, бигрәк тә юбилей вакытларында, бу хис аеруча ташып чыга...

Һәр халык төсләр, авазлар, сүзләр белән тарихта үзенең рухи сурәтен ясый. Әнә шул сурәтнең төп сызык-билгеләрен бөек затлар төшерә. XX гасыр татар дөньясында: хикмәтле сүз-шигырь буенча — Тукай, рәсем-сын буенча — Урманче, музыка дисәк, әлбәттә — Сәйдәш.

Моннан 10 еллар элек композитор турында күләмлерәк бер әсәр язу нияте белән (яза башлагач, ул әсәр поэма булып чыкты. «Сәйдәш» дип исемләнгән бу әсәр 1980 елны иң әүвәл «Казан утлары»нда, соңрак китапларда берничә мәртәбә басылды, сувенир басма булып та нәшер ителде) мин Сәйдәшнең тормыш һәм иҗат юлын шактый ук өйрәнгән идем. Әгәр: «Каян шулай бәреп чыккан да шундый талант, ничек халык йөрәгенә үтә алган?» — дип сорасалар, өлешчә болай җавап биреп булыр иде. Табигать талантын, табигать җәүһәрен Заман күтәргән 1905 еллардагы иҗтимагый шартлар алга этәргән. Сәйдәш — Тукайлар, Ф.Әмирханнар, А.Кариевлар, З.Яруллиннар мохитен тоеп үскән кеше. Ул вакытта әле Казанның Болактан башлап Яңа бистәгә таба ягы гел татар рухлы як булган. Урамнарда, базарда, мәдрәсәләрдә, ишегалларында, Бакал-

тай тугайларында туган телебез яңгырап торган. Чиста сулы Кабан өсләрендәге көймә-каекларда кичләрен татар гармуны, татар җыры тынмаган... Сәйдәш исә, шул милли рухны сеңдереп, тылсымлы талант иясе буларак, онытылмаслык көйләр иҗат иткән.

Әйе, гасыр башында татарда Сәйдәш дөньяга килде. Тагын бер дистә елдан Сәйдәш туган, яшәгән, иҗат иткән XX гасыр да тәмамланыр. Теге якка — XXI гасырга Сәйдәшне кемнәр алып чыгар да, безнең замандашлар кебек кемнәр мөкиббән китеп аны тыңлар һәм зурлар икән? Бүгенге яшь композиторларның шәхес буларак үзләренә һәм иҗатларына карап, төрле-төрле уйлар да килә. Сәйдәш замандашлары — Җ.Фәйзи, З.Хәбибуллин, А.Ключарев, Н.Җиһанов, Р.Яхин, Х.Вәлиуллин, алардан соңрак килгән А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов, Б.Мулюков, Р.Еникеев, М.Яруллиннарның иҗат хәзинәсендәге кебек татар халкының рух төпкеленнән килгән моң-мелос бармы, җитәрлекме аларда? Алар Сәйдәш иҗатын классик өлге итеп саныйлармы-юкмы, әмма барыбер аның халыкчанлыгын, моңын-дәртен, оптимистик рухын бәһаләргә, аның иҗатыннан киләчәккә этәргеч алырга тиешләр дип беләм.

Миңа калса, Сәйдәш иҗаты этап рәвешендә ике мәртәбә бәхетле тантана кичерә. Беренчесе, үзе исән чагында — 20 нче еллардан башлап 37 нче елларга кадәр чоры (ул бу чорда үзенең иң көчле әсәрләрен иҗат иткән), икенчесе — безнең хәзерге көннәр. Гасыр башындагы революцион кузгалыш аның талантына шифалы йогынты ясап, иҗатын үрләтеп җибәргән булса, бүгенге демократик вазгыять, яңартып кору-үзгәрешләр чоры аның мирасын яңача бәяләп, үзгә бер биеклеккә күтәрә.

Күтәрсен! Сәйдәш аңа бик-бик тә лаек. Чөнки ул бөек талант иясе. Заманында төрле катаклизмнар, репрессияләр чорында, күпмедер дәрәҗәдә рухи сындырылган зат та. Хәер, ул тупас көч белән артык көрәшеп азапланмаган да бугай...

...Йомшаклык белән генә булмый.
Көчле һәм нык булыгыз, талантлар!
Тарихыбыз шундый, заманасы...
Иманыңны бүтән кем саклар?

...Ялгышларны — була, мәнсезлекне... —
Тууларны булмый кабатлап!
Җырчыларны булмый кабатлап!
Даһиларны булмый кабатлап!

Сәйдәш язмышы —
гыйбрәт тә,
горурлык та,
алыр сабак та!

Нечкә җаннар —
талантлар белән
«Сак булыгыз!» дигән набат та!

Әйе, халык ярата Сәйдәшне, җан атыр дәрәҗәдә ярата. Күңелендә ул инде күптән аңа һәйкәл салган. Хәзер аның туган-үскән шәһәре Казанда мәгърур чын һәйкәл салырга кереште халык. Гомумән, халык кузгалды, милли хисе уянды, рухы турая башлады. Татар дөньясында да гасыр башындагы охшаш революцион үзгәрешләр бара. Димәк, яңа Сәйдәшләр кирәк!

*1990, ноябрь*

## БЕР РӘСЕМГӘ КАРАП...

*(«Сәйдәш»не язу истәлеге)*

Иҗат эшен алдан планлаштырып кую кыен. План-уй корып була, әлбәттә. Әмма... Илһам белән көтелмәгән теләк, яңа җигелгән кырыкмыш аттай, тәгаенләгән юлыңнан көтмәгәндә бөтәнләйгә борып, әллә кайларга алып китә кайчак. «Сәйдәш» поэмасын язганда да шундыйрак хәл булды.

Җитмешенче еллар ахырында С.Сәйдәшевтән бигрәк Н.Җиһанов турында язарга ниятләп йөри идем. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән (Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшрияты чыгарган ЖЗЛ китаплары шикеллерәк) булырга тиеш иде ул әсәр. Байтак материал тупланды, әсәрнең башы языла да башлады... Һәм тукталынып та калынды. Сәбәпләре күп. Бер җае чыгып бәян ителер әле...

Җитмешенче еллар ахыры. Сәйдәшнең тууына 80 ел тулу датасы якынлаша. Күңелдә композитор турында берәр нәрсә язасы килә, шушы юбилей бәйрәменә өлеш кертәсем килә. Ул вакытта Казанда музыкаль тормыш хәзергедән үзгәрәк иде. Чын мәгънәсендә милли дип әйтерлек зур композиторлар байтак иде әле. Язучы халкы да алар белән күбрәк аралаша иде шикелле. Уртак иҗади пленумнар, әдәби-музыкаль жанрлар турында сөйләшү-дискуссияләр, һөнәри семинарлар, төрле район-шәһәрләргә бергә-бергә сәяхәт итүләр... Теләк уянгач, димәк, язарга кирәк! Тыйган кеше юк бит. Тотындым өйрәнергә Сәйдәшне. Төрле чыганакларны укып чыктым. Аны күреп белгән кешеләр белән очрашып, аларны сөйләштереп, байтак мәгълүмат тупладым. Шул чор рухын чамаларлык иҗади даирә, композиторның үз шәхесен күз алдына килерлек дәрәҗәдә идем инде. Шунысын да уйлыйм: бу әзерлек Нәҗип Җиһанов турында язылачак әсәр өчен дә бик кирәк буласы бит әле!

Аллага тапшырып, Сәйдәш турындагы язмамны 1978 елның кышында башлап җибәрдем. Утырып түгел, күбрәк йөреп яздым. Рейс автобусларында, чаңгы шуганда, урманда

йөргәндә, җәен су буенда, комлыкта дигәндәй. Казна эшендә эшләмим, профессиональлыкта чагым. Кесәдә кәгазь-каләм. Уй-фикерләр килүгә, язып-теркәп куям. Тора-бара юллар, куплетлар ишәйде, шигъри тезмәләр, фикер сөрешенә карап, аерым бүлекләргә урнаша башлады. Язмам әкренләп эпик поэма рәвешен алды. Хезмәтне 1980 елның апрелендә Пицунда дигән иҗат йортында (Абхазиядә, Кара диңгез буендагы иҗат йорты) тәмамлап та кайттым. Шулай итеп, ике еллап күңелдә йөргән булып чыкты бу әсәр. Ул вакыт эчендә гел поэма өстендә генә басылып ятмадым, билгеле, бүтән шигырьләр, мәкаләләр дә байтак язылды.

Язуын яздым да, кешеләр фикерен беләсе килә бит! Сүз дә юк, күңел дигәне яхшы сүз әйтүләрен, хуплауларын көтә. Ашкынып кайттым Казанга. Каләмдәш дуслар белән киңәшләшкәч, халык алдында — язучы-шагыйрьләр, музыкант-башкаручылар, галим-голәмә алдында поэманы укырга, укучы-тыңлаучылар фикерен ишетергә дигән фикергә килдек. Искечәрәк әйтсәк — секция, хәзергечәрәк әйтсәк — остаханәнең киңәйтелгән утырышында яңа әсәрне укып, фикер алышу була инде. Язучыларның Тукай исемендәге клубның ул вакыттагы директоры, шагыйрь Әхмәт Рәшит кешеләр чакырырга булды, рәссам Эрот Зарипов, Сәйдәш рәсеме төшереп, берничә матур белдерү язып бирде. Мин дә поэманы машинкадан берничә данә бастырып алдым.

1980 елның 14 мае. Бауман, 19. Матбугат йорты. 5 нче каттагы Язучылар клубы. Көндезге сәгать өч. Зал шыгрым тулы! Ишек төбендә хәтта басып торучылар да байтак. Әле кемнәр җыелган диген! Язучы-әдипләрдән — Н.Исәнбәт, Ә.Еники, С.Хәким, Ф.Хөсни, Ә.Исхак, А.Расих, Н.Дәүли, Г.Минский; композиторлардан — Н.Җиһанов, З.Хәбибуллин, Ә.Бакиров, Х.Вәлиуллин, С.Садыйкова, Ф.Әхмәтов; бүтән төр иҗат кешеләреннән — Б.Урманче, Г.Шамуков, Ш.Сарымсаков, Г.Кайбицкая... Җыенысы 250ләп кеше! Бер әсәр язылу уңаеннан татар асыл затларының шулай бер мәҗлескә җыелуын кырык ел әдәбият мохитендә яшәү дәверендә бүтән күрмәдем мин. Мөгаен, янә күреп тә булмас. Замана бүтән, буыннар бүтән, рухи кыйммәтләрне бәяләү бүтән... Хәзер дә яңа әсәр, әйтик, яңа поэмалар укып-тикшерүләр булып тора. Җыелса, ун-унбиш кеше җыела, алары да әдәбият солтаннары булмый шул...




*«Сәйдәш» поэмасы укылган көн истәлеге 14 май, 1980*

Үткән бөеклеккә кайтып булмый,
сагынып кына була!

Архивымда шул көнне алынган фоторәсем сакланган. Җыелыш бетеп, залдан китеп өлгермәгән зыялылардан бер төркем. Зур булмаган төркемдәге затлар да әлеге мәҗлеснең югары кимәлдә үткәнен раслый дип уйлыйм. Укучыларыбызны фотодагы шәхесләр белән тәгаенрәк таныштырып узыйк. Сулдан уңга: беренче рәттә — шагыйрь Мөхәммәт Садри (1913–1999), профессор Үзбәк Әхмәров (1913), мин — Равил Фәйзуллин (1943), композитор Сара Садыйкова (1906–1986), әдип Нәкый Исәнбәт (1899–1992), җырчы Галия Кайбицкая (1905–1993), шагыйрь Сибгат Хәким (1911–1986), шагыйрә Роза Хәлиуллина (1931), шагыйрә Фирдәвес Әһлия (1954); икенче рәттә — педагог Дилбәр Саинова-Әхмәрова (1925), шагыйрь Галимҗан Латыйп (1912–1986), музыкант Исмәгыйль Илялов (1898–1992), шагыйрь Кави Латыйп (1927), шагыйрь Роберт Миңнуллин (1948), әдип

Әмирхан Еники (1909–2000), язучы Ринат Мөхәммәдиев (1948), шагыйрь Разил Вәлиев (1947), шагыйрь Әхмәт Рәшит (1936); өченче рәттә – композитор Әхмәт Хәйретдинов (1925), композитор Шамил Шәрифуллин (1949), шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов (1935), журналист М.Хәбибуллин (1940), галим Әбрар Кәримуллин (1925), язучы Нурихан Фәттах (1928), язучы-тәрҗемәче Рәис Даутов (1928), табиб Илдус Фәйзуллин (1955), шагыйрь Рәдиф Гатауллин (1941), музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина (1916); дүртенче рәттә – музыкант-пианист Марат Сиражетдинов (1948), педагог Фатыйх Макаев (1943), галим Рафис Әхмәт (1941), язучы Мәхмүт Хәсәнов (1927– 1990), язучы Рабит Батулла (1938), язучы Атилла Расих (1915–1996). Рәсемдәге утыз дүрт кешенең унбере, өчтән бере диярлек гүр иясе инде...

Поэманы укып чыктым. Бер сәгатькә сузылды бу уку. Сәгать ярым чамасы фикер алышулар булды. Шул мәҗлеснең беркетмәсенә карап, янә олуг шәхесләрне искә төшерәм. Кемнәр чыгыш ясаган соң? Сибгат Хәким, Заһит Хәбибуллин, Үзбәк Әхмәров, Әмирхан Еники, Сара Садыйкова, Ширияздан Сарымсаков, Галия Кайбицкая, Фатих Хөсни, Бакый Урманче, Әнвәр Бакиров, Ринат Мөхәммәдиев...

Нигездә, фикерләр уңай иде. Әсәрне баету-тулыландыру ниятеннән кайбер эшлекле киңәш-тәкъдимнәр әйттеләр. Тәнкыйть сүзләре дә булмады түгел. Андый чакта, мәгълүм, мактауда арттырып җибәрүләр дә булгалый. Хәер, минем дә һәр әйткән сүзне вәхи итеп, тулысынча ышанып, оеп утыра торган чагым түгел иде инде. Кешеләр фикереннән бигрәк, үз әсәремә үземчә аек дип уйланган фикерем бар. «Сәйдәш» поэмасы бөек композитор мисалында талантлар язмышы турында уйлану-монолог ул. Поэманың исеме астында – җәяләр эчендә – икенче иярчен исем – «Силуэт» дигән сүз булу юкка түгел. Поэма һич кенә дә музыкантның тормыш һәм иҗат юлын тулы чагылдыруга дәгъва итми. Мин ничек булдыра алдым, шуны яздым. Якты теләк белән ихластан яздым... Бары шул гына. Төптәнрәк уйлап карасаң, Сәйдәшне чын мәгънәсендә объектив бәяләгән киң полотнолы зур әсәр юк әлегә. Барлап карыйк: моңарчы ниләр чыккан? М.Ла-

тыйфуллинның моннан утыз еллар элек балаларга атап язылган бәләкәй повесте, Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе», Р.Харисның соңгы елларда чыккан «Сәйдәш яры», төрле буын шагыйрьләрнең аерым шигырьләре... Болар һәммәсе дә композитор тормышының теге яки бу эпизодын гына чагылдырган әсәрләр. Сәйдәш турында язу кыен. Тарихи документлар аз, үз архивы юк дәрәҗәсендә. Без Сәйдәшне бөек дибез, әмма аны расларга да кирәк, дөньяга танытырга да кирәк бит. Халыкның мәгълүм бер буынының бүгенге зур мәхәббәте киләчәк өчен аз булырга да мөмкин.

«Сәйдәш» поэмасының язмышы бәхетле булып чыкты. 20 ел эчендә биш тапкыр басылды. Радио фондында поэма буенча эшләнгән язмасы бар. Ул эфирдан әледән-әле тапшырыла. Телевидение спектакль-фильм эшләде. Сирәк булса да, аны да күрсәтәләр. Булган кадәренә бик шөкермен.

*2000, август*

## ӘДИП-КОМПОЗИТОР

Ихтимал, бу язманы «Сагыш» дип тә исемләп булыр иде. «Сагыш» — материалның эчтәлегенә дә туры килер, үземнең эчке халәтемне дә белдерер иде, бәлки. Шулай да бүтән исемне кулайрак таптым: әдип-композитор. Җәүдәт ага, чыннан да, зур әдип кеше, зур композитор иде. Ә сагыш дигәндә, ул аны безгә калдырып китте... Зур югалтудан соң әрнүле сагыш кичерү табигый хәл. Дөрес, вакыт дигәннәре үз көе белән, әкренләп әрнүнең әчесен ала. Табигать үзе яңарып тора: бер югалтуны икенче бер табыш белән тутыра, бер талантны икенчесе белән алыштыра... Шулай да бу процесс без теләгәнчә генә, ком сәгатен әйләндереп куеп булган шикелле генә, механик рәвештә бармый икән! Әдәбият-сәнгать дөньясында еш кына бер талант биләп торган урын шактый озакка буш кала икән! Җәүдәт Фәйзи шәхесе белән дә шундыйрак хәл. Бүгенге татар музыкасында аның булмавы бик нык сизелә. Кайчак, туган телне, культура тарихын юньләп белмәгән берәр яшьрәк композитор белән әңгәмә корганда: «Их, Җәүдәт ага исән булса, бу текст яки көй турында сөйләшүләр бөтенләй бүтән булыр иде!» — дип куясың. Музыкаль фольклор турында гыйльми дәрәҗәле кайбер музыка белгечләренең корырак язмаларын укыганда да, Җәүдәт аганың нәфис тел белән халыкчан, анык итеп язылган тирән фикерле хезмәтләре искә төшми калмый. Эфирларда яки сәхнәләрдә яңа җырлар ишеткән чакларда да аларны ирексездән Җәүдәт аганыкылар белән чагыштырасың. Хәер, җырларны гына түгел, тулаем иҗатларны, хезмәтләрне чагыштырасың. Уйландыра...

Җәүдәт Фәйзи — мәдәниятебез тарихында зур мирас калдырган шәхес. Чын иҗатчының хакыйкый бәясен берниндн саннар белән төгәл белдереп булмаса да, аерым очракларда алар да мәгълүм бер мөһим күрсәткеч була ала. Җәүдәт Фәйзи — 1 опера («Тапшырылмаган хатлар»), 3 музыкаль комедия («Башмагым», «Акчарлаклар», «Алтын көз»), 300дән артык җыр авторы. Моңа тагын егермедән артык спектакльгә язган музыканы, төрле музыка кораллары өчен махсус эшкәртелгән күпсанлы халык көйләрен, музыка сәнгатенең актуаль проблемаларына багышланган дистәләрчә мәкаләләрне өстәргә кирәк. Исәпләсәң байтакка җыела.

Һәр зур иҗатчының үзенә генә хас аеручa бер көчле ягы була. Җәүдәт Фәйзи мисалында ул — җыр. Ул җырның тылсымчысы һәм хакиме иде. Бу җәһәттән бездә аның белән тиңләшерлек бүтән композиторны атавы кыен. Аның күп



*Тукай премиясе лауреатлары һәм Татарстан хөкүмәте әгъзалары. Сулдан утырганнар: З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи, Ш.Әсфәндиярова, Х.Туфан, А.Ключарев; басып торучылар: Б.Гыйззәтуллин, А.Арсланов, М.Хәсәнов, Э.Гельмс, М.Сәлимҗанов, Н.Кузнецов, Ш.Биктимеров (1971)*

кенә җырлары инде менә берничә буын өчен яшьлек сердәше һәм гомер юлдашы булып, тормышның кадерен белергә, яшәүне олылауга өндәп килә. Әйтик, Җәүдәт Фәйзинең беренче җырларыннан 30 нчы еллар башында язылган мәшһүр «Урман кызы»н гына искә төшерик. Ничә йөз мең, юк, ничә миллион кешеләрне, нindidер бер сихри моңга төреп, Сафлык Илендә коендырмады икән ул җыр! Ә «Комсомолка Гөлсара», «Шауласын, гөрләсен безнең җыр» (Ә.Ерикәй сүзләре) көйләре?! Ә «Казан арты», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (С.Хәким сүзләре), «Тыңларсыңмы минем җырымны?» (Г.Зәйнашева сүзләре), «Сагыш» (Р.Фәйзуллин сүзләре) исемле җырлар кемнәрнең генә күңелләрен айкамады икән!

Сәнгатьтәге матурлык кануннарына зыян китермичә, халык үз итәрлек җырлар иҗат итү ул — халык күңелен тоеп, аның тормышы белән яшәп, аның белән бергә атлап гомер итү дигән сүз. Халык тарихын белми һәм аның рухи эволюциясен тоймый торып, аның җанына керермен димә! Икенче төрле әйткәндә, әдәбият-сәнгать кешесе — ул язучымы, рәссаммы, композитормы — халык иҗатының иң яхшы үрнәкләрен шулкадәр яхшы белергә тиеш ки, аның үз иҗаты да әнә шул халык тудырган иң яхшы җәүһәрләр белән бергә кушылып китә алырлык дәрәҗәдә булырга тиеш. Җәүдәт Фәйзи —

әнә шул биеклеккә ирешкән композитор. Үзенең таланты һәм тырышлыгы белән бу биеклеккә ирешкәч, ул үз алдына максатларның тагын да зурракларын куя. Безнең халыкның тамаша-театрга хирыслыгы мәгълүм нәрсә. Миңа калса, Җәүдәт ага, үз вакытында моны бик яхшы тоеп, халыкның киңрәк катлауларын музыкага, аның катлаулырак төрләренә тарту нияте белән көйне, җырны драматургия белән бәйләп иҗат итә башлый. Аның татар композиторлары арасыннан беренче буларак музыкаль комедияләргә мөрәҗәгать итүен, мөгаен, шулай аңларга кирәктер дә. Атаклы «Башмагым» музыкаль комедиясе үз вакытында мәдәният хәрәкәтендә зур вакыйгага әверелде. Тамашачы музыкаль гәүдәләнештә үз рухи портретын күрде, үзенең кимчелекле якларын танып, үз-үзеннән көлде, оялды; олы күркәм сыйфатларын тоеп үзе белән горурланды. Бу комедиянең бер Казан театры сәхнәсендә генә дә алты йөз тапкырдан артык куелуы үзе генә дә күп нәрсә сөйли. Бу әсәр рус, украин, үзбәк, башкорт, бурят һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп, илебезнең байтак театрларында уйналды. Гомумән, Г.Хаҗибәковның «Аршин мал алан»ы кебек, «Башмагым» — Җәүдәт Фәйзине зур композитор итеп таныткан әсәр, музыка дөньясында якты бер сәхифә булып тарихта калган әсәр.

Җәүдәт Фәйзи. Рәсми документча әйткәндә, Җәүдәт Харис улы Фәйзуллин. Миннән кайчакта, ихлас белергә теләпме, әллә болай гынамы: «Сез бер нәселдән түгелме?» — дип сорыйлар. Юк, бер нәселдән түгел. Җәүдәт агалар нәселе — бүтән нәсел, мәдәният тарихында тамырлы эз калдырган токым. Әтисе — Харис Фәйзи — заманында үзебездә һәм чит илдә төпле белем алган кеше, мәгърифәтче, педагог һәм берничә китап авторы буларак билгеле шәхес. Атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи дә Җәүдәт агага кардәш тиешле кеше. Әле моннан биш-алты ел элек кенә дөньядан киткән танылган тәрҗемәче Сәгыйть ага Фәйзуллин да шушы нәсел агачы кешесе. Ә Җәүдәт аганың бертуган энесе Мидхәт ага — исеме илебездән тышта да яхшы мәгълүм булган күренекле галим, профессор-рентгенолог. Күрәсез, белемгә һәм хезмәткә ихтирамлы мохиттә тәрбия алган Җәүдәт ага. Әтисенең дә, агасы Мирхәйдәр Фәйзинең дә яшь Җәүдәт Фәйзуллинның зур Җәүдәт Фәйзи булып китүендә, әлбәттә, уңай йогынтылары аз булмагандыр. Хәер, Җәүдәт ага үзе дә дөньяда теләсә нинди эшне булдыра алырлык шәхес булып туган булса кирәк. Күпләр бит аны укуы буенча юрист булуын, үз вакытында Казан университетының юридик факультетын тәмамлавын, соңрак юридик фәннәр институтының аспиранты,

гыйльми секретаре булып эшләгән чорларын, мөгаен, белмиләрдер дә. Өстәвенә Җәүдәт Фәйзи язучы да бит әле. Әдип-композитор дип әйтүнең төп хикмәте дә шунда. Ул берничә драма әсәре («Алты бармак» исемле комедиясе 1929 елда басылып та чыга) язган кеше, шулай ук байтак санда шигырьләр, нәсерләр, поэмалар иҗат иткән автор. Өлкән буын кешеләре, бәлкем, аның 1930 елда чыккан хикәяләр җыентыгын да хәтерлиләрдер әле. Җәүдәт Фәйзи өчен музыка һәм әдәбият аерылгысыз иде, ул аларның икесенә дә хәленчә фидакарьләрчә хезмәт итте. Соңрак ул үзенең әдәби сәләтен халыкның музыкаль иҗатын, гомумән, музыканы пропагандалауга файдаланды. Тышында Җәүдәт Фәйзи исеме куелган китаплар бер-бер артлы чыга торды. «Музыка кичәләре» (Казан), «Кунаклар» (Мәскәү), «Халык җәүһәрләре» (Казан)... Соңгысы, «Халык җәүһәрләре» дигәне — уникаль хезмәт. Бу китапта халкыбыз җырларыннан 235 исемдәгесе теркәлгән. Автор теркәп кенә калмый, аларны билгеле бер тәртипкә китереп классификацияли, килеп чыгу тарихларын аңлата, кайберләренең конкрет авторларын күрсәтә, ноталарын бирә. Әгәр Җәүдәт аганың бүтән бер генә дә хезмәте булмаса да, ул үзенең бу китабы белән музыка фольклорчысы буларак тарихка кереп кала алыр иде.

Җәүдәт Фәйзи — балалар өчен дә матур-матур әсәрләр иҗат иткән композитор. Алар — йә турыдан-туры үзе язган җырлар, йә халык көйләрен балалар өчен махсус эшкәрткән көйләр. Аның нәниләргә атап фортепьяно өчен язылган дистәләгән бәләкәй пьесалары музыка мәктәпләрендә өйрәнелә, балалар бакчаларында яңгырый, сәхнәләрдә башкарыла. «Курай», «Кыйгак-кыйгак, бак, бак, бак», «Балалар җыры», «Бабай» пьесалары әнә шундыйлардан.

Җәүдәт Фәйзи — чын мәгънәсендәге күпкырлы шәхес. Тукай үзенең иҗтимагый кредосын «мин коеп куйган шагыйрь генә түгел...» дип белдергән булса, бу тезис бик күп иҗат кешеләренең эшчәнлегенә дә карый. Шул җәһәттән Җәүдәт ага Фәйзи — зур җәмәгать эшлеклесе дә иде. Ул озак еллар буе Татар дәүләт филармониясенең директоры һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли, Татарстан Композиторлар союзы идарәсенең рәис урынбасары була, республика һәм ил масштабындагы байтак комиссияләрнең, худсоветларның, редколлегияләрнең әгъзасы сыйфатында бик күп җәмәгать эшләре башкара. Дистәләгән үзешчән композиторлар, соңрак профессионал булып киткәннәре дә үз вакытында Җәүдәт аганың ярдәмен хәзер дә ихтирам белән искә алалар.

Кызганычка каршы, минем үземә Җәүдәт ага белән аз аралашырга туры килде. Бер җырда әйтелгәнчә: «ул ашыкты, мин соңгардым»; иҗади хезмәттәшлегебез башланганда гына, ул безнең арабыздан китеп барды. Шулай да ул елларның истәлеге булып ике җыр калды. Берсе «Сагыш» исемле, икенчесе — «Бу дөньяда». Бу җырлар аның соңгы җырлары булды... Еш кына радиодан «Сагыш» дигән җырны тапшыралар. Күңел өзгәләнә, билгеле. Ул, асылда, лирик җыр, мәхәббәт җыры булса да, минем өчен зур Кешене, композиторның үзен сагыну җыры булып яңгырый. Ни өчендер төгәл аңлата да алмыйм, шул җырның көе белән рәттән үк Җәүдәт аганың икенче бер җыры колакта яңгырап-яңгырап ала. Ул — «Ташкыннар» спектакленнән Гайнавал җыры.

Телеграмм баганасы
Олы юлга маяк ул.
Сагынасыңмы дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул!

*1980*

# АК РОЯЛЬ ХУҖАСЫ

*(Бер уйлану)*



*Композитор Нәҗип Җиһанов. 60 нчы еллар*

Җиһанның Нәҗип ага Җиһансыз яшәвенә дә инде ике ел ярым вакыт узды. Исән булса, олуг шәхесләребезнең берсе буларак, аның 80 еллык юбилее зуррак һәм тантаналырак рәвештә узар иде. Дөрес, бу дата җәмәгатьчелек тарафыннан болай да киң билгеләнеп үтелә. Шулай тиеш. Әле узган декабрь аенда гына Салих Сәйдәшевнең 90 еллыгы гөрләп узды. Бер кыш эчендә ике мәшһүр, — хәтта бөек дип әйтүдән дә курыкмаскадыр, — композиторыбызның юбилей даталары. Төптәнрәк уйлап карасаң, гыйбрәтле һәм сөенечле хәл бит бу! Йә, кайсы халыкның, бигрәк тә төркиләрнең, шулай янәшәләтеп дигәндәй, зурлап яд итәрлек, бәйрәм итәрлек олуг композиторлары бар икән? Ихтимал, шул чордан болар рәтенә әзәрләрнең (азәрбайҗаннарның) Гөзәер Хаҗибәковны («Аршин мал алан» операсы авторы) гына куеп буладыр...

Һәрбер юбилей иясе нинди өлкәдә хезмәт итсә, беренче чиратта, табигый, аның иҗат бәйрәме шул өлкәнең, шул даирәнең бәйрәме булып уза. Әгәр хезмәте, иҗаты үзеннән соң килгән буыннарны да дулкынландыра, рухландыра икән — ул юбилей инде гомумхалык бәйрәменә әверелә. Бу очракта да шулай булды. Сәйдәшев һәм Җиһанов юбилейлары уңае белән без яңадан 50–60 нчы елда узылган музыка дөньябызга экскурс ясадык. Байтак мәкалә-истәлекләр укыдык, көйләре, җырлары белән бергә замандашларының хатирәләрен тыңладык, яңа мәгълүматларга ия булдык. Горурландык, кайчакта офтандык та... Үткәннәрне үзебезчә анализлап, киләчәккә барыр юлларны дөресрәк билгеләргә тырыштык. Мәрхүмнәргә дан да, мал да кирәкми. (Нәҗип Җиһанов-

ның үлү хәбәрен мин 1988 елның 4 июнендә Башкортстанның Мәләвез каласында ишеттем. Безгә, әдәбият-сәнгать көннәрендә катнашучыларга, бу кайгылы хәбәрне Татарстан партия өлкә комитеты секретаре Наил Кадермәтов җиткергән иде. Ул да инде (әле яшь иде) ике ел элек гүр иясе булды. Кабере — Нәҗип аганыкыннан 5–6 адым ераклыкта гына.) Аларның дөньялыкта калдырган гамәлләре исәннәр хөкемендә.

Юбилейларга әзерлек чоры кампаниясендә — матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында, аерым җыелышларда — татар музыкасы өчен горурлык уяткан тойгылар белән бергә, беркадәр ризасызлык кузгатырлык сәбәпләр дә булмады түгел. Шуларның берсе — иң рәнҗеткәне: кайберәүләрнең бу ике бөек композиторны бер-берсенә каршы куярга теләве, берсен күтәребрәк, икенчесен төшеребрәк күрсәтергә тырышуы. (Татар әдәбияты тарихында булып узды андый хәлләр! Тукайны Дәрдемәндкә, Ибраһимовны Исхакыйга, Такташны Кутуйга... каршы куеп сөйләшүләр. Вакытлар узгач, һәммәсенең үз урыны табыла, асыл бәясе биреләә барды.) Бу — акыллы караш түгел, милләт алга барсынга эшли торган юл түгел. Зирәк халык һәр зур талантның, һәр зур иҗатчының (алар сирәк туа!) уңай ягын әләм итеп күтәрә, аны көч санап, үзенең рухын көчәйтә, үзаңын арттыра... Әлбәттә, бер адәм дә, шул исәптән зур иҗатчы да, фәрештә була алмый. Берәү дә хатадан хали түгел.

Бер шагыйрь әйтмешли:

> Беләсең:
> Бик тигез салмадык эзне дә.
> Без дә бит бу Җирнең баласы,
> еллар сагыныр безне дә!

Мин шәхсән үзем Нәҗип ага белән шактыйдан ук таныш булып, соңгы ун-унбиш ел эчендә дустанә аралашып яшәдем дип әйтә алам. Үз вакытында аның тормышы һәм иҗаты турында бер әдәби хезмәт тә язарга исәбем бар иде. Ул үзе дә бу ниятемне белә иде. Шуңа күрә өендәме, эшендәме яки берәр бүтән җирдәме аның белән еш кына очрашырга туры килде. Ул үзе дә бу очрашып-күрешүләргә бик тә разый иде шикелле. Атна-ун көн күрешми торсак, «Нигә югалдың әле?» дип, өйгә дә шылтыраткалый иде. Күрәсең, миңа ышаныч күрсәтеп, эше, иҗаты, тормыш рәвеше турында күбрәк белүемне теләгәндер, мәрхүм. Шәхси архивының байтак өлешен бергәләп актарып чыгарга да вакыт тапкан идек. Ул мине иҗатын аңларга сәләтле дип уйлаганмы

(ә болай музыканы аңлавым чамалы), фикердәше дип таныганмы, тәгаен белмим, әмма аталарча якын итүен сизә идем. Күңел булсын диптер инде, шигырьләремне дә мактап куйгалый иде. Ихлас әйтүе дә бар: бу хакта шулай сөйләгәннәрен кешеләр аша да ишеткәләдем. Шулай «ахири» булсак та, без уртак бер генә көй дә, бер генә җыр да язмадык. Мин тәкъдим итмәдем, ул сорамады...


*Сынчы Б.Урманче, композитор Н.Җиһанов, артист Г.Шамуков. 1980*

**Нык ихтыярлы максатчан шәхес.** Күңелеңдә нинди зат булып калды дисәләр, тагын шул ук сүзләрне кабатлар идем: **нык ихтыярлы максатчан шәхес.** Әгәр шул сыйфатлары булмаса, ул тау кадәр хезмәт калдыра да алмас иде. Андыйлар турында кала интеллигенты — «титан!», ә авыл агае — «әш аты!» дип әйтер иде. Хезмәт җитештерүчәнлеге дигән производство терминын куллансак, бу яктан татар музыкасында бүтән андый кеше юк (әдәбиятта — Н.Исәнбәт, рәссамнар дөньясында — Б.Урманче белән тиңләп булса гына). Хезмәтләренең тау сырты кебек күренеп торганнарын гына санап узыйк: сигез опера, унҗиде симфония, өч балет (һәрберсенең партитураларын гына язып чыгар өчен айлар, еллар кирәк!), берничә симфоник поэма һәм кантата, дистәләгән вокаль-инструменталь әсәрләр, җырлар... Эстетик байлык күләм белән бәяләнмәсә дә, чагыштыру өчен әйтеп узыйк: мәшһүр Д.Шостаковичның опера һәм симфонияләр саны күпкә кимрәк.

Дөресен әйтим, кайчак язгы ташулар аккан кояшлы көннәрдә яки ямьле җәй сәгатьләрендә аны һаман саен ак рояле артында утыруын күреп, кызганып, җәлләп тә куя идем. Бу кадәр эшләп бер дә дөнья рәхәтен күрми, ахры, бу абзый! Бәлки ялгышамдыр. Ул, әлбәттә, эшеннән, нәтиҗәсеннән,

җиңүеннән, данышннан һәм хезмәте китергән тагын әллә нәрсәләрдән тәм һәм ләззәт алгандыр. Ә шулай да...

Шундый бер тәгъбир бар: җирдә теге яки бу миссияне башкару өчен, Ходай миң-тамга салган кешеләр була, имеш. Нәҗип агага күктән, белмим, ниләр иңдерелгән булгандыр, әмма татар музыкасының соңгы ярты гасырлык язмышында аның миссиясе гаять зур. Музыка дөньябызда этап булырлык төп тарихи вакыйгалар аның исеме, аның иҗаты белән берегеп калган. 1939 елда яңа оештырылган опера һәм балет театры Н.Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла, соңрак — Татарстан дәүләт филармониясе үзенең беренче эшен Җиһанов әсәре белән башлап җибәрә. 40 нчы елларда Татарстан Композиторлар берлеген оештыруда ул башлап йөрүче була, Берлек барлыкка килгәч, 30 елга якын аны җитәкли. Казанда консерватория ачылу көненнән башлап гомеренең соңына кадәр ул аның ректоры иде...

Ялгышмасам, татар композиторлары даирәсеннән профессор исемен йөрткән беренче кеше дә Җиһанов булды шикелле. СССР халык артисты. Өч тапкыр СССР Дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Татар әдәбияты һәм сәнгате дөньясында Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән беренче карлыгач... Беренче, башлап йөрүче, тәүге... Гел иң беренче... «Ах, беренче зөфаф кичәсе!» дигәндәй, һаман-һаман беренче булу, мөгаен, күңелне гел котырта, нәфселәндерә, ярсытадыр... Хәер, иҗат бәйгесендә кемнең койрыкта сөйрәләсе килсен икән. Әмма беренчелек ул — горизонталь яссылыктан бигрәк, вертикаль биеклек төшенчәсен дә үз эченә ала. Болытларга тиеп торган биек тауларның очына якынайган саен — җилләр көчлерәк һәм суыграк. Югары дәрәҗәгә ирешкән саен — җаваплылык хисе арифметик кына түгел, геометрик прогрессиядә арта гына. Андый кешенең ялгышы да, кояшлы көндә тау өстендәге кешенең күләгәсе ерак-еракларга төшкән шикелле, күпләргә кагылып үтә...

Әйе, Нәҗип Җиһанов — кабатланмас зур шәхес. Иш ише белән дигәндәй, Бакый ага Урманче да аны якын итеп: «Безнең Нәҗип! Безнең Җиһан!» — дип әйтергә ярата иде (сүз уңаеннан әйтеп узыйм: миңа калса, аның иң уңышлы портретын да Бакый ага иҗат итте). Йолдыз белән йолдыз, таулар белән таулар сөйләшә, диләр. Тауларның калкулыклар, түмгәкләр белән үз мөнәсәбәте булуы табигый. Һәр биеклекнең үз хакыйкате. Мондый табигый хәлне табигый рәвештә, шулай булырга тиеш дип кабул итәргә кирәктер.

Нәҗип аганы да музыка дөньясына әзме-күпме катнашы булган һәр кеше олуг, бөек дип кабул иттеме соң? Һич юк! Яшәве дәверендә аны яратмаган, аңа каршы кешеләр дә байтак булды, һәм алар хәзер дә җитәрлек. Аларның да үз дөреслекләрен расларлык дәлилләре бар. Чыбык озын булган саен, очы нечкәрәк була. Зур шәхес өчен кичерерлек объектив каршылыклар белән бергә, ихтимал, аның традицион кануннарга (ташламаларга) сыеп бетмәгән үзенең «авторски» хаталары да булгандыр. Шәхси һәм иҗтимагый тормышында аның да байтак драматик тетрәнүләре булган һәм булды. Җәмәгатьчелеккә билгеле булган ул фактлар үз эзен калдырган, әлбәттә. Миңа калса, Нәҗип ага үзенең иҗатында үзе тудырган киң масса «кара халык»ның ихтыяҗларына һәм зәвыкларына тиешле игътибар итеп җиткермичә, аларның реаль көчен тулы ук бәһали алмады бугай. Үзәк — Мәскәүнең югары музыкаль даирәләре белән бер дәрәҗәдә торып, җирле хакимият вәкилләре белән артык конфронтациягә кермичә фанатикларча эшләү — аның төп кредосы иде шикелле. Бар каршылыклары белән ул үз заманын, үз чорын чагылдырган бер зур шәхес.

Нәҗип Җиһановны өнәп бетермәүчеләрнең аргументлары тагын мондыйрак. Ул, янәсе, Салих Сәйдәшевне көндәш итеп, аны күләгәдә калдырган, яңа талантларны үстерүдә җитәрлек тырышмаган... Мөгаен, бу гаепләүнең икенчесендә өлешчә хаклык та бардыр. Татар республикасы үзәгендәге консерваториядә моңа кадәр татар музыкасы кафедрасы да булмау (андый кафедра үткән ел ачылды) үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Консерваториянең педагоглар составында да татар халкы вәкилләренең аз булуын да аклап булмый. Күрәсең, беренчедән, укыту программалары РСФСРдан моңарчы автономия булып килгән Татарстанга рус өлкә шәһәрләрендәге консерваторияләрендәгечә, диктат рәвешендә өстән тагылган, икенчедән, ректорның да милли музыканы үстерү проблемаларына игътибары җитеп үк бетмәгән, күрәсең. Ә менә Салих Сәйдәшевне кыерсыту мәсьәләсе, минемчә, уйдырма. Сәйдәш иҗаты белән таныш кешеләр беләбулыр: Салих аганың иҗади пигы 30 нчы елларда була. «Шәхес культы»ның канлы куллары К.Тинчурин кебек иҗатташларын, фикердәшләрен буып юк иткәч, Сәйдәш иҗаты да сүрелүгә таба бара. Үзеннән 10 яшькә кече Җиһанов бит әле ул чакта аренада юк иде... Татар музыкасы тарихындагы бөтен негатив якларны бер Җиһановка гына аудару дөрес булмас. Кемнең хыялына ирешүдә ихтыяр көче җитеп бетмәгән, кемнең гаиләсендә фаҗига булган, кемнең бүтән

бер кайгысы... Дөнья бу! Базар гайбәтен иҗтимагый фикер мөнбәренә күтәрмик!.. «Сәйдәш» поэмасын язганда, мин күп мәртәбә Нәҗип агага мөрәҗәгать иттем, киңәшләр сорадым. Ул һәрвакыт Сәйдәш турында ихтирамлы сүзләр әйтеп килде. Аның юбилей мәҗлесләрендә олы сүзләр сөйләде. Хәтердә, шагыйрьләр секциясенең «Сәйдәш» поэмасын укыптикшерү җыелышына да килеп утырган иде. Архив документларында Нәҗип аганың Салих Сәйдәшевне кыерсытканын дәлилләгән документлар таба алмассыз. Кыскасы, чәкештермәскә кирәк иде ике бөек затны!

Нәҗип ага ак рояль артына утырып иҗат итә иде. Менә инде ул рояльнең хуҗасы юкка өченче ел китте. Кемнәрдер уйлаганча, «Татар музыкасын басып торган «Җиһангир — Җиһан» юк инде. Тынычланыйк. Йә, музыкаль тормыш җанланыбрак киттеме? Татар музыкасы дөнья аренасына киңрәк чыгамы? Яшь композиторлар гөрләп үсә башладымы? Хәер, әле мондый сораулар куярга иртәрәктер, үзгәрешләр, әлбәттә, булыр. Ә хәзергә үзгәрешләр шул: элек опера һәм балет театры үз сезонын традиция буенча татар композиторы Н.Җиһанов операсы яки балеты белән башлап җибәрә иде, ә бу сезонны «Иоланта» белән... Симфоник оркестр да дистә еллар буена сезон ачылу концертында Н.Җиһановның яңа симфониясен яңгырата иде, бу юлы — яңа милли симфония әзерләнмәгән, бүтән — интернациональ программа...

Тукай шагыйрь булып җитешкән Җаекта (Уральск) туып, ятимнәр йортында үсеп, таланты һәм тырышлыгы белән Казан, Мәскәү калаларын таң калдырып, татар музыкасы вәкиле буларак, үз иҗатын Европага, Азия киңлекләренә яңгырата алган Нәҗип Гаяз улы Җиһанов ак рояльдә уйнап иҗат итә иде. Дөньяда ак рояльләр күптер ул. Әмма аларда бөтен дөнья тыңларлык әсәрләр иҗат итүчеләр генә сирәк.

Соңгы сүз итеп, бөек затка багышланган шигырем:

### АК ҖИЛКӘН

Биләүләрнең аклыгына кунгач,
ятимлекнең кара канаты —
саклап калды мине Әниемнең
күңеленнән иңгән нур-якты.

Чаган өсләреннән ак томанны
ак болытлар төшеп алырмы?
Кай як офыклары тартыр икән
ак хыяллы сабый җанымны?

Ап-ак күлмәгемнең изүендә
күз яшьләрем түгел, сәдәп лә...
Күпме булды ул чак өметемнең
ак канатын кисәр сәбәпләр!

Бу дөньяның ак көйләрен җыеп,
тибрәттем күңелем кылында.
Тыелгысыз дәрт-көч алып чыкты
ак чәчкәле илһам юлына!

Хак эш өчен җан аямас ирнең
шәүләсе дә, имеш, ак кына!
Тормышымда көйне корал иттем
җирдә аклык, сафлык хакына.

Сынмады Рух Замананың төрле
җил-давылы сынаган чакта.
Мин, капланып, Җиргә хезмәт иттем
һәм Җиһанны күрдем ак атта!

Ак тауларга мендем, биек җилләр
иркәләрме, егып китәрме?
Ак дулкынга кереп, каршы бардым,
сулышларым озакка җитәрме?

Һәм ышандым: иманың нык булса,
төз калырга дәрман җитә ул!
Ил йөзендә ак эшемне күргәч,
халкым мине үзе күтәрде.

...Гомер күкләрендә ак яшендәй
үтә еллар, үтә яшьнәр чак...
Күпме генә җанга кер кунса да,
бу дөнья барыбер ап-ак ак!

Ак чәчләрем җилдә җилфердиләр.
Ак җилкәндә инде хәзер мин.
Киләчәкнең ап-ак Хәтеренә
күчәр өчен җаным әзерлим.

*1980*

## ШИГЪРИ ҖАНЛЫ ГАЛИМ

Надиров. Җыр. Финляндия. Артык кыска һәм абстракт бу сүзләрне бераз шәрехли төшкәч, болайрак чыга: Илбарис Нурислам улы Надиров — фольклорчы, фронтовик; татар халык җырларын фәнни өйрәнеп, җыйнап, бастырып халыкка ирештергән галим; Финляндиядә яшәүче татарларны совет чорында янәдән Ана-йортка тартып, тарихи уртак мөнәсәбәтләрне урнаштыруга зур өлеш керткән шәхес.

Ышануы кыен булса да, аңа да 75 яшь тулган икән. Чыннан да, ышану кыен: әле ел ахырында гына редакциябезгә кергәч, уртак эшләр турында сөйләшкәндә, сүз уңаенда гына «минем дә юбилей сыман нәрсә якынлаша» дигәч, ихлас сорап куйган идем — әллә 70 кә якынлашасызмы? «Әзрәк күбрәк...» дип җавап бирде ул. Әйе, шактый гомер үтелгән. Бу яшьтә төп эшләр, нигездә, эшләнгән була инде. Энциклопедиядә И.Надиров турында ничек язылгандыр, карарга өлгермәдем, әмма мин белгәне шул: ул — рухи дөньябыз тарихында шанлы бер сәхифә булып калган татар халык иҗаты әсәрләренең 12 томлыгын дөньяга китерүне оештырган (җыр томнарын үзе төзегән) галим. Бу фундаменталь хезмәт иҗтимагый-рәсми яктан югары бәяләнде дә. 1989 елны И.Надиров җитәкләгән галимнәр төркеме Х.Мәхмүтов, Ф.Әхмәтова, Л.Җамалетдинов, Х.Ярми (үлгәннән соң) Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

Фольклор — үзе бер зур дөнья, әдәбиятның, сәнгатьнең нигезе. Илбарис ага гомерен халык иҗаты дигән әнә шул олуг мирасның бер тармагын — җыр жанрын өйрәнүгә багышлаган. «Миңа җан рәхәте биргән фәнни дөнья — ул халкыбызның җыр поэзиясе. Халык җыры — бөек шигърият әсәре ул. Анда иксез-чиксез хисси байлык, моң, хикмәтле, сурәтле фикерләр, тел бизәкләре тулып ята...» ди ул үзенең бер язмасында. Шунда ук өстәп тә куя: «Фольклор әсәрләренең төрлесен язып алсам да, миңа нигәдер җыр жанры якын булды. Җырның үзенә гашыйк итә торган ниндидер тылсымы бар, күрәсең». Тәкъдир кушуы буенча, гомер юлы дөрес сайланган булган. Ир җырны күтәргән, Җыр ирне күтәргән.

Ә Финляндиягә килгәндә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне «ачу», алар белән ныклап аралашу буенча бу ил — беренче ил булды шикелле. Төркия, Германия, Америка кебек илләргә юл соңрак ачылды... Моннан 40 еллар элек гади кеше өчен чит илләргә чыгып йөрү гайре табигый, сирәк хәл иде. Сәяхәтчеләр өчен, кем генә булмасын, сынау-таләпләр

бик көчле иде. Чит ил татарлары белән аралашасы да килә, тоталитар режим куйган тәртип-кысаларны да бозарга ярамый. Дипломатик акылга ия булсаң гына нәрсәдер майтарып була. И.Надиров бу яктан егет кеше булып чыкты. Казан татарларының гыйлем иярәренә, сәнгать осталарына Финляндиягә юл ярuda аның өлеше зур булды. Хельсинкидагы Тукай җәмгыяте җитәкчеләре (Г.Таһир һ.б.) дә Казанга килә башлады. 1968 елда безнең олуг затлар — Р.Яхин, И.Шакиров, А.Арсланов, В.Шәрипова һ.б.ларның Финляндиядәге гастрольләре, аларның Суоми иле президенты У.Кекконен белән очрашулары ул заман өчен олы вакыйга иде. Аннан соңгы елларда күпләр булды ул якларда. Финляндия татарларының байтак рухи хәзинәсе илебезгә кайтты. И.Надиров тырышлыгы аркасында, мәсәлән, Хәсән ага Хәмидулла иҗаты белән безнең укучыларыбыз ныклап таныша алды. Хельсинкида 1980 елда чыккан «Безнең җырлар» дигән җыелма китапка да без белмәгән байтак татар җырлары тупланган иде. Соңгы дистә елда И. Надировның бу юнәлештәге эшчәнлеге Финляндия белән генә чикләнмичә, дөньяның татарлар яши торган бүтән кыйтгаларына да күчте. Җөмләдән, Төркиядә яшәгән милләтпәрвәр шәхесләребез — Ә.Мәңгәр, С.Имре, М.Алукәй, Швециядәге — Төркәр Соуккан һ.б. турында ул кызыклы мәгълүматлар белән матбугатыбызда чыгыш ясады. Күрәсең, берара аның «Ватан» җәмгыятендә эшләп алуы да бу эшчәнлеккә этәргәндер.

И.Надиров без үзебез халкыбызның төп журналы дип санаган «Казан утлары» белән бик тыгыз бәйләнештә. Нәкъ 50 ел язышa ул безнең журналда. 40 тан артык хезмәте басылган. Ел саен диярлек безнең басмада катнашкан дигән сүз. Алга таба да активлык кимемәс дип ышанабыз. Чит илләрдә гомер кичереп бакый дөньяга күчкән һәм бүген исән-сау яшәп ятучы мәшһүр милләттәшләребез турында язмалар циклы язмакчы ул безнең журналга. Иншалла, теләкләр тормышка ашсын!

Һай, гомерләр! Илбарис ага белән танышып, аралашып яши башлаганга да 30 еллап гомер үткән. Еш күрешеп тордык дип әйтә алмыйм. Әмма һәр очрашу үзенчә истә, үзенчә кадерле. Шигырьгә, шигырь язучы затка үзенчә ихтирамлы ул. Шәхсән үзем моны һәрчак тоеп яшим. Хәер, ул үзе дә гомер буе шигырь язган кеше. Үсмер-егет чакта да, сугыш-фронтта булганда да, олпат ир-аксакал булганда да. Шигъри җан дигәндә, тагын бер күркәм зат — безнең уртак дустыбыз — Рим Кәримов искә төшә (ул озак еллар Татарстан



*Равил Фәйзуллин һәм Илбарис Надиров. 1993*

радиосында баш мөхәррир булып эшләде). Ул кайчакта, бигрәк тә күңеле нечкәргән чакларда, «Әйдә, Илбарис абый янына кереп чыгыйк әле!» ди торган иде. Галим өенә, көтелмәгәндә, өермәдәй килеп керәбез. Итагатьле каршылар, өстәленә затлы сыен куяр, яхшы якларыбызны мактар, хезмәтләребез хакында сорашыр... Гадәттә, андый очракларда, яңа чыккан китабыма автограф та язып бирәм, ул да шундук җавап итеп бирәр бүләк-истәлек бирер... Гомумән, канатланып, баеп чыга идек без Илбарис абыйлар өеннән! Ниндидер бер затлылык, иплелек бар аңарда. Нәселдән-каннан киләдер инде. Холык дигәннәренә тагын гомер буе халык иҗаты белән яшәү хикмәте дә өстәлгәндер. Халык сүзе, халык уе, халык моңы сеңгәндер аның җанына дип уйлыйсы килә.

Кайчак, бик сирәк, радиодан бер мишәр халык җыры яңгырап ала. (Аны композитор Ш.Шәрифуллин эшкәрткән, башкаручысы — консерватория хоры.)

Үлән арасында үләннәр күп,
Ат кузгалагыннан да биеге юк!..
Хәсрәт арасында хәсрәтләр күп,
Гыйшык хәсрәтеннән авыры юк...

Үзәк өзгеч җыр. Заманында бу җырны Илбарис ага белән Рим абый Пенза якларында ишетеп язып алганнар. Җырны тыңлыйм һәм күз алдыма китерәм. Моннан 40 еллар элек ике егет әллә кайдагы матур табигатьле татар авылында әллә нинди бөек хыяллар белән рух хәзинәсе җыеп йөриләр... Берсе инде менә байтак еллар гүрдә. Бабайлар сүзе белән әйткәндә, дустыбызның урыны оҗмахта, рухы шат булсын... Һай, гомерләр!..

Заманында Илбарис ага тарафыннан әзерләнеп, 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» дигән зәңгәр тышлы бер китап белән «яшәп» алган идем. Анда халкыбызның 450 гә якын җыры басылган. Галимнәр теле белән әйткәндә, үз көйләре булган «сюжетлы» җырлар. Аларның бик күбесе борынгы һәм әлегә билгесез булып калган җырлар. Чөнки алар бу гасырның илленче-алтмышынчы елларында гына язып алынганнар. Кызыксынып санап карадым, Татарстаннан тыш татарлар яшәгән унга якын өлкәдән җыелганнар икән алар. Менә кайда сурәтле сүз хәзинәсе! Нинди генә ритмик формалар, бормалар, кушымталар, нинди генә телбизәкләр, шигъри сурәтләр юк анда! Мин үз вакытында ул китапны кат-кат укып, өйрәнеп, үзем өчен шактый яңалык ачтым шикелле... Монда шунысын да әйтми калалмыйм, күрше өлкәләрдә җыелган ул җырларның байтагы Илбарис абый кулы белән язып алынган. Олы ихтирамга лаек бер эш бит бу!

Галимнең хөрмәткә лаек тагын бер эшчәнлеген телгә алып үтәсем килә. Халык җырларын җыю, өйрәнү белән бер үк вакытта, ул татар шагыйрьләренең халыклашкан җырларын өйрәнү буенча да мавыгып эшләгән кеше. Хәтерлим, моннан утыз еллар әүвәл язучыларның Тукай клубында шагыйрьләр һәм композиторлар язган җырлар турында зур сөйләшү булган иде. Анда төп докладны Илбарис абый ясады, фикер алышулар да кайнар гына булды. Соңыннан бу докладны нигезендә озын гына мәкалә язып, аны журналыбызда бастырды да. Янә шунысын да әйтү артык булмас, Илбарис абый татар халкының иң матур җырларын һәм шагыйрьләрнең халкыбыз арасында уңыш казанган әйбәт җырларын туплап берничә популяр җыентык та төзеп чыгарды. Шул елларда И.Надировны безнең Язучылар берлегенә әгъза булarak тәкъдим иткәннәре истә калган. Ул утырышта Сибгат ага Хәким дә Илбарис абый хезмәтләре хакында җылы сүзләр әйткән иде. Шунысы гаҗәп булды, Илбарис абый берлеккә керүдән нигәдер тыелып калды...

Сүзем ахырында шунысын да әйтеп узыйм. СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында кайчандыр мин дә аспирант идем. Фәнни эшем: «Хәзерге татар поэзиясендә халык иҗаты поэтикасы». Исеме бераз үзгәрергә дә мөмкин иде. Җитәкчем — Илбарис ага Надиров. Кандидатлык имтиханнарын әйбәт кенә биреп бетердем. Шактый күп фәнни китап укылды, татар поэзиясе тарихын яңа бер яктан өйрәнә башладым.

Рухымны баету күзлегеннән аспирантура елларының файдасы булмады дип әйтергә телем әйләнми. Әмма оештыру — иҗат эшенә, дөресрәге, Язучылар берлегенең җитәкчелек эшенә күчү сәбәпле, фәнни эшем бүленеп калды. Диссертация якламадым. Җитәкчемне беркадәр авыр хәлгә дә куйганмындыр, бәлки. Хәер, үткәнгә бик үк үкенмим. Хәзер, фән кандидатларыннан да бигрәк, «академиклар» күбәйде.

Академиклармы?
Бездә дә бар. Байтак алар:
хакыйкый да әгъза,
әгъза да хакыйкый...

Тик нишләптер юк арада
берәр Нәкый,
яки Бакый,
йә Исхакый...

И.Надиров 1959 елда кандидатлык диссертациясен яклаган. Ул һаман да «фәннәр кандидаты». Ә чын мәгънәсендә Фәннәр Кандидаты булу аз түгел бу дөньяда!

*2000, гыйнвар*

* * *

Журналыбызның бу санында («Казан утлары», 2005, 4 сан. — *Ред.*) без мәгълүм татар галиме — фольклорчы Илбарис Надировның Истанбулда эш алып баручы Әхмәтвәли Мәңгәр исемендәге төрек-татар мәдәни вакыфына багышланган мәкаләсен урнаштырабыз. Шунысы игътибарга лаек: ул вакыф оештырылуга быелгы яз айларында 10 ел тулды, ә түбәндәге мәкалә авторы Илбарис Нурислам улы Надиров апрель аенда 80 яшьлек бусаганы атлап керде. Шул рәвешле язмыш дигәнең бу түгәрәк даталарны бер-берсенә бәйләгән булып чыкты. Илбарис ага Надиров, искә алган вакыф корылган көннән башлап бүгенгә кадәр аның эшчәнлегендә якыннан катнашып, фәнни киңәшче сыйфа-

тында хәл кадәри хезмәт куйган могтәбәр галимнәребезнең берсе.

Мин аның фольклорчы буларак, төгәлрәк әйткәндә, халкыбызның җырларын җыючы, өйрәнүче белгеч буларак кылган эш-гамәлләре хакында «Шигъри җанлы галим» дигән бер мәкаләдә сөйләп тә узган идем. Ул юбилярның 75 еллыгына багышлап Тел, әдәбият һәм сәнгать институты чыгарган бер җыентыкта 2000 елда дөнья күргән иде.

Бүгенге язмамда исә, мин мөхтәрәм галимебезнең ерактагы татар диаспорасы белән бәйле эшчәнлегенә беркадәр киңрәк тукталып үтәргә телим.

Билгеле булганча, безнең «татар» дип йөртелгән туган кавемебез дөньяның төрле төбәкләренә таралып яши. Әйтик, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетында тупланган мәгълүматларга караганда, Австралия, Кытай, Канада, Польша, Румыния, АКШ, Алмания, Төркия, Финляндия, Швециядә һәм башка тагын берничә илдә 70 меңгә якын татар яши икән. Алар әлеге илләрнең кайберләрендә милли-мәдәни җәмгыятьләр оештырып, соңгы елларда Казан белән урнашкан рухи багланышларны сакларга тырышып гомер итәләр. Шул уңайдан Австралия, АКШ, Алмания, Төркия һәм Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең эшчәнлеген аерып күрсәтергә кирәктер. Чөнки нәкъ менә шул илләрдә милли-мәдәни җәмгыятьләр оешканрак төстә эш алып баралар дип ишетеп беләбез.

Илбарис ага Надиров иң әүвәл Төркия һәм Финляндиядәге татарлар белән күбрәк аралашып, алар турында күбрәк язган авторлардан. Күпләр хәтерли булыр: узган ел ахырында Казанда «Татарстан — Төркия: мәдәни багланышлар. 1992–2003» дигән күләмле бер җыентык дөнья күргән иде. 600 битле, фоторәсемнәр белән баетылган һәм латин имлясында басылган бу җыентык Илбарис Надиров тарафыннан төзелгән. Җыентыкның җаваплы мөхәррире дә ул. Мәгълүм булганча, китап Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының матди ярдәме белән нәшер ителгән. Хәбәрләргә караганда, аның тиражының бер өлеше Төркиягә җибәрелгән, шактые Татарстан Милли китапханәсенә, Бөтендөнья Татар конгрессына бирелгән һәм белгечләргә таратылган. Шунысын да әйтергә кирәк, бу басмага әйбәт бәя биргән берничә рецензия басылды да инде, ә Бөтендөнья Татар конгрессы аны тәкъдир итү утырышы үткәрде.

Әлеге китап белән танышканда, мине куандырган бер хәлне укучыларга хәбәр итәсем килә. Әйтик, җыентыкка соңгы елларда «Казан утлары» журналында басылган дистәгә

якын мәкалә сайлап алынган. Шулар рәтендә Төркия һәм анда яшәүче татарлар турында Тәүфикъ Әйди, Рабит Батулла, Әбрар Кәримуллин, Әлфинә Сибгатуллина тарафыннан язылган бай мәгълүматлы мәкаләләрне аерып күрсәтү гадел булыр. Боларга өстәп Илбарис аганың безнең журналда басылган «Төркиядәге ике милләттәшем» дигән кызыклы хатирәсен дә телгә алу кирәктер.

Гомумән, әлеге җыентыкны Татарстан белән Төркия арасындагы тарихи, мәдәни бәйләнешләрнең үткәнен, бүгенгесен шактый киң итеп яктыртучы һәм үзара багланышларга багышланган кыйммәтле бер чыганак дип санарга тулы нигез бар.

Илбарис Надировның Финляндиягә барган саен андагы милләттәшләр тормышыннан игътибарга лаек яңалыклар алып кайтуын беләбез. Соңгы утыз ел дәвамында Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең тарихы һәм бүгенге көнкүреше, Габдулла Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять һәм аның җитәкчесе профессор Гомәр Таһир хакында Казан матбугатында егермегә якын мәкалә һәм хәбәр-язма бастырды ул. Аларның күбесе «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Ул мәкаләләрнең кайберләре рус һәм инглиз телләрендә дә басылып чыкты. Шул нәүбәттән мин Илбарис аганы Татарстан белән Финляндия арасында рухи-мәдәни күпер салуга зур өлеш керткән хөрмәтле зыялыларыбызның берсе дип санар идем.

Татар диаспорасы тарихы турында әлегә монографик төстәге махсус тикшеренүләр булмаса да, алар һичшиксез язылыр дип өметләник. Чөнки бу өлкәдә эш алып баручы галимнәребез бар. Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты да әлеге проблема белән җитди кызыксына һәм бу хакта төпле хезмәтләр язуны күз алдында тота дип беләм.

Бу кыска гына кереш сүз-язмам ахырында мин фронтовик галимебез Илбарис ага Надировны олы юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм, аңа исәнлек-саулык һәм бәхетле гомерләр телим. Журналыбыз битләрендә яңа хезмәтләр белән укучыларыбызны сөендерергә язсын сиңа хөрмәтле авторыбыз!..

*2005, апрель*

# ХӘЗИНӘЛӘР ХУҖАСЫ

Заманыбыз турында үз эш-шөгыленә, үз аңлау-инануына карап, һәркем үзенчә фикер йөртә. Берәүләр — космос-кибернетика заманы, ди, берәүләр — иҗтимагый стресслар яки тәрҗемәләр заманы, ди, геноинженерия заманы, дип тә әйтәләр... Кем ничек кенә әйтмәсен, бер нәрсә ачык мәгълүм: заманыбыз мәгълүмат-информация заманы, халыкара аралашу заманы. Бу җәһәттән библиография фәнен өскә куеп сөйләү дөрес булыр. Тарихи хәзинәләрне барламый торып, киләчәккә ышаныч белән барып буламы? Гасырлар буена тупланган байлыкны, беренче чиратта, язма хәзинәне киң дөньяга чыгара алганда гына теге яки бу халыкны чын мәгънәсендә тәрәккыятле, цивилизацияле дип санап буладыр. Библиография — халык акылына, халык гыйлеменә, халык тарихына ышанычлы юл күрсәткеч ул. Галим Әбрар Кәримуллин — нәкъ менә үз мәйданында, библиография өлкәсендә, бүтән халыклар да күрерлек, танырлык итеп, халкыбыз тарихында рухи баганаларның бик тә олыларын утырткан кеше.

Сер түгел бит: язучы мин! — дип йөргән күбебез (без генә микән?), бар булган архивыбызны да йә ялкаулык, йә оешмаганлыктан тиешле тәртипкә китерә алмыйбыз. Үзебезне аклау өчен, әлбәттә, мең сәбәп табабыз. Янәсе, киләчәктә ул эшләрне кемнәрдер (мифик!) бүтәннәр башкарачак әле. Русча әйткәндә — «Увы!..» Ярый, монысы һәр кешенең үз эше диик. Ә менә гасырлар буена җыелып килгән, меңнәр тарафыннан иҗат ителгән уртак китап хәзинәсе белән нишләргә? Алар бит тау-тау. Ул китапларның ияләре, язгантудырган вакытта, без исәннәр үз әсәрләребез турында уйлаган кебек, алар да үз язганнары турында бөек фикердә булганнардыр... Ике гасыр ярым гомер-биографиясе булган татар китабы тарихында кемнәр генә язмаган да, нинди генә китап чыкмаган! Күбесе халык хәтереннән дә югалган бугай инде. Вакыт тузанын кагып, якты кояш астына чыгармасаң, әллә нинди асыл җәүһәрләрнең дә мәңгегә күмелеп калуы бар. Кемдер, үзендә хуҗа тойгысы сизеп, билгеле бер тәртипкә китерергә, бер төенгә төйнәргә тиеш бит ул байлыкны. Безнең Әбрар абыебыз, үзе теләп, әнә шул зур тарихи эшкә алынган асыл затыбыз.

Белмим, галимнең үз иҗаты буенча төзелгән үз библиографиясе нинди хәлдәдер, әмма аның матбугатта басылган йөзәрләгән хезмәтләре, ике дистәгә якын китаплары зыялы укучыларга яхшы таныш дип беләм. Әлегәчә басылмаган хезмәтләре дә байтак. Дөнья күргәннәреннән кайберләрен

санап үтик: «Татар әдәбияты: фольклор, әдәбият белеме һәм әдәбият тарихы», «Татар матур әдәбияты», «СССР һәм чит ил халыклары әдәбияты, фольклоры һәм сәнгате: татар теленә тәрҗемәләр», «Татарская литература в переводах на русский язык...», «Татар сәхнәсе» дигән зур библиографик хезмәт үзе генә ни тора! Ә аерым әдипләр — К.Насыйри, М.Җәлил, Х.Туфан; бүгенгеләрдән — Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, С. Хәким, Г.Ахуновлар иҗаты буенча аерым библиографик күрсәткечләр... Исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин. Библиография — түземлелек, бөртекчәнлек, сирәк кешеләргә генә хас ихтыяр көче сорый торган эш. Эскерткә өелгән саламнарны берәмтекләп бер тәртипкә тезеп кую белән бердер ул. Күпме эзләнергә, күпме кәгазь тузаны йотарга, күпме исәп-хисап алып барырга! Зур максат белән алынып, күп көч куйган гамәлнең әҗере-нәтиҗәсе дә олыдан шул: татар дөньясы тарихында Ә.Кәримуллинның иң өлкән, иң фидакарь библиограф-елъязмачы икәнлеге бәхәссез хакыйкать.

Ихтимал, библиография буенча кылган хезмәтләре генә дә галимнең исемен төрки әдәбиятлары тарихында җуелмас итәргә җитәдер. Әмма гаҗәп дәрәҗәдә эш сөючән бу шәхеснең фәннең бүтән өлкәләрендә башкарган эшләре дә сокланырлык. Ул да булса — матбагачылык тарихы. Бүтән өлкә дисәм дә, әлбәттә, библиография белән китап тарихы янәшә, бер-беренә үрелеп бара торган фәннәр. Әмма соңгысы тарихка күбрәк карый, бүтәнрәк үлчәүләр белән эш итүне сорый. Китап тарихы ул, асылда, халык тарихы. Язма әдәбиятны белмичә, бигрәк тә басма китапларны барламыйча, халык тарихына төшенү мөмкин түгел. Ә татар китабы тарихы исә, халык язмышына иш рәвештә, үтә четерекле, авыр, гыйбрәтле тарих. Әбрар Кәримуллинның рус телендә чыккан «У истоков татарской книги» (1971), «Татарская книга начала XX века» (1974), «Татарская книга пореформенной России» (1983), татар телендәге «Китап дөньясына сәяхәт» (1979) исемле китаплары әнә шул олы миссияне уңышлы башкарып чыгуына бик тә саллы дәлилләр. Алар халкыбызның иҗтимагый үзаңы үсүенә булышкан кадерле китаплар. Алар Ә.Кәримуллинны илкүләм мәгълүм китапчы галим итеп күтәрделәр. (Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: галимнең докторлык диссертациясе дә татар китабы тарихы турында. Ә андый китапчы галимнәр СССРда бармак белән генә санарлык.) Бу китаплар республикабыз һәм үзәк матбугаттан тыш чит илләрдә дә югары бәя алдылар.

Хәзер рәсми формада фәнни дәрәҗә йөрткән кешеләр бик күп. Казанның үзендә генә дә фән докторлары биш



*Әбрар Кәримуллин Америка галиме Ричард Фрайн белән. АКШ, 1988*

йөздән артык. Татар әдәбияты һәм филологиясе өлкәсендә генә дә берничә дистә фән докторы, йөзләгән фән кандидатлары исәпләнә. Һәр эштәге кебек, әлбәттә, арада төрлеләре бар. Берәүләр, моңарчы билгеле булган ачышларны билгеле бер системага салып, калыплап, тематик фокуска туплап, үзләренчә трансформацияләп, Фән дигән бөек храмга үрмәләп маташалар, икенче берәүләр исә, тормыш ихтыяҗыннан чыгып, әле моңарчы кул тимәгән өлкәләрне сөреп, яңа катламнар күтәрәләр, яңа буыннар өчен дә ачыш булырлык мәгълүматларны фәнни хәрәкәткә кертәләр. Әбрар Кәримуллин — әнә шул соңгыларыннан. Татар әдәбияты тарихын, бигрәк тә аның соңгы дәверләрен җентекләп өйрәнергә алынган кеше, һичшиксез, Ә.Кәримуллинның китап тарихына караган хезмәтләренә мөрәҗәгать итәчәк. Димәк, Әбрар абыйның кылган эшләре яңа фәнни хезмәтләр тудырачак. Фән кешесе өчен чын бәхетнең үзе бит бу! Халык тарихын, аның рухи үсеш баскычларын аңларга теләгәннәр өчен, алар үзгә бер мәктәп булырлык басмалар.

Библиограф һәм китап тарихчысы булудан тыш Ә.Кәримуллин шәхесе әле тагын байтак фәннәргә килеп тоташа. Этнография, археография, этимология, палеография, этнонимия... Йөзәрләгән, төрле характердагы, төрле күләмдәге хезмәтләр арасында нинди генә мәсьәләләргә караган мате-

риаллар юк дисез! Тегe яки бу халыкның гореф-гадәтләре турындамы, төрки телләр белән Көньяк Америка индеецларының тел уртаклыклары турындамы, нәкыш бизәкләре һәм тәрҗемә нечкәлекләре турындамы, графика яки борынгы сәяхәтчеләр турындамы... Кайберәүләре, әйткәнемчә, матбугатта чыккан, кайберләре әлегә кульязма хәлендә.

Әбрар Кәримуллин эшчәнлегенең тагын бер үзенчәлеген ассызыклап әйтеп китмәү дөрес булмас. Ул — халыклар дуслыгын ныгытуга бик зур өлеш керткән әдип. Казакъ, үзбәк, төрекмән һәм башка төрки телләрдә дөнья күргән беренче басмаларны барлауда тиңдәшсез галим ул.

Дөнья гамәлләренең төрле өлкәләрен колачлаган кешеләрне энциклопедист галим дип әйтәләр. Әбрар Кәримуллин — шундыйлардан. Адәм баласы төрле яктан никадәр генә талантлы булмасын, барыбер аның нечкәләп белгән бер эше була. В.Дальнең гомерлек эше — рус теле сүзлеге, К.Баронның — латыш җырлары, Н.Исәнбәтнең — татар фольклоры. Ә.Кәримуллинның исә, иң беренче чиратта — татар китабы тарихы. Ул шул ягы белән көчле дә, зур да, бердәнбер дә.

Безнең бәхетебезгә язган әнә шул олуг кеше кайларда туып-үсеп, нинди шартларда шундый зур галим булып җитешкән соң? Баксаң, Саба районының гади бер татар авылыннан чыгып күтәрелгән кеше икән ул безнең Әбрар абыебыз! Биографиясе гади, әмма шактый гыйбрәтле. Колхозчы, сугышчы, студент, китапханәче, фәнни хезмәткәр. Сугышчы дигәненә аерым басым ясап әйтми булмый. Яшьли сугышка китеп, Европа һәм Ерак Көнчыгышларны урап, яраланып, орден-медальләр тагып туган якларына кайткан кеше ул. Гади солдат булып сугышның иң хәтәр җирләрендә була. Курск дугасы, Днепр кичүләре, Гоби чүлләре, Хинган таулары... Фронтовикларда гына түгел, бик күп замандашларның коточкыч һәлакәтләр итеп искә төшерә торган атамалар алар... Шулай итеп, мең үлемнән могҗиза белән исән-сау калып, туган якларга әйләнеп кайткач кына укырга, фән белән шөгыльләнергә туры килә аңарга. Яшәүнең никадәр зур бәхет икәнен, тыныч хезмәтнең бөек куаныч икәнен бөтен күзәнәкләре белән аңлап кайткан шул ул. Үзе теләгән эшенә кадалып ябышкан ул. Шуңа күрә ил тарихында калырлык хезмәтләр тудыра алган да.

Башкарган эшләре тау кадәр булса да, гел генә дә даншөһрәткә коенып, мал-мөлкәткә тиенеп яшәде дип әйтмәс идем мин аны. Гомере буе диярлек китаплар, картотекалар, кәгазьләр белән тулган кечерәк кенә фатирда яшәде, бала-

лар үстерде, үземне күрсәтим дип, чәчрәп уртага чыкмады, милләт байрагы булып эшләде дә эшләде. Олы эшенә әдәплелек, тыйнаклык юлдаш булды. Үз гомерендә төрле имлялардагы бик күп басма китаплар күргән, аларга күпме күз нурын түккән кешегә, әйдәгез, без дә матбугат аша үзебезнең ихтирамыбызны белдерик, саулык һәм иҗат уңышлары телик. Моннан 15 еллар элек хөрмәтле галимебезгә атап язылган менә бу шигырь дә әлеге теләкләргә куәт булсын:

Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез аның.
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!
Чор-заманнарны үтәли
күралган зирәк ирләр,
сезнең үлчәү берәмлекләр —
гасырлар да дәверләр!
Кемнәре юк бу дөньяның!
Тиңсезе, ятимнәре...
Рухи мирас бакчасының
сез — хуҗа, хакимнәре!
Еллар аша ничек күренә
безнең эшләр, янулар?
Бәләкәйме? Әйтәсезме:
«Бичаралар, фанилар...»
Әйе, кылганнар аз, мыскал...
Шулай да бер сүз — бездән:
«Без фанидыр, фаниерак —
максатсызлар, йөзсезләр!»
Хаклыкка якын торучы,
әй, халык галимнәре!
Ил-йортның эшчән уллары,
милләтнең хадимнәре!
Дөнья бәһасе язу да,
мәкале, әйтеме дә,
мирасы — мәшһүр бинең дә,
бер дәрвиш хәкимнең дә —
язмыш сезнең хөкемдә!
Сезнең үлчәү берәмлекләр —
гасырлар да дәверләр!
Сезгәме соң тыңләшә ала
өч көн көчле Дәү ирләр!
Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез аның!
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!

*1985, май*

## ТЕЛ САГЫНДА ТОРА СОЛДАТ

Тел гыйлеме хезмәтләре кемнәргәдер мавыктыргыч һәм кызыклы тоелмаска да мөмкин. Кеше үзе сөйләшкән телне әйбәт белəм дип исәпли. Өстәвенә тел гыйлеме шактый катлаулы һәм четерекле фән. Һәр телнең үз фонетик закончалыклары, морфологик үзенчәлекләре, җөмлә төзелеше ысуллары, стиль күренешләре... Шуңа күрәдер яшьрәк чакта бу фән ялыктыргыч булып тоела. Аның никадәр кызык һәм әһәмиятле икәнен еллар үткәч төшенәсең икән! Төптәнрәк уйлап карасаң, тел — һәр халыкта өйрәтелә торган төп фәннәрнең берсе бит. Тел аша халыкның тарихын, фикерләү рәвешен, психологиясен, әхлагын, эстетик тоемын, икенче төрле әйткәндә, аның җанлы рухи портретын белергә була. Тикмәгә генә тел — милләтне билгеләүче төп компонентларның берсе, дип исәпләнми шул. Шундый четерекле фәннең лаек рәвештә үсүе өчен, әлбәттә, бу эшкә фидакарьләрчә бирелгән кешеләр — галимнәр булу кирәк. Бу язмамда төп сүз шундый шәхесләрнең берсе — профессор Вахит Хөҗҗәт улы Хаков турында. Ул хәзер тюркологиядә исеме киң танылган галимнәребезнең берсе.

Мәгълүм хакыйкать: һәрнәрсәнең, шул исәптән һәр игелекле зур эшнең яралгысы өчен төп нигез-сәбәп кирәк. Аннан соң әле шул яхшы яралгының үрләп китүе өчен этәргеч көч кирәк. Кечкенә Вахитның зур профессор булып җитешүенә башлангыч шартлар әйбәт булган: Зөя буйларының кабатланмас матурлыгы, хезмәт сөючән тату гаиләдә тәрбияләнү һәм укытучы әтисенең төпле киңәшләре, күңелнең сафлыгы, максат ачыклыгы...

Китапка-белемгә омтылыш Вахитта бик яшьли башлана. Моңа өйдәге бай китапханә дә зур этәргеч ясый. Анда XIX гасырда һәм XX гасыр башында гарәп әлифбасында чыккан, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Р.Фәхретдин, Ф.Әмирхан һ.б. әдип һәм галимнәрнең әсәрләре белән беррәттән, «Казан мөхбире», «Әл-ислах», «Кояш», «Карчыга», «Шура», «Яшен», «Уклар» кебек газета-журналлар да була. Борынгы классик татар әдәбияты үрнәкләрен — «Кыйссаи Йосыф», «Таһир вә Зөһрә», «Ләйлә вә Мәҗнүн»нәрне кышкы кичләрдә гаиләдә җыелып уку да зур тәрбияви роль уйнаган.

Вахит Хаков 1926 елда Татарстан республикасы Буа районы Күзби авылында туа. Үз авылында башлангыч белемне алгач, Килдураз урта мәктәбендә укый. Мәктәп елларында укыганда, язу-сызу, иҗат эше белән кызыксына, җырлар, бәетләр, мәзәкләр җыя, газета-журналларга хәбәрләр, әдәби парчалар яза. «Пионер каләме», «Яшь ленинчы» — аның иң

яраткан газета-журналларына әверелә. Балалар язучысы Абдулла Алиштан файдалы киңәшләр ала, кадерле хатирә буларак, аның хатлары бүген дә саклана. Язучы Абдулла Әхмәт тарафыннан төзелеп, 1942 елда басылып чыккан «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» дигән китапта аның да халыктан җыйган мәзәкләре кергән. Ул 8 сыйныфны гына бетереп кала, бөтен хыял һәм изге теләкләрне чәлпәрәмә китереп, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлана. Ихтимал, Вахит ага биографиясенең иң ялкынлы сәхифәсе — ул аның яшьли Ватан сугышында чыныгуыдыр. 17 яшь тулар-тулмас вакытта, ул шактый озакка сузылган гаскәри хезмәткә китә. Ике ел Монголиядә, аннары Кытайда була, аңа японнарга каршы сугышларда катнашырга туры килә. Ул хезмәт иткән дивизия кыска гына вакыт эчендә җәяүләп мең чакрымлык авыр хәрби юлны үтә, Гоби чүлен, Хинган тавын кичә. Монголиянең Баян-Төмән (соңыннан — Чойболсан) шәһәреннән башланган хәрби поход Кытайның Сары диңгез буенда гына төгәлләнә. Көнчыгыш экзотикасы, борынгы төрки бабаларыбызның яшәгән җирләре аңарда зур кызыксыну уята. Төрки рун язмаларын да ул беренче мәртәбә шунда күрә, алар белән шунда таныша. Табигый ки, аның дөньяга карашы, профессиясе формалашуда болар берсе дә эзсез калмый.

Сугыш беткәннән соң да ул озак кына армия сафларында хезмәт итә. «Без авырның өстеннән, җиңелнең астыннан чыгарга исәп тотмадык, — ди ул фронтовикларның ул чактагы бердәм халәтен белдереп. — Тыныч хезмәткә сусап кайттык». Шуңа күрә, анысы-монысы җитешмәүгә игътибар итмичә, солдат Хаковның фәнгә килүе шактый урау юллар аша була. Ул аңа мәктәптән — практик лабораториядән килә. Башлангыч мәктәптә укыта, урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, уку-укыту бүлеге мөдире була. В.Хаковның кайбер хәбәр-язмалары матбугатта сугышка кадәр үк күренгәләсә дә, тел һәм әдәбиятка караган җитдирәк мәкаләләре 50 нче еллар башына туры килә. Ул инде мәктәптә укытканда ук күңеленең фәнгә тартылуын ачык төшенә, һәм, мөмкинлек чыгуга, язмышын татар филологиясе белән бәйли.

1949 елда армиядән кайту белән, сугыштан соңгы авыр еллар булуга карамастан, ул укуын дәвам итәргә керешә. Тәтеш педагогия училищесын тәмамлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә, аны кызыл дипломга тәмамлап чыга. Шул елны ук СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага имтиханнар тота һәм конкурстан үтә. Профессор Л.Җәләй җитәкчелегендә



*Вахит Хаков университет студентлары белән. 1972*

аспирантураны уңышлы тәмамлагач, аны 1960 елда Казан университетының үзе укыган татар филологиясе бүлегенә укытучы-ассистент итеп күчерәләр. Вахит Хаковның моннан соңгы эшчәнлеге тулысы белән диярлек университет белән бәйләнгән. Аңа 1965 елда — доцент, 1974 елда профессор дәрәҗәсе бирелә. Ул XIX йөздә һәм XX йөз башында татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган кандидатлык диссертациясен 1961 елда, ә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсешенә багышланган, филология фәннәре докторы исемен алу өчен язылган докторлык диссертациясен, 10 ел үткәч, 1971 елда яклый.

...Кайчан гына ул, кандидатлык диссертациясе яклап, мәш килеп йөргән иде, инде баксаң, докторлыгын яклаганга да күп вакыт узган. Университетта студентларга лекцияләр уку, диплом, курс эшләре җитәкчесе булу, аспирантурада программалар, методик кулланмалар төзү, монографияләр язу... Республикада, үзәк һәм тугандаш халыклары матбугатында чыккан фәнни хезмәтләре генә дә берничә йөзгә якын. Шуларның 15 кә якыны аерым басма булып, китап итеп чыгарылган. Безгә аның күптән түгел зур күләмле «Татар әдәби теле тарихы» дигән хезмәтенең төгәлләнүе билгеле. (Бу хезмәт 1993 елда Казан университеты нәшриятында басылып чыкты. Күләме — 326 бит.) Чыкканнарының берничәсен генә искә төшереп үтик: «Тел һәм стиль мәсьәләләре», «Татар теле стилистикасына кереш», «Татар әдәби теле тарихы буенча очерк-

лар», «Мәктәптә стилистиканы өйрәнү», «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше», «Мәктәптә язучылар телен өйрәнү», «Стилистика һәм сүз сәнгате», «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20–30 нчы еллар)» һәм башкалар.

Тел мәсьәләсе җәмгыятьтә һәрвакыт зур иҗтимагый проблемаларның берсе булып санала. Өлкәнрәкләрнең хәтерендәдер, сугыштан соңгы елларда тел турында, аларның килеп чыгуы һәм үсеш юллары турында кискен-кискен бәхәсләр булган иде. Ул вакытта дәүләт башлыкларының һәм телчеләрнең хезмәтләрен һәрбер вузда өйрәнәләр иде. Тел мәсьәләсе хәзер дә актуаль булып кала бирә. Мәгълүм булганча, татар халкы сан ягыннан Русиядә икенче урында тора. Шунысын да әйтеп үтик: безнең телебез чагыштырмача әйбәт өйрәнелгән. Бу җәһәттән аның күркәм тарихы бар: элекке дәвердән — Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннар, К.Насыйри, ә бу гасырның беренче яртысында — Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Шәрәф, Г.Алпаров, М.Корбангалиев, Ш.Рамазанов, Л.Җәләй, В. Хангилдин хезмәтләре. Бүгенге көндә исән-сау һәм нәтиҗәле эшләп килүче галимнәребездән М.Зәкиев, Д.Тумашева, Х.Курбатов, Р.Юсупов, Г.Саттаров, Ф.Сафиуллина һәм башка галимнәребезнең тырышлыгы аркасында тел белеме фәнен өйрәнү һаман күтәрелә бара. Тел гыйлемендә, тырышлык һәм сәләт белән бергә, гражданлык һәм патриотизм хисләренең югары булуы да, фидакарьлек тә сорала. Тел бакчасы зур, андагы хәзинә бәһа җитмәс кыйммәтле булгач, билгеле, бакчачылар, аның сагында торучылар үзләре дә гадел, көчле, зирәк булырга тиештер. Әгәр Ватан сугышы утларын кичеп, күче-җегәре ташып торган мәһабәт гәүдәле ир кеше татар теле фәненә алынган икән, моны бик табигый сайланыш дип уйларга кирәк.

Профессор Вахит Хаковны тел гыйлеменең төрле яклары, әйтик, лексикология, терминология, фразеология, орфография, этимология проблемалары, сөйләм культурасы, мәктәпләрдә тел укыту методикасы да кызыксындыра, ләкин шулай да аның төп хезмәте — татар әдәби теленең тарихы, төрки-татар язма ядкярләрен тикшерү һәм бүгенге телдәге стилистика мәсьәләләре. Мәгълүм булганча, төрки һәм татар әдәби телләренең ерак гасырларга сузылган үсеш юллары бар. В.Хаковка моңа кадәр билгеле булган элекке төрки язма һәм басма әсәрләрнең барысы белән дә танышып чыгарга туры килә. Телнең хәзерге үсешен шул нигездә генә ачык күз алдына китерергә мөмкин. Аның 1971 елда Алма-Атада яклаган докторлык диссертациясенең исеме дә «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм аның стильләре үсеше» дип атала. Минем аңлавымча, бу — әдәби телнең

эволюциясен чагылдырган хезмәт. Билгеле, болай колачлау өчен тикшеренүчеләрдән телне һәр яктан: лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик яктан тирән белү сорала. Бу хезмәттә темага комплекслы килү сакланса да, барыбер аның үзәк өлеше әдәби тел тарихына һәм аның стильләренең дифференциация мәсьәләләренә багышланган. Автор, һичшиксез, бу өлкәнең зур белгече. Профессор В.Хаков инициативасы белән, аның хезмәтләре нигезендә югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләрендә «Татар әдәби теле тарихы» һәм «Стилистика» буенча махсус курслар барлыкка килде. Алар, хәзер фән буларак, Казан һәм Уфа университетларында һәм педагогия институтларында студентлар тарафыннан махсус өйрәнелә.

Кемдер әйткән канатлы тәгъбир бар: стиль — кешенең үзе бит ул! Бераз кискенрәк һәм көтелмәгәнчә әйтелсә дә, гаҗәеп мәгънә бар бу сүзләрдә. Чыннан да, стиль ул бик киң төшенчә. Стиль — рухи эшчәнлекне белдерүче бер билге ул. Ә инде кешенең уйлау рәвеше һәм аның чагылышы булган сөйләмендә һәм язуында стиль бигрәк тә ачык күренә. Профессияләре язу эшенә бәйле кешеләр өчен стиль төрләрен белү, шул стильләрне тәшкил итүче чараларны ачыклау аеруча зарур. Лингвистиканың кайбер өлкәләре фәннең эчке үсеше өчен күбрәк кирәк булса, минемчә, стилистика — тел фәненең практик гамәлгә якынрак торган өлеше. Әдәбият белән тел гыйлеме бергә йөргән кебек, матур әдәбият тудыручы язучыларның әсәрләре тел галимнәренең җитди хезмәтләре белән аерылгысыз итеп каралырга тиеш. Безнең шартлар өчен бу нәрсә аеруча мөһим. Әгәр әдәбиятчылар үзбаш, тел галимнәре үзбаш тормыш белән яшәсәләр, тел үзе дә, әдәбият та әллә ни алга китмәс, халыкның милли рухы да үсмәс иде. Шушы позициядән караганда, матур әдәбият телен фәнни нигезгә салып өйрәнүдә дә В.Хаковның хезмәте зур. Язучыларыбызның әсәрләрен телчеләребез укып, өйрәнеп барган кебек, язучыларыбыз тел гыйлемендәге яңалыклар белән тиеш дәрәҗәдә танышалар микән? Әйтик, каләмдәшләр тел галимнәреннән Х.Курбатов яки Ф.Сафиуллиналарның язучыларга кагылышлы яңа хезмәтләрен дикъкать белән укып бәһаләделәрме? Миңа, мәсәлән, В.Хаковның үткән ел Казан университеты нәшриятында чыккан «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше» дигән китабы аеруча ошады. Анда татар теленең революциядән соң гомуми үсеш тенденцияләре яктыртыла, конкрет мисалларда тел үзгәрешләренә анализ ясала. Әдәби телнең эшләнеше, 20–30 нчы елларда татар телен гамәлгә кую мәсьәләләренә багышланган бүлекләр аеруча гыйбрәтле.

Һәр фәннең бүгенге тормышта заман куйган проблемаларны хәл итә-итә үсүе хәерле. Без ана телебезнең үсешенә, реаль тормыштагы функциясенә, киләчәктәге язмышына битараф була алмыйбыз. Галим В.Хаков та үз хезмәте белән халкыбызның рухи пропагандисты. Ул әле укытучылар, әле журналистлар алдында тел һәм сөйләм культурасы турында лекцияләр, докладлар белән чыгыш ясый.

Телне «халыкның күмәк хезмәтен, күмәк акылын чагылдырган могҗиза» дип атыйлар. Профессор Вахит Хаков кырык елдан артык инде шул могҗиза сагында тора. Аның йөзләгән шәкертләренең берсе буларак, күңелдә шигырь юллары калка:

Яшәсен,
эш сөйгәннең — хезмәтеннән
зур шатлык ала алганы.
Егетләрнең бик түбәннән
күтәрелеп дан алганы!

* * *

*P.S.* Бу мәкалә 1986 елда басылган иде. Аннан соңгы ун-унике ел эчендә җәмгыятьтә зур үзгәрешләр барлыкка килде. Тел тарихын халык тарихы белән бәйләп объектив тикшерү өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, күренекле филолог һәм тюрколог Вахит Хөҗҗәт улы Хаков, татар тел гыйлемендә «Әдәби тел тарихы» фәненә нигез салучы, «Стилистика»ны фәнни әйләнешкә кертүче галим буларак, бүген дә шул тармакларның катлаулы проблемаларын киң күләмдә фәнни яктан тикшерүне дәвам иттерә. Ул — шушы өлкәләргә караган юнәлешнең фәнни җитәкчесе. В.Хаков Халыкара Тюркологик форумнарда, конференцияләрдә докладлар белән чыга, үзенең фәнни ачышлары белән уртаклаша: Казанда үткәрелгән Халыкара Тюркологик конференциядә (1992), Әнкарада (Төркия) оештырылган III Халыкара Төрки Телләр Корылтаенда (1996), Уфада җыелган Халыкара Тюркологик конгресста (1997), Казанда Г.Ибраһимовка (1997), Г. Исхакыйга (1998) багышланган Халыкара конференцияләрдә һ.б. 1993 елда аның университет нәшриятында «Татар әдәби теле тарихы» дигән зур күләмле (324 битле) китабы басылып чыкты, 20 басма табактан торган «Стилистика нигезләре» дигән китабы басарга әзерләнде.

В.Хаков — 400 дән артык фәнни-теоретик һәм методик-практик хезмәтләрнең, 20 дән артык китап, монографияләр,

дәреслекләр, уку-укыту кулланмалары авторы. Ул үзенең фәнни һәм педагогик эшчәнлеген соңгы елларда җөмһүриятебездә барлыкка килгән үзгәрешләр, татар телен гамәлгә кую, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә алып бара. 1989 елның февралендә Татар Иҗтимагый Үзәген оештыру Корылтаенда, Тел комиссиясе рәисе сыйфатында, ул «татар телен яклау һәм аңа дәүләт статусы бирү турында» дигән докладында, беренчеләрдән булып, татар телен рәсми рәвештә дәүләт теле итеп игълан итү мәсьәләсен күтәреп чыкты, моны фәнни һәм тарихи яктан дәлилләде.

Ул Татарстан Республикасы Югары Советы Президенты карары белән «Телләр турында Закон» проектын әзерләү комиссиясенең әгъзасы буларак та зур эш башкарды. В.Хаков хәзер дә Тел комиссияләренең эшендә актив катнаша, татар теленең кулланылышын киңәйтү юнәлешендә, туган телгә карата яңача фикер тәрбияләүдә дә күп эшли. 20 елдан артык Татарстан радиосыннан тапшырыла торган «Тел күрке — сүз»не оештыру һәм хәзерләү аның иҗади катнашлыгында бара. Бу хакта филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллин матбугатта: «Тел күрке — сүз» фәнни яктан әтрафлы, формасы ягыннан мавыктыргыч итеп алып барыла. Монда тапшыруларның фәнни консультанты В.Хаковның өлеше зур», — дип язып чыкты. Әйткәнемчә, профессор Вахит Хөҗҗәт улы Хаков — тюркология даирәсендә, гомумән, совет тел белеме дөньясында исеме киң мәгълүм галимнәребезнең берсе. Ул — Мәскәү, Алматы, Ташкент, Баку, Ашхабад, Фрунзе, Уфа, Махачкала һ.б. шәһәрләрнең галимнәре белән тыгыз элемтәдә яшәп, иҗат итә. Бөтенсоюз, вузара, региональ фәнни-теоретик конференцияләрдә дә аның чыгышлары елдан-ел ешрак яңгырый. В.Хаков зур һәм тырыш хезмәтләре өчен «II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены», күп медальләр, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгы тарафыннан «Эштә иң яхшы уңышлары өчен» билгесе һәм Мактау грамоталары белән бүләкләнде, күп рәхмәтләр алды. Аңа 1987 елда Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Татар теленең тарихи үсешенә багышланган хезмәтләре өчен ул Университет премиясе һәм Лауреат исеме алды. Ул — Көнчыгышны өйрәнүчеләр ассоциациясе әгъзасы. Дөньяда Кешелекне һәм Тормышны саклау, Гуманизм идеяләрен яклау буенча Халыкара Рыцарьлар конференциясенең әгъзасы (Австралия), шул оешманың ордены белән бүләкләнде.

Солдат, галим, гражданин һаман алгы сафта.

*1986–1998*

## АНЫҢ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Яшь аермалары шактый булса да, университетта без бер чорда укыдык. Ике генә курска алда иде ул. Шулай да аралашып яшәдек дип әйтә алмыйм. Хәер, андый шәриктәшлек өчен мөмкинлек тә, андый хаҗәт тә булмаган аңарга. Бик табигый: без әле яңа гына мәктәп бетереп килгән, малайлыгы чыгып җитмәгән унҗиде яшьлек егет кисәкләре... Ә ул инде (60 нчы еллар башында) яше белән утыз ягына авышкан, күп җир-сулар күргән, төрле халыклар арасында яшәп, телләрен, гореф-гадәтләрен үзләштергән, кыскасы, бу дөньяның шактый «лаеш шулпасын чөмергән», азау теше чыгып, акыл утырткан ир-егет иде. Үз группаларындагы яшьтәшләре белән дә артык әвәрә килеп йөрмәде шикелле. (Ә яшьлектә күңелнең күңелен күреп, заяга вакыт уздыру өчен җайлар күп инде ул!) Тулай торакларда яшәп мәшәкатьләнмәде, әдәби түгәрәкләрдә яки кыз-кымыз җыелган җирләрдә, кайберәүләребез кебек, «даһи шигырьләр» укып йөрмәде...

Йөргән җире аның бүтән: фәнни китапханә иде. Көндәлек мәшәкатьләренә сарыф иткән вакытыннан тыш, иң күп гомерен ул шул мирасханәдә — кулъязмалар, борынгы китаплар дөньясында уздырды. Шуңа күрә ул студент булып бик хәтердә дә калмаган. Белеме белән дә, үз-үзен тотышы белән дә ул — укытучылар составы вәкиле сыман тоела иде. Безне укытып йөргән өлкән укытучы, доцент кебекләрдән аерылмый диярлек иде. Аерылса да, тарихи белеме, үткәнне һәм киләчәкне күзаллавы белән, фәкать уңай якка гына аерылгандыр.

Мәгарәгә бикләнеп белем алган Әбүгалисина белән Әбелхарисларны хәтерләткән аның бу үҗәт максатчанлыгы ул чакта без — яшьләр өчен бераз сәеррәк тоела иде. Әмма хәзер — еллар аша карагач, Миркасыймның бу яшәү рәвеше, омтылышы бик тә аңлашыла.

Аның тарих-филология факультетының татар бүлегендә уку белән генә чикләнмичә, өченче-дүртенче курслардан соң, тарих буенча да белгечлек алуы, шул рәвешчә, ике бүлекне бетерүгә ирешүе дә бүген яхшы аңлашыла. Халыкның узганын, хәзергесен аңлар өчен аның телен, әдәби фикерен белү никадәр мөһим булса, тел-әдәбиятның серләрен ныклап төшенер өчен шул халыкның тарихын да төпченеп өйрәнү зарур. Нәтиҗәдә Миркасыйм Госманов университетны һәм филолог, һәм тарихчы буларак, ягъни ике белгечлек алып тәмамлый. Бу исә аңа борынгы кулъязмалар дөньясына иркенләп керергә мөмкинлек бирә.

Корсаклар чагыштырмача тук булса да, күңелләр ябык, өметләр сыек ул заманнар өчен мондый максатчанлык, фанатикларча фәнгә бирелү икеләтә, өчләтә зарур иде. Рус колониаль политикасының «прогрессивлыгын», совет чорында СССР халыклары ирешкән «казанышларның» әһәмиятен күперткән мөтәтарихчылар өчен шәп еллар иде алар. Каганлык, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын объектив өйрәнеп, тарихи дөрес бәяләмә биреп аңлату мөмкин дә түгел иде диярлек.

Кытайда туып-үскән, Тянь-Шань тауларын айкаган, казакъ далаларын иңләгән, Борынгы Ефәк Юлларын кичкән, төрки халыклар тарихы буенча шактый «белем биштәре» булган «яшь студент»-галимгә нишләргә кала? Тагын да белемне тирәнәйтергә, фәнне фән, тарихны тарих санап, хакыйкатьне засларга. Булган белем, җыелган акыл бер бәреп чыгар әле!

Һәм чыкты да! Без бүген Миркасыйм Госманов турындагы белешмәләрдә менә мондый мәгълүматлар укыйбыз. Ул — тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр Академиясе академигы, Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, фәнни-тикшеренү археографик лабораториясенең гыйльми җитәкчесе, республикада чыга торган абруйлы басмаларның редколлегия әгъзасы... Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Европа, Азия, Америка илләренә барып, төрле фәнни конференция-җыеннарда лекция-докладлар ясаучы халыкара масштабта мәгълүм галим. Ә бит 1958 елны Казанга килгәндә, аның монда бер таныш-белеше дә булмый. Казандагы гомерен, аның беренче төнен вокзалның «көтү залы»ндагы такта эскәмиясендә кунып уздырудан башлаган кеше ул («Казан утлары», 1992, 4 сан, 107 б.).

Бүгенгегә кадәр исән-имин яшәп, алтмыш еллык гомеренең кырыклап елын татарның рухи дөньясын өйрәнүгә багышлаган галим-әдипнең хезмәтләрен, берьяклы гына килеп, бертөсле бизмән белән генә үлчәп, бәһаләп бетерү һич мөмкин түгел. Хезмәтләренең бөтен нечкәлекләрен кертеп колачлап бетермәсә дә, Миркасыйм Госманов эшчәнлеген төп өч өлешкә бүлеп карарга була шикелле. Язма истәлекләрне, әдәби-тарихи чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару, ягъни археограф эшчәнлеге; популяр әдәби китаплар авторы буларак (ул 1970 елдан Язучылар берлеге әгъзасы), язучылык эшчәнлеге; һәм, ниһаять, фәнне оештыру буенча административ җитәкчелек эшчәнлеге.

Шушы шартлы схема буенча иң элек төрле җирләрдә,

төрле елларда басылып чыккан кайбер китап исемнәрен атап китү дә урынлы булыр бу очракта. «XVII–XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары», «XIV–XVI гасыр Җүчи Улусының ярлыкау актлары», «Хөсәен Фәезхановның изге хыялы», «Каурый каләм эзеннән», «Үткәннән — киләчәккә»... Боларның кайберләре үтә фәнни стильдә язылса, кайберләре әдәби-популяр телдә иҗат ителгән. Шунысын да искәртеп узыйк: Миркасыйм Госманов татарча да, русча да, хәзергечә әйтсәк, ике дәүләт телендә дә иркен яза ала торган кеше. Миңа калса, бу китапларның иң мөһим ягы шунда: галим татар тарихын ничек булганча объектив яктыртырга тырыша.

Без хәзер үзебез дә әкренләп — кыйтгалардан кыйтгаларга җәелеп, ерак гасырлардан килә торган тарихыбызның тар Болгар җирлегенә генә сыя алмавын аңлый башладык шикелле инде. Бу юнәлештә безнең буыннар өчен башлап сүз әйтүче кешеләрнең берсе — Миркасыйм Госманов булды. Җүчи Улусына, ягъни Алтын Урда чорына караган документаль истәлекләр хакында 1979 елда ук — татар болгарчылыкны күпләр дин-иман иткән заманнарда ук — зур күләмле фундаменталь монография язып, аны бастырып чыгару үзе хакыйкатькә омтылу юлындагы бер кыюлык иде.

Академик әзерлек һәм 30 еллап төрле архивларда, халык арасында йөреп, кульязмалар җыеп өйрәнү практикасы галимгә әдәби мирасыбыз, фольклор байлыгыбызның яңа катламнарын күтәрергә мөмкинлек бирә. «Хан кызы», «Яр-яр» җырларының яңа вариантлары, «Түләк-Сусылу» дастанының борынгы тексты табылу үзе ни тора!..

Язма хәзинәләребезгә тирән керү, элекке мәдәни хәятыбызны киңрәк иңләү, аның күренешләрен дөресрәк аңлау өчен җирлек тудыра. Бу хәл үз нәүбәтендә аңа табигый рәвештә татар тарихындагы байтак бөек шәхесләрнең мирасларына яңача караш ташларга, алар хакында торгынлык елларында да кыю-кыю фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Габделҗаббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла, Габдерәхим Утыз Имәни, Риза Фәхретдин, Сәит Вахиди... Бу бөек затларның шактый күләмле китапларының яки алар хакында махсус хезмәтләрнең дөнья күрүендә Миркасыйм Госмановның роле зур. Ул бу басмаларның кайберләренә кереш сүз язды, кайберләрен җыеп туплады, аларны текстологик яктан редакцияләде, искәрмәләр белән шәрехләде, кайберләре турында аерым китаплар язып чыкты.

Җегәре ташып торган бу талантлы шәхес әгәр төп вакытын әдәбиятка гына багышлаган булса, һичшиксез, данлык-



*Миркасыйм Госманов шәкертләре белән эш бүлмәсендә. 1978*

лы язучы булыр иде. Хәер, яшьрәк чакта — 1960–1970 елларда язылган китаплары да аның чын әдәби каләм иясе булуын раслый. Язучыларга багышланган белешмә китабында Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге хакында мондый сүзләр бар: «...язучы-галим укучы яшьләр арасында тарих фәнен киңрәк пропагандалау максаты белән, фәнни-популяр жанрга мөрәҗәгать итеп, «Киек сукмакларында», «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китапларын бастыра. Халкыбызның борынгы тормышын өйрәнүче тарихчы-археологларның хезмәте, кызыклы табышлары, ачышлары хакында сюжетлы хикәяләр рәвешендә язылган бу китаплар укучыга тарих, археология буенча киң фәнни мәгълүмат бирүләре белән әһәмиятле». (Совет Татарстаны язучылары. Биобиблиографик белешмә. — Төз: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.) Үзебездән өстәп әйтсәк, яшьләр өчен үтә мавыктыргыч, өлкәннәр өчен бик гыйбрәтле китаплар алар!

Фәнне оештыру буенча җитәкчелек эшчәнлегенә килгәндә, табигый, һәр зур галим үз тарафдарларын, үз шәкертләрен, үз мәктәбен булдырырга тиеш. Ә мәктәп кадәр мәктәп булдырыр өчен, әлбәттә, тиешле шартлар һәм күпмедер дәрәҗәдә хакимиятлек тә кирәк. Өлкән укытучы, доцент, профессор, кафедра мөдире, проректор, академик... Болар — фәнни оештыру, үстерү эшендә зарур баскычлар. Хикмәт — кемнең күпме баскычка күтәрелеп, үз биеклеген ала алуында. Миңа калса, Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге өчен аның татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, бигрәк тә Казан университеты проректоры булып эшләгән еллары аеруча мәгънәле һәм нәтиҗәле булды. Ул — университетның җитәкче постында эшләгән елларда татар тарихы фәнен, гомумән, мәдәниятен үстерүдә байтак игелекле эшләр башкарылды. Турыдан-туры аның инициативасы һәм актив катнашы нәтиҗәсендә бу мәшһүр югары уку йортында Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре дип йөртелгән аерым факультет оешты. Милләттәш студентларыбыз ишәйде. 1988 елда КДУда махсус археографик лаборатория булдырылды. Шуның нәтиҗәсендә берничә дистә еллар халык арасыннан төрле шәһәрләрдәге архивлардан бөртекләп җыелган дистә меңләгән борынгы язма истәлекләренең сакланып калуына, өйрәнелүенә ирешелде. Саный китсәң, ул кылган яхшы гамәлләр байтакка җыйнала.

Галим белән бергә эшләгән, аның белән аралашкан, йөрешкән кешеләр яхшы белә булыр: ул — бик актив, холкы белән шактый кызу һәм кискен шәхес. Бер уйласаң, андый хәрәкәтчән, тынгысыз кеше бүгенге сәяси катаклизмнар заманында төрле социаль төркемнәр арасына керешеп, җәмгыять буталышының эпицентрында булырга тиеш тә кебек. Юк, Миркасыйм Госманов андыйлардан түгел. Аны фани сәясәтнең — сәяси кампанияләрнең теге яки бу ягына аудара алмассың. Ул — көндәлек ыгы-зыгы күбеге белән мәңгелеккә кала торган кристалларны бик яхшы аера. Хәер, вакыйгаларны һәм тарихи төшенчәләрне объектив бәяли алмаган зат нинди галим була соң! Ул бит белә: бөек империяләр һәм бөек шәхесләр булган. Алар туган, яшәгән, беткән... Дөньяны тетрәткән Каганатлар, Алтын Урдалар, гүзәл Сарай шәһәрләре булган — барысы да вәйранга чыкканнар...

Шул ук вакытта аерым халыкларның гына теләгенә, аерым төркемнәрнең мәнфәгатьләренә буйсынмыйча, буыннардан буыннарга күчеп кала торган, әһәмиятләрен югалтмый торган фактлар һәм факторлар да бар. Ниһаять, теләсә нинди шәхесләрдән, лозунг һәм тәгълиматлардан өстен хакыйкать,

объективлык дигән нәрсә дә бар дөньяда. Иҗтимагый хәятның, тарихның өзлеклелеген, дәвамлылыгын шулар тәэмин итә. Болар белән дә кемдер даими шөгыльләнергә тиеш, уңгасулга тайпылмыйча дигәндәй... Минемчә, Миркасыйм Госманов шундыйрак иманны тота. Өстәвенә профессор-остаз, мөдир-администратор өчен бу болганчык, нәфесләрне供 аздыргыч заманнарда моңарчы булган гыйльми кадрларны саклау, аларга алмашка яшьләрне әзерләү эше дә мөһимнәрнеңмөһиме. Аерым предприятиеләр, институтлар гына түгел, төгәл бер дәүләтләр, империяләр җимерелгән, таркалган шартларда...

Болгавыр замана әледән-әле алга яңа сораулар куя. Болары аз дигәндәй, дөньяның үзе төсле искеләрен дә яңарта: безнең бүгенге яшәвебездән, кылган гамәлләребездән тагын берничә дистә, йөз еллардан соңниләр калыр икән? Гомумән, без бик ерак дип санаган, моннан биш-алты йөз еллар элек булган хәлләр, чыннан да, бик еракмы соң?

Бер генә мизгелгә уйлап багыйк: сиңа кырык, илле яки алтмыш яшьме? — озын гомер кичтем, дисеңме? Юк бит, күз ачып йомганда үткән дә киткән!.. Шуңа күрә, Тарих дип әйтәбез икән, без аны син үзең күреп белгән бабаң яки атаң туган, яки фәлән инкыйлаб, социаль тетрәнү елларыннан гына түгел, иң кимендә меңәр ел элек булган чорлардан башлап өйрәнергә тиешбез. Бик гади, наив, әмма мәңгелек хакыйкать — үткәнсез бүгенге юк, бүгенгесез киләчәк юк.

Әгәр халык үзен җиһан танырлык милләт булып яшәргә тели икән, тагын бер бәхәссез хакыйкатьне искә төшерик: андый халык хезмәт итә белергә, тарихи истәлекләрен, бүгенге талантларын саклый, бәһали алырга тиеш, һәм, ниһаять, үзенең узганын бик яхшы белергә, киләчәген күзаллый алырга тиеш.

Безнең замандашыбыз, олуг шәхес, галим-әдип Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның бөтен иҗаты, ул барлап, саклап калырга тырышкан мирас байлыгы безне әнә шуңа өнди.

*1994, март*

# ӘЛЕ БЕЗ ҺАМАН ДА ЗАМАНДАШ

Тарихчы-археолог Равил Фәхретдиновка 50 яшь тулганда, ягъни моннан 10 ел элек, ул вакыттагы «Социалистик Татарстан» гәзитендә «Замандашым-адашым» дигән бер язма бастырган идем мин. Язмам мондый сүзләр белән башлана: «Равилнең исеме студент елларында ук билгеле бер даирәгә яхшы ук таныш иде инде. Равил Фәхретдинов — Тукай, соңрак Ленин стипендиаты, оста баянчы, яхшы спортчы, хор җитәкчесе, төрле экспедицияләрдә катнашучы, өстәвенә килеш-килбәте ягыннан да сөлек кебек егет. Бар ягы да килгән, андый сәләтлеләр, гадәттә, һәр уку йортында берничә генә була... Хәер, боларны хәзер хатирә итеп искә төшерү, ул чаклардан соң утыз еллап гомер узды инде. (Хәзер янә ун! — *Р.Ф.*)

Шулай була бит, яшьлектә үк күңелгә берегеп калган кешене гомер буе күз уңаеннан ычкындырмыйсың. Инде үзебезгә — «кем булырга теләгән идек тә, кем була алдык?» дип сорау куя да алабыз. Яше белән ир уртасына җиткән Р.Фәхретдинов — күренекле тарихчыларыбыздан берсе. Ул — 5 китап (икесе академик характердагы хезмәт, калганнары — фәнни-популяр басмалар). Тарих фәннәре кандидаты. Докторлык диссертациясе әзерләнеп беткән...»

Бүген Равил Фәхретдинов — тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр Академиясе Тарих институтының баш гыйльми хезмәткәре, Татарстанның атказанган Фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә республикабызның Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстан, Идел буе һәм, гомумән, Көнчыгыш Европаның урта гасырлар археологиясе һәм тарихы буенча югары класслы белгеч, 12 китап (коллегалары белән берлектә язганнарын да кушсаң, 22 була икән), 200 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкалә авторы.

Ун ел өчен галимгә күпме бу, азмы? Фән дөньясы үлчәмнәренә мин күнекмәгән, бездә, шагыйрьләрдә, алар икенчерәк. Әмма, күптөрле авырлыкларны күкрәге белән ерып барып, һәртөрле хөсетле адәмнәр белән көрәшеп фәнне яклаучы, милләт тарихын тудыручы Равил Фәхретдиновлар өчен аз түгелдер, киресенчә, күптер дип уйлыйм. Әмма эш мактаулы исемнәрдә, китап саннарында гына да түгел. Миңа калса, ул шактый тирәндә — галимнең профессиональ һәм интеллектуаль акыл югарылыгында, фәнни принципиальлегендә, үз намусы алдында саф булып калуында, зур ихтирам көченә ия булуда, аның гражданлык батырлыгында.

Мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиевнең бер язмасында мондыйрак сүзләр укыганым бар. Әдип заманында үзенең шактый зур кыенлыкларга очраганын, докторлык диссертациясенең намуссыз кешеләрнең көнчелеге-үчлеге аркасында якланмый калганлыгы турында яза һәм бүтән ул эшкә әйләнеп кайтырга үземдә көч таба алмадым, кулымнан эш төште, ди. Ә менә Әгъдәс Борһанов һәм Равил Фәхретдинов, аларның да докторлык диссертацияләрен башта яклатмасалар да, югалып калмадылар, барыбер фән докторлары булдылар, үз эшләренә намуслы булып калып, эшкә тагын да дәртләнеп тотындылар, ди.

Хатирәләргә кереп киткәч, тагын берсе искә төшә. Моннан 30 еллар элек булса кирәк. Без, Татарстан язучыларының зур бер төркеме, Шәһри Болгарга сәяхәт ясадык. Шунда безнең «гид» Равил Фәхретдинов булды. Шул елларда гына «Казан утлары» журналында аның Болгар тарихы турында күләмле беренче мәкаләсе басылган иде. Безнең татарда аз очрый торган археология белгече, яңа яшь галим күпләрдә кызыксыну уяткан иде. Безнең ише яшь шагыйрьләр генә түгел, инде атаклы язучылар да — Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннурлар бар иде анда — Равилнең халкыбызның борынгы тарихы, Шәһри Болгар, урта гасырлар архитектурасы, җир астындагы таш-кирпечләр һәм чүлмәк ватыклары хакында дәртләнеп, ялкынланып, әмма ышандырырлык итеп сөйләү сәләтенә сокландылар. Без шул чакта археология фәненең киләчәгенә, аның ышанычлы кулларда булачагына ышандык. Һәм, шөкер, алданмадык.

Фәнни яшьлегендә — әүвәл студент, аннан аспирант, Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлаган елларда — Р.Фәхретдинов Татарстан археология экспедициясенең разведка отряды җитәкчесе буларак, республикабызның яртысын, күрше республика-өлкәләрнең күп җирләрен йөреп чыга, 600 дән артык археологик истәлек (шәһәр, авыл урыннары, борынгы каберлекләр, хәрби ныгытмалар, бай хәзинәләр) табып өйрәнә. Татарстанның археологик картасын төзүгә зур өлеш кертә, фәндә беренче тапкыр буларак 2000 гә якын истәлектән торган Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының археологик картасын төзи. Бу моңарчы эшләнмәгән җыентык була: һәр истәлек турында академик мәгълүмат — кайда урнашкан, кайсы чорга карый, кайчан һәм кемнәр тарафыннан өйрәнелгән, фәнни әдәбиятта, музейларда, архивларда йөздән артык ел буена нинди байлык тупланган — һәммәсе бар. Равил докторлык диссертациясе



*Равил Фәхретдинов Ибраһим бай (XVII гасырда яшәгән) дөрбәсе янында. Әтнә районы Олы Бәрәскә авылы, 1996*

яклаганда, аның төп оппоненты, күпмедер дәрәҗәдә үз-үзенә каршы килеп булса да, бу җыентыкны безнең фәндә әлегә күренмәгән уникаль хезмәт дип атарга мәҗбүр була. Әлеге 2000 гә якын истәлекнең күбесен Равил үзе табып-өйрәнеп, аларны фәнни юлга чыгара. Бүген Р.Фәхретдиновка каршы ямьсез көрәш ачкан, чынында болгар тарихын өйрәнүгә әллә ни өлеш кертмәгән кара «болгарчы»ларның берьяклы беркатлылыгына хәйран калырлык.

Татар укучысының шул чор буыны Равил Фәхретдиновның академик монографияләрен, аның «Ташлар моңы», «Мелодия камней» китапларын укып, тарихка шактый якын килде. Минем белүемчә, ул китаплар халыкта да, фәнни җәмәгатьчелектә дә яклау тапты, аларның авторы ихтирамга лаек булды. Соңгы вакытта Равил Фәхретдинов, Болгар тарихын онытып, башка чорларны, мәсәлән, Алтын Урданы мактый башлады, диючеләр очрый. Мин аның былтыр гына дөнья күргән «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» исемле менә

дигән дәреслеген укып чыктым. Зур бүлек итеп язылган Болгар тарихына аннан да зур бәя бирүче, гадел, хак сүз сөйләүче бармы икән әле бүген?

Ә тарихыбызның моңарчы йозак астында яткырылган чорлары — Бөек Төрки каганаты, кыпчак дәвере, ниһаять, Алтын Урда турында зурлап язарга тотынганы өчен (алар хакында Равил үзенең элекке китапларында да, ул еллар мөмкинлегеннән чыгып, әледән-әле язгалап килде) без аны, шиксез, олыларга тиешбез.

Яхшы хәтерлим: 1991 елның язында мәгълүм архитектор, сәнгать тарихчысы Фуат ага Вәлиевнең 70 еллыгына багышланган фәнни конференциядә — бу хәл «Казан» милли-мәдәни үзәгендә булды — Р.Фәхретдинов татар халкы тарихында Алтын Урда дәүләтенең тоткан урыны хакында төп доклад ясады. Ә бит әле СССР да таркалмаган, КПСС та бетмәгән һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы каһәрле карары көчендә һәм ул карар белән Татарстанда Алтын Урда тарихын өйрәнү һәм пропагандалау, нигездә, тыелган иде. Йә, шушы түгелме галимнең гражданлык батырлыгы? Хәзер «геройлар», шул чорны сүгүчеләр күбәйде. Ә менә сез нәкъ шул заманда рәсми сәясәт, рәсми идеология кануннарына туры килмәгән фәнни доклад кына түгел, бер-ике сүз әйтеп кара идегез. Сугыш туктагач, йодрык янаучы «каһарманнар» күп була. Шуннан соң Равилнең Алтын Урда тарихын яктыртуга багышланган мәкаләләре газета-журналларда да, кечерәк китап-брошюралар булып та басылдылар. Халыкка моңарчы тыелган гына түгел, алар турында ямьсез караш тудырылган, яла ягылган Чыңгыз, Бату, Үзбәк, Туктамыш, Олуг Мөхәммәт ханнарның исемнәре кире кайта башлады. Өстәбрәк әйтсәк, элекке иске фикердән арына алмыйча интегүчеләрнең кәефен кырып кайта башлады. Әдәбиятчылар, XX гасыр башы татар дөньясы тарихын өйрәнүче тарихчылар Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садрый Максудиларны кире кайтардылар, ә Равил Фәхретдинов, Марсель Әхмәтҗановлар — XIII–XVI йөз татар ханнарын вә ханбикәләрне, безнең данлыклы чорларыбызны, җиңелгән генә түгел, ә күбрәк җиңгән, җиңелүнең нәрсә икәнен белмәгән заманнарны, Тукай әйткәнчә, «вакытында җирне селкеттек» дәверләрне хәтеребездә ныгыттылар.

Тарихта беренче тапкыр буларак Алтын Урда тарихына һәм мәдәниятенә багышлап, 1993 елда Казанда Халыкара фәнни конференция уздырылды. Аның инициаторы, эшләрен башлап йөрүче, арбаны төпкә җигелеп тартучы тагын



*Ике Равил — ике дус. Равил Фәйзуллин һәм Равил Фәхретдинов. Иске Казан, 2002*

шул безнең тынгысыз Равил абзабыз булды. Аның өчен аңа шул вакытында рәхмәт укымадылар дип уйлыйсызмы? Укыдылар, бик укыдылар. Ләкин өстеннән язучылар да булмады түгел. Сөембикә манарасына ай кую мәсьәләсен күтәреп, шул хакта докладлар ясагач, үзе җитәкләгән тарихи Мирас комиссиясендә куркытулар да булды, ләкин ул курыкмады. Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстайның каберен табып, шуның өстенә таш куйдыртуны кем башлап йөрде? Тагын шушы тынгысыз җан. Бәләкәй Тукай турында халык арасында сакланып калган истәлекләрне беренче чиратта без, әдәбиятчылар, җыярга тиеш идек, әмма аларны да ул — археолог җыйды. Археолог-галим Илһам Шакиров турында беренче китап язды. Язганын белгәч, башта бер аптырадылар, укып карагач, икенче бер аптырадылар һәм яхшы сүзләр әйттеләр, уңай рецензияләр бастырдылар. (Рәис Даутов, Илбарис Надиров, Мәхмүт Нигъмәтҗановлар...) Минем үземнең дә ул китап турында җылы сүзләрне Сибгат ага Хәкимнән ишеткәнем булды. Ул әлеге китапка сүз башы да язган булган, Тукай, Сәйдәш, Илһам моңы турында язган, ләкин Обкомда каршы килгәннәр, иртә әле Илһамны ул бөек шәхесләр белән янәшә куярга, дигәннәр. Ә нигә куймаска? Нигә берәүләр 25–27 яшьләрендә бөек була ала да, ә икенчеләре 35–37ләрдә — юк?

Югыйсә гасырлардан килүче шул ук тирән сагыш, илаһи моң, олуг талант бит.

Ә археологка моң каян килгән? Әтисе Габдрахман абзыйның тәрәзә рамнары, өстәл-урындыклар, шкафлар ясаганда чыгарган ышкы тавышыннанмы, аның өздереп тальянда уйнавыннанмы, әнисе Нәгыймә апаның тутырып караган моңлы кара күзләреннәнме? Әллә тирәндәрәкме ул моң? Тарихтамы, ташлар моңында, Болгар хәрабәләрендә, ул казыган Иске Казанның тау итәкләрендәге әле бүген дә тарих исе аңкып тора торган җуалы һәм какылы, сукаланмаган болыннардамы? Һәммәсендә дәдер...

Вакытлар уза, заманалар үзгәрә, җәмгыятьләр алышына, тарихка, үткән мираска караш киңәя, тирәнәя. Дистә еллар буе тирән һәм караңгы базларда яткан, тыелган шәхесләр, тарихлар кире халыкка кайта, дөньяга чыга. Шул изге, бәрәкәтле эшнең алгы рәтендә минем чын адашым, якын замандашым Равил Фәхретдинов та тора. Ташлардан моң һәм илһам алып тарих язучы, яше 60 ка җитеп, чәчләре чаларган, тик бүген дә Казан артына, Тау ягына, Кама аръякларына чыгып, шул ташларны барлап йөрүче шушы затка озын гомер, җан тынычлыгы, яңа зур уңышлар телик. Яңа моңнар, яңа дастаннар, яңа тарихлар тусын, замандашым!

*1997, октябрь*

# НАРАСЫЙ ХӘКИМ



*Әхсән Фәтхетдинов һәм Равил Фәйзуллин. 1999*

Җәмгыятьне гел бимазалап, мәшәкать тудырып, Кеше дигәннең кешелеклелеген кытыклап тора Ходайның талантлы дигән бәндәләре. Холык-фигыльләре, эш-гамәлләре, уй-максатлары белән һич кенә дә гомумкысаларга сыймый үзләре. Яшәү рәвешенә үзгә карашлары; төсләр дә алар өчен җиде-сигез генә түгел, мең дә бер балкышта; авазлар да алар өчен мең дә фәлән аһәңдә... Шул ук бер Кояш, шул ук тулган Ай астында яшибез ләбаса! Ә дөньяны танып белеп аңлаулары бүтәннәрнекеннән бөтенләй үзгә! Күз күреме бүтән, күңел тоемы бүтән... Аралаша-аралаша яшәгәч, күрә-күрә, ишетә-ишетә иҗатларының кайбер серләренә төшенгәч, гаҗәеп бер гүзәл Дөньялары ачыла да куя! Бу Дөнья гаҗәпләндерә дә, сокландыра да, сискәндерә дә... Шуңа күрә Ходай тарафыннан талант мөһере сугылган шәхесләр белән санлашырга туры килә. Хаким түрәгә дә, гап-гади хезмәт иясе-юксылга да, таш бәгырьле тәкәббер бәндәгә дә, нарасый күңелле изге җанга да. Әйе, санлашырга туры килә!

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов турында бер-ике кәлимә сүз әйтергә теләп кулыма каләм алгач килгән өзек-өзек уйлар бу. Күрәсең, юкка түгелдер. Әхсән дә бит югары кимәлдәге талант иясе. Ул да бит бүгенге дәрәҗәле мөнбәренә авыр һәм газаплы юл үтеп, танылу-танылмау баскычлары аша күтәрелгән шәхес. Искә төшерик: әле моннан унбиш-егерме еллар элек кенә аны югары даирәләрдә зур сәнгать вәкиле итеп санамыйлар иде. Һәрхәлдә, рәсми яктан шулай булды. Аның СССР Рәссамнар берлегенә фәкать 1983 елда, 44 яшендә генә кабул ителүе шуны раслый. Сәнгать белгече С.М.Червоннаяның (ул татар рәсем сәнгатен пропаганда-

лауда күп хезмәт куйган галимә) шул елларда чыккан «Художники Советской Татарии» дигән библиографик белешмә китабын актарып карагыз. Анда сез Ә.Фәтхетдинов исемен иң ахыргы биттә, кечкенә генә белешмә рәвешендә күрерсез. Ә Әхсәннән күпкә, шактый күпкә яшь рәссам егетләр — Ш.Шәйдуллин, В.Аршинов, З.Гыймаев һәм тагын бүтәннәр берничә бит урын алып, портрет-сурәтләре белән бик иркен утыралар бу китапта. Бу мисалны алар лаек түгел дип китерүем түгел, алар да сәләтле рәссамнар, чагыштыру өчен генә искә алуым. Ә бүген? Ә бүген исә, торгынлык чорындагы замандаш байтак апофеоз шәхесләр арткы планда тоныкланып калганда, Әхсән Фәтхетдинов иҗаты, аның шәхесе мәйданыбыз уртасына чыкты. Бүгенге татар милли сәнгатен аның иҗатыннан башка күз алдына китерү кыен. Күпләрнең — сәнгать белгечләренең дә, гади халык вәкилләренең дә — фикере уртак: Әхсән Фәтхетдинов — уникаль сәнгать әсәрләре тудырган олуг рәссам. Бу коры комплиментарь сүз түгел, әйтелгәнне расларлык дәлилләр күп. Ул — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984). Ул — Республикабызның иң абруйлы — Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1993). Ул — әлегә республикабызда даими эшләп килүче бердәнбер шәхси галерея иясе (1997 елны ачылды)... Гомумән, Түбән Кама шәһәре, аның интеллектуаль дөньясы турында сүз чыкса, ирексездән Әхсән Фәтхетдинов бу каланың бер рухи символы булып күз алдына килә. Әйе, Кеше белән, талант иясе Кеше-Шәхес белән санлашырга туры килә. Соңарып булса да. Дөнья бу!

Кайсы яктан, кайсы туфрактан соң ул? Иҗат юлы ничек? Хезмәтләре нидән гыйбарәт? Башкалардан нәрсә белән аерылып тора да, милли сәнгать үсешенә нинди өлеш керткән? Болар — табигый сораулар. Хәл кадәри шуларга җавап эзләп карыйк, мәгълүматлар укучыларыбызны да кызыксындыра дип ышаныйк. Татарстанда туып-үскән егет ул. Тумышы — Чирмешән (ул вакытта Первомайский дип йөртелгән) районының Урманасты Үтәмеш авылыннан (милли җанлы икенче бер рәссам Канәфи Нәфыйков та шул төбәктән). Ишле гаиләдә үскән Әхсәннең малай, үсмер чаклары ничек үткәндер, анысын белмим, әмма Табигатьнең бөек сереннән кече яшьтә үк әсәрләнеп йөрүе турында үзе сөйләгәннәре истә. Табигатьнең нәни бер өлешен генә булса да — үлән-тирәкме ул, кошмы, болыт-төтенме — үзе ясап тудырырга ният итмә кели бит бу малай! Кул астына эләккән кәгазь кисәгенә нindидер сызыклар сыза, сурәтләр төшерә,

таякларны юна-юна сырлар уя, шакмак, такта кисәкләрен бергә укмаштырып нидер төзи...

Һөнәри белемне Әхсән Фәтхетдинов Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетында ала. Институтны тәмамлагач, берничә ел Әхсән Урал якларында эшли. Укыту белән дә шөгыльләнеп ала, иҗатка да ыргымнар ясап карый. Әмма... Әмма нидер җитми бит күңелгә! Торган җир үз түгел, мохит барыбер чит, ят... Ара-тирә артистлар килеп, татар моңнарын ишеттергәндә, Казаннан алдырган татар китапларын, газет-журналларын укыганда, күңелдә аңлатып бетермәслек сагыш, хатирәләр зилзиләсе, җирсү... Ниһаять, 1969 елда Әхсән, тәвәккәлләп, хатыны Таисия белән Татарстанга кайта. Ул вакытта үзенең колачы, үсеш темпы белән бөтенсоюзга яңгыраган, яшьләр каласы дип дан алган Түбән Камага килеп төпләнә бу яшь гаилә. Әйе, төпләнә. Тамырларын тирән җибәргән, ябалдашларын колачлы итеп мәгърур җәйгән имән шикелле, биек һәм бөек булырга кайтып төпләнә Әхсән. Түбән Камада 30 ел гомер. Иҗатчы өчен тулы бер дәвер. Үксегән чаклары да, иҗат һәм яшәү шатлыгыннан күк катларына менәрлек үсенгән чаклары да булгандыр. Һәрхәлдә, бүгенге милли сынлы сәнгатебезнең асыл бер өлешен тәшкил иткән әсәрләрне шушы шәһәрдә иҗат итте Әхсән.

Сәнгать белгечләре Әхсән Фәтхетдинов әсәрләрен, гадәттә, берничә төркемгә бүлеп карыйлар. **Агачка уеп ясалган декоратив бизәкләр** (балалар бакчалары, аэропорт, кунакханә диварларындагы бизәкләр). **Нәкыш сәнгате** («Тукай шигырьләре», «Түбән Кама җирендә», Хәсән Туфан, Бакый Урманче, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов портретлары). **Агачтан ясалган декоратив скульптура сыннары** («Сак-Сок», «Таһир-Зөһрә», «Ияләр», «Кабер ташлары», «Шүрәле», «Интеккәннәр» цикллары). **Монументаль язу үрнәкләре** (Түбән Камадагы төрле корылмалар (музыка училищесы, хастаханә, техникум һ.б.) диварларындагы бизәкләр.

Сәнгать фәненнән караганда, мондый бүленеш дөрестер, һәм кирәктер дә. Ә бит көндәлек тормышта, үзара гадәти сөйләгәндә болай классификацияләп тормыйсың. Иҗатчының хәтерендә калган берничә төп эшен исеңә төшерәсең дә, ул эшләрнең материалына, сәнгати «чыраена» карап, Останың төп асыл сыйфатын үзеңчә шәрехлисең. Ә.Фәтхетдинов — агаччы. Агач җанлы Оста. «Агач җанлы» дигәнне гадәти сөйләмдәгечә бер яклы аңламыйк, «бала җанлы» дип әйтәбез бит әле. Бу очракта әнә шул мәгънәдәрәк аңлашыл-

сын. Авторның күпсанлы гүзәл сыннарына карап, аларга Әхсән үз җанын биргән, ә агачларның җаны Әхсәнгә күчкән дип әйтә алмыйбызмыни («Каберенә агач үссә, ул — аның җаны булыр...»)? Нәкыш портретларының рамнарына гына игътибар итегез, алтын йөгертелгән академик багетлар түгел, һәрберсе агачтан, бер-берсен кабатламас, әсәрнең органик өлеше булып, эчтәлекне тирәнәйтүче детальләр алар. Дөнья сәнгатендә Әхсәнгә кадәр гомер кичеп үткән аналоглар да бар барын: Эрзья (С.Д.Нефедов), С.Коненков, Б.Урманче... Урманасты Үтәмеш егетендә генә түгел, уйлап баксаң, Табигать кочагында үскән безнең һәрберебездә күпмедер «агачлык» бар бит. Агач бишектән башлап ләхет уемындагы такталарга кадәр... Балачакта авыл өендәге сәкедә чалкан килеш түшәмдәге ботак киселешендәге сурәтләрне карап ятмадыкмыни? Ниндие генә, нәрсәгә генә охшаганнары булмый иде аларның! Үзенә күрә бер галерея. Түшәм галереясы. Кыскасы, Әхсәнне Агач кеше итте, Оста итеп дөньяга танытты. Икесенә дә рәхмәт! Шагыйрь Зөлфәт Әхсәнгә багышланган шигырендә тикмәгә генә болай дип язмагандыр:

...Остаханәңдә мин, Әхсән,  
Өнсез булдым.  
Кешене син бакый иткән бит...  
Син — җан табигате генә түгел,  
Табигатьнең җаны икән бит!

Ә.Фәтхетдинов сәнгате киң даирәгә 80 нче еллар башында танылa башлады. Казанда үткән беренче күргәзмәсе (1978) әле дә хәтердә. Рәссамнар өчен күргәзмә дигәннәре зур нәрсә. Биючегә мәйдан-сәхнә кирәк булган шикелле, рәссамга үз эшләрен кеше күзенә күрсәтү лазем. Яшьләр Үзәгендә (хәзерге «Ак барс» банкы бинасы) оештырылган иде ул күргәзмә. Күбрәк нәкыш әсәрләре — портретлар, пейзажлар, график эшләр, шулай ук бүгенге зур мирасның башлангычы — агач сыннар да бар иде анда. Казанлылар яратып калды Әхсәнне. Дуслары күбәйде. Язучылар, журналистлар үз итте. Арада, әлбәттә, сәнгатькярләр дә байтак иде. Фоторәссам Рифхат Якупов, композитор Шамил Шәрифуллин, бөек Бакый Урманче... Перифериядән килгән рәссамга рәсми «классик»лар тарафыннан өстәнрәк, бераз түбәнсетеп тә караучылар булмады түгел... Әмма татар милли сәнгатенең (агач җаны аша) бу төре үсешен ныклап башлап җибәрүче нәкъ Әхсән булачагына ышанучылар күбрәк иде. Дөрес, сынлы сәнгатьнең теге яки бу жанрында техник яктан заманча иҗат итүче сәләтле рәссамнар байтак. Алар йә С.-Петербург, йә Мәскәү



*Равил Фәйзуллинга багышланган музей экспозициясен ачу күренеше. Сулдан: Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Равил Фәйзуллин һәм Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин. 1998, ноябрь*

мәктәбен үтеп, бертөрле тәрбия, бертөрле идеологик юнәлеш алып үскән рәссамнар. Алар кайда да — Псковта да, Уфада да, Магаданда да рәхәтләнеп яши, үзләре үткән мәктәп курсы рухында иҗат итә алалар (мисалы ерак түгел: Бондюг егете Әмир Мәҗитов әллә ничә еллар буе Ярославль Рәссамнар берлеген җитәкләде, хәтта Казанга кайтып та шул дәрәҗәле хезмәттә булды. «Чайка», «Барабанщик», «Сигнал» кебек бөтенсоюзга киң таралган әсәрләр авторы булса да, мин аны чын мәгънәсендә милли рәссамыбыз дип таный алмыйм). Бәлки, осталыкның тегe яки бу хикмәтендә, Әхсән кемнәрдәндер калышададыр. Нишлисең, Ходай кемгә буй, кемгә уй биргән ди. Миллилеге белән, беркемне дә кабатламый торган үзенчәлеге, алынган теманы философларча хәл итүе белән, ахыр чиктә, Әхсән дигән шәхес булуы белән алдыра ул! Һәм ничек кенә әле!

Алда әйтелгәнчә, 1993 елда Әхсән Фәтхетдинов Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Рәссамнар берлегенә әгъза булып керүенә нәкъ 10 ел үткәч. Шул елның яз башында Казан милли-мәдәни үзәгендә гаять бай күргәзмәсе оештырылган иде аның. Вәт күргәзмә дисәң дә күргәзмә иде ул! Бусы инде — без теләгән (күпләр теләгән!) Әхсән иде. Жанрлар төрлелеге ягыннан, дисеңме, осталык, камиллек ягыннанмы, җаныбызда сыкрап яткан рухи катламнарны ачып күрсәтү ягыннан, дисеңме... Бу күргәзмәдә иҗатының үзәген билгели торган төп цикл-төркем эшләре куелган иде.

«Шүрәле»ләр. Алар — үзе бер дөнья. Чиста, пакь дөнья. Шүрәлеләрнең берсе, бәлки, автор үзедер әле! Ул да, безнең кылган гамәлләргә карап-карап тора да, хилафлыкларыбыз өчен бетереп үк ташламый, сынап-сынап карый да, аптырагач, шаяра, кытыклый, көлә... Ә «Интеккәннәр» циклы? Нинди генә йөз-чырайлар юк ул сыннарда! Алар — безнең үткән тормыш, безнең бүгенгебез. Әле яңа гына, 26 апрель — Шигырь бәйрәме көнендә, Камал театрында Түбән Камалыларның тантаналы концерт кичәсендә сәхнәдән торып Әхсән болай диде: «Минем ул сыннарның чытык, ямьсез йөзләренә карап гаҗәпләнмәгез, тормышларыбыз рәтләнеп китеп, хәлләребез яхшыргач, аларның да йөзләре үзгәрер, аларга да нур кунар...» Уйландыргыч сүзләр.

«Ияләр» циклы, мөгаен, Әхсән Фәтхетдиновның гомер хезмәтедер. Нинди генә ияләрнең иясе булмады ул! Җир иясе, күк иясе, урман иясе, зират иясе, чишмә иясе, юл иясе, су иясе, йорт иясе, абзар иясе, капка иясе... Алар әллә ничә дистәгә җыйнала. «Ияләр» хакында матбугатта күп язылды. Абруйлы язучылар да, үз эшләрен камил белгән сәнгать белгечләре дә: Р.Шаһиева, Г.Сөләйманова, И.Саттаров, Р.Хисмәтуллин, Э.Гаделов, Д.Вәлиева... Рәссамның «Ияләр»ен төрлечә бәяләделәр, аларның тууын төрлечә фаразладылар. Ислам дине кабул ителгәнгә кадәрле чорны, мәҗүсилек дәверен, чыганак итеп күрсәтүчеләр булды. Берәүләр аның бу әсәрләрен «коммунизм төзү чорындагы» ялган рәсми сәнгатькә протест билгесе итеп тә карадылар. Еретик рәссам дип мөһер сугучылар да булды. Ни генә булса да, хаклы шауладылар, хаклы бәхәсләштеләр, хаклы бәяләделәр. Хаклы рәвештә Тукай премиясен бирделәр. «Иясез шатлык» булу бер нәрсә, ә һәрнәрсәнең, табигатьтәге һәр җанлының үз иясе булуы кирәк бу дөньяда! Ияле булсаң, кадерең була. Кадерсез булу яман ул...

Бу урында Әхсән Фәтхетдинов белән минем шәхси иҗади

мөнәсәбәтләр турында да берничә сүз әйтү кирәк булыр. Әхсән иҗатының бер зур өлешен «Кабер ташлары» дигән цикл алып тора. «Татар иле» газетасында (6 сан, март, 1993) мондый юллар язылган иде: «Ә.Фәтхетдинов иҗаты соңгы елларда чын-чынлап чәчәк ату чорын кичерде. Равил Фәйзуллин шигырьләренә нигезләнеп иҗат ителгән «Кабер ташлары» рельефлы скульптуралар төркеме татар халкының кире кайтмас югалтулары һәм газаплары өчен тирән борчылу хисләре белән сугарылган. Бу — татар зиратының символик образы, анда халкыбызның тормышка ашмаган хыяллары күмелгән. Кешеләрнең рухи байлыгын, вөҗданын һәм хәтерен саклап калу өчен безгә әле бик күп эшләр эшләп өлгерергә кирәк. Һәм шигырьләр — шагыйрь иҗат иткән эпитафия, биредә бигрәк тә дулкынландыргыч яңгырыйлар...» (А.Шакиров). Сүз — берничә юллык кыска шигырьләремне Әхсән кулы белән агачка уеп язылган әсәрләр турында. 50 гә якын шигырь чокылган куна такталар алар. Дөрес, мин беркайчан да кайчандыр кабер ташларына (бу очракта агачка) уярлар дип иҗат итмәдем. Кыска шигырьләр — минем стихиям, бәлкем, асылымдадыр әле. Әмма олуг Останың һәрбер сүземне, һәрбер хәрефемне ырмау пычак белән агач бәгыренә уеп утыруын күз алдына китерик әле! Ничә көннәр, ничә айлар... Шагыйрь өчен әйтәсе дә юк, зур бәхет инде бу. Шунысы да мәгълүм: бу әсәрләр куелган күргәзмә кешеләргә нык тәэсир итә икән. Сүзләре дә, эшләнеше дә, агач булуы да... Гомумән дә уйландыра — зираттагы кабер ташлары нинди булырга тиеш? Һәрхәлдә, сурәт яки һәйкәли сыннар рәвешендә түгелдер. Сурәт белән таш кую безнең мөселман традициясе түгел. Безнең борынгы ташларда сурәт юк бит. Фотокүчермәдән кеше сурәтен ташка иңдерү соңгы чор, сәвит чоры галәмәтләре, ул гына да түгел, мәҗүси-христиан традицияләре. Уйлансаң уйланырлык: Чыңгыз ханның кабере нәмәгълүм (инде гасырлар буе эзлиләр), Л.Толстойның каберендә сурәтмазар юк, Истанбулдагы Г.Исхакый каберендә дә фәкать язулар гына... Борынгы төрки ядкарь — Күлтәгин ташларында да уйма язмаларны гына күрәбез. Сабый хәким — Әхсән Фәтхетдин төрлесен уйлап, киләчәккә карап уйгандыр ул сүзләрне.

Әхсән белән даими аралашып яшәгәнгә егерме биш еллап. Байтак гомер. Хәзер күрше белән күрше, туган белән туган юньләп аралашып яшәмәгән заманда, Әхсән миңа хатлар яза. (Тапшырылмаган хатлар түгел, тапшырылган хатлар!) Ә ул хатлар хатлар гынамы соң әле! — кайберләре

бер амбар кенәгәсе чаклы — машинкада 70–80 биткә җиткәннәре бар. Алар миндә 40 тан артык. Менә боларны укысаң, Әхсәннең җанында ниләр уйнаганын беләсең инде! Ул әле рәссам гына түгел, шагыйрь дә, әдип тә, философ та. Ходай боерган булса, ул хатлар (бераз өлеше генә булса да!) матбугатта бер күренер әле.

Сүз дә юк: Әхсән кебек намусны компас итеп алган шәхесләргә бу тормышта, безнең мохиттә яшәү җиңел түгел. Алар бәргәләнә, өзгәләнә... Ниндидер язылмаган кануннар бардыр инде: кемнәргәдер авыр булганда, кемнәргәдер җиңел була... Әмма барыбер бүген өзгәләнгәннәргә иртәгә җиңеллек киләчәк... Әхсән үткән юлга, тормышына, иҗатына карап шулай уйлыйм. Дөньяда үзеңнән яхшырак кешеләр барын тою яшәтә безне, турайта, өметләндерә, шактый ук уңган күзләребезне киләчәккә төбәтә.

«Казан утлары» журналында (1999, 6 сан) Әхсән Фәтхетдиновның «Сугыш еллары атлары» дигән сынының фоторепродукциясе чыкты. Редакциягә җибәргән хатында аның мондый сүзләре бар: «Соңгы зур күләмле «Ай шәүләсе астында» дигән эшемдә «Ияләр»не бергә җыйдым. Җир өстенә аларны күккә сибелгән йолдызлар кебек чәчтем, сиптем. Алар арасында байлар-ярлылар да, патша-коллар да юк, алар — тигезләр. Бу картина — үзем тудырган, үземә якын булган бер дөнья». Синең дөньяң безнең өчен дә бик зур Дөнья, Әхсән туган! Озак, бәхетле яшәп, игелекле иҗатың белән сөендереп тор гел.

*1999, май*

## СӘФӘР БАШЫ

Җыр-көйләребезнең исемнәрен генә искә төшерик: «Шахта», «Уел», «Порт-Артур», «Уфа — Чиләбе», «Байкал күле», «Ашхабад», «Тобол көе», «Җаек», «Ком бураны», «Әдрән диңгез», «Дим буе», «Бохара — Урал», «Агыйдел буйлары». Кайчан һәм кайларда гына тумаганнар да алар, кемнәр генә җырламаган аларны! Тарихи язмыш җилләре белән чәчелеп таралган халыкның язмышы нинди булса, җырларының да шулай ук, талантлы улларының да... Тыелгысыз чишмәләр кебек, дөньяның төрле почмакларында юл ярып чыкканнар да алар кыйтганың төрле тарафларында аваз салганнар. Әле соңгы чорда гына музыка яки башкару сәнгатенә килгән кайбер исемнәрне генә хәтергә алсаң да шул ук хәл. Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннар, Солтан Габәши, Мансур Мозаффаров, Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйповлар Казан җире тирәсеннән булсалар, Нәҗип Җиһанов — Җаектан, Җәүдәт Фәйзи — Оренбургтан, Заһид Хәбибуллин — Орскидан... Мәшһүр башкаручылардан Фәйзулла Туишев — Сембер ягыннан — Мәләкәстән, Рәшит Ваһапов — Нижгардан.

Шамил Шәрифуллин — комлы, чүлле яклардан, Төркмәнстаннан — Фарабтан. Фараб — Көнчыгышның бөек галиме Әбүнасыйр Мөхәммәт әл-Фараби җире. Шамил Шәрифуллин — бүгенге яшь татар композиторлары арасында иң өметлеләреннән берсе. Остазы Нәҗип Җиһанов фикеренчә, ул халык музыкасының онытылып бара торган борынгы катламнарын ныклап өйрәнеп, ерак гасырлардан килгән аһәңнәрне бүгенге тормышыбызга да бик кирәклеген исбат итеп, аларны киң дөньяга чыгарырга омтыла һәм, әйтергә кирәк, бу эштә билгеле бер уңышларга ирешә дә инде.

Шамил Шәрифуллин 1949 елны туган. Әти-әнисенең музыкага һәвәс кешеләр булуы, әлбәттә, Шамилнең сәләте ачылуга уңай тәэсир итә. Сугыш афәтләре аркасында үз вакытында тиешле музыкаль белем ала алмаса да, Камил ага — Шамилнең әтисе — хәзер дә Фараб, Чарджоу тирәләрендә атаклы мандолиначы, скрипкачы санала. Әнисе Ләйлә ханым да халык көйләрен яратып башкара. Кече яшьтән үк баянда уйнаган Шамил, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Ашхабад музыка училищесына укырга керә. Анда ике курс укыгач, Казан музыка училищесына күчә. Казан! Күчеп килү, әлбәттә, кинәт кенә булмаган. Сабый чактан ук өйдә татар көйләре язылган өем-өем патефон тәлинкәләрен тыңлап үсү дә, ара-тирә бу якларга килеп чыккан Илһам Шакиров, Әлфия



*Татарның ике зур композиторы — Алмаз Монасыйпов һәм Шамил Шәрифуллин (уңда). 1981*

Афзалова кебек күренекле җырчыларны ишетү дә, Шамил белән бер йортта яшәгән скрипкачы грек Тамбулидиның халык көйләрен үзәк өзгеч итеп башкаруы да, әтисенең кайчандыр бабалары яшәгән Казан яклары турында еш кына сөйләүләре дә тәэсир итми калмагандыр.

1969 елны Шамил Казан музыка училищесының халык уен кораллары бүлеген уңышлы тәмамлап чыга. Уку елларында ул баянда уйнау буенча училище, район, шәһәр, өлкә һәм Идел буе регионы смотрларында лауреат исемнәрен алып, җиңүчеләрдән саналып килә. 1969–1973 елларда ул Казан консерваториясенең композиторлар хәзерләү факультетында укый. Бу елларда Шамил күләмле берничә инструменталь әсәр — бер симфония, скрипка һәм фортепьяно өчен ике соната, тынлы уен кораллары триосы өчен бер сонатина иҗат итә, унбиштән артык мишәр көйләрен эшкәртә, гармонияләштерә. Консерваторияне тәмамлаганнан соң, ул аның фольклор кабинеты мөдире булып эшли. Бер үк вакытта студентларга музыка буенча дәресләр дә бирә. Башкара тор-

ган әшенең үзенчәлеге һәм кече яшьтән үк килгән табигый кызыксыну халык иҗаты белән якыннанрак, тагын да системалырак шөгыльләнүгә китерә. Соңгы берничә елда ул мишәрләр яши торган байтак төбәкләрдә булып, биш йөздән артык халык көен язып алып кайтты. «Халык көйләре — бәя җитмәс зур байлык, искиткеч хәзинә!» — ди Шамил. «Инде байтак көйләр җыйгансыз икән», — дигәч, ул: «Венгр халкының бөек композиторы Барток дүрт меңнән артык халык көен җыеп язып калдырган!» — диде. Халык иҗатына ихлас бирелгәнлек һәм шәхсән тырышлык — яшь композиторның киләчәк эше өчен ныклы нигез. Эзләнүләр һәм тырыш хезмәтнең бер күркәм нәтиҗәсе итеп аның катнаш акапелла хор өчен язылган «Мөнәҗәтләр» концертын күрсәтергә мөмкин. Бу концерт яшь композиторга чын-чынлап иҗади куаныч китерде. Ул әсәр Казаннан тыш Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләрдә дә яңгырады, республика һәм Бөтенсоюз пленумнарында башкарылып зур бәя алды. Быел яз көне язучыларның Тукай клубында да бу концертны яратып тыңладылар. Соңыннан Нәкый Исәнбәт, Мөхәммәт Гайнуллин, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак кебек өлкән әдипләр үзләренең фикерләре белән уртаклашып, зур хуплау сүзләре әйтеп чыктылар. Әле күптән түгел генә Мәскәүдә булып үткән совет-болгар яшь композиторларының халыкара дуслык очрашуында да бу әсәр уңай бәяләнде. Болардан тыш Шамил Шәрифуллинның орган өчен махсус иҗат ителгән «Вариацияләр»е татар театрларында барган спектакльләр («Ике килен килендәш» — Х.Вахит, «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» — И.Юзеев) өчен көйләре, бүгенге татар шагыйрьләренең сүзләренә язылган кайбер лирик җырлары белән дә музыка сөючеләргә яхшы таныш. Алда — хыяллар тулы олы юл. Рояль өстендә — язылып килә торган балет партитуралары, яңа симфония караламалары... Әйе, алда олы юл, ерак сәфәр. Олы Иҗат Иленә сәфәр. Ничек үтелер киләчәк юллар? Алдан әйтү кыен. Ә юл башы, безнеңчә, дөрес сайланган.

Бу көннәрдә Шамил, иңенә магнитофон асып, Ульяновск өлкәсе авылларында йөри. Ул анда могтәбәр ил картлары, әбиләр белән очрашып, алардан борынгы көйләр язып ала-дыр. Кызык: борынгы мөнәҗәтләрнең аһәңен заманча яңгыратып безгә ирештерер өчен, ерак Караком далаларыннан Шамил дигән егетнең килеп чыгуы кирәк булган!

Ерак Төркмәнстанда яшәүче Камил ага язмышы белән канәгать булырга тиештер кебек. Аның тормышка ашып ук җитмәгән хыялларын уллары дәвам иттерә. Бер улы —

Шамил кыю адымнар белән татар музыкасында үз юлын ярып бара. Икенче улы Фәрит тә абыйсы юлы белән китте: ул быел Казан консерваториясен тәмамлап, үзе дә мөстәкыйль рәвештә әсәрләр иҗат итә башлады. Шамилнең тормыш юлдашы Наилә ханым да музыкадан югары белем алган кеше. Хәзер ул Ленинград консерваториясенең аспирантурасында укый. Скрипкачы Тамбулидидан васыять булып калган, өйдә кадерләп саклана торган тылсымлы скрипканы ышанып тапшырыр куллар күренеп тора.

Төркстан якларындагы сугышлардан Оренбургка кайтып, 1920 елда Салих Сәйдәшев үзенең беренче әсәрен — «Озын сәфәр»ен язып, халык йөрәгенә юл алды. Зур сәнгатькә сәфәр озын, авыр. Шамил Иҗат Иленә үз сәфәрен уңышлы башлады. Армый-талмый башлаган эшен дәвам итсен иде ул, халык күңелен баетырлык әсәрләр белән сөендерсен иде! Бездән теләк шул.

*1977, июль*

# ИХТИРАМ ТУДЫРА

Яңа театрыбызны күргәч, куанып үткән шикелле, Горький урамындагы иске бина яныннан узганда да үзгә бер дулкынланулы тойгылар кичерәсең, татлы хатирәләр искә төшә, күңелне сагыш биләп ала. Театр алкышлардан гына түгел, сагышлардан да тора шул. Кемнәр бар да, кемнәр юк!.. Әле мин белгәннәрдән генә — бар иде гаҗәеп шәхес-артистлар Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиковлар, ике Гөлсем — Камская һәм Болгарскаялар, Галимә Ибраһимова, Галия Булатова, Фатих Колбарисовлар... Тагын бар иде әле безнең өчен, әдәбият кешеләре өчен аерата кадерле кешеләр, кабатланмас шәхесләр Габдулла Шамуков, Хәким Сәлимҗанов... Болары белән бер күрешү үзе бер гомер иде. Кирәк — тарих турында, кирәк — әдәбият турында сөйләш, кирәк — милли культура тарихындагы олы шәхесләрнең язмышын сораш... Менә шундый күпкырлы, күңелләре халык рухының төрле якларын колачлаган өлкәннәрнең эшләрен яңа заманда дәвам итүчеләр бармы? Бар. Барын бар алар, әмма, күп түгел — берән-сәрән генә. Шуларның берсе итеп, чагыштырмача яшьрәк буын артистлар вәкиле Илдус Әхмәтҗановны санар идем мин. Соңгы елларда җәмәгатьчелекнең театрыбызга игътибары көчәйгән чорда, аның бүгенге вәкилләре, инде сыналып һәм танылып өлгергән яшь талантлары турында сүз әйтү, табигый булыр.

Илдус Әхмәтҗановның зур сәхнәдә иҗат эшчәнлеген башлавына да инде ун елдан артык. Ленинградтагы театр, музыка һәм кинематография институтын 1973 елда тәмамлап, академия театрына кайтты. Беренче зур роле Р.Батулланың «Өчәү юлга чыктык» әсәре буенча куелган спектакльдә актерның үзе шикелле, әле яңа гына институт тәмамлап, хезмәт юлын башлаган журналист роле иде. Драматургның да академия театрында куелган беренче әсәре, төп рольләрнең берсен башкаручы Илдусның да юл башлавы, тагын башка артистларның да (Ш.Бариев, Ш.Галиуллин) беренче чыгышлары иде. Дулкынланулар да, «бу яшьләр ни күрсәтер?» дип сынап караучылар да, һәр уңышка ихлас сөенгән тамашачылар да җитәрлек булды ул вакытта. Спектакльне оештырган, сәхнәдән торып уйнаган кешеләр, белмим, үз эшләреннән ни дәрәҗәдә канәгать булганнардыр, әмма тамашачылар яшь артистларны танып, хәтерләп, үз итеп калдылар. Шул көннәрдән башлап бүгенгә кадәр Илдус Әхмәтҗанов олы сәхнәдә утыздан артык роль башкарган икән инде. Бөтенесенә дә шаһитмын



*Илдус Әхмәтҗанов Тукай ролендә*

дип әйтә алмыйм, әмма күргәннәре, хәтергә сеңеп калганнары да шактый. «Канлы күләгәләр»дә (Г.Боровик) үз халкының намусын чагылдырган яшь эшче Педро, «Ак калфак»та (М. Фәйзи) инсафлы җырчы егет — Бакый, «Банкрот»та (Г.Камал) Закир, «Һаваларда йолдыз»да (М.Горький) Алексей Пешков, «Болан патша»да (К.Гоцци) Тарталья, «Яшь йөрәкләр»дә (Ф.Бурнаш) Галимҗан... Төрле елларда иҗат ителгән бу рольләр хакында театр тәнкыйте елъязмасы сәхифәләрендә уңай фикерләр мул теркәлеп калган. Шулай да актерның соңгы еллардагы иң зур уңышы итеп «Без китәбез, сез каласыз»да (Т.Миңнуллин) Тукай роле. Бөек шагыйрь булып уйнау байтак артистның хыялыдыр ул. Бу очракта теләк кенә җитми, ә бөеклекне гәүдәләндерер өчен тышкы һәм эчке бөтенлек, рухи куәт кирәк. Миңа калса, И.Әхмәтҗанов бу олы миссияне бик уңышлы башкарып чыкты, автор һәм режиссер теләгән, тамашачылар көткән образ иҗат итте. Тукайның 100 еллык бәйрәменә килгән Мостай Кәримнең спектакльне карагач әйткән сүзләре хәтергә килә: «Тукай ролен башкаручы Илдус Әхмәтҗанов яхшы уйный. Тукай — тормышчан, ышандыра. Артист шагыйрь образын әдәпле итеп, югары культура күрсәтеп башкарды. Мин тере Тукайны күрдем». Бу уңыш, әлбәттә, очраклы түгел; артист бу рольгә зур әзерлек белән килде. Моннан ун ел элек үк инде ул телевизион спектакльдә («Яз сулышы» — Ә.Зарипов) Тукай образын бер гәүдәләндереп күрсәткән иде. Ул гына да түгел, Тукай иҗатын төбенә төшеп өйрәнеп, аның шигырьләре буенча махсус программа төзеп, үткән ел Актерлар йортында махсус кичә

ясады. Өстәвенә үзенең дә шигърияткә турыдан-туры катнашы барын — шигырьләр язуын да искә алсак...

Без һәммәбез дә тумыштан тел, аваз җәһәтеннән өлешсез калмасак та, табигать аерым кешеләргә тавышны аһәң һәм көч ягыннан сайлабрак биргән. Чиста, көчле, төрле төсмерләргә бай, кешелекле тавыш һәрчак сокландыра. Нәфис сүз сөйләүче артистмы, радио яки телевидение дикторымы, яки халык алдына чыккан лектормы — аның яхшы мәгънәсендәге хезмәт карьерасы табигать бүләге — тавышы белән бәйле. Радиода бар иде Камал апа Саттарова, Рим Кәримов, телевидениедә Иркә Сакаева... Шөкер, тавышлары сирәгрәк яңгыраса да бар әле Эльс Гаделев, Әминә Сафиуллина, Фоат Галимуллин... Ничәмә дистә ел буе поэзиябез көчен ил мөнбәренә күтәргән мәшһүр Айрат Арслановыбыз бар. Саналганнарның күбесе инде үткәнебезгә карый. Ә киләчәккә өмет багларлык яшьрәк талантлар, кызганычка каршы, теләгәннән күпкә аз. Күпгасырлык тирән фикерле, матур яңгырашлы шигъри үрнәкләребезне телеэкраннан яки эфирдан, яисә сәхнәдән сәнгатьле тел белән укый алырлык затлы тавышлы кешеләрне сирәк күрүдән гаҗизбез. Бу җәһәттән мин янәдән Илдус Әхмәтҗановка зур өмет баглыйм. Шигъриятебезнең хак сүзен күп меңнәргә ишеттерерлек эчке рухи байлык та, көчле һәм ягымлы тавыш та, чама хисе дә, буй-сын да бар аңарда. Зур залларда берничә мәртәбә тыңлаганым булды. Мәскәүдәге әдәбиятчыларның Үзәк йортында Кол Галинең 800 еллыгы уздырылганда, Тукайның 100 еллыгы уңае белән Колонналы залда үткән тантаналы кичәдә... Аның башкаруында безнең әдәбият көчле һәм горур яңгырый. Илдус телевидение аша «Кырыгынчы бүлмә»не укыгач, ул вакытта шифаханәдә яткан шагыйрь Сибгат Хәким: «Тукай бәйрәмендә беренче тапкыр катнаша алмадым. Илдус Әхмәтҗанов минем берүземә Тукай бәйрәмен ясады...» — дип язды. Безнең белүебезчә, Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын бары тик атаклы Хәким Сәлимҗанов кына сәхнәдән сөйли ала иде. И.Әхмәтҗанов әлеге әсәр буенча быел әдәби театр иҗат итте һәм ул телевидение аша кат-кат күрсәтелеп, мәдәни тормышыбызга үзеннән бер нур өстәде. И.Әхмәтҗанов турында сөйләгәндә, аның әдәби процесстагы конкрет эшләрен дә искә алмау дөрес булмас. Кайбер остазлары кебек, ул менә дигән тәрҗемәче дә. «Мәхәббәт мажаралары» (Лопе де Вега), «Капкан саен калҗа булмас»(А.Н.Островский), «Алтын чеби» (В.Орлов) пьесалары аның тәрҗемәсендә (беренчесе шигырь калыбында тәрҗемә ителгән) республикабызның

төрле театрларында уйналып килә. Актер сәхнәдә уйный, нәфис итеп укый, әдәби әсәрләр тәрҗемәли, шигырь яза... Шәп бит бу! Халыкның күпкырлы рухи культурасын күпмедер дәрәҗәдә үзендә йөртү, аның варисы һәм хуҗасы булу дигән сүз бит бу! Тар һөнәр иясе, хәтта шул һөнәрнең остасы булу белән бергә, иҗатның бүтән өлкәләрендә үз булып фикер әйтә алу — ихтирам тудыра. Бар иде Җәүдәт ага Фәйзи. Менә дигән көйләр язды ул һәм шул ук вакытта әдәби һәм фәнни китаплар чыгарды. Әдип-композитор иде. Бар Бакый ага Урманчебыз. Үзе сыннар коя, рәсем төшерә, үзе шигырь чыгара, үзе җырлый, үзе тарих сөйли... Андыйлар белән бер әңгәмәләшеп утыру ни тора!

Сүземне театр корифейларының берсе булган Габдулла Шамуков кебек шәхесләрне сагыну хисләре белән башлаган идем. Әйе, сагындыра алар, бик сагындыра. Өмет — Илдус Әхмәтҗанов кебек талант ияләрендә. Халык рухының, культурасының төп тамыры — әдәбиятка тоташкан булу беркайчан да нәтиҗәсез булмас.

*1986, декабрь*

# МӘҢГЕЛЕККӘ КАЛСЫН МИЗГЕЛЛӘР



*Рифхат Якупов. 1999*

Һәр чын иҗатчы үз заманының сурәт-образын ясап калдырырга омтыла. Һөнәренә карап һәркайсы үзенчә: берәүләр — сүздә, берәүләр — төстә, берәүләр — авазларда, берәүләр — мизгел-кадрларда... Ах, ул тоттырмас кош кебек кабатланмас кирәк мизгел! Табигый да булсын, чын да, матур да, тарихи дөрес тә! Шуңа да фото сәнгатен тикмәгә генә четерекле, бик нечкә сәнгать димиләр бит! Объектив (хәзер искитмә бәяле фотообъективлар бар!) төшерер ул, — нигә төбәсәң, шуны төшерер... Чын сәнгать әсәре туар өчен объектив-пыяла белән бергә үткен акыллы күз, шуңа өстәп, күңел күзе кирәк шул! Бусы инде — олы иҗатчылар шөгыле, алар миссиясе. Рифхат Якуповны мин шундый Оста дип саныйм.

Парадокс: тормышта кешене яхшы белсәң, гел аралашып торсаң, аның турында язу кыен; информациядән, күргән-белгәннәрдән туган кичерешләр ташкыны төп контурны — аңа гына хас төп сыйфатларны билгеләүгә комачаулый. Кырык еллап беләм мин Рифхатне. Университетта бер чорда укыдык, бер бүлмәдә тордык, бер чорда иҗат итә башладык, беренче гонорарларны бергә «юдык»... Шулай да шәхеснең кайбер штрихларын шәрехләп карыйм.

Интеллигент. Үз эшенә фанатикларча бирелгән. Максатчан үҗәт. Хезмәтен бүгенге дөнья казанышларына карап бәяли. Милли рухлы. Чын профессионал... Әйтелгәннәрне дәлилләр белән ныгытып үтик. Аның (татар егетенең!) шәхси күргәзмәләре Европа илләренең зур шәһәрләрендә әледән-әле булып тора (Казан. Татарстан. 1982; Тампере. Финляндия. 1990; Стокгольм. Швеция. 1991; Люблин. Польша. 1994; Симферополь. Кырым. 1995; Берлин. Германия. 1995; Пертшах. Австрия. 1997). Гомум халыкара күргәзмәләрдә дә (Гаага. Голландия. 1978; Мәскәү, 1980; Памплона. Испания.

1982; Оксфорд. Англия. 1986; Рочестер. АКШ. 1991) аның эшләре күрсәтелде. Турыдан-туры авторы Р.Якупов булган фотоальбомнар: «Казан» (1976), «Сабантуй» (1979), «Совет Татарстаны» (1980), «Г.Камал исемендәге театр» (1996)... Әйе, эшләнгән эшләр байтак. Алар — колачлы һәм эчке мәгънәсе белән тирән хезмәтләр.

Сәнгатьтә үз эшләрен камил белгән профессионаллар аз түгел. Алар, гадәттә, махсус гали белем алганнар, югары осталык мәктәбе узганнар. Дөньяның теләсә нинди почмагында үз ишләре белән иркен аралаша, яши һәм иҗат итә алалар. Мин моны музыка, рәсем яисә театр-тамаша өлкәсендә үзем белгән кешеләрдән чыгып әйтәм. Әмма, кызганыч, аларның кайберләрендә (күбесендә булмаса!) анык бер кыйбла, инанган иман, милли рух булмый. Ә Р.Якупов иҗаты бу яктан ничек соң? Мондый сорау тууы табигый дә, чөнки ул Татарстанда тумаган, совет чоры мәгънәсендәге интернациональ мохиттә үскән, рус мәктәпләрендә укыган... Ни гаҗәп: ул — генетик рухны югалтмаган, татар җирлегенә тирән тамырланган Оста. Күрәсең, гаиләдә милли традицияләр нык булган. Үз вакытында Казанга килеп, югары белем алу, татар тарихын өйрәнү, иҗат кешеләре белән якыннан аралашу, соңгы 5–6 елда Кырымда яшәү аңа төрки, аерым алганда татар дөньясын аңларга, һичшиксез, шифалы булган. Дөнья күрелгән, «лаеш шулпасы эчелгән», нәтиҗәләр ясалган, иҗатта ориентирлар ачыкланган...

Рифхат Якупов — бүгенге көндә югары иҗат үсешенә ирешкән фотохудожник. Хыял-ниятләре зурдан. Ул — татар халкының төрлесен — казанлыларның, себерлеләрнең, нижгарлыларның, кырымлыларның, чит илдәгеләрнең һәммәсен берләштерелгән зур альбом-атлас чыгарырга әзерләнә. Нияте тормышка ашса, Казанның 1000 еллыгына үзенчә зур бүләк булачак ул. Бер генә теләк: ул зур хезмәттә халкыбызның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген чагылдыра алган сәламәт рухлы, көчле характерлы, күзне иркәләрлек типаж-образларны (бу заманның әллә нинди тискәре типажлары да җитәрлек!) күбрәк күрәсе килә. Бүтән халык вәкилләре сокланырлык, үзебез горурланырлык булсын!

*2000, февраль*

## КИЛӘЧӘГЕБЕЗ — БИШЕК ҖЫРЫНДА

Гаҗәп: дөньяда күбрәк яшәгән саен сораулар арта гына бара. Болары, дөрес, сабый чактагыча, дөньяны танып белү чорындагы «бу нәрсә?», «ник алай?» кебек сораулар түгел инде. Таный алган кадәр танылды, беләсе беленде... «Кая бара дөнья?», «Киләчәктә ниләр көтә?», «Балаларыбыз безнең дәвамчылар булырмы?» кебек сораулар бимазалый хәзер... Иҗатның, язуның мәгънәсе дә, асылда, шуларга җавап эзләү. Хакыйкать, хак җавап эзләп артык гасабилансаң, үз уй-гамьнәреңдә буталып-чәбәләнеп, үрмәкүч җәтмәсенә эләккән чебен хәлендә калуың да бар... Шулай булмасын өчен, уй-фикерләреңне бүлешерлек, эч бушатырлык кешеләрең булу кирәк. Бүтәннәрне белмим, минем ни хикмәттер андый кешеләр, күбрәк хатын-кызлар була.

...Роза ханым Туфитулова белән дөнья хәлләре турында әңгәмәләшеп утырабыз. Тәгаенләгән темабыз юк, төрлесен сөйләшәбез: үткән гомерләр, кичкән вакыйгалар, балалар турында... Таныш-белешләрне барлыйбыз, кем — исән, кем — гүр иясе... Күбрәк — хатирәләр. Бер даирәдә, байтак еллар бер үк бинада, кырык еллап аралашып яшәлгән шул. Үзе бер гомер бит! Мин белә башлаганда, ягъни алтмышынчы еллар башында Зәйнуллина фамилияле япь-яшь студентка кыз иде әле ул. Матбугат йортына — әдәби берләшмә утырышларына килгәләгәнен хәтерлим. Күрәсең, хыялында язучы булу теләге дә яткандыр. Яшь, чибәр, чая, ә күзләрендә ниндидер серле моң... «Бәлки, төп җегәрне язу эшенә салырга кирәк булгандыр, шулай килеп чыкты инде: гомерем тулысы белән диярлек җәмәгать эшендә сарыф ителде» — дип әйтеп куйды Роза. Зур күзләренә багып алам: канәгатьлек белән әйтәме, горурланыпмы, офтаныпмы? — белеп булмый.

Гомерләрен җәмәгать эшенә (күпмедер дәрәҗәдә «казна эшенә» дип тә әйтеп буладыр) багышлаган хатын-кызлар бар алар. Элек тә булган, хәзер дә бар, булырлар да. Күп яктан уртаклыклары булса да, һәркайсының үз язмышы, үз миссиясе, үз бәхете, үз сагышлары... Үзем күреп белеп, азмы-күпме аралашкан шәхесләрне искә төшерәм: Садия Беглова, Дания Дәүләтшина, Асия Хәсәнова, Зилә Вәлиева, Флера Зыятдинова, Фәридә Гайнуллина... Бөек галим Риза Фәхретдиннең үткән гасыр башында чыккан «Мәшһүр ханымнар» исемле атаклы китабы бар. Ул анда мөселман дөньясының, шул исәптән төрки-татар кавеменнән чыккан данлыклы хатын-кызларның исемнәрен теркәгән, алар турында шактый

тулы мәгълүмат биргән. Галим исән булса, мондый библиографик хезмәтенә бүгенгеләрдән кемнәрне кертер иде икән?

> *«Бүгенге сабый нинди тәрбия күрсә, иртәгәсе көнебез дә шундый булыр. Безгә милләтне милләт итәрдәй асыл сыйфатларга ия булган яңа буыннар кирәк. Дөньяга килгән һәр сабый гаилә тотрыклыгы өчен, нәселне дәвам итәр өчен генә түгел, дәүләт иминлеге, дәүләт тотрыклыгы өчен дә кирәк!»*

Роза Рәхмәтулла кызы Туфитулова гомеренең төп өлешен журналистлык хезмәтенә һәм җәмәгать эшенә багышлады. Егерме елдан артык төрле басмаларда баш мөхәррир вазифасын башкарды. Ә җәмәгать эше дигәндә, ул — Бөтентатар хатын-кызларының «Ак калфак» ассоциациясен оештыручы һәм аның беренче рәисе (1992–2002), Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары (1992–2002), Татарстанның Дәүләт Советы депутаты (1999–2004)...



*Роза Туфитуллова (алгы рәттә сулдан икенче) — «Яшь ленинчы» газетасының баш мөхәррире. 1980*

*«...Заманында башка халыкларның телен, мәдәниятен, аңын үстерүгә ярдәм иткән татар кешесе, татар хатын-кызы нигә бу чаклы таланып калды соң? Нигә башка милләтләр эчендә эреп, югалып ята ул?»*

«Хатын-кызның үз хокуклары чикле җәмгыятьтә бөтен милләт хокукларын яклап көрәшелде», — ди Роза. Чыннан да шулай бит. Тарихка борылып карыйк: халык язмышының иң кыен, иң фаҗигале көннәрендә көрәшнең алдынгы сызыгында һәрчак хатын-кызларыбыз булган. Сөембикә-ханбикә заманнарыннан бирле шулай килә. Моннан унбиш еллар элек — 90 нчы еллар башында ил хакын хаклап ак яулыклы әбиләребез, әниләребез, хатыннарыбыз, сеңелкәшләребез урам-мәйданнарны иңләп күтәрелеп чыкмадылармы? Көрәшнең төрләре күп: берәүләр — көч белән, берәүләр — хис, берәүләр — акыл белән...

*«...Татар хатын-кызы язмышы хакында уйланганда, халкыбызның йөрәгеннән кан саркыткан катнаш никахлар хакында да уйланмый мөмкин түгел. Мондый гаиләләр кимүгә бармый. Ә бит татар мохитен тудыруда, яшәтүдә гаилә башкарасы эшләрне бер генә оешма да эшли алмый. Күпме генә сөйләнсәк тә, лаф орсак, мактансак та, татар язмышын сәясәтчеләр, мәгърифәтчеләр генә хәл итә алмый. Татарның киләчәге иң әүвәл ана карынында, бишектә, гаиләдә хәл ителә».*

Журналыбызның яңа чыккан саннарының берсендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең мондый юлларына тап булдым. «Казан шәһәрен хатын-кызларның хәер-догасы, рәхим-шәфкате яклап һәм саклап киләдер, дип уйлыйм. Милләтебезне халык күңелендәге Сөембикә рухы гасырлар буе яшәтеп килде. Ул XX гасыр башында Казанда чыга башлаган «Сөембикә» журналы булып гамәлләшсә, 90 елларда сөекле журналыбыз шушы изге исемне кире кайтарып һәм Сөембикә милләтебез киләчәген кабат үз канаты астына алды». Өстәп шуны гына әйтәсе килә: журналның төп исеме — «Сөембикә»не Роза Туфитулова кайтарды. Кемнәрдер өчен әһәмияте әллә ни булмаган бу фактның үзенең гыйбрәтле тарихы бар. Ул вакытта үзләрен дөнья кендеге санаган кайбер түрәләрнең мәгънәсез каршылыгын җиңү өчен байтак көрәшергә туры килде Роза ханымга... Иҗтимагый эшчәнлегенең күпсанлы сәхифәләреннән бер генә мисал бу.

Озак еллар баш мөхәррир булды, дидек; ун еллар «Яшь ленинчы»да (хәзерге «Сабантуй»), берничә ел «Ялкын» журналында, ун елдан артык «Азат хатын» («Сөембикә») журналында. Әле бит баш мөхәррирлеккә кадәр күпме эшләргә, күпме баскычлар үтәргә кирәк! Күрәбез, Роза Туфитулованың бөтен иҗтимагый эшчәнлеге балалар һәм аналар дөньясы белән бәйләнгән. Аналар һәм балалар бөтен яшәешебез мәгънәсен тәшкил итә түгелме соң! Димәк, юл дөрес сайланган, гомер изге максатка багышланган. Мөхәррир һәм җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитулованың халык күзе төшәрлек кайбер хезмәт-гамәлләрен искә төшерергә тырышам.

Шуларның берсе — «Олы Мәңгәр—гомер бишегем» исемле китап. Латыш журналисты Андрис Спрогис белән берлектә язылган китап. Олырак буын кешеләренең кайберләренә, бәлки, мәгълүмдер: Ватан сугышы елларында йөзләгән латыш балаларын Татарстан җире — Әтнә районының Олы Мәңгәр авылы сыендыра. Тетрәндергеч язмышлар сәхифәсе... Китап, ялгышмасам, латышча һәм русча да чыкты.

Депутат буларак, парламент трибунасыннан ясаган чыгышлары хәтердә. Исән-имин кала алуыбызның төп нигезе-сәбәбе булган демографик хәлләр, татар гимназияләренең язмышы, катнаш никахлар, бүгенге татар хатын-кызының иҗтимагый тормышта үсеш мөмкинлекләре (бу очракта, 2000 елларда безнең яктан сайланган депутат буларак, Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш урта мәктәбенең—заманында үзем дә укыган мәктәбемнең яңа бинасын салуда керткән өлешен рәхмәт хисләре белән искә алам)...

Роза Туфитулова «Ак калфак» җитәкче булган елларда халык күңелендә эз калдырган «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» дип исемләнгән конкурс-тамашалар... Алар башкалабызның иң матур залларында гөрләп уза иде...

— Ярый, Сөембикә исеме журналга кире кайтарылды. Җәмәгатьчелеккә синең һәм синең тарафдарларыңның Сөембикә исеме белән бәйле матур тәкъдимнәрегез дә бар иде бит. Казанның үзәк урамнарының берсенә Сөембикә исемен бирү, аңа һәйкәл кую һ. б.

— Бу гамәлләр Казанның 1000 еллыгы уңае белән хәл ителер дип өметләнгән идек. Кызганыч, без хыялланганнар әлегә тормышка ашмады. Рәхмәт, университет абсерваториясе галимнәренә — үзләре ачкан бер йолдызга Сөембикә исемен бирделәр. Галәмдәге йолдыз яктылыгы әкренләп безнекеләрнең дә күңеленә төшәр әле! Гомумән, Сөембикә безнең халыкның тарихи бер рухи символы. Халыкның үзаңын

үстерүдә андый шәхесләрнең, андый символларның хакыйкый ролен дөрес аңларга бик вакыт безгә.

*«Асылыбызга кайтыр өчен, меңьеллык тарихыбызны каныбызга сеңдерер өчен яңа буыннар кирәк. Милләт язмышын үз кулына алырдай яңа буын саф милли гаиләләрдә генә туа, үсә, ныгый ала. Баланың яшәү рәвешен, телен, иманын иң әүвәл һәм гомерлеккә дип әнкәсе сеңдерә».*

Табигать тарафыннан билгеләнгән илаһ миссиясен башкарырга, ай, җиңел түгел хатын-кызга! Авырлык белән алынган биеклекне тою, җиңү кичерүнең, бәлки, шатлыгы, ләззәте зуррактыр?.. Шулай дип уйлыйсы, юанасы килә. Күрәсең, беләсең, чагыштырасың да, бөтен вөҗүдең белән сөенеп куясың: фидакарь һәм талантлы хатын-кызлар күп бездә! Яшәешнең һәр өлкәсендә — фәндәме, сәнгатьтәме, идарә эшендәме — йолдыз булып калыккан олуг шәхесләре бар.

*«Бүген саф татар гаиләсендә дә ир-атка, гаилә башлыгына кытлык. Атасыз бала тудыру очраклары көннән-көн арта бара. Бүген татар гаиләсендә әби-бабай тәрбиясенә урын бик аз калган. Кысыр гаиләләрнең елдан-ел саны артуы күзәтелә. Татар гаиләсендә дә бүген эчкечелек гадәти күренешкә әйләнде. Наркомания дә аны читләтеп үтми. Хатын-кызларыбыз тарафыннан яңа туган сабыйларны ташлап калдыру яки асрамага бирү гадәти хәл санала. Татарда гомер-гомергә мактаулы изге эш саналган яучы-димче институты тулысынча юкка чыккан. Халкыбызның мәшһүр кендек әбиләрен, акъәбиләрне сагынып искә алырга гына калды. Бүген гаилә кормый яшәүче сазаган кызлар, буйдак егетләр күплеге дә милләт файдасына түгел. Инде алда әйтеп үзганымча, катнаш никахларның саны кимүгә бармый. Мондый гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның 6% гына милләте татар дип языла. Ә бала тудыруга килгәндә, Россиядә 1000 кешегә алып исәпләгәндә 8,6 бала, Татарстанда 9,8 бала туры килә. Татарстанда да менә икенче ел инде үлүчеләр саны туучылар саныннан артып китте. Дөньяга килүче сабыйларның бары тик 10% гына сәламәт булып туузын искә алсак, әлеге саннар милләтнең һәлакәткә баруы хакында кисәтүче саннар».*

Эчке хисемне сизгәндәй, Роза ханым дәвам итә:

— Халык кадәр халыкның мәшһүр ханымнары байтак инде ул. Замандашларыбызның кайберләрен генә искә төшерик: Сара Садыйкова, Мөнирә Булатова, Диләрә Тумашева, Мәдинә Рахманкулова, Флора Әхмәтова-Урманче, Венера Шәрипова, Нинель Юлтыева. Минемчә, Риза хәзрәт Фәхретдин бу исемнәрне үзенең «Мәшһүр ханым»нар тупламасына рәхәтләнеп кертер иде.

...Без — берничә кеше — затлы сарай итеп салынган матур йорт болдырында утырабыз. Йөзләрдә — җәй ахыры кояшының үзгә җылылыгы, күзләрдә — бакча чәчәкләренең чагылышы, җанда — әңгәмә-аралашудан алынган канәгатьлек... Әйе, хатын-кыз, әгәр ул лаек икән, гөлбакчада яшәргә тиеш. Җәмгыять аңа лаек шартлар тудырырга тиеш. Киләчәк иң әүвәл Ана кешегә бәйле. Кемнәр үстерәбез? Алар безнең дәвамчыларыбыз булырмы? Барысы да хатын-кызның саулыгына, иманына бәйле.

...Яхшы кәеф, янда фикердәш җаннар булганда, әңгәмә вакыты сизелмичә дә үтеп китә. Хушлашыр алдыннан, йортка иминлек, бер-беребезгә исәнлек-саулыклар телибез, балаларыбызны телгә алабыз. Роза ханымның үзенең дә җиткән балалары, җиткән генә түгел, гаилә корган улы, кызы бар, оныклары бар. Шулай була торып, ничек киләчәк турында уйламыйсың, борчылмыйсың ди.

Замандашыбыз Туфан Миңнуллинның моннан ун ел элек язылган «Татар кызы» дигән нәсерендә мондый юллар бар: «Татар кызы, дигәндә мин һәрвакыт инсафлы, чибәр, акыллы, пөхтә, чая, сабыр, өзелеп ярата һәм яраттыра белгән асыл затларны күз алдына китерәм. Мин аларның ничә яшьтә икәнен санамыйм. Дөньяга күзен тутырып, сокланып һәм исе китеп карар яшькә җиткән япь-яшь гүзәлләр дә, тормыш арбасына җигелеп Җир шары өстеннән горур атлаучы затлы ханымнар да, заманның хәсрәт-кайгыларын, куанычшатлыкларын күңелләренә сыйдырып олыгайган мөлаем апалар да — барысы минем өчен Татар кызы!» Бу нәсерне автор Роза Туфитуловага багышлаган икән. Бу язманы укыгач, Роза ханым өчен горурландым, Туфанның шагыйрьлегенә сокландым. Моңа өстәп шуны гына әйтергә кала: туган көннәрең котлы булсын Татар кызы — хөрмәтле Роза Рәхмәтулла кызы Туфитулова!

*2005, 30 август, сентябрь*

# ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

## ВАТАН БУЛА БЕР ГЕНӘ!

**Яңа меңьеллыкка күчкәндә.** Бу баш исем астында ике публицистик мәкалә-язма урнаштырылган. «Кояш астында без дә бар» дигәне «Заман» (Халыкара иҗтимагый-сәяси, мәдәни газета) газетасында (2000, 47–48 саннар, 24 ноябрь, 1 декабрь) басылган. Беренче варианты «Гасыр йомгагын төенләгәндә» дигән исем белән «Казан утлары» журналында да (1999, 1 сан) дөнья күргән. «Иман безне ташламасын» — алдагы мәкалә-чыгышның дәвамы. Автор бу язмасында да татар милләтенең егерменче гасырдагы яшәү рәвеше, рухи-иҗтимагый тормышындагы үзгәрешләр турында уйланып, халыкның киләчәк язмышы хакында үзенең уй-фикерләре белән уртаклаша («Казан утлары», 2001, 1 сан).

**Йә, нишлибез, газиз каләмем?** «Баш мөхәррир сүзе» рубрикасында басылган («Казан утлары», 2004, 1 сан).

**Иле барның — теле бар.** «Казан утлары»ның үткән гасыр ахырында һәм XXI гасыр башында чыккан биш саны шагыйрьнең публицистик язмалары белән башлана. Эссе-уйланулар рәвешендә язылган бу хезмәт — әнә шуларның берсе («Казан утлары», 2003, 1 сан).

**Яңа елда яңарган уйлар.** «Баш мөхәррир сүзе» рубрикасында басылган публицистик язма («Казан утлары», 2002, 1 сан).

**Хәерле булсын бу көн!** 1990 елның 30 августы — Татарстан Югары Советының XI чакырылыш депутатлары һәм, гомумән, республика халкы өчен тарихи көн. Ул көнне Татарстан суверенитеты турында Декларация кабул ителде. 30 август көнендәге сессия утырышы депутат Равил Фәйзуллин чыгышы белән башлана. Шулай ук бу сессиядә депутат язучылар — Ф.Бәйрәмова, Р.Миңнуллин, Р.Вәлиев, Р.Мөхәммәдиевләр дә чыгыш ясый. Бу томлыкта

урнаштырылган язма — Р.Фәйзуллинның әнә шул чыгышы. Үз вакытында бу чыгыш-нотыкның сөземтәләре республика матбугатында дөнья күрә, ә тулы варианты «Казан утлары» журналында (1990, 12 сан) басылган.

**Яңача хуҗа булып яшик!** 1990 елда Татарстан Югары Советы тарафыннан суверенитет турында Декларация кабул ителгәч язылган мәкалә. «Татарстан яшьләре» газетасында (1990, 6 сентябрь) басылган.

**Битараф кала алмыйбыз.** Мәкалә «Ватаным Татарстан» газетасында (1991, 21 май) басылган.

**Хәлиткеч көннәр.** 1991 елның 12 июнендә Россиядә һәм Татарстанда Президентлар сайлау булып узды. Республикада сайлаучылар, Россия Президенты кандидатурасына аз тавыш биреп, күпчелек тавыш белән фәкать Татарстан Президентын гына сайладылар. Мәкалә әнә шул сайлаулар алдыннан язылган һәм «Ватаным Татарстан» газетасында (1991, 8 июнь) «Язмышыбыз хәл ителгәндә» дигән исем белән басылган.

**Иҗатка хокук.** 1978 елның март ахырында «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасы «Иҗат иреге» дигән темага «Түгәрәк өстәл» янында сөйләшү уздыра. Бу әңгәмә-сөйләшүдә әдипләрдән — С.Хәким, Р.Фәйзуллин, Б.Камалов, Ф.Сафин, Ш.Рәкыйпов, галимнәрдән — профессорлар И.Нуруллин, К.Фасеевлар катнаша. Күп тә үтми, шул сөйләшүнең кыскача язмасы «Социалистик Татарстан» газетасында (1978, 9 апрель) басылып та чыга. Р.Фәйзуллинның бу томлыкка кергән язмасы әнә шул газетадан алынды.

**Оят бит!** Мәкалә «Социалистик Татарстан» газетасында (1989, 10 август) басылып чыккан.

**Нәрсә мәгънәле дә, ни мәслихәт?** Дистә еллар буе килгән традиция буенча, 1993 елның гыйнварында язучыларның әдәби ел (1992) йомгакларына багышланган җыелышы уза. Әдипләрнең Тукай клубында үткәрелгән бу абруйлы җыелышында Р.Фәйзуллин да чыгыш ясый. Җыелыш материаллары татарның көндәлек матбугат битләрендә дә чагылыш таба. Томлыкта урын алган бу язма

«Ватаным Татарстан» газетасында (1993, 6 февраль) басылган текст буенча бирелә.

**Ул җәйдән бер хатирә.** 1998 елның 12 июнендә Балык Бистәсе районының кечкенә генә Үрнәк дигән авылында зур Сабантуй бәйрәме уздырыла. Авыл тарихында беренче мәртәбә уздырылган бу бәйрәмдә Казаннан һәм районнан байтак кунаклар, шул исәптән Р. Фәйзуллин да катнаша. Татар авылларының киләчәге турында уйланулардан гыйбарәт бу мәкалә «Ватаным Татарстан» газетасында (1999, 22 гыйнвар) басылган.

**Язучылар өчен дә мәктәп булды.** Казан университетының ачылуына 200 ел тулуга багышлап чыгарылган «Казанский университет» дип исемләнгән китапта басылды (Ягсуф Шафиков. Казанский университет. Казань: «Идель-Пресс». — С. 318–319.).

**Шаулап узды бөек бәйрәм.** Казанның 1000 еллык юбилее уңаеннан уйланулар. «Ватаным Татарстан» газетасында (2005, 18 ноябрь) басылган.

## КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

**Әдип исеме — олы исем.** Татарстан язучыларының VII съезды алдыннан «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») (1968, 14 март) газетасында «Съездны каршылап» дигән рубрикада басыла. Мәкалә үз вакытында шактый зур резонанс ала. Мәкалә Язучылар берлеге рәисе М.Әмир докладында һәм башка чыгышларда телгә алына.

**Үр артында яңа үрләр.** 1971 елгы татар поэзиясенә күзәтү итеп язылган бу хезмәт иң әүвәл язучыларның Г. Тукай клубында (1972, февраль) — ел йомгаклары җыелышында шигърият буенча махсус доклад рәвешендә укыла. Соңрак «Казан утлары»нда (1972, 6 сан) басылган.

**Без әзерме?** «Татарстан яшьләре» (1975, 18 март) газетасында басылган.

**Шигъриятебез турында.** Татарстан язучыларының VIII съездында ясалган чыгыш. Соңрак, «Югары идеяле поэзия өчен» дигән исем белән, «Казан утлаыры» (1974, 10 сан) журналында басылган.

**Съезддан соң.** «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1975, 5 март) газетасында басылган.

**Тарихи мирас аша — киләчәккә.** «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1978, 4 февраль) газетасында басылган.

**Юлларда туган уйлар.** «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1984, 20 май) газетасында чыккан.

**Сүз көче.** Татарстан язучыларының XII съездында (1994, июнь) ясалган чыгыш. Соңрак «Казан утлары» (1994, 8 сан) журналында басылган.

**Рухи тормышыбыз көзгесе.** «Казан утлары» журналының 50 еллык юбилее уңае белән язылган. «Журналның үз архивын булдырыйк!» дигән исем белән «Казан утлары» (1972, 5 сан) журналында басылган.

**Журнал язмышы — безнең язмыш.** «Казан утлары»ның 60 еллыгы уңае белән язылган мәкалә («Казан утлары», 1982, 5 сан).

**Хәлләребез, шиксез, яхшырыр.** «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1990, 16 октябрь) газетасында басылган.

**«Казан утлары» — безнең юл.** Журналның 70 еллык юбилее Бөтендөнья Татар конгрессы (I конгресс) программасы кысасында Г. Камал театрында тантаналы рәвештә үтте. Мәкаләнең тезислары шул кичәдә яңгырады һәм мәкалә үзе «Казан утлары» (1992, 5 сан) журналында басылды.

**Рухи елъязмабыз.** «Казан утлары» журналының 75 еллыгы уңаеннан язылган мәкалә («Казан утлары», 1997, 5 сан).

**«Безнең заман герое».** 2004–2005 елларда «Казан утлары» журналында «Безнең заман герое» дигән темага дискуссия уздырылды. Мәкалә шул уңай белән язылган. Беренче тапкыр басыла.

«Казан утлары» журналының 80 еллыгы уңаеннан шул ук журналда («Казан утлары», 2005, 5 сан) басылган.

**Сүз — болын, җыр — чәчәк.** Шагыйрьнең 1996 елда «Мәгариф» нәшриятында «Җил — Вакыт ул» дип исемләнгән кыска шигырьләр китабы чыга. Бу мәкалә әнә шул китапка кереш сүз итеп язылган.

**«Мәйдан»га — киң мәйдан.** — 2001 елның августында Чаллыда «Мәйдан» дип исемләнгән әдәби журнал чыга башлый. Теләк-тәбрик рәвешендә язылган бу язма шул журналның беренче санында басылган.

**Гыйбрәтләр алырлык үткән юл.** Күләмле бу хезмәтнең икенче исеме — «Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар». XX гасыр әдәбиятына гомумкүзәтү ясала; аерым чорларга, үсеш-яңару тенденцияләренә, әдип-шәхесләргә бәя-мөнәсәбәт белдерелә; шул чор әдәби хәрәкәтенең үзенчәлекле панорамасы күз алдына китерелә. Хезмәт «Казан утлары» журналында (2004, 8–9 саннар) дөнья күрә, шул ук елны аерым китап («Идел-Пресс» нәшр., 2004. — 152 б.) булып басыла.

**Киләчәк өчен эшләргә тиешбез.** Равил Фәйзуллинның Татарстан язучыларының XV корылтаенда ясаган чыгышы. «Казан утлары» журналында (2005, 9 сан) басылды.

## КЕМНӘР БАР ДА, КЕМНӘР ЮК...

**Горурлыгыбыз.** Р.Фәйзуллин бөек сынчы һәм рәссам Бакый Урманче (1897–1993) белән рухи дус, фикердәш булып яшәгән әдип. Б.Урманче үз вакытында шагыйрьнең портретын да иҗат иткән иде. Мәкалә Б.Урманчега 90 яшь тулу уңае белән язылган, «Татарстан яшьләре» газетасында (1987, 21 февраль) басылган.

**Сагындыра торган шәхес**. Салих Сәйдәшевнең (1900–1954) тууына 90 ел тулу уңаеннан бу язма «Яшь ленинчы («Сабантуй») газетасында (1990, 6 декабрь) басылган.

**Бер рәсемгә карап...** Равил Фәйзуллин 1980 елда укучыларга яхшы мәгълүм «Сәйдәш» поэмасын тәмамлый. Шул ук елның 14 маенда шагыйрь аны, сынау һәм таныштыру максатыннан, әдәбият һәм сәнгать вәкилләренә укып күрсәтә. Язучыларның Тукай клу-

бына (Бауман ур., 19) язучылар, композиторлар, сәнгать белгечләре — җыенысы 250 ләп кеше җыела. Хатирә рәвешендә язылган бу язма «Татарстан» журналында (2000, 10 сан) дөнья күргән.

**Әдип-композитор.** Мәшһүр композитор Җәүдәт Фәйзи (Җәүдәт Фәйзуллин) (1910—1973) шәхесе һәм иҗатына багышланган бу мәкалә иң әүвәл «Ялкын» (1980, 6 сан) журналында басыла, соңрак шагыйрьнең «Җырларда — ил гаме» китабында (1984) урын алган.

**Ак рояль хуҗасы.** Бу хезмәт 1990 елда языла, «Казан утлары» журналында (1991, 1 сан) басылып чыга. 2001 елда композитор Нәҗип Җиһановның (1911—1988) тууына 90 ел тулды һәм шул уңайдан бөек музыкант турында махсус китап дөнья күрде. Мәкаләнең кыскартылган русча варианты әнә шул китапка да кертелгән.

**Шигъри җанлы галим.** Фольклорчы галим Илбарис Надировка (1925) багышланган бу мәкалә «Казан утлары» журналында (2000, 4 сан) дөнья күргән. Биш елдан соң мәкаләнең икенче өлеше языла һәм ул шул ук «Казан утлары» журналында (2005, 4 сан) басыла.

**Хәзинәләр хуҗасы.** Академик Әбрар Кәримуллинга (1925—2000) багышланган бу мәкалә «Социалистик Татарстан» газетасында басылган.

**Тел сагында тора солдат.** Вахит Хаков (Хаков Вахит Хөҗҗәт улы, 1926 елда туган) — күренекле тел галиме. Казан университеты профессоры. Заманында, 60 нчы еллар башында, татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентларына, шул исәптән Р.Фәйзуллинга лекцияләр укыган остаз. Мәкалә В.Хаковның 60 яшьлек юбилее уңаеннан язылган һәм «Татарстан яшьләре» газетасында (1986, 26 август) басылып чыккан.

**Аның яшәү рәвеше.** Тарихчы галим, академик Миркасыйм Госмановның (Усманов) (1934) тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә багышланган бу мәкалә «Казан утлары» журналында (1994, 5 сан) басылган.

**Әле без һаман да замандаш.** — Тарихчы-археолог Равил Фәхретдинов (1937) турында матбугатта автор ике тапкыр язып чыга. Беренчесе — «Адаш — замандаш» дигәне «Социалистик Татарстан» газетасында (1987, 14 март) басылган, икенчесе — бу томлыкка кергәне — «Татарстан» журналында (1997, 1 сан) дөнья күргән.

**Нарасый хәким.** Рәссам һәм сынчы Әхсән Фәтхетдинов (1939) белән шагыйрь Равил Фәйзуллинны берничә дистә еллар дәвам иткән зур иҗади дуслык бәйли. Ә. Фәтхетдинов шагыйрьнең кыска шигырьләрен агачка уеп илледән артык сәнгать әсәре тудырган сынчы. Р.Фәйзуллинның Әхсән Фәтхетдиновның 60 еллык юбилее уңае белән язылган бу мәкалә «Казан утлары» журналында (1999, 6 сан) басылган.

**Сәфәр башы.** 1977 елда язылган бу мәкалә композитор Шамил Шәрифуллин (1949) иҗатының башлангыч чорына багышланган. Язма «Азат хатын» («Сөембикә») журналында (1977, 9 сан) басылып чыккан.

**Ихтирам тудыра.** Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты И.Әхмәтҗанов (1950) иҗатының башлангыч чорына багышланган бу язма «Социалистик Татарстан» газетасында (1986, 28 декабрь) басылган.

**Мәңгелеккә калсын мизгелләр.** Фотохудожник Рифхат Якупов (1944) иҗаты турында бу кечкенә күләмле хезмәт «Татарстан» журналында (2000, 8 сан) дөнья күргән.

**Киләчәгебез — бишек җырларында.** Журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова турында бу мәкалә «Сөембикә» журналында (2005, 10 сан) басылган.

# ЭЧТӘЛЕК

## Ватан була бер генә!

Яңа меңьеллыкка күчкәндә ............ 8
Иман безне ташламасын ............ 24
Йә, нишлибез, газиз каләмем? ............ 29
Иле барның — теле бар ............ 44
Яңа елда яңарган уйлар ............ 49
Хәерле булсын бу көн! ............ 55
Яңача, хуҗа булып яшик! ............ 60
Битараф кала алмыйбыз ............ 64
Хәлиткеч көннәр ............ 67
Иҗатка хокук ............ 73
Оят бит! ............ 75
«Нәрсә мәгънәле дә, ни мәслихәт?» ............ 77
Ул җәйдән бер хатирә ............ 80
Язучылар өчен дә мәктәп булды ............ 88
Узды шаулап бөек бәйрәм ............ 91

## Каләм изгегә тартыр

Әдип исеме — олы исем ............ 96
Үр артында яңа үрләр ............ 106
Без әзерме? ............ 134
Шигъриятебез турында ............ 139
Съезддан соң... ............ 147
Тарихи мирас аша — киләчәккә ............ 155
Юлларда туган уйлар ............ 161
Сүз көче ............ 167
Рухи тормышыбыз көзгесе ............ 172
Журнал язмышы — безнең язмыш ............ 175
Хәлләребез, шиксез, яхшырыр! ............ 179
«Казан утлары» — безнең юл ............ 184
Рухи елъязмабыз ............ 191
Бу гасырда да балкыр! ............ 196
«Безнең заман герое» ............ 205
Сүз — болын, җыр — чәчәк ............ 210

«Мәйдан»га киң мәйдан ........ 215
Киләчәк өчен эшләргә тиешбез ........ 217
Гыйбрәтләр алырлык үткән юл ........ 222

**Кемнәр бар да, кемнәр юк...**

Горурлыгыбыз ........ 326
Сагындыра торган шәхес ........ 332
Бер рәсемгә карап... ........ 335
Әдип-композитор ........ 340
Ак рояль хуҗасы ........ 345
Шигъри җанлы галим ........ 352
Хәзинәләр хуҗасы ........ 359
Тел сагында тора солдат ........ 364
Аның яшәү рәвеше ........ 371
Әле без һаман да замандаш ........ 377
Нарасый хәким ........ 383
Сәфәр башы ........ 391
Ихтирам тудыра ........ 395
Мәңгелеккә калсын мизгелләр ........ 399
Киләчәгебез — бишек җырында ........ 401
Искәрмәләр һәм аңлатмалар ........ 407

Литературно-художественное издание

***Файзуллин*** *Равиль Абдрахманович*

Избранные произведения

В шести томах

Том 4

Казань. Татарское книжное издательство. 2005

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Фәйзуллин*** *Равил Габдрахманович*

Сайланма әсәрләр

Алты томда

4 том

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.З.Шиһапова, Г.Х.Сундукова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.12.2005. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 21,84 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 22,58. Нәшер-хисап табагы 21,96 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ А-884.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.